**Файзуллин Р.Г.**

Избранные произведения

В шести томах

Том 5

*Литературно-*
*публицистические статьи*
*Интервью*

Казань • Татарское книжное издательство • 2005

**Фәйзуллин Р.Г.**

# Сайланма әсәрләр

Алты томда

5 том

*Әдәби-*
*публицистик язмалар*
*Әңгәмәләр*

Казан • Татарстан китап нәшрияты • 2005

УДК 821.512.145
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ф91

**Редколлегия:**

*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин,
И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов,
Р.Х.Корбанов*

**Фәйзуллин Р.Г.**

Сайланма әсәрләр: 6 т./Равил Фәйзуллин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.

ISBN 5-298-04201-5

5 т.: Әдәби-публицистик язмалар, әңгәмәләр. — 2005. — 527 б.

ISBN 5-298-04206-6
ISBN 5-298-04206-6 (5 т.)
© Татарстан китап нәшрияты, 2005
ISBN 5-298-04201-5
© Фәйзуллин Р.Г., 2005

## *Элгәргеләр, бүгенгеләр*

### ҮЛЕМСЕЗЛЕК СИМВОЛЫ

*(Ул — мөнбәр тәрәзәбез)*

Без яшәгән гасырның башыннан ахырына кадәр (алга таба да бу хәл, һичшиксез, шулай дәвам итәчәк) халык Тукайны олылый, бөекли, инде әллә ничә буын, аңа иман китереп, күңелен түгә. Ни өчен? Хикмәт нәрсәдә?

Һәр милләт, һәр халык, кавеменең исәбе-санына, җиренең зурлыгы-киңлегенә, үткән юлының гомумтарихта ни дәрәҗәдә беркетелеп калуына карамастан, Кояш астында тулы хокуклы яшәвен расларга һәм киләчәктә дә Җир йөзендә лаеклы урыны барлыгына һәм булачагына дәгъва кыла. Шуны Тарих алдында, бүтән халык-илләр алдында раслар өчен, Аңа таяныр нокталар, инандыргыч дәлилләр, рухи генетик потенцияне күрсәтә алырлык шәхесләр, бөек затлар кирәк.

Заманында миңа байтак халыкларның бөек саналган шәхесләренә багышланган тантаналарда катнашырга туры килде. Русларның — Пушкин, казакъларның — Абай, латышларның — Райнис, украиннарның — Шевченко, әзәриләрнең — Физули, төрекләрнең — Юныс Әмрә, кыргызларның — Токтогул, чуашларның — Иванов бәйрәмнәре... Татар әдәбияты вәкиле булып бу юбилейларда чыгышлар да ясадым. Фейерверклы рәсми тантаналардан соң ялгыз калгач, күңелгә төрле уйлар да килгәли иде. Ни өчен бу шәхесләргә пәйгамбәр күреп табыналар да, аларны илаһ күкләренә күтәрәләр соң әле? Ярый, гомер кичеп зур иҗат калдырганнар. Ләкин бит алар моннан фәлән йөз ел элек булган биеклекләр. Ни өчен алар безнең өчен, киләчәк өчен гел өлге булырга тиеш соң әле? Һәркемнең үз йолдызы дигәндәй, иң әүвәл алар үз халыкларының газизләре, нигә аларга бөтен дөнья баш ияргә тиеш? Өстәвенә, адәм заты булып яшәү рәвеше буенча, бер генә каләм иясенең дә Тукай яки Шевченконың, Мәгарри яки Достоевскийның шәхси тормыш-хәяттә кичергәннәрен кабатларга теләгәнен ишеткәнебез юк... Әмма... гомер кичкән саен, яфраклары коелган урманда ерактагы агач силуэтлары да ачыграк күренгән сыман, яшьлектәге өермәле уйлар тынып-утырып калгач, фикерләр дә үзгәрә төште. Кирәк икән, бик кирәк икән үткән заманның кабатланмас Затлары! Чөнки алар — Бөек! Бусы — бер. Ә һәр Бөек шәхес ул — гомумкешелек хәзинәсе. Әгәр Бөек булсаң:

Нечкә җанлы, чын иманлы
булып тууың кирәк.
Шатлык-кайгыңны аңларлык
җирлек булуы кирәк.
Шагыйрь булсаң, Дөнья өчен
давың, януың кирәк.
Януыңны күп халыклар
күмәк тануы кирәк.

Икенчедән, югарыда әйтелгәнчә, милләтне милләт итеп раслар өчен кирәк аларны олылау. Үзеңне үз милләтең баласы итеп, Кеше итеп тояр өчен кирәк икән! Шулай булмаса, үзләрен зур милләт итеп дөньяга таныткан, тарихта тирән эз калдырган милләтләр, әйтик, алманнар, үзләренең Гете, Шиллер; инглизләр — Шекспир, Байрон, испаннар — Сервантес, итальяннар Дантеларын шулай планета масштабында күтәрмәсләр иде. Болары — Гареп цивилизациясеннән. Ә Шәрекъ дөньясыннан күпме бөек исемнәрне атап булыр иде!

Билгеле хакыйкать: күтәрердәйне генә, булганны гына күтәреп була. Максат куеп чөяр өчен мәгълүм масса-авырлык кирәк. Кош мамыгын ыргытып булмый. Аны җил кая тели, шулай өреп йөртәчәк. Рухи сабантуйда, яңа буыннар киләчәккә алып барыр өчен, Үлемсез Иҗат булу фарыз. Үлемсезлек турында уйланырга безнең өчен Тукай — иң кулай мисалларның берседер.

Үлемсезлек — бөек мәгънәгә ия сүз. Ул, мөгаен, Кешелек хыялының иң биек ноктасыдыр. Үлемсезлек юлын беркем дә тәгаен генә кистереп күрсәтә алмас. Юкса әкиятләрдә Әбелхәят суын эзләмәсләр, Фаустлар алданмас, Ләйлә-Мәҗнүннәр харап булмас, Гайсә пәйгамбәрләр кадакланмас, фидакарьләр утларга ташланмас иде... Шулай да без аңлаган асылында Үлемсезлек юлына баруның кайбер төп нигез принциплары бар ул: ул заманның чын мәгънәсендәге гадел һәм зирәк баласы була алудан, ягъни дәвереңнең төп проблемаларын чишү үзегендә булудан, үз халкыңның мәнфәгатьләрен кайгыртудан (Вакыт галиҗанаплары күзгесендә һәр халыкның үз хәлләре), киләчәкне анык күрә алудан гыйбарәт. Тукай — минемчә, бу принципларның һәммәсенә дә туры килгән шагыйрь.

Халык күңеленең тагын бер ягын онытмыйк: дөньялыктан пәйгамбәрләрчә яшьли янып китү — мәңгелеккә баруның тәгаен бер ышанычлы юлы. Безнең халык яшьли фаҗигале үлемгә дучар бул-

ган кызга яки егеткә тикмәгә генә җырбәетләр чыгармаган. Тукай бу яктан да Үлемсезлек кодексына бик туры килә.

Һәм, ниһаять, бер Бөек затны тану, аның олуглыгын бәяләү өчен, чорына лаек замандашлары булуы, илаһи рухны киләчәктә дә саклап, олылап бару өчен, оныклары кирәк — яңа буыннарның тууы кирәк. Сандугач тавышын аерыр өчен, бихисап кош сайравын тою-белү кирәк... Бу җәһәттән дә Тукай бәхетле шәхес. Чөнки аның иҗат чоры гаҗәеп дәвергә — халкыбызның гасыр башындагы олуг күтәрелеш — Ренессанс чорына туры килә. Халык бөеклегенең рухи маякларын төгәл ачыклау, барлау заманы ул. Аннан соңрак дәвер буыннары рухи биеклекне тану, бәяләү буенча тагын да зирәгрәк булдылар — Тукайны бөек итеп танып, аны киләчәккә илттеләр. Ни генә димик, бу очракта бөеклекнең төп сәбәпчесе, әлбәттә, Тукай үзе, гаҗәеп иҗаты, XX йөз башында Россия киңлекләрендә шагыйрьләрдән бердәнбер диярлек уникаль шәхес бит ул. Ятим үсеп, дәүләт уку йортлары күрмичә тәрбияләнеп, бик аз гомер яшәп, ятимлек һәм ялгызлык кичереп, биш-алты томлык мәңгелек әсәрләр язган иҗатчы дип ул чорда тагын кемне атап була соң?

Хәер, үз бәһасен Тукай үзе дә яхшы белгән. Бу җәһәттән кечкенә генә лирик чигенеш. 1974 елның июнендә Михайловскоеда Пушкин бәйрәме үткән көннәрдә куен дәфтәремә мондый юллар язылган:

**Михайловскоеда**

Йолдыз, Кояшларны күрми торып,
ничек белмәк кирәк бу Айны!
Мин, Пушкинның торган җирен күреп,
бөеклеген тойдым Тукайның.

Һәм, ниһаять, бу кереш сүзне язган чакта, янә бер мәртәбә Тукай томлыкларын актарганда, аның «Пушкин вә мин» дигән шигырендәге мондый сүзләргә юлыктым:

...Шунда да күрмим үземне һич тә Пушкиннан түбән;
Тугры күз салсаң эшенә — ул үзе миннән түбән!

Мин берәүне дә түбән йә югары санарга теләмим. Әмма — сүз әйтелгән!

Инде шагыйрьнең 100 еллыгына чыккан китап турында. Аңа йөзгә якын авторның Тукайга багышланган шигъри әсәрләре тупланган. Гомумән, Тукай хакында шигырь язмаган бер генә татар шагыйре бармы икән? Ул гына да түгел, башка халык шагыйрьләре, әдипләре дә аның турында үзләренең ихлас фикерләрен әйтеп калдырганнар, шигырьләр иҗат иткәннәр. Шуларны туплап, 1976 елда, төзүче буларак, «Тукайга чәчәкләр» дигән бер җыентык чыгаруда катнашкан идем. Менә 20 еллап гомер үткәч янә бер китап. 20 ел эчендә Тукайга багышлап язылган шигырьләр никадәр ишәйгән! Аларда инде яңа төсмерләр, киләчәккә төбәлгән яңа мотивлар. Элек язылган әсәрләрдә «сүнде йолдыз», «калдырды үксез милләтен», «һәммәбезгә син әрәм» кебек тәгъбирләр өстенлек итсә, соңгы чорларда «Тукай безнең белән», «син яшьтәш тә, замандаш та», «Тукай үлемсезлеген син озайтырга бурычлы», «мин Тукайга барам» кебек күтәренке рухлы юллар хас.

Әйе, безнең халык та кояш астында үзенә урын даулый. «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дигән сорау, шөкер, хәзер юк инде! Уянып торып баскач, нишләргә? Ничек хәрәкәт итәргә? Менә төп тойгы — хис-уй! Тернәкләнеп, үз хакыңны даулау чорында — Тукай иҗаты үзе бер таяныч! Үзаңы уянган халык вәкилләре, бу очракта шагыйрьләр, Тукайга багышланган шигырьләре аша үзләренең иң мөкатдәс, иң изге идеалларын ачыклыйлар шикелле. Ул — югалган Дәүләтчелегебезне кайтару. Ул — Дөньяның ирекле халыклары гаиләсендә булу. Бу хыял-максатка ирешү юлында Тукай үзе бер юл күрсәткеч, үзе бер тәрәзә. Без шул мөнбәр тәрәзә аша, күзләребез яшьле булса да, кояш ягына таба карыйбыз. Китапка кергән шигырьләр дә бу сүзләрне раслый дип уйлыйм.

*1995, декабрь*

## «...БУЛДЫМ ҺИЧ ТӘ ОНЫТЫЛМАС КЕШЕ»

Яздан аерып булмый Тукайны!
Язда килгән, язда ул янган...
Язы, киләчәге барлар ничек китсен,
Ничек югала алсын дөньядан?!

Бер уйласаң, Тукай әллә кай заманда яшәгән кебек. Яңа тарихны без революциядән соңгы еллар белән санап йөртергә ияләнгәнгәдер, бәлки. Тукай революциягә кадәр янып үткән йолдыз ич. Без еш кына халык тормышындагы этапларны революциягә кадәрге чор, революциядән соңгы чор, дип йөртәбез, әдәбияттагы хәрәкәтне Тукайга кадәргесе, Тукайдан соңгы чордагысы, дип тә әйтәбез. Тукай — иҗтимагый тормышның дәверләр чатындагы маяк шәхес. Ә тагын бер уйлап карасаң, Тукай — безнең замандаш, хәтта әле җисми яшәве белән дә безнең арада булырлык кеше ләбаса! Әле кай-

чан гына Корней Чуковскийның йөз еллык юбилее билгеләп үтелде. Ә бит ул күптән түгел генә безнең арада яшәгән язучы, безнең буыннарга да яхшы ук таныш кеше иде. Бик еракка барасы юк: Софья Радзиевская апабыз әле һаман да җир җимертеп дигәндәй актив иҗат итеп йөри. Ә бит алар — Тукайның чын мәгънәсендәге чордашлары. Безнең бәхеткә, әле арабызда исән-сау йөрүче Бакый ага Урманче, Нәкый ага Исәнбәтләрне дә билгеле бер дәрәҗәдә Тукайның замандашлары дип әйтә алабыз. Ә Тукайның вафатына быел инде нәкъ җитмеш ел...

Әйе, җитмеш ел инде. Бу еллар эчендә тормышта күп үзгәрешләр булды. Татар әдәбияты сан һәм сыйфат ягыннан яңа баскычларга күтәрелде. Әдипләребезнең кайберләре, әйтик, Җәлил кебекләре, ил тарихында алтын хәрефләр белән язарлык данлы сәхифәләр калдырдылар, бу вакыт эчендә әдәбиятта берничә мәртәбә буыннар алышынды. Халкыбызның дистәләгән талантлы уллары төрле жанрларда бүтән халык укучылары да сокланып укырлык әсәрләр иҗат иттеләр. Шулай да алар арасында үзенең табигый талантының көче, халык күңелендәген әйтә белүе, кыска гына вакыт — җидесигез ел эчендә биш-алты томлык әсәрләр иҗат итә алуы, фидакарьлеге ягыннан Тукайга җиткәне, мөгаен, әлегә юктыр. Дөнья әдәбияты тарихында Тукай кебек яшьли янып киткән даһиларны очратырга була. Әмма аларның бөтенесе диярлек йә халкы тарихы ягыннан, йә чыгышы — тәрбия алу ягыннан, йә саулыгы, шәхси тормыш шартлары ягыннан Тукайдан шактый ук аерылалар. Еш кына уйланасың да тагын бер кат таң калып куясың: кечкенәдән үк кимлек-хурлыклар күреп үскән япаятим, саусызлыктан интеккән күбәләк җан, мәхәббәт һәм гаилә җылысыннан мәхрүм егет, күңеле белән чиксез горур булып та, үзенең зәгыйфь тәнен җылытырлык та үз куышы булмаган шагыйрь ничек итеп бөтен бер халыкның рухи биеклеген билгеләүче затка әйләнә алды икән? Әлбәттә, уйлансаң, бу феноменаль күренешне аңларга да мөмкиндер. Элегрәк мәдәниятkә ия булып та, шактый гасырлар торгынлыкка хөкем ителгән халык рухының генетик бер бәреп чыгуыдыр ул, бәлки. Тукай, әлбәттә, сирәк туа торган табигый талант. Өстәвенә шул талантның формалашуына уңай тәэсир итәрлек объектив шартлар — 1905 елдагы революцион кузгалыш, матбагачылык үсеше, Ренессанс дип әйтерлек мәдәни күтәрелеш — Тукайны Тукай иткән. Шулай булуга да карамастан, Тукай барыбер дөнья әдәбияты тарихында уникаль күренеш!

Тагын берничә елдан, төгәлрәк әйткәндә, тагын өч елдан, Тукайның тууына 100 ел тула. Хәзерге планлы заманда бу дата инде килеп терәлгән дигән сүз. Ничек үтәр ул олы юбилей? Үзебезнең өйрәнелгән төбәк масштабындамы яки даһи талантына лаек гомумдөнья масштабында, ЮНЕСКО кебек халыкара оешмалар югарылыгындамы?

Бер караганда, Тукай бөеклеге өчен борчылырлык та түгел шикелле. Ул халык күңеленә мәңгелеккә кереп урнашкан. Һәрхәлдә, шуңа инанасы килә. Бүгенге яшәештә дә аның исеме белән бәйле мәдәни учаклар шактый. Карагыз: кайчандыр милли музыкантларыбыз турында хыялланган шагыйрь исемендәге филармония үзенең иң яхшы башкаручыларын бөтен ил, алай гына да түгел, дөнья аренасына чыгара; язучыларыбыз үзләренең иң яхшы әсәрләре хакында аның исемен йөрткән клубта җыелып сөйләшәләр, фикер алышалар; кешеләр җәйләрен Идел-Кама киңлекләрендә «Тукай» теплоходына утырып сәяхәт кылалар; әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге зур хезмәт күрсәткән әдипләр, рәссамнар, композиторлар, артистлар, архитекторлар, аның хөрмәтенә булдырылган Дәүләт премиясе лауреаты исемен йөртәләр... Шагыйрь исемендәге колхозлар, урамнар ничаклы! Кинотеатрлар, мәктәпләр... Аларны илнең төрле меридианнарында очратырга була.

Соңгы елларда Тукай исемен мәңгеләштерү юнәлешендә башкарылган иң зур эш, әлбәттә, шагыйрьнең Тукай-Кырлайдагы мемориаль-музее. Ниһаять, туган әдәбиятны сөючеләрне һәм кунакларны алып барып күрсәтерлек урын булдырылды. Язучы һәм галим И. Нуруллинның «Тукай» исемле китабының Мәскәүдә «Атаклы кешеләр тормышы» (ЖЗЛ) сериясендә чыгуы соңгы вакытта Тукайны ил масштабында күрсәтүдә шулай ук күркәм хезмәт буларак кабул ителде. Тукай турында, бер караганда, күп тә язылган кебек. Ләкин араларда тарихи ядкәр булып калырлыклары санаулы гына; Ә. Фәйзинең «Тукай» романы (мәрхүм әдип аның беренче кисәген генә язып калдырырга өлгерде), С. Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә» поэмасы... Соңгы елларда И. Юзеевның «Очты дөнья читлегеннән» исемле шигъри трагедиясе, Р. Ишморатның «И мөкатдәс моңлы сазым» әсәре язылды, Чиләбе шәһәрендә яшәүче язучыбыз Рөстәм Вәлиевнең Тукайга багышланган романы әле яңа гына «Урал» журналында басылып чыкты (соңгылары турында чын бәя соңрак — еллар үтә төшкәч ачыкланыр). Музыка өлкәсендә соңгы ун елда бу юнәлештә иҗат ителгән әсәрләр арасында иң уңышлысы — А.Монасыйповның «Тукай аһәңнәре» дип исемләнгән вокаль циклыдыр. Ул моңа кадәр Тукай мотивлары буенча иҗат ителгән симфоник һәм балет әсәрләренең яхшылары янына өстәлерлек цикл булды. Бу уңайдан шуны да искәртеп үтәсе килә: «Тукай турында опера язабыз» дип, җәмәгатьчелек алдында вәгъдә биргән, хәтта үзара конкурентлык дәгъвасы да белдереп алган хөрмәтле композиторларыбызның иҗат нәтиҗәсе әлегә күренми. Бу мәсьәләнең күтәрелгәненә инде егерме еллап вакыт узды. (Искә төшерү комачау итмәс: Алма-атада яшәүче композитор Хәмидиләр Абай турында күптән опера язып, җырчы Абдуллиннар төп партияләрне башкарып, күптән пенсиягә чыктылар инде!) Рәссамнарыбыз да Тукай темасын игътибар үзәгендә тотып киләләр. Б. Урман-

че, Б. Әлминев кебек рәссамнарның исемнәрен Тукай иҗатыннан аерып карау кыен. Аларга өстәп Ленинградта яшәүче Ф. Әминевнең шагыйрь иҗатына багышланган әсәрләр сериясе, А. Абзгильдинның Тукайга багышланган полотнолары, Т. Хаҗиәхмәтов, И. Әхмәдиевләрнең график рәсемнәре... Түбән Камада яшәүче рәссам Ә. Фәтхетдинов өчен Тукай Шүрәлесе төп иҗат героена әверелеп бара. Ихтимал, без белеп бетермәгән бүтән хезмәтләр дә бардыр. Кыскасы, Тукай иҗат кешеләренең игътибарын көннән-көн күбрәк җәлеп итә бара.

Әлбәттә, Тукайның бөеклеген пропагандалауда иң төп корал — аның үз әсәрләре. Соңгы елларда шагыйрьнең Татарстан китап нәшриятында академик басмага якын итеп эшләнгән дүрт томлыгы чыкты, рус телендә бер томлыгы дөнья күрде, шулай ук балалар өчен язылган әсәрләре кат-кат басылды, сувенир басмасы нәшер ителде. Кардәш халыклар телләрендә дә Тукайның берничә китабы басылды. Болары бик яхшы. Шулай да, безнеңчә, үзәк нәшриятларда шагыйрьнең әсәрләре бик артык күренмәде. Кулга тотарлык соңгы басма — ике китап — 1974 елда «Советская Россия» нәшриятында чыккан кечерәк күләмдәге сайланма әсәрләре (редакторы Е. Имбовиц). Рус телендәге китаплар, дигәч, иң әүвәл Тукай әсәрләрен русчага тәрҗемә итү мәсьәләсе килеп баса. Бу — безнең авырткан урыныбыз. Дөресен әйтергә кирәк, Тукайның күп кенә әсәрләре шагыйрьнең үз таланты дәрәҗәсендә тәрҗемә ителмәгәннәр. Күбесе һәм мәгънәне бирү, һәм аһәңне саклау ягыннан оригиналдан шактый ук кайтышлар. Шул ук тәрҗемәләр бер басмадан механик рәвештә икенчесенә күчә торалар. Яңа тәрҗемәләр булдыру ягыннан Язучылар берлеге кайбер оештыру эшләрендә беркадәр активлык күрсәтсә дә, нәтиҗәләр канәгатьләнерлек булмады. Шагыйрь иҗаты үрнәкләре алга таба да шул ук иске тәрҗемәләрдә чыкса, Тукайның бөеклеген бүтән халык укучылары алдында исбат итү җиңел булмаячак. Тукайны чит телләрдә чыгару буенча бөтенләй диярлек эш алып барылмады. Бу җәһәттән Мәскәүдәге «Радуга» (элеккеге «Прогресс») мөмкинлекләреннән нәтиҗәлерәк файдаланырга булыр иде. Мәсәлән, үткән ел әлеге нәшриятта ике телдә — русча һәм инглизчә чыгарылган М. Җәлил китабы татар әдәбиятын пропагандалауда зур роль уйнады. Бу эшләрне киңрәк масштабта кузгатып җибәрер өчен, шагыйрьнең, әйтик, инглиз, немец, француз, испан һ.б. телләрдә подстрочникларын — сүзгә-сүз тәрҗемәләрен эшләтергә вакыт җитте. Шулай булганда, Тукайны чит телләрдә бастыру эше җиңеләер иде. Уйлап карасаң, бу — башкарып чыгарлык эш. Республикабыз вузларында никадәр чит тел кафедралары бар. Аларда туган телне, рус һәм чит ил телләрен камил белүче белгечләр ничаклы! Шуларны да халкыбыз горурлыгы булган Тукайның иҗат мирасын тагын да пропагандалау эшенә мөмкин булганча тартырга иде.

Тукайчылар, Тукай иҗатын өйрәнүчеләр турында да берничә сүз. Үзеннән-үзе аңлашылганча, шагыйрь иҗатын пропагандалауда алар төп көч булырга тиешләр. Әгәр Тукай үлеменнән соңгы җитмеш ел эчендә аның турында язылган бөтен кәгазьләрне, басма һәм кулъязма хәлендәге кәгазьләрне бергә җыйсаң, үзе үк шактый биек тау хасил булыр иде. Кемнәр генә кайчан, күпме, ничек язмаган аның хакында! Кемнәр генә аның иҗатына таянып галим булмаган да, кемнәр генә фәнни дәрәҗәләр алмаган! Үзләренең гыйльми эзләнүләре белән теге яки бу дәрәҗәдә Тукайга бәйле булып, тормышларын бөек зат иҗатын өйрәнүгә багышлаган кешеләрне барлый башласаң, алар йөзәрләп җыйналыр иде. Шулай да Тукай иҗатын бөтен ил мәйданында горур рәвештә пропагандалый алырлык хезмәтләр күп түгел. Кайбер хезмәтләр, үзләренең фәнни көче, колачы бәләкәйрәк булу сәбәпле, үз төбәгебездән биеккәрәк күтәрелә алмый. Үзәк нәшриятларда теге яки бу җитди басмалар чыгып, кереш сүз яки мәкалә кирәк була калса, башлыча шагыйрьләр үзләре язарга мәҗбүр. Әгәр дә һәр тукайчы галим үзәк яки чит илләр матбугатында берничәшәр мәкалә яисә чыгыш белән генә катнашса да, Тукай күптән үзгә яңгыраш алыр иде. Сүз уңаеннан шуны да искәртеп узу кирәк: күпмилләтле әдәбиятларга багышланган фундаменталь китапларда, дәреслекләрдә Тукай исеме сирәгрәк күренә башлады. Бәлки, бүтән халыклар үзләренең классик әдипләрен активрак пропагандалау нисбәтендә бу хәл шулайрак күренәдер. Һәрхәлдә, галимнәр, тикшеренүчеләр өчен уйланыр нәрсәләр бар.

Тукай юбилее — шагыйрь юбилее гына түгел, татар халкының рух биеклеген билгеләүче бәйрәм һәм сынау да. Гомергә бер килә торган хәл. Безнең бөтенебезнең дә өлешенә тигән җаваплы миссия. Аның ничек үтүе халыкның акылына, күңел байлыгына, үткәненә һәм киләчәгенә аек карый алуына бәйле.

Юбилей, әлбәттә, яхшы үтәр. Шулай булырга тиеш. Моңа ышаныч зур. Республика җитәкчеләре, партия һәм совет оешмалары бу юнәлештә комплекслы зур оештыру эшләре башлап җибәрделәр дә инде. Әмма билгеләнгән зур чараларны тормышка ашырыр өчен вакыт дигәннәре күп түгел. Әйтик, Тукай турында тулы метражлы нәфис фильм булсын дисәк, бу эшкә бүген үк тотынырга кирәк, әгәр шагыйрьнең русча күп томлыгын чыгарыйк дисәк, аны инде әзерләп тапшырырга вакыт, әгәр кардәш халыклар чыгарган Пушкин, Шевченко сүзлекләре кебек, Тукай сүзлеген булдырыйк дисәк, аны бер генә көнгә дә кичектерү ярамый. Болардан тыш булмаганны булдырасы, булганны тәртиплисе эшләр дә җитәрлек. Тукайның музей-квартирасын оештыру, урамнарда эленгән истәлек такталарын яңарту, шагыйрьнең һәм якыннарының каберләрен матурлау (сүз уңаенда шуны да әйтеп

узыйк: Тукай кабере тирәсе болай да кысан. Соңгы дәвердә шул тар җирдә яңа җирләүләр булды. Ә кирәкмәс иде...), алдынгы студентлар өчен Тукай исемендәге стипендия булдыру... Кыскасы, эшлисе эшләр җитәрлек.

Йөз еллык юбилей алдыннан шигырь бәйрәмен дә дәрәҗәлерәк, колачлырак итеп уздырасы, яңа формалар белән баетасы иде. Тукайның туган көнендә уздырыла торган әлеге бәйрәмгә тугандаш халык вәкилләрен күбрәк чакырырга кирәктер. Бәйрәмнең дәрәҗәсе килгән кунаклар белән дә бәяләнә ич.

Әгәр ниндидер могҗиза белән Тукай терелеп безнең бүгенге көнгә кайта алса, тормышыбыздагы күп хәлләргә таң калыр иде. Үзен зурлаган халкына баш иеп рәхмәт әйтер иде. Ихтимал, кайбер нәрсәләрдә бездән усал көлеп тә алыр иде. Мөгаен, үзен мактап сүз әйтүчеләргә караганда, үзенең эшен дәвам итүчеләрне күбрәк үз итәр иде. Без, каләм ияләре, Тукай идеалларына тугрылыклы булыйк дисәк, халкыбыз сөенерлек талантлы әсәрләр күбрәк иҗат итәргә тиешбез. Бу — безнең тарафтан Тукайга үзе бер һәйкәл булыр!

*1983, апрель*

## Ә ГОРУРЛЫК ХИСЕ ҺАМАН ШУЛ...

Төрле елда — төрле янулар.
Ә горурлык хисе — һаман шул!

Быел зурлап билгеләп үтелә торган әдәби юбилейлар байтак. Әле яңа гына Ф. Әмирханның 110 еллыгы булып узды, бу айда җәмәгатьчелек М. Җәлилнең 90 еллыгын яд итә, апрельдә Г. Тукайның 110 еллыгы. Шуңа өстәп исән-имин әдипләребезнең төрле дистә еллар уңае белән үткәреләчәк иҗат бәйрәмнәре...

Сөенергә генә кирәк! Билгеләп үтәрлек, кешеләргә күрсәтерлек, әсәрләре белән мактанырлык шәхесләребез, әдипләребез булмаса нишләр идек?.. Уйлап баксаң, һәр юбилей тантанасы — горурлык тойгысы кузгатучы Хәтер тукталышы бит ул.

Әхлак, этика, эстетик идеал кебек төшенчәләр, асылда тотрыклы булып, тиз генә үзгәрмәсәләр дә, барыбер һәр заманның шул ук категорияләргә — үз бизмәне, үз мөнәсәбәте, үз сурәте. Элгәрге Олыларны хөрмәтләү мәсьәләсенә дә кагыла бу.

50 нче елларны хәтергә төшерик. Ул вакытта да юбилейлар, төрле тантаналар, искә алу кичәләре уздырыла иде. Шул исәптән әдәби тантаналар да. Кемнәрнеке? Әлбәттә, Тукайныкы. К. Насыйри, Г. Камал, Ш. Камал, Һ. Такташ кебек шәхесләргә игътибар зур иде. Фронтта һәлак булган Ф. Кәрим, Г. Кутуй иҗатлары да киң пропагандаланды. Шул елларда бу рәткә Сталин премиясе алган язучылар — Г. Бәширов, К. Нәҗми килеп кушылды. Ул вакытта Г. Ибраһимовлар, К. Тинчуриннар юк, Х. Туфаннар юк. Бәйрәмнәре генә түгел, исемнәре дә «онытылган» иде.

Менә берчак, тоталитар режим тетрәнеп китеп, җәмгыятьтә демократик шытымнар күренә башлаган 1956 елларда, татарларның әле мондый шәхесе дә бар! дигәндәй, Муса Җәлил пәйда булды. Җәлилнең кайтуы татар әдәбияты өчен илаһтан иңгән вәхи кебек кабул ителде. Әдәбиятыбызны дөньяга танытуда зур ыргым ясалды. Җәлил исеме белән халкыбызның иҗтимагый рейтингы күтәрелде. Фани дөньяда кырык ел да яшәмәгән Җәлил инде менә кырык ел (каһарман шагыйрьгә әверелгән чорыннан бирле. Хәер, аның сугышка кадәр язган иҗаты да — данлы сәхифә) буе, әдәбиятыбызның байракчысы булып, сафыбызның алдында бара.

Дөрес, соңгы дистә ел эчендә безнең тарихи рухи хәзинәбез бермә-бер баеды. Инкыйлаб еллары вакытында аударылган «алтын баганалар» яңадан торгызыла. Халыкка бөек Гаяз Исхакый иҗаты кайтты. Бүгенге татар аңына Р. Фәхретдин, С. Максуди, Г. Баттал кебек акыл ияләренең фикер-идеяләре сеңә башлады. Бәрәкалла, машалла!

Йолдызлар бер-берсен капламыйлар. Аларның күләгәләре юк. Рухи күгебездә Җәлил дигән йолдызның күзәнәкләргә үтә торган үз нуры, үз яктысы бар. Җәлил безгә шәхес буларак та, шагыйрь буларак та, каһарман буларак та бик кирәк, һәр заман өчен. Безнең өчен.

*1995, гыйнвар*

*P.S.* Шушы төштә нокта куйгач, элегрәк елларда Җәлил турында уйланып, кыска-кыска гына тезмә һәм чәчмә формадагы публицистик язмаларым искә төште. Аларны да укучыларыма тәкъдим итәргә булдым.

* * *

Үлемнәре белән Үлемсезлек
Яулап ала безнең шагыйрьләр.
Кемдер сорар: кая дәлилең?

Мин эндәшмим.
Каберләре әйтсен
Тукай,
Кәрим,
Кутуй,
Җәлилнең...
Үлеп күрсәттеләр безнекеләр!
Гомерләре булды, һай, кыска!
Ә бит үлеп үлемсезлек яулау —
Бердәнбер юл түгел тормышта.

*1968, гыйнвар*

* * *

Горурлык. Яшәүнең мәгънәсен, шәхеснең кешелек дәрәҗәсен билгели торган төшенчәләрнең берсе бу. Горурлык сүзенең фәлсәфи асылын аңлаган зат Җирдә күкрәк киереп нык басып тора. Башын югары йөртә; Кояш һәм Күк астында үзен тулы вәкаләтле хуҗа итеп тоя; дөньяга, яшәешкә үз сүзен әйтә; инанган идеаллары өчен көрәшә, сугыша... Җенес яки аерым шәхес горурлыгы, гаиләыру горурлыгы, профессия яки һөнәр-кәсеп горурлыгы, ил-халык горурлыгы, дөнья горурлыгы...

Күпләр кебек, бүген мин дә горурмын. Чөнки горурланыр өчен ныклы нигез, хаклы сәбәпләр бар. Горурландырырлык шундый исемнәрнең берсе — Муса Җәлил. Сокланулы хисләр кичереп һәм таң калып, инде ничә дистә еллар күп илләр, күп халыклар искә ала аны.

Зур залларда тантаналы кичәләр үтә.

Илнең төрле почмакларында туганнарының истәлекләре, көрәштәшләренең тетрәткеч сүзләре яңгырый.

Типография конвейерларыннан шагыйрьнең яңа басмалары агыла.

Укучы балалар, ил чигендә торучы солдатлар, диңгез-океан киңлекләрендә йөзүче матрослар, акыллы машиналар төзүче эшчеләр, кыр хуҗалары-игенчеләр, студент-яшьләр мәктәп классларында, кызыл почмакларда, тулай торакларда аның шигырьләрен йотлыгып укыйлар.

Дистәләгән тәрҗемәчеләр аның шигырьләрен төрле телләрдә яңгырата.

Мәгърур көйләр чыгарып, оркестрлар уйный. Аңа атап язган җырлар, симфонияләр, опералар күңелләрне айкый, үз җырлары бәгырьләрне телә, уйландыра, көрәшкә әйди.

Экраннарда аның образы.
Мәйданнарда сурәтләре.
Һәйкәле янында кешеләр агымы. Тере чәчәкләр...

...Әйе, бу бер үзгә бәйрәм, зур тантана. Бу — без шаһит булган бүгенге көн. Ә аңа хәтлесе, бүгенге тантананың ерак яралгысы, моннан утыз елдан артык элеккесе — газаплы көрәш, үлем белән якалашу, рухи ныклык, корыч ихтыяр. Туган илгә тугрылык, җиңүгә ышану. Палач балтасы астында үткән еллар, айлар... Бүгенге тантана тавышлары концлагерьлардагы әсирләрнең теш кысып ыңгырашу авазларына, бүгенге затлы кәгазьләргә матур хәрефләр белән басылган юллар фашист өнендә аннан-моннан тапкан кәгазь кисәкләренә карандаш белән тырналган сүзләргә барып тоташа. Кимлек-хурлыкларда, салкын таш капчыкларда, гильотина балтасы асларында сынмаган рух, бүген бөтен халык рухына әйләнеп, бөтен зурлыгында, бөтен иркенлегендә тантана итә.

Үзенең иң яхшы сыйфатларын хәлиткеч сынауларда егетләрчә күрсәтә алган улларына халыкның рәхмәте чиксез. Халык андый шәхесләрнең исемнәрен мәңгегә йөрәгендә саклый. Күңеленнән ташып чыкканын Җирдә — Кояш астында материальләштерә. Табигатьтән ул шәхес-зат төсләр ала, кәгазьләргә, киндерләргә аның сурәтен төшерә, аның исемен ташларга уя; җилләрдән, камышлардан, диңгезләрдән тавыш-авазлар алып, музыка аша, җырлар аша аны данлый; ком-ташларны өеп, биналар, урамнар, проспектлар, калалар төзи дә аларга аның исемен бирә; таулар күкрәгеннән гранит-мәрмәр ташларын алып шомарта да аның сынын мәйданнарга бастырып куя; килер буыннарга батырлык васыяте итеп аның сүзләрен китаплар рәвешендә дөньяга тарата... Муса Җәлил — халыкның әнә шундый зурлавына лаек булган кеше.

Ә аның батырлык чыганагы кайдан килә соң? Әлбәттә, халыктан. Ул халык улы, хезмәт һәм икмәк тәмен яхшы белгән катлаудан — түбәннән күтәрелгән талант, халыкның рухи ихтыяҗын яхшы тойган әдип, ул үз талантын һәрчак ил ихтыяҗы белән бергә бәйләп алып бара алган шәхес. Ул — һәрвакыт тормышның, көрәшнең алгы сызыгында. Ул — яшьләр хәрәкәте үзәгендә, ул — культура революциясе елларында интеллигенциянең алгы сафында, ул — язучылар оешмасының башында, ул — антифашистик хәрәкәтнең иң хәвефле урыннарында... Менә корыч ничек чыныккан!

Мин горурмын. Шагыйрь сүзләре белән әйтсәк: «Бер горурлык хисе яна миндә». Муса Җәлил — шагыйрь. Зур илнең төрле почмакларында, ерак-ерак авыл-калаларында йөргәндә, чит мәмләкәтләр-

гә сәяхәт вакытларында башка милләт вәкилләре белән очрашканда, үзеңнең кем, кайдан икәнлегең белдерергә кирәк булганда, башта ук әйтелгән сүзләрнең берсе итеп Җәлил исемен телгә аласың. Бу исемне әйткәч, күп нәрсә ачыклана төшә. Бу исем читләрдә йөргәндә, татар халкын белгертә торган үзенә күрә бер пароль, паспорт шикелле яңгырый. Шагыйрь исеме аркылы халыкны таныйлар, исәпләшәләр, бәялиләр. Безгә, татар әдәбиятының бүгенгесен дәвам итүчеләргә, ифрат зур бер дәрәҗә һәм гыйбрәт бу. Шул ук вакытта уйга калдырырлык җаваплылык та. Менә чын язучының иҗтимагый тормышта тотарга тиеш урыны! Муса Җәлил — аның бер өлгесе. Заманның алгы сафында бул, фидакарь хезмәт ит, ян, олы идеаллар өчен көрәш, кирәксә, башыңны куй...

Ил Муса Җәлил юбилеен билгеләп үтә. Телләрдә — батыр шагыйрьнең исеме. Шулай да бу хосусый тантана гына түгел. Без Муса Җәлил белән бергә аның көрәштәшләрен дә, ил азатлыгы өчен гомерләрен биргән миллионлаган патриотларның исемнәрен дә искә төшерәбез, сугыш кырларыннан кайтмый калган бабаларыбызны, әтиләребезне, якыннарыбызны да яд итәбез. Батырлык япа-ялгыз була алмый. Горурлык та шулай ук. Без бүген күмәк горурланабыз. Чөнки бу уртак горурлык, миллионлаган кешеләрнең гомум горурлыгы. Иң куанычлысы: горурланырлык кешеләр тудыручы халык бар, ул — мәңгелек, аның рух чишмәсе бетмәс-төкәнмәс.

*1976, февраль*

* * *

Хәтердә: моннан берничә ел элек Җәлил көрәштәшләренең берсе белән Кремль калкулыгыннан — хәзерге 1 Май мәйданыннан — Казансу елгасына, Елан тавы ягына, Идел киңлекләре тарафына, сүзсез генә бик озак карап торган идек. Вакыт — кичке чак, шәфәкъ чагы. Тын, моңсу вакыт. Кабаланмаган кеше өчен уйландыра торган вакыт. Офыкта кызгылт төсләр мәхшәре, һәм шул алсу кызыллык Казансу суында үзгә бер киң коридор ясап сузылган да ак Кремль диварларына кадәр күтәрелгән. Бөтен тирә-юньдә әлеге шул алсу кызыллык чагылышы — Җәлилнең бронза сынында да, агач ябалдашларында да, ак манарадагы сәгать телләрендә дә, сөзәк дамбаның шомарып беткән ташларында да. Скверлардагы кызыл гөлләр, үзләренең кызыллыкларына яңа кызыллык өстәлгәч, бөтенләй яңа бер кайнарлык белән дөрлиләр шикелле, һәммә җирдә кызыллык. Без басып торган һәм шул мәгърур һәйкәлне күтәреп торган туфрак-җир үзе дә кызыл төстәдер кебек... Хәер, символик мәгънәдә болай фараз итүдә дөреслек тә бар. Күп яуны сынаган, күп кан сеңдергән туфрак бит ул. Тарих түрләрендә дә, безнең гасырның шанлы революция елларында да. Ветеран агайның йөзенә күз сирпеп алам. Минем уемда — менә шушы кызыл төсләр һәм шул төсләр аша ассоциатив чагыштырулар, параллельләр... Соңрак мондый тезмә юллар да язылды:

Казан Кремле янында
сүзсез басып тордык
бер җәлилче ветеран белән.
Кан өстендә — Җәлил һәйкәле.
Казансуда,
Иван явы килгән якта —
кызыл офыкта —
канлы Кояш.

Ә менә гомерендә күпне күргән, күпне кичергән бу агай ниләр уйлый икән? Теләгемне күңеле белән сиздеме, әллә үз уеның табигый агышы шулай идеме, ветеран агай, борылмыйча, үз турына караган килеш, салмак һәм нык тавыш белән әйтеп куйды: «Муса турында менә шулай биектән торып уйларга кирәк шул!..»

Чыннан да, Җәлил язмышы һәм иҗаты, аның кылган гамәле һәм батырлыгы хәзер Дөньяның иң биек мөнбәрләреннән торып, кешелек акылы ирешкән иң югары фәлсәфи категорияләр белән анализланырга, бәһаләнергә тиеш. Еллар үтә. Төрле рухи һәм җисми үзгәрешләр кичерә-кичерә кешелекнең янә бер гасырын очлау ягына барабыз. Шунысы ачык: еллар үткән саен, халыклар күз алдында Җәлил күтәрелә генә бара... Исем түгел, эш күтәрә аны, Матурлык һәм Батырлык елъязмасына керткән өлеше күтәрә... Әйе, еллар үтә. Җәлилнең һәм көрәштәшләренең үтерелүләренә дә инде байтак гомер үтте. Аның үзен күргән, аралашкан, якын белгән кешеләр дә көннән-көн азрак калып бара. Хәзерге яңа буыннар — яшьләр өчен, гәрчә алар шагыйрьнең тормыш юлын китаплар һәм башка чыганаклар аша шактый ук яхшы белсәләр дә, Җәлил, беренче чиратта, рухи яктан — тарихи каһарманлык эшләгән кеше буларак якын һәм кадерле. Еллар үтү белән шәхеснең бәндәлеге онытыла, рухы кала, игелеге, кешелеклеге кала, батырлыгы, фидакарьлеге, тугрылыклыгы кешеләр хәтерендә яңа яхшы төсмерләрдә яңара. Җәлилнең тормышы һәм үлеме хәзер инде яшәеш факты булып кына түгел, ә тарихи вакыйга булып танылды.

Муса Җәлил бөеклек баскычына шагыйрь фидакарьлеге һәм солдат батырлыгы күрсәтеп күтәрелде. Шагыйрь батырлыгы. Солдат батырлыгы. Үлемсезлек өчен, ихтимал, берсе генә дә җитә ке-

бек. Ике төр батырлык. Ә Җәлил мисалында бу батырлыклар — органик бербөтен, алар гүя аның асылын ача торган ихтыяҗи чаралар. Җәлил, гомумән, күпкырлы, күпьяклы шәхес. Ә кирәк чакта, хәлиткеч сынау вакытында, ул үзенең иң асыл ягы белән ачыла: бөтен көчен һәм рухын бер максатка — Илгә һәм Поэзиягә тугрылыклы булып калуга юнәлтә. Кайчак, сирәк кенә булса да, Җәлил турында мондыйрак фикер дә ишетелгәләп куя: ул — герой да, шагыйрь дә, геройлыгы зурмы, шагыйрьлегеме? Янәсе, геройлык күрсәтмәсә, иҗаты белән Җәлил бөек шагыйрьләр рәтендә йөрер идеме? Мондый сорау һәм бербөтен күренешне аерым бүлеп карау, әлбәттә, шагыйрьнең иҗтимагый тормышын һәм мирасын тиешенчә белмәгән очракта гына туарга мөмкин. Муса Җәлилгә табигать күпне биргән. Шуңа өстәп Җәлил үзе дә табигать бүләкләренең ни бәһа икәнен яхшы аңлаган, саулыкның, вакытның, хезмәтнең кадерен һәм ләззәтен бик яхшы белгән. Сез аның күптән түгел генә чыккан дүрт томлык китапларын ешрак ачып укып карагыз! Дөньялыкта шактый аз яшәп киткән шагыйрьнең безгә калдырган рухи һәйкәле бит алар! Шигырен укыйсыңмы, мәкаләсен яки публицистик чыгышынмы, Җәлилнең кабатланмас шәхесе күз алдына килеп баса. Ул — тынгысыз, ул — эш кешесе, ул — һәрвакыт динамик хәрәкәттә, ул — оптимист, ул үз эшенә нык инанган... Ул томнарда Муса Җәлилнең татар әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендәге титаник хезмәте һәм, гомумән, культурабыз тарихындагы урыны бик ачык күренә.

Күп эшләгән шагыйрь!
Нык янган!
Ташка басып чыгарганы —
Йөзләп табак...
Дүрт томлыгы тора киштәмдә,
күзне иркәләп,
җанга рух биреп.
Ә калган томнары —
төрмә, вәхшәт йотканнары —
күңелемдә йөри әрнешеп...

Муса Җәлилнең әдип буларак зурлыгы, олылыгы бәхәссез нәрсә. Очраклы хәлме: илнең иң зур бүләге булган Ленин премиясен шагыйрьләр арасында беренче булып Җәлил шигырьләре алды бит! Бу аның поэтик батырлыгын ил һәм дөнья күләмендә тану һәм билгеләү булды.

Әйе, Муса Җәлил батырлыгының мәгънәсе вакытлар үтү белән һаман зурая бара. Аның батырлыгы — үткән өчен генә түгел, хәзер дә, киләчәк өчен дә бик кирәк батырлык, ихтыяҗи батырлык булып чыкты. Җәлилчеләр көрәше — Кешелекнең фашизм кебек афәтне җиңә алу мөмкинлегенең бер дәлиле, җиңә алу тантанасының бер чагылышы иде. Әмма тынычланырга әле иртә. Фашизмның да, шовинизмның да беткәне юк. Киләчәк өчен төрле социаль системалар, кыйтга-континентлар, илдәүләтләр арасында аяусыз көрәш бара. Тупас көчнең канаты һаман җәюле. Геноцид хәлләре, яман чир кебек, аз санлы халыкларның җанын кимерә бирә... Көрәш кискенлегенең, рухи киеренкелекнең кимегәне юк. Димәк, көрәшчеләр кирәклеге, Җәлил кебек гуман сәнгатен һәм гомерен салып көрәшә алырлык шәхесләрнең күбрәк кирәклеге торган саен ныграк сизелә. Кешелекне кешелеклегенә чакыру, аның вөҗданын уяту, Җир йөзендәге җаннарның мөмкин кадәр күбрәген бөек идеалларга хезмәт иттерү... Тере материянең йөрәген саклау, җанын пакьләү... Менә хәзер безнең Яшәеш килеп терәлгән глобаль проблемалар. Мондый проблемаларны Кешелек файдасына чишәр өчен, Җәлил кебек интернациональ күңелле, көчле рухлы чын көрәшчеләр кирәк. Миңа калса, менә шуның өчен дә төрле милләтнең акыл ияләре — дәүләт эшлеклеләре, философлары, шагыйрьләре — Җәлил турында үзгә бер патетик тойгы йөртәләр. Үзебездә бер хәл, инде шушы соңгы дистә еллар эчендә тугандаш халыклар телендә Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында күпме җыр, шигырьләр, пьеса, поэмалар, повестьлар туды, күпме сынлы сәнгать һәм сәхнә әсәрләре иҗат ителде. Хикмәт — Җәлилчеләрнең батырлыгына дан җырлау гына түгел, төп максат — киләчәк буыннарда Җәлил кебек ватанчыл, илсөяр тойгылар тәрбияләү, аларны чын кешеләр итеп үстерү.

Җәлил — татар халкының бер газиз улы. Әгәр ул бөтен дөнья таң калырлык батырлык үрнәге икән, димәк (батырлык та, чын сәнгать тә буш урында, нигезе булмаган җирдә туа алмый), аны тәрбияләп үстергән халык үзе дә — олы халык, чын сәнгать тудырырга һәм үлемсез батырлык күрсәтергә сәләтле халык, рухи потенциаль мөмкинлекләре зур халык.

Безнең өчен, бүгенге татар әдәбиятын үстерү эшенә күңелләребез белән алынган кешеләр — язучылар өчен, Җәлил шагыйрь һәм әдип буларак аеруча кадерле. Җәлил — зур тарихи поэтик мирасны нык үзләштергән, поэтикабызны яңа шартларда үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән шәхес. Әгәр аның шагыйрьлек һәм гражданлык батырлыгы турында олы сүзләр сөйләп, аның традицияләре турында бик еш яза килеп тә, бүген аның юлын, иҗтимагый идеалларын конкрет эшебездә, конкрет хезмәтләребездә дәвам иттермәсәк, без берьяклы һәм рухи яктан фәкыйрь кешеләр булыр идек. Шөкер, бүгенге татар поэзиясе туктаусыз үсештә. Тукай, Җәлилләр эстафетасын яңа буыннар ышанычлы адымнар белән яңа сыйфатларда дәвам иттерә. Без бүген, иманнарыбызга хилафлык китермичә,

хәзерге заман поэзиясенә үзләреннән лаеклы өлеш кертә алырлык байтак исемнәр саный алабыз. Димәк, Җәлил шагыйрь буларак та һаман безнең белән, ул — күңелләрдә, йөрәкләрдә, рухы һаман исән, сау-сәламәт!

*1980, октябрь*

## ШАГЫЙРЬ, ПОП ҺӘМ ЯКТАШ

Ул — күптән яшәп дөнья кичкән зат. Тууы — моннан 150 ел элек, вафатына да 100 елдан артык. «Кайсы дәвер соң ул һәм кемнәр заманы?» диярләр. XIX гасырның икенче яртысы. Россиядә Александр II патша вакыт. Реформалар (крепостное право бетерелү) чоры. Рус булмаган халыкларны көчләп чукындыруның, миссионерлык басымының котырган дәвере. Мөселман-татар дөньясында вәисевчеләр хәрәкәте, Мәрҗаниләр мәгърифәтчелеге, басма китап тәэсире көчәйгән чорлар... Менә шул заманда яшәгән җырчы Җәкәү (Җәкәү-җырау) — Яков Емельянов дигәннәре. Шул заман тирәлеген күзалласаң, ул — Кандалый, Чокрый, Акмулла, Мәрҗани, Насыйрилар замандашы. Җирдә шаккатарлык байлык-мөлкәт, том-том әсәрләр калдырмыйча, 1893 елны 45 яшендә дөнья куйган якташны әдәби җәмәгатьчелек һаман онытмый. Элек заманда да, совет чорында да, хәзер дә аның исемен даими телгә алалар. Тормыш юлы һәм иҗатына багышланган язма-мәкаләләр дә җитәрлек: А. Григорьев, Х. Госман, М. Гайнуллин, М. Глухов, Р. Әхмәт һәм башкаларның хезмәтләрен күздә тотып әйтәм.

Ни-нәрсә өчен бу олылау? Н. Ильминский, В. Тимофеевлар шәкерте, миссионерлык тарафдары бит юкса! Замандашлары да әхлакый яктан үрнәк шәхес дип сокланмаганнар бугай. Язганнары да бик аз: нибары ике дистәләп шигырь. Ә шулай да антологияләргә кергән, дәреслекләрдә урын алган! Хикмәт, билгеле, күләмдә түгел. Хикмәт, хәтта шигырьләрнең ювелир эшләнешендә дә түгел. Хикмәт ул әсәрләрнең — зурмы, кечкенәме — үз заманын объектив чагылдыра алуында, чор рухын бирүендә, яңа буыннарга тәэсир итә алырлык көчендә, һәм... иҗатчының ихласлыгында, үзенә хыянәт итмәвендә.

Яков Емельянович Емельянов 1848 елда Лаеш өязенең (хәзерге Балык Бистәсе районы) Алан (Алан-Полян) авылында крестьян Емельян Петров гаиләсендә туа. Тугыз яшендә аны Мамадыш өязенең Җүкәче авылындагы волость писарьлары әзерли торган Удельное училищега укырга бирәләр. 1864 елны Казандагы Үзәк керәшен-татар мәктәбенә (В.Тимофеев — Бәчли эти ачкан Учительская школа) керә. 1869 елны укытучы сыйфатында туган авылының күршесе генә булган Үригә (Урей Чаллысы) кайтып, балалар укыта. Ильминский инициативасы белән 1874 елны янәдән Казанга килә һәм Духовная академиягә (дөресрәге, академия каршындагы миссионерлык институтына) алына. Аны тәмамлагач, дьякон дәрәҗәсе бирелә, ә 1880 елны ул инде протопоп була (шактый ук югары рухани чин бу!). Шул елдан башлап үлгәненә кадәр диярлек төрле (Чура Сала — Кукмара районы, Тәңкә — Саба районы, Шәмәрбаш — Балык Бистәсе районы) төбәкләрдә поп вазифаларын башкара. 1893 елда Үридә вафат була һәм шул авылда җирләнә дә. Бүгенгә килеп җиткән әдәби мирасы юка гына 2 китапчыкта тупланган: Дьякон Я. Емельянов стихлары. — Казан: Св. Гурий җәмгыяте типографиясе, 1879; Стихи на крещено-татарском языке. — Казань: типография Чиркова, 1888. (Шунысын да искәртик: татар шигъриятенең кириллицадагы беренче үрнәкләре бу. Бүгенге имлябызның башлангычы «Братство св. Гурия» җәмгыятьләреннән килә икән ләбаса! Тикмәгә генә кайчак кириллицаны «керәшен хәрефләре» дип әйтмәгәннәр шул.)

Яков Емельянов иҗаты, үз шәхесе кебек үк, каршылыклы, һәм, әйтер идем, идеологияләштерелгән иҗат. Бер яктан, аңы белән остазы Ильминский идеяләренә хезмәт итәргә тырышса, икенче яктан, күңеле белән үзен тудырган гади, ярлы халык интересларын якларга, аларга үзләренең нинди хәлдә икәнлекләрен аңлатырга, төшендерергә тырыша, үгет-киңәш белән генә булса да аларга ярдәм итәргә омтыла. Христиан динен пропагандалау дип аның «Ходай сине илдән алган», «Саташканны уяту» кебек шигырьләрен санасак, ә «Кайгы», «Ярлы тормыш», «Олысыманлык», «Әләк», «Улым», «Әби үгете» кебекләре халык тормышының җанлы чагылышын күрсәткән ачык мисаллар.

Миңа калса, шагыйрьнең эчке мәгънәгә, поэтик яңгырашка, эстетик кыйммәткә ия шигырьләре берничә: алар — «Әләк», «Кайгы», «Улым», «Кояш»... Я.Емельянов иҗаты турында үз фикерем үзгәрә-үзгәрә байтак еллардан бирле тәгаенләнеп килә инде. Беренче тапкыр бу исемгә мин үсмер чакта (1957 ел бугай) «Татар поэзиясе антологиясе» китабын укыганда тап булдым. Безнең төбәк кешесе булгач, үзгә бер кызыксынып, дулкынланып укыдым ул шигырьләрне. Дөресен әйтим: артык тәэсир итмәде алар миңа. Аңлашыла да: үсмер җанга романтика кирәк, оптимистик дәрт, хисләндергеч лирика кирәк, китапча югары стиль, матур чагыштырулар, томанга өретелгән образлар, хыялый серләр кирәк... Укылган шигырьләр минем өчен гыйбад авылча, артык гади, хәтта тупасрак та булып тоелды. Безгә артыгы белән таныш натур фәкыйрь күренешләр... Беришләре әбиләр көн дә диярлек безгә тукып килгән үгет-нәсихәт, акыл өйрәтү сүзләре булып кабул ителде. Беренче тойгылар, беренче кичерешләр күп чак дөрес була. Ул тәэссораттан ваз кичәргә җыенмыйм.

Соңрак, студент елларында, бу шагыйрьне бүтәнчәрәк аңлауда профессор Х. Госманның йогынтысы зур булды. Ул очынып-очынып укып күрсәтә иде «Җырчы Җәкәү» шигырьләрен! Халыкчанлыгына басым ясар иде, ритм-рифмаларының үзгәлеген әйтер, юл ахырыннан юл башына күчеп йөреп кабатлана торган сүзтезмәләр куллануны ачышларга тиңләр иде... Ул да, мәрхүм, үзенчә хаклы иде. Әмма эчке каршылыклы хис хәзер дә бетмәде... Хәер, объектив булыйк: кайчан, кем тарафыннан, ни максаттан язылган әсәрләр алар? Җавап: моннан 120—125 ел элек христиан рухани тарафыннан, шагыйрьлек миссиясенә дәгъва итмичә, күңелен бушатып, ачынып язылган «җырулар». Үзешчән иҗатның бер бөек (отышлы) ягы бар: ул — халыкчан. Я. Емельяновның 1879 елда чыккан җыентыгының халык телендә «Дарҗа әби кенәгәсе» дип йөртелүе дә үзгә бер мәгънәгә ия. Бүгенге «мерседес» машинасыннан арбалы атка карап үз «бөеклегеңә» соклану егетлекме? Хәлне, вакыйганы, фактны шул заман күзлегеннән, шул заман хәятыннан чыгып бәялә син! Шул чорда иҗат иткән шагыйрьләрнең кайсысында гади халык тормышының реаль чалымнары күбрәк чагылган икән әле? Һәм дә кайсысының әсәрләрен бүгенге укучы аңлап, йөгертеп укый алыр икән? Бу җәһәттән Я. Емельянов иҗаты бик тә отышлы хәлдә. Алда әйтелгән «Аны ни-нәрсә өчен олылыйлар?» дигән сорауга бер җавап-дәлил бу. Гомумән, бүгенге поэзиядә киң колач алган иректе, сөйләм интонациясенә корылган шигырьләрнең беренче яралгылары бит аларда.

Я. Емельянов турында әдәбият дәреслекләрендә беркадәр мәгълүмат булса да, алар шагыйрь шәхесен тулы күз алдына китертә алмыйлар. Асылда, ул мәгълүматлар язмадан язмага кабатланып кына йөриләр. Поп буларак Я. Емельяновның бер авылдан бер авылга, бер приходтан икенчесенә күчеп йөрүе дә хәтер кардиограммасын тоныкландырган, әлбәттә. Халыкның хәерчелеге, руханиларның икейөзлелеге, өстеннән туктаусыз язылып торган шикаятьләр, әләкләр, һәм, ниһаять, реаль тормышның үзе үк өндәгән максаттан бик-бик ераклыгы шигъри җанлы ирне нык уйландырган, йөдәткән булса кирәк.

Җәшнә, Кояш, җалтыра!
Яктың җирдә уйнасын.
Иртәнге кырау, соңгы суык
яңа орлыкны коймасын, —

дип оптимистик рухта язса да, кырыс тормыш барыбер аны бөгә, сындыра. Исеме «каһәрләнгән поплар» рәтенә керә. Тикшеренүчеләрнең язуынча, гомеренең соңгы елларында ул депрессиягә бирелә. Тикмәгә генә остазы Ильминский бер хатында аңа болай дип язмагандыр: «Тормышыңны рәтләргә тырыш, югыйсә бетәрсең. Мин сине кызганам. Алла сине үзеңне кулга алырга ярдәм итсен. Син аптырап калма, бер кеше дә сиңа явызлык теләми. Бу икебезнең арада гына калырга тиеш. Синең дустың, кабак тотучы Афанасий синең өстеңнән архиерийга... жалоба биргән».

Я. Емельяновның Борис исемле (Стариков Борис Яковлевич, нигә Емельянов түгел?) улы булуы билгеле. А.Н. Григорьев язмаларына караганда, ул да шигырьләр язган, матбугатта катнашкан. Язмышы ничек булып беткән, безгә билгесез. Алан-Полян авылында хәзер дә Стариков фамилияле гаиләләр бар. Аларның Емельяновлар нәселенә катнашы булырга тиеш. Һәрхәлдә, кызыксынучылар өчен җирлек бар.

Сүз уңаеннан безнең як керәшен татарлары арасыннан соңгы дәвердә чыккан шәхесләр турында. Шактый алар. Чагыштырып карасаң, мөселман татарлары авылларыныкына караганда күбрәк. (Хәтердә: 1950—1960 елларда Котлы Бөкәш урта мәктәбенә — Кызыл Йолдыз районына бер урта мәктәп! — Шәмәрбаш, Алан-Полян, Үри авылларыннан укырга килүчеләр дистәләгән иде, ә Күгәрчен, Күки, Балтач, Ямаш кебек зур татар авылларыннан килеп укучылар 1—2 генә була иде). Кечерәк кенә авыллар үзләре — Алан-Полян, Үри, Иванай, Керәшен Казысы, Шәмәрбаш (күп чак, ялгышып, Шомыртбаш диләр), Казак Чаллысы (Казаклар дип тә йөртәләр)... Ә күренекле кешеләре күп, шөһрәт-даннары зур. Я. Емельяновның авылдашы — атаклы математик, профессор Петров А.Н. (1900—1969); Шәмәрбаштан — педагог, Үзәк керәшен мәктәбенең директоры Егоров Н.Н. (1870—1922); медицина фәннәре докторы, профессор Кибяков А.В. (1901—1989); профессор, үз вакытында Казан финанс-экономика институты ректоры Абрамов П.В. (1918—1985); Иванай (Тупылат, Тук-Пулат) авылыннан — генерал-лейтенант Яковлев А.Е. (1903—1991); техник фәннәр докторы, профессор Никитин И.З. (1928); математик-профессор Ильин И. Ф. (1943); Казаклар Чаллысыннан — Советлар Союзы Герое Иванов В.П. (19...); филолог-профессор Марганова Р.А. (1954); Үридән — тарихчы әдип (керәшеннәр турында фундаменталь хезмәт — «Tatarica. Энциклопедия»нең авторы) Глухов М.С. (1937)... Исемлекне яңа заман балалары исәбенә дәвам да итәргә мөмкин. Ә бүтән төбәк, әйтик, Зәй, Бондюг, Чистай, Бакалы (Башкортстан) якларыннан чыккан атаклы кешеләрне барлый башласаң? Уртак цивилизациягә кушылучы көчле агым килеп чыга! Моны бәһаләргә, моңа сөенергә кирәк.

Гомумән, соңгы ун ел эчендә керәшен татарлары рухи тормышында җанлылык һәм яңарыш сизелә. Этномилли җәмгыятьләр барлыкка килә, җыр һәм бию ансамбльләре оеша яки торгызыла («Бигәш», «Игәнәй», «Айбагар» һ.б.), «Керәшен сүзе» газетасы нәшер ителә (1991), конкурс-фестивальләр уздырыла... Дөрес, халык тарихының чишмә башын эзләгәндә, төрле каршылыклар, гипотеза белән аксиоманы буташтырулар, чиктән чиккә ташланулар да була. Нишлисең, хакыйкать, күк капусы кебек, җиңел һәм тиз ачылмый. Шунысы куанычлы: теләсә кайсы ыру-төркемнең үз тарихын ачыклавы, үз рухи байлыгын барлавы, ахыр чиктә, Уртак Хәзинәбезне баету бит! Без XIX гасырның шанлы бер улы Я. Емельяновның 150 еллыгын билгеләп үтүне дә әнә шул юнәлештә күркәм бер гамәл дип бәялибез.

*1998, сентябрь*

## АНЫҢ САЗЫ ТӨЗЕК САЗ ИДЕ...

Нәкый ага вафат...

Үлем дип аталган Илаһи Кара Канатның башларыбыз өстеннән сискәндереп үтәсен сизенгән булсак та, без аның килеп җитәсенә әзерләнеп җитмәгән булганбыз икән... Җан өзгеч бу хәбәрне ишеткәндә, без — бер төркем каләмдәшләр — Язучылар йортында идек. Мәһабәт бинаның (хәзерге Мөштәри урамы, 14) ишегалдында мәш килеп кино төшерәләр. Без тамаша кылып кырыйдан карап торабыз. Сәер очрак: кызык та, кызганыч та. Тирә-якта ясалма төтен, янгынчыларның кызыл машиналарыннан сиптерелгән ясалма яңгыр, актерларның (күбесе Н. Исәнбәт спектакльләрендә каһарман рольләрен уйнаган артистлар) ясалма киемнәре, ясалма күз-елмаюлары... һәм Бөек Шәхеснең фани дөнья белән саубуллашу мизгелләре...

Төтен... Ясалма яңгыр... Тотрыксыз сәясәт... Ә чыны — күз. Сирәк була торган кояшлы, җылы көз татарның Бөек Улы Нәкый Исәнбәтне (чын фамилиясе — Закиров) мәңгелек юлга озатырга үзенчә әзерләнгән кебек. Тирә-юньдә моңсу олпатлык... Сарылык, сагыш, чарасызлык...

Нәкый аганың, һәр олуг шәхеснеке кебек, тормыш һәм иҗат юлы фаҗигаләр белән түшәлгән. Бөеклекләр дә, түбәнкелекләр дә, шатлыклар да, кимсетүләр дә... Бу гомергә заманының дәһшәт хакимияте КПСС ҮКның аңа карата махсус боерык карарлары да, подвалларда кочегар-мич ягучы (зур әдип булган елларда!) булулар да, сәхнә түрендә алкышларга һәм чәчәкләргә күмелүләр дә...

Нәкый Исәнбәт — тарихи фигура. Андыйлар сирәк. Табигатьнең асыл заты буларак, дөньялыкта үз миссиясен аңлаган кеше. Халык рухының, халык иҗатының энҗе чәчкәләрен, такыя кебек үреп, килер буыннарга тапшырган зат. «Татар халык мәкальләре»нең өч томлыгы үзе бер бөек хезмәт. Күләмле кереш сүзе генә дә әллә ничә диссертациягә торырлык, һәр татар кешесе бу хезмәтләр белән танышып, аны җанына сеңдерсә, без Җир йөзендә бик абруйлы милләт булыр идек... Ә ул төзегән сүзлекләр? Кызганыч, аларның күп өлеше әлегәчә дөнья күрмәгән. «Идегәй» дастаны — үзе бер эпопея. Зур шәхесләр, күрәсең, төрле яктан талантлы була. Ул — энциклопедик белемгә ия галим, сәхнә остасы — драматург, шагыйрь. «Уракчы кыз», «Син сазыңны уйнадың» кебек җырлары гына да ни тора!

Күптән түгел генә аның 90 еллык юбилее булып узган иде. Тантанада ул үзе катнаша алмады. Кадер-хөрмәт күрсәтеп бирелгән бүләкләрне, «иясенә тапшырырмын» дип, улы Празат Исәнбәт алган иде... Хәзер инде аңа бер нәрсә дә тапшырып булмый. Үзен генә Җир куенына тапшырырга кала... Сүз җаеннан әйтәсе килә: юньледән юньле нәсел кала. Нәкый аганың улы Празат — татар театрының олуг режиссеры, хикмәт иясе, кызы Йолдыз — татар музыка сәнгатенең зур белгече, сәнгатькяр кеше... Үзеннән соң эшеңне дәвам итүчеләр булу — үзе зур бәхет, Ходай бүләге.

Газраилгә һәркем тигез. Аңа патша ни дә, мәхлук кол ни! Туганбыз икән, һәммәбез бер юлда, чакрым баганалары гына төрлечә... Әмма һәр Бөек Акт тетрәндерә; ми генә түгел, тән дә кымырҗып куырылып ала кебек. Зур Кеше китеп бара. Аны кем алыштырыр соң? Әлбәттә, беркем дә алыштыра алмас. Шулай да Хәтерле кешеләр, яшьләр аның эшен дәвам иттерә алалар. Тиешләр. Һәммәбезгә онытмаска иде: ул үзе яшәгән чордагы татар халкының рухи анатомиясен язып-күрсәтеп китте. Үзенә күрә бер күрсәтмә-харита...

Без бу арада митинглар шаукымында яшибез. Гомер үткәч, бу еллар гаҗәеп еллар булып искә төшәр әле! Татар соңгы ничә гасырдан соң үзен «Дөньяда без дә бар!» дип күтәрелеп чыкты, үз тавышын ишеттерә башлады. Ә каян килә соң бу уяну, бу күтәрелеш? Әлбәттә, Нәкый агалардан! Ул, хәл-вәзгыятьне тирәннән аңлау, замандаш һәм хәким зат буларак, дәүләтчелекне (ата-анасыз йортта тәртип булмый ул!) торгызу юлындагы хәрәкәттә иң төп баганаларның берсе иде. Таяну ноктадарыннан тора бу Дөнья!

Нәкый Исәнбәт вафат. Шул сәбәп белән хисләнеп уйлануларым болар. Меңләгән бүтән милләттәшләребезнең фикерләре, бәлки, бүтәнчәрәктер. Тирәнрәктер... Уртак максат юлында барганда һәр нәрсә аклана. Хәтта үлемне дә аңлап була кебек...

...Казан уртасында кино төшерәләр. Литфонд егетләре җеназа хәстәрләре белән йөри. Без, бу сәгатьтә конфузия алган кешеләрдәй гаҗизләнеп, Казан уртасында басып торабыз. Бөек кеше китә. Тарихның асыл бер сәхифәсе ябыла.

Безгә, әлегә исән-сау, сәламәт егетләргә, тамаша кылып торырга гына түгел, саф башындагыларның әләмен алга — алгарышка илтергә кирәк. Бүтән юл юк.

Рухың тыныч булсын, Бөек Татар Улы!

*1992, 15 сентябрь. Казан*

## ТЫНГЫСЫЗ ҖАНЛЫ ОЛЫ ШАГЫЙРЬ

Моннан өч-дүрт ел элек бер газетада, шигырь бәйрәме көне мөнәсәбәте белән, Хәсән аганың чәчәкләр турында дүрт кенә строфадан торган шигыре басылган иде. Кайбер юллары хәтердә калган:

Каядыр дәшәләр,
Нәрсәдер әйтәләр...
Мөгаен, Матдәнең
Җырыдыр чәчәкләр.

Кулымда — Хәсән ага Туфанның әле күптән түгел генә дөньяга чыккан сайланма әсәрләр китабы. Дулкынланып укыдым. Гыйбрәтле, уйландыра торган шигырьләр, эшләнешләре ягыннан нәфис, Тукайның «Туган тел»е шикелле күңелгә шундук бикләнергә торган садә һәм мәгънәле шигырьләр никадәр анда! Китапны укып чыккач, чәчәкләр, мөгаен, матдәнең җырыдыр дигән юлларны тагын бер кат күздән үткәргәч, шундый уй килде: уйлап баксаң, Хәсән ага үзе — халыкның гүзәл бер гаме бит. Тик бусы мөгаен түгел, ә тәгаен. Халкыбызның зур шагыйре ул безнең Хәсән агабыз! Бусы да тәгаен.

Яше белән дә, эше белән дә бик өлкән, шәхес-кеше буларак та чибәр, затлы һәм мәһабәт бу шагыйрь турында дустанә интим итеп, төпле һәм җылы итеп язуы шактый авыр. Чөнки иркенәеп китеп булмый, чөнки аралар ерак, безнең арада ярты гасырга якын давыллы еллар ята.

Хөрмәтле шагыйребезгә 70 яшь тулган бу көннәрдә аның иҗаты, әдәбияттагы урыны, шәкертләре, үзенең исән-саулыгы һәм киләчәккә корган план-хыяллары турында тагын бер кат уйланасың. Миңа, чагыштырмача яшьрәк буынның бер вәкиленә, аның иҗатының яшь иҗатчыларга йогынтысы ни дәрәҗәдә һәм шагыйрь буларак безгә үрнәк асыл яклары нидән гыйбарәт икәнлеген ачыклау мөһим. Шагыйрьнең тарихи бәясен, зурлыгын билгели торган бер күрсәткеч — аның мәктәбе, шәкертләре булу. Хәсән аганың да шәкертләре бар, мәктәбе бар. «Ул мәктәпнең вәкилләре кемнәр соң?» диючеләр булыр. Моңа җавап шул: ул мәктәп әле яшь, чөнки Х. Туфанның бу соңгы ике буын өчен табылуына һәм ачылуына унбиш ел да юк шул әле... Шулай да соңгы өч-дүрт ел эчендә әдәбиятка шактый кыю кереп килүче М. Әгъләмов, Зөлфәтләр иҗатында Х. Туфанның уңай мәгънәсендәге йогынтысы нык сизелә. Алга таба аның тарафдарлары, аның иҗат принципларын килер заман аһәңендә дәвам иттерүчеләрнең күбрәк булачагына нык ышанам. Хәсән ага — нәфис интеллектуаль тоемга ия, шигъриятнең формаль һәм мәгънәви хасиятләрен бик яхшы белгән, аларны үзенчә беркадәр фәнни нигезләгән шагыйрь. Шигырь төзелеше турында аның махсус теоретик хезмәтләре дә бар. Аның фикерләре белән килешергә яки килешмәскә мөмкин. (Мин, шәхсән, аның 60 нчы еллардан башлап татар шигъриятендә үзен актив раслап килүче сөйләм шигыренә, уй-хис агышына карап төрлерәк, үзгәрәк һәм беркадәр иреклерәк форма алган шигырьләргә караган фикерләре белән килешеп бетә алмыйм.) Ләкин шунысы хак: Хәсән ага һәрчак халык хәзинәсе үрнәкләреннән чыгып хөкем йөртә, һәр сүзен әдәбиятыбыз тагын да бай булсын, Тукай, Җәлилләр калдырган мирасның яхшы формалары дәвам итсен дип, чын күңелдән хуҗаларча кайгырып әйтә.

Газета-журнал редакцияләренә «Ничек шагыйрь булырга?» «Шагыйрь нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?» кебек сораулар белән шактый күп хатлар килә. Минемчә, һәр чын шагыйрьдә Хәсән агадагы байтак күркәм сыйфатлар булырга тиеш. Ул нинди сыйфатлар соң? Беренчедән, әдәбият эшен изге эш дип карап, аңа фидакарьләрчә хезмәт итү. Шагыйрь С. Хәким аның хакында бүтәнчәрәк, кыскарак итеп әйткән: «Туфан — фанатик шагыйрь». Үз-үзләрен аямыйча, көнне, төнне, вакытны онытып, шашынып иҗат итүче әдипләр бездә, белмим, тагын ничәү икән? Хәсән ага күбрәк төннәрен иҗат итә. «Төн — серле, Шәхескә Дөнья белән япа-ялгыз калып серләшер өчен җай чак», — ди шагыйрь.

Йокысыз да бара
Тормыш юлы.
Ә җырсыз юк, җырсыз баралмый.

Ул — бөтенләе белән үзенең шигырьләрендә. Шигърият — аның яшәве.

— Ничек икән синең йөрәк? — дисең,

Ничек икән гомер көннәрең?
Кулымдагы китабымда, чордаш,
Шигырьләрдә — минем йөрәгем.

Шагыйрьләрнең чынлыгын раслый торган сыйфатларның, минемчә, икенчесе ул — үз Заманың һәм Халкыңның улы була алу. Хәсән аганы без бу җәһәттән заманның гадел елъязмачысы һәм халкының сөекле улы, дип авыз тутырып, сөенеп әйтә алабыз. Алыгыз аның китапларын, кирәксә, хронологик тәртиптә карап чыгыгыз: крестьян агайның күмәкләшү чорындагы уй-фикерләрен дә, беренче бишьеллыклар гөрелтесен дә, Урал заводларының металл чыңын да, сугыш чорындагы халыкның нәфрәт авазын да, культ корбаннарының өзгәләнү авазларын да ишетерсез, шагыйрьнең кешене, илне, телне, гадел тарихны, Ленинны зурлавын да күрерсез, киләчәкнең бүгенгедән гүзәлрәк булачагына нык ышанганлыгына инанырсыз. Халыкның «Ир язмышы — ил язмышы» дигән әйтеме бу очракта илсөяр табигатьле Хәсән ага иҗатына бик тә туры килә.

Зирәк илем, кыю, чая илем,
Сиңа бит бер сүзем бар минем, —
Йә үлемемдә шуны, йә теремдә
Искә ал идең:
Һәр эшне мин
Башкардым тик бары
Синең өчен кирәккә күрә.
Кирәк төштә утка-суга кердем,
Бата-чума һәм яна-көя.

Хәсән аганың без яшьләргә тагын бер ягы үрнәк: ул гаять актив, гражданин буларак, чорның һәм җәмгыятьнең актуаль мәсьәләләренә аның үз сүзе, үз мөнәсәбәте бар. Җыелышларда, үзара әңгәмәләрдә булсын, матбугат битләрендә яки радиодан булсын, без аның янып һәм ярып үз фикерен әйткәнен күрәбез, ишетәбез. Ул битараф күзәтүче түгел, ул — көрәшче. Көрәшче исә тормышны янып сөюче. Менә шулай — яшәп туймаслык гаҗәп нәрсә син, и Тормыш!

Аның балаларга атап язган шигырьләрен дә безнең укучыларыбыз яхшы белә. «Юкмыш бабай» әкиятен генә искә төшерегез. «Яшь ленинчы» газетасында яки «Ялкын» журналында чыккан шигырьләрен хәтерләгез! Шагыйрь киләчәк турында уйлый икән, киләчәк ул — без, сез, бүгенгеләр, сабыйлар, киләселәр. Шагыйрь, балаларның күзләренә туры карап:

Шатлыклар китерә иленә
Чын кеше булганнары,
Үзенең илдәшләренә
Иш булып туганнары,
Беркайда илнең исемен
Каралтмый торганнары, —

ди. Чын талант белән күрешү, аралашу үзе бер бәйрәм. Халык арасыннан чыккан талант һәрчак гади һәм кешелекле. Гәрчә ул зур булса да, аның дустанә мөгамәләсе аркасында үзеңне аның белән тигез, тиң хис итәсең. Моннан берничә ай элек миңа Хәсән ага белән ерак сәфәргә — Урта Азиягә, каракалпаклар иленә барып кайтырга туры килде. Юлдашыңның үзеңнән яхшырак булуын тою үзе бер рәхәт икән!

Хәтерлисез микән, Хәсән ага!
Җитәкләшеп, тотакланышып
Йөргән идек икәү Азия буйлап,
Дуслар иле белән танышып.

Яңа китабыгыз котлы булсын, хөрмәтле Хәсән ага! Озын гомер сезгә, олы җанлы тынгысыз Кеше!

*1970, ноябрь*

## УЛ КИЛӘЧӘККӘ АТЛЫЙ

Юлым төште дә, быел җәй Кутуй туган якларга – Пенза якларына барып чыктым. Татар әдәбиятын, сәнгатен ихтирам иткән һәр кеше өчен кызыклы, гыйбрәтле яклар бу. Мишәрләр яши торган бу төбәктән беренче татар романнарының авторлары Муса Акъегет, Заһир Бигиевлар чыккан. Гафур Коләхмәтов, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Шамил Усмановлар — шушы якларда туып үскән кешеләр. Юлыңны бераз дәвам итсәң, Такташның Сыркыдысына барып чыгасың. Сыркыдыдан ерак түгел Габдрахман Әпсәләмов туган җирләр...

Менә без, Якуб бабай Кутуев белән, Татар Кынадысы авылы урамнары буйлап йөрибез. Якуб бабай — Гадел Кутуйларның кардәш туганы. Ул Гадел Кутуй турында, аның туганнары, нәсел-нәсәбе, бала чактагы кызыклы хәлләр турында сөйли. Хәтерендәге кайбер вакыйгаларны кабат-кабат сөйли, кайбер нәрсәләрне хәтерләми, инде оныткан. Ничә әйтсәң дә, аңа да байтак яшь шул инде... Гадел Кутуй туган нигезгә барып чыгабыз. Хәзер бу нигездә Әхтәмов фамилияле кешеләр тора. Яңа өй, яңа кешеләр. Бакчада шаулап торган карт өянкеләр генә Кутуйлар яшәгән елларга шаһит. Алар элеккечә һаман шаулый да шаулый. Әманәт үтәп, Казанга алып кайтыр өчен нигездән бер уч туфрак алам. Тынлык. Тәрәзә каршында өйнең хуҗалары басып тора. Өч кеше. Өч буын: Васфи карчык, аның улы Касыйм һәм сабый бала. Туфрак алганга бераз гаҗәпсенделәр бугай, аңлатмакчы булам: «Туганнары сораган иде...» Китәр алдыннан Касыйм салмак тавыш белән әйтеп куйды: «Тыныч булсыннар, бу нигездә аның рухы рәнҗерлек булмас...» Байтак урамнарны урап, мәктәпкә таба кайту юлында бер чишмә янында тукталдык. «Әйдә, Кутуйлар чишмәсеннән бер су эчеп җибәр булмаса!» — ди Якуб ага. Торбадан челтерәп аккан су салкын һәм тәмле иде, чишмәнең Кутуй исеме белән йөртелүен белү, тою тагын да ләззәтлерәк булды. Кутуй исемен йөрткән урамнар бар, пионер дружиналары бар, аның исемендәге чишмәне ишеткән юк иде әле.

Шулай килеп чыкты: Кузнецк районының Татар Кынадысы авылыннан Казанга кайткач, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте буенча эшләнгән спектакль карарга туры килде. Аны Башкорт дәүләт академия театры сәхнәләштергән иде. Спектакль яхшы куелганга күрә, ул көннәрдә халык театрга ифрат күп йөрде. Тамаша карарга теләүчеләр бик күп булды, зал сыйдыра алмыйча, билетсызлар урамда өелеп-өелеп калды. Спектакльне караганда, сәхнәдә барган дулкынландыргыч күренешләрдән бик аз мизгелләргә генә айнып китеп, күңелгә төрле уйлар килде. Кинокадрлардагы шикелле: бу әсәрне мәктәптә укыган еллар, әле яңа гына булып кайткан Кынады җирләре, дәреслекләргә кертелгән «Без — сталинградчылар» әсәре, язучының фронтта төшкән фоторәсеме... Тәнәфескә чыккач, спектакль карарга килгән язучылар белән сөйләшәбез. Нәрсәдә соң бу «Тапшырылмаган хатлар»ның сихри көче! Нәрсәсе белән тарта соң ул халыкны? Ә бит залда утыручыларның күпчелеге бу әсәр белән күптән таныш, байтагы, мөгаен, кат-кат укыган. Әйе, ул — классик әсәр, мәңгелек әсәр. Юкса ул, бик күп телләргә тәрҗемә ителеп, бүтән халыкларның да күңелен дулкынландырып, уртак рухи хәзинәгә әверелә алмас иде. Әйе, кайдадыр Кутуй чишмәләре челтери, ә «Тапшырылмаган хатлар»ы дөнья буйлап миллионнарча укучыларына тапшырылып йөри.

Татар мәдәнияте тарихында әйтер өчен шундый ансат, кыска исемнәр бар. Тукай, Сәйдәш, Җәлил, Такташ, Туфан... Бу исемнәр белән рәттән Кутуйны да әйтергә була. Исемнәре кыска, гомерләре кыска, ә дөньялыкта кылган эшләре, хезмәтләре озак-озак дәверләргә калырлык. Телгә шигырь юллары килә:

Үлемнәре белән үлемсезлек
яулап ала безнең
шагыйрьләр.
Кемдер сорар: кая дәлилең?
Мин эндәшмим.
Каберләре әйтсен
Тукай,
Кәрим,
Кутуй,
Җәлилнең!

Минем буын тере Кутуйны күрә алмады. Ул фронтта, ут эчендә йөргәндә, без әле бишектә генә булганбыз. Без түгел, бездән бераз өлкәнрәк булган улы Рөстәм дә (хәзер ул — Рөстәм Кутуй, күренекле язучы һәм шагыйрь) әтисен ачалак-йомалак кына хәтерли. Тикмәгә генә әтисе турында болай дип язмагандыр ул:

Әти...
Төннәрен кайчак уянып
бер кычкырып әйтәсе килә
малайлар көн дә әйткән бу сүзне!

Гадел Кутуй, сугышның башыннан ахырына кадәр авыр юл үтеп, 1945 елның июнендә чит ил туфрагында ятып калды. Ул Польшаның Згеш шәһәрендәге туганнар каберлегенә күмелгән. Үлем нинди рәхимсез, мәгънәсез! Сугышның буеннан-буена сугыш та, дошманны меңнәрчә чакрымнар куып, өненә барып җит тә җиң... Һәм Бөек Җиңүнең әһәмиятен, шатлыгын, ләззәтен тоеп яшәргә, аз гына да яшәргә өлгерә алмыйча дөньядан кит!.. Аның «Сагыну» нәсерен тагын бер кат алып укып карыйм да, аңларга авыр бу фаҗига үзенең бөтен ярасы белән ачыла шикелле миңа. «Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил!.. Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем...»

Әйе, без тере Кутуйны күрә алмадык. Ләкин без аны үз замандашларыннан ким белмибез шикелле. Чөнки без аның исеменең көннән-көн тарала баруына, әсәрләренең үлемсезлегенә шаһит кешеләр. Язучы Кутуй белән бергә, без тормыштагы шәхес-кеше Кутуйны да ул заман документлары аша — истәлекләр, мәкаләләр, хатлар аша яхшы беләбез. Аны белгән кешеләр — язучымы ул, эшчеме, артистмы, офицермы — һәркайсы беравыздан шуны әйтә: ул сөйкемле, әдәпле, ярдәмчел кеше иде; ул шәп оратор, публицист иде; ул зур эрудициягә ия шагыйрь, язучы, драматург; ул педагог һәм җәмәгать эшлеклесе иде. Никадәр күпкырлы, гражданлык дәрәҗәсе никадәр югары шәхес! Әдәби талант өстенә, нур өстенә нур булган менә нинди күркәм сыйфатлар аны татар культурасының зур вәкиле дәрәҗәсенә күтәргән икән! Кутуй әнә шул күпкырлылыгы белән безнең бүгенге яшь әдипләребезгә рәхәтләнеп өлге була алырлык.

...Хәзер инде бездә кыш. Быел күп уңыш биргән Кынады басуларына инде кар яткандыр. Польшада һава хәлләре бераз йомшаграк булырга тиеш, Згешта хәзер, бәлки, суык яңгыр явадыр. Уфада, бәлки, «Тапшырылмаган хатлар» спектакле барадыр. Ихтимал, каядыр Ерак Көнчыгыштагы берәр солдат кулына Кутуйның китабын тоткандыр. Казанның Гадел Кутуй урамы тирәсендәге тулай торакларның берәрсендә бүгенге көннәрнең берәр Галиясе хат язадыр. Шәһәрнең икенче бер почмагында Кутуйның үз улы шигырь яки хикәя турында уйлыйдыр... Тормыш дәвам итә. Ватан өчен, Халык өчен бар күңел байлыгын һәм гомерен биргән Гадел Кутуйлар бүгенге кешеләр белән бергә киләчәккә атлый.

*1973, ноябрь*

**АВЫЛДАШ**

Башлангыч сыйныфларда укыганда ук безнең авылдан Зәйнәп Бәширова дигән шагыйрә чыкканлыгын ишетеп белә идем. 1956 елда «Татар поэзиясе антологиясе»ндә аның шигырьләре басылып, безнең Балтач (совет чорында Юлсубино булып киткән) авылында туып үсүе турында язылгач, тагын да горурланыбрак киттем: «Исеме әнә нинди затлы, калын китапларга кергән кешеләр дә күктә яралмаганнар икән лә бит, тырышсам, мин дә шагыйрь була алачакмын!» дигән ышаныч тагын да ныгый төште. Кызыксына торгач, аның исән-сау икәнлеген, заманында Казан рабфагын, Мәскәү университетының журналистика факультетын тәмамлавын, нәшриятта һәм шәһәр китапханәләрендә җаваплы эшләр башкаруын белдем. 30 нчы елларда Горький мишәрләре ягында чыккан «Октябрь коммунасы» газетасының редакторы да булып эшләгән ул. Еллар үткән саен, исеме антологияләргә кергән шагыйрәне күрәсе килү көчәйде генә. Ни әйтсәң дә, авылдашлар бит. Җитмәсә, этисен — Хуҗа мулла бабайны күреп тә беләм әле. Безнең өйдә әллә ничә кат булганы да бар. Ә менә атаклы кызын һаман күрә алган юк!

Исәя төшеп, Казан университетында укый башлагач, Зәйнәп апа турында мәгълүматым, әлбәттә, күпкә артты. Профессор Хатип Госман да үз лекцияләрендә аның исемен телгә алгалый иде. 30 нчы елларда Г. Кутуй, Һ. Такташлар белән якыннан аралашып йөргән, революция «казанышларын» күпләргә караганда ныграк аңлаган «авангард яшьләр»нең берсе булган, гаилә һәм әхлак мәсьәләләрендә гасырлар буе килгән кануннарга төкереп (исегезгә төшерегез: «өйкибарм»чылар, ягъни өйләнмәүчеләр, кияүгә бармаучылар хәрәкәтләре булган, «әбиизм» заманнары бу!), «Долой стыд!» төркемнәрендә актив йөргән... Менә бит кем булып чыккан безнең Хуҗа мулла кызы Зәйнәп Бәширова! Шаярма, безнекеләр бер тотынсалармы...

1965 елда үземнең дә нәниләр өчен рәсемле беренче китабым чыкты. Мин моны Зәйнәп апа Бәшировага — Жуковский урамындагы фатирына да юлладым. Танышуны китаптан башлау хәерле булыр дип уйлаганмындыр инде. Янәсе, яшь авылдашыгыз да тегенди-мондый гына малай түгел, студент булса да, инде китап авторы! Озакламый берике җөмләдән торган җавап хаты да алдым. Әмма иркенләп күзгә-күз карашып очрашуга һаман җай чыкмады. Өйләнеп җибәрдем, ел ярым чамасы солдатта йөреп кайттым, аннан Әлмәткә эшкә киттем... Шулай да Казанга килеп айлап-айлап Язучылар берлегендә эшләгән 69—70 нче елларда күреп-таный башладым мин Зәйнәп апаны. Ул Бауман урамындагы татар ашлары йортына төшке ашка йөри иде. (Әлеге бина хәзерге кебек түгел, кыяфәте белән бүтән рәвешле иде ул вакытта, аны 70 нче еллар башында үзгәртеп салдылар. Хәзер хосусый оешмалар кулына күчеп, милли ашлар йортының рухы да калмады инде анда... Бу йортның шөһрәтле чагы шагыйрь Шәйхи Маннур исеме белән дә нык хәтердә калган. Ул анда еш килә иде. Аш-суга бик нәзберек, бөртекчел, күпмедер дәрәҗәдә вакчыл һәм холыксызрак булганга күрә, ашханә пешекчеләре һәм хадимәләре аннан бик өркеп торалар иде.) Матбугат йорты белән күрше генә булганлыктан, ул ашханәгә төшке ашка сирәк булса да мин дә йөргәли идем. Шулай бер көн йөзгә-йөз дигәндәй очраштык без Зәйнәп апа белән. Кул биреп күрештек. Ул да мине, теге бүләк китаптан тыш, бераз ишеткәләп белә булып чыкты. Беркавым әңгәмәләшеп тордык. Сүзне туган авыл турында, аның балачагы хатирәләренә борыбрак сөйләшеп карадым. Чөнки туган авыл дөньяның иң гүзәл

җире иде әле минем өчен (кайбер төсләр тоныкланып, хисләр бераз тупасланса да, — хәзер дә шулай). Әмма ул минем сүзләргә бер дә кабынып китмәде. Йөзендә дә хисләнү, дулкынлану әсәре юк, ниндидер салкын битарафлык. Сүземне дәвам итеп, мин аңа конкрет тәкъдим ясадым:

— Зәйнәп апа, Сезнең авылга 40 еллап инде кайтканыгыз юк икән. Әйдәгез, бергәләп кайтып киләбез — авылдаш ике шагыйрь кайта, янәсе! — кул астында ялтырап торган кара «Волга» да бар. (Мин ул вакытта, әйткәнемчә, Язучылар берлегенең җаваплы секретаре булып эшли идем.) Җилтерәтеп кенә кайтып киләбез.

— Юк! Кайтмыйм! — диде ул кистереп.

— Нигә? Сез шунда туган, авылыбыз чишмәләренең суын эчкән, чыклы чирәмнәрендә тәпиләп чабып йөргән. Әти-әниегез шунда күмелгән. Кем белә, көне килгәч, Сезне дә шул туфрак үзенә тартыр, бәлки?

— Юк, энекәш! Әйткәннәрең сентиментальлек кенә. Без — атеистлар. Без — коммунистлар. Чын коммунистка Җир шарының теләсә нинди ноктасында күмелсә дә, аңа барыбер!

Менә сиңа вәт җәме! Дөресен әйтим, бу минутта мин, өнсез үк димәсәм дә, шактый ук югалып калдым. Ул үз сүзләрен шактый көчле тавыш һәм ниндидер бер эчке инану белән әйтте. Хөкем карарын игълан итүчеләр, кайбер лекторларда була шундый тавыш, һаман күз алдымда: ап-ак чәчле, йомры гәүдәле, юантык аяклы 70 яшьләрдәге бер татар карчыгы. Кайчандыр исеме мәгълүм шагыйрә!

Соңрак, ара-тирә, әйле-шәйле генә очрашып, баш кагып дигәндәй сәламләшсәк тә, бүтән әңгәмә корып сөйләшергә насыйп булмады. Дөресрәге, теләк тә булмады. Ә баштарак теләк-ниятләр бик зурдан иде. Ул яшәгән заман рухын күбрәк беләсе, шул чор шәхесенең эчке дөньясын аңлыйсы, табынган идеалларының безгә яраклыларын күңелгә күчерәсе, үстерәсе килгән иде!..

Зәйнәп апа Бәширова 1984 елның җәендә вафат булды. Аны Яңа бистәдәге татар зиратына җирләделәр.

Менә бу язмамны язып утырам да уйлап куям: хурлап язмадыммы авылдашымны? Мин бит аны, асылда, белмәдем дә бит. Чынында кем булган ул? Үз заманының каһарманымы, әллә бер корбанымы? Ходайның бәхетлесеме, әллә үги бәндәсеме? Мулла баласы булуыннан ваз кичкән бер гыйсъянчымы? Соңгы сәгатьләрендә иреннәрендә нинди сүзләр тибрәнгән икән?.. Авыр туфрагы җиңел булсын!

Ә 1986 елда чыккан «Совет Татарстаны язучылары» дигән белешмә китапта (төзүчесе Рәис Даутов) аның тормышына һәм иҗатына билгеләмә рәвештә язылган мондый юллар бар: «Азатлыкка чыккан халыкның бәхетле киләчәге хакына яшьләрне иҗади хезмәткә, көрәшкә чакыру, ленинизм идеяләренең мәңгелек булуын раслау, шуңа тирән ышаныч З. Бәширова шигырьләренең төп пафосын, рухын билгели». Әйе, совет хакимияте һәм партия идеологиясе чоры бәяләмәсе бу. Ә без, иманнар яңартып, социаль тетрәнүләр кичереп, XXI гасырга керергә әзерләнгән буын (һәм бездән соң килүчеләр), XX гасыр башында шагыйрә дип телгә кергән З. Бәшированың иҗади-иҗтимагый эшчәнлеген ничек дип бәяләргә тиеш булабыз соң?

Алдымда Зәйнәп апа Бәшированың гарәп имлясында чыккан бәләкәй күләмле шигырь китаплары. «Очкыннар» (1921), «Көрәш җырлары» (1923), «Яшь инкыйлабчы җырлары» (1923). Монысына шул заманда популяр булган рус җырлары: «Молодая гвардия», «Кузнецы», «Мы поколение живое» һ.б. җырларның тәрҗемәләре тупланган. Авылдашым китапларыннан җаныма ятышлы, рухыма иш шигырь юллары эзлим. Таптым дип әйтә алмыйм, бар булган язмаларыннан кайбер мисаллар китерәм:

Яшьлегемдә кош кебек читлектә тоткын иттеләр,
Якты дөньяга чыгармый күкрәгемне череттеләр...
Ә хәзер инде азат, мәңге азат мин эшчемен,
Күкрәгем гайрәтле, дәртле, мин иманлы көчлемен.

*(«Татар кызы»)*

* * *

Әнә анда, ерак түгел, күрәсезме,
Балкып тора нурга чумган кызыл байрак.
Әнә, чиксез халык агыла шунда таба —
Ил яктырткан кызыл нурга таба.

*(«Кызыл байракка таба»)*

* * *

Көйлә Туган илнең шатлыкларын,
Алда якты көннәр көткәнен,
Әкрен-әкрен шулай ярлы илдән
Ямьсез, караңгы көннәр үткәнен.

*(«Көзге җил»)*

Мисалларны күбрәк тә китерергә мөмкин. Ләкин моңа ихтыяҗ юк. Китерелгән шигырь юлларына комментарий да кирәкми. Аңлашыла. Гомумән, шул чорда иҗаты зур шагыйрьләр дип кемнәрне атый алабыз? Тагын да ераккарак китеп уйланып карыйк: без белгән күп гасырлы татар шигърияте тарихында шагыйрә-алиһә дип санарлык бирәр шәхес бармы? Булганнардыр алар, фаҗигале тарихыбыз аркасында гына онытылганнардыр, дип уйлыйсы килә. Әгәр булмаганнар икән, ерак бабаларыбызга, буыннарыбызга оят. Куелган четерекле сорауның икенче ягы да бар. Хатын-кыз кайсы заманда да хатын-кыз инде ул! Табигатьнең төп миссиясе — аңарда. Шагыйрьне дә, батырны да, хакимне дә ул тудыра. Хатын-кыз үзенең кемлеген онытса, гомеренең финалы үкенү белән томалана. Шагыйрьләр язмышы да чыгарма була алмый. Хәзер татар шигъриятендә беренче адымнарын ясаучы кыз балалар шактый. Алар да уйлансыннар иде: шигырь — синең язмышыңны, әллә үзеңнең яшьлегеңне, дәртеңне, хислегеңне күрсәтеп алу гынамы? Икенчесе үтәр, ә беренчесе — язмышың булса, нишләрсең?..

Күптән түгел генә 81 яшьлек әтием Габдрахман Фәйзуллин авыл зиратында Зәйнәп Бәшированың әтисе Хуҗахан Габдрахманов каберен тәртипкә китереп, язулы такта куйды. Савап өчен түгел, күңелемә тынычлык өчен тәртипләдем ул каберне, диде әтием. Безгә дә, бүген исән язучы-шагыйрьләргә дә, гыйбрәт өчен әдәбият әһелләренең каберләрен ешрак яд итү савап булыр иде. Шул исәптән шул заманның символы һәм корбаны булган шагыйрә Зәйнәп Бәширова каберен дә. Беренче чиратта, мин моны үземә әйтәм.

*1998, 4 июнь*

## БАТМАСКА ТУГАН БАТТАЛ

Яңа салынган күпер аша Каманы чыгып, Биләр якларындагы атаклы Изгеләр тавына бару юлында Зур Тигәнәле авылы кала. Исеме Шәле, Әлдермеш, Кырлай кебек телдә гел яңгырап тормаса да, үзенчә данлы авыл ул. Ерак тарихи тамырларны барлап тормыйча, бер генә факт та шуңа дәлил була ала: биредә үткән гасыр башында Вазыйх исемле агайның өч угланы туган — Салих, Абдулла, Мөбарәк. Соңрак татар халкына дан китерә торган шәхесләр — шагыйрь, музыкант, каһарман солдат (һәр өчесе дә заманында солдат булып сугышта катнашкан, Абдулла дигәне Җәлилләр белән көрәштәш булып һәлак була). Тигәнәлене үтеп киткәндә, миндә һәрчак сораулы уйлар туа: авыл халкы үзенең данлыклы уллары белән тиеш дәрәҗәдә горурлана микән? Без — язучы-сәнгать кешеләре — аларны тиешенчә зурлый-бәяли алдыкмы? Һәм, ниһаять, яшь буыннар алар турында яхшы беләме? Сорауның беренчесе турында кистереп әйтә алмыйм, әмма соңгы икесенә җавабым шул: юк, тиешенчә бәһали дә алмадык, алар турында килер буыннар аңына тиешенчә сеңдерә дә алмыйбыз шикелле. Бу сүзләрне иң элек Салих Баттал мисалын күз алдында тотып әйтүем, утыз елдан артык әдип белән азмы-күпме аралашып, иҗатын беркадәр белгән каләмдәше буларак фикер йөртүем.

Исән булса, быел аңа йөз яшь тулган булыр иде. Салих ага Баттал, туксан ел яшәп, моннан ун ел элек гүр иясе булды (хезмәттәшебез шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов белән бер көннәрдә вафат булды ул). Салих Баттал гомере буе кабатланмас зур шәхес булып яшәде, зур шәхес булып иҗат итте, соңгы көннәренә кадәр үз вөҗданына, үз иманына тугрылыклы булып кала алды. Бездә Ходайдан талант бирелгән каләм ияләре шактый, әмма аларның һәммәсен дә зур шәхес дип тану кыен. Асылда, фәкать зур шәхес кенә тормышта тарихи эз калдыра аладыр ул. Салих Баттал, әйтелгәнчә, XX йөз башында дөньяга килгән. Искә төшерик: әдәбиятның киләчәген белдерәчәк кемнәр туган дәвер соң бу? Һ. Такташ, Г. Бәширов, К. Нәҗми, М. Җәлил, Х. Туфан, А. Шамов, Ш. Маннур, Ә. Ерикәй… Болар — С. Батталның яшьтәшләре, чордашлары, буындашлары. Иҗатлары да саллы һәркайсының. Рәсми яктан да киң танылу алган (дөрес, кайберләре үлемнәре аша, төрмә-сөргеннәр аша…) әдипләр. Кайсы — герой-каһарман, кайсы — югары дәрәҗәдәге депутат, кайсы — лауреат, кайсы — рәис-җитәкче, кайсы — яшьләй үк орденлы шагыйрь… Ә Салих Баттал? Ул да танылу алды. Шөһрәтле рәсми исемнәрсез, үзе булып, шәхес булып, Салих Баттал булып кала алды. Калмый ни! Ике метрлы мәһабәт буй-сын, курку белмәс холык, халыкчан талант… Табигать аңа күпне биргән булган. Ул үзе дә бу дөньяга кем булып туганын яхшы белеп яшәгән, күрәсең. Кемгә дә баш имәде, кеше иреген тыйган тәртип-кануннарга җайлашмады. Сирәк очрый торган шәхес. Яшәү рәвешендә һәм иҗатында төп сыйфат-билгеләрнең берсе — колачлылык, масштаблылык, туры сүзлелек, хөрлек… Аңлашыла да, уналты яшеннән үк нык бәдәнле үсмер Мәскәү якларында

батрак-зимагурлык мәктәбен үтә, егетлек чорында Ленинград, Оренбургларда укып, очучы-летчик була, әдәби иҗат белән актив шөгыльләнеп, әсәрләрен бастыра… Үзе яшь, үзе очучы, үзе язучы. Экзюперидан кай җире ким! Өстәвенә беренче буын совет язучысы, 1934 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы.

Салих Баттал — күпкырлы талант иясе. Ул — шагыйрь, прозаик, драматург, балалар язучысы, сатира-юмор остасы, тәрҗемәче. Шулай да, минемчә, әдәбият тарихында шагыйрь һәм прозаик булып калачак ул. Заманында пьесалары Академия театрында спектакль итеп куелса да, аны драматург буларак яхшы беләм, дип әйтә алмыйм. Театр белгечләре төгәлрәк әйтер. Чәчмә әсәрләреннән иң билгелеләре — «Сигезенчесе кем?» һәм «Баштан үткәннәр» дигән повестьлары. Беренчесендә беренче бишьеллыклар һәм Ватан сугышы чорында яшь очучының катлаулы язмышы сурәтләнсә (повесть детектив әсәрләргә хас мавыктыргыч сюжетка корылган), икенчесендә — «Баштан үткәннәр» дигән автобиографик әсәрдә — автор, гомеренең истәлекле, кызыклы вакыйгаларын искә төшереп, ил һәм чор турында уйлануларын, заманының атаклы шәхесләре В. Чкалов, А. Фадеев, Г. Ибраһимов белән очрашу тәэсирләрен бәян итә. Татар әдәбияты тарихында гыйбрәтле әсәрләр алар.

Салих Баттал, беренче нәүбәттә, әлбәттә, шагыйрь, эпик жанрларны иярләргә сәләтле фикерле шагыйрь, халыкчан шагыйрь. Үткән гасыр урталарында ул үзен шулай итеп таныта алды да. Совет чорындагы шагыйрьләрдән беренчеләрдән булып бөтенсоюз масштабында яңгыраш алды. «Олы юл буйлап» (икенче исеме — «Газзә») шигъри повесте «Новый мир» журналында басылып чыкты (сирәк хәл!). Аның иҗаты турында А. Твардовский кебек олуг шагыйрьләр язып чыкты. 50 нче еллар башында ул, мөгаен, татар поэзиясенең иң алдынгы сафындагы кеше булгандыр. Шул чорны фаразлап карыйк: поэзиябезнең горурлыгы булачак С. Хәким, Н. Арслановларның чын талантлары ачылып кына килә; Х. Туфан, М. Җәлилләр халыкка әле кайтмаган… Дөрес, Ф. Кәрим иҗаты да бик популяр иде ул чорда.

С.Батталның иң күренекле әсәре, әлбәттә, «Чирмешән ярларында» исемле шигъри романы. Соңгы дәвердә язылган беренче шигъри роман ул. Ни өчен соңгы дәвердә, дим, чөнки ул рәткә борынгы чордагы «Кыйссаи Йосыф», «Идегәй»ләрне дә шигъри романнар рәтенә кертергә буладыр. Заманында шигъри повесть, шигъри роман дип аталган озын әсәрләр чыккалады бездә: Ш. Маннурның «Җир-әнкәнең сылу кызы», Ә. Давыдовның «Йокысыз төннән соң»… Әле күптән түгел генә Р.Харисның «Исемсезләр» дигән күләмле әсәре аерым китап булып дөнья күрде. Бу әсәрләрнең кайсы — әдәби факт, кайсы — вакыйга, кайсы казаныш икәнен Вакыт галиҗәнаплары әйтә килә һәм әйтәчәк. С. Батталның «Чирмешән ярларында», жанр ягыннан ничек кенә аталмасын, классик әсәрләр рәтенә керергә лаек, минемчә. Р. Даутов, Н. Нуруллиналар төзеп чыгарган «Совет Татарстаны язучылары» дигән белешмәдә (1986) бу әсәр турында мондый юллар бар: «Халык җырларының форма үзенчәлекләреннән оста файдаланып язылган, шигъри детальләргә, үзенчәлекле күренешләргә, отышлы драматик ситуацияләргә бай булган бу әсәр 1905–1921 еллар арасындагы татар авылының катлаулы тормышын, кискен сыйнфый каршылыкларны, халык массаларының азатлык өчен көрәшен сурәтли». Дөрес әйтелгән. Шуны гына өстисе килә: бу әсәр яңа буын шагыйрьләренә осталык мәктәбен үтү өчен менә дигән кулланма да. Халык иҗатын үз әсәрләрендә менә ничек итеп оста файдаланып була икән! Мәңге өйрәнерлек «Идегәй» чалымнары бар бу әсәрдә.

Гомумән, Салих ага Батталның яшәү рәвеше дә, иҗат алымнары да, мирасы да гыйбрәт-сабаклар алырлык. Кодрәтле генга ия булып яратылу, җирне-күкне бер итеп дигәндәй, алыпларча яшәү, сөю-сөелү һәм гаилә фаҗигаләре, рухи маяк-ориентирлар билгеләгәндә ялгышулар, үзе инанган принциплар өчен кирәк-кирәкмәскә көч түгүләр… һәм финал — ялгыз картлык (ни кызганыч, күктә очып янмаган, җирдә батмаган Салих ага ятакта, җылыткыч рефлектордан одеалына ут кабып, ис һәм ялкыннан буылып үлде)…

50 нче елларда әдәбият каһарманы булган Салих Баттал, гомеренең икенче яртысында элек алынган иҗади темпны саклый алмады. Совет-партия системасы корган күпсанлы барьерларны җиңәргә тырышып бихисап вакыты әрәмгә китте аның. Ахырда, Вакыт һәм Система баш бирмәс Батталны да «почмакка терәде». Бирелүен бирелмәде Баттал, әмма кирәкмәгән ыгы-зыгы аның иң кадерле вакытын ашады, иҗат көчен таркатты, талантының тиешенчә үсүенә ирек бирмәде… Ул гына да түгел, заман идеологиясе басымы сәбәпле, әдипнең иҗаты тиешенчә өйрәнелмәде һәм бәһаләнмәде. Әдип иҗатын җитди өйрәнгән фәнни хезмәтләр юк дәрәҗәсендә.

Замандаш каләмдәшләренең күбесе аңа битараф булдылар. Күпләр әдип гамәлләрен эчтән генә хупласалар да, аның белән ачыктан-ачык фикердәш булудан курыктылар. Дөрес, бик сирәк булса да, үзе исән чакта ук, аңа уңай мөнәсәбәт белдерүчеләр дә табылды. Мәсәлән, 1990 елда А. Гыйләҗев матбугатта язып чыкты: «Кичерә алсаң, кичер Салих ага! Без синең арттан килүче, аз-маз кыен ашаган кешеләр дә сиңа терәк була алмадык! Безгә сабак, бездән соң килүчеләргә акыл бу!» Икенче бер зур әдип И. Нуруллин «Казан утлары»нда (1993) болай дип чыгыш ясады: «Салих

Батталның, шагыйрь буларак, бүгенге көнгә кадәр тәнкыйтьтә үзенең тиешле бәһасен алганы юк. Мин, шәхсән, совет чоры поэзиясеннән өч шагыйрьнең исемен атагыз, дисәләр, Такташ, Туфан, Салих Баттал, дияр идем».

Үзе исән вакыттагы кебек, хәзер дә аның иҗаты турында каршылыклы фикерләр ишетелә. Менә кичә-бүген генә әйтелгән кайбер яңа искәртүләр. «Безнең заман герое» дигән бәхәс уңаеннан Айдар Хәлим болай яза: «Безнең диссидентыбыз — бердәнбер диссидентыбыз — бөек шагыйребез Салих Баттал иде… Татар шагыйрьләренең Тукайдан кала беренче бишлегенә керә торган сирәктән-сирәк шагыйрь». Ә тәнкыйтьче Р.Мостафин, аңа каршы килеп: «…һич тә бөек дип атап булмый. Шигъри осталыгы чамалы, метафоралары сай, поэмалары артык озын һәм күбесенчә коры сөйләмгә корылган. Беренче бишлеккә түгел, егерменче бишлеккә дә керүе шикле» («Казан утлары», 2005, 5 сан).

Менә шулай… Хәер, кем ни сөйләмәс! Атаклы җырчы Рафаэло турындагы фильм исеме искә төшә: русчасы —«Пусть говорят». Сөйләнсеннәр сәнә! Әдәбиятчы галимнәргә кайсы тишеккә, гафу, кайсы бишлеккә кертәсе турында баш ватканчы, әдипнең мирасын җыеп тупларга, томлыкларын бастырып чыгарырга булышырга иде! Юбилей уңаеннан табигый бер сорау: кайда икән Салих Баттал архивы? Бармы ул? Булса, ышанычлы куллардамы? Әйтик, шагыйрьнең «Батый ханга хат» дигән поэмасының тулы варианты кайда икән? 80 нче елларда Себердә чыга торган «Байкал» журналында кыскартылган тәрҗемә варианты чыккан иде. Үз телебездә басыла алмады шикелле ул поэма. Гомумән, С.Баттал иҗаты белән бәйләнешле сораулар байтак, һәм алар әледән-әле чыга тора. Яшәве гадәти, иҗаты шома булса, бәлки, сораулар, каршылыклы фикерләр азрак булыр иде.

Алда әйтеп үткәнчә, С. Баттал иҗаты бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Төрле елларда аз-маз күренгәләгән мәкаләләр, нигездә, юбилей даталары уңае белән язылганнар. Р. Мостафинның шактый кискен сүзләреннән соң мин, кулым җиткән кадәр, С. Баттал турында моңарчы язылганнарны барлап чыктым. Әллә, мин әйтәм, шагыйрь иҗатын кирәгеннән артык бәялимме (чыннан да, С. Баттал иҗатында бәйләнерлек нәрсәләр җитәрлек!)? Бүтәннәр ни уйлый? Үзебезнең журналда моннан ун ел элек әдип турында мондый сүзләр укып тынычландым тагын. «Салих Баттал — егерменче гасыр татар әдәбиятының иң мәртәбәле олы исемнәреннән берсе саналырга хаклы. Ул — безнең чор тормышын бөтен каршылыклары белән тулы чагылдырган күпсанлы шигырьләр, поэмалар, шигъри һәм чәчмә повестьлар, драма әсәрләре авторы. Ул, барыннан да бигрәк, халкыбыз, аның милләт буларак яшәве өчен иң кыен чорларда да каһарманнарча көрәшкән бунтарь, үзе дә легендага әверелгән зур шәхес» (редакцион кереш мәкаләдән өзек).

Язмамны Вазыйх атлы агайның Зур Тигәнәле (кайбер язмаларда Олы Тигәнәле дип йөртелә) авылында туып үскән өч улы турында әйтеп башлаган идем. Алда искәрткәнчә, бер улы — Абдулла дигәненең 1944 елда Җәлилләр белән бергә башы киселә. Салих абый моннан ун ел элек вафат булды. Мөбарәк дигәне — татарның атаклы гобойчысы — әле исән дип беләм. Күреп танысам да, уйнавын ләззәтләнеп тыңласам да, шәхсән таныш түгелмен. Азмы-күпме аралашканым Салих ага булды. Ул чак яшьрәк булганмынмы, әллә акыл шәрифләре җитеп бетмәгәнме, аның белән дә аз очрашылган. Күп нәрсәләрне сораштырасы калган да бит!.. Шулай да Салих ага Баттал турында кайта-кайта уйланылган икән! Аңа бәйләнешле моннан 12 ел элек язылган истәлек язмам да бар. Бүгенге сүзләремә өстәп, анысын да укучыларга тәкъдим итәм. Кемнәргәдер, бәлки, гыйбрәтле булыр.

*2005, июнь*

* * *

«Мин монда бер булган идем күк...» дигән шикелле, бу кульязманың тулырак вариантын (беренче нөсхәсе иде шикелле) егерме еллар элек бер күреп калган идем инде. Ни өчен күреп кенә калганмын? Эш болай булды. 1973 елның мартлары. Язучылар союзында җаваплы сәркатип (хәзергечә — рәис урынбасары) булып яңа гына эшли башлаган көннәр. И. Гази кинәт үлеп киткәннән соң, идарә рәисе булып З. Нури эшләгән дәвер бу. Көннәрнең берендә Зәки абый: «Бу папканы син дә карап чык әле!» — дип, кулыма шактый ук күләмле бер кульязма тоттырды. «Салих Батталныкы бу. Мәскәү редакциясеннән җибәргәннәр (кайсы редакциядән икәнлеге хәтердә калмаган). Әсәрне оешмада тикшереп, авторга фикер җиткерүебезне сораганнар, мондый әйберне без баса алмыйбыз, дигәннәр». Эш бүлмәмә алып чыгып карый башладым. Сәер язма. Урыс телендә. Титул биткә Салих Баттал дип түгел, Иванов Иван Иванович дип куелган. Исеме — «Я отрекаюсь (исповедь)». Кульязманың бер битендә газета-журналлардан алынган вак-вак кисемтәләр җилемләнгән. Кызыксынып укып киттем. Бәй, без укып күнеккән публицистика түгел икән бит бу! Кайбер абзацлары сискәндереп үк җибәрә.

Ай-һай хәтәр юллар, баш китәр фикерләр! Мондый уйлар күпмедер дәрәҗәдә безнең һәммәбездә дә бар барын... Тик болай итеп әйткән юк та, яза алган юк. Кара, без алтын манаралар итеп күргән

офыклар рәшә-мираж гына түгелме соң? «Безнең иман — коммунизм!» дип басып торган нигезебез, мәрмәрдәй нык өслелектән бигрәк, тымызык бер сазлык кына түгелме соң?

Шул ук көнне идарә утырышы булды, соңрак бүлмәмә Илгиз Хәйруллин килеп керде. Партия өлкә комитетының культура бүлеге инструкторы, бүлекнең иҗат оешмалары белән эш итүче кураторы иде ул. Әзрәк сөйләшеп утырдык. Минем «җаваплы урында яңа кеше буларак» эшләрем белән кызыксынды. Өстәлдә ачык килеш яткан кулъязма да күзгә төртелде. (Ул вакытта андый әйбернең күз төшәрлек җирдә түгел, өстәл тартмалары тирәсендә торуы яхшырак булгандыр, бәлки.) Кулъязманы кулына алып, кайбер битләренә күз салгач, ул да тәэсирләнеп, кызыксынып китте. Бәлки, З.Нури аңа әлеге әсәр турында алдан әйткән дә булгандыр? Тик анысын тәгаен белмим. «Кая, мин дә укып чыгыем әле!» — диде ул. Хәзер кайтып уйлап карыйм: бирергә тиеш идем микән мин ул кулъязманы? Шунысы шиксез: әүвәл, әлбәттә, үземнең укып чыгуым кирәк иде! Партиянең өлкә комитеты вәкиле кызыксынгач, аның укып алуы ул заман этикасы өчен табигый нәрсә иде. Җитмәсә, Илгиз — замандаш, күп нәрсәләрдә фикердәш, әдәбият-сәнгатьне, кешеләрне яхшы белә. Төрле оештыру эшләрендә гел киңәшеп эшлибез... Болары — шулай шулаен. Кызганычы шул: кулъязма миңа бүтән әйләнеп кайтмады, 20—25 битен укыган килеш өзелеп калдым. Дөрес, атна-ун көннән соң кире сорап карадым мин аны. «Ул папка хәзер Вәлиевтә»,—дип җавап кайтардылар. (М.Вәлиев — Брежнев хакимияте чорында байтак еллар Татарстан партия өлкә комитетында идеология буенча секретарь булып эшләде. Тарих фәннәре кандидаты. 1993 елда вафат.) Укырлар да әсәрне Союзга кайтарырлар дип йөрдем. Әмма мондый наив ышанычым юкка булган. Кулъязма КГБ киштәсенә барып кунаклаган икән. Берәр айдан соң Бауман урамындагы Союз катларында әлеге оешма хезмәткәре капитан Хуҗахмәтов пәйда булды. Базык гәүдәле, башкорт чырайлы, ипле генә татарча сөйләшә торган кеше иде ул. («Иде» диюем дөрес үк булмас: ул соңрак Казаннан Түбән Камага китеп эшләде, хәзер, мөгаен, пенсиядәдер.) Хуҗахмәтов миңа турыдан-туры болай диде: «Салих Батталның кулъязмасын Язучылар союзы КГБ карамагына тапшыра» дигән белешмәне басып, кул куеп бирегез!» — «Андый язуны бирә алмыйм, чөнки сез эшләгән оешмага бернинди кулъязма биргәнем юк»,—дидем. Ул кабат миңа нәрсәдер әйтте, аннары дивана затка караган кебек карап торды да беркавым, күршедәге рәис бүлмәсенә кереп китте. З. Нури ялдамы, командировкадамы булып, аның вазифасын вакытлыча Гази Кашшаф башкара иде. Эшне тиз тоттылар алар. 15—20 минуттан кирәкле белешмәне машинистка ханым басып та бирде. Гази ага кушканны бик тиз үти белде. Авыр туфрагы җиңел булсын!.. Шулай итеп, кем маллары кая китми дә, кемнәргә генә барып җитми икән... Күңелдә авыр тойгы калдырды бу вакыйга. Вакыт-вакыт гел искә төшеп җанымны кыйнады. Авторда яки дусларында берәр нөсхәсе сакланып калды микән? Бу аяныч вакыйга турында сер сыйган каләмдәшләремә дә әйткәләгән чаклар булды. Ни дисәң дә, бу әсәрнең эзсез югалуында минем дә өлеш бар бит! Минем кулымнан да үтте бит ул. «Гаепсездән гаепле генә син» дип үземне юаткаласам да, әрнүле хис барыбер калды. 1989 елның ахырында бу әсәр турында Салих абыйның үзеннән дә сораштым, әмма ул, көлемсери төшеп, «кайчандыр бер язган идем бугай» дип кенә җавап бирде һәм сүзне бүтәнгә борды... Мин ирексездән 70 нче еллар ахырында аңа багышлап язган (соңрак китапларда да басылды) дүртьюллыгымны кабатлап куйдым:

...Бу дөньяда шуыша да
белми бит ул, булмаган!
Ул очар өчен туган шул,
сөйрәлергә тумаган!

Шулай да моның белән генә бетмәде әле бу әсәр тарихы. Яшьлектә бер югалтып, соңрак янә табылган кадерле кеше шикелле, язмыш кабат очраштырды мине бу кулъязма белән. 1993 елның сентябрь аенда, «Идел» журналында утырганда, баш мөхәррир өстәлендә икенче данәсе ята иде. «Кайдан? Ничек? Кемнән?» кебек өзек-өзек дулкынланып әйткән сорауларыма Фәиз Зөлкарнәй тыныч кына: «1994 елның башында басып чыгарырга әзерлибез»,—дип җавап бирде. Бу әсәрне мин моннан егерме еллар элек белгәнемне, югалту тарихына «өлеш керткән шаһит» булуымны ишеткәч, ул минем шул хакта кереш сүз итеп язып бирүемне үтенде. Бу юллар шуңа җавап рәвешендә язылдылар да инде.

Сүз уңаеннан өстәп шуны гына әйтәсе килә: ачылып, өйрәнелеп, бәһаләнеп бетмәгән олуг шәхес, олуг талант иясе ул Салих ага Баттал. Якты дөньяда 90 нарга хәтле камил акыл белән яшәп, шул гомеренең 60 елдан артыгын актив иҗатка багышласа да, аның иҗаты системалы рәвештә өйрәнелмәгән әле. Шагыйрь буларак та, проза остасы һәм драматург буларак та. Кем гаепле соң? Әлбәттә, үзе! Талант кадерен белә торган заманда туа белмәгән, тоталитар режимга яраша алмаган, вөҗданына хыянәт итмәгән, башын имәгән, сүзен бирмәгән... Ул заманның әдәби даирәсендә Ә.Еники «ялгыз каз» саналып йөртелсә, С. Баттал, үзе әйтмешли, «Тигәнәле тилесе» булып кала бирде. Замандаш каләмдәшләренә, ул заманның түрендә хөрмәттә йөргән чордашлары да, Салих ага

башына хакимиятнең идеологик чукмарлары төшкән чакта, аны яклап, саклап кала алдылар, дип әйтмәс идем. Күбесе читтә торды, «диссидент корымы» тиюдән сакланды. Әмма яшьләр (70 нче елларда әдәбиятка килгән буынны әйтәм) арасында аның дәрәҗәсе һәрчак зур булды. Нәрсә генә димәсеннәр, ул безгә легендар шәхес булып тоела иде. Ике метрлы мәһабәт гәүдә, кыю очучы, оригиналь язучы, оратор, җыелышларда түрәләрдән Се—Ге—Бе (ТАССР Югары Советы Президиумы председателе С.Г.Батыев күздә тотыла) сүзләре белән көлә ала торган шәхес... Дөрес, үз заманының аерым бер рухи күзәнәге буларак, режим юлбашчылары чыгарган теорияләргә, тәгълиматларга ихлас ышанып, утопик хыяллар белән рухланып, артык мавыгып киткән чаклары да булды әдипнең. Мәсәлән, ул үзен партиядән чыгаруны бик авыр кичерде. «Коммунист» төшенчәсе аның өчен изге булган, күрәсең. Партия сафларына яңадан торгызылу артыннан байтак йөрде ул. Ленин хезмәтләрен яхшы белде. Цитаталарны яттан сибә генә иде. Гасырларның байтак акыллары үз вакытында «яхшы патшага» ышанган кебек, Салих ага да Ленинга бик ышана, аның өйрәтмәләрен бозалар, шуңа күрә дә милли мәсьәлә дөрес бармый, дип, еш кына тәкрарлый иде. Хәер, кем белә! Бәлкем, ялгышамдыр. Талантның кодрәте чиксез, диләр бит.

*1993*

## ВӨҖДАНЫНА ТУГРЫ ӘДИП

Тулы бер гасырның буеннан-буена диярлек гомер кичеп, җисмән исән-сау, рухани сәламәт булып кала алганнарга хәйраннар калырлык. Гасыры да нинди бит! — гел катаклизмнардан гына торган диярсең. Сынган-сындырылганнар, югалган-югалтылганнар никадәр! Шулай да шөкер итә дә белик: вөҗданнарына хыянәт итмичә, иманнарын саклап, идеалларына тугры калган бөек шәхесләребез дә юк түгел. Бакый Урманче, Нәкый Исәнбәт... Алар рәтеннән бүген дә безнең арада үзгә бер дәрт белән иҗат итүче мәшһүр әдибебез Әмирхан Еники бар. Ихтимал, Рәсәйдәге яшәү рәвешенә, яшәү мохитенә нисбәтән Табигать биргән талант-сәләтләренең бар куәте ачылып ук бетә дә алмагандыр аларның... Хәер, булганы, иҗатының халыкка ирешкән кадәресе дә сокланырлык, таң калырлык. Милләтебез өчен Ходай саклагандыр аларны. Дөрес, «Сакланганны саклармын!» дигән гыйбарә дә бар. Әмирхан ага үзе дә гомере буе үз гамәленә үзе хуҗа булган зат. Сабыр-тыйнак кына, кабаланмыйча, очар биеклекләрне анык белеп, узгынчы сәяси-конъюнктур хәрәкәтләрдә буталмыйча, талантының кодрәтен, шәхес буларак үз дәрәҗәсен белеп яшәде, иҗат итте. Бу очракта чыгышы ягыннан мәгълүм ыру-токымнан, затлы нәселдән булуы да шактый ук әһәмиятле булса кирәк.

Һәр иҗатчы, телиме-теләмиме, таныймы-танымыймы, ул барыбер Вакыт галиҗәнаплары белән алышка чыккан зат. Чарасызлыкны, Вакыт кодрәтенә беркемнең, бернәрсәнең дә каршы торалмаганын белсә дә, Иҗатчы, Вакытның «ялына ябышып булса да», хезмәтләре белән Аңа үз исеме белән мөһер суга... Киләчәктә Идел-Урал тирәлегендә XX гасырның төрки прозасы турында сүз чыкса, иң беренчеләрдән булып Ә.Еники исеме телгә алыначак. Иҗаты һәм яшәү рәвеше белән килер буыннарга, бигрәк тә каләм ияләренә, бик тә кирәк әхлакый сабаклар да бирде Әмирхан агабыз. Шуларның берсе (гәрчә аксиома кебек мәгълүм булса да) — язучы нинди генә заманда, нинди генә шартларда яшәп иҗат итсә дә, вөҗданына тугры калып, көндәлек мәшәкатьләрдән өстен торып, тормыш дөреслеген язарга тиеш.

Бу — Аның язучылык кредосы, күпләр өчен өлге булыр сыйфаты. Тагын икенче бер гыйбрәтле сабак-нәтиҗә: хикәяләү, тасвирлау шигырь рухы белән сугарылмаса, чәчмә әсәр шигъри телле булмаса, чын проза әсәре юк ул. Әмирхан Еники — прозаның шагыйре ул.

Ә. Еники — олуг әдип, олуг фикер иясе. Ул инде бу фани дөнья хикмәтләрен күп күргән, кичергән, аңлаган кеше... Ни хикмәт, ул, кайбер «бар нәрсәне белгән» яшьрәкләрдән аермалы буларак, яшәү хәлләренә һаман гаҗәпләнә, теге яки бу хәлне аңларга тырышып гасабилана, икеләнә, киңәшләшә, үзенә һәм бүтәннәргә сораулар куя, борчыла, илдәге вакыйгаларны йөрәге аша үткәреп, үзенчә киләчәкне фаразлый...

Әмирхан Еники исән чагында данда коенып, иҗатына тиереннән артыгын алган (андыйлар да булды!) язучы түгел. Чын бәһасе киләчәктә алыначак әдип ул. Әмирхан учагы әле дөрли генә башлады.

*1999, 21 февраль*

## ОЛЫ ШАГЫЙРЬ, КИҢӘШЧЕ ШАГЫЙРЬ

Чор. Шәхес. Шагыйрь. Шушы өч төшенчә торган саен ешрак уйландыра. Безнең эшнең асылын аңлау, иҗатчының иҗтимагый кыйммәтен бәяләү фәкать шушы төшенчәләр, алар арасындагы эчке

бәйләнеш аша гына мөмкин. Әйе, хикмәт шушы бәйләнештә. Шуңа карап шагыйрьнең олылыгы, кешелеклелеге, батырлыгы, гражданлыгы беленә. Тумыштан талантлы кешеләр байтак. Шигырьгә дә сәләтле яшьләр, шөкер, килеп тора. Яхшы гына башлыйлар. Еллар үтә. Карыйсың, әйе, шомарган, чарланган, оста яза, ә әдәбиятта үз йөзе, үз эзе юк. Бу нидән? Баксаң, аның чорга, яшәешкә кеше буларак үз ачык мөнәсәбәте, үз иҗади платформасы юк икән, язганында үз шәхесе, үз гражданин «мин»е юк икән. Аның иҗат итүе, тырышуы — табигый булган беркадәр сәләтен ничектер эффектлырак итеп, үзен ничек тә даһилык чалымнары булган берәү итеп күрсәтергә генә тырышу икән! Бәхеткә каршы, бездә очраклы хәл һәм очраклы күренеш бу. Шагыйрьләр полкында, өлкәннәр арасыннан булсын, яшьрәкләр арасыннан булсын, чын мәгънәсендә талантлы, чорны аңлап, илнең шатлык-кайгылары белән яшәүче, үз фикере, үз сүзе булган, җанындагын яшерми-нитми кешеләр белән уртаклаша алучы гражданин шагыйрьләр байтак, һәрхәлдә, алар төп көч, шигъриятнең үсеш юнәлешен билгеләүче намуслы көч. Бу — Тукай, Җәлилләрдән килә торган традиция. Ә традиция үзеннән-үзе генә дәвам итми, үзеннән-үзе генә үсми. Аның үсеше өчен дә көрәшергә, даулашырга кирәк. Бу көннәрдә — татар совет поэзиясенең иң күренекле вәкилләреннән берсе Сибгат Хәкимнең иҗат бәйрәме көннәрендә — әнә шулар турында уйландым мин. Аның шигырь, поэмаларын тагын бер кат карап чыктым. Кулда булган публицистик язмаларын күздән кичердем. Әйе, олы шагыйрь безнең Сибгат агабыз, зур шәхес, үткәне, бүгенгесе, киләчәге бар әдип. Бүгенге поэзиябез гөмбәзен тотып торучы бер мәрмәр колонна-баганага тиңләргә мөмкин аның иҗатын. Традицияләр үсешенең яхшы үрнәкләре аңарда. Шагыйрь һәм шәхес буларак аның әдәбиятта абруе, хакимлеге зур. Шәкертләре күп. Әгәр безнең урта һәм яшь буын шагыйрьләре чор турында, шагыйрь турында, аның җәмгыятьтәге урыны турында җитди уйланалар, һәм бу уйланулар аларның иҗатларында чагыла икән, монда өлкән шагыйребез Сибгат ага шәхесенең, аның иҗатының шифалы йогынтысы аз түгел.

Сибгат Хәкимнең татар поэзиясендә, киңрәк итеп алганда, халыкның рухи тормышында тоткан урыны һәркемгә ачык, билгеле хакыйкать. Татар совет поэзиясенең сугыштан соңгы үсеш юлларын өйрәнүче һәр әдәбият белгече аның иҗатына мөрәҗәгать итми кала алмый. Сибгат Хәким иҗаты турында диссертацияләр, байтак диплом эшләре язылган, мәкаләләр, иҗади портретлар тудырылган, алар алга таба да булырлар. Әлбәттә, иҗатының төп асыл сыйфатларын калкурак күрсәтә торганнары, шагыйрьнең иҗат лабораториясе серләрен ачарак төшә торганнары күбрәк булыр. Миңа шагыйрьнең бу юбилей алды көннәрендә, аның турындагы гыйльми хезмәтләрдән бигрәк, шагыйрьләрнең аңа багышлап язылган шигырьләрен күздән кичерергә туры килде. Кызык, кемнәр генә аңа багышлап язмаган! Х. Туфан, Н. Арсланов, Н. Дәүли, Н. Нәҗми, Г. Афзал, Х. Камал, Ә. Баян, С. Сөләйманова, Р. Гәрәй... Боларга күпсанлы яшь һәм башлап язучы шагыйрьләрнең дә Сибгат Хәкимгә багышланган язмаларын өстәсәң, аның үзенең самими җырларын, шигырьләрен укып һәм тыңлап моң һәм дәрт алган бихисап күп укучыларның аңа карата булган рәхмәт сүзләрен җыйсаң, тулы бер китап, антология килеп чыгар иде. Юк, бу заказ биреп яки кушып яздыру түгел, — күңелгә боерып булмый. Бу — халыкның үз улына, үз җырчысына табигый мәхәббәте. Бу — ил мәхәббәте.

Сибгат Хәким яшь һәм башлап язучы шагыйрьләргә иң якын торган өлкән шагыйрь. Бу бүтән аксакал шагыйрьләр яшьләр белән якын мөнәсәбәттә түгел икән дигән сүз түгел. (Киресенчә, әгәр бүгенге поэзиябезнең кайбер уңышлары бар икән, ул, һичшиксез, төрле буын шагыйрьләренең органик дуслыгына бәйләнгән.) Үзләренең бай тәҗрибәләрен һәрчак уртаклашырга, киңәш бирергә, булышырга әзер киң күңелле шагыйрь әдипләребез бар. Ләкин шулар арасында Сибгат ага аерым урын тота. Соңгы ун-унбиш ел эчендә әдәбиятка килеп, Сибгат аганың булышлыгына һәм ярдәменә юлыкмаган берәр талантлы шагыйрь бармы икән? Мөгаен, юктыр. Чын дуслык араларның тигезлеген ярата, үзара мөнәсәбәтләрнең тугрылыгына нигезләнә. Әгәр С. Хәким үзенең иҗаты һәм кылган игелекле эшләре белән яшьләр иҗатына уңай тәэсир итә икән, үз чиратында яшьләр дә өлкән шагыйрьне яшәртәләр, иҗатына дәрт һәм яшьлек өстиләр кебек миңа. Чөнки С. Хәким һәрчак яшь талантларның үзәгендә, ул бүгенге Тукайларны эзли; шуңа да сәләтле каләм ияләренең баштагы иҗатлары бөтенләе белән диярлек Сибгат ага аша уза. Ә инде нурлы һәм мәгънәле шигырь синең күңелең аша үтә икән, ул сине зурайтмыйча, баетмыйча кала алмый.

Соңгы җиде-сигез ел эчендә әдәби хәрәкәткә беркадәр катнашып килү миңа бер хакыйкатьне танытты. «Бу халыклар аралашкан зур чор»да, һәр кешенең җәмгыять алдында тау кадәр җаваплылыгы булган заманда, шагыйрьне чын-чыннан аңлау өчен шигырен уку гына җитми, аның үзен, шәхесен дә белергә кирәк, көндәлек иҗтимагый эшләренә дә шаһит булу кирәк икән. Яшермим, унсигез-унтугыз яшьлек студент вакытта минем С. Хәким шигырьләренә мөнәсәбәтем бераз үзгәрәк иде. Миңа аның шигырьләре артык басынкы, моңлы, артык гади тоела иде. «Англиягә барып кайт син, диләр» шигыре аңлашылмаган каршылыклы сәер тойгылар уяткан иде... Әгәр ун елдан соң әдипнең иҗатына карата фикерләр үзгәргән икән, гаҗәп түгел, һәм шул ук вакытта мин иртә яшьлегемдәге әлеге халәтемнән, уйларымнан да баш тартырга яки, ялгышканмын икән, дип әйтергә дә җыенмыйм. Яшьлекнең үз логикасы. Әдәбиятка ашкынган яшь җанның теләге аңлашыла. 60 нчы еллар башында совет әдәбиятын яңа үрләргә күтәргән төрле милләт язучылары Ч. Айтматов, Р. Гамзатов, Э. Меже-

лайтислар бөтен дөньяга яңгырап алганда, күп гасырлык традициясе булган татар әдәбияты вәкилләрен дә шулар рәтендә күрәсе килүдән, исән татар шагыйрьләренең дә авазлары Җәлилләрнеке кебек бөтен дөньяга яңгырауларын ишетәсе килүдән уянган хисләр алар. С. Хәкимнәрне дә Англияләрдә йөртеп кайтарасы килүдән туган хис, бүтән халыкларны да баета торган яхшыны, гүзәллекне күбрәк таратасы килүдән туган хисләр иде... Хәзер исә С. Хәкимне иң алдынгы һәм күренекле совет язучыларының берсе дип саныйм. Моны мин аның бай иҗатын, көндәлек әдәби тормыштагы эшләрен, халык күңеленә йогынты ясау дәрәҗәсен — барысын күз алдында тотып әйтәм. Безнең һәрберебездә гүзәллекне тагын да күбрәк күрергә теләү хисе яши. Бу нәфес эше генә түгел, бу — табигый хис. Ләкин һәр үрнең, биеклекнең чиге бар. Бу рухи тормышта да шулай. С. Хәким биеклеге — халыкның рухи биеклеге дәрәҗәсендә. Ә безнең халыкның рухи биеклеге — югары биеклек.

Сибгат Хәким иҗаты соңгы елларда тагын да күтәрелебрәк, шәбәебрәк, күпкырлырак булып китте. Бу хәл — ил-йортның сау-имин торуының, тормышыбызның көннән-көн ямьлерәк, баерак була баруының, әдәбиятыбызның һаман өскәрәк үрләве һәм аның өметле киләчәге булуының, ниһаять, шагыйрьнең үзенең тәмам зур оста булып җитешүенең, эшенең, хезмәтенең бөтен ил күләмендә тәкъдир ителүенең һәм тагын күп факторларның уңай нәтиҗәсе. Сибгат ага шигъриятенең офыклары киңәю белән бергә, аның публицистикасы да үткенрәк һәм куәтлерәк була башлады. Әдәби хәрәкәт яки каләмдәшләре хакында язган мәкаләләре, чыгышлары, истәлекләре торган саен мәгънәлерәк, кирәгрәк һәм әдәбият өчен зарури ихтыяҗлы була баралар. Әле яңа гына басылган С. Хәкимнең «Күңелдә юылмаган эзләр» исемле истәлек-язмаларын дулкынланып укып чыктым. Ул шигырь дә, сагыш та, сафлык та, кисәтү дә...

С. Хәким үзенең бөтен вөҗүде белән Тукайга бәйле шагыйрь. Туган ягы белән дә, иҗаты белән дә. Ул шагыйрь турында заманында «Шагыйрьнең балачагы», «Пар ат» исемле поэмалар язган булса, хәзер исә бөек шагыйрьнең Казанда яшәгән чорын тасвирлаган яңа зур әсәр тәмамлады. Әгәр «Татар поэзиясендә Тукай традицияләрен кемнәр дәвам иттерә?» — дип сорасалар, һич икеләнмичә, беренче итеп С. Хәким исемен атар идем. Әгәр Тукай үзе хакында «Мин... коеп куйган шагыйрь генә түгел, мин — дипломат, политик, җәмәгать эшлеклесе дә бит...» дигән булса, шагыйрь С. Хәким турында да шушы ук сүзләрне әйтергә мөмкин.

...Иртәнчәк яки кичкырын Казанның үзәгендә — Ирек мәйданы, Ленин бакчалары тирәләрендә — урта буйлы, башын үзенә генә хас бер горурлык белән югары тотып, салмак кына атлаучы шагыйрьне очратырга мөмкин. Ул уйланып йөри. Ә шагыйрь өчен уйланыр нәрсәләр күп. Бәлкем, беренче күргән кешегә ул йомшак табигатьле, басынкы, сабыр, хәтта беркадәр юаш кебек күренергә дә мөмкин. Ә асылда һич юаш, йомшак түгел, иң дөресе — нык ул, усал ул безнең Сибгат ага! Ул гаделсезлеккә, хаксызлыкка усал, халык күңелен олыламаучыларга усал. Әдәбиятны кәсеп итеп караучы халтурщиклар моны белеп торсын. Сабыйларча саф күңелле кешегә, нечкә күңелле шагыйрьгә, икмәкнең һәм тирнең ни икәнен бик яхшы белгән җир кешесенә, солдатка, җәмәгать эшлеклесенә, кирәк чакта, чак кына усал булу килешә ул. Хаклыкны эченә җыеп та, эндәшмичә, йомыкый яшәүче йомшак кешеләргә караганда, үз хәленчә хакыйкать сагында торучы гадел усал кешеләр күбрәк кирәк бу тормышта.

*1977, ноябрь*

## ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ҖИТДИ ХЕЗМӘТ

Китапның тышлыгында ике исем: Рафаэль Мостафин. Сибгат Хәким. Әдәбиятта, гомумән рухи тормышыбыз елъязмасында яхшы мәгълүм: хезмәтләре белән ерак-ерак төбәкләргә билгеле исемнәр болар. Аларның һәркайсының иҗаты турында аерым китаплар чыгарырга мөмкиндер. Киресенчә, С. Хәким дә Р. Мостафин иҗаты турында төпле сүз әйтә алыр иде. Ә менә бу юлы әле киресенчә: башта өлкәннәрнең хезмәтен таныйк, бәялик дигәндәй, күренекле галим-язучы (журналист-язучы дисәк тә дөреслеккә туры килә) Рафаэль Мостафин шагыйрь Сибгат ага Хәкимнең тормышы һәм иҗат юлы турында китап язып, аны Мәскәүдәге «Советская Россия» нәшриятында «Совет Россиясе язучылары сериясе»ндә бастырып чыгарды. Китап рус телендә, күләме биш басма табак чамасы, 125 бит, тиражы 10 мең.

Сибгат Хәким — телдә күп тибрәнгән, язуга күп төшкән исем. Сугыштан соңгы утыз-утыз биш ел эчендә аның иҗатын гел уңай яктан гына диярлек бәяләгән дистәләрчә мәкаләләр басылды. Без бу хәлгә — уңай бәяләүләргә күнектек тә шикелле инде. 1971 елны шундый мәкалә-чыгышларны берләштергән «Сибгат Хәким» дигән библиографик характердагы бер китап Казанда да басылган иде. Татар «Сибгат Хәким»ендә авторлар саны шактый ишле һәм төрле булып, китапның рухы үзгә һәм стиле дә төрлечәрәк иде. Ә монысының авторы бер, язылу вакыты да шактый ук конкрет. Тагын шунысы да бар: үз Казаныңда татарча чыккан китапны үз өендәчәрәк, үзең белгән таныш укучыларың белән бергәрәк торып һәм уртак югарылыктан чыгыбрак укыйсың, хөкем итәсең. Ә инде бүтән телдә, бу очракта рус телендә чыккан хезмәт, аның кайларга таралуын һәм укучылар контингентын

истә тотып булса кирәк, бүтәнчәрәк күз белән укыла. Ирексездән бүтән әдәбиятлардагы хәлләр, үрнәкләр белән чагыштырасың һәм... әйтергә кирәк, үз әдәбиятыңдагы теге яки бу күренешне дөресрәк бәяли башлыйсың.

«Йөзгә-йөз торганда, чын йөзне күрмәссең» дигәнрәк бер тәгъбир бар. Р. Мостафинның бу китабы белән танышкач, шул әйтем искә төште. Чыннан да, Сибгат аганы, аның тормыш юлын, иҗатын шактый ук яхшы беләм дип йөри идем мин (заманында аның турында матбугатта мәкаләләр белән дә чыкканым булды). Юк, алай түгел икән! Ул катлаулырак, тирәнрәк, бүтәнрәк икән! Китаптан алган беренче тәэсир әнә шундый булды. Бу әле бергә-бергә иҗат иткән, бер Казанда бергә дөнья көткән каләмдәше алган тәэсир. Ә рус һәм бүтән халыкларның киң катлау укучылары өчен Сибгат Хәким дигән шагыйрь бөтенләй үзгә, хәтта өр-яңа булып ачылуы да мөмкин бит әле! Димәк, әлеге тойгының тагын да зуррак һәм тәэсирлерәк булуы бар. Рафаэль Мостафин — журналист каләмле язучы. Укучының күңелен яхшы тоеп эш итә, фикерен ачык һәм җиңел формаларда җиткерә белә торган язучы. Ул — төпле тәнкыйть мәкаләләре белән беррәттән документаль нигездә язылган әсәрләр остасы да. Муса Җәлилгә багышланган популяр китаплары, «Экваторлар аша» дигән сәяхәтнамә повесте һәм башкалар моңа ачык дәлил. Журналист-язучы һәм документаль-популяр әсәрләр авторы буларак, ул безнең әдәбиятыбызда кабатланмас матур бер урын алып тора. Р. Мостафин — өйрәнеп-белеп яза һәм алынган материалына чын мәгънәсендә мөкиббән китеп иҗат итә торган автор. Аның бу сыйфаты әлеге монографик китабында да ачык күренә. Автор мөмкин кадәр (әлбәттә, кеше күңеленең бөтен нечкәлекләрен белеп бетереп булмый!), шагыйрьне баштанаяк, энәсеннән җебенә хәтле өйрәнергә тырышкан. Шагыйрь шәхесенә аның ихтирамы зур, шагыйрь язганның күбесе аның күңеленә хуш һәм якын. Бу хөрмәт хисе һәр абзацта, һәр биттә сизелеп тора. Китап кече күңеллелек белән, зур такт саклап язылган. Шагыйрьнең кайбер әсәрләрен беркадәр тәнкыйть иткән очракта да, автор йомшак тон сайлап, теге яки бу җитешсезлекнең асылын ачканда, аны, шагыйрьнең үзенә кайтарудан бигрәк, шул заманның рухи атмосферасына бәйләп аңлатырга тырыша.

Китап кечерәк-кечерәк егерме бер бүлектән тора, бүлекләр аерым уйлану-эссе рәвешендә язылганнар. Теләсә кайсы бүлекне аерым алып укыганда да, төп мәгънә-фикер ачык аңлашыла, өзеклек сизелми, һәр бүлек шагыйрь тормышының бер этабын яки иҗатының бер ягын ача. Автор шагыйрь турындагы төп фикерләрен әнә шулай «төйнәп-төйнәп» бер төзек хикәяләр мәрҗәне итеп тезгән.

Һәр иҗатчының, һәр язучының чын бәясе халык рухына йогынтысының дәрәҗәсе белән билгеләнә. Халыкта матурлык тойгысын арттыру, фикерләвен-үзаңын үстерү, көч-дәрманын кешелек идеалларына хезмәт иттерергә юнәлтү... Әлбәттә, мондый миссияне башкарыр өчен әдипкә, талантлы булу белән бергә, халык, ил тормышының иң үзәгендә тору шарт. Үзең яшәгән дәвернең чын мәгънәсендә замандашы, аваздашы, фикердәше һәм көрәштәше булу шарт. Хәтта, алай гына да түгел, син үз заманыңнан ярты күкрәккә генә булса да алда да барырга тиешсең әле! Юкса сиңа иярмәячәкләр. Ә әйдәүче булыр өчен сиңа ышанулары кирәк. Ә ышанычны ничек яулыйлар соң? Халык белән булып, аның тормышы белән яшәп, шатлык-кайгысын бергә бүлешеп. Сибгат Хәким исә үз халкының язмышында «эрегән» әдип. Р. Мостафин шагыйрь биографиясенең һәм иҗатының халык тормышыннан аерылгысыз икәнлеген һәм шушы аерылгысызлык, бердәмлек — аның яшәү һәм илһам чыганагы икәнлеген бу китабында тагын бер кат раслый.

Сибгат Хәким биографиясе — ул безнең халык вәкиленең, хезмәт иясе баласының соңгы илле-алтмыш ел эчендәге типик биографиясе. Крестьян улы, балачагы һәм яшьлеге авыл табигатендә, киеренке хезмәт атмосферасында үткән, аннан — рабфак, педагогия институты, Ватан сугышы... «Заман белән сөйләшеп яшәргә омтылганмын, — дип язды Сибгат Хәким соңрак үз иҗаты турында, — сөйләшү өчен урын бар: сүз арасына үзенең фаҗигаләре белән сугыш килеп кергән, югалтулар ачысы, төзелеш мәйданнары, яңа буын кешеләре, туган илнең табигате, бәхәсләре, шатлык һәм әрнүләре... Минем өчен иң кирәге — халык рухы. Минем өчен иң авыр, ирешү иң читен нәрсә — һаман шул тирәдә яткан уйлар... Шуңа кайчан да булса бер ирешергә омтылу хисе яздырта шагыйрьне...»

Кайчан да булса бер ирешү... Халык рухын аңларлык, аңларлык кына түгел, аның җырчысы булырлык шагыйрь дәрәҗәсенә кем кайчан ирешә? Тукайлар, Такташлар, Җәлилләр бу югарылыкка үсмер чакта ук ирешсәләр, икенче берәүләр исә чәчләре чалара башлагач кына күтәреләләр. Бу процессны шәхси теләк яки тырышлык белән генә аңлатып булмый, хикмәт талантның үзенчәлегендә. Сибгат Хәкимне дә зур поэзиягә иртә килде дип әйтеп булмый. Беренче юка китапларын утыз яшенә кадәр чыгарса да, чын мәгънәсендә җитлеккән шигырьләре шактый озак еллар үткәч кенә язылды. Шуңа күрә дә шагыйрьнең 1976 елны Казанда чыккан сайланма шигырьләренең бер томлыгында башлангыч ун-унбиш елдагы иҗаты бик аз урын алган. Кемнәрдер зур Сибгат Хәкимнең башлануын «Пар ат»тан саный, кемнәрдер «Суд залыннан» исәпли... Р. Мостафин да Сибгат Хәкимнең иҗат эволюциясенә шактый киң туктала, чагыштырмача озак өлгерүенең сәбәбен ачыкларга тырыша. Китабының бер урынында телдә йөргән мәгълүм караш-теорияне дә искә төшереп үтә: «...иҗатчы өч стадия үтә. Башта ул чынбарлыкны танып белә, күрә, кичерә; аннан ул аларны «оныта», соңын-

нан күңеле аша яңадан искә төшерә». Иҗади өлгерүне беренче күргән, тойган тәэсирләрне яңадан искә төшерү аралыгы белән билгеле. Ихтимал, бу караштa да дөреслек бардыр, әмма бүтән төрле сәбәпләрнең дә булуы мөмкин. Талантның ачылу хикмәтләрен, судагы балыкның, һавадагы кошның юлын белеп булмаган кебек, аңлатуы авыр. Сибгат Хәким иҗатының башлангыч елларында сүлпәнрәк эшләсә, аның каравы ул соңгы егерме-егерме биш ел эчендә ат кебек эшләде. Бу хакта сүз куерту, зур әдипнең үзеннән бигрәк, бүгенге әдәби хәрәкәттәге яшьрәк кешеләргә карый. Яшьтән җиң сызганып эшләп калу хәерлерәк. Иртә торсаң, ит пешә, соңга калсаң, бит пешә, ди халык. Сер түгел бит: дөньяда һәрвакыт системалар арасында, илләр-халыклар арасында ярыш бара. Ә инде иҗат эшендә, сәнгатьтә, әдәбиятта, эстетик казанышлар сферасындагы ярыш ул — иң гуман ярыш, кешелекле ярыш. Дөнья алдан юл ярып баручыларны, «беренче эшелон»дагыларны таный, иң әүвәл аларга соклана, аларны күтәрә. Сабан туенда иң артта килгән атка да игътибар зур зурын, әмма әдәбиятта кануннар бүтән. Сибгат Хәкимнең «дөньяда Пушкин бар, Пушкин бар!..» дигән юллары бар. Әйе, дөньяның тагын Лермонтовлары, Петефилары, Тукайлары бар... Сибгат аганың тагын мондый юллары да бар бит әле: «Беренчеләр мине сагындыра, беренчеләр минем истә гел». Кыскасы, әдәбиятка мөмкин кадәр иртәрәк килсәң, заманың өчен күбрәк кирәгең булуы мөмкин.

Китап рус телендә язылып, шул телдә укучылар өчен чыгарылгач, табигый, шагыйрь иҗатының үрнәкләре дә, өзекләр һәм цитаталар рәвешендә, тәрҗемәдә бирелгәннәр. Авторның шагыйрь иҗаты турында әйтергә теләгән күп фикерләре дә әлеге шул тәрҗемә мисаллар белән беркетелеп барыла. Шулай булгач, тәрҗемәнең нинди дәрәҗәдә булуы бу очракта ифрат зур роль уйный. Шуңа күрә китапта Сибгат Хәкимнең тәрҗемә китаплары һәм тәрҗемәчеләре турында аерым бер бүлек булуы бик урынлы. Милли әдәбиятларның үсешен һәм язмышын хәзер тәрҗемә эшеннән башка күз алдына китерүе кыен. Тәрҗемә эше — дәүләт күләмендә әһәмиятле бер эш. Һәр эшнең асылы сыйфат белән билгеләнә. Тәрҗемәдә дә шулай. Бүтән милләт укучылары күңеленә бәйрәм китерә алырлык байтак поэтик ачышлар тәрҗемә начар булу сәбәпле югалып кала. Кагыйдә буларак, тәрҗемә оригиналдан кайтышрак чыга. Бу җәһәттән Сибгат Хәким мисалы шактый гыйбрәтле. Аның тәрҗемә китаплары мисалында бездәге поэзия тәрҗемәсе эшенең гомум торышын, уңай һәм кимчелекле якларын чамаларга була. Бер яктан караганда, С. Хәкимнең бу җәһәттән эше яхшы бара кебек. Ул, Хәсән Туфан яки Нури Арсланнар кебек, бу эшне үз агымына куйган кеше түгел, тәрҗемәгә нык игътибар биреп, рус телендә күп китаплар чыгарган шагыйрь. Русчада чыгару ягыннан аны безнең поэзиядә Тукай, Җәлил, Ерикәйләрнең китаплары саны белән генә чагыштырып була. Исән татар шагыйрьләреннән рус телендә иң күп басылган бердәнбер кеше. 1947—1977 еллар арасында аның русча егерме китабы чыккан. Шуның сигезе — Казанда. Аларның барлык тиражы — 308 мең чамасы. Шигъри әсәрләр өчен шактый зур сан бу. Ихтимал, тиешле дәрт, җегәр һәм хуплау булганда, мондый «багаж» белән ил поэзиясе орбитасына гына түгел, ә Рәсүлләр, Кайсыннар, Эдуардаслар, Мостайлар кебек, Европа, дөнья әдәбияты аренасына да чыгу мөмкин булыр иде... Алда әйткәнебезчә, киңрәк чыгуда тәрҗемәчеләрнең роле зур. Әлбәттә, авторның үз роле дә кечкенә түгел: ул тәрҗемәләргә талымсыз карарга, поэзияне кыерсыту хисабына компромисска барырга тиеш түгел. Рафаэль Мостафин үз китабында бу мәсьәләгә бик тәфсилләп туктала. Шагыйрь иҗатын рус телендә яңгыраткан С. Липкин, М. Львов, Н. Сидоренко, Р. Моран, Н. Беляев, Р. Кутуй һәм башка тәрҗемәчеләрнең иҗади концепцияләрен һәм эш стильләрен анализлап, бүгенге тәрҗемә эшенең торышы, спецификасы, үсү перспективалары турында кызыклы гына теоретик фикерләр әйтә һәм кайбер практик киңәшләре белән уртаклаша.

Сибгат Хәким — җырчы шагыйрь. Аның сүзләренә язылган йөзләрчә җыр халык күңелендә урын алган. Сибгат Хәким — Тукайчы шагыйрь. Бөек Тукай рухына һәм эшенә тугрылыгын раслап, аның турында поэмалар циклы иҗат иткән шагыйрь. Сибгат Хәким — Ленин Татарстаны шагыйре. Ул «Ленин фәрманы белән», «Языгыз, җир уллары!», «Дәверләр капкасы» кебек поэмалар, «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Бер горурлык хисе яна миндә» кебек шигырьләр авторы. Сибгат Хәким — фронтовик шагыйрь. «Дуга», «Үрләр аша» поэмалары, «Уналты йорт безнең тыкрыкта», «Белгәннәр тик тора», «Торыгыз, Мусалар!» кебек шигырьләр аның кулы белән язылган. Сибгат Хәким — публицист шагыйрь. Ул — йөзләгән чыгышлар, мәкаләләр, рецензияләр авторы (әле 1979 ел ахырында гына аның әдәби-публицистик мәкаләләрен берләштергән калын бер томлыгы дөнья күрде). Сибгат Хәким — яшь язучыларның (бер язучыларның гынамы әле!) якын дусты һәм киңәшчесе. Сугыштан соңгы еллардан башлап дистәләгән язучы турыдан-туры аның ярдәме белән әдәбиятка аяк басты, иҗади үрләр яулады... Һәм, ниһаять, Сибгат Хәким — мәшһүр Казан артының илгә игелек күрсәткән данлы бер улы... Кеше һәм иҗатчы буларак, әдипнең күпьяклы эшчәнлеге Рафаэль Мостафинның монографиясендә шактый тулы күрсәтелгән. Тәнкыйтьче Сибгат Хәким иҗатын татар әдәбиятының бер казанышы итеп кенә карамый, ә күпмилләтле совет әдәбиятының органик бер өлеше итеп күрсәтә. Дөресе дә шул: шагыйрь иҗаты — милли бизәкле, интернациональ эчтәлекле бай иҗат.

Тәнкыйтьче бу китабында шагыйрьнең иҗат лабораториясе серләрен дә беркадәр ачарга тырышкан. «Шигырьләр ничек туа?» дигән бүлектә шагыйрьнең укучыларга киң мәгълүм шигырьләреннән «Тәрәзә рамнары», «Фәрхинур», «Рамазан» шигырьләренең язылу тарихын бәян итә. Һәр шигырь артында конкрет кешеләр, конкрет язмалар тора икән бит! Кайберләренең исемнәре дә шул көе үзгәртелмичә шигырь тукымасына кереп киткән. Гомумән, Р. Мостафин шагыйрь иҗатының төп этапларын билгели торган байтак әсәрләргә җентекле анализ ясый. Шулай да С. Хәким иҗатында әһәмиятле урын тоткан кайбер әсәрләр автор игътибарыннан беркадәр читтә калганнар. Әйтик, «Бакчачылар», «Дала җыры» кебек башлангыч чор әсәрләренә шактый урын бирелеп тә, атаклы «Кырыгынчы бүлмә» турында бер сүз дә диярлек әйтелмәве аңлашылып бетми. Ихтимал, кайбер әсәрләрне шагыйрь замандашларының (мәсәлән, Ф. Кәрим, М. Җәлил, Х. Туфан, Ә. Давыдов, Ш. Мөдәррис һ.б.) шул ук темага яки якынрак темага язылган әсәрләре белән чагыштыру нисбәтендә анализлап караганда да кызыксыз булмас иде. Гомумәдәби процесс фонында шагыйрьнең уңышлы һәм кимчелекле яклары ачыграк күренер иде. Шулай ук кайбер шигырьләргә аңлатма биргәндә, урыны-урыны белән нечкә поэтик тоемның да җитенкерәп бетмәве сизелгәли... Әлбәттә, үзең эшләүгә караганда, кеше хезмәтен бәяләү җиңелрәк. Хезмәт белән танышкач, тагын бүтән фикерләр дә тумады түгел. Алары китапны тагын да яхшырак күрү теләгеннән иде. Без хәзергә булганын тәкъдир итә белик. Мәскәүдә беренче тапкыр исән татар язучысы турында төпле монография чыкты. Бу үзе бер шатлыклы вакыйга! Гомумән, Сибгат ага Хәким — бәхетле язмышлы шагыйрь, ә ул хезмәт итә торган әдәбиятның язмышы бәхетле микән? Бездә Хәким кебек әдипләр күбрәк булса, бу сорауга да уңай җавап бирергә мөмкин.

*1979, ноябрь*

## ХИКМӘТЛЕ ДӘ ҖЫРЫ, ДӘРТЛЕ ДӘ

Язмышлары, ялгышлары белән
Әрни-әрни сөйдем илемне.
Әгәр дәваз кичсәм илдән-телдән,
Син мине үз итәр идеңме?

*Н. Арсланов*

50 нче еллар уртасында шагыйрь Нури Арсланов «Кордашлар җыры» исемле шигырь язган иде. Композитор тарафыннан көйгә салынгач, ул шигырь чыннан да җыр булып китте. Анда мондый юллар бар:

Солдат булып йөрдек сугышларда,
Үттек таулы-ташлы юллардан...
Ни кичмәде безнең бу башлардан,
Ни килмәде безнең куллардан.
Гаҗәп түгел чәчкә чал керсә,
Булса да тик кырык яшь безгә!

Ун еллап гомер үтте. Бу җыр үзгәрде. Исеме дә, сүзләре дә, көе дә.

Ир уртасы — илле яшь, дигәннәр.
Кемнәр безне картка саныйлар?!
Егетләрчә әле безнең хәлләр,
Кемнәр шуны күрә алмыйлар?!
Картаербыз, бәлки, без йөздә...
Хәзергә тик илле яшь безгә.

Тагын ун ел үтте. Бу юлы шагыйрь әлеге җырны кабат үзгәртеп тормады, инде моны яңадан эшлисе юк дигәндәй, «Ир уртасы — илле яшь» исеме белән «Моңсар» дип аталган зур сайланма китабына кертте. Мәсьәлә ачык: картаербыз, бәлки, без йөздә... Хәзергә — шигырьләр, шигырьләр...

Акыл белән эш ит, диләр миңа...
Ә йөрәкне кая куясы?
Анда һаман әле давыл уйный,
Анда һаман «җеннәр оясы»!
Аның әле Амур укларыннан
Һаман килә яра аласы.
Булса булыр икән бу кадәр дә
Тынгы белмәс адәм баласы!..

Яки:

Типсәң тимер өзәр чак узса да,
Мин калышмыйм әле ярыштан.
Мәйдан тотсам, исемем генә түгел,

Бөтен рухым, җисмем арыслан.

Яки:

Азмы җирдә тумый картайганнар!
Син картайгач, бер ту яңадан!
Олыгайган саен хәят телим,
Мин яшәгән саен яңарам.

Яки:

Акчарлакка җимгә икмәк
Атасым килә минем.
Иделгә түгел, бәхеткә
Батасым килә минем.

Эшләр менә шулай тора шагыйрь Нури ага белән. Берәүләр аны «һаман яшь, һаман көләч» ди, икенчеләр аны «бөтен җаны белән елмаючы иптәш» ди. Шагыйрь үзе дә моны инкяр итми.

Баштук, ахры, күзгә чалындым мин:
«Яшь!» — диделәр, «Яңа!» — диделәр.
Ә картайгач: «Бу яшәгән саен
Гел яшәрә бара!» — диделәр.

Шулай да алтмыштан артык ел гомер ителгән. Күпме язлар кичелгән! Хәер, Тукаебыз әйтмешли, «шагыйрь күңелендә кыш булмый да, кар яумый», анда — гел яз. «Йөрәк әле һаман унсигездә». Тик акыл гына менә бераз өлкәнрәк бугай. Еллар шуңа ишарәли... Күпме җир гизеп, күпме юл үтеп, кемнәр белән генә очрашылмаган да кем язмышларына гына шаһит булынмаган! Никадәр шатлык татылмаган да ничаклы сагыш кичерелмәгән!..

Н. Арсланов — кырык елга якын иҗат гомерендә утызлап китап чыгарган шагыйрь. Алар — төрле пафоста, төрле темага язылган, күләмнәре дә төрле булган (кайсы 25 бит, кайсы 400 биткә якын), әлбәттә, әдәби кыйммәтләре ягыннан да төрле дәрәҗәдә торган китаплар. Арада 50 нче елларда чыккан, хәзерге поэзиябез югарылыгыннан караганда йомшаграк басмалар белән беррәттән, Н. Арслановны зур шагыйрь итеп таныткан «Моңсар» кебек китаплар да бар. Шуңа өстәп күпме тәрҗемә! Җыйсаң, алар, ихтимал, 20 табактан да артып китәр. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк, «зур тау булыр иде иткән хезмәт, өеп куйсаң аны әгәр дә».

Әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан ничек кабул ителгән бу хезмәт һәм тәнкыйть аның иҗатын ничек бәяләгән соң? Н. Арслановның, шагыйрь буларак, татар совет поэзиясе үсешенә керткән өлеше, үзенчәлеге, көчле һәм йомшак яклары нидән гыйбарәт? Шагыйрь китапларын тагын бер кат укып танышу процессында шундыйрак сораулар туды һәм, аларга җавап эзләү нияте белән, мин хәл кадәрле Н. Арсланов иҗатына карата үз вакытында матбугатта күренгән мәкаләләрне карап чыктым. Бер дә юк түгел икән рецензияләр, беркадәр бар икән, заманында чыккалаганнар икән. Менә Фатих ага Хөснинең 50 нче елларда «Совет Татарстаны»нда (1952, 4 сентябрь) чыккан мәкаләсе. Ул Н. Арслановның «Мәхәббәт» исемле китабына кергән «Ай Хян белән Ли», «Корея гөле», «Мәхәббәт» поэмаларына (рецензент аларны поэма дип түгел, мәхәббәт хикәяләре дип атый) анализ ясаган. Шагыйрь С. Хәким, республикабызда нефть промышленностеның көннән-көн күзгә күренеп күтәрелүенә сөенеп, инде «кара алтын» яклары кешеләре турында җырлар, поэмалар тууына куанып, Н. Арслановның «Девон фонтаннары» китабы турында фикерен әйтеп чыккан. Шул ук «Совет Татарстаны»нда Л. Җәләй шагыйрьнең «Рус кызы» исемле поэмасы хакында чыгыш ясаган. Шактый еллар узгач, Н. Арслановның «Ак таңнар» исемле күләмле генә җыентыгы турында И. Саттаров «Социалистик Татарстан»да «Шигърият тавы каршында» исемле рецензия бастырган. Үз вакытында Ә. Исхак, Ш. Максудова, Р. Фатыйховлар шагыйрь иҗатына үзләренең мөнәсәбәтләрен белдереп чыкканнар. Төрле елларда чыккан китапларга З. Мансур, С. Хәким, М. Садрилар кереш сүз язган. Ихтимал, миңа очрамаган, мин тапмаган мәкалә, язмалар тагын бардыр. Димәк, үз вакытында шагыйрь иҗаты турында беркадәр язылган икән. Ләкин шунысы бар: бу мәкалә-рецензияләрнең һәммәсе дә йә китап чыгу, йә юбилей уңае белән язылган. Ә менә шагыйрьнең бөтен иҗатын яктырткан, гомумиләштерүләр һәм нәтиҗәләр ясаган күләмле мәкаләләр юк диярлек. Төрле «уңай»лар белән язу, гәрчә күп яклардан акланса да, гадәттә, әдәбият тарихында зур эз калдыра алмый. Дөресрәге, андый мәкаләләр объектив ук булып бетә алмый. Мәсәлән, китапка кереш сүз язучы кеше, беренче чиратта, әсәрнең уңай яклары турында сөйли, һәм бу табигый. Юбилей уңае белән сүз әйтүче дә, кагыйдә буларак, әдип иҗатының күркәм якларына күбрәк тукталa.

Н. Арсланов бүгенге татар шигъриятендә ниндирәк урын тота һәм ул кай ягы белән үзгә шагыйрь? Гомумән, безнең кемнәребез бар соң? Бүгенге шигъриятебез шактый көчле. Артык күп булмасалар да (бәлки, шагыйрьләр йөзәрләп була да алмыйлардыр. Хәтта хәзерге рус поэзиясендә дә бик талантлы шагыйрьләрне дистәләп санау кыен. «Хакыйкатьне әйтеп бирү өчен бер Толстой житкән, бер Тукай»), шагыйрьләребез юк түгел, алар бар. Сабыйларча беркатлы, интеллектуаль Туфаннары, халыктагы хәкимлекне һәм сабырлыкны үзенә җыйган зирәк Хәкимнәре, чәнечкеле Карәхмәт-

ләре, әрем телле Гамилләре, самими һәм шук Шәүкәтләре, моңлы романтик Илдарлары, сагышлы Саҗидәләре, нечкә поэтик тоемга ия авыр холыклы Робертлары, чичән телле Рәшитләре, рациональ акыллы Ренатлары, яшьли ирләрчә уйларга күнеккән Кадыйрлары, үтә талантлы Мөдәррисләре, күңелләрен җилбәгәйрәк ачкан Зөлфәтләре... Һәм тагы шушы ансамбльдә үзенчә аерылып торган горур һәм затлы Нури ага Арсланов та бар. Ул үзенең килеш-килбәте белән (аны шәхсән белмәгән, күрмәгәннәр өчен рәсеме белән) классик мәгънәдәге борынгы интеллигентны хәтерләтә. Ни өчен шәхеснең, күңеленнән бигрәк, шәкли ягына кагылдым. Чөнки кеше күзендәге кешеләр — әдәбият-сәнгать кешеләре өчен бу да бик мөһим. Эстетик байлык халык массаларына тирән үтеп кергән чорда, рухи иҗатчылар белән материаль байлык тудыручыларның интенсив аралашуы, берлеге заманында, әдип кеше һәр яктан сынала: кыяфәте дә, үзен тотышы да, шәхси тормышы да, әйткән һәр сүзе дә. Тыңлаучыга, шәхес буларак, уңай тәэсир ясыйсың икән, ул синең иҗатыңа да бүтәнчәрәк — яхшырак караячак, игътибарлырак булачак. Бу — әлбәттә, мәгълүм хакыйкать. Ләкин бу хакыйкатьне форсат чыгып торганда искә төшерүдән зыян юк. Сукбай булып халыкның исен китәрә торган заманалар узды. Әдип һәрчак әдип булырга тиеш. Интеллигент әдип дигәч, Пушкиннар, Байроннар, Ролланнар, Фадеевлар, Ибраһимовлар, Дәрдемәндләр, Рәмиевләр, Кутуйлар бар кыяфәт-сыннары белән күз алдына киләләр. Бу яктан Н. Арсланов — татар язучылары арасында байтак яшьләргә үрнәк булып торырлык интеллигент әдипләрнең берсе.

Н. Арсланов — чыгышы белән Казакъстаннан. Ул 1912 елда Кызылъяр (Петропавловск) шәһәрендә туа. Күкчәтауда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Казанга килә, сәнгать техникумында укый. Аннан соң Татарстанның Кукмара районында рәсем, әдәбият укыта. 1934—1936 елларда Кызыл Армия сафларында була. Тыныч хезмәттә берничә ел эшләүгә, Ватан сугышы башлана. Н. Арсланов беренче көннәрдән үк фронтка китә. Рота командиры дәрәҗәсенә күтәрелә. Сугышчан батырлыклары өчен орден, медальләр белән бүләкләнә. Яралана. Сугыштан соң Татарстан китап нәшриятында, газета редакцияләрендә рәссам булып эшли. Шул ук вакытта һәр мөмкинчелекне иҗат өчен, шигърият өчен файдаланып калырга тырыша. 60 нчы еллар ахырында ун елга якын Н. Арсланов «Казан утлары» журналының поэзия бүлеген җитәкләде. Анкета мәгълүматларын санап чыгу, әлбәттә, җиңел. Тормыш итү, яшәвеңне мәгънәле итү, ай, катлаулы! Бер шигырендә шагыйрь болай дигән иде: «Ярты гасыр җирдә яшәдем мин, Бер гасырлык хәлләр кичердем». Ә «Тәрҗемәи хәлем» дигәнендә мондый юллар бар:

Төрле хәлләр кичте баштан — сабыр кылдым,
Башкалардан калышмадым — сафта булдым;
Кагылсам да, сугылсам да авыр юлда,
Бирешмәдем, мин абынган саен тордым.
........................................................
Ил каршында абруй өчен көрәштем мин,
Башкалардай борчылдым, көнләштем, ләкин
Кызыксам да күреп миннән өстеннәрне,
Түбәннәргә карап күтәрмәдем борыным.

Тырышмадым җитди булып кыланырга,
Язмаганны сыктанырга-сыранырга,
Яшәмәвем өчен каш-кабагым төеп —
Гомерлеккә мин сакаллы сабый булдым.

Н. Арслановның укучыларга ирешкән беренче әсәрләре — «Мәхәббәт» һәм «Рус кызы». Беренчесе госпитальдә дәвалану вакытында 1942 елда язылган һәм бер елдан соң «Совет әдәбияты»нда басылып чыккан, икенчесе — бераз соңрак. Заманында алар авторны танытган әсәрләр. Сугыш вакытында һәм соңрак бу әсәрләр укучыларда патриотик хис тәрбияләүдә, һичшиксез, зур роль уйный. «Рус кызы» турында 50 нче елларда бик күп мактау сүзләре әйтелә. Ләкин бүгенге поэзия биеклегеннән, шигъри әсәрләргә бүгенге таләпләр югарылыгыннан караганда, бу поэманың байтак кына йомшак яклары да күренә. Акланмаган озынлык күзгә бәрелә, тасвирчылык, риторик купшылык үзен сиздерә.

Үз вакытында Зоя Космодемьянская батырлыгы турында бүтән шагыйрьләр дә язды. Төрле халык шагыйрьләренең байтак әсәрләре чыкты. Кабат укып карыйм, чагыштырам, уңай якларын табам. Әмма барыбер бу поэма — Н. Арслановның өйрәнчегрәк әсәре. Чын әсәр, шигырьме ул, хикәяме, теләсә кайсы вакытта да, теләсә нинди биеклектән караганда да дулкынландыра, әсир итә. «Рус кызы» поэмасы — ул еллардагы поэзиянең типик бер үрнәге. Гомумән, никадәр генә аяныч булмасын, 50 нче еллар татар поэзиясе укучыларны зур һәм тирән мәгънәле шигъри әсәрләр белән артык куандыра алмады.

Беркадәр формальрәк булса да, Н. Арсланов иҗатын берничә чорга бүлеп карарга мөмкин. 43—50 нче еллар — өйрәнү чоры, 50—60 нчы еллар — чыныгу чоры, 60 нчы еллардан бүгенгегә кадәресен өлгерү чоры дип атарга мөмкин.

Беренче чор — тулысы белән диярлек Бөек Ватан сугышы тәэсирләреннән туган иҗат. Шагыйрьнең төп нияте — «җиңелмәс» фашист илбасарларын җиңгән, «дошман башын хурлыкка сала алган» совет халкының көченә, рухи бөеклегенә дан җырлау. Иҗатының бу чорын күзаллау өчен, югарыда әйтелгән поэмалардан тыш, «Авылда», «Сугышчы төне», «Хат», «Дустымны сагынганда» шигырьләрен китерергә мөмкин. Сугыш турында шагыйрь бу елларда байтак язса да, аның сугыш мөнәсәбәте белән язылган «Билгесез солдат кабере янында», «Триумфатор булып», «Адым саен әкият», «Уникe батыр турында баллада» кебек көчле әсәрләренә соңрак туарга насыйп булды. Гомумән, сугыш хәлләрен Н. Арсланов бөтен авырлыгы һәм дәһшәтлелеге белән бирергә омтыла. Шушы омтылыш һәм билгеле бер дәрәҗәдә моңа ирешү аның әсәрләрен ышандырырлык итә дә.

Шагыйрьнең икенче чор иҗаты тематик диапазонның киңрәк һәм әдәби осталыкның камилрәк булуы белән характерлы. Җирдә тынычлык өчен көрәш — Н. Арслановның 50 нче еллар иҗатының төп бер мәгънәсе шул. Җиде-сигез елын фронтларда уздырган, утны-суны кичкән солдат-шагыйрь өчен бу бик табигый. Ул елларда Кореяда барган сугышлар, халыкара хәлнең киеренкелеге тынычлыкның кадерен белергә, аның өчен көрәшергә кирәклекне һәрдаим искәртеп торды. Н. Арсланов, Корея халык иҗатын өйрәнеп, күләмле байтак шигырь-поэмалар («Корея гөле», «Ай Хян белән Ли», «Давыл кызы» һ.б.) иҗат итте. Тынычлык өчен көрәш ул, иң беренче чиратта, Ватан хакына фидакарь хезмәт итү. Татарстанда нефть промышленностеның үсеп килүе, нефтьчеләрнең тырыш хезмәте шагыйрь күзеннән читтә кала алмый. Н. Арсланов, беренчеләрдән булып, алар турында шактый кызыклы шигъри әсәрләр тудырды. 1953 елда чыккан «Девон фонтаннары» асылда җир асты байлыгын күяшка чыгаручы хезмәтчәннәр турында иде. Ул елларда Н. Арсланов сүзләренә З. Хәбибуллин тарафыннан язылган «Баулылар» җыры гаҗәеп популярлык яулады. Байтак еллар буе бу җырны бөтенләй нефть исе килмәгән чит якларда, хәтта малай-шалайга кадәр җырлап йөрде. Н. Арсланов бу елларда балалар өчен дә байтак язды. «Карамай малай әкияте», «Сыерчык», «Ауда» кебек китаплар әнә шундыйлардан.

Н. Арслановның сугыштан соңгы унбиш еллык хезмәтен тәкъдир иткән хәлдә, икеләнмичә шуны әйтергә мөмкин: иҗатының иң игелекле һәм күпләрне куандырган өлеше соңгы ун-унбиш елга туры килә. Аның бу вакыт аралыгында язылган шигырьләре турында һичбер ташламасыз сөйләп, фикер әйтеп була. Әгәр Н. Арсланов элегрәк бу тормышка катнашучы шагыйрь булып чыгыш ясаса, хәзер ул бу тормышта хуҗа-шагыйрь булып сүз әйтә. Элегрәк язган бер шигырендә үзен ул шигъриятнең яшь бер альпинисты санап, Парнас тавына менәчәге турында әйтеп, укучылары күңеленә сөенечле очкын салган иде. Сүзе бер булды, егет сүзе булды:

Бирә, диләр, анар агачы да
Картайганда җимеш татлысын.
Яшькә карыймыни шагыйрь җаны —
Яна икән, әйдә яктырсын! Фирдәүсиләр,
Гомәр Хәйямнар да
Мирас итеп гаҗәп моңнарын,
Хикмәт кунып, акыл утырганда
Язган, диләр, гүзәл җырларын.

Мәкаләнең кереш өлешендә үк сүземне, шагыйрь соңгы елларда иҗади яшәрде, дип башлаган идем. Табигый сорау туа: бу яңарышның сәбәбе нидә соң? Ни өчен аның яшендәге яки аннан өлкәнрәк байтак сәләтле шагыйрьләр иҗатларында этаплы «сикереш» ясый алмаганда, Н. Арсланов шигъриятнең алгы рәтенә чыга алды? Барыбыз өчен дә гыйбрәтле бу үзгәрешнең сәбәпләре байтак булырга тиеш. Минемчә, бу яңарышның төп нигезе түбәндәгеләрдән гыйбарәт. Беренчедән, Н. Арсланов — тумыштан шагыйрь булып туган җан («үзең хәким, үзең дивана»), һәм бу табигый талант өстенә аңа кеше буларак күркәм сыйфатлар: әдәплелек, затлылык, чама хисен нечкә тою («тырышмадым җитди булып кыланырга, язмаганны сыктанырга-соранырга»), зирәклек һәм горурлык хас. Шушы асыл сыйфатлар заманның төрле җил-давылларыннан аның шагыйрьлеген исән-аман саклап алып чыкты да шикелле («сугыш аты кебек мин, мөлдерәп, күзләреңә (ил, халык күзенә. — *Р. Ф.*) карап яшәдем»). Икенчедән, Н. Арслановның иҗади күтәрелүенә 60 нчы еллар башында илнең рухи тормышы кичергән үзгәрешләр, иҗади атмосфераның кешелекле һәм дустанә булуы, әдәби мирасның классик әдипләр исәбенә баюы һәм, гомумән, әдәби хәрәкәтнең тулы канлы булуы уңай тәэсир итте. Шунысы да бар: әдәби-иҗтимагый тормыштагы бу уңай үзгәрешләр, беренче чиратта, иҗатта үзенең анык кредосы, ил, халык сулышына сизгер күңеле һәм инанган позициясе, тормышта үз миссиясен ачык белгән, илсөяр табигатьле көрәшче шагыйрьләргә шифалы булды. Кайберәүләр иҗатында, кызганычка каршы, бу яңарыш үзен сиздерә алмады. Өченчедән, Н. Арслановның яшәрүенә аның яшь иҗатчылар белән тыгыз иҗади бәйләнештә булуы да билгеле бер роль уйнады. Яшьләр белән тулы аңлаша алу — яшь була алу дигән сүз ул. Яшь шагыйрьләргә үзенең иҗаты белән йогынты ясаган хәлдә, ул үзе дә кирәк чакта яшьләрдән өйрәнә алды. Чөнки һәр яшь иҗатчы әдәбиятка үз дөньясы, үз кызыгы белән килә. Аңа сизгер күңел битараф кала алмый. Моннан берничә ел

элек «Татарстан яшьләре» газетасында Нури ага үзе дә болай дип язып чыккан иде: «Соңгы биш-алты ел эчендә... бик күп талантлы, өметле һәм җитди яшьләребез әдәбиятның киң һәм изге мәйданына кыю адымнар белән килеп керделәр. Аларның һәркайсының бер дә кабатланмаган үз җыры, үз моңы, үз авазы бар. Мин бу яшь шагыйрьләребезгә карап шатланам да, сокланам да. Алар безнең хакта ни уйлыйлардыр, ә менә миңа аларга карап үз тулпарымны еш чыбыркыларга туры килә». («Татарстан яшьләре», 1969, 51 сан.)

Өметле дә мин,
Бәхетле дә мин!
Тик яшьләр, сезнең
Язмышны көнлим:
Ник сезнең белән
Кордаш түгел мин!
..........................
Яңа үрләргә
Ак юл, туганнар!
Яшьләр, сез нинди
Бәхетле җаннар!

Яшьлегенә көнчеле белән булса да һәрдаим якыная алган кеше ул — яхшы кеше.

Н. Арслановның соңгы еллардагы иҗади йөзен аның Туган ил, Туган җир турында уйлану рәвешендә язылган шигырьләре һәм мәхәббәт лирикасы билгели. Бу шигырьләр әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итте һәм шагыйрьнең үзенә хөрмәт, ихтирам китерде. Шагыйрь Туган ил, Ватан төшенчәсенә фәлсәфи мәгънә сала, һәм аны югары поэтик осталык белән укучыга җиткерә ала. Шагыйрь өчен Ватан төшенчәсе конкрет, ул аңа үткәне, бүгенгесе, киләчәге белән газиз. Ватан киң — ул Татарстан да, казакъ далалары да, Кырым ярлары да, Идел буйлары да. Шулай да шагыйрь өчен туган казакъ далалары һәм үзен кеше иткән, шагыйрь иткән Казан аеруча кадерле.

Тусам да мин казакъ даласында,
Үссәм дә мин атта, иярдә,
Гел ашкындым Казан каласына —
Истәлекле изге җирләргә.
Бу туфракта минем туган илем,
Йорт корганнар монда бабамнар,
Монда минем акчарлаклы Иделем,
Үз халкым, үз республикам бар!

Шагыйрь, кем генә һәм кайда гына булса да, үзенең бала чагыннан, үсмер чагыннан китә алмый. Дөресрәге, ул аннан китмәскә тиеш. Балачак — авыр үткәнме, җиңелме, барыбер һәр иҗат кешесе өчен бетмәс-төкәнмәс саф чыганак. Балачак — кешенең дөнья белән эчкерсез, дипломатиясез сөйләшкән чагы, аңлашкан чагы...

...Миңа илһам аты биргән
Далаларым искә төшкәндә,
Мин әйләнәм кабат бүз балага —
Җан яшәрә, күңел нечкәрә.

Н. Арсланов үзенең бала чагы үткән Кызылъяр, Кәрәкәү, Күкчәтау яклары, Колынды, Күксөңгер далалары турында кешелекле һәм тирән мәгънәле байтак шигырьләр иҗат итте. «Далаларым», «Кәрәкәү икмәге», «Сабира җыры», «Акбүз ат хикәясе», «Әти белән сөйләшү», «Тугайлы Иртеш буйлары» исемле шигырьләре, «Романтика», «Майра» кебек кечкенә поэмалар — әнә шундыйлардан. Ул як халкының тормышын, гореф-гадәтен, халык авыз иҗатын яхшы белү шагыйрьне бай телле итте.

Майра, Майра,
Кәрәкәүле Майра,
Яшьле күзем, җайна!
Кызыл гөлем, сайра!
Сөйгән ярың кайда?
Майра, Майра!

Гомумән, казакъ халкы тормышы хакында без Г. Ибраһимов, И. Салаховларның чәчмә әсәрләреннән, Н. Арслановның шигырьләреннән байтак мәгълүмат ала алабыз. Бу әсәрләрнең ике кардәш халык арасындагы дуслыкны тагын да ныгытуда ярдәме зур булды. Н. Арсланов рус халкы турындамы, казакъ, кыргыз, молдаван, Кавказ һәм Кырым халыклары турындамы булсын, ул аларның һәркайсына тигез күз белән карап, тарихларын белеп, милли үзенчәлекләрен танып һәм хөрмәт итеп

язарга тырыша. Милли кәпрәю һәм чикләнгәнлек шагыйрьгә ят. Аның килер буыннарны чын интернациональ рухта тәрбияләнгән, сугышларны белмәгән, бай рухлы, азат һәм шат итеп күрәсе килә.

Сугышлардан дөнья сыкрый-сызлый.
Авыр яралары...
Үстерергә иде бер дә бозмый
Газиз балаларны.

Татарстан һәм Казан турындагы шигырьләр шагыйрь иҗатында аерым бер урын тота. Гомеренең яртылабын яшәп үткәргән Татарстанга, асылда, аның төп туган иле булып киткән җиргә — Казанга — шагыйрьнең үзенең ихтирамлы мөнәсәбәте бар, җыры бар. «Казан» дигән шигырендә ул болай ди:

Шуннан киттем ике сугышка да,
Тормыш юлын шуннан башладым;
Шуңаргадыр, монда тумасам да,
Казан җире, Казан ташлары —
Туган йортым бусагасы миңа,
Идел ярын Туган яр итәм...

Шагыйрь Туган ил, Татарстан темасын төрле яктан ача. Н. Җиһанов көй язган «Республикам минем» җырын кем генә тыңламаган икән.

Азат та син,
Гүзәл дә син,
Әй туган җирем!
Күкрәп яшә,
Республикам минем,
Татарстан, Татарстан!

Туган ил өчен горурлык хисе шагыйрьгә һәрчак юлдаш булды. Чөнки хезмәт сөючән, батыр татар халкының Ватан данын арттыручы уллары һәм кызлары бар, илне яңа үрләргә күтәргән хезмәте бар. Шагыйрьнең Р. Яхин көй язган «Унике батыр турында баллада»сын Э. Җәләлетдинов башкарында күз алдына китерегез.

Таш утрау шикелле бу төрмә,
Таш койма әйләнә-тирәсе.
Белделәр бу ташлар мәйданга
Бүген дә корбаннар киләсен...
Дарларга унике батырның
Ашуын бу ташлар күрделәр.
Таң калып тетрәде диварлар:
Батырлар елмаеп үлделәр,
Татарлар елмаеп үлделәр...

Шагыйрь җаны халкының үткәненә, тарихына битараф була алмый. Киләчәкне үткәннән, бүгенгедән аерып карап булмый, дөресрәге, аерып карасаң, дөрес булмый, гадел булмый. Менә шагыйрь үзенең бабалары туып үскән Мамадышта. Ул бер конкрет шәхес аша татар халкының тарихын күргәндәй була. «Давылларда күтәрелгән комдай чәчелгәннәр, язмыш куганнар». «Үз илем, үз республикам бар» шигырендә шагыйрь болай ди:

Көзен киткән казлар язын кайта,
Кыйгаклашып, Идел-суларга.
Киек казлар... Без дә төрле якка
Таралганбыз, охшап шуларга.
Бер кайтмаса, бер кайталар илгә
Өмет өзми калалмаганнар.
Идел-йортта Татарстан дигән
Үз илем, үз республикам бар!

Тарихи үткән юл никадәр гыйбрәтле һәм четерекле булмасын, бар халык танырлык игелекле эше, бөтен дөнья күрерлек гигант төзелешләре булган халыкка шагыйрь киләчәк тарихта мактаулы урын хәстәрли.

Атлантида! Атлантида баткан!
Эз калмаган бөек халыктан...
Ә без — менә, без — бар, эз бар җирдә —
Без батырган саен калыккан.
........................................
Татарстан дигән Ватаным бар,
Татар дигән халкым бар минем.
Узганнардан түгел, мин халкыма

Киләчәктән урын барлыймын.

Гомумән, Н. Арсланов иҗатында Татарстан, Казан турындагы шигырьләр күләм ягыннан да шактый. Югарыда әйтеп үтелгән шигырьләрдән тыш, аның бу темага язылган «Сагындым», «Ак таңнар», «Казан кызы» һәм тагын башка яхшы шигырьләре бар. Казан дигәч, XVIII гасырның билгесез бер татар шагыйрәсе иҗат иткән юллар хәтергә килә: «Казанда булган туфрак — күз генәмә лә сөрмәдер...»

«Н. Арслановның иҗади яшәрүен дәлилләрлек нинди шигырьләрен санийсың?» — дип сорасалар, мин иң әүвәл аның соңгы елларда язган мәхәббәт шигырьләрен китерер идем. Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы аерым алып махсус өйрәнелергә лаек. Әгәр шагыйрьне һаман яшь, һаман көләч, дип әйтәләр икән, моны, мөгаен, беренче чиратта, аның мәхәббәт шигырьләрен истә тотып әйтә торганнардыр.

Мәхәббәткә рөхсәт сорамыйлар,
Мәхәббәткә рәхмәт әйтмиләр.
Ул бүләк тә һәм бурыч та түгел,
Мәхәббәтне гаеп итмиләр.
Сөя белгән, сөелә белгән җаннар...
Шулар белән бергә атладым:
Сөймәгәннең сөюен теләдем мин,
Сөйгәннәрнең бәхетен якладым.

Мәхәббәт кебек бөек хисне ниндидер категорияләр кысасына кертеп өйрәнергә тырышу ничектер уңайсыз, сөю шигырьләренә комментарийлар бирү артык кебек. Аларны укырга кирәк. Ошыйлар, дулкынландыралар икән, тагы укы, күңел сизгечләрен шагыйрь кичергән хисләр дулкынына көйлә. Теләсәң — сагышлан, көл, дәртлән, җырла... Яңадан укы!

Башларымның, акылын җуеп, әйләнгән чагы,
Яшәреп, җаным егеткә әйләнгән чагы.
Тел сөяксез — сөйләсеннәр, ни сан аларга!
Бүген минем кәлисәмдә бәйрәмнәр чаңы!
................................................................
Кайда тынгы, кайда ирек! — Күр, мин богаулы...
Әгәр дә син әмер итсәң — аударам тауны!
Тәңресеннән вәхи алган пәйгамбәр сыман
Кояш иңде күкрәгемә, йолдызлар яуды!..

Яки:

Эх, сөймим димәсәнә,
Җаныма тимәсәнә...
Йөрәгем, көймәсәнә!
Сөйсәң сөй, сөймәсәң сөймә,
Сөймәсәң сөймәсәнә.

Яки:

Әй колыным, колыным!
Чәчәге син болынның.
Бер генә күз ташла, бәгърем,
Хәлләренә колыңның!

Яки:

Көннең көлеп туар иртәләре,
Айның аерылмас кичәләре,
Даланың давылы,
Атның асавы,
Бәйгенең бүләге,
Ярның ялкынлысы
Инде миңа түгел...
Ләкин
Өмет өзәме соң күңел!

Мәхәббәт — күңел илендәге бер гүзәл чәчәк шул. Анда, салават күперендәге кебек, Хәяттагы бөтен төсләр, кеше хисенең бөтен тирбәнешләре бар. Әйе, көчле дә ул! Сине йә күкләрнең өске катларына күтәрә, йә бөтен барлыгың белән үксетә. Ләкин ни генә булса да, мәхәббәт — яшәүгә көч биргән иң кодрәтле чыганак. Шагыйрь иҗатында ул шулай яңгырый да. Шәхси мәхәббәт хисе халыкны, илне, Ватанны сөю хисе белән үрелеп бара, һәм шушы берлек шагыйрьнең шигырьләрен иҗтимагый бәһале итә дә.

Мәхәббәтем белән яшәдем мин,

Рухландым мин аның нурыннан.
Мәхәббәттән мәхрүм булсам әгәр,
Нәрсә килер иде кулымнан!

Шигырьләрнең эмоциональ тәэсирле булуы, форма ягыннан төзеклеге, камиллеге байтак композиторларыбызның игътибарын шагыйрь иҗатына юнәлтте дә булса кирәк. Күренекле композиторлардан Н. Җиһанов, Җ. Фәйзи, А. Ключарев, З. Хәбибуллин, Р. Яхин, А. Монасыйпов, С. Садыйкова, үзешчәннәрдән М. Имашев, И. Хисамовлар Н. Арсланов сүзләренә көйләр яздылар. Ул җырларның саны кырыклап булыр. Бүгенге көндә аеруча киң таралганнары: «Республикам минем», «Унике батыр турында баллада», «Сезне яратам», «Казан кызы», «Нәсимә» һәм башкалар. Бу җырларны шагыйрьнең шигырьләрендәге Зөбәрҗәтләр, Дилбәрләр, Миләүшәләр, Мәдинәләр, Раузалар, Нисалар, Нәсимәләр генә түгел, бөтен татар иле җырлый.

Гамьсезлектән җырлый, диләр мине,
Үзем генә беләм хәлемне.
Өзелеп-өзелеп сулкылдый да бәгърем,
Җырлыйм: «Бөркән зәңгәр шәлеңне...»
..................................................
Гамьсезлектән җырлый, диләр мине,
Гамьсезгә соң җыр-моң ни аңа?!
Эчендәге сагышлары кушкач,
Җырлый башлый миндәй дивана.

Гамьсезлек димәктән, кемгәдер Н. Арсланов либераль карашлы гамьсез Гулливер кебек күренергә дә мөмкин. 50 нче елларда бер өлкән шагыйребез: «Сак булыгыз, гамьсез Гулливерлар, лилипутлар килә шигырьгә!» дип язып та чыккан иде. Бәхетебезгә, безнең Нури ага алай гамьсезләрдән булмады. Озак еллар журналыбызның поэзия бүлегендә эшләү дәверендә яшь шагыйрьләр моны яхшы тойды. «Ничек кенә булмасын, кайчакта үз зәвыгына, үз стиленә каршы килеп булса да, иҗади эзләнүләр юлында яшьләргә киң мөмкинлек бирергә кирәк» («Татарстан яшьләре», 1969, 51 сан). Әгәр без бүген поэзия жанрының сөенечле дәрәҗәдә үсүе, төрләнүе, тирәнәюе турында еш сөйләшәбез икән, иң яхшы поэтик әсәрләрне пропагандалаучы булган «Казан утлары» журналының һәм аның хезмәткәрләренең эшен танырга тиешбез. Н. Арсланов әнә шул җаваплы, тынгысыз эштә — редакциядә — байтак еллар эшләде, һәм ул төрле буын, төрле стиль шагыйрьләре белән уртак тел таба алырлык, әйткән сүзенә колак салырлык, үз позициясендә нык торган принципиаль, авторитетлы редактор булып саналды. Юк, бу дөньяда гамьсез булып булмый. Бу — егерменче гасыр. «Җирнең тарту көчен җиңеп, пьедесталга менгән данлы гасыр, бу — бер котыптан бер котыпка канлы эзе яткан рәхимсез гасыр».

Тын, караңгы бүлмә. Тып-тын акыл.
Йөрәк кенә уяу, талпына.
Өзелердәй булып үзәктә кыл
Чамасыннан чыгып тартыла.

Н. Арслановның «Шигырь китапханәсе» сериясендә чыккан сайланма шигырьләр китабының яртысын диярлек аның поэмалары, шигырь белән язылган әкиятләре, легендалары алып тора. Һәм алар күләм ягыннан да, идея-эстетик кыйммәте ягыннан да төрле әсәрләр. Арада, мең ярым юлга сузылган «Егет яуда сынала» дигән шигъри хикәя белән бергә, кыска, дулкынландыргыч, шул ук вакытта фикри тирән «Майра» кебек әсәрләр дә бар. Арада, минемчә, иң мәгънәлесе һәм сәнгатьчәлеге ягыннан да бик камил, нәфис эшләнгәне — «Моңсар». Авторның бу әсәре үзенә дә бик газиз булса кирәк, китабының исемен дә «Моңсар» дип атаган. Шагыйрь белән тиран, хаким көч белән изелгән халык арасындагы бәрелеш, конфликт. Ил, халык күңелендәге әйтүче җырчы шагыйрьләрнең тормыштагы роле, бәндә буларак Хәяттагы хәлләре — менә шулар турында бу әсәр. Әлбәттә, яңа хакыйкать түгел бу, борынгы заманнардан килә торган көрәш инде бу. Әмма шагыйрь бу әсәрен виртуоз-оста булып язган, шуңа да һәр строфаның матурлыгы һәм динамикасы сине үз стихиясенә алып кереп китә, дулкынландыра. Уй сөреше белән «Моңсар» безнең борынгы дастаннарны искә төшерә.

Тәхет биек, таҗ биек,
Тик җыр килмәс баш иеп.
Тотам дисәң — ул киек:
Аны җитәр толпар юк.
Аңа җирдә токтар юк.
Ул — йөрәктән аткан ук:
Ул тисә, кан чыгармый,
Ләкин аның ярасы

Мәңгелеккә каласы.

«Моңсар» — җыр турында уйлану, җыр турында җыр. Шунысы куанычлы: шагыйрь җырны бөек идеаллар көрәшендә байрак итеп, халык күңеленең иң бөек ноктасы итеп күрә.

Җырны чабар балта юк
Бөтен дөнья йөзендә.
Хакыйкать бар, хата юк
Минем шушы сүземдә.
Җырның кисәр тәне юк,
Үлемдә бер гаме юк.
Җыр яши җанга кереп,
Җыр — үлемсез, мәңгелек!

Шагыйрьнең сайланма китабына, «Моңсар»дан тыш, «Кинешма бәете», «Диңгез ярында», «Романтика», «Горур Гайшә» кебек яхшы әсәрләре кергән. Кырым легендасына нигезләнеп язылган «Горур Гайшә» — трагик ситуациясе һәм геройларының нык характерлары, тетрәндергеч язмышлары белән хәтердә кала. Гыйбрәтле, көчле, ләкин бәхетсез мәхәббәт турында бу әсәр.

Н. Арслановның төрле халык әкиятләреннән алып язылган «Икмәк валчыгы», «Тылсымлы кое», «Тапкыр игенче», «Көзге» кебек әсәрләрен укыганда, шундый уй туды: әкиятләрне, легендаларны шигырьгә салуның артык хаҗәте бармы икән? Әкият әкият килеш, легенда легенда килеш, халык авыз иҗатындагыча сакланса да начар түгел ич. Алар бит шул килеш тә үзләренчә матур, үзләренчә килешле. Әлбәттә, әкиятнеме, легенданымы, сюжетлы берәр вакыйганымы йөгерек шигъри телдә сөйләү җиңел түгел. Бу — осталык эше. Әкиятләргә карата үз фикеремдә калган хәлдә, шагыйрьнең бу әсәрләрдә дә осталыгын барыбер танырга кирәк.

Н. Арсланов иҗаты турында сөйләгәндә, аның тәрҗемә өлкәсендәге хезмәтләрен әйтми китү мөмкин түгел. Кемнәрне һәм нинди әсәрләрне генә тәрҗемә итмәгән ул! Аның ихтыяры һәм хезмәте нәтиҗәсендә Пушкин белән Лермонтов та татарча телгә килгән. Тагын Байрон, Гете, Шелли, Беранже, Хәйям, Хафиз, Мәхтүм Колый, Токтогул, Райнис, Гамзатов... Төрле заманда иҗат иткән төрле халыкларның зур шагыйрьләрен белү, аларның поэтик фикерләре белән эш процессында ныклап танышу, өйрәнү, чагыштыру шагыйрьнең үз иҗади йөзе формалашуында, һичшиксез, зур бер уңай фактор булган. Шагыйрьнең иҗатын өстән генә карап чыкканда, күп гасырлык поэтик арсеналның нинди формаларын гына очратмыйсың! Шунысы шәп: төрле үлчәмнәрдә дә тел табигый һәм шигъри матур яңгырый. Тел дигәннән, бер яшь иптәш егет белән сөйләшү хәтергә килде. Ул болай дигән иде: «Нури агайның шигъри теле беркадәр кадимирәк». Әлбәттә, төрки телнең нигезен юньләп белмәсәң, Шәрекъ шигърияте белүең дә чамалы булса, андый уй килергә мөмкин. Менә бер генә мисал:

Булса синдә Әфләтунның акылы,
Садәлеге керсез сабыйның,
Дәрвишлеге Хуҗа Насретдинның,
Исәрлеге Мәшрәп Сафиның,
Телгә оста булсаң чичән кебек,
Уйга — йөгерек, дала атыдай,
Гаделлектә Нәүширваннан гадел,
Юмартлыкта булсаң Хатом-Тай...
Анда да син камил түгел, шагыйрь!

Монда инде аңлау-аңламау синең белемеңә, эрудицияңә бәйле. Ә телгә килгәндә, Н. Арсланов, минемчә, төрки телнең бөтен нечкәлекләрен иң нык белгән һәм иҗатында бу белүне иң уңышлы файдалана торган шагыйрьләребезнең берсе. Гомумән, әдәби сурәтләү чараларының байлыгы ягыннан аның иҗаты аерым өйрәнүгә, аерым хезмәткә лаек. Максатыбыз шагыйрь иҗатына гомумирәк күз ташлау, барлау булганга һәм мәкаләнең күләме сыйдырмаганга күрә, табигый, шагыйрьнең әдәби осталыгы мәсьәләләренә бик тәфсилләп туктала алмадык. Гадәттә, чыгышның ахырын нәтиҗәләр белән очлыйлар. Мин алай эшләмәскә булдым, чөнки шагыйрь турында нәтиҗәләр ясарга иртәрәк әле. Ул көннән-көн иҗади яшәрә бара, ул үсештә. Шуңа да ашыгыбрак ясалган нәтиҗәләр тиз искерергә мөмкин. Н. Арсланов иҗаты турында шушы уй-фикерләремнән соң, әйдә, шагыйрьнең үз сүзләре дәвам итсен!

Тумаганнар тусын бәхете белән,
Ирекләләр җирдә ишәйсеннәр;
Туганнары имин яшәсен,
Баш өстендә кылыч яшьнәмәсен,
Татулыкта дөнья яшәрсен.
Кайтмаганнар кайтсын илләренә,
Бәгырьләргә бәллүр булып яткан
Сагыш төере, яшьләр эресен.

Ленин рухы иңсен күңелләргә —
Йөрәкләрдә ташлар эресен.
Үлгәннәрнең урыны тыныч булсын,
Табутында сыкрап кыйналмасын —
Яшәүчеләр эшенә наразый.
Безнең кебек түгел, камил булып
Үссен иде барлык нарасый.

*1972, март*

## ПРОМЕТЕЙ УТЫҢ СҮНМӘСЕН!

Вак мәшәкать, ыгы-зыгы тәмам,
Бар эшемнең чыктым очына.
Шуңа күрә бүген, таңнан алып,
Күкрәгемнән кошлар очырам.

*Мостай Кәрим*

Мостай Кәрим дигән исемне хәреф танып, укый-яза башлаган еллардан бирле беләм шикелле. Дөрес, әле ул вакытта миңа Мостай Кәрим, Фатих Кәрим, Хөсни Кәрим, Ярлы Кәрим, Марат Кәрим дә әллә ни аерылмый, миңа исемнәр берни аңлатмый иде әле. Китаплары гына кызык булсын! Шул сабый малай дәвереннән, ярты гасыр дәвамында ничә дистә мең китап укылмаган да, ничә мең автор исеменә юлыгылмаган! Күпләре онытылган, кайберләре белән үз вакытында тәэсирләнеп, тәмам сихерләнеп, еллар үтү белән хәтер томаннары артында югалган, әмма аерым берәүләре торган саен күңелдә ныграк тамырланган. Мостай Кәрим әнә шул соңгыларының берсе булып чыкты. Ялгышмаганмын — чорыбызның бөек әдипләренең берсе икән ул!

60 нчы елларда әдәбиятта мәңгелек шигырьләр язып калдырырбыз дип ихлас ышанган без — яшь максималистларга Мостай Кәрим исеме үзенә магнит сыман тартып торган шөһрәтле исем иде. Кара, үзебезчә, без аңлый торган телдә яза торган шагыйрь бөтенсоюз, бөтендөнья мәйданында бил алыша! Әнә Балтыйк якларыннан Ленин премиясе алган Э. Межелайтис килеп чыкты. Кавказдан — Р. Гамзатов, К. Кулиев... Ерак Кыргызстанда туып үскән Ч. Айтматовның исеме теллärдән төшми. Казакълардан яшь, темпераментлы О.Сөләйманов калкып килә... Идел буеннан, без татарлардан, нишләп андый гайрәтле әдипләр күренми? Уйландыра иде, бик уйландыра иде бу хәл. Дөрес, татар әдәбиятында да теге яки бу ягы белән әлеге азаматларга тиң, хәтта иҗатларының кайбер сыйфатлары белән өстенрәк әдипләр дә бар барын... Әмма дөньякүләм иҗтимагый яңгыраш алалмыйлар. Нидер җитми. Теге әдип белән бу әдипне бергә кушсаң, фәлән бөек килеп чыгар иде дә бит, дигән уйлар да килгәли иде. Хәер, империя олимпларында утыручылар да татарны артык үстерергә ашкынып тормадылар шул. Бәхетебездән, рухи түбәбезне күтәреп, әле дә ярый легендар Муса Җәлил кайта алды. Үлеме белән үлемсезлек яулап, абруебызны күтәрде... Әмма шул чорда исәннәр арасында бүтән халыклар өчен республика, милләт символы булырлык әдипләр күтәрелеп үк җитә алмады... Шулай да, күрше тугандаш Башкортстан вәкиле булса да, Мостай Кәрим дигән олы исемнең яктысы безгә дә төште, үзебезне хаклы санап, аның белән без дә горурландык.

Башта әсәрләре күңелгә иңеп калган булса, соңрак — 60 нчы еллардан башлап — аның үзе белән дә шактый еш аралашып яшәргә насыйп булды. Кайбер язучы яки шагыйрьнең фәкать әсәрләрен генә белеп яшәү дә бик җиткән. Үзен кеше буларак күбрәк белгәч, кайчак әсәрләреннән алган татлы тоем тоныкланыбрак та кала. Талантлы кешенең холык-фигыле гел генә дә бал-шикәр түгел шул. Ә Мостай ага белән очрашып сөйләшүләр үзе бер гомер. Акыл иясе, олпат, алдан күрүчән зирәк, яшьли аксакал була алган талант... Озын гомер кичергән һәр кеше диярлек миллионлаган кешеләр белән очраша бу дөньяда. Һәркемнең күңелендә сокланулы тойгы калдырып яши алу — үзе бер талант. Исемнең бөек булып формалашуында зур фактор.

Мостай Кәрим Казанга еш килде, Татарстан җәмәгатьчелеге белән һәрчак дустанә мөнәсәбәттә булды. Зур тантаналар, Тукай, Җәлил кебек шәхесләргә багышланган юбилейларда еш катнашты, онытылмас чыгышлар ясады, мәкалә-хезмәтләр язды, бәйрәмнәребезне уртаклашты, табын күрке булды. Үзенең дә байтак китаплары Казанда басылып чыкты. Татар әдәбиятының бөек әдәбият икәнен яшьли үк танып, аның корифейлары белән горурланып яшәде һәм хәзер дә шул тойгылар белән яши дип беләм. Хәсән Туфанга багышланган берничә шигъри юлын гына искә төшерик:

Шагыйрьгә нигә чин кирәк,
Нәрсәгә Аңа титул!
Патшалар ятлап алырлык
Шигырьләр яза бит ул!

Исемнәр димәктән, Мостай Кәрим совет чорындагы илкүләм дәрәҗәле бөтен исемнәрне яулап алган әдип. Ул инде 44 яшендә үк Башкортстанның халык шагыйре иде. Ул — СССР Дәүләт

премиясе лауреаты, РСФСРның Станиславский исемендәге һәм Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое, Ленин премиясе лауреаты... Хаклы алынган дәрәҗәле исемнәрме? Һичшиксез! Бүген кайбер яссы маңгайлылар уйлаганча, сәяси уеннар корып, номенклатура кануннарына ярашып кына андый үрләргә менеп булмый. Акча дигәннәре бүгенгедәй тормыш доминанты түгел иде әле ул чакта. Кешене — кешедән, талантны — талантсыздан, шәхесне инфузориядән бик яхшы аералар иде.

Мостай Кәрим иҗаты — киләчәктә күп буыннар өйрәнерлек гаҗәп бай һәм күпкырлы иҗат. «Европа-Азия» шигырьләр циклы, «Кара сулар» поэмасы, күпсанлы фәлсәфи-лирик шигырьләр аны чорыбызның олуг шагыйре дәрәҗәсенә күтәрсә, «Озын-озак балачак», «Ярлыкау», «Авылым адвокатлары» исемле чәчмә әсәрләре аны проза остасы итеп танытты. Ә «Ай тотылган төндә», «Айгөл иле», «Ташлама утны, Прометей!» кебек пьесалар авторын тамашачылар атаклы драматург итеп бәяләде. М.Кәримнең йөзләгән тәнкыйть, әдәби-публицистик язмаларын укыган кешеләр аны халкының хәким елъязмачысы итеп кабул итте. Төрле жанрларда үз биеклеген саклап, югары кимәлдә иҗат итүчеләр сирәк дөньяда.

Ни гаҗәп, олуг шәхесләр тирәсендә кирәкмәгән, ясалма низаг тудыручылар, мәгънәсез сүз куертучылар да табыла. Кайчак әйткәлиләр: янәсе, ул теләгәндә, татар шагыйре булып китә ала иде! Мостай Кәрим — татармы, башкортмы, россиянмы? Бәлки, бөтенеседер! Шунысы анык: Мостай Кәрим — башкорт шагыйре, башкорт әдәбиятын үстергән, аның яңа бер этабын тудырган, яңа бер сәхифәсен ачкан әдип. Кардәш, тугандаш халыкның бөек әдибе булу без татарларга куаныч, шатлык түгелмени? Әлбәттә, куаныч, әлбәттә, шатлык. Шуңа күрә Мостай ага ул безнеке дә! Гомумкешелекнеке дә. Ә менә соңгысына үзеңнән өлеш кертә алу — анысы инде Ходайның сирәк затлары вазифасы, бөекләр миссиясе.

...Моннан нәкъ утыз ел элек бөтен Башкортстан, ул вакытта ук республика горурлыгына әйләнгән Мостай Кәримнең 50 еллык юбилеен зур тантана, зур бәйрәм итеп үткәргән иде. СССР дигән илнең иң зур язучылары җыелган иде бу юбилейга. Татарстан делегациясе составында Х. Туфан, Г. Ахуновлар белән беррәттән миңа да катнашырга туры килде анда. Ул көннәрдә Уфа күпмилләтле совет әдәбиятының Мәккәсе иде шикелле. Кемнәр генә юк иде анда! Р. Гамзатов, Ч. Айтматов, Д. Көгелтинев, К. Кулиев, Х. Туфан, М. Дудин, Я. Ухсай... Фәкать зур шәхес кенә үз янына үзенә тиң йолдызларны җыя ала.

Белмим, астрономнар берәр яңа ачылган йолдызга Мостай Кәрим исемен кушарлармы-юкмы, әмма шунысы анык: күп миллионлаган укучыларның күңелендә ул иңдергән нур елдан-ел яктырак яна.

Мостай агага бу айда 80 яшь тула икән. Дөресен генә әйткәндә, бу юбилей мине бераз сискәндереп җибәрде, көтелмәгән хәл кебек тоелды. Без аны өлкән яшьтә итеп күрергә гадәтләнмәгән шул. Ул безнең өчен һәрвакыт сәламәт рухлы таза ир-егет. Шулай да... 1942 елны сугышта йөрәгенә пуля ярчыгы килеп кадалгач, ул 80 яшьләргә җитәрмен дип уйлады микән? Ходайга рәхмәт. Бу юлларны язганда, Сара апа Садыйкованың Мостай ага сүзләренә язылган «Өченче көн тоташ кар ява» җыры яңгырап куйгандай булды.

1970 елда язган бер шигырем искә төште. Ул атап Мостай агага махсус багышланмаса да, бу очракта хәзерге уйларыма тәңгәл килә.

Яу-дауларны күргәннәр күп.
Көрәш-шауда җиңгәннәр күп.
Вакыт-яу — иң-иң яманы!
Җиңүчеләр сирәк аны!
Вакыт белән хезмәте тау
ирләр генә алыша ала.
Заман, иелеп, җиңүченең
шанлы исемен алып кала.

*1999, сентябрь*

## ХАЛЫКЧАН ШАГЫЙРЬ

Әлмәттә, шәһәр читендәге биек таш йортларның берсендә шагыйрь Гамил Афзал яши. «Шәһәр читендә» диюем бик дөрес үк тә булмас, чөнки берничә елдан хәзергә «кырый, чит» саналган бу урам-чатлар шәһәрнең үзәгенә әйләнәчәк. Әгәр ул чагында аның турында берәр нәрсә язарга насыйп булса, беркадәр горурлык белән: «Шагыйрь Гамил Афзал яши шәһәрнең үзәгендә», — диярбез. Биш катлы йортның иң өстәге чат бүлмәсе — шагыйрьнең эш урыны. Бу бүлмә, миңа калса, тыштан шактый шыксыз күренгән шушы таш йортның иң тынгысыз, иң ялкынлы төше, йөрәге урнашкан төшедер шикелле.

Биредә шигырьләр туа. Биредә Яхшылык белән Яманлык күзгә-күз очраша. Таһир-Зөһрәләр утында янучы гашыйклар өзгәләнә, ил явында авып калган уллар, терелеп, телгә килә, кышкы бураннарда сыерчыклар әйләнеп кайта, борынгы алмаз кылычлар, айбалталар уйный, абагалар чәчәк ата, космонавтлар ял итәргә туктый. Биредә шигырь туа! Биредә төннәр буе, «таң нурлары җиргә тамганчы, халкына нур көлтәсе бүләк итәргә» хыялланып, шагыйрь иҗат итә. Ул «матурлык эзли, ил туена сүздән чәчәкләр җыя»! Яхшы җыр, яхшы шигырь туган җир — изге җир ул!

Шагыйрь бүлмәсендәге тәрәзәдән карасаң, Зәй әрәмәлекләре, Бигеш кырлары, Урсал таулары, арырак күз атсаң, күкселләнеп, томанланып торган офык читләре күренә, аста Чистай—Казан якларына таба тасма юллар сызылып китә. Бу күренеш, бу панорама байтак татар шагыйрьләренә, каләмнәрен әле яңа тибрәтә башлаган бик күп яшь авторларга таныш дип беләм. Казан яки күрше-тирә районнардан Әлмәткә килеп тә, Гамил Афзалларга керми киткән язучы сирәктер... Аңа киләләр, гаиләсен күреп чыгалар, хәл-әхвәл сорашалар, шигырь укыйлар, чәй эчәләр... Бер уйлаганда, гаиләкөнкүрешкә генә караган бу хәлнең икенче бер мәгънәле ягын күрәм мин, күптән эчтә йөртә торган уема терәк, дәлил табам: кешеләрне сөйми, ялгызак, үз-үзенә бикләнгән кеше яхшы шагыйрь була алмыйдыр; эчкерле, хөсетле, эгоист, заман һәм халык уй-тойгыларына битараф кеше, хәтта талантлы булса да, шагыйрь түгел ул. Шагыйрь күңеле энә күзе кебек тар була алмый. Тар күңелгә ваклык, мәкер сыя алса да, халыкның шатлык-кайгыларына бүтән күңел, киң, ачык күңел кирәк. Кешеләрне ярату, аларны чыннан да табигать таҗы итеп күрү, акылына инану кирәк. Бер шагыйрь үзенең китабына автограф итеп болай язган иде: «Кешеләрне ярату, һай, кыен эш! Шул эштә без чын кешеләр булып калсак икән!» Еллар үткән саен, бу сүзләрнең мәгънәсен тирәнрәк тоя барасың. Г. Афзалның да кешеләр турында мондый юллары бар:

Йөз кабат сөртенәм, абынам,
Йөз кабат таянам кешегә.
Йөз кабат кимсенәм, алданам,
Йөз кабат ышанам кешегә.
Йөз кабат читсенәм, шикләнәм,
Йөз кабат кизәнәм кешегә.
Йөз кабат сөенәм, хушлашам,
Йөз кабат сокланам кешегә.

Яки менә икенчесе:

Язам-сызам, язам-уйлыйм, ярармы, дим.
Кешеләргә файдамы бу, зарармы, дим.
Хурлыйммы мин, зурлыйммы мин аларны, дим.
Ак намусым күзен тутырып карап тора.

«Ак намусың күзен тутырып карап торганда», кеше күңеле түрендәге туры итеп әйтми кала аламы соң! Менә Г. Афзалның «Үзем турында» дигән шигыре:

Күзләремнең нурын,
Йөрәгемнең моңын
Кураема салып җыр итәм.
Йөзем аклыгы да,
Күңел шатлыгы да
Минем өчен шаян җыр икән.
Бәхет балкыр заман.
Ә мин ятып язам.
Күпме сагыш килде өелеп!
Үзем сүнеп ятам,
Үзем көлеп ятам,
Кеше бәхете өчен сөенеп.

Гамил Афзалга килгән кеше аның язу өстәлендә, китап шкафларында яткан амбар кенәгәләренә игътибар итми калмыйдыр. Аларда булачак шагыйрьнең өйрәнчек шигырьләре дә, татар шигърияте хәзинәсенә керерлек нәфис эшләнгән соңгы дәвер шигырьләре дә бар. Алар — 16 данә. Һәммәсендә борынгы язма китапларга хас пөхтәлек белән тигез юллар тезелгән. Дөресен әйткәндә, ул кенәгәләр мине башта бераз сәерсендергән дә иде, — айга менгән заманда, язу эше белән шөгыльләнгән һәр кешенең диярлек «Оптима» яки «Эрика» кебек язу машиналары булган чорда, дебит-кредит графалары сызылган соргылт-сары битле бу шыксыз кенәгәләр гаҗәпләндергән иде. Хәзер инде алай түгел. Хәтта аерым-аерым битләргә караганда бар язганың бергә теркәлеп бару ягыннан хуп та күрәм.

Шулай да беркөн, ярым шаяртып:

— Гамил абый, бу амбар кенәгәләрен каян табып бетерәсең? — дигән идем, ул балаларча җитди һәм беркатлы итеп:

— Менә бусын, кызыл тышлысын, балдыз Урта Азиядән алып кайтты, ә менә бу икесен үзебезнең Миңнур биргән иде, — диде.

Әйе, кемнәрдер акча ясарлык шыгырдап торган кәгазьләргә, кемнәрдер амбар кенәгәләренә яза. Ул кәгазьләргә төшкәннәрнең чын бәясен киләчәк әйтер. Кем белә, килер буынның Альберт Фәтхи кебек китапчы-галимнәре, 60 нчы еллар татар шигъриятен өйрәнгәндә, бәлки, беренче чиратта әнә шул амбар кенәгәләрен бик кадерле кулъязмалар итеп өйрәнерләр, һәрхәлдә, шулай булсын иде, дияик, шуңа юрыйк.

Г. Афзал 1921 елда Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылында туа. Нәни Гамилнең дөнья белән таныша башлавы җирнең шушы ноктасыннан башлана. Монда тел ачылган, чишмәләрнең серле чылтыраулары тыңланган, күзләргә беренче күргән таңнарның нурлары иңгән, беренче такмаклар әйтелгән.

Гамилгә өч яшь тулгач, әнисе вафат була. Унынчы яшькә чыккач, Афзаловлар семьясы Урал-Магнитка якларына күчеп китә. Малайның Одиссеясе! Беренче мәртәбә идәне дә, стенасы да, түшәме дә таш йортларны күреп шаккатулар, «электр» дигән керосинсыз лампаларга ис китүләр, киң, коточкыч тирән Кама-Чулман елгасы, андагы ап-ак пароходлар, челтәр күперләр, чуен юлларны кыздырып үтүче паровозлар... Туган авылдан китү — булачак шагыйрь Гамилдә мәңге онытылмаслык кичерешләр тудырып, онытылмаслык хатирәләр калдырган. Әле быел гына язылган, беркадәр Г. Тукайның «Исемдә калганнар»ын хәтерләткән, «Юл башы» дип аталган автобиографик язмасында автор гомеренең бу көннәрен тормышының кискен бер борылышы — зур дөньяга чыккандагы юл башы дип саный. «Бөтен халык утырып беткәч, паровоз ак парлар чыгарып бер-ике пошкырды, озын итеп: «Ки-и-и-т-тек!» — дип кычкырды да ләштер-ләштер кузгалып китте. Уралга барабыз, Уралга! Урманнар, кырлар, күгелҗем офыклар, кечкенә инешләр, телеграм баганалары артка йөгерәләр. Без ак болытларга каршы, биек тауларга каршы йөгерәбез. Вәсилә апа әкрен генә, борын эченнән генә җырлап бара:

Телеграм баганасын
Саныйсым калган икән;
Күз керфекләрем талганчы
Карыйсым калган икән...

Без Уралга барабыз. Авыл урамнары, кычытканлы читән буйлары, тыкрык әрекмәннәре, какылы ындыр артларыннан башка берни күрмәгән авыл малаена бу сәяхәт киң дөньяга чыгу иде. Үсеп килә торган, барын да күрергә, барын да белергә тырышкан балага дөньяны тану, тормышны өйрәнү өчен сикәлтәле юллардан йөрү бик кирәк икән. Бәрелә-сугыла йөреп, күп михнәтләр күрсәм дә, язмышка бер тамчы да үпкәм юк, үземчә бик кызык булды минем тормышым. Мин бик бәхетле кеше».

Яңа җирләрнең үзгә матурлыгы һәм кырыслыгы, төрле мәктәпләрдә белем эстәп йөрүләр... Башта — Магнитогорскида җидееллык мәктәп. Аннан — Троицк педагогия училищесының беренче курсы, аннан — металл кою заводлары, Мартен мичләре, һәвәскәрләр белән «Галиябану», «Ак калфак»ларны сәхнәләрдә уйнаулар. Тагын завод. Бу юлы инде сугыш ихтыяҗына эшләүче заводлар. Үзгә киеренкелек, үзгә ритм. Үсмер чакта ук аягын имгәткән Гамил илленче еллар башында тәмам түшәккә егыла.

Сизәм, сызлыйм, сөенәм, тынмыйм һич тә.
Бөтен дөнья сыйган минем эчкә.
Мин түшәмгә карап уйлап ятам
Иртә дә, көндез дә, кич тә.
Аксын әле, егет, синең кулда,
чәчеп ялкын!
Шушы ташкын җиңү алып барды
Эльба ярларына,
Шушы ташкын ирек алып барды
Карпат тауларына.
Корыч кошлар илнең күкрәгендә,
Корыч линкор диңгез өсләрендә —
безнең куллар көче.
Мин үзем дә завод цехларында
тимер юнган кеше.

Сугышта Кавказ таулары итәгендә ятып калган яшьлек дусты, яшь шагыйрь Касыйм Таһиров истәлегенә язылган «Табылдык дәфтәр» шигырендә шагыйрь ул дәһшәтле сынау елларын тагын бер кат хәтеренә төшерә:

...Авыр сулап валлар ухылдады,
Боерык булып килде бар нарядлар:
— Снарядлар кирәк, снарядлар!
Отпуск та, ял да сораучы юк,

Атып үлү яхшы кол булганчы!
Кара таңны кара төнгә ялгап,
Сменалар эшли егылганчы.

Авыр еллар, сынау, чыныгу еллары барыбер гомернең бик газиз еллары... Сау бул, Урал!

Бодай кырларына тарта йөрәк,
Гудокларга күңел күнсә дә;
Болыннарның саф һавасы кирәк
Гөлләр исен сөйгән үпкәгә.

Теге яки бу дәрәҗәдә шәхси тормышы белән авылга бәйләнмәгән, җиргә мөнәсәбәте булмаган татар шагыйрен табу, гомумән, кыен. Берәүләр туган җире — авылын яшел бишек, берәүләр алтын бишек, диләр, һәркем үзенчә хаклы. Эпитетларны һәркем үзенчә сайлый, сүзнең төбе, мәгънәсе бер: авыл, чыннан да, күпләребез өчен бишек. Г. Афзалның яңадан авылга, табигатькә, ике дистә елдан артык аерылыбрак торган җир кешеләренә әйләнеп кайтуы аның рухи тормышында икенче бер зур борылыш булды.

1954 елга кадәр, Башкортстанның ямьле табигать кочагында утырган Шәрип авылына күчеп кайтканга кадәр, булачак шагыйрьнең тормыш университетлары чоры, аның кеше, гражданин буларак чыныгу чоры, туачак әсәрләренә хәзинә-материал туплау чоры. Г. Афзалның «Магнитогорск» дигән беренче шигыре матбугатта 1937 елда ук басылса да, 1955 елларга кадәр шагыйрь үзен таныта алмады. Дөрес, ул язмый тормаган, язган, шигырьләрен газета-журнал редакцияләренә, шагыйрьләргә (бигрәк тә С. Хәкимгә) җибәреп торган... Күрәсең, талантының әдәбиятка бәреп керерлек көче әле максатлы хәрәкәткә килә алмаган, нindидер яңа шартларга кадәр тыелып торган. Бу җәһәттән шагыйрьләр мәйданына чыгар алдыннан бик зарур — кайнап торган әдәби мохитнең булмавы, махсус әдәби белемнең җитенкерәмәве дә, һичшиксез, сәбәп булмый калмагандыр. Г. Афзал гомеренең бу чорын сагыш катыш көлемсерәп, сагынып, беркадәр горурланып искә ала:

Көрсенмә син, күңел,
Көрсенмә!
Йөгереп үткән якты елларыңның
Эзсез диеп булмый берсен дә,
Төссез диеп булмый берсен дә.

Яки:

Бишьеллыкның данлы төзелешләре
Урал даласында еракта...
Күзем йомсам, күз алдымда тора,
Гөрелтесе шаулый колакта.

Дөрес, болар соңрак язылган шигырьләр. Ләкин алар ул вакыттагы тәэсирләрнең, ул чордагы уйхисләрнең нәтиҗәсе, дистә еллар соңыннан кире кайткан яңгырашы. Ил белән бергә, халык белән бергә булганда, Ватан хакына, җиңү хакына көрәшкәндә ничек итеп ул елларны эзсез, төссез дип әйтеп булсын!

Дулап-дулап кызыл улак буйлап
Кызыл ташкын ага,
Бөгелмәдем,
Бирелмәдем чиргә.
Моңын җиңеп кайгы-сагышның,
Тешем кысып,
Шушы туган җиргә
Ун тырнагым белән ябыштым.
Һәм
Җир бирде миңа Салсал көчен,
Иркен сулыш өрде үләннәр...

Ә дөнья шундый матур, шундый киң! Табигатьтә мәңгелек хәрәкәт, мәңгелек яшәү! Яңадан, балачактагыдай, язлар килә, сыерчыклар бала чыгара... «Җир яшәрә сугышлардан туеп, гашыйк булган үзе кояшка!» Яшәргә! Яшәргә!

Чөнки:

Күктә кояш, җирдә гөлләр,
Алда юллар, юлда мин.
Күктә йолдыз, җирдә ярым,
Сөйгән ярым гөлгә тиң.
Дөнья матур, дөнья киң!
Күктә нурлар, җирдә дуслар,
Дус янында кем ятим?!
Күктә нурлар, җирдә шатлык,

Җирдә бәхет гөлгә тиң.
Дөнья матур, дөнья киң!

Авылда бераз яшәп савыга төшкәч, ниһаять, Гамил Афзалның да шушы «матур, киң дөньяның» шигърият атлы симфониясендә үзенчәлекле авазы яңгырый башлады. «Авыл, табигать тәнемә сихәт, күңелемдәге уйларымны кешеләргә илтер тел бирде», — ди шагыйрь. 1955 елда аның бер цикл шигырьләре балалар өчен язылган шигъри әсәрләргә конкурста премиягә лаек булды. Аларның күбесе шагыйрьнең «Кар сулары» исемле китабында 1957 елда басылып чыкты. Магнитка якларына китү — киңрәк тормышка юл башы булса, бусы инде зур әдәбиятка юл яру иде. Шуннан соң унбиш елга якын гомер үтте һәм шагыйрьнең татар телендә унбиш китабы басылып чыкты. Ул китаплар кибет киштәләрендә кадерсезләнеп, тузанланып ятмадылар, аларның күбесе күңелләрдә урын тапты. С. Хәким дә аның бер китабына язган кереш сүзендә: «Ул әдәбиятка үзеннән алда кергән кайбер өлкән буын шагыйрьләренә караганда да үзенең укучыларын тизрәк тапты», — ди. Хәзер, шагыйрь татар поэзиясендә нык урын алгач, аның иҗаты турында уйланып, үзеңне кызыксындырган кайбер сорауларга үзең үк җавап эзлисең. Шагыйрьнең илһам чыганагы, таяну ноктасы кайда? Остазлары кем? Иҗатының нинди сыйфатлары укучыга газиз? Чагыштырмача тиз арада шигырьләрнең популярлашып китүенең сәбәбе нәрсәдә?

Шагыйрьгә, гомумән, теләсә нинди жанрда иҗат итүче әдәбият кешесенә талантының үрләп китүенә төп шарт — рухына, җанына муафыйк табигый җирлек, табигый мохит булу. Г. Афзал — авыл баласы, табигать баласы. Табигатьне бөтенебез яратабыз. Ләкин үз яратуы бүтәннәргә дә күчәрлек итеп ярату, аның гүзәллеген, сафлыгын кешеләр күңеленә күчерә алырлык дәрәҗәдә җырлый алу — талантларга гына бирелгән. Г. Афзал табигатьне бик нечкә тоеп, садә һәм халыкчан итеп тасвирлый ала, тасвирлап кына калмый, аны кешеләр күңеленә якынайта, яки кешенең үзен табигатькә күзгә күренмәс җепләр белән бәйли, аларның берлеген искәртеп тора. Аның тугайлары, болыннары, тирәкләрендә рәшә булып кешенең шатлык-сөенечләре уйный, томан булып сагыш иңә, әрем-куакларны иркәләп искән талгын җилләренә кеше тоемы ияреп йөри. Менә берничә мисал:

Соры дулкын булып арыш җитә,
Болыннарда зәңгәр моң йөри...

Яки:

Урман буйларында соры юрган,
Галиябану монда арыш урган.
..........................................
Көтү үткән тугайларга тулып,
Минем моңым агыла томан булып.

Яисә:

Кырлар яшел, күкләр зәңгәр сатин,
Таңнар комач кебек...
Гомер буе карап торсаң да син
Күреп туймас кебек.

Г. Афзалның 50 нче еллар ахырында әдәбиятка үзенең юмористик һәм сатирик шигырьләре белән омтылышлы керүе — аның үз геройлары арасында яшәвендә, авыл кешеләренең гадәт-психологиясен нечкәләп белүендә, аларны аңлый алуында. Ул алар турында яратып, сөеп яза. Күпчелек очракта ул кешеләр аңа рухи якын, үз кешеләр. Шагыйрьнең аларга кешелекле эчке бер җылы хисе бар. Юкса ул аларның рухына, эчке дөньяларына үтеп керә алыр идеме, алар теле белән, алар булып яза алыр идеме?! 50—60 нчы еллар колхоз авылының байтак кызык, кабатланмас типларын үзенчә буяулар белән калку итеп күрсәтеп бирә алды шагыйрь. Аның геройлары билгеле бер төбәкнеке, әйтик, Шәрип авылы тирәләренеке генә түгел, гомумән, Урта Идел, Урал буйлары татар авылларыныкы. Алар типик геройлар. Алар һәр авылда бар. Кайберләрен генә исегезгә төшерегез: ат караудан зур юаныч табучы колхозчы Сабирҗаннар, яшьләрне чак кына сүгеп, картлыкның да яхшы якларын табып, җаннарын тынычлатучы Фәтхелсәлим агайлар, махра урап, политика сүткәннән соң, янкичәнкиләргә ачу итеп, «печтек кенә салгалап» кәефләнүне дә читкә куймаучы Гаптелислам агайлар, өй борынча сүз җыеп, сүз чәчеп йөрүче Мәүҗидәттәйләр, харам малга кулы ымсыныбрак тора торган Сәлимгәрәй җизниләр, бераз мактанчыграк Сәләхетдин бабайлар, теленнән очкын, кулыннан ут уйнатып, көләч йөзле кодачаларга ялт иттереп мич чыгаручы җор Шиһабетдиннәр, ава-түнә йөрүче бригадир Ахуннар...

Г. Афзалның авыл кешеләре турында елмайта-көлдерә торган шигырьләре матбугатта чыгу белән, укучы үзенең танышларын, күршеләрен, авылдашларын күрде, бик оста язылганнарын ятлап алды, сәхнәләрдән сөйләде, көйгә салды. Чөнки ул шигырьләр тормышчан иде, халыкчан иде.

Шагыйрь халыктан алганны, күңеле аша үткәреп, тәртипкә, көйгә салып, янәдән халыкның үзенә кайтарып бирде.

Шагыйрьнең китаплары турында, авылча, халыкчан теле турында, гомумән, юмористик һәм сатирик шигырьләре турында моңа кадәр матбугатта байтак язылды. Бу төр шигырьләрнең художество үзенчәлекләре хакында махсус мәкаләләр дә булды. Җыйнап әйткәндә, Г. Афзалның 50—60 нчы еллардагы юмористик һәм сатирик шигырьләре татар поэзиясендә кызыклы, мәгънәле күренеш иде.

Г. Афзал югары уку йортларында махсус белем алган кеше түгел. Ул тумыштан нечкә хисләргә бирелеп, көйләр тыңлап, халык арасында рухи чарланып, хикмәтле сүзләр ишетеп, түбәннән күтәрелгән табигый талант. Ләкин тормышта тиктомалдан гына могҗиза ясалмый, сәбәпсез нәтиҗә булмый. Г. Афзалның да шагыйрь булып китүенә күп факторлар сәбәп. Аның да өйрәтүчеләре, остазлары булган. Шагыйрь нечкә тоемлы күңелгә, чичәннәрнекедәй телгә ия. Ул, беренчедән, бу байлыгы белән табигатькә һәм гасырлар буена мирас-хәзинә булып килгән уй-фикерләрне садә итеп, ягымлы, тапкыр һәм төзек итеп әйтеп бирергә сәләтле халык теленә бурычлы. Икенчедән, шәхси остазларга бурычлы. Г. Афзал өчен алар — Г. Тукай, Ш. Бабич, Такташ... Хәзерге көндә Тукай традицияләрен тугрылыклы рәвештә дәвам иттерүчеләрнең берсе, һичшиксез, Г. Афзал. Бу жанрлар ягыннан да, тематик яктан да раслана. Мәсәлән, Н. Исәнбәткә багышланган шигырьләр циклында мондый юлларны укыйбыз:

Мин бу җирдә төпле хуҗа, туган,
Рәхмәт әйтеп алдым әзерне.
Тукай, Бабич кулы сыйпап узган
Һәр чәчәге миңа кадерле.
Миңа илләр, еллар сере ачык,
Төсен таныйм акның, караның.
Даһиларның иңбашына басып,
Заман үрләренә карадым.

Тукай, Бабичлар үзләренең мираслары — гүзәл шигырьләре белән рухландырып, көч өстәп торсалар, Г. Афзалның әдәбият мәйданына чыгуында күренекле шагыйрь С. Хәкимнең роле бик зур. Ул аның өмет дусты — киңәшчесе һәм укытучысы.

Бүгенге әдәбиятта Тукай традицияләрен дәвам иттерүче булып саналучылар яки саналырга әзерләр байтак табылырга мөмкин. Ләкин аңа лаек булу кирәк бит әле! Тукай традицияләрен дәвам иттерү — беренче чиратта, заман һәм халык улы була алу, ил алдында торган иң актуаль мәсьәләләрне үз итеп кабул кылып, хәл итәргә алыну, чын гражданин булу. Әлбәттә, бу олы бурычларны үтәргә талант кирәк, идеаллы максат кирәк, йөрәк кирәк.

Фәлсәфәне ничек кенә боргалама,
Берәр генә өч нәрсә бар бу дөньяда.
Иң кадерле,
иң мөкатдәс,
иң изге зат:
Туган илең,
Туган телең,
Туган ана.

Р. Кутуйның «Ленинга карап» исемле новелласы бар. Анда балаларча беркатлы, әмма рухы нык, күңеле нечкә берәүнең, урта яшьләрдәге авыл кешесенең Мәскәүгә беренче тапкыр килгәч, кешеләр торганчы, иртүк, бәйрәмчә киенеп, Ленин янына мавзолейга баруы сурәтләнә. Әсәрдә исеме күрсәтелмәсә дә, ул — Г. Афзал. Моннан өч-дүрт ел элек бер-төркем язучылар Мәскәүгә барып татар әдәбияты көннәре үткәреп йөргәннәр иде. Шагыйрь Р. Кутуй Гамил Афзал белән «Украина» гостиницасының бер бүлмәсендә тора. Рөстәм аны натурадан кәгазьгә күчергән. Укып карагыз, көлке шигырьләрен яратып укыган шагыйрегезнең лирик җанын беркадәр аңлый төшәрсез! (Шунысы да кызык, Г. Афзал үзе дә мавзолейны күрү тәэсиреннән нәкъ шул ук исемдә шигырь иҗат итә.)

Шагыйрьнең 15—20 еллык иҗатын яңадан күздән кичереп, китапларын кат-кат укып, анализлап карагач, бәй, дип куясың — юморист Гамил янында лирик Гамил бер дә ким түгел лә баса! Г. Афзалның 50 нче еллар урталарында язылган «Дөнья матур, дөнья киң», «Матурлык эзлим», «Шиһабетдин», «Коммунист йөрәге турында баллада», «Ана», 60 нчы елларда иҗат ителгән «Идел ага», «Ел буе», «Моң» һәм соңгы елларда басылып чыккан «Ленин булып уйлап кара», «Фәлсәфәне ничек кенә боргалама», «Ак күгәрчен», «Үткәннәрне онытырга кирәк», «Искә н җилләр сөйли» һәм башка бик күп лирик-публицистик, лирик-интим шигырьләре моңа яхшы дәлил була алырлардыр. Шуңа өстәп республикабызның күренекле композиторлары тарафыннан көйгә салынган «Дөнья матур, дөнья киң», «Татарстан таңнары», «Гөлмәрьям», «Газинур», «Әлли-бәлли», «Очрашу» кебек җырларын күрсәтеп үтү дә әле әйтелгән фикерне куәтле дип уйлыйм. Шулай да лирик һәм сатирик Г.

Афзал хакында уйлаганда, яшьтәш шагыйрьләремнән берсенең күптән түгел генә әйткән сүзләре хәтергә килә. «Миңа, укучы һәм әдәбият кешесе буларак, сатирик Афзал кирәгрәк тә, якынрак та. Иҗатындагы һәр ике якның уңышларын инкарь итмәстән, шуны әйтәм: безнең әдәбиятта аның кебек сатирик юк диярлек, ә аның белән тигез яки аннан көчлерәк лирикларны бармакларны бөгеп санарга була...» Нигездә төпле фикер бу. Ләкин шунысы бар: шәхеснең, шагыйрьнең объектив иҗади эволюция процессын теләү, кушу яки боеру белән генә капыл үзгәртеп булмый. Инде сүз Г. Афзалның юмор-сатира өлкәсендәге эшчәнлеге турында икән, минемчә, соңгы еллардагы бу юнәлеш шигырьләре 50—60 нчы елларда иҗат ителгәннәреннән өстен түгел. Кемгә ничектер, минем өчен аның «Мыек борам», «Өф-өф итеп», «Кызыл балчык» артелендә», «Тотып җибәр, апаем» кебек әсәрләре соңгы елларда басылып чыккан «Бөркет», «Мине картайткан, йөзне саргайткан өч нәрсә», «Шомакойрык белән Сарытырнак диалогы», «Автор киңәш итми», «Кара песинең этлеге» исемле шигырьләренә караганда көчлерәк. Элегрәк язылганнарының көлдерү хасияте белән бергә мәгънәләре тирәнрәк, социаль яңгырашлары үткенрәк, көчлерәк иде. Мәгълүм нәрсә: көлүнең, сатираның объекты, гадәттә, конкрет, һәм шуңа да, сатираның үсеше, шәхеснең талант дәрәҗәсе белән бергә, җәмгыятьнең, тормышның конкрет үсеш этапларына, күренешләренә һәм типларына бәйле. Тәвәккәл әбиләр, бригадир Ахуннар конкрет бер заманның типлары иделәр. Инде ул чорлар узды. Колхозлар үзгәртелде, кешеләре үзгәрде. Ләкин «һәр заманның була үзенә күрә сволочы (каһәр суккыры!)» дигәндәй, бүгенге көндә дә сатираның үткен угына бик лаек типлар бар. Андыйларны авыл җирендә дә, шәһәрдә дә табып була. Тик аларны таный белергә, иң характерлы, гыйбрәтле якларын тотып, җәмгыятьнең алга барышына комачаулаучы көч икәнлекләрен фаш итеп, көлдерә белергә кирәк. Ә аларның үзләрен, психология-гадәтләрен, мохит-җирлекләрен белмәгәндә, ничек фаш итмәк кирәк?! Бу — асылда анык хакыйкать — тормышны тирән белүгә, өйрәнүгә кайтып кала. Бу безнең бөтенебезгә, шулай ук «кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла» дигәндәй, Г. Афзалга да карый.

Шагыйрьнең сатирасы һәм лирикасы турындагы фикерне түгәрәкләр алдыннан тагын шуны да әйтү кирәк булыр: лириканың һәм сатираның төп функциональ аермаларыннан тыш, тәэсир итү формалары да шактый үзгә. Юмор-сатира — гаять тиз тәэсир итүчән, чөнки сүз — конкрет, объект — конкрет, тасвирлау, сурәтләү чаралары — эффектлы, бай. Шуңа да уңышлы сатирик шигырь сәхнәдән яңгырауга, зал алкышларга, шаркылдап көлүләргә күмелә. Шигырь шартлый, бенгаль утлары кебек ахырынача янып бетә. Кабатлый башласаң, эффект югала, кими, тагын кабатласаң — тагын күбрәк кими... Бәлки, шуңардыр, авыл сәхнәләреннән бик күп яңгыраган «Ир бала яхшымы, кыз баламы?», «Тәвәккәл әби», «Әсмабикә җаным, ахирәт»ләр хәзер алай ук тәэсир итми. Чөнки күп тыңланган, күп ишетелгән. Ә менә лирик шигырьнең табигате башкачарак, үзгәрәк. Ул сәхнәдән дә бүтәнчәрәк кабул ителә: озаграк, салмаграк, ләззәте дә «күңелнең хис тартмачыкларына» туфракка сеңүче тамчылар кебек әкрен юл ала... Ни хикмәттер шагыйрь йөрәгеннән чыккан җитди шигырьләр беркайчан да туйдырмыйлар, кабат укыган саен, алар сиңа нидер өсти, яңа кичерешләргә этәрә, яңа ассоциацияләр тудыра. Тукайның «И мөкатдәс моңлы сазым...» яки «Галибанә яктырып әкрен генә ал таң ата...» кебек юлларын инде уннарча кабат укыган булсаң да, һаман күңелнең иң нечкә кылларына кагылып тәэсир итү көчен югалтмыйлар. Г. Афзалның «Дөнья матур, дөнья киң», «Моң» кебек башка байтак җитди шигырьләре дә искерер өчен язылмаганнар шикелле.

Г. Афзал, үзе әйткәнчә, бәхетле кеше, бәхетле шагыйрь. Әдәбият мәйданына үз яшьтәшләреннән соңарып килсә дә, ул татар поэзиясенең күренекле иҗатчысы, халыкның популяр шагыйренә әверелде. Бу соңгы дистә еллар дәвамында үз репертуарларына Г. Афзал шигырьләрен яки җырларын кертмәгән татар сәхнәсе, мөгаен, юктыр. Китапларыңның куллардан кулларга, язганнарыңның күңелләрдән күңелләргә күчеп йөрүләрен тою — һәр иҗат кешесе өчен зур куаныч. Г. Афзал шул куанычка, шул бәхеткә ия шагыйрь.

Соңгы елларда шагыйрь нәрсәләр язды, хәзер нинди әсәрләр иҗат итә, дип сорарлар. Әлмәттә яшәү дәверендә, алты ел эчендә, ул унга якын шигырь китабы чыгарды. Күпсанлы лирик һәм сатирик шигырьләр белән беррәттән, «Искән җилләр сөйли», «Сөембикә сылу», «Назыйм Хикмәт» кебек эпик пландагы озын шигырьләр иҗат итте. Үткән елда Г. Афзал чәчмәдә дә үзенең каләмен сынап карады. Унбиштән артык кечкенә күләмле сатирик хикәяләр язды. Язган берсен диярлек безгә — каләмдәшләренә күрсәтеп килә, җыелышып укыйбыз, кызыксындырырлык хикәяләр! Кайберләре инде «Чаян» журналында басылып та чыкты! Әйе, шагыйрь иҗат итә, үзен төрле жанрларда сынап карый.

Г. Афзалның 16 нчы амбар кенәгәсендә кыска гына бер шигыре бар. Ике юлы болай:

И Ходаем, хур итәргә теләмәсәң,
Шагыйрьләргә байлык бирмә, власть бирмә!

Әле моңарчы татар шагыйрьләренә байлык дигән афәтнең куркыныч булып килеп басканы юк, һәм, мөгаен, басмас та, — аннан бик вәсвәсәләнгән юк, минем курыкканым бүтән: берүк, Ходай,

шагыйрьләргә тынычлану, битарафлык бирә күрмә, «классиклык чирен» йоктыра күрмә, күңелләренең илаһи пакь чагында язганнарына тугры итеп калдыр!

Шигырь булып туды әманәтем,
Шигырь булып чыкты хәсрәтем,
Матурлыкка — чиксез мәхәббәтем,
Явызлыкка — чиксез нәфрәтем! —

ди безнең Гамил.

Шагыйрь үсештә. Ә үскән саен, үрләр биегрәк. Алда дөнья кадәр эшләр тора! Галиябануларны (шагыйрьнең яңа туган кызының исеме) үстерәсе бар. Үскәч алар да «Дөнья матур, дөнья киң!» дип җырлый алсыннар өчен, ил тормышы — тыныч, имин, халык күңеле — көр һәм кешелекле, шигърият баскычы һәрчак гүзәл булсын һәм җимешле булсын өчен күп көч куеп бергәләшеп иҗат итәсе бар. Яңа уңышлар, яңа иҗади шатлыклар сиңа, шагыйрь дустыбыз Гамил Афзал!

*1970, декабрь*

## ХУШ, ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ!

Газраил һәрчак аяусыз, үлем һәрвакыт үкенечле... Гамил абыйның вафат хәбәре аны якынрак белгән кешеләр өчен көтелмәгән хәбәр түгел иде: байтактан бирле каты авыру халәтен белә идек. Гомумән, гомере буе диярлек саулыкка туеп яшәмәде. Шулай да, хөр фикерле, рухи сәламәт булып, 82 елдан артык гомер кичерде. Раббыбызга рәхмәт. 70 нче елларда Әлмәт төбәгендә бергә-бергә иҗат иткән каләмдәшләр — Гамил Афзалдан яшьрәкләр күптән инде гүр ияләре. Шамил Бикчурин, Мәхмүт Хәсәнов, Саҗидә Сөләйманова, Фәрит Гыйльми...

Гамил Афзал чын мәгънәсендә халык шагыйре иде. Мотлак шулай булып калыр да. Аның тапкыр, шаян шигырьләре, дәртле, моңлы җырлары ярты гасыр буе татар яшәгән, татар теле яшәгән төбәкләрдә киң яңгыраш тапты. Заманында Гамил Афзал шигырьләре яңгырамаган сәхнәләр сирәк булгандыр. Гамил Афзал халык иҗатыннан кирәкле хикмәтне, кирәкле моңны ала белеп, аларны күңеле, йөрәге аша үткәреп, шул байлыкны яңа, уңышлырак вариантта янәдән халыкка кайтарып бирүгә ирешә алды. Иҗатының көче, мөгаен, шундадыр аның.

Соңгы кырык елда Гамил абый беркая да чыкмыйча диярлек тоташ Әлмәттә яшәде. Ерак сәфәрләрдә, чит мәмләкәтләрдә йөрергә мөмкинлеге дә, артык теләге дә булмады шикелле. Ара-тирә Казанга килеп-китүне исәпләмәгәндә, яшәү пространствосы нигездә Әлмәт булды. Мине һәрчак бернәрсә гаҗәпләндерә иде: яңа җирләр күрмичә, яңа кешеләр белән артык аралашмыйча, яңа тәэсир-тойгылар кичермичә, ничек бу Шагыйрь заман сулышын шулай сизгер итеп тоя ала икән? Язганнары аның гаҗәп актуаль бит! Күрәсең, хикмәт талант кодрәтендә, геннар яшәүчәнлегендә. Мөгаен, аның ерак бабалары затлы, аксөяк нәселдән булгандыр. Утызынчы елларда хәлле, мөлкәтле, җир-йортлы булганнары өчен авылның ярлы әтрәк-әләмнәре Афзаловларны тикмәгә генә Себер якларына сөрмәгәннәр шул. Гамил абый бу гаделсезлеккә гомере буе әрнеп яшәде... Әмма бөгелеп яшәмәде, горур яшәде, мәгънәле яшәде!

Алдымда Гамил Афзалның берничә фотосурәте. «Казан утлары» журналында чыгачак некролог өчен рәсемен сайлыйбыз. Менә аның алтмышынчы елларда төшкән бер рәсеме. Фотоның икенче ягында мондый сүзләр:

Үлем авыр, диләр, дөрес түгел.
Үлем юлы авыр, минемчә.
Яшьлек чәчәкләрен коя-коя,
Идеалларың тереләй күмелсә.

Идеалларын байрак итеп югары тотты Шагыйрь. Аның идеалы, максаты — халыкка хезмәт итү иде. Бу юлда ул бик күпләргә үрнәк булырлык батырлык кылды — сөйгән халкына Олуг иҗат мирасы калдырды.

Гамил Афзал исемле мәшһүр Шагыйрь фани дөньяны бакый дөньяга алыштырды. Шагыйрь җаны кешеләр күңеленә күчеп, яңа яшәү рәвеше алды. Үлем — бөтенебезгә насыйп өлеш. Кешеләрнең яше-карты булса да, Үлемнең яше юк. Әмма кешеләрдә әле Иҗат белән Үлемсезлеккә омтылу дигән Бөек Көч тә бар. Гамил Афзал әнә шул көчкә ия шәхес иде. Рухың шат булсын, Шагыйрь.

*2003, 26 август*

## ҮЗБӘК АБЫЙ ҮЗ ИДЕ...

Үзбәк Саттаров, язучы булудан бигрәк, иң әүвәл Татарстан нефть хуҗалыгының зур бер җитәкчесе, оештыручысы булып хәтергә килә. Ул озак еллар «Татнефть» берләшмәсенең генераль директор урынбасары булып эшләде. Ул елларда нефть эше башында үзебезнең җирлектә туып үскән зур җитәкче кадрлар аз иде әле. Күбесе килгән, дөресрәге, китерелгән кешеләр иде. Алар, гадәттә, күпмедер эшләгәч, дан-дәрәҗәләр алгач, җиңел килгән кебек, җиңел генә китеп тә баралар иде...

Үзбәк Газиз улы — Әлмәт кешесе, нәсел-нәсәбәсе белән шушы җирнеке. Заманында Казан химия-технология институтында укыган, Ватан сугышында катнашкан, нефтьче һөнәренең бөтен нечкәлекләрен үзләштергән, зур һәм катлаулы тормыш юлы үткән кеше иде. Халыкта «башлы кеше» дигән сүз бар. Үзбәк абый чыннан да бик башлы һәм зыялы зат иде. Югары квалификацияле белгеч-инженер, уйлап табучы, техник фәннәр кандидаты, нефть һәм газ эшкәртү буенча күпсанлы фәнни хезмәтләр авторы. Нефтьне товар рәвешенә кертү өчен беренчел эшкәртү ысулларын эшләүгә зур өлеш керткән кеше дип саный аны белгечләр. Ул билгән постның рәсми исеме дә «нефтьне эшкәртү буенча генераль директор урынбасары» дип тикмәгә аталмый иде шул.

Югарыда әйтелгәннәр Үзбәк Саттаровның мәшһүр технарь икәнен расласа, якыннан аралашып йөргән кешеләр аның нечкә күңелгә, үткен телгә, образлы күзаллауга, әдәби куәскә ия шәхес итеп тә белә. Ул әдәбият-сәнгатьне үлеп ярата иде. Татарның зур талант ияләрен шәхсән белә, аралаша, хәл кадәри татар рухын күтәрүгә булышлык итәргә тырышты. Хәтердә, Әлмәткә Г. Бәширов, Х. Туфан, Ә. Еники, С. Хәким кебек зур язучылар, шагыйрьләр килсә, алар Үзбәк Газизович белән очрашмый калмыйлар иде. Ә атаклы җырчылар, музыкантлар, артистлар... Андый очрашу-күрешүләр, дустанә мәҗлесләр бихисап булды. Гариф абый Ахунов белән дә дуслыклары көчле иде. Гариф абый аны тыңлый, киңәшләрен тота, кеше буларак бик хөрмәтли иде. Ялгышмасам, Үзбәк Саттаров турында бер әсәр дә яза башлаган иде... Әлмәттә биш елга якын яшәү дәверендә, миңа да Үзбәк абый белән еш аралашырга туры килде. Әлмәт язучыларының җитәкчесе идем ул чакларда. Эш дәверендә аның ярдәмен күп тойдым. Яшь кеше өчен вакытында таяныч-терәк бик кирәк икән ул! Еш очрашылды. Кабинет өстәлләре арасында да, сәхрәләргә чыгып, табын корып утырулар да булды. Сүз иярә сүз чыгып, көндәлек вак-төяге дә, сәяси хәлләр дә сөйләнелә иде. Әлбәттә, җир мае — нефть турында сүз чыкмый калмый иде. Кая китә бу байлык? Бик үк ачылып бетмәсә дә, тоела, сизелә иде: үз байлыгыбызга үзебез хуҗа булмаганга эчтән сызлана, уфтана иде. Минем турыдан төбәбрәк биргән сорауларга, акланырга тырышыпмы яки бүтән максаттанмы, «бүтәнчә була алмый ул, дөньяда ике төрле системаның көрәше бара, сыйнфый каршылыклар көчәя» һ. б. дип әйтеп ала иде. Чынлап, инанып сөйләве булгандырмы, әллә шул чор саклыгымы? Әллә мине тынычландырып үз-үзен юатуы булдымы?

Хәзер нефть якларында беркадәр вазгыять үзгәрде. Тамчылап булса да, байлыгыбызны үз җиребездә калдырып, әҗерен күрә алдык. Җирле халыктан хуҗа тойгысы булган җитәкчеләр үсеп чыкты. Халыкка кирәк байтак йорт-биналар, сарай-корылмалар төзелде. Язу-сызу өлкәсендәге кешеләргә дә кояш елмаеп алды: «Рухият» дигән фонд ачылды. Бу фонд ярдәме белән менә дигән китаплар чыкты. Бу якның асыл затлары—Риза Фәхретдин, Фатих Кәрими, Һади Атласилар рухы янәдән күңелләргә керә башлады... Болар Үзбәк Саттаров хыяллангандагы кайбер гамәлләр инде. Гөл чәчәкләрен үзләре күрә алмасалар да, шытымнарын алар — Үзбәк абый кебек ир-егетләр чәчеп калдырды.

Үзбәк абый зур язучы булырга өлгерми вафат булды. Ә теләге көчле, мөмкинлекләре зур иде. 1980 елда аның балалар өчен «Алма биргәч ни диярге?» дигән китабы дөнья күрде. 1982 елда СССР Язучылар союзына кабул ителде. Бу китап турында «Совет Татарстаны язучылары» исемле биобиблиографик белешмәдә мондый сүзләр бар: «Нәниләр дөньясының сафлыгын, самимилеген, ышанучан, садә беркатлылыгын тормышчан ситуацияләр, оста тотып алынган детальләр аша сурәтләгән бу хикәяләр үзләренең җыйнаклыгы һәм образлы теле белән аерылып торалар». Бу бәяләмәгә әллә ни өстисе килми, ризалашып баш кына кагасың.

Үткән ел бер төркем язучылар Әлмәткә баргач, татар гимназиясендә очрашу вакытында китаплар бүләк иттеләр. Алар арасында Үзбәк Саттаровның «Молекулалар дөньясына сәяхәт» дигән бик шәп китабы да бар иде. Кызыклы фәнни-популяр бу басма мәктәп укучылары, студентлар, гомумән, табигать байлыклары белән кызыксынган һәр кеше өчен менә дигән кулланма! Китапны Үзбәк абыйның шәкертләре М. Газизов, Р. Фәхретдиновләр төзеп, әзерләп чыгарган. Кеше китә, җыры кала, диләр. Әйе, кешеләр китә, ә сирәгенең генә җыры кала. Бу дөньяда җырың калсын өчен иң әүвәл кеше булуың кирәк, изге гамәл-хезмәтләрең кирәк, дәвамчыларың булуы кирәк!

*2002, гыйнвар*

**ЕГЕТ ӘДИП**

Аның эш бүлмәсеннән Казансу күренеп тора. Балконга чыксаң, җиләс җил биткә бәрелә. Җил үзе белән яр буе таллыкларының, җиләк-җимеш агачларының хуш исен алып килә. Элегрәк андый матур урыннарны «Швейцария» дип атаганнар. Моннан утыз еллар элек ике коры елга ярына бакча утырттылар, ике рәт итеп дүрт-биш катлы йортлар салып куйдылар. Исемен дә таптылар: Новаторлар урамы. Казанлылар бу урынны үзара «Куба» дип тә йөртәләр.

Әмма Казан елгасы, Идел дәрьясына койган урынында бик киңәйсә дә, исемен дә, үзәнен дә алыштырмады. Ул мең еллар элек ничек аккан булса, хәзер дә шулай ага, Идел-ана белән очрашырга ашкынып килә. Әгәр уңга борылып карасаң, моннан 70 чакрымнар ары, әнә теге офыклар артында олуг язучыбыз Гариф Ахуновның туган җирләре. Мөмкин була торган булса, дулкыннар буйлап кына йөгереп китәр иде. Казан елгасы бит аның туып үскән якларыннан башлана...

Гариф ага Ахунов әле күптән түгел генә «Идел кызы» трилогиясенең икенче китабын тәмамлады. Зур хезмәт. Авторның ун ел вакытын суырып алган хезмәт. Икенче китапның соңгы ноктасы куелган инде югыйсә, ә чынлап торып борчылу яңарак кына башлана төсле. Ничек булып чыкты икән? Укучылар күңеленә хуш килерме? Романдагы утызынчы еллар һәм дәһшәтле сугыш еллары ышандырырлык сурәтләндеме икән? Тәҗрибәсез яшь әдип борчылу бер хәл, инде каләм остасы борчыла икән, бу — бөтенләй башка нәрсә. Заманында «Хәзинә», «Хуҗалар» романнары өчен дә шулай борчылгандыр ул. Соңыннан бу әсәрләр, безнең әдәбият дөньясында шаулап, үзләренең лаеклы урыннарын алдылар, татар телендә һәм рус телләрендә күп мәртәбәләр басылып чыктылар.

— Кыска документаль повестьлар сериясен уйлап йөрим әле, — ди Гариф ага. — Күңелемдә язылып та бетеп киләләр инде, кәгазьгә генә төшерәсе бар. Берсе Әлмәт егете — нефтьче инженер Үзбәк Саттаров турында. Минем өчен ул нефть-химия индустриясеннән аерылгысыз. Бик тә акыллы, төпле кеше иде. Иртәрәк китеп барды... Икенчесе — колхоз председателе, укытучы баласы Мирбат Хәстиев. Холкы йомшак, мөгамәләсе ягымлы, әмма аңарда сүз белән әйтеп биреп булмый торган әллә нинди бер көч бар... Тагын бер бик якын дустым бар әле минем: ул — Борһанов Тимерхан. Гаҗәеп кеше. Искиткеч оста гармунчы. Язмышы да бик гыйбрәтле. Тимерхан дус дип йөртәм мин аны. Аның турында да бер әсәр өлгереп килә. Бәлки, дәвамлы документаль повесть булыр ул...

...Без сүзне Казансу тезмәләрендәге тау башында учак янында дәвам итәбез. Елга өсте караңгылана бара. Елганың теге ягындагы биек йортларның тәрәзәләреннән ут баганалары сузылды. Учактагы утны таяк белән кузгата-кузгата, миңа күз дә салмастан, Гариф ага сөйләвен дәвам итә:

— Әле бүген генә Биектау районыннан кайтып төштем. Уңыш мул быел. Авылларның тышкы күренеше матур. Терлекчелек комплекслары, механикалашкан ындырлар төзелгән, Культура сарайлары, мәчетләр... Йортлар алты почмаклы, калай яки шифер белән ябылган. Болар әле байлык ялагысының тышкы билгеләре генә. Иң мөһиме — безгә җир кешеләренең күңел муллыгын онытмаска кирәк. Әгәр бүген бер гаиләнең бер кешесе яхшы эшли икән, бу — бер биеклек, әгәр гаилә тулаем үрнәк эшли белә икән, монысы — икенче биеклек, әгәр бөтен хуҗалык бер гаилә балалары булып яхшы эшли ала икән, монысы — өченче биеклек; инде килеп, районның барлык колхозлары бер сулыштан кабынып эшлиләр икән, монысы дүртенче, хәлиткеч биеклек булыр. Әхлакый климат әнә шулай туа. Биек Тау әнә шулай хасил була. Биеклеккә омтылырга, шул биеклекне алу турында район җитәкчеләре хыялланып яшәргә тиешләр...

Ул әкрен генә, үз уена сәҗдә китеп, аксакалларча сөйләп утыра. Күңелдәге уйларыңны башкаларга җай гына күчерә белү, күрәсең, остазлар эшедер.

Олуг елга буенда утырганда, аргы якка да багасың. Төпкел агымны җуймас өчен, күңелдә генә булса да, ярларны очраштыру кирәк. Менә бу мәлдә Казан елгасының теге ярындагы биек бинада — Матбугат йортында әңгәмәдәшем хакында дөнья кадәр мәкалә-мәдхияләр баса торганнардыр. Татар иле Гариф Ахуновның тууына 60, әдәби-җәмәгать эшчәнлегенә 35 ел тулуны сентябрь аенда үткәрә. Моңа әдипнең хакы да бар. Филология фәннәре докторы Ә. Кәримуллин төзегән библиографияне игътибар белән укыган кеше сизми калмас дип беләм. Романнар, повестьлар, пьесалар, хикәяләр, очерклар, тәнкыйть мәкаләләре, әңгәмәләр, публицистика. Төрле елларда, төрле төбәкләрдә төрле дәрәҗәдәге матбугат органнарында ул Толстой һәм Шевченко, Шолохов һәм Ибраһимов, Купала һәм Такташ, Ойунский һәм Цадаса, Хәмзә һәм Айни, Гамзатов һәм Айтматов, Исәнбәт һәм Мостай Кәрим турында мәкаләләр бастырды. Татарстан китап нәшрияты чыгарган томлыкларының соңгысында каләмдәшләре һәм классикларыбыз хакында аның 30 дан артык әдәби портреты басылган. СССР һәм РСФСР язучыларының пленумнарында, күчмә утырышларында, Әдәбият көннәрендә, конференцияләрендә һәм симпозиумнарда ул үзбәк һәм якут, башкорт һәм дагстан, Төньяк Кавказ һәм Урта Азия әдәбиятлары турында чыгышлар ясады. Монда бер нәрсәне онытырга ярамый: боларның барысы Татарстан Язучылар союзы аппаратында зур эшләр алып барган кеше тарафыннан эшләнде бит. Ун ел буена ул Татарстан Язучылар берлеген җитәкләде, Әлмәт һәм Чаллы язучылар оешмаларын төзүнең төп инициаторы булды, «Казан утлары» журналында ун еллап эшләде — әдәби хезмәткәрдән башлап баш редакторга тикле!

Иҗаты аның күптармаклы. Әдәби тәрҗемәләрне генә алып карыйк. 200 табактан артык тәрҗемә әсәре. Алар арасында М. Шолоховның «Тын Дон» романының ике китабы, А. Чехов һәм Р. Тагор хикәяләре, А. Макаренконың «Педагогик поэма», В. Закруткинның «Йөзмә станица», Н. Шундикның «Боланнар илендә» романнары, А. Островский, Н. Погодин, К. Финн пьесалары. Болар үзләре генә дә бер профессиональ тәрҗемәче гомеренә җитәрлек. Уйлап карыйк: бүгенге яшьләр аның менә дигән тәрҗемәче булуын юньләп белә микән? Шикләнәм. Күпләр аны танылган романчы, талантлы повестьлар авторы, драматург, сценарист, кайнар публицист, принципиаль әдәби тәнкыйтьче итеп таныйлар.

Һәркемнең үзе өчен кадерле, канат ныгыткан чоры була. Гариф Ахуновның ул чоры 60 нчы елларга, Әлмәттә яшәгән дәверенә туры килә. Олуг иҗатның нигез ташлары шул чорда салынган да инде. «Кара алтын»ның фонтан булып аткан дәвере бу. Татарстанның СССРда чыккан нефтьнең өчтән берен биреп торган заманы. Нефтьчеләрнең ул чордагы эшләре хакында читтән күзәтеп кенә язу мөмкин түгел иде. Язган геройларыңны яхшы белергә, алар белән аралашырга, аларның язмышын үзеңнекедәй кабул итәргә кирәк иде.

Гариф Ахунов шул эшне эшләде дә. Әлмәттә ун елдан артык яшь гомерен уздырды. Ә бит аның Казанда да бик әйбәт эше бар иде. Гаделлек хакына шуны да әйтик, «халык тамырына» юлыкканчы, «Хәзинә», «Хуҗалар» романнарын, «Хыялый Хәйрүш егетләре», «Канатлар кая илтә?», «Артышлы тау буенда» повестьларын, «Чулпы җыры», «Утлар яна учакта» пьесаларын язганчы, аңа җитмеш җиде кат тир түгәргә туры килде. Аның «Җир куенында» исемле драмасы зур бер сәхнәдән дөбершатыр җимерелеп төште. Әмма ул аңардан үзенә тиешле нәтиҗә ясый белде. Ахыр чиктә тимер-томырга түгел, кеше күңеленә юл алды.

Аның иҗатында көчле кешеләр, хезмәт ратучы намуслы кешеләр яши. Шулай булмаганда, беренче бишьеллыкларның легендар баһадиры Мирсәет Ардуанов хакындагы повесть язылыр идеме? Яки «Чикләвек төше» повестен алыйк. Заманында бу әсәргә Мостай Кәрим югары бәя бирде. «Чикләвек төше» повесте һәм «Хәзинә» романы өчен әдип Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Хезмәт ярату һәм кешене ярату. Язучы өчен кирәкле төп сыйфатлар. Бәхетледер, Гариф агада алар кечкенәдән үк булган, әнә шул асыл сыйфатлар аңа күпмилләтле совет әдәбиятының олы юлына чыгарга ярдәм иттеләр.

Без учак янында утырабыз. Мин аның юбилеена чыккан «Чишмәләр белән сөйләшү» исемле китабының төп героен күз алдыма китерәм (юл уңаенда әйтеп узыйк, бу китапка тирән эчтәлекле, акыллы сүз башын күренекле башкорт прозаигы Әхияр ага Хәкимов язган).

— И улым-балакаем, берни дә белмисең бит син, — ди борынгы карт Сәйфелмөлек. — Газиз башкайларниләр генә күрмәде! Җир казырга кирәкме, көрәкнең зурысын Сәйфелмөлеккә тоттыралар. Кама елгасыннан сал агызырга кирәкме, Иделдә баржалар бушатасы бармы — әлеге дә баягы — Сәйфелмөлек. Аркадагы грузчик «мендәренә» бер капчык тозны китереп салган чакта, умырткалар шыртлап китә, аяк астындагы басмачалар сыгылып килә. Әнә нинди заманалар барые! Син әйтәсең, язачак китабыма герой эзлим, дисең. Эзләп торырга кирәкмени аны?! Дөньядагы иң зур, иң глауный герой халык бит ул.

Әгәр халык үз гомерендә көрәк белән казыган үзәнгә су салсаң, яңа бер Идел дәрьясы җыелыр иде, билләһи әгәр! Әгәр Рәсәй шахталарында халык чыгарган ташкүмерне бер урынга җыйсаң — яңа бер Урал тавы калкып чыгар иде!

Гариф Ахуновның «Идел кызы» трилогиясе хакында уйлый башлагач, минем күз алдыма тагын Сәйфелмөлек карт килеп басты. Бу төп китабы өчен Гариф ага Ахунов халык тормышының тирән катламнарын өйрәнеп чыкты, бер милләт язмышында, бу очракта татар халкы язмышында, илле ел эчендә нәрсәләргә ирешкәнен, ниләр югалтканын күрсәтеп бирүне максат итеп куйды.

Минем уйларымны белгәндәй, Гариф ага янә дә сүз башлады:

— Чит илләрдәге коллегаларыбыз белән очрашканда, әңгәмәләр вакытында миңа үзебезнең халык турында анохроник төшенчәләр ишетергә туры килде. Янәсе, татарлар әле һаман кибиткаларда яшиләр, кыргый атларны чаптырып йөриләр. Көлке дә, көенечле дә бу хәлләр. Мин үзебезнең Татарстаныбыз турында русча ике китап чыгардым. Күрәсең, ул гына җитми, гел язып, дөньяның исенә төшереп торырга кирәк. Без кем идек тә, кем булдык! Аз язабыз, язсак та үтемле итеп язмыйбыз, ахрысы...

Каләм остасы үз эшеннән канәгать түгел икән, димәк, безне алда яңа ачышлар, яңа геройлар көтә дигән сүз. Остаз кеше хакны, дөресне әйтер.

*1985, сентябрь*

**ЗУРАЕП КАЛУ**

* * *

Яшәсен! —
ирләрнең, кеше рәнҗетми,
якты хәтер калдырганы.

Ни-нәрсәдән мәхрүм калганыңны югалткач кына аңлыйсың. Исән чакта, теге дә, ул да, бу да, мин дә дигәндәй, кайчандыр бер-беребездән мәңгегә аерылачакны белсәк тә, ул вакытта хис-тойгы әле шактый томанлы, абстракт, югалтуның ачы хәсрәте сәгате суккач кына йөрәккә төшә икән. Гариф абый Ахунов үлемен ишеткәч тә шулай булды.

Гыйбрәтле хәл: берәүләр киткәч, алар хәтер офыгы томанында шундук эреп югалалар, берәүләр, киресенчә, тагын да зураеп күңеленне билиләр; шәхеснең яшәештәге бәндәлеге онытыла, мәңгелеккә дәгъва иткән изге эшләре, олылыгы гына кала. Гариф абый Ахунов Бакый дөньяга җиңел күчте дип беләм. Озаклап хаста булып үзе дә интекмәде, бүтәннәргә дә борчу салмады. Үлемнең табигый, Яшәүнең үзгә дәвамы икәнен раслагандай, тыныч кына китеп барды. Һәм, әйтергә кирәк, Бөек Күчештән соң аның исеме, рухы Фани Дөньялыкта зураеп, үсеп калды. Бу зураю, үсү күпмеңләгән кешеләрнең күңелләре, сыкрау-әрнүләре, сагыну-сагышлары аша зураю булды. Озаккамы?

* * *

Яшәсен! —
егетләрнең бик түбәннән
күтәрелеп дан алганы.

Соңгы ярты гасырлык татар әдәбиятын Гариф Ахуновсыз күз алдына китерү кыен. Язган әсәрләре — китаплары буенча да, әдәби хәрәкәтне оештыруда кылган гамәлләре буенча да. Аны, мөгаен, татар совет әдәбияты классигы дип атау дөрес буладыр. Шушы чор сәяси тормышның, әдәби барышның бөтен позитив һәм негатив яклары чагылыш таба аның иҗат эшчәнлегендә. Бер яктан, Г. Ахунов шул чор идеологиясенең күндәм хезмәтчесе (КПСС съездлары делегаты, СССР Югары Советы депутаты, Татарстан Язучылар берлеге җитәкчесе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе секретаре...), икенче яктан, татар милләте, татар әдәбияты мәнфәгатьләрен армый-талмый кайгыртучы фидакарь халык улы булды (зур полотнолы әсәрләр авторы, Әлмәт Язучылар оешмасын оештыручы, йөзләгән яшь каләм ияләренә фатиха бирүче, татар әдәбиятын башка халыклар арасында үтемле пропагандалаучы, ару-талуны белми иҗат итүче...). Әле санап әйтелгән-нәрнең һәрберсе турында бит-бит тәфсилләп язып булыр иде. Әмма андый хаҗәт юк: Гариф Ахунов бик билгеле шәхес һәм аның эшчәнлеге дә халыкка яхшы мәгълүм.

Кояш астында үз урыныңны алып, җирдә ышанычлы нык басып яши алу, шуңа өстәп, зур хезмәтләр һәм шанлы исем калдыру, һай, җиңел түгел бу дөньяда! Г. Ахунов — түбәннән күтәрелгән шәхес. Ятим балачак, сугыш уты өткән яшьлек... Югалып калырга, сынарга, бозык юлдан китәргә дә мөмкин... Әмма Гарифҗан Ахунҗан улы югалыр өчен яратылмаган булган шул. Үзәк ныклык, үҗәтлек, черәшеп эшли алу, халыкның киләчәгенә ышану, сүз кодрәтенә табыну аны олуг әдип иткән. Төрлесе булган гомерендә, төрлесе кичерелгән. Төрмә сәкеләре дә күрелгән, патша табыннарында да утырылган...

* * *

Яшәсен! —
дус-ишләрнең көнләшмичә
якын итә торганнары.

Гариф Ахуновның дуслары күп иде. Егетлек, ихласлык, юмартлык, ярдәмчеллек хас иде аңа. Бу сыйфатлар күпләрне әсир итәрлек асыл сыйфатлар шул. Шәхсән минем үземә дә утыз елдан артык Ахунов мохитендә яшәргә насыйп булды. Әдәбиятка ныклап аяк басуда аның шифалы йогынтысы зур булды. Хәтта күпмедер дәрәҗәдә әдәбиятта ул кичкән хезмәт юлын үтәргә туры килде. Әлмәт Язучылар оешмасы, Татарстан Язучылар берлеге, «Казан утлары» журналы... Бер үк постларны диярлек биләдек. Аңа алдарак, миңа соңрак насыйп булды бу миссия. Киңәшләшеп, ярдәмләшеп, әдәбиятыбыз тәрәккыятле милләтләрнекеннән ким булмасын дигән ният белән эшләргә тырыштык. Шөкер, кайбер игелекле эшләр башкарылды дип уйлыйм. Хәер, аның кешелеклелеген тойган, хәер-фатихасын алган, олылау сүзен ишеткән каләмдәшләр бихисап. Кемнәр турында гына язып чыкмады да кемнәр турында гына зур-зур трибуналардан сөйләмәде Гариф абый! Йөзләгән-

йөзләгән мәкаләләр, иҗат портретлары, рецензияләр, тәкъдим-рекомендацияләр... Бүгенге Язучылар берлегендәге өч йөз илледән артык каләмдәшебезнең, ихтимал, яртылабы теге яки бу формада аның булышлыгын алганнардыр дип уйлыйм. Каләмдәшләр генәме соң? — артисты да, рәссамы да, игенчесе дә, нефтьчесе дә...

* * *

Яшәсен! —
исәннәрнең үлгәннәргә
чардуган кора алганы.

6 июньдә Гарифҗан Ахунҗан улын Арчаның татар зиратында җирләп кайттык. Моннан нәкъ ике ел элек без — «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре — әдипнең туган авылы Өчиле җиренә барып, табын корып утырган идек. Ул авыл инде юк, кайбер нигез урыннары гына беленеп тора. Әмма зират исән калган. Гариф абыйга бик моңсу иде бугай. Аның тау итәгеннән ургып аккан чишмәгә озак карап торганы хәтердә калган. Кайткач, куен дәфтәренә шигырь сыман мондый юллар язып куелган.

## СӘХРӘЛӘРГӘ ЧЫККАН ИДЕК БЕР...

Бу җирләрне яд итәргә
Төркем булып килдек каладан.
...Авыл күптән беткән.
Тау битендә
Зират та чишмә калган.
Яктык учак. Кыздырдык шөшлек.
Тостлар яңгырады телдән телгә күчеп.
Янда бөтерелә иясез бер көчек.
Фанилыкны искәртә талгын җил исеп
зират ягыннан.
...Бу адәмнәрнең дә күбесен юк дип була,
йөрсәләр дә монда ашап-эчеп.

...Арча зиратын үзенең калку урынында калдырып, Казанга кайту юлында сагышлы, борчулы уйлар биләде күңелне. Арча җиреннән чыккан әдәбиятыбызның имәндәй баһадир әдипләре китеп бетеп бара. Г. Бәширов, М. Мәһдиев, Г. Ахунов... Боларсыз татар прозасын күз алдына китереп буламы соң? Биш-алты ел элек кенә бергә аралашып йөргән идек бит әле!.. Аларны кемнәр алыштыра? Аларныкы кебек тормыш тәҗрибәсе һәм тел байлыгы булган яңа буын язучыларыбыз бармы?

Әле күптән түгел генә дөньякүләм мәшһүр әдипләр, төрки халыкларның уртак горурлыгына әверелгән язучылар Ч. Айтматов белән О. Сөләйманов, Казанда булып, татар язучылары белән очраштылар. Кызыклы гына әңгәмә булды. Шунысы да сискәндереп куйды, бәй, бу зур затлар белән аралашкан, бер-берләре белән кочаклашып күрешерлек язучыларыбыз юк дәрәҗәсендә икән. Янә Гариф абый искә төште. Ул арада булсамы?!

* * *

Яшәсен! —
ирләрнең көчле булып та,
сабыйлыгын җуймаганы.

Гариф Ахунҗан улы Ахунов безнең күңелләрдә сабый күңелле, көчле ихтыярлы ир-егет булып калды.

*2000, июнь*

## «ҺӘРКЕМ ҖИРДӘ БЕР БИЗӘК...»

Дөресен әйтим, кыска гына бу кереш мәкаләне авыр яздым. Бер башлыйм, бер ташлыйм, бер ташлыйм, бер башлыйм дигәндәй... Төп сәбәп шул: Кави Латыйп кем ул, дигән бик гади сорауга тәгаен инанып, чатнатып әйтү кыен. Шагыйрьме? Әйе, берәүләр шуны раслый. Унга якын шигырь китабы бар. Прозаикмы ул? Моны да танучылар бар. Чәчмә әсәрләре тупланган берничә җыентыгы чыкты. Кайбер әсәрләре безнең «Казан утлары»нда басылды. Тәрҗемәчеме? Әйе, бу да факт. Аеру-

ча чуаш әдипләре белән тыгыз бәйләнештә. Берничә ел элек Чуаштанның олуг премиясенә лаек булды. Публицистмы? Монысын да инкяр итеп булмый. Җәмәгать эшлеклесе, сәясәтчеме?.. Бәлки, ул, беренче чиратта совет офицерыдыр, ә калган әдәби гамәлләре бер хоббидыр? Бусы белән дә килешүчеләр табылырга мөмкин.

Мин үзем шәхсән Кави Латыйпны халкыбызның самими күңелле, үзенчә талантлы, иманлы бер улы дип саныйм. Күпне күргән, күпне кичергән Кави абый. «Балачактан туры без көрәшкә кердек» дигән шикелле, язмыш аны яшьли гарасат упкыннарына еш ыргыткан. Җитмеш ел гомер кичергән һәркем җитмеш җиде бәла-каза, кайгы-хәсрәт кичеп мең сынаулар үтәдер.

Бу дөньялыкта һәркемнең үз сират күпере. Кави аганың ярты вөҗүден, ярты дөньясын сугыш кичерешләре билидер дип уйлыйм. Аны, шәхес буларак, сугыш еллары калыплаган. Гомумән, Ватан сугышы (мин аны Бөек Ватан сугышы дип түгел, Бөек Афәт дип атар идем) совет иле биографиясенең төп вакыйгасы, төп фаҗигасе һәм берничә буын илдәшләрнең аңын формалаштыручы фактор. Гуман фактор түгел, әлбәттә. Язмыштыр инде... Үсмер егет Кавига сугыш янгыныннан көйрәп яткан утлы күмерләр өстеннән күп йөрергә туры килә. Ялан тәпиләрен үк булмаса да, яшь егет бәгырен байтак көйдергәннәр алар...

Кави абый белән утыз еллар буе дустанә мөнәсәбәттә яшәсәк тә, кызганыч, гомере сәхифәләрен җитәрлек белмәгәнмен икән. Соңгы биш-алты елда матбугатта дөнья күргән истәлек язмалары К. Латыйп турында байтак яңа мәгълүмат бирә. Тәэссораттан сискәнеп куйган мизгелләр дә булмады түгел. Бу яктан «Югалган кыйбла» дип исемләнгән новеллалар циклы («Идел», № 7, 1993) аеруча гыйбрәтле. Кереш сүзендә автор болай яза: «НКВД гаскәрләренең бер рядовое буларак, мин унҗиде яшемдә... сугыш операцияләрендә катнаштым. Абверчылар, эсэсовчылар, террорчылар, диверсантлар... Көнбатыш Украинаны аркылыга-буйга кат-кат үттем. Сугыштан соң, КГБ (НКВД) гаскәрләренең хәрби училищесында укыганда, без курсантларны Балтыйк буена алып киттеләр, анда безгә Литва, Латвия, Эстония җирләрендә хөкүмәтнең «махсус заданиеләрен» үтәү йөкләтелде... Милләтчеләр биргән сабаклар мәңге онытылмас... Мәгънәсез, канлы ул көрәштә, сугышта ике яктан да корбаннар гаять күп булды. Әле дә мин аларның соңгы авазларын ишетәм. Без үзебезне тикмәгә генә «Сталин корбаннары!», «Әҗәл кешеләре!» дип атамадык шул... Хәрби училищены тәмамлагач, мин чит илдә, Кара диңгез буенда хезмәт иттем... Соңыннан Татарстан Язучылар берлегенең һәм үземнең тырышлыгым аркасында Совет Армиясеннән китә алдым. Әле һаман да солдат чактагы тәэсирләр белән яшим...»

Әйе, гомер юлын яңадан үтеп булмый. Нәрсә булган — шул булган. Үзәгендә ниндидер фаҗига ятмаган язучы бездә сирәктер. Кави Латыйп шагыйрь булып туып, офицер булып яшәп, соңрак аңга килеп, янәдән юл башы — шагыйрьлегенә кайткан кеше. Бу кайту каршылыклар һәм күңел җәрәхәтләре аша озакка — берничә дистә елларга сузылды. Ул аны үзе дә таный: «Ә төптән уйланганда, гаеп минем үземдә, Аяз Гыйләҗев әйткәнчә, ориентирым дөрес булмады. Гаскәри вә офицер буларак, яшьлегем армия сафларында узды, төп тәрбияне мин шунда алдым... Шигырьләрем ничектер, ә бит чыннан да гражданскида олыгайгач кына яшәргә өйрәндем. Соң булса да уң булсын! Үземә шундый теләк теләп калам» («Шигърият мине яшәргә өйрәтте», 1995 ел). Кем әйтмешли, Кави Латыйп башлаган юлы белән китсә, бәлки, күптән генерал булыр иде. Әмма ул, үз сүзе белән әйтсәк, гражданскида да рядовой булмады... Хәер, гаҗәп тә түгел, хәрби дөньядан киткәненә дә 40 елдан артык бит. Беләсез, 50 нче елларда, соңрак та, офицер халкы бик дәрәҗәле санала иде. 25 яшен яңа тутырган капитан Кави Латыйпның җәмгыятьтәге урынын чамалап була.

Юллар ачык! Һәм тәвәккәл Кави Латыйп капка-читәннәр ашамы, сукмак-магистральләр үтепме, әдәбият-сәнгать дөньясына ыргыла. Шул чорның күренекле шәхесләре, мәшһүр талант ияләре белән аралаша, иҗади хезмәттәшлеккә омтыла. Салих Сәйдәшев, Хәсән Туфан, Рәшит Ваһапов, Әнвәр Давыдов, Габдрахман Әпсәләмов, Сара Садыйкова, Фатих Хөсни... Әдәби кичәләр, театр премьералары, сәхраларга чыгып күңел ачулар... Үзе бер дөнья, үзе бер мәктәп! Күргәнне генә күзаллап, белгәнне генә искә төшереп, кичергәнне генә хәтерләп була. Ә Кави аганың хәтер сандыгы бай! Соңгы елларда дөнья күргән «Кояшны күмү» (1990), «Югалган кыйбла» (1993), «Әдрән диңгез» (Салих Сәйдәш ядкаре) (1994), «Мин дә мишәр, син дә мишәр» (1996), «Җәйге шәфәкълы, шәфкатьле көннәрендә» (1996), «Боеручылар һәм башкаручылар» (1996) һ.б. истәлек язмалары укучыларда зур кызыксыну уятты һәм бу бәрәкәтле башлангыч ары табан дәвам ителер дип ышанасы килә. Хәтерне яңарту, үзебездән бигрәк, киләчәк буын өчен кирәк.

Быелның май аенда Кави Таһир улы Латыйпка 70 яшь тулды. Матбугатта шактый тәфсилле мәкаләләр чыкты. Юбилей мөнәсәбәте белән, гадәттә, укучылар өчен беркадәр биобиблиографик мәгълүмат та бирелә. Без дә шул вазифаны үтәп китик.

Ул 1927 елның маенда Чуаштанның Батыр районы Кызыл Чишмә авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Татар Тимәше авылында укытучы булып эшләп ала. Алда әйтелгәнчә, 1944—1955 елларда хәрби хезмәттә. Демобилизацияләнгәч, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетында, Мәгариф министрлыгында, Казан телестудиясендә, күп тиражлы газетада, СССР Педагогия фән-

нәре Академиясенең фәнни-тикшеренү институтында эшли. Читтән торып М. Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый. Пенсиягә чыккач та җәмәгать эшләрендә актив катнаша: Татарстан республика партиясендә җаваплы эшләр башкара.

Әдәбиятта кылган гамәленә килсәк, ул инде ярты гасыр дәвамында актив иҗат итә. Татар, рус, чуаш телләрендә унбишләп китап чыгарды. Күбесе — шигырь китаплары. Минемчә, арада аеруча игътибарга лаеклылары — «Вакыт канатында», «Хәтер йомгагы», «Иркен сулыш»... Кайбер шигырьләренә композиторларыбыз матур-матур гына көйләр яздылар. Кави Латыйп шигырьләре турында төрле фикерләр бар. Шагыйрьлеген танымаучылар да юк түгел. Болары, нигездә, кулуар сөйләшүләрдә. Рәсми тәнкыйтьтә иҗатын хуплаучылар күп. Мәрхүмнәрдән — Ә. Давыдов, С. Хәким, М. Мәһдиев, исәннәребездән — И. Юзеев, Р. Мостафин, Н. Фәттах, Р. Гаташ, Г. Рәхим, Р. Мингалимов, Зөлфәт... «К. Латыйп үзенең сөйләм ысулын, поэтик интонациясен тапты. Аның шигырьләрендә нindидер эчке драмага, бик тирән яшерелгән трагедиягә ишарә бар. Аның һәр шигыренең нигезендә фикер ята, ләкин коры риторика түгел — хисле фикер...» — ди Р. Мостафин. «Алда — ачылмаган дөнья» исемле кереш мәкаләдә И. Юзеев болай дип өсти: «Һәм менә... Һич тә уйламаганда, К. Латыйп үзенчәлекле шагыйрь булып ачылды... Минем алга җаны белән хыялый-сабый, акылы белән абый, дөньяның михнәтен дә, рәхәтен дә татыган, йомшак табигатьле, әмма каты характерлы Кави килеп басты». Бәлки, бу урында бәхәсләшергә дә мөмкиндер. Картаеп барган бер бирмеш көндә кинәттән генә яңа Уитменнар, Нерудалар туа алмастыр... Поэзия — Бөек сер. Үтә күренмәле примитивизмны, иректә яки ирексез формада нинди генә рифмалар белән үрмә, Поэзия кабул итмәячәк. Миңа калса, К. Латыйп инде шул Бөек сергә ачкыч тапты шикелле. Әмма алда әле ачасылар да ачасылар!.. Аның «Үземә» дигән кыска шигырендә мондый юллар бар:

Шагыйрьмен тумыштан,
каләм тотарга миңа Тәңре үзе кушкан.
Шигърият дигән сандал сукканмын,
шигырь яза-яза чыныкканмын
вә җиңеп чыкканмын.

Җиңеп чыгу тойгысы — бөек хис. Бу очракта Козьма Прутков сүзләре искә төшә: «Если хочешь быть счастливым, будь им!»

Шагыйрьне аңлыйсың, беләсең килсә, аның туган җирен барып күр, диләр. Үткән ел «Казан утлары» егетләре белән без Чуашстанга кергән Батыр районы авылларында булып кайттык. Кави аганың туган авылы — Кызыл Чишмәдә булган очрашулар бик нык хәтердә калды. Затлы, иманлы кешеләр күрдек, мәктәптә сөйкемле балалар белән очраштык. Мәктәп директоры Сәет Гаязов сүзләре һаман колакта: «Безнең авыл Казанга Кави Латыйпны бирде. Сез саклый күрегез инде аны! Ул безнең өчен бик кадерле кеше!» Бераз төчерәк тоелырга мөмкин бу сүзләрне менә ни өчен дә язам: Татарстаннан читтә татарлар яши торган бүтән төбәкләрдә хәл бүтәнчәрәк, аянычрак дип беләбез. Әйтик, Һ. Такташның Сыркыдысында, Ш. Камалның Пешләсендә, Г. Кутуйның Кынадысында... Барып кайткан кешеләр бу якларда элеккеге милли рух нык какшаган, диләр. Татар мохите, татар рухы, татар мәктәпләре ипле генә эшләп килгән Батыр якларыннан, шөкер, әдәбиятыбызга яңа көчләр әле һаман килеп тора. Р. Зәйдулла, Р. Сүлти, Җ. Сөләйман, Р. Якушев... Кави абый бу яшьрәк әдипләрнең үзенчә бер өлкәннәре-старосталары сыман тоела.

Кави аганың бер китабы «Тормыш бизәкләре» (ул урыс телендә «Краски жизни» исеме белән чыкты) дип атала. Төптәнрәк уйлап, шагыйрь яшәешенең бөтен рухын, омтылышын, холкын күңелең аша кичерсәң, ирексездән мондый тәгъбир телгә килә: фронтовик әдип Кави ага Латыйп үзе дә тормышыбызның бер бизәге бит!

*Май, 1997*

## САЛМАК УЙЛЫ ХӘКИМ ШАГЫЙРЬ

Һәрвакыт, бигрәк тә кара көннәрдә,
Шагыйрь тиеш яктылыкка өндәргә.

Шамил Анак... Анак дигәне — псевдоним. Тулы исеме — Мәхмүдов Шамил Гомәр улы. Әлегә бу исем Татарстанның киң катлам укучыларына тиеш дәрәҗәдә мәгълүм түгел. Моңа сәбәп — беренчесе, шагыйрьнең татар телендә чыккан китаплары аз булуы: нибары — бәләкәй күләмле ике китап («Юл өстендә Кояш», 1966; «Көтелмәгән очрашулар», 1971), икенчесе — аның Казаннан еракта яшәве. Гомумән, Татарстаннан читтә — Мәскәүдә, Үзбәкстанда, Казагыстанда, Себердә һәм Союзның бүтән өлкәләрендә гомер кичеп иҗат итүче язучыларыбыз байтак безнең. Ш. Анак —

шуларның берсе. Ул Башкортстанның Раевка эшчеләр поселогында яши. Популярлык бер нәрсә (ул — вакытлы да, даими дә; иртә дә, соң да; булырга да, булмаска да мөмкин...), мөһиме шул: арабызда Шамил Анак исемле зур шагыйрь бар. Ул — исән-сау, ул яши, бөтен күңел байлыгын салып иҗат итә, рухи күгебезне биегәйтә.

Яшәмәдем куркып яки көнләшеп,
яшәдем мин тормышка туры эндәшеп,
сугыштым, алыштым, кирәк икән дуладым,
бар йөрәктән
сөйдем,
көйдем,
көлдем,
еладым!

Ышанычсыз меңәвең булуга караганда, таянырлык берәвең булу хәерлерәк. Ш.Анакның сыналган, поэзиянең эчке хасиятен һәм серләрен тирән аңлаган ышанычлы үз укучылары бар. Интеллектуаль шагыйрьнең тәэсир итү сферасы, иң беренче чиратта, төпле белемле, әдәби зәвыклы кешеләр мохитендә булуы табигый хәл. Шунысы куанычлы: ул сфера елдан-ел киңәя бара. Моның нигезе — шагыйрьнең заман рухы белән сугарылган кешелекле иҗаты.

Ш. Анак — интернациональ шагыйрь. Ләкин аңа космополитизм дигән нәрсә хас түгел. Ул үз җирлегенә, халыкның борынгы традицияләренә нык береккән шагыйрь. Ш. Анак иҗатының бер күркәм ягы шул: ул үз халкының гасырлар буе чарланып килгән рухи җәүһәрләрен бүтән халыкларда булган шундый ук аналогик рухи байлыклар белән кушылып, бердәмләшеп китә алырлык яссылыкка куя белә һәм иҗатында шул синтезны бөтен матурлыгы белән күренерлек итеп балкытырга тырыша. Шуңа күрә, ахры, аның күп шигырьләре бүтән телләрдә дә иркен һәм табигый яңгырый, үз итеп укыла. Моның шулай икәненә инаныр өчен аның төрле телләрдә чыккан китаплары белән танышу кирәк. Әйтик, рус телендә чыккан «Оды мирным вещам», «Три синих холма», «Полночный бой часов» дигәннәрен алып укып карагыз. Алыгыз башкорт телендә чыккан «Европа уртаһыннан репортаж» яки «Прага дәфтәре» циклларын. Йә булмаса, ниһаять, үз телебездә — татарча чыккан китапларын! Йә, алар чын мәгънәсендәге шигъри китаплар түгелмени? (Һәрхәлдә, Бөтенсоюз һәм Татарстан матбугатында чыккан Р. Мостафин, Ст. Куняев, Р. Харисов, А. Хузангайларның мәкалә, рецензияләре шуны раслый.) Төрле телләрдә бер дәрәҗәдә диярлек мәгънәне саклап, поэтик яңгырашлы булып кала алу үзе бер гыйбрәтле күренеш. Бу очракта шагыйрьнең үзенең дә берничә телне иркен белүе уңай роль уйный дип беләм.

Шамил Анак — поэзиябезнең формаларга баюына үзеннән билгеле бер өлеш керткән шагыйрь. Аның традицион калыптагы шигырьләре булса да, ул күбрәк сөйләү интонациясенә корылган һәм фикер агышына иш ирекле формаларда иҗат итә. Бу исә поэзиянең төрлелегенә, фикер һәм хис синтезының күпкырлылыгына, күпбалкышлылыгына китерә. Әгәр бүген татар поэзиясендә ирекле шигырь формалары тәмам ныгып, гражданлык хокукы алган икән, бу юнәлештә үз вакытында күп-медер хезмәт куйган Ш. Анак иҗатын да уңай бәяләргә кирәк.

Ирекле шигырь дигәннән, 60 нчы еллар искә төшә. Гаҗәеп еллар! Университетта әдәбият түгәрәге гөрләп эшли. Сафлар шактый ишле: Р. Мингалимов, Р. Гатауллин, Г. Родионов, Ә. Синегулов, Ш. Маннапов... Шигырь белән дөньяны үзгәртәбез! дип мәш килеп йөргән чаклар! Үзендә иҗат дәрте сизгән студент яшьләр бүтән югары уку йортларыннан да безгә киләләр. Пединституттан — Р. Харисов, Х. Хөснуллин, М. Садыйков, М. Гаскәров... Түгәрәк утырышла-рындагы кайнар бәхәсләр урамнарга ташып чыга, тулай торак бүлмәләренә күчә... Шул елларда Шамил ага Мәхмүдовның (ул вакытта аны Анак исеме белән белми идек әле) без яшьләр белән күрешеп әңгәмәләшкән чаклары сагындырып искә төшә. Аның сөйләгәннәрен авыз ачып тыңлый идек. Дөнья әдәбиятыннан мәгълүматы зур, без кумир итеп йөргән шагыйрьләрне үз күзе белән күргән, теоретик яктан әзерлекле, үз сүзен бирмәс бәхәсче. Аны Р. Харисов өлкән фикердәше, оста-зы санап бик хөрмәт итә иде. Шамил ага да Ренатны үз итте, ялгышмасам, аңа багышлап шигырь дә язды шикелле. Һәрхәлдә, Шамил Анакның без яшьләргә үзенчә шифалы йогынтысы булды ул елларда.

Ш. Анак — шигъри тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшләп килүче әдип. Назыйм Хикмәт, Пабло Неруда һәм башка дөньякүләм данлыклы шагыйрьләрнең аерым шигырьләре безнең телебездә иң әүвәл аның тәрҗемәсендә яңгырады. 1957 елда СССР Язучылар союзы тәкъдиме белән Чехословакиягә махсус барып, анда беркадәр яшәп, Муса Җәлил шигырьләрен татарчадан турыдан-туры чех теленә тәрҗемә итү эшендә катнашты. Ул шулай ук классик драматургиянең дә кайбер үрнәкләрен тәрҗемәләде.

Заманында Мәскәү университетында укып белем алган, соңрак шунда ук аспирантура тәмамлап, әдәбият институтында укыткан, чит илләрне күреп белгән, төрле телләрдә дистәдән артык шигырь һәм тәрҗемә китаплары чыгарган шагыйрь инде менә 20 еллап туган ягында — авылда яши. Яшәү

рәвеше — һәр иҗатчының рухын, кыйбласын билгели. 50 нче еллар ахырында «Европа уртасыннан репортаж»лар язган булса, соңгы дистә елда үзенең якташлары — күршеләре Сабрия әби истәлегенә багышланган «Күлмәк» яки «Мәрхүм абзыйга элегия» кебек «авыл» шигырьләрен иҗат итте. Кайда гына торсаң да, нәрсә турында гына язсаң да, — язганың кешелекле һәм талантлы булсын. Шамил Анак үзенең иҗат кредосын шулай аңлый. Ул бүген дә җаны теләгән туган ягында яши, күңеле теләгән кешеләр турында яза. Бәлки, фәлсәфи уйланулар, күңел ачышлары ясар өчен кәрәз йортлар шыплап тутырылган таш калада түгел, табигатьне, Җир сулышын бөтен җаның белән тоя алырлык авыл җирендә яшәү кирәктер дә.

Яшим мин
тормышның
бөтен тулылыгын тоеп, —

дип шагыйрь тикмәгә генә язмагандыр?

Күптән түгел генә ул яңа шигырьләр китабын тәмамлап, нәшриятка тапшырды. Тиздән дөнья күрер, дип ышаныйк. Поэзиядән тыш ул әле әдәби хәрәкәттә әдип-тәрҗемәче буларак та актив катнаша. Татарстан Язучылар союзы, Ш. Анакның рус һәм төрки телләрне яхшы белүен истә тотып, аңа бик җаваплы эш — Тукай шигырьләрен (яңа әдәби тәрҗемәләрен булдыру максаты белән) русчага сүзгә-сүз фәнни тәрҗемәсен эшләүне йөкләде. Уңышлар телик аңа!

*1979, апрель*

## ТИРӘБЕЗДӘ ЯХШЫ КЕШЕЛӘР

Тереклегебезне тәэмин итүче фидакарь игенчеләребез, данлы эшчеләребез, рухи дөньябызны баеткан әдәбият-сәнгать йолдызларының сокланырлык эшләрен тәкъдир итү белән бергә, без хәзер үзләренең эш спецификасы һәм яшәү рәвешләре белән сәхнә уртасында ук булмаган, нур көлтәләре, тамашачыларның сокланулы карашлары бик үк төшеп тормаган, әмма алардан тыш дөнья алга бара алмаган кешеләр турында ныграк уйлана, аларның кылган игелекләрен гаделрәк бәяләргә өйрәнә башладык шикелле. Космонавтларның исемнәрен бөтен дөнья белә. Ә бит аларның үзләрен, очачак корабларын кемнәрдер әзерли. Ихтимал, аларның кылган хезмәтләре галәмгә күтәрелгәннәрнекеннән бик үк ким түгелдер. Дөнья — мәшһүр артистларны белә. Ә бит аларны күпләр — режиссердан алып чәч тараучыга хәтле сәхнәгә чыгарга әзерли... Ахалтекин нәселле атларда ыспай киемле чапкыннар халыкара ипподромнарда беренчеләрдән килеп, алтын медальләр, призлар алалар. Ә ул атларны туендырган, чистартып, юып, тәрбияләп караган кешеләрнең хезмәте иярдәгеләрдән киммени? Соңгы вакытта матбугатта, нәшрият, полиграфия, гомумән, культура-агарту оешмаларында озак еллар буе эшләп килгән ветераннар турында матур-матур гына язмалар, зарисовкалар, очерклар ешрак күренә башлады. Бу — бик әйбәт. Мин дә менә нәшрият эшендә озак еллар нәтиҗәле эшләп килүче бер каләмдәш иптәшебез турында берничә сүз әйтмәкче булам. Ул — Даутов. Юк, мәшһүр җырчыбыз Нияз ага Даутов түгел, бу юлы — Рәис Даутов. Редактор һәм тәрҗемәче Рәис Даутов.

Редактор дигәнне, белмим, кем ничек аңлыйдыр, мин үзем, мәсәлән, бу төшенчәнең, гомумән, бу профессиянең чын асыл мәгънәсен чагыштырмача соң аңладым. Элегрәк, үсмер чакта, редактор дигәч, газетаның — районныкымы, өлкәнекеме яки үзәкнекеме — баш кешесе дип кенә аңлый идем. Баксаң, без балачактан укып килгән меңләгән-меңләгән китапларның да үзенчә баш, хуҗа кешеләре бар икән. Алар да редактор дигән зур исемне йөртәләр икән. Бераздан үзем дә әдәби мохиткә кереп, китаплар чыгара башлагач, редакторның язучы өчен бигрәк тә кирәкле икәненә ышанып җиттем шикелле. Чөнки китапның дөньяга ни рәвешле чыгуы күп яктан аларга бәйле. Намуслы, тәҗрибәле әдип-редактор яхшы кулъязмадан тагын да яхшырак китап чыгара ала. Язучы һәм укучы өчен шул гына кирәк тә инде! Ә бит яхшы гына кулъязмадан кайтышрак китаплар да чыкмый түгел... Рәис Даутов, Татарстан китап нәшриятында 25 ел эшләү дәверендә, берничә йөз китапның җаваплы редакторы булган кеше. Чирек гасыр эчендә кайларда кемнәр генә укымагандыр аларны! Кемнәр генә алардан гыйбрәт алып, нинди генә хис-уйларга тарымаганнардыр! Яхшы редактор ул — китапның чын мәгънәсендәге соавторы. Ул китапларның авторлары төрле җирләрдә, төрле телләрдә язучы, төрле характердагы кешеләр булсалар да, ул китаплар — Рәис Даутовныкы да. Аларда — аның да хәләл хезмәте, иҗади табышлары, янулары, кичерешләре... Әгәр ул китапларны табаклап исәпләсәң, 2000 табактан артыр, баганалап өеп куйсаң, ихтимал, өй биеклеге булыр иде! Рәис Даутов нәшриятта 1953 елның февраленнән бирле эшли. Башта балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты редакциясе редакторы, соңрак шул ук редакциянең мөдире. 1964 елдан матур әдәбият редакциясенең өлкән редакторы. Соңгы елларда күбрәк классикларыбызның күптомлы әсәрләренең редакторы булып танылды ул. Бу — бик җаваплы эш. Чөнки классик мирасны тиешле фәнни дәрәҗәдә, бүгенге укучы канәгатьләнерлек итеп чыгару — төзүчеләрдән, редактордан зур эрудицияле булуны, шуның өстенә шул чор һәм тарихны, шул заманда яшәгән күренекле шәхесләрнең тормышларын, иҗатларын яхшы бе-

лүне таләп итә. Соңгы елларда дөнья күргән борынгы әдәби ядкарьләрдән Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы, Утыз Имәни әл-Болгари, Акмулла, Дәрдмәнд әсәрләре җыелмалары, Г. Тукай, Г. Камал, Г. Ибраһимовларның күптомлыклары — барысы да Рәис Даутов редакциясендә. Ачып карасагыз, ул томнарның соңгы табакларын: анда күпме комментарийлар, саннар, исемнәр, белешмәләр, теге яки бу сүзгә аңлатмалар!.. Һәр сүзнең, һәр аңлатманың, һәр тыныш билгесенең дөреслеген карап-тикшереп чыгарга кирәк. Ә кайда тикшерәсең? Революциягә кадәр яки соңрак чыккан басмалардан, газета-журнал төпләмәләреннән, архив документларыннан, кулъязма һәм башка төр чыганаклардан. Аларның күбесе төрле имляларда, йә гарәп, йә латин шрифтында... Кыскасы, бу — фидакарь хезмәт. Мондый китапларны грамоталы итеп редакцияләү өчен, оста стилист булу белән бергә, галим дә булу кирәк, архивариусларга хас түзем һәм, ахыр чиктә, әдәбиятның чын патриоты булу да кирәк. Шуңа күрә драматурглар үз пьесаларын теге яки бу режиссердан сәхнәләштерәсе килгән шикелле, үз кулъязмаларының редакторы Р. Даутов булуын телиләр дип беләм. Соңгы елларда өлкән шагыйрьләребез Х. Туфан, С. Хәким һәм башка күренекле әдипләребезнең сайланма әсәрләре аның редакциясендә чыкты һәм алар бүгенге әдәби казанышларыбызны билгеләүче китаплар рәтендә.

Без Рәис Даутовны редактор һәм тәрҗемәче, дидек. Югарыда әйтелгәннәр аның редакторлыгы турында булды. Ул, тәрҗемәче буларак, шундый ук хуплау сүзләренә лаек. 1972 елда ул тәрҗемәче сыйфатында СССР Язучылар союзына кабул ителде. Р. Даутов тәрҗемә иткән зур күләмле әсәрләр дистәдән артык. Кечерәк күләмле әсәрләр, хикәяләр берничә дистәләп. Нинди әсәрләр соң алар? Ф. Достоевский — «Җинаять һәм җәза» («Преступление и наказание»), А. Куприн — «Молох», «Гранат кашлы беләзек» («Гранатовый браслет»), «Олеся», «Атышу» («Поединок»), М. Твен — «Король Артур сараенда янкилар» («Янки при дворе короля Артура»), Ф. Купер — «Соңгы могикан» («Последний из могикан»), М. Галәү — «Мөһаҗирләр» һ.б. Бу исемнәр үзләре генә дә тәрҗемәләрнең нинди таләпләргә җавап бирергә тиешлеген искәртәләр шикелле. Бәхетебездән, тәрҗемәче авторларының рухын һәм стилен бозмыйча, ул әсәрләрне ана телебездә табигый яңгырата алды. Бу китаплар татар укучыларының яраткан әсәрләренә әйләнделәр. Рәис Даутовның тагын бер эше — якташыбыз, рус телендә иҗат итүче Роман Солнцевның (Ренат Суфиев) «Көймә ватылса — утын» («Лодка идет на дрова») исемле повесте. Татар тормышын чагылдырган бу әсәр башта «Казан утлары»нда басылып, соңрак аерым китап булып та чыкты.

Хәзерге замана — илләр үзара аралашу, аңлашу заманасы. Халыклар, илләр, дәүләтләр үзара уртак тел табар өчен, иң әүвәл бер-береңнең тарихын, рухын белү, идеал-омтылышларын ачыклау мөһим. Хәзер инде ихтыяҗ булып әверелгән миссиядә тәрҗемәчеләрнең роле ифрат зур. Шуңа күрә дә әдәбият-сәнгать өлкәсендә булсынмы, техник-информация алышу юнәлешендә булсынмы — хәзер яхшы тәрҗемәчеләр бик тә кирәк замана. Безгә хәзер теләсә нинди телдән теләсә нинди телгә — русчадан татарчагамы яки татарчадан русчагамы яисә бүтән бер телгәме — бу эшнең зур осталары кирәк. Әйткәнемчә, бу — заман таләбе, мәдәни үсеш, тәрәккыят таләбе. Актуаль һәм үзәк мәсьәләләр турында һәрчак бәхәсләр һәм хәл ителергә тиеш проблемалар булган кебек, тәрҗемә эшендә дә бүгенге көндә төрле карашлар, төрле принциплар яшәп килә. Берәүләр «мәгънә бирелгән — җиткән» дип эшлиләр, икенче берәүләр «сүзен — сүзгә, өтерен — өтергә» принцибыннан чыгып тәрҗемәлиләр... Безнеңчә, Рәис Даутов үзе иҗат итеп тәрҗемә итә. Икенче төрле итеп әйткәндә, ул оригиналның стиль үзенчәлекләрен бозмыйча, авторның күңел хәрәкәте кичерешләрен татар теле нормаларына туры китереп, табигый яңгырашлы итеп тәрҗемә итә. Ахыр чиктә бит укучы өчен, китапны укыганда, автор үзе дә, тәрҗемәче дә юк, бары китап бар, аның геройлары бар; сүзтезмәләр, җөмлә-тәгъбирләр, вакыйга-сурәтләр биргән кичерешләр, дулкынланулар бар... Әлбәттә, зур тәҗрибәле һәр тәрҗемәченең әдәби сәнгатьнең катлаулы бу төренә карата үзенең шәхси күзәтүләре, кагыйдә-тәртипләре, гомумиләштерүләре, инанулары булырга мөмкин. Һәм ул шулай да. Әмма шунысы ачык: тәрҗемә эшендә зур тәҗрибәләре булган язучы-тәрҗемәче И. Гази, А. Шамов, Г. Ахунов, Н. Фәттах, Х. Сарьян; коллегаларыннан — К. Миңлебаев, Я. Халитов, Т. Нурмөхәммәтов, С. Ибраһимова, В. Зыятдинов кебек танылган тәрҗемәчеләр Рәис Даутов тәрҗемәләренә һәрвакыт зур ихтирам белән карадылар.

«Эше бар янында кеше бар» диләр. Рәис Даутов яныннан да кешеләр өзелеп тормый. Әнә аның яныннан Хәсән Туфан чыгып килә. Икенче бер кергәндә Сибгат Хәким яисә Гомәр Бәширов утыра... Нидидер бер йомыш белән Мөдәррис Әгъләмов кергән. Юк, әдипләр генә түгел, сәнгатьнең бүтән өлкәсе кешеләре дә аны үз итеп йөри. Рөстәм Яхин, Заһид Хәбибуллин, Хөснул Вәлиуллин, Фасил Әхмәтов, Алмаз Монасыйпов кебек композиторлар; Х. Якупов, Л. Фәттах, Т. Хаҗиәхмәтов кебек рәссамнар... Кемнәрне генә очратмыйсың аның бүлмәсендә! Юк, кемнәрдер уйлаганча, эш калдырып, гәп сатып утыру түгел бу, бу — иҗади атмосфера. Кайчак белемле галим кеше белән тиешлесен сөйләшү — көннәр буе чыганакларда яки архив документларында казынып утыруны алыштыра. Җанлы кеше җанлы кеше инде ул!.. Әнә нәшриятның дүртенче катына заманында бик күп дәреслекләр чыгарган, инде хәзер лаеклы ялда булып, сиксәнен тутырган Риза ага Газизов (аның хакында, пышылдап кына булса да, Г. Исхакыйга якын кеше булган икән дип тә әйтәләр!..) менеп бара.

— Кая юнәлдегез, Риза ага?

— Рәис янына менүем иде, бер-ике гарәп сүзенең мәгънәсен ачыклыйсыбыз бар...

Әйе, аның янына кешеләр килә. Гариза язып, нәрсәдер сорап, үтенеп түгел — теләп, күңелләре тартылып. Бу инде үзенә күрә бер бәхет.

Күктә төрле-төрле йолдызлар бар. Анда Зөһрә йолдыз бар. Казык йолдыз да, Киек Каз Юллары да... Төрлесе төрле яктылыкта. Ләкин һәммәсе үзенә кирәк урында һәм кирәк балкышта. Яшәеш күгендә дә шулай. Әдәбият-сәнгать күгендә дә. Бар үтә җете талантлы шәхесләр, бар бик тә якты йолдызлар. Ләкин ялгыз карлыгачлар яз ясамый, диләр. Бер энҗедән таҗ йөзе бизәлми... Күпер алдындагы субайларның язгы ташуларда очлары гына күренеп тора. Ә төптәрәк? Еш кына — алкышлардан ерак, ә кылган эшләре белән фидакарь булган кешеләр турында уйлап куясың. Бу сәгатьтә университет китапханәсендә әдәби мирасыбызның төп нөсхәләренең хакыйкый хуҗасы, зур галим Альберт Фәтхи үз бүлмәсендә борынгы кулъязмаларны өйрәнеп утырадыр; библиография һәм китаплар тарихы буенча зур белгеч Әбрар Кәримуллин берәр бик тә кирәкле хезмәт язадыр; талантлы археолог Равил Фәхретдинов моннан әллә кай заманнарда гөрләгән шәһәр-авылларны реаль күз алдына китереп, аларның карта-атласын төзидер; икенче бер тирән мәгълүматлы редактор Рашат Гайнанов гасыр башындагы берәр әдип псевдонимын ачыклыйдыр... Галим Хәлиф Курбатов поэтик хәзинәбезнең серләрен ачу белән мәшгульдер... Ә менә Бауман урамындагы Матбугат йортында аларга иш шәхесләрнең берсе — Рәис Даутов дөньяга бик кирәк бер китапны редакцияләп утырадыр... Әйе, Күк ул бөтен йолдызлары сау-имин булганда гына чын күк була ала!

Кайчандыр Мамадыш районының кечкенә генә бер Шәмәк дигән авылында туып, соңрак Биектау (элеккеге Кызыл Йолдыз районындагы бер авыл, халыкта ул авылны Кечек дип тә йөртәләр) авылында башлангыч белем алып йөргән малайга, соңрак Казанга килеп махсус мәктәп бетереп, солдат хезмәтләрендә йөргән егеткә, алма кебек балалар үстергән һәм йөзләрчә китапларга фатиха биреп, канат куеп дөньяга очырган ир затка 50 яшь тулды. Без аңа игелекле хезмәтендә яңа уңышлар һәм саулыклар телибез.

*1978, март*

* * *

Нәкъ 20 ел элек язылган бу мәкалә. Рәис абыйга 50, миңа — 35 яшь булган. Фикерләү рәвеше, стиль-язу манерасы шул заманча, әлбәттә. Егерме ел аккан су кебек үткән дә киткән... Әле яңа гына әдәби җәмәгатьчелек Рәис абыйның 70 еллык юбилеен зурлап уздырып җибәрде. Газета-журналларда аның хакында этрафлы мәкаләләр басылды. Аңа карата мөнәсәбәт элеккечә: ул — чын китапчы, чын әдип, кече күңелле, ярдәмчел... Әмма эпитетлар үзгәрә төшкән: күренекле тәрҗемәче һәм галим, энциклопедик мәгълүматлы редактор, халык академигы, «эшчән керпе»... Гадәт буенча уздырыла торган юбилей кичәсе дә бик күркәм узды аның. Әдипне зурлауларына сөенеп утырды халык. Язучыларның Тукай клубында әйтелгән һәр сүз, һәр чыгыш ихлас, чын, дустанә иде. Сирәк була андый кичәләр.

Рәис Даутов гомеренең кырыклап елын багышлаган Татарстан китап нәшриятында эшләми инде хәзер. Пенсиядәдер, диярсез. Яшь ягыннан пенсиядә пенсиясен, ә үзе һаман казна эшендә. Дөресрәге, бик тә җаваплы, кирәк эштә. Менә биш ел инде ул Татар энциклопедиясе институтының өлкән редакторы. Тиздән замандашларына, оныкларына барып ирешәсе энциклопедик китаплар төзү белән мәшгуль. Моннан 20—30 еллар элек эш-мәшәкатьләре күбрәк булганмы бу «эшчән керпе»нең, әллә хәзерме — кистереп әйтә алмыйм...

*1998, 29 апрель*

*P.S.* Хронологик эзлеклелек беркадәр үзгәрсә дә, Рәис ага Даутов турындагы бу язмага тагын бер-ике җөмлә өстәргә телим. 1998 елдагы язмага кечкенә генә кушымта булып чыга инде бу абзац.

* * *

1976 елны Татарстан китап нәшриятында миңа үзем өчен бик тә кадерле «Шигырь һәм поэмалар» исемле калын китап чыгарырга насыйп булды. Күләме ягыннан дисеңме, полиграфик эшләнеш ягыннан яки эчтәлек-төзелеш ягыннан дисеңме, күпләрне, хәтта классик дип йөртелгән өлкән шагыйрь агайларны да көнләштерерлек басма булды ул (34 яшемдә ул китап өчен Тукай премиясен дә биреп куйдылар). Менә шул китапны эшләгәндә Рәис абый белән якынлаштым да инде. Рәхәтлеге, үзгә бер ләззәте бар иде бергә эшләүнең! Келтер-келтер көлеп кенә шигырьләргә үз фикерен белдерә, артык вакланмый, булганны күрә, бәяли белә. Гомумән, миңа гомер буе әйбәт, үз эшләрен бик тә яхшы белгән редакторлар белән эшләргә туры килде (К. Миңлебаев, Я. Халитов, Н. Гамбәр). Рәис абый белән иҗади дуслык дәвамлы булды. Без берничә китапны бик тә аңлашып, бер-беребез эшеннән канәгать булып эшләдек. Күз алдына китерегез: кулъязмадагы шигырьләрне актарабыз. Ул ши-

гырьне берме-икеме кат укыган, аның «күпме торганын» белә, кәгазьгә ниндидер үзе генә белгән билгеләр дә куйган... Әмма әлегә фикерен әйтми, сынап күзгә карый. Авторның да бу шигырьгә үз хакыйкый бәясе бар бит әле! Башны иеп куясың, ул да шундыйрак ым кага. Бу — шигырь китапка керә дигән сүз була. Тагын актарабыз. Менә монысы, сизеп торам, аңа ошаган, ә мин баш чайкыйм. Шигырь китапка керми, кырыйга куела... Дөресен әйткәндә, шигырьләр күп, сайлап алырга мөмкинлекләр дә зур иде. Без Рәис абый белән әнә шулай күз һәм күңел белән аңлашып китаплар әзерләдек. Шәп еллар, Марсель Гали әйтмешли, догалы еллар!

*1998, 13 март*

## ОЧРАШУЛАР

Һай, гомер! — бу Шәриф Хөсәенов дигәннәрен дә егерме биш еллап беләм икән ләбаса! Акча алыштырган саен бәрәкәтсезләнә барган шикелле, еллар торган саен җитезрәк йөгерәләр, йөгерәләр генә түгел — очалар! Әле моны яше кырыкка да җитмәгән кеше әйтә: ә җитмешкә, сиксәнгә җиткәннәр ни генә уйламыйлардыр... 50 нче еллар урталары иде бугай, Казанда «Профессор кияве» дигән спектакль куйганнар дигән хәбәр безнең якларга да килеп ишетелде. Башкалага барып, спектакльне күреп кайткан берәр укымышлырак кеше әйттеме, әллә укытучыларның берәрсеннән ишеттемме, әллә радиодан өзек-мазар тыңлап истә калганмы, — хәтерләмим. Ни генә, ничек кенә булса да, безнең үсмер колакларга да килеп җитте бу хәбәр! Дөресен әйтим, спектакль, бу очракта пьеса үзе, әсәр буларак ул кадәр үк кызыксындырмады, ә менә исеме! — анысы инде шаккатырды. Кияү дигәнен беләбез, анысын өй-урам тирәсендә көненә йөз ишетәсең, ә менә «профессор»ны күрү түгел, ишеткән дә бик сирәк. Киноларда йә бик хикмәтле русча китапларда гына. Менә бит дөньяда ниләр бар! Казанда «Профессор кияве» дигән татарча спектакль куелган, ди бит. Нишлиләр икән ул профессорлар? Ничегрәк итеп сөйләшәләр икән? Профессор хәтле профессорлар турында язган кеше үзе кем икән? Тизрәк мәктәпне тәмамлыйсы иде дә, авыл читендәге үр юлларны үтеп, киңрәк дөньяга чыгасы иде! Бәлки, ул зур дөньяларны да күрербез әле!.. Шәриф Хөсәенов дигән исем миңа әнә шулай унике-унөч яшьләрдә, бераз серле, әмма зур һәм якты, хыялларны үстереп җибәрә торган исем булып хәтергә сеңеп калды.

Шуннан соң үткән егерме елдан артык вакыт эчендә чын профессорларны, әйтергә кирәк, төрле дәрәҗәдәгеләрен, байтак күрергә туры килсә дә, малай чакта күңелне кытыклаган «Профессор кияве» спектаклен тәки карарга туры килмәде. Соңрак пьеса кайта-кайта укылды, билгеле. «Төзәтелергә тиеш спектакль», «Спектакль төзәтелгәч» дигән сәеррәк исемле рецензияләр белән дә танышылды. Заманында Татарстанда, шулай ук тугандаш халык сәхнәләрендә зур уңыш белән барган бу пьесаның яше белән егермедән әз генә өстә булган студент, медицина институты студенты тарафыннан язылганын ул чакта белгән булсам, ихтимал, гаҗәпләнү һәм соклануым тагын да арткан булыр иде. Хәер, бу тойгының хәзер дә кимегәне юк. Татар дәүләт академия театры кебек зур сәхнәдә шулай яшьли пьеса куйдыра алган бүтән авторны мин хәтерләмим.

Бу исем белән икенче тапкыр очрашу көтмәгәндәрәк булды. Кайда дисезме? «Татар халык мәкальләре» дигән китапта очраттым мин бу Шәриф Хөсәенов дигән исемне. Күпләрнең хәтерендәдер: халык телендә бик хаклы рәвештә академик саналган Нәкый Исәнбәтнең 1959 елны мәдәниятебез тарихында сөенечле вакыйга булып, «Татар халык мәкальләре» дигән фундаменталь хезмәтенең беренче томы басылып чыкты. Кереш сүзенең бер җирендә Нәкый ага болай дип яза: «Язучы Шәриф Хөсәеновның Буа районыннан җыйган бер мең чамасы мәкаль һәм әйтемнәре дә... шушы томга керәләр... Аңа рәхмәт белдерүне бурычым дип саныйм». Бу юлларны укыгач, бу кешегә, табигый, ихтирамым бермә-бер артты, бу исем үзем өчен тормышта үрнәк алырга лаек дип санаган исемнәр рәтенә күчте. Шул ук вакытта — инде әзрәк каләм тибрәтә башлаган чак — бу исә яхшы мәгънәдә көнләштерде дә. Бар бит кешеләр! Үзе медик, үзе драматург, үзе халык иҗатын җыйган фольклорчы. Ә без?.. Эшләргә! Тырышыбрак, көч-дәртне җыя төшебрәк эшләргә!

Очрашуның нәүбәттәгесе тагын бер ел үткәч булды. «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы 1960 елда үзенең 4, 5, 6 саннарында Шәриф Хөсәеновның «Мәхәббәт сагышы» повестен бастырып чыгарды. Бик күп әдәбият сөючеләр өчен бәйрәм китергән әсәр булды ул. Дөрес, кемнәргәдер ул ошап та бетмәде бугай, тәнкыйтьләүчеләр дә табылды, повесть аерым китап булып биш-алты ел үткәч кенә чыга алды... Нишлисең, әдәбиятта булгалый андый хәлләр. Әмма Матбугат йорты тирәсендәге агай-эне ничек кенә бәяләмәсен, укучы үлеп яратты бу повестьны. Авылда булсын, шәһәрдә булсын, әле үз теле белән исәп-хисапны өзеп бетермәгән зыялы һәр татар укучысы укып чыккандыр. Күңелне чистарта торган нәзакәтле әсәр ул «Мәхәббәт сагышы»! Мәхәббәт-сөю хисен татыган һәр яшь кеше Хәбир белән Мәдинә мисалында күпмедер дәрәҗәдә үзен күрде, үз кичерешләрен таныды. Хикмәт повесть каһарманнарының кемнәр һәм вакыйгаларның кайда һәм ничек барудында гына түгел, хикмәт — мәгълүм бер чор, әйтик, 50 нче еллар яшьләренең рухын ачуда, күңел тибрәнешләренең тәңгәллеген сиздерүдә, уртак кылда уйный алуда! Өстәвенә гаҗәп халыкчан тел

белән затлы стильдә язылган бу әсәр. Шул елларда, икенче кат укыганда булса кирәк, повестьтан үземә ошаган байтак җөмләләрне аерым бер дәфтәргә язып куйганмын. Хәзер укып карыйм да, бик дөрес эшләгәнмен, дип куям. Чөнки алар хәзер дә дулкынландыра. «Казан урамнары нинди кыска!» (сөйгән ярны тиз генә өйләренә кертәсе килмәүне кайсыбыз гына кичермәгән!); «Күңелләр мөлдерәп тулган, сүзләр иреннәргә бал булып сыланган»; «Мәдинәләр өендә берәү дә кычкырып еламый» (безнең халыкның рухи халәтен күрсәткән бер сыйфат түгелме соң бу?!); «Аягың аксаса, таякка таянырсың, күзләрең күрми башласа, күзлек киярсең, сусасаң, су эчәрсең, арысаң, утырып ял итәрсең, ятып йокларсың... Мәхәббәтең сүрелә башласа, нишләрсең?»; «Ләкин бу гасыр, фәннең һәр казанышын, даһилыкның һәр чагылышын җимерү өчен генә файдаланырга исәп итүче кешеләре дә булган бу замана — сәнгать заманымы соң?»; «Бу рәхәтлек болай да мөлдерәп тулган. Аның бөтен татлылыгын тою өчен дәшмәү кирәк»...

«Мәхәббәт сагышы» белән мин 1967 елның көзендә тагын бер мәртәбә көтмәгәндә очраштым. Куйбышев шәһәрендә хезмәт иткәндә, солдат казармаларының берсендә бер татар егете «Мәхәббәт сагышы» дигән китаптан ниндидер сүзләрне, ниндидер җөмләләрне үзенең куен дәфтәренә күчереп утыра иде. Шулчак үземне үзгә бер шатлыклы хис чорнап алган иде. Менә бит ул — дөньяның җандаш кемнәре юк дисең! Ул көнне полкның шактый ук соры ишегалды да хәйран гына матур булып күренгән иде...

Еллар үтте. Очрашулар ешая төште. Очрашу шул: бер-бер артлы (дүрт-биш ел ара калдырып булса да) Шәриф Хөсәеновның ике пьесасы сәхнәдә куелды. Хәзерге татар драматургиясенең иң камил әсәрләреннән саналырга лаек ул әсәрләр — «Зөбәйдә — адәм баласы» һәм «Әни килде». Бу әсәрләр җәмәгатьчелеккә киң мәгълүм әсәрләр, алар турында күп сөйләнгән, күп язылган, халыкның ихтирам мөһере сугылган... Зөбәйдә образын иҗат иткән Наилә Гәрәева һаман күз алдында, Галимә ханым Ибраһимова башкаруындагы Ана мәңге онытылмаслык. Тамашачыны уйландырды ул спектакльләр, урыны-урыны белән сискәндерде, оялтты, искәртте, өндәде, кече күңелле һәм олы җанлы булырга чакырды. Бу әсәрләр заманның төп проблемаларыннан берсе булган әхлакый тәрбия эшендә шактый ук игелек күрсәткән булып чыктылар. Шуңа күрә булса кирәк, аларны илебезнең төрле почмакларында байтак театрлар бик теләп һәм яратып сәхнәләштерде. Шәриф Хөсәенов әсәрләренең үзенә тарта торган тагын бер күркәм ягы бар: аның пьесасындагы персонажлар — катнашучылар диикме — табигый мохиттә, табигый ситуациядә, табигый халәттә сөйләшәләр, хәрәкәт итәләр, яшиләр. Әсәрнең халыкчанлыгын билгеләүче төп сыйфатларның берсе түгелме соң бу? Тормышыбыздагы гомумиләштерүне «сорап торган» вакыйга-хәлләрне һәм типик характерларны «тотып» алып, аларны ышандырырлык рәвештә халыкчан телдә бәян итү өчен, әлбәттә, чынбарлыгыбызны тирәнтен белү, үткен күзле һәм зирәк акыллы булу шарт. Гомумән, сәнгатьтә табигый була алу инде талантка, осталыкка, хикмәткә ия булу галәмәте. Еш кына фикерле генә драматургларыбызның әсәрләренә нәкъ шул табигыйлек җитенкерәми дә. Кайбер спектакльләрдәге геройлар, әйтик, җыештыручы апайлар, каравылчы агайлар, балта осталары рәхәтләнеп сәхнәдә язучының үз лексиконы белән сөйләшәләр. Шулкадәр оста һәм дөрес, фәнни итеп сөйләшәләр ки, инде ахырга таба тәмам ышанмый башлыйсың. Тимерче агайга дирижер фрагын кидерткән шикелле килеп чыга... Бу яктан, шөкер, Шәриф Хөсәенов әсәрләренә тел-теш тидерерлек түгел. Соңгы елларда Казан телевидениесеннән еш кына тапшырыла торган «Генеральная уборка» спектаклен генә искә төшерегез, персонажларның сөйләм телләренә игътибар итегез. Никадәр тормыш дөреслеге аларда!

Язмыш, һәр теләгәнне кулыңа китереп тоттырмаган кебек, күңел сусаган һәр очрашуны да гел насыйп итеп тормый. Шәриф Хөсәенов иҗаты белән очрашулар да шулайрак. Кайчак еллар буе бу исем матбугат битләрендә күренми. Юксына башлыйсың. Шулай да ул, рәхмәт төшкере, бөтенләй үк югалып бетми: йә берәр журнал битендә берәр хикәя, йә үзе хөрмәт иткән берәр сәнгать остасы турында язма бастырып куя... Быел яз башында иде бугай, аның белән тагын бер мәгънәле очрашу булып алды. Бусы эфир аша. Күренекле җырчыбыз Мәрьям ханым Рахманкуловага багышланган борынгы җырлар белән бергә үрелеп, әңгәмә рәвешендә барган бу радио тапшыруының авторы Шәриф Хөсәенов иде. Тапшырулар шактый күп булып торган кебек, тапшыру-сценарий авторлары да байтак булырга мөмкин. Шуңа күрә тапшыру авторы булу факты әле әллә ни гайре табигый нәрсә түгел. Нинди тапшыру бит! Шунда хикмәт! Зур җырчының иҗаты нисбәтендә халкыбызның җыр сәнгате, тарихы һәм үсү перспективалары турында югары дәрәҗәдәге тирән анализлы, уйландыра торган зур сөйләшү иде ул. Мәрьям ханым башкаруындагы «Кызыл төлке» кебек шедевр җырлар белән бергә, авторның җырларны комментарияләү рәвешендә сөйләве, ягымлы һәм хөр авазы хәзер дә колак төбендә, һәр сүздә, һәр фразада, һәр җөмләдә авторның җырны, көйне тирән белүе, музыкада зур мәгълүматка ия булуы сизелеп тора иде. Күбрәк музыкаль терминнар белән эш итәргә яратучы кайбер музыка белгечләре бер кырыйда торсын!.. Быел җәй көне матбугат битләрендә Шәриф Хөсәенов исеме тагын бер күренеп алды. ТАССР Верховный Советы Указы белән аңа «Татарстанның атказанган врачы» дигән мактаулы исем бирү хәбәре чыкты. Бусы үзе менә дигән очрашу бит инде! Медик булып, бигрәк тә язучы булып тарихта калган Чеховлар, Вересаевлар искә төште.

Шул ук вакытта уйланырга да мәҗбүр итте бу хәбәр. Хәзер безнең әдәбиятта бер үк төрле биографияле (гадәттә, мәктәп — филологик профильдәге вуз-газета-журнал редакцияләре), бер үк почерклы стереотип яшь язучылар шактый күбәеп китте... Бер үк ысул белән эшкәртелгән, бер үк төрле орлык чәчелгән җирдән бертөрле уңыш чыгуы бер дә гаҗәп түгел. Ә тормыш бит үзе гаҗәп күпкырлы! Тормышның көзгесе — әдәбиятка килү һәм игелек күрсәтү юллары да күптөрле бит. Әйтик, Шәриф Хөсәенов мисалы шуны күрсәтмимени? Хәер, бер ул гынамы соң? Әдәбиятта андый мисаллар бер дә юк түгел: комиссар Шамил Усманов, очучы Салих Баттал, галим-химик Җәвад Тәрҗеманов, галим-ветеринар Атилла Расих, диңгезче Миргазиян Юныс...

Сүземнең ахырында өстәп шуны гына әйтәсе килә: мин Шәриф Хөсәеновның үзен күреп белмим диярлек. Инде егерме елдан артык әдәби мохиттә азмы-күпме катнашып килүче буларак, мин бөтен исән язучылар белән беркадәр аралашкан кеше. Ә менә Шәриф Хөсәенов белән аралашырга туры килмәде. Дөрес, аны берничә мәртәбә ачалак-йомалак күреп тә калганым бар... Хәтта бик озын өстәлле бер мәҗлестә бер түбә астында утырдык та шикелле. Әмма ул кеше белән махсус беркайчан да очрашканым булмады. Шулай да менә инде чирек гасыр мин аның белән, аның иҗаты белән очрашып, һәр очрашуга куанып яшим. Иҗади очрашудан, уй-хисләр уртак булып кушылып китә алудан да зуррак очрашу мөмкинме соң!

*1979, ноябрь*

**АТЫЛГАН ЙОЛДЫЗ КЕБЕК...**

Тәбриз Мөбарәков татар прозасында, яшендәй атылган йолдыз кебек, тиз арада якты эз калдырып киткән шәхес. Аның әдәбиятка килү юлы да үзенчә гыйбрәтле. 1932 елның февралендә Арча районының Мөрәле авылында дөньяга килгән Тәбризнең әтисен 1937 елны халык дошманы дип кулга алалар һәм атып үтерәләр. Әтисез калган Тәбризгә фәкать үз көче һәм тырышлыгы белән зур дөньяга юл ярырга туры килә. Ул бик яхшы билгеләренә Сеҗе урта мәктәбен тәмамлый. Соңрак, Казан университетының физмат факультетында укып, аның аспирантурасын тәмамлап, физика-математика фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә ирешә. 1970 елларда ул Алабуга пединститутында эшли, ә гомеренең соңгы 25 елы Уфа авиация институты белән бәйләнгән. Т. Мөбарәков — машиналар төзү өлкәсендә физика-математика теорияләрен куллану буенча 20 дән артык фәнни хезмәт авторы. Аның кайбер гыйльми хезмәтләре чит ил галимнәре арасында да танылу таба.

Гаҗәп хәл: гомере буе югары уку йортларында рус телендә төгәл фәннәр укыткан галимнең күңелендә, ком-таш эчендәге алтын кисәге шикелле, саф туган телебез стихиясендә кристаллашкан олуг хәзинә — әдәби талант яткан. Шунысы кызганыч: бу хәзинә галим-әдип гомеренең соңгы елларында гына халыкка ачыла алды. Т. Мөбарәковның укучылар күңеленә кереп калган төп әсәре — «Хәтер аланы» исемле повесть. Бу әсәр «Казан утлары»нда 1995 елның 4 санында басылып чыкты. Повестьның журнал вариантын мәрхүм шагыйребез Рәшит Әхмәтҗанов әзерләгән иде. Тормыш чынлыгы ягыннан булсын, тел җәһәтеннән булсын, әсәр гаять үзенчәлекле, һәм ул хаклы рәвештә җәмәгатьчелек тарафыннан үзенә лаеклы бәһане алды да. Соңрак журналыбызда М. Мәһдиев турында истәлекләре дә басылды. Шул ук елларда аның «Кәшемир шәл», «Аю белән Аккош мәхәббәте», «Гөләби», «Космоста булмасак та» кебек матур-матур хикәяләре «Сөембикә» журналында, «Шәһри Казан» газетасы битләрендә дөнья күрде. Т. Мөбарәков әсәрләре гади укучыны гына түгел, танылган язучыларның һәм әдәбият белгечләренең дә игътибарын җәлеп итте. Ә. Еники, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, А. Хәлим, В. Ихсанова һ.б. аның иҗатына югары бәя бирделәр. Ул Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы итеп кабул ителде.

Ни аяныч, Т. Мөбарәков үзенең зур иҗат планнарын тормышка ашыра алмыйча, 1996 елны вафат булды.

*2002, февраль*

**ӨЛКӘНЕБЕЗ**

*(Каләмдәш, хезмәттәш, остаз турында берничә сүз)*

Әдәби хәрәкәтне аерым бер буыннарга, аерым бер юнәлеш-стиль тарафдарларына яки аерым бер төбәк-регион вәкилләренә бүлеп өйрәнүче кайбер тәнкыйтьчеләр өчен Марс Шабаев иҗаты бик үк кулай иҗат түгел. Инде трафарет рәвешенә әйләнгән «обоймалар»га да сыеп бетми ул, фәлән әдәби мәктәп вәкиле дип әйтү дә кыен, әдәбиятта «Минзәлә феномены» да шәйләнми шикелле. Өстәвенә Марс Шабаев иҗатын әдәбиятчылар җентекләп анализлап өйрәнделәр, пропагандаладылар дип тә булмый. Кайчак Марс Шабай белән Мин Шабайны буташтыручылар да очраштыргалый. Шулай да Марс Шабаев — үткән гасырның икенче яртысындагы әдәби мохитнең төп тенденцияләрен

ачыклый алырлык иҗатчыларның берсе саналырга лаек. Гомумән, яшьләре бүген 70 ләр тирәсе булган әдипләрнең ярты гасырлык иҗат гомерләре—әлбәттә, тормыш юлын тоташ әдәбиятка багышлаганнарны күздә тотам — шул чорның үзенчә бер рухи кардиограммасы ул. Бар казанышлары, ялгышлары, иманлылыклары, дәһрилекләре белән... Әмма бернәрсә бәхәссез: соңгы ярты гасырдагы татар әдәбиятында шәхесләр, талантлар бихисап булган. Объектив яки субъектив сәбәпләр аркасында алар үз талантларын никадәр реальләштерә, киләчәк файдасына эшләтә алганнар? — монысы инде бүтән мәсьәлә...

Марс Шабаев, беренче чиратта, әлбәттә, шагыйрь. Анык һәм тайпылышсыз үз гражданлык позициясе булган шагыйрь. Әдәбиятны кеше аңын формалаштыруда бөек көч дип санаган буынның күренекле бер вәкиле. Гражданлык позициясе булу — зур нәрсә; безнең аңлавыбызча, җәмгыять куйган идеалга максимум тугры хезмәт итү ул. Никадәр генә талантлы булсаң да, җәмгыять мәшәкатьләренә битараф булып, үз-үзеңә генә бикләнеп, үз җаныңда гына казынып иҗат итсәң, язганнарыңа замандашларың да битараф булуы мөмкин. Марс Шабаев моны гомере буе аңлап яшәде дип беләм. Ул һәрвакыт тормышның фарватерында, әдәби-сәяси хәрәкәтнең үзәгендә булды. Иҗатын иҗтимагый эш белән бергә алып барды, таланты куәтенчә илгә, булсынга дип хезмәт итте. Ул —Татарстан радиосында редактор, балалар газетасы «Яшь ленинчы»да бүлек мөдире; ул — «Азат хатын» («Сөембикә»), «Чаян» журналларында, «Идел» альманахында җаваплы секретарь, тәрҗемәче, җаваплы редактор; ул — байтак еллар Татарстан китап нәшриятының баш редакторы, соңгы ун елда «Казан утлары» журналының бүлек редакторы. Гомере буе җаваплы эшләр. Артта — озын-озак казна хезмәте, алдында — тынгысыз иҗат нәтиҗәсе — егермеләп китап.

Минем шәхсән үземә Марс Шабаев белән безнең заманның ике чорында ныклап аралашырга туры килде. Беренчесе — безнең буын шагыйрьләренең әдәбиятка юл ярган елларында, ягъни 60 нчы еллар башында. Шул вакыттагы сәләтле яшь каләм ияләрен үз тирәсенә туплый алган иде ул. Кайберәүләр өчен, шул исәптән минем өчен дә, Марс абый остаз, русчалап әйтсәк, наставник ролен үтәде. Без аңа тартылдык, макталдык, тиргәлдек, кирәк киңәш-сабаклар алдык. Рәхмәт әйтеп искә алыр матур еллар!.. Икенчесе — байтак гомерләр үткәч—узган гасырның 90 нчы елларыннан башлап хәзергәчә «Казан утлары» редакциясендә бергәләп эшләү чоры. Ул — бүгенге көндә, әйткәнемчә, журналыбызның бүлек редакторы. Югары профессионал осталык һәм тәҗрибә таләп иткән вазифа. Һәм, әйтергә кирәк, кайбер яшьрәкләргә үрнәк рәвештә егетләрчә эшләп килә Марс абыебыз! Җитмешкә җиткән димәссең! Хезмәттәшләребезгә сер түгел: журнал портфеленә кергән четереклерәк сәяси-публицистик материалларның байтагын басарга әзерләү эшен аңа йөклибез. Дөресен әйткәндә, бәгъзеләрнең андый мәкаләләрне эшкәртергә «теше үтми», йә эрудиция-гыйлем җитенкерәми, йә язу-стиль куәсе чамалырак... (Ах ул профессиональ кадрларга дефицитлык!)

Талантлы кеше һәр эштә дә талантлы була, диләр. Мөгаен, шулайдыр. Марс Шабаевка бу тәгъбир туры килә. (Хәер, нигә гаҗәпләнергә? — профессионал кеше үз эшенең бөтен тармакларын яхшы белергә тиеш. Күппрофильлек дигән төшенчә юкка гына тумагандыр бит!) Шагыйрь, менә дигән редактор булу өстенә ул яхшы тәрҗемәче дә. Элегрәк тә тәрҗемә эшенә хирыс булса да, соңгы елларда аның бу өлкәдәге хезмәте зур бәягә лаек. Мәсәлән, Мәскәүдә яшәп рус телендә иҗат итүче Рауль Мирхәйдәровның «Ранняя печаль» («Иртәләгән сагыш»), «За все наличными» («Һәммәсенә акчалата») романнарын, тәрҗемә икәнен сиздертмичә, саф татарча яңгырата алды ул. Бәлки, үзенең язасы әсәрләре өлешенә кереп башкарыладыр бу хезмәт... Әмма мактаулы хезмәт, бүгенге көндә тәрҗемә эшенең аяныч хәлдә икәнен искә алганда, бигрәк тә кирәк мөһим хезмәт.

Бу бәләкәй генә язманы сызгалаганда, белешмә кирәксенеп, Татар энциклопедик сүзлегенә (дөресе — «Татарский энциклопедический словарь», әле татарчасы дөнья күрмәгән) күз салдым: «Ш» хәрефендә беренче булып куелган белешмә-мәкалә. «Шабаев Марс Садриевич (р. 1933), поэт. Заслуженный работник культуры... «Избранные произведения» («Сайланма әсәрләр», т. 1–2, 1993)... Гос. пр. им. Г. Тукая». Һәммәсе дөрес кебек, әмма бер төгәлсезлек. М. Шабаевның сайланма 2 томлыгы дөнья күрә алмаган икән бит! Энциклопедияләр дә ялгышыр икән! Ярый, баш ярылып, күз чыкмаган — төзәтерлек хата... Тотарга да шагыйрьнең томлыкларын чыгарырга кирәктер! Иҗат бар бит...

*P. S.* Марс Шабаев турында 1976 елны да балалар матбугаты өчен бер кечкенә мәкалә язган булганмын. Искә төште дә, ничек бар, шул килеш бу язмама ул мәкаләне дә өстәп куярга булдым. Бәлкем, шагыйрь һәм тәрҗемәче турында мәгълүмат тулырак булыр.

**Чал чәчле, яланаяклы...**

Сезнең салда йөзгәнегез бармы?

Ә минем юк. Кызганыч, әлбәттә. Йөзмәүнең йөз төрле сәбәбен дә табып була булуын... Ә бит кешеләр йөзә. Тур Хейердаллар, ирле-хатынлы Папазовлар көймә-салларда океан-дәрьяларны кичәләр.  Алар кебек кыю йөрәкле, тәвәккәл кешеләр вакытын да табалар, җаен да... Марс Шабаевның «Салда сәяхәт» китабын укый башлагач, күңелдә көнләшүле-моңсу бер тойгы уянды: нигә инде мин дә «Шыртлака» экипажында булмаганмын? Өйләрендә хатыннарын, инде җитеп килүче балаларын калдырып, айлыклап, су буйлап ил гизәргә чыккан бу агайлардан киммени мин? Дөрес, тора-бара соңга калып туган бу теләк бераз кими төште. Күңел утыруның сәбәбе — китапны укып чыгудан алган ләззәт иде. Мин дә бу сәяхәттә катнашкандай булдым. Иң матур елгаларыбызның берсе булган Ык дулкыннарында тирбәлдем, таң алдыннан итәкләре белән суга ук тиеп торган куе томаннарны ишкәкләр белән тараттым, әрәмәлекләрдәге кошларның сайрауларына хәйран калдым, табигатьнең эченә кереп, аның белән бер булып китүемә, аның да иң камил җаны — Кеше булуыма сөендем, үзем өчен дөнья кадәр ачышлар ясадым. Инде мең тапкыр күрелгән, әмма исемен белмәгән бу үләнне авыл халкы менә ничек атый икән! Бездә тагын менә нинди кошлар бар икән! Туган җиребезнең табигате, күрә һәм таный белгәндә, менә нинди бай һәм нинди гүзәл икән!

М.Шабаев — шагыйрь. Һәр кеше күңеле белән күпмедер дәрәҗәдә шагыйрь булса да, ил танырлык чын шагыйрь булу өчен күп нәрсә кирәк. Шуларның, ихтимал, иң кирәкләре — үзеңдә балалыгыңны һаман яшәтә алу, күзләреңнең уңмавы, гаҗәпләнү тойгысын җуймау. Бу табигый шигъри халәткә гомер дәвамында тупланган тәҗрибә, гражданлык сыйфатлары өстәлергә тиеш әле тагын, алар — принципларың, иманың, иҗтимагый йөзең, намусың, ныклыгың... Миңа кайчак шагыйрьләрнең символик образы чал чәчле, яланаяклы бабай да, малай да булып күренә.

Бүгенге көн татар поэзиясендә яхшы шагыйрьләр байтак. Аларны төрле буында күреп була. Урта буын, ягъни, яшьләре кырык белән илле арасындагы шагыйрьләр безнең шигырь дөньясында аерым бер күркәм урында тора. Бу — яшьлекләрен сугыш өткән буын. М. Шабаев — әнә шул буын вәкиле.

Түзмәде күңел, ярсыды
Тәкәрлек тавышына,
Балачакка кайтып, хәтер
Моң булып калды шунда.
Ул йөрде балтырган ашап,
Юа белән юанып...
Хәтер — сагышлы бер йолдыз:
Һич сүнәсе юк аның!
Уенны иртә оныткан
Сагышлар дөньясыннан
Ул йөрде күкәйләр эчеп
Тәкәрлек оясыннан...
Тәкәрлекләр, үксисез лә:
«Ти-и-иде!.. Ти-и-иде!..»
— Кем тиде?
Кайтармагыз шул елларга,
Кайтармагыз сез мине.
Көйде, көйде... утта көйде
Әтиләр...
Үстек ятим...
Ти-и-иде!.. Ти-и-иде!..
Безгә тиде
Зур сугыш...
Нәрсә әйтим?..

Ә шагыйрьнең әйтер сүзләре күп. Ил иминлегенең кадерен белергә, бер кабым икмәкнең һәм бер авыз җылы сүзнең тәмен һәрчак тоеп яшәргә, эти-бабаларыбызның каннары һәм гомерләре белән беркетеп безгә калдырган  рухи васыятьләрен онытмаска, заман куйган йөкне сыкранмыйча күтәрә белергә...

Марс Шабаев — уннан артык шигырь китабы иҗат иткән шагыйрь. «Яңа җыр», «Кына гөле», «Ашкыну», «Сине эзлим», «Җикән камыш», «Онытма» һ. б. Ул сигез поэма авторы («Шәймәт карт», «Яңа җыр», «Җирән Конрад», «Кына гөле», «Әби-апа», «Дие татарише фрау», «Сине эзлим», «Артист»...). Американың бөек шагыйре У.Уитменның мәшһүр «Үлән яфраклары» китабын татарчага тәрҗемә иткән кеше. Кордаш шагыйрьләре — Е.Евтушенко, Б.Әхмәдуллиналарның да кайбер әсәрләре аның тәрҗемәсендә татар укучыларына барып иреште. Шагыйрь иҗаты турында әллә ни күп булмаса да, беркадәр мәкаләләр язылды да инде. Тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият белгечләре аның иҗат колачы киңлеген, шигырь һәм поэмаларының фәлсәфи тирәнлеген, кешелеклелек белән сугарылган интернациональлеген, фикерләренең эзлеклелеген әледән-әле әйтеп

киләләр. Бу мәкалә-чыгышлар авторларының, гадәттә, өлкәнрәк буын вәкилләре булуыннандыр, күрәсең. М.Шабаевның балалар өчен язган әсәрләре һәм яшь каләм ияләрен үстерүдәге эшләре читтәрәк кала, ә аның бу өлкәдә дә хезмәте зур. Әле мисалга китерелгән шигырендәге «тиде» сүзе белән әйтсәк, аның яшь поэзия өчен шифасы күп тиде. Ф.Яруллин, мәсәлән, турыдан-туры М.Шабаев ярдәме белән шагыйрь һәм язучы булып танылды. Ә 60 нчы еллар уртасында поэзиягә килгән бүтән шагыйрьләр? Аларның күбесе М.Шабаевны үзләренең тәрбиячесе һәм якын киңәшчесе итеп таныйлар. Иҗатының нигезен тоткан принциплары аның иҗтимагый һәм көндәлек тормышыннан аерылмый. Димәк, буыннар эстафетасы дәвам итә! Димәк, тоткан юл дөрес, түккән көч яңа таза шытымнар бирә, димәк, яшәргә була!

Ә салда йөзүгә килсәк, андый хыялның әле миндә һаман сүнгәне юк. Кем белә, бәлки, сезнең берәрегез белән без дә йөзәрбез әле, сау булсак!

*1976, апрель*

## ЯШӘҮГӘ ЫШАНЫЧ

Алкышларга исең бик китмәсен,
Син сугышчан сафта, шигырем!

*Әхмәт Рәшитов*

Ул үзенең китабын «Киек Каз Юлы» дип атаган. Киек Каз Юлына тезелгән йолдызларны аерым-аерым сирәк кеше беләдер. Шигърият күгендә дә балкышлары төрле-төрле булган йолдызлар бик күп. Гадәттә игътибар үтә җетеләренә төшә, бүтәннәре күз уңыннан читтә кала бирә. Шагыйрь Әхмәт Рәшитовны да әдәби җәмәгатьчелек үзенең сүзе һәм игътибары белән гел үсендереп торды дип әйтмәс идем. Ә ул исә үз җаена эшли, әйтергә кирәк, актив эшли бирә, күңел яктысын, үз урындагы йолдыз кебек, җиргә, кешеләргә өләшә тора.

Әхмәт Рәшитов — яше ягыннан да, язганнары белән дә тәгаен урта буын вәкиле. Аның иҗат багажы — йөзләгән публицистик һәм лирик шигырьләр, алты поэма, популяр җыр текстлары, тәрҗемәләр... Аларның күбесе соңгы ун ел эчендә «Хатирә», «Сәяхәтнамә», «Кояшлы ил — бәхет иле», «Киек Каз Юлы» кебек китапларда басылган. Әле яңа гына Мәскәүнең «Современник» нәшриятында шагыйрьнең рус телендә дә тәрҗемә китабы чыкты. Яңа әсәрләре газета-журнал битләрендә шактый еш күренә. Соңгы елларда үзәк матбугат битләрендә дә, әйтик, «Молодая гвардия», «Поэзия», «Истоки» журналларында һәм альманахларында, «Литературная Россия», «Социалистическая индустрия», «Советский патриот» газеталарында аның шигырьләре күренүе күңелле хәл. Бигүк еш булмаса да, аның әсәрләрен үзәк радио аша да ишеткәләп торабыз. Шагыйрь иҗаты турында болай экскурс ясап сөйләп узуым, беренчедән, укучы өчен беркадәр гомум мәгълүмат бирү булса, икенчедән, соңгы чыккан китабының төп мәгънәсен һәм авторның үсү юнәлешен ачыклау өчен элеккеләрен дә белү кирәк.

Әхмәт Рәшитов — газиз әтиләрен яшьли югалткан буын вәкиле. Аларның балачакларын, күкрәп үсеп килгән яшь игеннәрне боз суккан шикелле, сугыш алган. Күңелләре үтә нечкәреп, тиз җәрәхәтләнүчән булып калган. «Бик аз күреп әткәм-әнкәм назын, мин тугызда ятим калып үстем, көтә-көтә илнең зәңгәр язын, хәсрәт дәрьясыннан сулар эчтем...», «Нәселем агачлары ботаклары ботарланган сугыш елында...», «Үксемәгез әле, акчарлаклар! Болай да бит үксез күңелнең ташып чайкалырга торган чагы!..» Әтисенең сугышчан истәлеге итеп командиры салган медальнең дә язмышы бүтән бик күп малайлар горурланып тоткан медальләргә караганда бүтәнчәрәк. «Тик медальне күкрәгемә тагып, мактанырга насыйп булмады. Карамыйча йөрәк ай-һаена, сыйланырга теләп чак кына, биреп тордым күрше малаена ярты сынык икмәк хакына...» Шагыйрьнең иҗатын шушы буын кичергән тарихи фаҗигадән аерып карап өйрәнеп булмый.

Борынгыдан килгән хакыйкать: һәр зур сәнгатьнең нигезендә һәрчак фаҗигале хәл, фаҗигале халәт ята. Ә фаҗига орлыгы үзенең кайчан да булса шушы якты дөнья белән саубуллашып китәчәген белеп торган һәр адәм затында бар. Мәсьәлә аның масштабында. Ул — шәхси «мин» дигән җисми тирәлектәме, әллә күп меңнәрнең омтылышларын туплаган иҗтимагый иман югарылыгындамы? Ә. Рәшитов, минемчә, әнә шул иҗтимагый иманга табынып, безнең уртак идеалларга йөз тоткан шагыйрь. Аның көчле ягы — иҗтимагый ышанычында. Әлбәттә, табигый сәләт белән кушылган ышанычта. Чыннан да, артык кашык ук булмаса да, сугыштан каһәрләнгән дөньяда ятимлек, ачлык-ялангачлык күреп үсеп кара да, киләчәк көненә якты ышанычың булмаса, ничек итеп шактый авыр елларда укып йөр, университетларга кер, әдип-шагыйрь булырга батырчылык ит! Ышаныч! Дөньяда ышаныч, өмет-хыялларның сау булуыннан да зуррак байлык бар микән? «Бәрәңгегә кайчак туймасак та, йолдыз иде уйда!», «Бары — алга! Бары — югарыга! Еллар аягүрә. Җилкәненә безнең хыялларның йолдыз җиле өрә». Ә ышаныч үзе каян килә соң? Күп нәрсәдән килә. Абстракт итеп әйткән-

дә, яшәештән, чынбарлыктан; конкретрак, бу очракта шагыйрь күңеле аша белдергәндә — туган җирнең иминлегеннән, тарихи зирәклеген җуймаган көчле ирләреннән, шатлык-кайгыларны уртак бүлешеп, гомер буе бергә атларлык сөйгән ярлардан. Туган җир, дөнья тоткасы ирләр, турылыклы ярлар... Мөгаен, Ә. Рәшитов язган шигырьләрнең күбесен шушы төшенчәләр тирәсенә туплап аңлатып булыр иде. Шуларның берсе — ирләр темасын алыйк. Ирләр — автор өчен беренчел мәгънәсеннән тыш, киңрәк аңлашылырга тиешле төшенчә. Алар — аның өчен, беренче чиратта, әңгәмәдәш (ул аларга биргән сорауны үзенә дә бирә ала, чөнки: «Безнең буын — бүген ир уртасы, акыл теше безгә чыкты күптән»), бүгенге һәм иртәгәге көн язмышы өчен борчылып сорау бирә алырлык кешеләр, ышанычыңның, эшеңнең ныклыгын алар аша белеп була. Чын ирләрсез яшәешне күз алдына китерүе кыен. Гомумән, бу тема аның беренче шигырьләреннән, бигрәк тә поэмаларыннан (мәсәлән, «Минем шәҗәрәм», «Варислар» поэмаларыннан) башлап «Киек Каз Юлы» китабына кергән һәм әле аңа керергә өлгерә алмаган соңгы шигырьләренә кадәр дәвам итеп килә. Бу мотив шагыйрьнең «Тормыш әлифбасы» әсәрендә, минемчә, аеруча калку чагыла. «Баһадирлар — ирләр токымыннан, пәйгамбәрләр — ирләр җенесеннән», «Безнең антлар йөрәк түрләрендә, безнең уйлар постта көнтөн уяу. Ахыргача тора алырбызмы? Куя тормыш сорау арты сорау». Ә бүгенге тормышның сораулары күп. Аларны шагыйрь кешеләр алдына, безгә, шул исәптән үзенә дә куя. «Һәрчак көчлеме без? Юмартмы без назга-иркәләргә? Авыр йөкне иңнән алып ташлап, салмыйбызмы нәфис җилкәләргә? Һәрдаим без батыр, намуслымы?», «Без һәрвакыт гомер юлларында ирләр булып кала алабызмы?» Мондый мисалларны шагыйрь иҗатыннан күпләп китерергә мөмкин. Ир булуның дәрәҗәле атрибутлары күп: илеңнең иминлеген тәэмин итә аласыңмы? Сөйгәнең сиңа «мәхәббәт сакчысы» дип горурланып әйтә аламы? Балаң өчен син чын этиме? Соңгысы шагыйрьнең күләмле һәр әсәренә диярлек үзеннән-үзе бәреп керә. Менә балалар йортында тәрбияләнүче Данияр. Бер караганда, аның тормышы җитеш, ләкин... «Даниярга ике җәпле үткен пәке кирәк... Кесә кирәк... Таш тутырыр өчен... Иң мөһиме ләкин — эти кирәк. Аның хәтта почык борынынннан үбеп ала торган эти кирәк, арт ягына авырттырмый гына сугып ала торган эти кирәк!»

Туган нигез, туган авыл, туган республика, туган ил турында шигырьләр шагыйрьнең һәр китабында зур урын алып тора. Бүтәнчә булуы да мөмкин түгел. Киләчәккә, кешеләргә булган олы ышанычның, ватандарлыкның чыганагы, тамырлары бит шушы җир туфрагында. Ә. Рәшитов иҗатында туган ил мотивы кайбер яшьрәк шагыйрьләребезнекенә караганда киңрәк. Туган ил төшенчәсе аның өчен туган авыл, иген кырлары, чишмәләре белән генә чикләнми, аның өчен ул — зуррак, географик яктан масштаблырак. Туган ил ул — Пискарев каберлегендәге миләүшәләр дә, Тянь-Шань итәгенә җәелгән томаннар да, Семей комлыкларындагы рәшәләр дә, Агыйделнең ак ярына баскан Салават та, Болгар хәрабәләре янында яңгыраган кыз җыры да, Яңа Афон мәгарәсендәге тамчылар да, Чуфут-Каленың кабер ташлары өстендә сырт җылытып ятучы кәлтәләр дә... Туган ил тарихын юньләп белми торып, аның киләчәге турында аек фикер йөртү кыен. Шагыйрьнең бу юнәлештәге шигырьләренә тарихилык хас. Авторның тарихны шактый ук яхшы белүен дә искәртеп узасы килә. Ә белгән, гыйлеме булган кеше, гадәттә, уйламыйча сөйләми, җавапсыз сүз әйтми.

Һәрбер шагыйрьгә хас булган шикелле, Ә. Рәшитовта да мәхәббәт шигырьләре байтак. Мәхәббәт шигырьләре беркайчан да начар була алмыйлар, дөресрәге, начар булырга тиеш түгелләр. Күрәсең, эш — ихласлылыкта, шатлыкларның яки сагышларның ни дәрәҗәдә тирән булуында, кичерешләрнең кешеләр күңелендәге тирбәнешләр белән никадәр аваздаш, иш булуында. Ә. Рәшитовның да халык күңелендә ныклап урын алган җырлары («Беренче мәхәббәт», «Зәңгәр күлмәк», «Тәрәзәләр язга елмая» һ.б.), гыйбрәт алып укырлык яхшы мәхәббәт шигырьләре бар. Алар аның бу соңгы китабында да шактый. Ихтимал, аларның кайберләре җыр булып халыкка таралып та китәр әле.

Поэмалар авторы буларак бик әллә ни телгә кермәсә дә, ул — алты поэма язган кеше. Поэма дигән терминны бу очракта мин шартлы рәвештә алам. Классик мәгънәдәге поэмалармы алар, әллә озын балладамы, әллә публицистик монологмы, кистереп әйтмим, һәрхәлдә, безнең көндәлек тәнкыйтьтә андый характердагы озын тезмә язмаларны поэма дип йөртәләр. Алар арасында күңелемә хуш килгәннәре — «Минем шәҗәрәм», «Варислар», «Тормыш әлифбасы». Соңгысы — «Киек Каз Юлы» китабына кертелгән. Ә менә «Варислар» дигәне — безнең поэзиядә КамАЗ төзелеше җирлегендә язылган беренче поэмаларның берсе иде. Моннан ун ел чамасы элек иҗат ителгән бу әсәр нишләптер үз вакытында (һәм әле хәзер дә) игътибардан төшеп калды. КамАЗ турында язылган әсәрләр рәтендә уңай яктан саналырга лаек әсәр ул. Инде поэмалар хакында сүз башлагач, авторның үзенә җиткерәсе фикерләр дә бар. Минемчә, аңа бу жанрның үзенчәлекләрен һәм нечкәлекләрен бик җентекләп өйрәнергә кирәк. Аның поэмага тотынуы очраклы түгел. Авторның кешеләргә әйтергә теләгән кайнар сүзе бар. Ләкин теләк әле бер хәл, мөмкинлек икенче нәрсә, формаль озынлык бер хәл, гасырлар буе төйнәлеп килгән табигый кануннар таләбе икенче нәрсә.

Әхмәт Рәшитовның иҗаты белән җентекләбрәк танышып чыккач, тагын бер нәрсә хакында әйтеп узасы килә. Авторның кайбер шигырьләрендә, бигрәк тә озынрак шигырьләрендә, акланып бетмәгән риторика, декларативлык сизелгәләп куя. Кайбер поэмаларның пафослары, фикер рәвешләре

һәм язу алымнары белән, мөгаен, бүтәнчәрәк булырга тиешләрдер. Без Әхмәт Рәшитовны ышануын югалтмаган, үз кануннарына тугрылыклы шагыйрь, дидек. Бу чыннан да шулай. Әмма аның кайбер шигырьләре ышандырып ук бетми. Әмма... Әхмәт Рәшитов, башта әйтеп узганымча, дөньяга аңлы карашлары илленче елларда формалаша башлаган буын вәкиле. Үзләре ипигә туймаса да, күзләре сафрак, инанулары ныграк булган буын вәкиле, һәм беркадәр максимализм да юк түгел бу буында. Шулай ук беркадәр беркатлылык һәм наивлыкны да сызып ташлап булмый. Бәлки, кайбер риторик өндәмәләр, үзләре артыннан ияртер дәлиле булмаган лозунгка охшаш сүзләрне күбрәк куллану шушы буынның сыйфатыдыр? Икенче яктан караганда, кеше инануына ничек итеп күләгәле сүз әйтмәк кирәк?

Әхмәт Рәшитовның китабы — аның иҗат юлында яңа бер баскыч. Элегрәкләре белән чагыштырганда, «Киек Каз Юлы» — салмаграк, гамьлерәк, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан камилрәк. Шигырьләрдәге уй-хисләр — ир уртасы кешегә лаек уй-хисләр, дөньяга хуҗа һәм җаваплы зат булып карый торган кеше фикерләре. Әдәбият, зур әдәбият кемнәрнедер калкытыбрак, кемнәрнедер төшеребрәк куюга мохтаҗ түгел. Ахыр чиктә вакыт галиҗәнаплары һәрнәрсәне үз урынына куя бит.

*1983, июль*

## ХӘТЕР

Шагыйрьнең соңгы шигырьләрен укыйм. Соңгы шигырьләр... Шәрә калган агачның актыккы яфраклары өзелгәнен күзәткәндә була торган халәт күңелдә. Бер-ике юл шигырь укыйсың да тукталып каласың, җанны сагыш кыса, хатирәләр яңара, Зиннур үзе дә җанланып әйтеп тора сыман: «Әйе, шулай, ашыкма, әкрен генә укы, шигырьләрем, гомерем еллары кебек, ул хәтле күп түгел...»

Бу китап, шагыйрьнең 50 еллыгы уңае белән чыгып, авторның үзен, дусларын, меңләгән поэзия сөючеләрне куандырырга тиеш басма иде. Әмма аңа, кулъязманы ахыргача эшләп бетереп, китап чыгу шатлыгын тоярга насыйп булмады. Ул, шигъри тәлгәшләрен безнең хөкемгә — халык хөкеменә калдырып, вакытсыз арабыздан китеп барды...

Зиннур Насыйбуллин — ашыкмыйча, салмак кына иҗат итүче шагыйрьләребезнең берсе иде. Бусын да исәпләп, нибары ике китабы чыкты. Җыенысы 6—7 табак шигырь. Әлбәттә, күп түгел, күбрәк һәм яхшырак булса, тагын да күңеллерәк булыр иде. Әмма иҗат — хуҗалык өлкәсендәге шикелле, йөкләмәләр алып, планнар арттырып үти торган эш түгел. Күңелгә әмер биреп булмый. Тумый икән — кирәкми, начарның булмавы яхшы. Зиннур Насыйбуллин бу хакыйкатьне яхшы аңлап яшәде һәм иҗат итте булса кирәк. Шунысы бәхәссез: чагыштырмача аз язса да, бар булган иҗаты белән каләмдәшләре һәм әдәби җәмәгатьчелек аны талантлы шагыйрь итеп таныды, ихтирам итте.

Татар поэзиясенең Ватаны булган Казанга ул моннан егерме еллар элек килгән иде. Сибелми-чәчелмичә генә ике дистә елга якын Татарстан радиосында хезмәт итте. Шунда эшләгән дәвердә СССР Язучылар союзы әгъзасы булды. Эфирда яңгыраган бик күп әдәби һәм музыкаль тапшырулар аның ярдәме белән тыңлаучылар күңеленә барып ирешә. Көн саен язучылар, композиторлар, галимнәр, журналистлар белән аралашып яшәү аның үз иҗатына да шифалы йогынты ясады. Ул, композиторлар белән берлектә, матур-матур гына җырлар иҗат итте. «Кара шәле килә сөйрәлеп», «Көтә күңел» — әнә шундыйлардан.

Чиктән чиккә ташлана, күтәрелеп бәреләә, чәбәләнә, кеше күзенә керә торган зат түгел иде Зиннур. Сабырлык, үзенә генә хас олпатлык, күзгә бәрелеп тормаган эчке бер горурлык хас иде аңа. Йөрер җиреңне, җегәр чигеңне белеп яшәү, очар биеклекләреңне бутамау — аз нәрсә түгел дөньяда! Ерак экзотик илләр турында хыялланмыйча, елга бер тапкыр, ял вакытында, Башкортстанга олы яшьтәге әти-әнисе янына утын-печән әзерләргә кайтыр иде, ә радио эшендә исә, булмастай дан артыннан кумыйча гына, үзенең гадәти, әмма бүтәннәр өчен бик кирәк эшен башкарып утырыр иде... Әйе, болары шулай. Ә шагыйрьлек? Сабырлык, басынкылык, тыйнаклык белән генә шигырь туамы соң? Күрәсең, тыштан шулай тыныч күренгән кешенең күңелендә әллә нинди шашкын хисләр, яшенле уйлар уйнагандыр.

* * *

Шундый чаклар була: дөнья — кайгы,
Күз яшьләрең кайный, син — утта...

* * *

Дөньяга без, ялкын ярып,
Мең үлемгә тудык үч белән!..

* * *

Шуңа безнең нерв җепләренә
Тоташтырган Заман Җир шарын...

Йомыкый күңелдә мондый гамьле һәм ярсулы юллар туа алмастыр. Хәер, сабыйлык һәм яшьлек чакларын сугыш уты өтеп тә, югалып калмыйча, тормышның олы мәйданына юл ярган, авырлыкларны җиңә-җиңә югары белем алган, ил чикләрендә солдат хезмәтләре үткән ир-егетнең күңеле ничек йомыкый булсын икән! Дөрес:

Күкрәк киереп, санны туры тоту
туры килә кайчак авырга...

Шагыйрьнең бу китабында гражданлык рухы белән сугарылган шигырьләр дә, лирик шигырьләр дә, робагыйларны хәтерләткән ике яки дүртьюллыклар да, сурәтле-картиналы парчалар да бар. Алар традицион алымда ныклы профессиональ кул белән язылган. Сөю-мәхәббәт, кавышу-аерылышу шигырьләрен, кыска фәлсәфи шигырьләрен тәкъдир иткән һәм хуплаган хәлдә, миңа аның Туган ил һәм халык тарихы, Туган тел турындагылары күбрәк ошый төшә. Аларда ныклы иманны, җитлеккән ир сүзен күбрәк сизеп була. «Хәрабәләр арасында», «Тарих — чорлар чылбыры», «Туган тел», «Туган тел ул», «Хәттатлар», «Киселгән карама», «Без җаваплы» кебек шигырьләр әнә шул әйтелгән фикерне раслыйлар.

Шагыйрьнең соңгы әсәрләре арасында Тукайга багышланган озын шигырь дә бар. Бәлки, ул берәр булачак поэманың бер өлешедер. Гыйбрәтле: шагыйрь, үләр алдыннан, гомер юлы кометадай янып үткән бөек Тукайга мөрәҗәгать итә, әйтерсең үзенең шигъри утын бөек ялкын яктысына карап үлчи, нәтиҗәләр ясый. Күрәсең, авыру халәт, соңгы чик, тормыш ваклыкларын, мәшәкатьләрен оныттырып, Мәңгелеккә һәм Үлемсезлеккә омтылдыра.

Күзе генә калган, күзләре — ут.
Бөтен тәне үтә күренә.

Ул Тукай турында шулай яза. Асылда, бу юлларны язганда, ул үзе дә нәкъ шундый хәлдә иде инде...

...Шәһәр читендә кышкы эңгер үзенә бертөрле. Күзгә күренеп ак кар зәңгәрләнә, күк белән офык тоташа, бөтен дөнья бер серле төскә керә, ул төс — әле шәмәхәләнеп, әле күкселләнеп — әкертен генә караңгылыкта эри. Шагыйрьнең күзләре Такташныкы кебек зәп-зәңгәр иде. Соңгы көннәрендә аның күзе офыклар күренеп торган балкон ягы тәрәзендә булды. Кичке зәңгәр эңгергә аның күзләре төсе дә кушылгандыр.

Ана күңеле дә ирешмәслек
еракларга китеп барышым...

...Кеше китә — җыры кала. Ә җыр инде ул — яхшы хәтер. Гамьле шагыйрьнең хәтер дәфтәре бу китап.

*1986, 5 март*

## ҖИҢӘРГӘ ЯРАТЫЛГАН

1963 елны Татарстан китап нәшрияты дәфтәр калынлыгындагы гына бер китапчык чыгарган иде. 36 битлек бу җыентыкка (титул битендә «балаларга шигырьләр язучы яшь көчләр җыентыгы» дип куелган) унике авторның, ягъни унике яшь көчнең шигырьләре (үзенә күрә иҗат үрнәкләре!) тупланган. Һәр авторга уртача өчәр бит туры килә. Кемнәр соң бу яшь шагыйрьләр? Фәнис Яруллин, Равил Фәйзуллин (китаптагы тәртип буенча саныйм), Хәкимҗан Халиков, Рөстәм Мингалимов, Харис Әшрәфҗанов, Илсөяр Җәләлетдинова, Җәүдәт Тәрҗеманов (Дәрзаманов), Мөдәррис Әгъләмов, Зәки Хәнәфиев, Айдар Сәләхов, Рәдиф Тимершин, Фаяз Әгъзамов... Хәзер — бу басманың чыгуына кырык еллап гомер узгач — уйлап куясың: җыентыкны төзүче Җәвад Тәрҗеманов һәм Кыям Миңлебаев дигән агайлар шактый нәрсәне алдан тоеп, булырдайны алдан күреп, ышанып, талантлы яшьләрнең байтагына фатиха биреп, үз вакытында бик тә изге гамәл кылганнар икән! Исемлектәгеләрнең күбесе бүгенге әдәбиятыбызны хәрәкәткә китерүче төп көчләр булып үсеп җиткәннәр бит! «Җырчы чишмә» — безнең өчен бик кадерле җыентык: исемең, күмәк йолдызлыкта булса да, беренче мәртәбә китап хәтле китапта дөнья күрсен әле!

Бу китапта Фәнис Яруллин шигырьләре беренче булып бара. Күләме дә бүтәннәрнекеннән күбрәк. Гомумән, ул елларда Ф.Яруллин исеме бик популяр иде. Әдәби мохиттә бигрәк тә. Нинди ихтыяр көченә ия кеше! Татарның Николай Островские! Армиядән каты имгәнеп кайтса да, тормышта үз урынын, үз бәхетен тапкан! — университетта укый (дөресрәге, укытучылар килеп

укыта), өйләнеп гаилә корган, менә дигән шигырьләр яза... Мәктәпләр, аерым оешмалар шефлык итте аңа, фатирыннан төркем-төркем укучы балалар өзелмәде... Ни гаҗәп: бер елларда яза башласак та, милләт, әдәбият мәсьәләләрендә, күп очракта фикердәш, мәсләктәш булсак та, миңа Фәнис Яруллин белән тормышта аралашып, әңгәмәдәш, табындаш булып утырырга туры килмәде диярлек. Бәлки, яшәеш-хәятның бу ягы бик мөһим дә түгелдер, безнең эштә иң кирәге — хезмәт берлеге, максат берлеге.

Кайчакта шундый уй да килә: әгәр Фәнис Яруллин, фаҗигагә юлыкмаса, физик яктан типсә тимер өзәрлек ир-егет булып яшәсә, бу тормышта ул нинди юл белән китәр иде икән? Бүгенге татар әдәбиятының мәшһүр Фәнис Яруллины булыр идеме? Мәсьәләне болай куюның этик яктан хилафлыгы бар барын. Шулай да... Шәхсән, минем моңа ачык җавабым юк. Әмма бер нәрсә анык: арабызда булган Фәнис Яруллин чыннан да каһарман-батыр шәхес! Кешенең бөеклеген, аның чиксез мөмкинлекләре барлыгын тагын бер мәртәбә раслаган көчле зат! Сау-таза килеш төшенкелеккә, сәрхушлеккә, мескенлеккә бирелгән байтак бәндәләрне оялтырлык, тәүбәгә иңдерерлек үрнәк Кеше! Беренче басылып чыккан шигырьләр китабының исеме дә бик тә мәгънәле — «Мин тормышны яратам!». Ә адәм баласы, ирексездән дөньяга килгәч, ирекле булып яшәп китәргә тиеш! Әлбәттә, тормышны яратып, яраттырып...

Фәнис Яруллин — төрле жанрларда уңышлы иҗат итә торган нык каләмле, киң колачлы язучы. Шагыйрь, прозаик, драматург... Бөтен язганнарын җентекләп беләм дип әйтә алмыйм, әмма шигъри әсәрләрен эзлекле күзәтеп барам. Зур шагыйрь ул! Тормышчан шагыйрь, кешеләр өчен кирәк шагыйрь.

Шигырьләренең тәрбияви әһәмияте турында уйлаганда, әдәбият галиме, күп кенә дәреслекләр авторы Азат Әхмәдуллинның бер үзара сөйләшкәндә әйткән сүзләре искә төшә. «Теге яки бу темага үрнәк әсәрләрне Ф.Яруллиннан теләсә күпме табып була, ә менә кайбер шагыйрьләрнеке, хәтта бик үзенчәлекле талант булсалар да, һич кенә дә дәреслек таләпләренә туры килми». Агымдагы дәреслек-әсбапларга иллюстратив материал булып керү-кермәү — әдәби әсәрне бәяләүдә иң төп критерий түгелдер дә, бәлки. Шулай да күп нәрсәне аңлатучы күренеш. Дәреслекләрдә гадәттә классик әсәрләр басыла.

Фәнис Яруллин — бүген дә популяр, әдәбият сөючеләрнең яраткан язучысы. Алда әйткәнемчә, ул 60 нчы елларда бик билгеле иде. Әмма ул еллардагы популярлык белән кырык ел үткәч, гасыр ахырындагы популярлык, минемчә, икесе ике нәрсә. Баштагы елларда халык аны беренче чиратта тән газапларын җиңүче көчле рухлы зат, егетләр егете дип үз итсә, соңгы елларда, бернинди ташлама ясамыйча, зур язучы-әдип итеп кабул итте. Әйтергә генә ансат: ул — утыздан артык китап чыгарган кеше. Соңгы елларда «Татнефть» АҖ ярдәме белән дөнья күргән өчтомлыгы бүгенге әдәби процесста үзе бер зур вакыйга...

Еллар үтте, буыннар алышынды, укучылар үзгәрде, бүгенге кайбер яшьләр язучының тәрҗемәи хәлен, үткәнен белмәве дә бар. Иң мөһиме — аның әсәрләрен укыйлар, шигырьләрен ятлыйлар, пьесаларын спектакль итеп куялар... Язучы буларак бу җиңү инде! Фәнис Яруллинның икенче җиңүе — төп җиңүе.

Менә безнең әлегә рәсми тәкъдирләнмәгән халык шагыйре, халык язучыбыз бар!

*1999, октябрь*

## БАР ШУНДЫЙ БЕР БАТУЛЛА...

Моннан ике айлар элек Академия театрының иске бинасында яңа спектакль күрсәтелде. Татар дәүләт драма һәм комедия театрының чираттагы премьерасы. Чираттагы булса да, бик үк гадәти дә түгел иде ул; чөнки спектакль бөек Тукай турында (шагыйрь турында уңышлы зур әсәрләр әлегә аз), икенчедән, әсәрнең авторы да, режиссеры да бер үк кеше — театрның баш режиссеры, күренекле язучы Батулла. Шуңа күрә дә, табигый, кызыксыну көчле иде.

Пьеса әллә ни мавыктыргыч сюжет-вакыйгага корылмаган. Бөтен бер спектакль бер урында — Тукай бүлмәсендә («Болгар» номерларының берсендә) бара, катнашучыларның да тормыш тәҗрибәләре бер чамадарак, һәммәсе дә диярлек 20—30 яшьлек кешеләр, замандашлар. Алар алай шаккатырлык тамаша да кылмыйлар, экстремаль ситуацияләр дә кичермиләр, бер үк мезансценада дигәндәй, шул бер бүлмәгә керәләр, сөйләшәләр, чыгалар, янәдән керәләр... Тамаша вакыт ягыннан да чикле — Тукай гомеренең берничә көне. Шулай да тәнәфессез сәгать ярымга сузылган спектакльне тамашачы шылт та итми, дикъкать белән карый, күңеле белән сәхнә геройларының язмышын кичерә.

Тамашачыны шундый әсирләнгән халәттә нәрсә тота соң? Вакыйгалар өермәсеме? Юк шикелле. Дөрес, вакыйгасыз спектакль булмас, алар Батулла әсәрендә дә бар. Әмма бу очракта хикмәт — фикердә, фикер динамикасында, фикер сюжетында. Бөтен спектакль буенча лейтмотив булып бара торган төп фикер — халыкның киләчәге нинди булыр? Мондый фикер, аңы ни югарылыкта булуы-

на карамастан (әгәр инде ул бөтенләй үк маңкорт булмаса), һәркемне теге яки бу дәрәҗәдә борчый, уйландыра. Спектакль персонажларының бөтенесенең диярлек сүз сөреше, асылда, шул хакта. Хәтта тискәрерәк дигәннәре дә халык киләчәге турында үзенчә фараз итә, үзенчә юрый. Тукай, Ядкәр (Х.Ямашевны хәтерләтә), Анабәк (Ф.Әмирхан күз алдына килә) халык язмышы мөнәсәбәтенә бер платформада булсалар, шул ук мәсьәләгә Байның үзгә карашы, Ханымның аңлавы бүтәнчәрәк... Әмма берсе дә битараф түгел, һәрберсенең үз карашын акларлык дәлилләре дә бар. Менә шушы бер мәсьәләгә — халык язмышы проблемасына төрле карашларның бәрелешүе, көрәше — спектакльне спектакль итә, тамашачыны киеренке хәлдә тота да. Ирексездән сорау туа: төп каһарман Тукай образы ничек бирелгән соң? Җавабы үзе бер катлаулы сорау. Чөнки Тукайның шәхесе, кыска гомере һәр җәһәттән шактый җентекле өйрәнелгән, һәрберсенең күңелендә аның үзебез белгән, үзебез аңлаган образы бар (Ә. Фәйзинең «Тукай» драмасы һәм шул ук исемдәге романы, И. Нуруллинның шагыйрь турындагы җитди хезмәте, Т. Миңнуллин, Р. Ишморат, И. Юзеев пьесалары аша бөек шагыйрьнең без шактый ук җанлы образын чамалый алабыз инде). Миңа калса, «Сират күпере» драмасында драматург һәм уйнаучы артист шагыйрь гомеренең соңгы көннәрен ышандырырлык, табигый итеп күрсәтергә ирешкәннәр. Гасабилана шагыйрь, гомер чигенең котылгысыз якынлашуын сизә, яшәештә кылган гамәлен барлап, йомгак ясамакчы, яшәвенең мәгънәсен аңламакчы була, идеалларының һәм мәхәббәтенең челпәрәмә килүен тоеп тетрәнә, шул тетрәнүләрен кешеләрдән яшермәкче дә була. Дөнья бәясе торырлык шәхеснең гомер шәме сүнеп килә... Яшь артист Рафил Сәгъдуллин (бу аның баштанаяк сәхнәдән чыкмый уйнала торган беренче зур роле) үз ролен уңышлы башкарып чыкты дияр идем. Рафилнең Тукайга тышкы охшашлыгы, ихласлыгы, тырышлыгы үз эшен эшләде, сәхнәдәге Тукайга без ышандык. Әҗәл угы төбәлгән чакта да Тукайның көрәшче рухы җиңелергә теләми. Тукай — үз чорының Бөтенроссия масштабында иң зур шагыйрьләрнең берсе. Моны сәхнәдә ныграк тоясы килә. Яшь артистның мондый зур рольне камил итеп башкарып чыгарга тормыш тәҗрибәсе, эрудициясе дә җитеп бетмидер. Бәлки, драматургның үзенә дә шагыйрь образын тагын да баетыр өчен кайбер кирәкле штрихлар өстәргә дә мөмкиндер.

Спектакльдәге Тукай образының уңышын тәкъдир иткән хәлдә, спектакльдәге иң отышлы һәм хәтердә кала торган образны мин Шәүлә дип санар идем. Провокаторлык, шымчылык, хыянәтнең гомумсимволын белдергән җыйнама образ ул Шәүлә. Дистә еллар буе сәхнә түреннән муллалар һәм комганнар белән шактый җитди көрәшсәк тә, Шәүлә кебек куркыныч көчне бөтен тулылыгы белән күрә алган юк иде әле сәхнәдән. Шәүлә — чыннан да, мәкернең мәкере, дошманның дошманы! Тарихи яссылыктан караганда, Шәүлә һәрвакыт безнең яшәешебездә булды, төрле битлекләргә кереп, халыкның фидакарь уллары белән янәшәдә яшәде, җаен туры китереп, аларны чагып торды. Халыкның бөек уллары галереясын күздән кичерик. Шул ук Тукай, Ямашев, Кариев, Ибраһимов, соңрак Тинчурин, Туфан... Безнең мәдәният тарихын Шәүләләрсез күз алдына китереп булмый. Тормышчан тип, безнең сәхнәләр өчен яңа тип. Ихтимал, Шәүлә монологларында бәхәсле моментлар да булырга мөмкин. Ни генә булмасын, Шәүлә спектакльдә иң көчле образ булып чыккан. Артист та оста башкарды аны. Марсель Җаббаров бу рольдә үзенең талантлы, җитди артист икәнлеген тагын бер кат раслады. Без караган спектакльдә катнашкан байтак артистларның яхшы уеннары турында әйтергә мөмкин. Исламия Мәхмүтова, Фатин Фәтхуллин, Тимер Зиннуров... Спектакльне тәфсилләп анализлаган, артистларның уеннарына, рәссам Әхәт Закировның эшенә чын бәя бирә алырлык белгечләрнең абруйлы рецензияләрен алга таба, шәт, укырбыз әле. Спектакль турында фикеремне пьесаның бер каһарманы сүзләре белән, дөресрәге, гарәпләрнең «тәсмәгы бин Мәгайди хәйрен мин ән тәраһе» дигәннең киресен белдергән «Мәгайдыйне күреп белүгә караганда ишетеп белүең яхшырак» дигән сүзләр белән тәмамлап, бу спектакльне үзегезгә барып карау кирәк дип әйтәм.

«Сират күпере» — Р. Батулланың соңгы, дөресрәге, чираттагы соңгы әсәре, театр сәнгате өлкәсендәге билгеле бер уңышы, исемен драматургиядә тагын да ныгыткан җитди хезмәте. Бу көннәрдә Батулланың иҗат эшчәнлегенә 25 ел тула. Әдәбият һәм сәнгатькә сарыф ителгән чирек гасыр гомер! Шушы уңай белән әйтелгәннәргә өстәп, замандашым турында, шәхесе һәм иҗаты турында янәдән бер-ике сүз әйтергә телим.

Галиҗәнап Табигать Батуллага күпне биргән. Буй-сынны да, саулыкны да, сәләтне дә. Теләсә, сыздырып гармун уйнап җибәрер яки курай тартыр, теләсә, җыр сузар яки эч катырлык көлке мәзәкләр сөйләр, теләсә, пьеса язып «тиятр» куяр, кирәк дисә, әкият чыгарыр яки хикәя-повестьлар язып, хаҗәтен күрсә, мөгаллим булып студентлар укытыр... Бүтәнчәрәк, рәсмирәк әйткәндә, ул — язучы, драматург, режиссер, артист, педагог... Шулай күптөрле эшләрне, һөнәрләрне җиренә җиткереп, заманына лаек итеп башкарып чыгып була микән соң, диярләр. Әнә бит, янәсе, каз да — йөзә дә, оча да, җирдә дә йөри... Әйе, Батулла төрле якка сибелеп, төрле-төрле жанрларда эшләп «чәчелә» диючеләр дә бар. Моңа каршы килеп, күпкырлы талантка ия шәхесләр булмыймыни? дияр идем. Тарихта бар бит андыйлар да. Батулла — әнә шундый бәхетле өлешкә ия кеше, вакытның кадерен, хезмәтнең тәмен белеп эшли белүче булдыклы кеше, егет кеше. Кайсы өлкәдә рейтингы өстен икәнен Вакыт Галиҗәнаплары әйтер.

Батулла иң әүвәл үзен хикәяче итеп танытты. Аның беренче дөнья күргән китаплары да — проза әсәрләре. Хикәя өлкәсендә ул үзен шактый оста язучы икәнлеген исбат итте. Ләкин ни өчендер аның кыска, әмма тирән мәгънәле хикәяләре тәнкыйть игътибарыннан читтә кала килде. Батулланың бөтен хикәяләре дә диярлек кинаяле, аларның һәрберсендә дә тел төбенә яшеренгән бер сер ята. Әнә шуны ача алсаң гына, хикәяләрнең төп мәгънәсенә төшенә аласың. Мисал өчен «Мираж» дигән хикәясен генә алыйк. Бер карасаң, бензиннары бетеп, чүл уртасында калган ике шоферның адашып йөрүләре генә сурәтләнә кебек. Ачыккан, хәлсезләнгән бу ике кешенең уйлары бер: бу чүл тозагыннан, үлемнән ничек тә котылу. Ә менә ничек? Берсе, бер юлдан китик, ди, икенчесе, миражга, офыкта күренгән матур «шәһәргә» таба барыйк, ди; анда бәхет, рәхәтлек, җиләк-җимеш, салкын су булыр, ди. Берсе шул миражга ышана, алдана, ә икенчесе алдагы матур шәһәрнең ялган икәнен белә, белгән килеш матур ялганга таба барырга мәҗбүр була... Яки аның «Соңгы чабыш» исемле кыска гына хикәясен хәтерлик. Әти-әнисен, авылдашларын сагынып кайткан Җәгүрне (Егорны) туган авылын капылт ташлап китәргә нәрсә мәҗбүр итте соң әле? Әллә хикәя кайчандыр бәйгеләрдә баш бирмәгән, бүген инде йончу хәлгә калган карт алаша турындамы? Хикәяне өстән генә укыган кешегә шулай тоелырга да мөмкин. Әмма хикәянең төбенә төшеп уйласаң, әсәр халык язмышы турында бит.

Батулла берзаман әкиятләр язаргаябышты. Бу өлкәдә дә аның байтак уңышлары бар. «Исемем минем Дүрткүз», «Куян баласы Нуяк», «Үлемсез егет», «Ташсуар патша» әкият-повестьларын яхшы дигән әсәрләр рәтенә керткән хәлдә, мин Батулланың иҗат югарылыгы, әдәбиятыбыз өчен үзенә бер ачыш булган «Алып батыр» маҗараларын аерып куяр идем. «Алып батыр» — әкият, олылар өчен дә, балалар өчен дә гыйбрәтле фәлсәфи әсәр. Һәр бүлек үзенә күрә бер проблема күтәрә. Бу әкиятләр төркеме «повесть» дип аталса да, роман хокукындагы күләмле проза. «Алып батыр» — татар халкының узганы, бүгенгесе, киләчәге турында уйлану ул. Бу әсәрне тел ягыннан да, этнография һәм тарихи яктан да, күтәрелгән актуаль фәлсәфәсе ягыннан да өйрәнерләр әле дип уйлыйм.

Соңгы 20—25 елдагы әдәби-мәдәни процессны Батулласыз күз алдына китерү кыен. Һәрхәлдә, безнең буын өчен бу шулай. Батулла әдәбият-сәнгать мохитенә 60 нчы еллар башында килеп керде. Ул елларда әдәбиятка килгән шагыйрьләр турында инде күп сөйләнде. Ә бит ул еллардагы күтәрелеш бер шагыйрьләр иҗатында гына чагылып калмады. Сәнгатьнең бүтән өлкәләрендә дә көчле дулкыннар туды. Алыйк Мәскәүнең Щепкин исемендәге театр училищесын тәмамлап кайткан яшьләрне. Яңа бер сәхифә ачтылар алар театрыбыз үсешендә. Исемнәрен генә атап үтү дә күп нәрсә сөйли. Ринат Таҗетдинов, Равил Шәрәфиев, Гөлсем Исәнгулова, Нәҗибә Ихсанова, Фирдәвес Әхтәмова, Әзһәр Шакиров, Наил Дунаев... Теге яки бу сәбәпле театрда артист булып төпләнмәгәннәре дә, икенче җирлектә, икенче яклап бәреп чыкты. Шул когортадан Туфан Миңнуллин халык горурланырлык драматург булып үсеп җитте. Миргалим Харисов үз юлын журналистикада, әдәбиятта — тәрҗемә эшендә тапты. Батулла да әнә шул көчле төркемнән бит. Сәхнә тутырып уйнаучы артист булып китмәсә дә, барыбер театрдан, тамашачылыктан аерыла алмады Батулла. Миңа калса, ул нәрсә генә иҗат итсә дә, язганын йөзәрләгән, меңәрләгән тамашачы күзе белән карый, меңәрләгән тамашачы күңеле аша үткәрә кебек. Камерный түгел аның сәнгате. Аңа мәйдан кирәк, халык кирәк. Бу сыйфат аңа эчтә яткан асылы — артистлыгыннан килә булса кирәк. Әкият язса, әйдә — телевизорга, мәзәк-миниатюра булса — эстрадага, озын пьеса икән — олы сәхнәгә... Шуңа күрә дә аның драматурглык ягы соңгы елларда аеруча үсте. Иҗади бәйрәмен дә ул сәхнә әсәрләре тупланган егерме биш табаклы калын китабы белән каршылады. Бу китапка аның халык арасында киң мәгълүм «Кичер мине, әнкәй», «Өчәү чыктык юлга», «Туйлар узгач» кебек әсәрләре тупланган. «Кичер мине, әнкәй» спектакленең язмышы аеруча бәхетле булды. Ул инде әллә ничә еллар буе ил театрларында куелып килә. Академия театры кебек олы сәхнәдә генә дә ул 500 тапкыр куелды инде. Җитди пьеса өчен үзенә күрә бер рекорд!

Әйе, исәпләсәң, кылган эшләре аз түгел икән Батулланың. Унбишләп китап чыгарган, егермедән артык пьеса язган, телевизордан дистәгә якын ел эчендә йөзәрләгән әкиятләр сөйләгән, режиссер сыйфатында дистәләгән әсәр сәхнәләштергән... Шуларга өстәп үз инициативасы белән җәмәгатьчелек тәртибендә башкарылган эшләр — популяр ШТМның (шаяннар, тапкырлар мәҗлесе) хуҗасы-тамадасы, онытылмас «Ядкәр» кичәләрен оештыручы һәм башлап йөрүче, байтак каләмдәшләренең иҗат кичәләрен алып баручы... Җәмәгать эше өчен яну көчле Батуллада. Кушып, өстән әйтеп кенә булмый; әйткәнне, кушканны, яхшы дигән очракта, үтәп теге яки бу дәрәҗәдә башкарып чыгып була. Батулла кушканны күндәм үтәп-башкарып утыручы түгел. Ул янып, бирелеп, фидакарьләрчә эшләргә яратылган кеше, бүтәннәрне үзе белән әйдәргә, аларның да йөрәкләрен үзенеке кебек яндырырга алынган кеше. Тынгысызлык, бирелгәнлек, иманлылык хас аңа. Батулла — безнең буынның бер бизәге, арабызда аның булуы үзе зур бер куаныч.

*1988, март*

## ТУКАЙЛАР, БАБИЧЛАР ЮЛЫННАН

Хатирәләргә бирелсәң, әллә нәрсәләр искә төшә. Башкортның Равил Бикбаев дигән азамат шагыйрен кайчаннан беләм соң мин? 30 елдан артык икән. Хәтеремдә: 1968 елның 28 июле. Борынгы София шәһәре. Бөтендөнья яшьләренең IX фестивале ачылу көне. Халык мәш килә, ыгы-зыгы. Болгар иленә бөтендөнья кыйтгаларыннан бөтен яшь-җилкенчәк җыелган диярсең. Безне Авала тавы ягындагы бер мәктәп-интернатка урнаштырдылар. Фестивальнең тантаналы ачылышына әзерләнәбез.

Иркен юыну бүлмәсендә каратутлы, чибәр бер егет, сөртенгән сөлгесен иңенә салган килеш, миңа озак кына карап-карап торды да «Нихәл, адаш?» дип кочаклап алды. Менә шулай танышкан идем мин Равил белән. (Андый җирдә — агы, карасы, сарысы дигәндәй — әллә нинди ыру-расалар тугланган җирдә үз телендә сөйләшкән кешене очрату уен эш түгел ул!) Дөрес, аңарчы да ишетеп, газета-журналларда бер-беребезнең шигырьләрен, сурәтләрен күргән булган инде, әлбәттә. Ни дисәң дә, без бит инде ул заманда Идел-Урал шигъриятендә үзебезчә ат уйната башлаган егетләр... Без байтак җирләрдә йөрдек Болгариядә, күп кешеләр күрдек, болгар коньягын уртлый-уртлый, байтак серләр дә сөйләштек... Искә төшерү дә татлы...

Бу айда Равил Төхфәт улы Бикбаевка 60 яшь тула. Теге чакта аңа 30 булган икән. Тумышы белән Оренбург өлкәсенең Покров районы Кунакбай авылыннан. Заманында шул яклардан М.Бурангулов, С.Агиш, Г.Амантай кебек күренекле кешеләр чыккан. Гаярь кыяфәте, ныклыгы һәм тәвәккәллегенә карап, башкорт казаклары ыруыннан түгел микән ул дип тә уйлап куя идем. Равил Бикбаев — галим шагыйрь. Бездә шагыйрьлеге дә, галимлеге дә мондый югары кимәлгә тәңгәл килгән шәхес юк та бугай. Аның хәзерге башкорт поэзиясе буенча төпле хезмәтләре — башкорт әдәбият гыйлеменең казанышлары саналырга хаклы. Башкортостанның халык шагыйре, Салават Юлаев премиясе лауреаты, филология фәннәре докторы, Башкортостан Язучылар берлеге рәисе... Басылып чыккан китаплары да утызлап бардыр. Чөнки кырык еллап актив иҗат иткән Равил. Аның «Вокзал», «Кәрвансарай» кебек поэмалары 60 нчы еллар башында ук киң билгеле иде инде. Соңрак «Тамгалы ук», «Җыр», «Күк әрем», «Система», «Ностальгия», «Сусадым — сулар бирегез», «Халкыма хат» һ.б. Поэмаларны безнең Илдар Юзеев кебек күп язды ул. Гомумән, аның иҗаты сокландыра да, уйландыра да. Һәрхәлдә, тирән һәм аңлаешлы фәлсәфә белән сугарылган шигырьләре, поэмалары үзләренең камиллеге, вакыйгалар тыгызлыгы җәһәтеннән аерылып торалар. Укыйсың да бу Равил стиле, адаш әсәрләре дип горурланып куясың. Шагыйрьнең гомерлек темасы — үз халкының тарихын барлау, замандашларда — үткән белән бүгенгенең чагылышын ачыкларга омтылу. Аны Тукайлар, Бабичлар язмышы белән бергә бүгенге иҗатчыларның җәмгыятьтә кылган гамәлләре нык уйландыра, борчый. Шәехзадә Бабичка багышланган гыйльми хезмәтләре аерым бер казаныш саналырлык. Үткән ел аның Уфада «Шагыйрь сүзе — шагыйрь намусы» дигән күләмле китабы чыкты. Әдәбият үсеше турында уйланулар, төрле буын шагыйрь һәм язучыларның (китапта Г.Тукай, Х.Туфан турында да җитди мәкаләләр бар) иҗат портретлары һәм тәнкыйть мәкаләләре тупланган бу китапның исемен Равил Бикбаев дигән олуг шагыйрьнең иҗат кредосы дип уйлыйм мин.

Әйе, Равил туган, шактый гомер яшәгәнсең, күп эшләр башкаргансың икән. Софиядә очрашканнан соң, без кимендә елына бер тапкыр күрешә торганбыздыр. Очрашкан саен, теге яки бу формада туган тел, туган әдәбият, ахыр килеп, халыкларыбыз язмышы турында сүз булмый калмый. Идел-Урал язмышы, уртак халыкларыбыз язмышы... Син хәзер шушы уртак зур пространствода үз фикерен, үз тавышын ишеттерерлек гали шәхес (Башкортостан милләтләр ягыннан катлаулы республика, иминлек, татулык, рухи уртаклык дигәндә, синең сүзең олы сүз булып яңгырый дип уйлыйм мин).

Берничә ел элек Казанда да бер томлык китабың чыккан иде. Аның исеме — «Сак-Сок». «Башкорт белән татар — Сак-Сок кебек игезәкләр, алар мәңге бер-берсен эзләп, сагынып яшиләр...» дигәнсең ул китапта. Бик хак сүзләр. Сагыныша-сагыныша бергә яшәсеннәр, дип өстисе килә. Бу хис-тойгыны без тудырмаган, гомер бакый килгән туганлык ул. Юлайлар заманында да булган (бәлки, көчлерәк тә) ул, Тукайлар заманында да, безнең заманда да. Безгә бу изге эстафетаны балаларыбызга гына тапшырасы кала.

«Нихәл, адаш?», «Исеңдәме?» дип, XXI гасырның да фәлән дистә елларында уңышларыбыз өчен бергә-бергә сөенергә насыйп булсын!

*1998, октябрь*

## САЛМАК, ӘММА САЛЛЫ

Безнең каләмдәшләр арасында «авызы белән кош тота торган» шома телле җор кешеләр бар. Аларны тыңлагач, кемнәрдер: «Вәт бу язучыларның да язучысы, шагыйрьләрнең дә шагыйредер!»

— дип уйлап та куядыр. Әмма телдә тибрәнгән сүз белән кәгазьгә төшкән сүз арасында аерма бик зур була кайчак. Әлеге ут уйнатып сөйли торган иптәшнең язганнарын укып карыйсың да еш кына аптырабрак каласың: колакка тәэсир иткән аваз фейерверклары кая да күңелләрне кузгатырлык мәгънә, фикер кая?.. Шөкер, безнең бәхеттән, тормышта киресенчә дә булгалый. Кешеләр белән артык сүзгә керми торган, карап торышка да юаш, йомыкый гына күренгән берәр иптәшнең язганнарын укыйсың да тагын хәйран каласың: кара, сүзе белән таулар күчерә бит бу, ташны кысып суын чыгара, чүлләрне гөлбакча итә, тираннан мәҗнүн ясый...

Ямаш Игәнәй (Ананий Нестерович Малов) әнә шул — карап торышка тыныч, салмак, сабыр күренеп тә, күңелендә янартаулар, бәхет кыңгыравы чыңнары, әрнүле яралар йөртә ала торган замандашларыбызның һәм каләмдәшләребезнең берсе икән ләбаса! Кеше, шәхес буларак бөтен сыйфатлары һәм нечкәлекләре белән беләм дип әйтә алмыйм, шулай да аның белән егерме елга якын танышмын. 60 нчы еллар ахырында шигырьләрен күтәреп, Язучылар союзының Әлмәт бүлегенә килеп йөри иде ул. Уртага чыгып үзен күрсәтеп, акыллы фикерләр әйтергә тырышып, тавышын җыелышка яраштырып сөйләгәнен беркайчан да хәтерләмим. Юашлыктан килгәндерме ул нәрсә, тыйнаклыктанмы, әллә тәҗрибә җитмәгәнлектәнме, анысын да кистереп әйтә алмыйм. Әмма бүлеккә калдырып киткән шигырьләренең күбесе безгә, Әлмәт язучыларына ошый иде. Аларның кайберләре шул елларның көндәлек матбугатында басылып та чыкты. Аннан соң инде байтак гомер узды. Ямаш Игәнәйнең дә әкертенләп булса да кечерәк күләмдәге өч китабы чыкты. «Сәфәр чыгам» (1981), «Йолдыз булып ян» (1983, балалар өчен), «Хәзинәләр иле» (1984). Алар турында тәнкыйтьчеләр һәм шагыйрьләр нигездә уңай бәяләп язып чыктылар. Күркәм якларын күреп, сөенеп, хуплау сүзләре әйттеләр, җитешмәгән якларны да читләтеп үтмәделәр, дустанә теләкләр белдерделәр. Әйе, әнә шулай итеп Ямаш Игәнәй әдәби хәрәкәтебездә үз җаена катнашып килә бирә. Ә вакыт дигәннәре дә бер дә туктап тормый икән шул — елларны санаган-санаган да Ямаш Игәнәйне дә 50 яшь дигән бер чатка китереп җиткергән. Шагыйрь дә үткән Гомер Инеше аһәңенең кире кайтмаслыгын яхшы тоя булса кирәк, аңарда язганнарын тизрәк һәм күбрәк итеп чыгару теләге хәзер бермә-бер арткан...

«Игелекле төбәк» — авторның җыйнама характердагы чагыштырмача тулырак китабы. Элегрәк чыккан китапларына кергән шигырьләр дә бар монда, яңарак язылганнары да байтак. Һәрхәлдә, бу китап аша шагыйрь Ямаш Игәнәй иҗат портретының төп чалымнарын чамаларга була. Иң әүвәл күңелгә хуш килгән ягы — ул кыска һәм ачык итеп язарга омтыла. Фикерсез, су буе сүз уйнату, ахыр чиктә кешенең вакытын алу, минемчә, әдәбиятта үзенә күрә бер җинаять, сүзгә исрафчыллык — әдәби культура һәм укучыларны ихтирам итү билгесе. Кыскалык һәм ихласлык хакына кайчак авторның кайбер стиль кытыршылыкларын да кичерергә мөмкиндер хәтта (сүз юк — камиллеккә ни җитә!). Менә автор кульязмасыннан сайламый-нитми генә күзгә чалынган кайбер строфалар:

Ир бәхете белән ир язмышы —
Шыткан гөлләр бер үк тамырдан.

Яки:

Җирне гөл итәм, дигәннәр әйләнгән гөлгә.
Җирне көл итәм, дигәннәр әйләнгән көлгә...

Яки:

Әти яраланган дигән хәбәр килде...
Күктә канлы болыт ага шуннан бирле...

Шулай ук шагыйрьнең халыкчанлыгын, садәлеген һәм үзен табигать белән берлектә тоеп иҗат итүен дә ассызыклап үтәргә кирәк. «Мин язам тик җан авазын...» — ди ул үзенең бер шигырендә. Икенче бер шигырендә исә мондый юллар бар: «Табигатькә җан һәм тән белән кушылам. Гүя мин аның бер күзәнәге сыман». Әйе, шагыйрь Табигатьнең бер җырчы күзәнәге булырга тиеш.

Ямаш Игәнәй — патетик пафослы, эпик колачлы озын әсәрләр авторы түгел, ул беренче чиратта нечкә тоемлы, хисчән лирик шагыйрь. Яктылык һәм моң, уйчанлык һәм самимилек күп аның шигырьләрендә.

Кырказ тавышы камыш булып шыткан күлдә.
Сандугачның җыры чәчәк аткан гөлдә.
Каян килә тылсымлы бер аһәң дисәм —
Сөю булып сарылгансың йөрәгемә...

Ямаш Игәнәй — халкыбызның керәшеннәр дип йөртелә торган этник группасының бер вәкиле. Сөйләш, җыр-көй ягыннан булсын, тарихи катламнарның яңарышы ягыннан булсын, бу группаның бүгенге әдәбиятыбызга һәм сәнгатебезгә керткән өлеше зур. Поэзиябез тарихында да үткәненнән һәм бүгенгесеннән байтак абруйлы исемнәр санарга мөмкин. Ямаш Игәнәй дә шулар рәтендә. «Авыл ызбасында керәшен туе — чал тарихның нәни ярчыгы...»

Ямаш Игәнәй балалар өчен дә уңышлы гына иҗат итеп килә. Алга таба нәниләр кулында аның яңа китапларын күрербез әле дигән өметтә калабыз.

Һәм, ниһаять, фәлсәфи фикерләүгә сәләтле шагыйрьнең тоткан кыйбласы дөрес, кредосы кешелекле, теләге изге: ил-дөнья иминлеге өчен кайгыра ул, кешеләрнең сау-таза һәм бәхетле булуын тели, киләчәкне бүгенгедән яхшырак итәр өчен хәл кадәре көчен куя... Болары, әйе, шулай, әйбәт. Шулай да авторга активлыкны арттырырга киңәш итәсе килә. Кабаланырга түгел, кабатланырга түгел, үзең тапкан сукмагыңны киңәйтә төшәргә, аны ераграк офыкларга чыгарырга. Артыңнан кешеләр ияреп китәрлек булсын!.. «Ир-егетнең йөрәгендә иярләнгән ат ятыр», — ди бит халык. Ә аты булган җанга сукмак кына җитми, киңрәк юл да кирәк бит әле...

Сарман буйларында туып үскән, белгеч булып урман хуҗалыгында эшләгән, авыр солдат хезмәтен кичкән, республикабызның индустриаль төбәкләрендә журналист мәктәбен үткән, хәзер Чаллы якларында иҗат итүче каләмдәшебез Ямаш Игәнәйгә яңа үрләр-биеклекләр теләп, аның үзенә дә, безгә дә гыйбрәт булырлык бер кыска шигыре белән сүземне тәмамлыйсы килә.

Вакыт җиткәч, шиңәр барыбыз.
Гап-гади гөл генә бары без —
Гомерегез гүзәл чагында
Такыялар үреп калыгыз!

*1988*

## ЯКТАШЫМ УЛ МИНЕМ

Мансур Шиһапов — якташым ул минем. Хәер, кешеләрне олы мәгънәгә ия берәр максат, уртак эшчәнлек берләштермәсә, якташлыкның әллә ни әһәмияте юк. Безне берләштерә торган уртаклык— халкыбызга, туган ягыбызга ихлас хезмәт итү дип беләм. Без — гади халык арасыннан чыгып, иҗатка килгән кешеләр. Мантыйк буенча үзебезне үстергән шул халыкка хезмәт итәргә, алган хакны кайтарырга тиешбез дә.

Бер авылда туып, бер мәктәптә укымасак та, бер урамнарны таптап, кичләрен кыз-кыркын озатышып йөрмәсәк тә, Мансур замандашны кырык еллап беләм инде мин. Беренче очрашуларда ук, «киң күңелле, тапкыр, аралашучан, оештыру эшләрендә маһир, олпат кеше икән бу абзый» дигән фикер калган иде. Күп еллар үтеп, яши-яши, күңелдә кайбер төсмерләр үзгәрсә дә, фикер үзгәрмәде, хәзер дә аны шул сыйфатларга ия дип беләм.

Мансур Шиһапов гомер буе иҗат кешеләре күмәк булып оешкан коллективларда эшләде. Аның рухы һәм сәләте шулай кушадыр инде. Татар дәүләт драма һәм комедия, Курчак театрларының директоры, Г.Камал театрының баш администраторы, Язучылар берлегенең оештыру эшләре буенча рәис урынбасары, Зур концерт залының директоры... Моннан утыз еллар элек Язучылар берлеге каршындагы Матур әдәбиятны пропагандалау бюросы җитәкчесе булып та эшләп алды. Гел халык арасында, гел иҗат кешеләре белән бергә. Гадәттә, иҗат эше ялгызлыкны, тынычлыкны тансыклый. Күп әсәрләр Дөнья белән бергә-бер ялгыз калып илһамланганда туа. Әмма жанрларның да төрлесе бар бит; әйтик, җыр — демократик, халыкчан жанр. Өстәвенә шагыйрь, композитор, башкаручы бергәләп иҗат итә торган коллектив жанр. Мансур Әхмәт улы Шиһапов үз табигатенә туры килә торган сәнгатьнең нәкъ шул төрен сайлады да. Һәм дөрес эшләде. Сәхнә, җыр, моң, тамашачы алкышы — аның бәгърендә. Шуңа да ул халык арасында бик популяр булган дистәләгән бик матур җырларның авторы була алды. Ул җырлар турында заманында М. Мәһдиев, Г.Ахунов, Р.Батулла кебек мәртәбәле кешеләр язып чыкты инде. Кабатлап тормыйм, үзен татар дип санаган һәр кеше аларны белә булыр.

Мансур Шиһаповның Туган якка мөнәсәбәте, авылдашларына, якташларына мәрхәмәтле карашы сокландыра мине. Игелекле бала әти-әнисен кадерләгән кебек, чын кеше, туган ягын изге җир дип санап, аны зурларга, олыларга тиеш. Кайтырга вакытын да таба Мансур якташ кирәк чакта, сүз беләнме, эш беләнме, ярдәм итү җаен да таба. Әле быел яз башында гына талантлы балаларның сәләтен үстерү ниятеннән, район күләмендә үз җырларының фестивален уздырып, бер күркәм эш башкарды ул. Санап китсәң, андый гамәлләре байтак аның.

М. Шиһапов бүгенге көндә С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы директоры. Зал дип кенә әйтеп булмый аны, бу бина Россия күләмендә мәшһүр сәнгать сарае. Ул анда инде Залның яңартылып ачылган көненнән бирле эшли. Килгән чит ил кешеләренә, ил башлыкларына горурланып күрсәтә торган бинада эшләүнең үз кыенлыклары, хикмәтләре бар. Дөньякүләм атаклы җырчылар, музыкантлар, ансамбльләр чыгыш ясый анда. Шунысы куандыра: татар музыкасы, халык җырлары да еш яңгырый бу залда. Үзебезнең татар әдәбият-сәнгать вәкилләренең авторлык кичәләре, концертлары еш була. Якташларын җыеп зур сәнгать бәйрәмнәре дә ясый... Боларның күбесе Мансур Шиһаповның тырышлыгына, максатчан хезмәтенә бәйле. Кайчак уйлап куясың, әгәр бу урында бүтән берәр кеше, космополитик рухлы башка берәр иптәш утырса?..

Безнең Балык Бистәсе дип йөртелгән төбәк, шөкер, талантларга бай. Дистәләгән язучы-шагыйрь дисеңме, артист-җырчы дисеңме... Сүз уңаенда әйтеп узыйк: аның бертуган абыйсы Рәшит тә

(Рәшит Шиһап) талантлы шагыйрь, берничә китап авторы иде. Заманында безнең яктан чыккан популяр композитор Фәтхерахман Әхмәдиев бар иде. Мансур Шиһапов дигәндә, еш кына әнә шул композиторның исеме искә төшә. Белүемчә, алар яхшы ук таныш булганнар үз вакытында. Ф. Әхмәдиев туган ягыбызны зурлап бик матур җырлар калдырды. Дөрес, М. Шиһапов көй чыгаручы түгел, ул сүз белән җыр чыгаручы, менә дигән җыр текстлары язучы. Үткәннәрдән яхшы үрнәкләр бар безгә. Якташыма теләгем шул: яңа иҗат уңышлары юлдаш булсын! Туган халкыбызны, туган ягыбызны зурлауда бергә булыйк, исән-сау булыйк!

*2004, 12 май*

## НЕЧКӘ ХИСЛЕ, БАТЫР ЙӨРӘКЛЕ

1989 ел. Эреле-ваклы китаплары чыккаласа да, ул вакытта Рәшит Әхмәтҗановның учта сизелерлек калын китабы юк иде әле. Юка тышлы китап чыгарып, зур шагыйрь саналып була димени! Рәшитнең максаты — иң яхшы әсәрләрен туплап, «Шигырь китапханәсе» сериясендә томлык чыгару. «Шигырь китапханәсе»ндә чыгу — үзе зур дәрәҗә, шигърияттә үз урының булуын билгеләүче бер күрсәткеч. Һәрхәлдә, бу сериядә басылу күпләрнең хыялы иде ул елларда. Өстәвенә шагыйрьнең 50 еллыгы да якынлаша...

Китап чыгу мәсьәләсе нәшриятта тәгаенләнгәч, ул миннән шушы томлыкка кереш сүз язуымны үтенде. Хәзер уйлап куям: озак көтелгән кадерле китабына баш сүз язуны нигә миннән сораган? Холык-фигыль белән дә, язу-стиль ягыннан да шактый аерылабыз, ул вакытта мин иректә иҗатчы, профессионал, түрә-мазар да түгел, дәрәҗәле урын да биләмим... Дөрес, аның әсәрләренә төрле елларда берничә эчке рецензия (нәшриятта элегрәк шундый тәртип: компетентлы саналган язучы яки шагыйрь, авторлардан кергән кульязмаларны укып, бәяләмә бирә иде) язганым бар иде. Бәлки, шуларны да истә тотып мөрәҗәгать иткәндер. Ризалык бирелде, «вәгъдә — иман» дигәндәй, 4–5 битлек мәкалә язылды, һәм ул 1991 елда Рәшит Әхмәтҗановның «Моңлану» исемле сайланма әсәрләр китабында «Күңел һәм җан сәфәре» исеме белән кереш сүз булып басылып та чыкты. Бүләк итеп биргән китабына болай дип язган: «Равил! Гомер шулай узды инде. Безнең бергә яшәүгә мин бер генә караңгылык та төшермәдем. Рәшит Әхмәтҗанов. 6 май, 1991 ел».

Бу хәлләрдән соң нәкъ ун ел гомер үткән. Әйтелгән, ташка басылган сүзләр әле ул арада гына искерергә тиеш түгелләрдер ләса! Шуңа күрә әлеге кереш сүздән озынрак булса да кайбер өземтәләр китереп узам.

«Рәшит Әхмәтҗановның шагыйрь һәм дә зур шагыйрь икәнен кешеләргә раслыйсы юк. Әмма аның шигъриятенең үзенчәлеген, нечкәлекләрен үзебезгә аңлыйсы, күпләребезгә төшендерәсе бар әле. Өч дистә елга якын шактый ук актив эшләп килсә дә, аның иҗаты турында әдәби җәмәгатьчелекнең аерым төпле фикере соңгы биш-алты ел эчендә генә ишетелә башлады. Бу хәлнең сәбәпләре нидә? Бәлки, тәнкыйтьчеләрнең исемлек кысасына үз вакытында керә алмый калуындадыр? Бәлки, шигъриятебездә берьюлы ике талантлы шагыйрь — ике Әхмәтҗанов (Роберт һәм Рәшит) булуның «файдасыдыр»? Бәлки, иҗатының артык үзенчәлекле булуындадыр? Яшермим, укый-өйрәнә торгач, Рәшит Әхмәтҗанов дигән шагыйрь үзем өчен дә шактый ук «каты чикләвек» булып чыкты. Налим балыгы шикелле шома (яхшы мәгънәдә), тиз генә тоттырмый... аның шигъриятен «саңагыннан» эләктереп булмый... Шигырьләре техник яктан, Хәсән Сарьян «юнган агач» шикелле, бик нечкә зәвык белән эшләнгән; өстәвенә образ, чагыштырулар, эпитетлар һ.б. калфак чигешендәге энҗеләр шикелле бик мул сибелгән. Шагыйрьлекне аерым юл-строфалардан, исемләнгән шигъри башламнардан да тоеп була («Яшь чагында авыр ташлар — тау астында», «Төшләремә кердең каен булып», «Акка кызыл ачык булып төшәр», «Сандугач керде күңелгә», «Минем өчен дөнья — нәкъ дүрт гамәл», «Кошлар» бәйрәменә чакыру», «Салкын кышлар аккош булып кайтыр» һ.б.).

Яки менә бу дүртьюллыкны укып узыйк:

Муеныма аскан ташың — тау иде,
Мине тирән су төбенә салды ул.
Бүләк алып чыктым әле мин сиңа:
Сине сөйгәч — энҗе булып калды ул.

Рәшит Әхмәтҗанов — чын мәгънәсендәге татар милли шигъриятенең төп, дөрес юлында торучы шагыйребез. Ул — Р.Харис та түгел, Г.Рәхим яки Р.Мингалимов та түгел. Ихтимал, аны күпмедер дәрәҗәдә М.Әгъләмов белән параллель куеп буладыр. Икесе дә Хәсән Туфан шигърияте тарафдарлары. Аларның төп эчкән чишмәләре — халык иҗаты, татар халкының эстетик традицияләре. Биредә сүз иҗатчының юнәлеше, кыйбласы турында бара. «Һәр сүз миннән бер матурлык сорый, мин фәкыйрьмен — алыйм кайлардан?..» дисә дә, шагыйрь, әйткәнемчә, сүзне,

илһамны, җимне халык иҗатыннан, халык күңеленнән ала. Шуңа күрә дә аның шигырьләрендә безнең фольклорга хас бик күп традицион атрибутлар, образлар, тәгъбирләр тулып ята. Беренче карашка гади күренгән шигъри сүзберәмлекләр, шагыйрь күңелендә үзгәртелеп, яңа төсмерләр ала, образ-фикергә әйләнә:

Урман эчләрендә урман шаулый,
Урын тапмый болан үзенә.
И болан...

Йә сугарлар балам күзенә дип,
Ачык аланнарда төлке уйный,
Урманнарга кача яшь болан.
Кил, болан...

Урманнардан берни урламаган
Соңгы җан иясе — мин булам.

Кызганыч, безнең бүгенге яшьләребезнең күбесе халык иҗаты белән җимләнеп үсмәгәнгә, шагыйрь күңеле тудырган гаҗәеп бай һәм тылсымлы дөньяны тиешенчә танып, эстетик ләззәт ала алмый. Шәхес культы һәм торгынлык елларында бер-ике буын милли укучыларыбызны югалттык. Шулай да, үзебезне юатып, үзгәртеп коруларның нәтиҗәсе яңарышларга китерер дип өметләник.

Рәшит, үзенең шигърият өчен яратылганын сизеп микән, бүтән жанрларга сибелмичә, фәкать поэзиядә генә эшләп килә.

Ул бу яктан күпмедер дәрәҗәдә Х.Туфан, С.Хәким, Н.Арслановлар юлы белән китте. Бөтен җегәрен бер ноктага — бу очракта поэзиягә юнәлтү, табигый, аны бу өлкәнең чын остасы итә. Шуңа күрә дә Р.Әхмәтҗанов, гармуннарның теләсә нинди төрендә уйнаган Фәйзулла Туишев, Фәйзи Биккининнар шикелле, шигырь жанрының теләсә кайсы биләмәләрендә виртуозларча иркен эш итә: шигырьләрнең озынын яки кыскасын булсын менә дигән итеп коеп куя, поэмаларны да оста үреп чыга, моңлы яки дәртле җыр текстларын да үзенчәлекле итеп яза. Әйтик, шагыйрьнең «Акчарлак-лар»ы классик җырлардан саналырга хаклы дип уйлыйм. Балалар өчен дә җыйнак һәм тәрбияви әһәмиятле итеп яза белә. Бу китапта шагыйрь иҗатының тулы чагылышы: давылларын җанына яшергән ир-егет әдипнең дөньяга түккән күңел байлыгы, кешеләргә әйткән фикер-хикмәтләре, хис-моңнары тупланган монда.

Поэмалар өлкәсендә дә актив эшли Рәшитебез. Бу китапта алар берничә: «Язлар быел соңга калды», «Исәннәр моңы», «Бишташ», «Аучылар кибетендә». Соңгы икесе авторның гына түгел, гомумән, поэзиябезнең казанышы саналырлык поэмалар. Бер караганда, бу поэмаларның сюжет җепләре өзелеп-өзелеп киткәндәй тоела. Алай түгел икән шул. Ул җепләр үзәк өзгеч моң белән тоташтырылганнар икән. Моң сихеренә ия булган шагыйрьнең үзенчәлеге, иҗади табышы итеп кабул итәргә кирәк моны.

Р.Әхмәтҗанов — үзендә шагыйрьлек куәсе булган өчен генә иҗат итә торган кеше түгел. Ул — ил тарихы, халык язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында борчылып, әрнеп иҗат итүче шагыйрь. Шигырьләрендә эчке моң саркып тора. Күңелдә бар булганны ачыктан-ачык әйтергә мөмкинлекләр җитмәгән очракта (торгынлык елларында язылган шигырьләрен күздә тотып әйтәм), иҗатчы бүтән юлны сайлый — кинаяләр, катлауландырылган образлар аша тасвир итә. Тик шунысы хак: Рәшит Әхмәтҗанов нәрсә турында гына язмасын — авыр тойгылы уйлармы алар, якты-дәртле хисләрме — Шигъриятнең Матурлыкка һәм Гаделлеккә хезмәт иткәнен бер генә минутка да онытмый. Шагыйрь күңеле үз халкының бөтен тарихын хәтердә тотып иҗат итә. Хәтерсезләрне уятыр өчен нәкъ менә шундый шагыйрь кирәк булгандыр да әдәбиятыбызга».

Югарыда әйтелгәннәр Шагыйрь турында бүгенге уй-тойгыларыма, инануларыма бер дә каршы килми икән. Моңа бик шөкермен. Әлбәттә, хәзер язылса, бераз бүтәнчәрәк, бәлки, тирәнрәк, анализлырак итеп язылыр иде. Әмма Шагыйрьгә төп караш, мөнәсәбәт элеккечә калыр иде дип уйлыйм.

Табигый хәл микән? — күбрәк яшәгән саен, хатирәләргә ешрак биреләсең. Шагыйрь әйтмешли, «җир өстендә дуслар сирәгәйде, җир астында дуслар күбәйде». Сәбәбе шулдыр. Еллар узган саен, гомереӊ сәхифәләрен инде дөнья кичкән танышларыңныкы, дусларыңныкы белән чагыштырасың да әллә никадәр уртаклыкларга тап буласың. Рәшит — безнең буын шагыйре, бер-ике яшькә аерма булса да, минем буын шагыйре. Әдәбиятка бер чорда килдек. Беренче китаплар да бер үк елны — 1965 елда чыкты. Төрле еллардарак булса да бер үк шәһәрләрдә яшәдек — Әлмәт, Казан. Янә, еллары бергә туры килмәсә дә, бер үк шәһәрдә (Самара), бер үк частьта, бер үк казармаларда армия

хезмәтен үткәнбез (солдаттан ул пеләшләнеп кайтты, минем дә чәчләр хисабына маңгай нык кына «үсә» төште ул елларда. Шунлыктан дип беләм, Рәшит күп чак баш киемендә йөрде: кышын — бүрек, җәен — берет, бүлмә-биналарда — түбәтәй. Күп фотоларда ул шулай сурәтләнеп калган да). Соңрак бер үк редакциядә шактый еллар бергә эшләү... Әйе, хәтердә казынсаң, үткән гомердәге янәшәлекләрне тагын да санарга була. Болары — тәрҗемәи хәлгә караган фактлар. Ә максат берлеге? Иҗаттагы уртаклыклар? Үзе әйтмешли, бергә-бергә үткәргән «күңел бәйрәмнәре»? Исәпләп китсәң... Бу очракта әле бер кешене, бер шагыйрьне хәтерләп искә алганда туган уйлар. Ә андый затлар аз түгел бит! Дистәләгән, хәтта күп дистәләгән. Хәтерләр хәл-вакыйгалар күп, яшьрәк буыннарга әйтерлекләре дә җитәрлек. Кыскасы, безнең буынга да мемуарлар язарга вакыт җиткән икән!

Рәшитнең фанилыктан бакый дөньяга күчүенә дә җиде ел үтеп китте. Хәтер офыгыннан китеп онытылу рәшәсендә эреп югалыр өчен ярыйсы гына вакыт. Юк, бу шәхес онытыла торганнардан түгел. Еш искә төшә, юксындыра... Бездә кайчак киткән затлар турында, тәүбәгә килгәндәй булып, ярым рия, ярым риясыз сөйләнүчеләр табыла. Янәсе, вакытында кадерен белмәдек, бәяләмәдек (дөресрәге, үзләре үк белмәделәр, бәяләмәделәр)... Вакытында фәлән исем бирелмәде, төгән премия алмады... Гадәттә, андый соңарып «гаделлек урнаштыручылар» хаклы булмый. Һәр конкрет очрак-фактның үз вакыты, үз сәбәбе, һәр төеннең үз чишелеше. Тормыш логик юрауларга караганда күпкә катлаулырак... Әйе, чыннан да, соңарулар булгалый. Шулай да, премияләрдән, мактаулы исемнәрдән фетиш ясарга да ярамый. Тарихта Вакыттан кристаллашкан Исем генә кала. Тукай, Такташ, Җәлил... Премияләре юк шикелле. Бүгенге замангарак күчсәк, «Әни килде»нең авторы, драматург Шәриф Хөсәенов — Тукай премиясе лауреаты Диас Вәлиевтән ким саналамыни? Яки Саҗидә Сөләйманова шигърияте Гөлшат Зәйнашеваныкыннан түбәнмени? Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты да кайбер исемле лауреатларныкыннан бер дә ким түгел; кайбер яклары белән өстенрәк тә әле.

Шагыйрь гомеренең байтак еллары «Казан утлары» журналы белән бәйле. 15 еллап эшләде ул бездә. 1991 елда аңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе исеме бирелде. Соңгы елларда редакция вазифаларын күбрәк өендә утырып эшләде. Бергә эшләгәндә кешене шактый ук яхшы беләсең. Төрле яктан. Юк, фәрештә түгел иде шагыйрь Рәшит. Кешегә хас бөтен сыйфатларга ия иде ул. Кирәк чакта кыю һәм усал, кирәк чакта «сабыйларча» хәйләкәр... Тар иңнәргә утыртылган бу «якты башка» Ходай кинаяле, гаҗәп сыгылмалы төртмә тел биргән... Әмма, башкалардан аермалы буларак, бер үзгә сыйфаты бар иде, ул — нечкәлек. Һәрнәрсәдә: шигъриятта дә, мәхәббәттә дә, җор-мәзәк сүздә дә... Ә суверенитет өчен кискен көрәш көннәрендә, Азатлык мәйданында ачлык тотучылар белән бер рәткә басып, халкыбыз киләчәге өчен җанын фида кылырга да әзер көрәшче, милләтпәрвәр икәнен раслады.

Рәшит Әхмәтҗановның рухи яшәве дәвам итә. Әсәрләре чыгып тора. 1998 елда «Рухият» нәшриятында затлы китап рәвешендә аның янә бер томлыгы дөнья күрде. Иҗатын зурлаган мәкалә-очерклар басыла. Туган авылы мәктәбендә 1996 елда ачылган музей бүлмәсенә яңа буыннар аны яд итәргә килә. Казан зиратында Тукай белән янәшә үк диярлек күмелгән каберендә чәчәкләр өзелми...

*2001, февраль*

## ӘЙДӘҮЧЕ

*(Тәүфикъ Әйдинең күптомлыклары чыгу уңаеннан уйланулар)*

Кайчак уйлап куясың: адәм баласы нилектән язу эшенә тотына икән? Дөньяны танып белүдә минем үзгә карашым, ачышым бар дипме? Тирә-юньне бүтәннәр күрә алмаганча образлы-сурәтләү сәләтен раслау өченме? Сүз тылсымы белән Җир йөзендә Матурлык арттырып Гаделлеккә көч өстәргә теләвеме аның? Күңеле уйнаклавымы? Язу эше, әллә аерым бер затларга гына бирелгән илаһи инстинктмы?.. Иҗат — бөтен нечкәлекләрен беркайчан да, беркем дә ачып бетерә алмаслык серле процесс, җанның үзгә халәте; шуңа күрә иҗатчыда әлеге саналганнарның өлешчә һәркайсы да булырга мөмкин. Кешелек дөньясы безгә кадәр тудырган бихисап китаплар хәзинәсенә баксаң, әлеге сорауларга дәлил-җавапларны күпләп табарга була.

Әсәр, әйтик, шигырь, көтелмәгәндә, үзеннән-үзе җиңел генә туарга мөмкин. Икенче бер әсәрнең, хәтта кыска гына әсәрнең дә, газаплы кичерешләр аша, еллар дәвамында язылуы да бар. Кемнең ничек килеп чыга! Ярты гасыр буе диярлек язучылык иҗаты белән шөгыльләнгән кеше буларак каләмдәшләрнең төрлесе күрелде: фидакарь затларны да, көнлекчеләрне дә, талантларын исраф итүчеләрне дә, аз сәләт белән күпне дәгъвалаучыларны да… Арада сирәк булса да үтә зирәк, киләчәкне күзаллап, гомеренең һәр сәгатен, язган һәр сүзен, һәр җөмләсен, гомумән, һәр кылган

гамәлен үзе инанган иҗтимагый максатка юнәлткән язучылар да булды. Мәшһүр милләттәшебез Тәүфикъ Әйди әнә шундыйлардан иде. Ул нәрсә өчен язганын тәгаен аңлап, язганыннан нинди нәтиҗә чыгарга мөмкинлеген анык фаразлап иҗат итте.

Тәүфикъ Әйдинең тормыш һәм иҗат юлы җиңелләрдән булмады. Яратылышы белән зыялы һәм әдип зат булса да, шушы табигый барлык — булганлыкны дөньялыкта раслар өчен аңа биниһая көч, хезмәт куярга, «вакыт эчендәге вакытны табып» хәят кичерергә туры килде. Барысын да юклык ноктасыннан — нульдән башларга туры килсә дә, ничек тә юл ерырга, җиңелмәскә, максатка ирешергә! Моның өчен Вакыт — озын гомер кирәк. Ә Вакыт дигәннәре санаулы… Алтмыш еллап гомер кичереп, аның күпме өлешен чын иҗатка багышлый алды икән Тәүфикъ? Күпкә җыелмыйдыр. Башта Кояш астында яшәү өчен хокук һәм урын даулау (ятимлек, качаклык, төрле мәктәпләрдә, төрле телләрдә белем эстәп йөрүләр), соңрак Ходай биргән сәләтнең ия-хуҗасы нәкъ ул икәнлеген эш белән раслау (китапханәче, эшләп укучы студент, укытучы, милиция хезмәткәре, журналист…) һәм, ниһаять, җан теләгән иҗат белән шөгыльләнеп, уй-фикерләреңне дөньяга җиткерү (ирекле профессиональ язучы)… Бу тормышта, ир-ат буларак, тормыш арбасын тартасы, балалар үстереп, аларны кеше итәсе дә бар бит әле! Татар язучыларының бөтенесе диярлек, классик сүзләренчә, «без тормышның төбеннән күтәрелдек» дип әйтә ала. Белүемчә, Тәүфикъ Әйди гомеренең фәкать азак елларында гына төп вакытын чын иҗатка бирә алды. Шулай да…

Тәүфикъ Әйдинең «Сайланма әсәрләр»ен янә актарып-карап чыгасың да «эшләп тә күрсәткән икән егет!» дип сокланып куясың. Унбер томлык хезмәт. Романнар, повестьлар, фәнни-популяр очерклар, юлъязмалар… Соңгы елларда күптомлыклар (күбрәк өч-биш томлыклар) күренгәләсә дә, әлегә унбер томы чыккан язучыбыз юк шикелле. Күләм дигәннәре күп нәрсә белдерсә дә, әлбәттә, хикмәт күләм-санда түгел, иң мөһиме—хезмәтләрнең мәгънәви көчендә, кирәклек дәрәҗәсендә, тарихи-иҗтимагый әһәмиятендә.

Дөньяда талантлы язучылар да, яхшы әсәрләр дә җитәрлек. Татар әдәбиятында да шулай бу хәл. Һәр һәйбәт әсәр кеше күңеленә тәэсир итми калмый. Димәк, ул әсәр үзенең тууын аклаган… Хәтер—хәтәр нәрсә, аннан качып булмый. Төрлечә искә алына элгәргеләр: кайберләре—фәлән исемдәге әсәре белән хәтергә килә, кайберәүләре—үзләре кызык шәхес буларак күз алдына баса. Ә менә кискен хәлләрдә, рухи сынауларда, тормыш һич тә «мәгънәсез, уен-көлке» булмаганда, бигрәк тә халык язмышы, киләчәк турында уйланганда, сирәк әсәрләр, сирәк шәхесләр искә төшә. Т. Әйди—әнә шул сирәк әдипләрнең берсе инде.

Әгәр, Тәүфикъ Әйди иҗатының төп асылы, әһәмияте нидә, дип сорасалар, җавабым бер: мәгълүм бер чорда татар дигән халыкның дөньяда барлыгын раслауда үзеннән саллы өлеш кертә алуында. Татар—аның бәгырендә. Күпләр үз туган телен дә оныткан заманда, Т. Әйди халык киләчәген—үз балаларының язмышына тиң итеп карый белде, Дәрдемәнд сүзләре белән әйтсәк, «татарлыкта татар угълы татармын» булып калды. Иҗатың ихлас икән, анда һәммә нәрсә ярылып ята. Т. Әйди хезмәтләренең—мәкаләме ул, юлъязмамы—исемнәренә генә игътибар итегез. «Без тарихта эзлебез», «Бәхет бары туган илдә», «Төрки нигезне ныгытыйк», «Язмышыбыз үз кулыбызда», «Себер үзебезнеке», «Аһ, туган кавем газиз!», «Өмет—бары үзебездә»…

Инде томлыкларның төзелү тәртибе, эчтәлекләре турында берничә сүз әйтеп китик. Томлыкларның күбесе берничә әсәрдән гыйбарәт. Берсе, әйтик, сәяхәтнамәләр; берсе—мәшһүр шәхесләр турында тупланма; берсе—мәкалә-очерклар җыелмасы… Зуррак күләмлеләре, бу очракта романнар (алар өчәү), аерым томлыклар итеп бирелгән. Җөмләдән романнар турында берничә сүз. Т. Әйди—четерекле, күпләр кузгатырга базмаган темаларга алынды. Менә 90 нчы елларда дөнья күргән «Елан угы» романы (икенче том). Вакыйгалар үткән гасырның егерменче елларына карый. Аннотация-аңлатмада болай язылган: «сәяси детектив төсендә язылган бу әсәрдә милләттәшләребезнең Төркстанга революция экспортлауда катнашуы, сыйнфый көрәшне куертуның җирле халыкларга да, яңа битлек кигән колонизаторларга хезмәт итүче татарларга да бәхет китермәве, яңа фаҗигаләргә генә юл ачуы гәүдәләндерелә. Татарларның Төркстанда да ике тарафка аерылып, большевиклар һәм «басмачылар» сафында үзара көрәше, кан коюы тарихи саташу, адашулар нәтиҗәсе буларак сурәтләнә».

«Иблискә ришвәт» романы (өченче том) икенче дөнья сугышы вакытында немецларга әсир төшкән татар хәрбиләре турында. Мәгълүм булганча, өченче Рейх җитәкчеләре алардан Идел-Урал легионы төзеп, Советларга каршы көрәштерергә ниятли… Фаҗигаи хәлләр, гыйбрәтле язмышлар… «Нинди җир ул Ватан? Сатлыклар кемнәр? Татар хәрбиләре ни өчен легионга кергән? Әсирләрнең алман халкы белән бәйләнешләре нинди була?» — Автор әсәрендә әнә шундый сорауларга җавап эзли. Бишенче томга кергән әсәрләр — фәнни-популяр хезмәтләр җыелмасы. Анда «Гөлчәчәкләр илендә кара болыт» (Болгарстан), «Дунай буендагы кардәшләр» (Румыния), «Исәнме, Гагаузстан!», «Оҗмах утравы» (Кипр-Кыбрыз) исемле язмалар тупланган. «Үткән һәм бүгенге заман, гореф-гадәтләр һәм мәдәният, вакыйгалар һәм шәхесләр, ерак җирләрдә яшәп яткан милләттәшләребез һәм кардәш төрек халыклары» — Т. Әйдинең бу томдагы «иҗат кишәрлеге» әнә шулар. Мәшһүр

милләттәшләребезгә багышланган очерк-мәкаләләр кергән томлыкның аңлатмасына күз салсаң, анда бик ачык әйтелгән: «Бу китапта Шәркый Төркстан, Үзбәкстан, Себер, Идел-Урал буйларында яшәүче милләттәшләребез сурәтләнә. Алар бу тарафларда кайчан тамыр җибәргән? Нигә шундый чиксез киңлекләргә таралган? Саннары күпме? Башка халыклар арасында нинди урын билиләр? Ят һәм кардәш милләтләр белән мөнәсәбәтләре нинди? Горурланырлык казанышлары бармы? Автор әнә шундый күп кенә сорауларга җавап эзли, табышларын укучылары белән уртаклаша». Әйе, бу—Тәүфикъ Әйди стиле. Төпле, бөртекчән Тәүфикъ стиле. Татарстанның халык язучысы Нурихан Фәттах тиккә генә болай язмагандыр: «Татарстаннан читтәге татарлар турында җентекләп, тәфсилләп һәм даими рәвештә Тәүфикъ Әйди яза… Кем турында гына сөйләмәсен, автор һәр эшнең, һәр профессиянең асылына төшенеп, үзе тасвирлаган шәхесләрнең социаль, тарихи һәм профессиональ мохитен күз алдына китереп бастыра. Шунлыктан Тәүфикъ Әйди әсәрләренең тәэсир итү, ышандыру көче зур».

Язучының яртылаш язылып тәмамланмыйча калган хезмәтләренең берсе—моңарчы беркайда да басылмаган «Ак җилкән» әсәре. «Сайланмалар»ның дүртенче китабына кертелгән ул. Әсәрдә—20–30–50 нче елларда системалы рәвештә юк ителгән милли интеллигенция һәм алардан соң килгән «югалган буын» язмышы, һәм дә «курпы» булып калыккан яшь милли хәрәкәт хәлләре… Әйе, соңгы чор татар Ренессансы лидерларының берсе буларак Т. Әйдинең бу теманы күтәреп чыгуы табигый иде һәм көтелә дә иде. Шунысы игътибарга лаек: ул бу әсәрне үткән гасырның 80 нче еллар уртасында, партия диктатурасының бик ныклы чорында ук яза башлаган. Тема бик катлаулы һәм четерекле. Моңа тотыну өчен какшамас иманлы, курыкмас йөрәкле булу кирәк.

Башка томлыкларга килгәндә (санап китүемнең сәбәбе шул: бу мәгълүматлар, бәлки, кемнәргәдер томлыкларга юл күрсәткеч ролен үтәр), алардагы әсәрләрнең урнаштырылу тәртибе мондый: алтынчы том авторның Алмания, Эстония, Әстерхан яклары турында сәяхәтнамәләре; җиденче том тулысынча Төркиягә багышланган; «Ах, туган каумем газиз!» дип исемләнгән сигезенче том чит якларда яшәп иҗат итүче мәшһүр милләттәшләребез турында; тугызынчы томда Казакъстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан турында язмалар; унынчы том янә атаклы милләттәшләребез турында; унберенче том — төрле елларда көндәлек матбугатта чыккан мәкаләләр җыелмасы.

Язучы кеше, тумыштан талантлы булу белән бергә, үз заманындагы һәр үзгәрешләргә үтә сизгер, аның «күңел локаторы» һәр нәрсәне тота алырга тиеш. Бу сизгерлек, бәлки, талантның бер үзәк өлешедер дә әле. Хәзер дөньяда бер караганда табигый, икенче яктан сәеррәк тә процесслар бара. Шуның берсе—глобальләшү галәмәте. Кодрәтле җиһангирләрнең Кешелек Болынын тоташ сөреп, үзләренә хас бертөрле үлән-чәчәк (ягъни җәмгыять) булдырырга йөз тоткан дәвердә, икътисади яктан көчсезрәк, сан ягыннан азрак байтак халыклар ничек итеп үз йөзен, үз тарихын, үз генын саклау турында хәвефләнеп уйлана хәзер. Бу, әлбәттә, безгә дә кагыла. Мондый очракта, гадәттә, «мөтәпәйгамбәрләр»—«милләт аналары, милләт аталары» пәйда булучан. Шагыйрь әйтмешли, «кемдер, дин! ди, кемдер, мин! ди». Әлбәттә, исән-имин калуга булышкан һәр юл, һәр ысул, һәр идея файдалы. Әмма, ни генә булмасын, иң әүвәл нигез тамырларыңның ныклыгын, аларның яшәү көче дәрәҗәсен ачыклау фарыз. Бу очракта безнең өчен төп юл—төрки бердәмлекне ныгыту. Тәүфикъ Әйди моны бик күп акыллы башларга караганда алданрак тойган, аңлаган, гамәл кылган булып чыкты. Әдип иҗатын аркылыга-буйлыга карап-өйрәнеп чыксаң, моңа тиз инанасың. Ул кызыксынмаган, өйрәнмәгән берәр төрки халык бар микән? Дөресрәге, ул аяк басмаган төрки җирләр (ә ул җирләр иксез-чиксез!) калды микән? Мәсәлән, аз санлы гагауз дигән халык турында юньләп белә идекме? Ишетеп белсәк тә, алар тормышы хакында сирәкләребез хәбәрдар иде. Тәүфикъ Әйди яңача «ачып» күрсәтте безгә ул халыкны. Әлбәттә, үзебезгә дә сабак, гыйбрәт алырлык иттереп... Зуррак санда исәпләнгән үзбәк, казах, әзәри, кыргыз кебек халыклар турында язуын әйткән дә юк. Ул алар белән нык аралашып, «тел-лөгать алмашып» яшәде, рухи тормышлары турында һәрдаим язып килде, атаклы кешеләрен үзенең хезмәтләрендә сурәтләде, аркадаш каләмдәшләренең әсәрләрен, турыдан-туры тәрҗемәләп, татар укучысына җиткерде. Иң мөһиме: уртак рухи байлыкны—тарихны, мәдәни ядкәрләрне туганнарча бәрәкәтле файдаланырга, үстерергә чакырды. Бу җәһәттән телебезне баету юнәлешендә үз иҗатында игелекле үрнәк тә күрсәтте: йөзләрчә төрки тамыры булган уртак сүзләрне әдәби әйләнешкә кертте, аларны янәдән тел хәзинәбезгә кайтарды.

Һәр чорның үз көе, үз җыры дигәндәй, әдәбият та бик нык үзгәрешләр кичерә хәзер. Эчтәлеге һәм иҗтимагый әһәмиятлелеге ягыннан гына түгел, шәкли-формалар үзгәрү ягыннан да. Әйтик, традицион жанрлар бер-берсенә керешеп, үзара синтезлашып яңалары туа, язу стиле торган саен лаконик төс ала бара. Үз вакытында Лев Толстойлар фаразлаганча, дөньяны танып белергә өйрәтә торган информация-белешмәгә бай әдәбият туды. Тәүфикъ Әйди бу хәлне дә күпләргә караганда алданрак тоемлаган булса кирәк. Тарихи даталар, исемнәр, саннар, атамалар һ. б. кирәкле белешмә-хәбәр бихисап аның әсәрләрендә. Укучылар, бигрәк тә яшьрәк буын өчен әһәмияте зур андый

язмаларның. Кемнедер эстон яки латыш язучылары кызыксындыра, кемгәдер Кытай яки Төркиядәге татарлар турында мәгълүмат кирәк… Рәхим итеп, Тәүфикъ Әйди әсәрләренә мөрәҗәгать ит, кирәксенгәннәреңнең байтагын табарсың…

Әйе, Тәүфикъ Әйди бөтен дөнья буйлап татарны барлады, асыл зат ул-кызларын күтәрде, яшь буыннар үрнәк итәрлек маяклар эзләде. (Хәзерге вакытта нәтиҗәле эшләп килүче Бөтендөнья татарлары Конгрессы миссиясе инде!) Ул яхшы мәгънәдәге чын милләтче иде. Кемгәдер, бәлки, пародокс булып тоелыр: асылда, чын милләтче генә чын мәгънәдәге интернационалист була ала. Үз баласын юньләп багып тәрбия итә алмаган кеше ничек итеп бүтәннәр баласын сөя алсын, үз милләт-кавемен кадерли белмәгән адәм ничек башка халыкларны хөрмәтли алсын! Җентекләбрәк укып карагыз Әйди әсәрләрен: татар кешесе турында яза, үзе бүтән милләт вәкилләрен—казакъмы ул, эстонмы, немец яки японмы—нинди ихтирам күрсәтеп бәян итә! Шигарь формасында булмаса да, язучы-әдипнең төп эчке фикере шул: бу дөньяда халыкларыбызда булган иң яхшы сыйфатларны үзләштереп тату яши белик, үз милли йөзебезне югалтмыйча, киләчәк буыннарга уртак хәзинәбезне баетып калдырыйк! Ул әйтерсең лә безнең халыкның ЮНЕСКОдагы бер вәкиле. Чынлыкта да, Тәүфикъ Әйди, шартлар булган очракта, берәр зур илдә татарның вәкаләтле илчесе булып торырлык иде: буй-сын, килеш-кыяфәт, белем-интеллект, сабыр холык, чама хисе… Бәлки, ул чакта рәсми даирәләргә ошап та бетмәгәндер, әмма факт: Т. Әйди өендә чит республикалардан, чит илләрдән килгән әдипләр еш була иде. Күрәсең, илгизәрләрдә формаль очрашулардан тыш зур эрудицияле әдипләр белән ачыктан-ачык аралашу ихтыяҗы зур булгандыр. Әлбәттә, андый очрашулар эзсез үтми. Мәсәлән, 1989–1990 елларда Эстониядә Татар әдәбияты, Татарстанда Эстон әдәбияты көннәре узуында Т. Әйдинең өлеше зур дип уйлыйм мин.

Күп йөргән—күп белгән, диләр. Күп белгәннең, әлбәттә, фикерләве дә колачлырак, төгәлрәк, дөреслеккә якынрак була. Әгәр без авыз тутырып татар әдәбияты дибез икән, ул инде, табигый, бөтентатар әдәбияты булырга тиеш. Һәр төбәктә яшәүче татар—Себердә яки Пенза якларында яшиме ул, Нижгар яки Ногай далаларында гомер кичерәме, аның үз итеп укырлык әсәрләре булырга тиеш татар әдәбияты хәзинәсендә. Бу—безнең өчен, язучылар өчен иң җитди, иң мөһим проблемаларның берсе. Татарстанның халык язучысы, халык рәссамы яки артисты булу бер нәрсә, ә син менә бөтен татар халкының абруйлысы булып кара! Тормышка ашкан очракта, тарихи да, саваплы да, шөһрәтле дә миссия була инде ул. Тәүфикъ Әйди әсәрләрен укыганда, мондый уйлар күңелгә еш килә.

Талант—Табигать бүләге. Иҗат кешеләре, алда әйтелгәнчә, үзләре бер дөнья тудырырга сәләтле, гаҗәп кызыклы, кабатланмас токым. Араларында төрлесе бар. Күзәнәкләренә нарциcслык сеңгәннәре дә җитәрлек. Андыйлар, гадәттә, халык язмышы, милли идея, иҗади миссия кебек «вак» нәрсәләр белән изаланып тормый: яздым—бетте! Калганы—алкышлар көтү… Иҗади эгоизм… Дәүләте, зур матди һәм рухи маясы булган халыкларга андый «иркәләр», сәерләр дә төстер… Французлар Франсуа Вийонны да бөек ясаганнар. Ә безгә? Безнең язмыш, безнең юл бүтәнрәк, шактый ук бүтәнрәк шул… Тәүфикъ Әйди, боларны яхшы тоеп, халыкның егет улы буларак, аңлы рәвештә авыр юл сайлады. Уйлылар һәм күңеле нечкәләр өчен заманы да авыр иде. Демократия юк дәрәҗәсендә, рухи маяк—утопик һәм фальшь; асылда, берне сөйләп, икенче төрле гамәл кылып яшәгән заман. Хакыйкатьне ярып әйткәннең башыннан сыйпамыйлар. Күз-колак булучылар һәрвакыттагыча көчле һәм сизгер. Тәүфикъ Әйдинең тормыш рәвеше һәм иҗаты да һәрчак игътибар үзәгендә булды. Талкучылар да җитәрлек иде… Кайбер «бөек»ләр Сүз кодрәтен үз җанына нирвани халәт тудыру чарасы санаганда, Тәүфикъ Әйди Сүзне халыкның үзаңын үстерүдә бөек көч булганын раслар өчен яшәде. Аның өчен хак-тугры сүзнең кешеләр күңеленә барып ирешүе, гамәл-хәрәкәткә китерелүе кыйммәт иде. Язучының сүзе, билгеле, аның әсәрләрендә, басма китапларда, көндәлек матбугатта—газета-журналларда. Милли матбугатыбызны пропагандалауда Т. Әйдинең хезмәте әйтеп бетергесез зур. Эшчәнлегенең зур өлешен, бәлки әле иң күп вакытын алган өлешедер әле ул. Хәтерлим, 60 нчы еллар урталарында, җәйләрен, аркасына биштәр тулы газета-журналлар төяп, ул Чуваш, Мордовия, Мари якларында велосипедка утырып сәяхәтләр кылып йөрде, татар матбугатын таратты, халыкны үгетләде, өндәде… Мондый акцияне фәкать фидакарьләр генә эшли ала. Матбугат таратучы сыйфаты мәгънәле бер шөгыль булса, асылда, ул әлеге халыкларның яшәеш хәлләрен-үткәннәрен, бүгенгеләрен өйрәнде, тарихи яссылыктан карап аларның милләт буларак рухи потенциальләрен ачыкларга тырышты. Һәр халыкның тарихы үзе бер онытмаслык мисал-гыйбрәт бит! Үз халкыңның киләчәге өчен җан атып көрәшкәндә, һәр нәрсәнең—һәр вакыйганың, һәр фактның кирәге чыгуы бар…

Тәүфикъ Әйди турында язганда, үзеннән-үзе дигәндәй, шәхеснең җәмгыятьтәге урыны, роле турында да еш уйланылды. Без үскәндә, —үткән гасыр урталары була инде ул, —шактый еш сөйлиләр иде бу хакта. Тарихи вакыйгалар фонында шәхеснең ролен кечерәйтебрәк аңлаталар иде. Шәхес культының «чәчәк аткан» заманы югыйсә… Бәхәссез хакыйкать: теләсә нинди чорда да, билгеле бер шартлар булганда, әгәр бөтен җанын-тәнен, бар җегәрен бер максатка юнәлдерә икән,

бер генә кеше дә (бер генә данә кеше дә!) күп эшли ала бу дөньяда! Тәүфикъ Әйдинең тормыштагы гамәлләре моңа мисал. Минемчә, Т. Әйди иҗатының, бу очракта мирасының, рухани мәгънәсе, икенче төрле әйткәндә, язылмаган васыяте шул: татарны фәкать татар үзе генә яклый-саклый ала; шуның өчен дә таралып яткан бу халык яһүдләр кебек тупланырга тиеш; иң әүвәл, милләтнең асыл затларын барлап, алар аша халыкның хакыйкый урынын дөньяга таныту зарур. Бу максатка милли идеяне (ансыз ни халык, ни дәүләт, ни киләчәк юк) үстереп кенә ирешеп була. Аны үстерүнең бер ышанычлы чыганагы—ана телендәге матбугат. Ягъни татар телендәге басмалар—китаплар, газета-журналлар. Соңгы гасырларда халкыбыздагы дәүләтчелек геннарын югалттырмауда басма сүз, борынгыларча әйтсәк, китап сүзе төп рольләрнең берсен үтәп килде. Тәүфикъ Әйди киң катлауга, бигрәк тә яшь буынга, әнә шуны аңлатырга тырышты да. Бу җәһәттән милләтпәрвәрлеге, сәяхлеге белән аны күпмедер дәрәҗәдә Рәшит казый (Габдрәшит Ибраһимов) белән дә чагыштырып буладыр. Классик язучыбыз Галимҗан Ибраһимов үзенең фамилиядәш адашын заманында «тарихи кыңгырау» дип бәяләсә, Тәүфикъ Әйдине исә без «тарихи бер төен», «Милләтнең ышанычлы, нык бер төене» дип әйтә алабыздыр. Т. Әйди үзе дә Рәшит казый турында сокланып язды, тормышы маҗаралар, кыю гамәлләр белән тулы шәхес турында бүгенге укучыларга шактый мәгълүмат бирде. Ә андый шәхесләр Т. Әйдинең иҗат картотекасында дистәләп җыйнала. Татар җирендә туып үсеп, төрки дөньяның мәшһүр галиме исәпләнгән Габделбари Баттал, Кытайда Мао-Цзедун даирәсендә югары пост биләгән Борһан Шәһиди… Моннан ун еллар элек Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев, Тәүфикъ әле үзе исән чагында болай дип язып чыккан иде: «Т.Әйди кадерле шәхесләребезне бергә туплап сурәтләп, укучыларда милли горурлык хисе тәрбияләүдә җитди өлеш кертеп килә. Ул берчакта да коры, буш сүз сөйләми, фикерләрен, йомгакларын катгый дәлилләр белән сиплэп, нык ытып бара».

Тәүфикъ Әйди ниятләгәннәренең күбесен тормышка ашыра алмый китеп барды. Алда әйткәнемчә, табигатьтән бирелгәнне раслауга күп вакыты китте. Таяну ноктасыз башлаганнар язмышы. Юнәлеш анык булса да, юллар сикәлтәле, урау. Максатка ирешү юлында күпмедер дәрәҗәдә компромиссларга да барырга туры килә. Безнең чор каләм ияләре идеологик кайбер канун-тәртипләр белән исәпләшми булдыра алмый иде. Әйтик, фәлән төбәкнең, фәлән авылның үткәнен-бүгенгесен язар өчен генә дә җеп очы иң әүвәл райкомнар, парткомнарга тоташа иде. Журналистның, язучының ак кәгазьдәге каләме белән бергә партия күзе ияреп барды. Бу нәрсә, табигый, Т.Әйдинең дә кайбер мәкалә-очеркларында, репортаж-юлъязмаларында чагылыш тапмый калмады. Язучының кайбер юлъязмаларында һәркем күрә алган, шулай ук төрле энциклопедия-сүзлекләрдән, белешмә-проспектлардан алынган мәгълүматлар артыккарак китә. Илләрне-җирләрне беренче барып күргәндә, андый «Америка ачу»лар буладыр ул. Бигрәк тә чит илләргә «тимер пәрдә»нең яңа ачыла башлаган дәвердә… Хәер, беренче кичерешләрне, сабыйлар сүзе шикелле, дөресрәк була дип тә әйтәләр. Бу очракта безнең әдәбиятка хас мәгърифәтчелек традицияләренең яшәвен дә искә алырга кирәктер, мөгаен.

Тәүфикъ Әйди, күпләребез шикелле, журналист язучы. Яшәү һәм иҗат җепләребез көндәлек матбугатка бәйле. Бу урында «журналист язучы» төшенчәсенә ачыклык кертеп узыйк; күпләрнең бу тәгъбиргә үз стереотип карашы бар: журналист язучылар алар—көндәлек тормышны оператив яктыртып, мәкалә, очерк, документаль хикәя-повесть һ. б. язучы каләм ияләре. Нигездә, дөрес. Әмма бүтән төрдәгеләре дә бар газета-журналларда эшләүче әдипләрнең. Алар, гадәттә, тирән белемле, оптимистик фикер йөртүче зур язучылар. Аларның күбесе тереклек итү хакына матбугатта ялланып эшләргә мәҗбүрләр (әйтик, татар халык шагыйре Илдар Юзеев, пенсиягә чыккач та, соңгы көннәренә кадәр диярлек редакцияләрдә эшләде). Тәүфикъ Әйдигә килсәк, ул журналларда эшләүче галим язучы иде. Әсәрләрендәге тормышка карата дәлилле тарихи караш, фәннилек, документальлек, фәлсәфи анализ шуны раслый. Язучыларыбыз арасында милләт исеменнән халыкара трибуналардан чыгыш ясый алырлык шәхесләр күп түгел. Т.Әйди Европа һәм Азиянең шактый илләрендә булып, төрле дәрәҗәдәге фәнни конференцияләрдә, симпозиумнарда чыгышлар ясады. Фәнни яктан нигезле, тарихи фактларга бай чыгышларын ишетми, матбугатта, бигрәк тә төрки дөнья матбугатында басылган хезмәтләрен укып, галим-голәма аның фикерләре белән санлашырга мәҗбүр иде.

Т.Әйдинең байтак еллары Матбугат йортында узды. Кайбер редакцияләрдә («Татарстан» журналы, «Заман» газетасы) күпмедер хезмәт куйса да, гомеренең бастырып төп эшләгән урыны «Казан утлары» журналы булды. Күп көч куйды ул анда. Унике елдан артык эшләү дәверендә, шаблонрак сүз белән әйтсәк, якты эз калдырды. Журналның кайбер рубрикалары, әйтик, «Татар халкы: төрле төбәкләрдә, төрле илләрдә», «Чит илләрдәге милләттәшләребез иҗаты», турыдан-туры Т.Әйди инициативасы белән булдырылды, һәм ул материалларны туплаучысы да күп чак ул булды. Һәм, әйтергә кирәк, Тәүфикъның күпчелек үз әсәрләре дә шушы журналда басылды, халыкка ирешеп танылу алды.

Танылу димәктән, әйтергә кирәк, үзенә тиешле бәя-хөрмәтне алмыйча, аны тоеп сөенү ләззәтен күрмичә китеп барды Тәүфикъ Рамазан улы. Бу урында олуг галимебез Миркасыйм Госмановның «Табышмакка әверелгән истәлек» дигән язмасындагы берничә юлны китереп узу урынлы булыр: «…үзе исән чакта гомум эшчәнлеге, конкрет иҗаты тиешле бәһасен ала алмаган, бәлки мәгълүм көчләр тарафыннан шәхесе гел кыерсытыла, эзәрлекләнә килгән, мәгәр шундый авыр шартларда да үз иманына тугрылыклы булып кала алган Тәүфикъ Әйди иҗаты алдында без һаман бурычлыбыз. Моны аңлый белү безнең аң дәрәҗәбезнең күрсәткече булыр».

Мин үзем Тәүфикъ Әйди белән кырык еллап белешеп, аралашып яшәгән кеше. Шуның ун елга якыны «Казан утлары» журналы редакциясендә якын хезмәттәшлектә үтте. Табындаш әшнәләр булмасак та, күп мәсьәләләрдә фикердәшләр идек, сынауларда бер-беребезгә таяна алырлыгыбызны тоеп яшәдек. 2001 елның язында, хастаханәдә каләмдәшләре арасыннан иң соңгы күрешкән кеше дә мин булдым шикелле. Хушлашыр алдыннан мин ишеткән иң соңгы сүзләре мондый иде: «Халкыбыз да безнең кырку шул, Равил…» Кырку… Бу сүзнең төп-төгәл мәгънәсен аңлап та бетмәдем ул чак. Хәзер дә тулысы белән аңлыйм, беләм дип әйтә алмыйм. Нинди мәгънәләр салып әйтте икән ул сүзне? Монысы инде ачылмаслык мәңгелек сер. Кырку… Тәүфикъ Әйди дигәч, еш искә төшә бу сүз. Сискәндерә дә, шомландыра да, уйландыра ул мине… Андый чакларда әдипнең китапларын кулга алам, борчыган сорауларыма җаваплар эзлим.

*2005, март-апрель*

## ЯНА-ЯНА ИҖАТ ИТӘ

Айдар Хәлим — үзенең яшәү рәвеше, иҗтимагый гамәле, иҗади эшчәнлеге белән безнең хәят-яшәвебездә феномен күренеш. Моны бүген кемнәрдер таныймы, инкяр итәме яки махсус күрмәмеш-белмәмешкә салынамы — анысы мөһим дә түгел — әмма Вакыт галиҗәнаплары бу Шәхеснең кабатланмас зурлыгын әкренләп раслап килә инде.

Әдәби даирәдә Айдар Хәлим (баштарак ул совет паспортындагыча Борис Хәлимов булып таныла башлады) исеме инде кырык еллап даими ишетелеп, аңга сеңеп килә. Элегрәк — 60 нчы елларда ул, башкалардан әллә ни аерылып тормыйча, дистәләгән яшь һәм башлап язучылар исемлегендә йөрде. Җәмәгатьчелекнең күз уңыннан югалгалап торган чаклары да булды. Әле Башкортстанда, әле Татарстанда, тагын әллә кайларда яшәп-яшәп алулары да, күрәсең, моңа сәбәп булгандыр. Ул шулай ук әдәбиятта «Фәйзуллиннар буыны» (мин чыгарган термин түгел!) дигән обойма-исемлектә дә саналып йөртелмәде. Гәрчә ул яшь һәм иҗат башлангычы потенциясе белән нәкъ шушы буынның табигый талантлы бер вәкиле булса да. Хәер, мондый шартлы дифференциянең хаҗәте дә шуның кадәр генә. Ахыр чиктә һәр Иҗатчы үзенең намусы, Вакыт һәм Халык алдында япа-ялгыз бергә-бер бит! Әнә тәнкыйтьчеләргә барлар өчен җайлы булган буын-төркемнәргә кермәгән Роберт һәм Рәшит Әхмәтҗановлар, прозада Миргазиян Юныс һәм Адлер Тимергалиннар, драматургиядә Шәриф Хөсәенов, Туфан Миңнуллиннар үзләре бер тылсымлы иҗат дөньясы тудырмадылар мени?

Айдар Хәлим — бу дөньялыкта Яшәү казыгын нык каккан әдип. Таныйк: соңгы 10–15 ел эчендә ул халыкара масштабтагы фигурага әйләнде. Аны һәр даирәдә шактый ук яхшы беләләр: гади укучылар да, сәясәттәге эшмәкәрләр дә, хакимият-күзәтү вәкилләре дә, чит ил даирәләре дә... Хикмәт нидә? Шагыйрьлеген, язучылыгын таныган хәлдә, миңа калса, ул иң әүвәл бүгенге көннең иң актив милләтпәрвәр публицисты. Ул ике башына да ут капкан шәм шикелле. Өстәвенә уртасын үзе үк бик теләп яндыра шикелле. Күрәсең, генетик коды шундый. Ул гүя МЧСның (Министерство чрезвычайных ситуаций) бер җаваплы идарә пультында. Кайда хәвеф, кайда бәрелеш, кайда яра — Айдарның каләме шунда. Соңгы ун елда чыккан китапларын искә төшерик: «Книга печали, или Записки аборигена», «Гомеремнең ун көне», «Этот непобедимый чеченец», «Минем түгәрәк имәнем»... Кайберләре, үзебездә мөмкинлек табылмагач, чит илләрдә басылган, суд-мәхкәмә чикләрен үткән... Аннан да кыюрак, зирәгрәк, гайрәтлерәкләр бар икән, — әйдә, андый әсәрләрне үзләре язып күрсәтсеннәр! Бу китапларның берсе генә дөнья күргән очракта да, Тарихта урын дәгъва итәргә мөмкиндер ул.

Кайчак уйлап куясың: ничек шулай төрле яклап универсаль югары кимәлдәге профессиональ иҗат итеп була икән? Айдар Хәлим ике телдә — рус һәм татар телләрендә (теләгәндә саф башкортча да!) иркенләп иҗат итә ала. Сирәк хәл. Аңлаганнар өчен ул зур шагыйрь (әле яңа гына чыккан «Милли шигырьләр» китабын укып карагыз!). Шагыйрь булам дип башлаган иде иҗатын, — максатына иреште. Өстәвенә балалар өчен дә менә дигән шигырьләр яза. Бусы — талантның зурлыгын белдерүче бер сыйфат. Пьесалар язуы да мәгълүм... Әмма, минемчә, соңгы еллардагы төп иҗади хезмәте ул — проза әсәрләре. Кайберләре аерым китап булып чыкты, кайберләре әле әзерләнә генә дип беләм. Шулай да төп проза әсәрләре — «Өч аяклы ат», «Татар вакыты», «Казыктагы итальян» «Казан утлары»нда үз вакытында басылып чыктылар. Кемгә ничектер,

бүгенге татар прозасының яңа казанышы, яңа биеклеге дип бәялим мин бу әсәрләрне. Теләгәндә, теләсә нинди дәрәҗәдәге премия-бүләкләргә лаеклы әсәрләр.

Айдар Хәлим — һәр зур талантка хас булганча, гаять катлаулы һәм каршылыклы шәхес. Дөрес, аны тирән беләм дип әйтә алмыйм, нык аралашып бер мохиттә яшәлмәде, холкын һәм гамәлен күзәтүләрем буенча шулай дип уйлыйм. Ярсулы, ашкынулы, каудар әдип. Җанындагын, күңелендәген әйтеп калырга өлгерә алмамдыр дип, бәргәләнә-кабалана да бугай ул. Кайчак уй-фикерләре, хис-тойгылары кирәк дәрәҗәдә «утырып» та өлгерми, алар инде ялкын йә хәнҗәр булып кемнәрнедер яндырып, яралап та өлгерә. Кайчак берәр затны өскә чөйгәндә, бүтән берничәне билгә кадәр батырып та куйгалый... Нишлисең, талант табигате хәлләре... Иман һәм талант хакына кайбер чиктән чиккә ташлануларны кичерергә дә туры килә. Әйе, ашыга Айдар. Ашыгырсың да шул: төрле төбәк-кыйтгаларда сүнеп бара торган татар учакларына тын-сулыш өрергә өлгерергә кирәк! Бүген үк, хәзер үк! Иртәгә инде соң булуы бар... Ул гел юлда кебек миңа. Әле Урта Азиядә, әле Кавказда, әле Урал якларында, Оренбург далаларында… Сүз уңаеннан Айдар Хәлимнең соңгы биш елда татар халкының Милли Мәҗлес рәисе булуын да искә алып үтик. Дөресен әйтим, аның бу хезмәтенә, эшнең асылын һәм нәтиҗәлелеген тиешенчә белмәү сәбәпле, бәя бирә алмыйм. Милләт мәнфәгате өчен саулыгын, рух җегәрен кызганмый янып йөрүен генә беләм. Күрәсең, дөньялыкта һәммәсен дә колачлап бетереп булмый торгандыр. Бәлки, Милли Мәҗлес башлыгы өчен Садри Максудига хас сыйфатларга ия булырга кирәктер, халкыңның да XX гасыр башындагы кебек ишле һәм бердәм булуы шарттыр...

Айдар Хәлимгә 60 яшь тулган икән! Гаҗәп түгел, яшәгәч, яшь саны барыр инде ул. Иллесе дә, алтмышы да, җитмеше дә... Бу алтмыш еллык Олуг шәхес Айдар замандаш турында, аның иҗаты турында уйланып алу өчен бер форсат кына. «Алда гомер бардыр барын, сагындыра узганы» дисәк тә, шагыйрәбез Клара Булатова әйтмешли, «алда язлар әле!». Чын язлар, үткән гомер белән түләнеп алган язлар! Айдар Хәлим феномены безгә яңа хикмәтләр, яңа ачышлар күрсәтер әле.

*2002, гыйнвар*

## ЗАМАНГА ИШ ИҖАТ

*(Шагыйрь портретына кайбер штрихлар)*

«Алтмышынчы еллар буыны» вәкилләренә алтмышар яшь... Быел, гомумән, каләмдәшләр арасында «алтмышлылар» ишле: Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Фоат Галимуллин, Гәрәй Рәхим, Фоат Садриев, Рауль Мирхәйдәров, Ризван Хәмид... Исемнәрне дәвам итәргә мөмкин. Мәрхүмнәрдән — Рәшит Әхмәтҗанов, Тәүфикъ Әйди (бу юлларны язган кичне бакый дөньяга күчте, урыны җәннәттә булсын!). Исәпләсәң, һәр ай саен — берәр юбиляр. Һәм исемнәре нинди әле! Һәркайсы үз эшләренең зур осталары. Һәрберсенең әдәбиятта үзенең абруйлы урыны, дәрәҗәсе бар. Шулай да бу алтмыш яшьлекләр арасында әдәбиятыбызда «алтмышынчы еллар» дулкынын тәшкил итүчеләр берничә генә. Бу термин-атаманы, асылда, ул вакыттагы яшь шагыйрьләр тудыртты. Ул шагыйрьләр арасында иң күренеклеләренең берсе, һичшиксез, Ренат Харис булды.

Морза әдип Әмирхан Еники әйтмешли, значится, Ренат Хариска да алтмыш икән!

Ходай язган булган: әдәби мохиттә бергә-бергә кырык еллап иҗат гомере кичерелгән. Гомерләребезнең өчтән икесе бергә үтелгән. Әйтергә генә ансат. Кырык ел бит ул, кырык көн түгел... Яшь чакта кырык-илледәге кешеләр дә бик өлкән, алтмыш тирәләрендәгеләре инде бик карт булып күренә иде. Хәзер кемнәрдер безгә дә шулай карыйлардыр. Җырдагыча «минем елларым — минем байлыгым!» дип әйтергә генә кала. Хәер, Яшәү дигән Бөек Халәтнең табигый агышын тойган-аңлаган кеше артык уфтанмас. Гомер заяга узмаган бит! Утыртасы агачлар утыртылып ябалдашланган, балалар үсеп җитеп дөнья кендегенә тоташтырылган, салынасы йорт-диварлар салынган... Өстәвенә дистә-дистә китаплар язылган. Теләсәң, өеп куй да аларны, бала сөйгән кебек, тышлыкларын сыйпап иркәлә йә булмаса өсләренә утыр да бер, чиксез офыкларга карап мәңгелек турында уйлан... Ренат Харис, кайбер каләмдәшләре кебек, бу яктан тыныч һәм бәхетледер дип уйлыйм. Артта тынгысыз, әмма мул җимешле, мәгънәле гомер, татлы һәм газаплы иҗат еллары...

Табигать Ренатка талант оеткысын мулдан биргән. Төрле яктан. Ул, теләгәндә, әти-әниләре шикелле, мактаулы педагог була алыр иде (заманында, пединститут бетергәч, Арча педучилищесында укытып та алды), теләгәндә, оста рәссам (ул рәсем ясау белән һәрдаим шөгыльләнә, берничә ел элек Казан музейларының берсендә үз рәсемнәреннән күргәзмә дә оештырды), теләгәндә, музыкант та була алыр иде (нәселләрендә атаклы музыкантлар бар, үзе дә гармуннарда көйләрне оста яңгырата)... Дөньялыкка ярарлык без белеп бетермәгән тагын бүтән сәләтләре дә бардыр. Әмма ул иң әүвәл шагыйрь буларак билгеле. Шагыйрь булу — бөек ләззәти биеклектер ул, мөгаен. Кешелек тарихын шагыйрьләр бизәкли. Гомер бакый шулай килгән. Ярты дөньяны яулап алган яугир ханнар, патша-корольләр дә Шагыйрь данына кызыккан. Һәр халыкта Шагыйрьнең үзгә

бер символ-образы. Кызганыч, бездә шагыйрь образын стереотип рәвештә «тамга салынган» Ходай бәндәсе итебрәк күрәләр. Шагыйрь — Тукай яки Мөдәррис Әгъләмов кыяфәтенә, холык-фигыленә генә сыеп бетә алмый. Шагыйрьләрнең төрлесе булган — дәрвиш-чичәннәре дә, хәким-хөкемдарлары да, бае-ярлысы да, кәрләсе-баһадиры да... Үзебезнең әдәбияттагыларын гына күз алдына китерик: әрвахлар сакчысы Мөхәммәдъяр, гомерлек мосафир Акмулла, зыялы миллионер Дәрдемәнд, гыйсъянчы Такташ, мәхбүс риясыз Туфан, башбирмәс Баттал... Миңа калса, Р.Харис Гете тибындагы шагыйрьлекне үзенә өлге итеп алган. Шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе. Ай-һай! бигрәкләр дә бөек биеклек! Бездә булырдай эшме бу?

Ренат Харис гомере буе җаваплы хезмәттә булды. Бер ел педагог булып эшләүгә, аны ВЛКСМ өлкә комитетына инструктор итеп алдылар. 60 нчы еллар ахырында «Яшь ленинчы» газетасының җаваплы секретаре, аннан Язучылар берлегенең җаваплы секретаре, хәзергечә әйтсәк, рәис урынбасары, ун елга якын (1973—1982) Татарстан культура министры урынбасары, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире (1982—1989), соңгы дистә елларда КПССның Татарстан өлкә комитетында идеология бүлеге мөдире, «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире, Татарстан Дәүләт Советының рәис урынбасары. 1990 елдан бирле (рәттән өч чакырылыш) Татарстан халык депутаты... Безнең арада болай озак еллар буе дәүләти вазифалар башкарган шагыйрь юк та сыман. Халыкча әйтсәк: түрә шагыйрь. Белүемчә, бу статусның күп җайлы яклары белән бергә шактый үзгә кыенлык-тыенлыклары да бар: һәрдаим мәгълүм кысаларда тота торган рәсмилек, сәяси манипуляцияләргә әзер булу, мәҗбүри этикет... Тауның башынарак менгән саен, җилләр көчлерәк! Шундый юл сайлагансың икән... Әмма түрәлек китә торган нәрсә, шигырь кала, шагыйрь кала. Безгә шагыйрь Ренат Харис турында сөйләү дөрес булыр.

Иң әүвәл ретроспектив планда, үткән еллар елъязмаларына күз салып алыйк әле. Моннан унбиш ел элек чыккан «Совет Татарстаны язучылары» дигән биобиблиографик белешмәдә (төзүчеләре Р.Даутов, Н.Нуруллина) Р.Харис турында менә нәрсәләр язылган: «...Р.Харис — әдәбият мәйданына алтмышынчы еллар башында килгән һәм беренче адымнарыннан ук шигърияттә үз сөйләү формасын, үз стилен булдырырга тырышкан үзенчәлекле шагыйрьләрдән берсе... Р.Харисның шигъри әсәрләре заманча үткен яңгырашы, интернациональ рухы, образлы фикерләүдәге яңача алымнары, кыю метафоралары һәм чагыштырулары, форма өлкәсендәге оригиналь табышлары белән җәлеп итә. Ул поэзиянең тематикасын, жанр чикләрен төрләндерү, шигъри сүзнең җегәрен, эчке куәтен арттыру, чорның олы проблемаларын лирик чаралар ярдәмендә үтемлерәк итеп җанландыру юнәлешендә өзлексез эзләнә, фикер-хисне укучыга сурәтле итеп җиткерү өчен, халык иҗаты символикасыннан һәм әдәбият-сәнгатьтәге шартлы алымнардан мул файдалана.

Шагыйрь үзенең шигырь һәм поэмаларында халкыбызның тарихи яшәеше, кеше шәхесенең тормыштагы урыны, җәмгыять каршындагы җаваплылыгы, буыннар дәвамлылыгы турында уйлана, заманның әхлакый, рухи, иҗтимагый күренешләренә, үзгәрешләренә үзенең фәлсәфи һәм гражданлык мөнәсәбәтен белдерә. Гомумән, халыкның тарихи үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге, кеше һәм табигать, аларның үзара бәйләнешы — шагыйрь иҗатында үзәк темалардан санала...»

Бу бәяләмәнең конкрет авторы кемдер, әмма төпле әйтелгән. Шагыйрьнең тоткан юлы, кредосы бүген дә шул. Бу Олы Юлдан баручы юлчы-мосафир гына бераз үзгәргән: гайрәтле ир-егеттән хәзер инде ул халык гамен күңеленә җыйган ил агасы-хәким-аксакалга әверелгән... Күп ил-җирләр күрелгән; дөнья тоткасы саналган күпме асыл затлар белән очрашылган, әңгәмә корылган; мәңгелек һәм беркөнлек кануннар турында күпме уйланылган; максат-идеяләрнең дөреслеген кат-кат исбатларга тырышылган... Һәм иң мөһиме: кайда гына, нинди вазифада булынса да өзлексез язылган, иҗат ителгән.

Бүгенге Ренат Харис — төрле телләрдә чыккан утызлап китап авторы, Республиканың М.Җәлил премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Каракалпакстанның мәдәният хезмәткәре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Төрле жанрларда уңышлы эшләрлек сәләте булса да (матбугатта чыккан беренче язмалары тәнкыйть мәкаләләре иде), Ренат гомер буе шигырь язды. Тезмә әсәрдә булган бөтен мөмкинлекләрне файдаланып, бөтен форма-төрләрен сынап карады. Озын шигырь, кыска шигырь, сонет, баллада, хикәят, либретто... һәм поэма. Поэмаларны күп язды шагыйрь. Утызлап бар бугай. Төрле рухтагылар: һәм лирик, һәм патетик, һәм эротик, һәм публицистик. Менә кайберләренең исемнәре: «Мулланур», «Камил Якуб», «Рәссам», «Җәлилчеләр», «1972 ел икмәге», «Ат иярләү», «Ант суы», «Өч үбешү», «Гармунчы», «Сәйдәш яры», «Борылышта», «Чехов базары», «Идегәй», «Бүре күзе»... Күп бит! Композитор өчен симфония язу нинди зур фундаменталь хезмәт саналса, шагыйрь өчен поэма да шуңа тиң. Бүгенге шигърияттә шулай күпсанлы поэмалар язучылар сирәк. (Дөрес, бу жанрда да зур активлык белән эшләүчеләр бар. Мәсәлән, үзләре әйтүе буенча, И.Юзеев — утызлап, Ә.Рәшитов — унлап, Ф.Гыйззәтуллина дистәдән артык поэма язган. Тик аларның һәрберсе дә поэма микән соң? Бу хакта байтак бәхәсләр булса да, жанр күпләр—һәм шагыйрьләр, һәм укучылар өчен һаман ачыкланмаган булып кала бирә.) Заманында поэма сымак берничә озын

нәрсә язган булсам да, бу жанрның чын хасияте, бу очракта, шагыйрьнең әсәрләре турында төпле сүз әйтеп, объектив бәяләмә бирә алмам. Бу эшкә көчем дә, вакытым да җитмәс. Махсус өйрәнүне сорый торган зур мәсьәлә. Каләмдәш хезмәтенә сокланырга һәм яхшы мәгънәдә көнләшергә генә кала.

Шагыйрьне җырлары буенча да яхшы беләләр. Аның сүзләренә йөзләп көй язылган. Арада менә дигән җырлар бар. Шулай булмый ни! — байтак еллар татарның иң талантлы композиторлары белән хезмәттәшлек итте бит ул. Н.Җиһанов, Р.Яхин, А. Монасыйпов, Р.Еникиев, Ф.Әхмәтов... Чагыштырмача яшьрәк буын вәкиле Резеда Ахиярова белән иҗади дуслыгы бигрәк тә нәтиҗәле булды.

Шагыйрьнең поэзиясе җыр-көйләрдән тыш музыканың катлаулырак сфераларына да үтеп керә алды. Аның либреттолары буенча дүрт оратория язылды. «Кеше» (М.Яруллин), «Казан» (Б.Мөлеков), «Кеше һәм машина» (И.Якупов), «Мулланур» (В.Кожевникова). Үз вакытында алар композиторларның пленум-җыелышларында яңгырап, җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәяләнделәр.

Гомумән, шагыйрьнең иҗаты зур, бай, күпкырлы. Ул «кырлар» сәнгатьнең бүтән төрләре белән дә табигый тоташып китә, икенче төрлерәк әйткәндә, бер зур сәнгать икенче сәнгатьне кузгата, үстерә, ягъни бер-берсенә керешә. Әдәбият-сәнгать тарихында моңа мисаллар бик күп. Ул гына да түгел, аерым бер шагыйрь-иҗатчы аша (зур иҗатчы булса, әлбәттә) тулы бер чорның, бер буынның «кардиограмма»сын күреп була. Алда әйткәнемчә, Р.Харис 60 нчы елларда килгән шагыйрьләр плеядасының күренекле вәкиле. Ирексездән, яшьлекне искә төшереп, бүгенгедән киләчәкне күзалларга тырышып, әлеге буынның әдәбияттагы урыны турында уйланасың. Уйланыр өчен җирлек зур. Язылмады түгел, байтак язылды бу буын турында, алга таба әле күбрәк тә язылыр.

Тарихи закончалыктыр: җәмгыятьтә мәгълүм иҗтимагый шартлар тугач, аренада милли-рухи алгарышны тизләтүгә сәләтле көчләр пәйда була. XX гасырның икенче яртысындагы татар әдәбиятында, бигрәк тә аның шигъриятендә, шундый көч 60 нчы еллар башында килгән бер төркем талантлы шагыйрьләр булды. Кемнәр иде соң алар дип баш ватып торасы юк, исемнәре яхшы мәгълүм: Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гаташ һәм без фәкыйрегез. Шау-шулы төркемнең үзәгендә булмасалар да, бу рәттә Рәшит Әхмәтҗанов, Айдар Хәлим, Кадыйр Сибгатуллин исемнәре дә бар. Хәзер, кырык еллар үткәч, бастырып әйтеп була: көчле булган икән бу буын! Берсе генә дә бит төшеп-югалып калмаган, һәммәсе, кем әйтмешли, үз казыгын каккан, үз биеклеген өйгән, арабыздан иртәрәк китеп барганнары да әдәбият тарихында җуелмас «автограф» — зур иҗади мирас калдырып киткән. Бу буынның иҗат башлангычы елларында — илленче еллар ахырында — татар шигъриятенең хәле шактый мөшкел иде. Чын мәгънәсендәге зур поэзия әсәрләре сирәк. Мәктәп елларында, күңел шигырьгә сусаган чорда, безгә күбрәк мөтәшагыйрьләрнең китапларын (ә китапларны су урынына «эчә» идек!) укырга туры килде. Дөрес, элгәрерәкләрдән Г.Тукай, Һ.Такташ, Ф.Кәрим бар иде. Ә студент елларында без «максималистлар» ул чорда бик күп шагыйрь саналганнар арасыннан С.Хәким, Н.Арсланов, Ә.Давыдов, З.Мансур, С.Батталларның гына кайбер әсәрләрен таный идек. Тик кайберләрен генә! Бездән бер баш өлкәннәрдән И.Юзеев, Г.Афзал, Х.Камалов, Р.Гәрәй, М.Шабаев, Ш.Галиевләр яшьләр арасында популярлашып барсалар да, кызганыч, безнең буын иҗатчылар өчен кумир булып, поэзиядә кискен борылыш, сыйфат яңарышы ясый алмадылар. Өлкән абыйларының бишмәтенә ябышу, дөресрәге, сталинчыл идеология традицияләреннән арына алмау көчле иде булса кирәк. Туфан, Җәлилләр әдәбиятка кайтып кына киләләр иде... Әлбәттә, бу ретропанорама, билгеле бер бәяләмә шул чор өчен. Соңгы 30—40 ел эчендә заманалар нык үзгәрде. Шөкер, уңай якка.

Кемнәр килүенә карамастан, әдәбиятта сыйфатый үзгәрешләр булу котылгысыз иде. Тормыш «көзгесе» — әдәбият тоныкланган яки күзне чагылдырырлык дәрәҗәдә көмешләндерелгән иде. Шул еллардагы шигырь китапларын алып карагыз. Баш өлешендә Ленин, Сталин, партия турында мәдхия куплетлары, аннан хезмәт, бәхетле яшәү рәвеше турында патетик шигырьләр, ахырдарак лирик-мәхәббәт шигырьләре, иң соңыннан әз-мәз юмор-сатира. Олылар шигърияте генә түгел, балалар поэзиясе дә бик нык идеологияләштерелгән иде шул. Тематик яктан грамоталы итеп укмаштырылган шигъри цикллар да сирәк иде (шулай да С.Хәкимнең «Суд залында», Х.Туфанның сайланмаларындагы цикллар хәтердә калган). Хөр фикергә иркен мәйдан булмаудан килгән күренеш. Күрәсең, күпләрнең фәлсәфи-эстетик платформалары, үз принцип-кредолары да анык булмаган. Шигырьнең куплет-шакмак калыбыннан чыгып, ирекле строфалар итеп язу шигырьне «бозу» санала иде, хәтта куплет эчендәге юлбаш хәрефләрне кечкенәдән башлау да гайре табигый кабул ителә иде. Нигездә, партия органнары булган газеталарда фикерле шигырьләрне бастыру үзе бер проблема. Ярый ла елына берничә шигырь бастыра алсаң! Эх, Замана! Үткәнгә бүгенгедән торып, акыллы булып бәя бирү җиңел. Ә үзең шул сугыш, культ тегермәннәрендә «тартылсаң» нишләр идең?

Алтмышынчы еллар буынының элгәргеләрдән бер өстен ягы шул: алар гали белем алып, Шәрык һәм Гареп мәдәниятен ярыйсы ук үзләштереп, үз тарихыбызның моңарчы яшерелгән сәхифәләрен белеп, өйрәнеп, әдәбиятка зур әзерлек белән килделәр, шуңа күрә, беркадәр язу тәҗрибәсе туплангач, тиз арада үз эшенең чын профессионаллары булып җитешә алдылар. Аларның беренче китаплары ук, юка гына булуларына карамастан, эчтәлек ягыннан булсын, җыентыкны тезү-төзү, хәтта иллюстрация-бизәү ягыннан булсын, уңай якка аерылып тордылар.

Ренат Хариска 60 яшь. Шагыйрь өчен аз гомер түгел. Шагыйрьнең олпатлык юбилее. Юбилей димәктән, мин Ренатның теге яки бу зур залларда иҗат кичәләре, юбилей тантаналары үткәргәнен хәтерләмим. Мәһабәт театр биналарында кемнәр генә нинди генә кичәләр уздырмады соңгы елларда. Бер генә түгел, кат-кат, өч-дүрт мәртәбә. Теләсә, Ренат та үткәрә алыр иде. Иҗаты да бар, дәрманы-власте да бар иде. Күрәсең, фейерверклы шау-шуга караганда, сабыр гына язып ятуны мәгъкульрәк күргәндер. Бәлки, алтмыш еллыгы уңаеннан зур кичәләр узар? Узуын телибез, халык алкышлары зур иҗатыңа аваздаш булсын.

Һәр шагыйрь иҗатын төрле кеше төрлечә кабул итә. Р.Харис шигъриятен өнәп үк бетермәүчеләр барлыгын да беләм. Кемнәргәдер Р.Харис поэзиясе салкын, теле моңсыз тоелырга мөмкин. Хәтта «Шигырендә үзеннән дә акыллы булмакчы!» диючеләр дә бардыр. Стиль ул — Кешенең үзе! диләр. Нишлисең, тормышта Харис үзе ничек булса, шигыре дә шул була инде! Әмма беркем дә аның зур фикер иясе шагыйрь икәнен инкяр итмәс. (Сүз уңаеннан Ренатка шуны да әйтәсе килә: татар әдәбияты тәнкыйтен кризис хәленнән чыгаруда өлеш кертергә иде бит! Синеке кебек теоретик әзерлекле, зур тормыш һәм язу тәҗрибәсе булган әдипләр үзләренең фәнни-тәнкыйди хезмәтләре белән активрак катнашсалар, әдәбияттагы хаос кими, иҗади атмосфера савыга төшәр иде. Шигырьдәгегә караганда тәнкыйтьтә идеолог булу, отышлырактыр, бәлки.) Талантлар төрле була һәм аның һәрберсе ихтирамга лаек. Бездә артык шагыйрьләр юк. Максатлар бер булганда, һәркем үзенең кирәк урынында. Милләт, ил язмышы хәл ителә торган гасырда «Татар акыллары, татар шагыйрьләре, җыелыгыз!» дип кычкырасы килә. «Каруман» җырындагы «заманалар авыр, еллар ябык» дигән сүзләр көннән-көн актуальрәк яңгырый...

Әтисе Мәгъсум (шөкер, ул әле исән-сау!) сугышка алынганда, нәни Ренатка берничә ай гына була. Ата кеше сабыеның бердәнбер фоторәсемен үзе белән ала, фронтлар буйлап күкрәк кесәсендә йөртә. «Шушы сабый хакына исән үттем сугыш мәхшәрен»,— ди Мәгъсум ага. Әнә шул сабый хәзер булдыклы ир, алтмыш яшьлек олпат шагыйрь булып XXI гасырга аяк басты. «Яшим, эшлим, раслыйм!» дип иҗат итә ул.

*2001, март*

## НУРЛЫ ҺӘМ МОҢЛЫ ШИГЫРЬЛӘР

Сөйләм телендә «тәмле телле керәшен» дигән сүз бар. Ярым шаярып, ярым чынлап әйтелә торган бу сүзнең тәгаен дөреслегенә керешмим, әмма бу эпитет Гәрәй Рәхимгә, паспорттагы исеме белән атасак — Родионов Григорий Васильевичка бик тә туры килә. Кешеләр белән бик тиз үзләшеп китә алуы, эчкерсезлеге һәм беркатлылыкка якын самимилеге, шул ук вакытта шук табигатьле, җор күңелле булуы, йомшаклыгы белән әдәбият кешеләре төркемендә ул аерым бер урында тора. Иҗат — кеше күңеле көзгесе, шулай булгач, табигый, әлеге асыл сыйфатлар аның әсәрләрендә дә ярылып ята. Киң катлам әдәбият сөючеләргә Гәрәй Рәхимнең лирик пландагы уйчан шагыйрь һәм прозаик булып танылуы бер дә гаҗәп түгел.

Гәрәй Рәхим дигән исемнең матбугатта күренә башлавына да инде егерме елга якын. Зур әдәбият мәйданына килеп, җиң сызганып эшли башлавына да унбиш еллап булыр. Шушы вакыт эчендә аның уннан артык китабы дөнья күрде. Ул иң әүвәл үзен шагыйрь итеп танытты, аннары берничә повесть чыгарып, проза язарга да сәләтле икәнен күрсәтте, балалар әдәбияты өлкәсендә дә уңышлы эшли алуын белдерде. Шуңа өстәп ул, скетч, кыска пьесалар, интермедияләр, либреттолар иҗат итеп, сәхнәдән башкарыла торган әсәрләр язуда да шактый оста икәнен раслады. Болар һәммәсе әдипнең иҗат интереслары киң, потенциаль мөмкинлекләре зур, хыял-максатларының олыдан булуы турында сөйли.

Табигый, Гәрәй Рәхим миңа шагыйрь буларак якынрак, аның бу юнәлештәге хезмәте турында фикер йөртүе дә җиңелрәк. Г. Рәхимне шагыйрь итеп тулырак күз алдына китерерлек китап ул «Моңнарым» дип исемләнгән сайланма шигырьләр китабы. Бу җыентык турында матбугатта уңай фикерләр булгалады да инде.

«Моңнарым» — полиграфик басма буларак, ике йөзләп битле, җиде бүлекле, ике йөзләп шигырь туплаган гадәти бер китап. Ә инде сайланма җыентыкның мәгънәви йөге, иҗтимагый әһәмияте, шигъри хәзинәбездәге урыны хакында уйлап карасаң, шактый ук гыйбрәтле һәм уйландыра торган яхшы китап булып чыккан ул. «Моңнарым» — 60 нчы еллар башында әдәбиятка килгән бер төркем шагыйрьләрнең иҗат кредоларын, иҗтимагый һәм эстетик идеалларын беркадәр, — бу очракта бер

вәкиленең күңел призмасы аша, — чагылдырган китап. Безнең буын иҗат кешесенең омтылышлары, теләк-хыяллары, сөю-янулары... Безнең буын дигәнем — үсмер егетлектән ир булып чыныгу дәверен, яшьлекнең иң асыл һәм көчле чагын 60—70 нче елларда кичергән, сугыш чоры тирәләрендә туып, хәзер инде яшьләре белән кырык ягына авышкан кешеләр. Ил тормышындагы рухи үзгәрешләргә бәйле рәвештә, бу буынның шәхес, гражданин һәм шагыйрь буларак формалашуы гаять кызык, гыйбрәтле, ихтимал, үзе бер кабатланмас күренештер. Шагыйрьнең «Буыннар елъязмасы» дигән шигыренең исеме дә очраклы түгел, ул шигырь атамасыннан тыш киңрәк мәгънәгә ия шикелле. Кыскасы, «Моңнарым» — әнә шул буынның рухи халәтен шактый тулы ачып бирә алган китап. Әйдәгез, махсус сайлап тормыйча, кайбер шигырь юлларын гына укып китик: «Заманага лаек җырлар эзләп йөрәкләрдән кайчан каннар тама...», «Тизрәк булыш, шигырем, чүп сүзләрдән арынырга бөек бу чорга...», «Мин бит тамыр! Миңа бар дөньяга күрсәтергә кирәк чәчәк көчен...», «Кайгыларны тоям, тик бирешмим, таныйм бары шатлык хакыйкатен!», «Мин ашкынам тизрәк кешеләргә кыңгыраулар чыңы илтергә...», «Кинәт шундый якты җөмлә туа — чаткылары чәчри йолдызга!», «Барган саен минем юл өстемә эткәй кабере калкып чыга һаман...», «Мин яратам, ахры, бу дөньяны җанда матур яра булганга...», «Мин сокланам синең иҗатыңа, синең иҗат — минем мәхәббәтем», «Тормыш төялгән бу Җир шарында сагышны шатлык җиңәргә тиеш!»...

Чордашы буларак, мин Гәрәй Рәхимне егерме еллап беләм. Байтак шигырьләренең биографияләре миңа таныш. Шигъри актның ни икәнен шагыйрь фәкать үзе генә белсә дә, бик күп шигырьләренең кайда, ничек, нинди халәттә туганына шаһитмын. Университет тулай торагының кысан бүлмәләре, кылганлы Федотовка таулыклары, Мәскәү бульварлары, акчарлаклы Идел буйлары, Ай-Петриле Кара диңгез ярлары... Күңеленең шатлыктан ташкан чаклары, сыкранган, өзгәләнгән мизгелләре, гайрәтле һәм көчле минутлары, ялгызлыкның сагышлы сәгатьләре... Менә аның университетка укырга кергән, зур шәһәргә яңа аяк баскан, өмет-хыялларның гаять көчле чагында язган шигырьләре: «Көзге урман», «Буыннар елъязмасы», «Миләш төбендә», «Язга алдану», «Болыннарны атлар табырлаган»... Менә аның үз буыны иҗат платформасына тугрылыклы булырга тырышып, үз рухын һәм стилен расларга теләп, үҗәтләнеп һәм гайрәтләнеп язган шигырьләре: «Рас!», «Игеннәр илендә», «Рәхмәт, нәфрәт!», «Сагыш һәм шатлык», «Чакыру», «Әниләр зары», «Вөгъдә», «Ә буш кырда буран дулады»... Менә аның дөнья әдәбиятының асыл җәүһәрләре белән танышып, аларны тоеп, аңлап, үз язганнарын классик үрнәкләр белән чагыштырып, кылган эшенә һәм мөмкинлекләренә аеграк карап, беркадәр моңсуланыбрак, кырыс хакыйкать белән исәпләшебрәк язылган шигырьләре: «Малайлыктан уздык бугай инде», «Ун чуртан», «Димәк...», «Китмә!», «Авылдаш картларга», «Тарихта күпме башкисәр кеше», «Сагышланма», «Елагыз!», «Бүләк», «Юл уңаенда»...

Сәер хәл: шагыйрьнең үзен күбрәк белгән саен, иҗатын аның кеше буларак яшәү рәвешеннән аерып карау, рухының Матурлык һәм Кешелеклелек мирасына керердәй өлешен аралап күрә алу кыенрак. Үзе күп тапкыр күрелгән, сыналган, язганнары күп тапкыр укылган, тыңланган... Ә икенче шул яхшы ягы бар — инанган ул бәяң объектив бәягә шактый ук якын да була. Чөнки авторның кайсы шигыре «ни бәһа» икәнлеге сиңа яхшы билгеле. Кайсы «көнем» өчен язылган шигырь дә, кайсы җан бәясе торырлык шигырь... Минем үземә «Моңнарым» китабына кергән ике төр шигырьләр аеруча кадерле: беренчеләре — туган туфракка һәм аның кешеләренә бәйле шигырьләр, икенчеләре — мәхәббәт турындагылар. Беренче төр шигырьләрдә шагыйрьнең ил ире буларак кылган гамәле һәм иҗтимагый зурлыгы билгеләнсә, икенче төр шигырьләре аша шагыйрьнең җир баласы буларак яшәү шатлыгын һәм ләззәтен аңлау дәрәҗәсен чамалап була. Мөгаен, китапта җиде бүлеккә сибелгән тагын байтак шигырьләрне дә шушы шигырьләр төркеме тирәсенә җыярга мөмкин булыр иде. Әйтелгән ике төр шигырьләрдән берәр генә мисал китереп узыйк.

Мин авылга кайткач, ялгыз гына
Чыгамын да ындыр артына,
Каралтылар ышыгына кереп,
Тынып калам...
Һәм елыйм мин. Ялгыз рәхәтлектән,
Сабый чаклар хатирәсеннән.
Каралтылар белән бергә елыйм,
Үксеп-үксеп елыйм һәм көләм...
«Мин бит бары синең өчен генә
Бу дөньяга яратылган кеше.
Син соклансын өчен чәчәк итеп
Киң болынга таратылган кеше».

Һәр әсәр, әдәби әсәрме яки бүтән төр сәнгать әсәреме ул, Җирдә хаклыкны раслау белән бергә, кешеләрдә, гомумән, яшәештә Матурлык тойгысы арттырырга тиеш. Безнең эштә шигърияттә бу максатка бүтән чаралар белән бергә фикер хәрәкәте үзенчәлеге белән, фикер кардиограммасы үзгәлеге белән дә ирешеп була. Фикерләү ысуллары, фикерләү формалары... Гәрәй Рәхим — халык поэ-

тикасын, бигрәк тә үзе туып үскән керәшен авыллары тирәләрендәге халык сөйләмен, аның авыз иҗатын яхшы үзләштергән әдип. Бу нәрсә аның иҗатына әйбәт мәгънәдә үзгә төсмерләр өсти. Ул укып белем алуы һәм яшәү рәвеше белән традицион татар шигърияте үрнәкләрендә тәрбияләнсә дә, барыбер әлеге борынгы тамыр үзенең тибешен сиздереп тора. Бусы, минемчә, бик яхшы. Әйтик, чагыштырмача бер дәвердә яшәгән Акмулла белән керәшен шагыйре Яков Емельянов бер-берсеннән бик нык аерылып торсалар да, гомумпоэзия күзлегеннән караганда, һәркайсы үзенең кирәкле урынында. Үз халкының поэтик мирасын һәм фикерләү формаларын үзләштерүгә җитди караган шагыйрь, һичшиксез, алга таба безне яңа табышлар белән сөендерер әле.

«Моңнарым» китабын әдәби җәмәгатьчелек һәм киң катлам укучылар яратып кабул итте. Бу китапка кергән байтак шигырьләр, җырлар халык арасында популяр булып китте. Китапка кергән кайбер шигырьләр рус теленә тәрҗемә ителеп, үзәк матбугат битләрендә басылды, кайберләре шагыйрьнең рус телендә чыккан «Цветочная калитка» китабына керде, хәтта бер ишеләре Мәскәүдә чыга торган «Советская литература» журналы аша Европа телләрендә дә дөнья күрде... Чын шигърият, чын фикер һәм чын хис, канатлары булгач, ерак күкләр биеклекләрендә дә оча ала шул. Гәрәй Рәхим — инде урта дип йөртелә торган буынның талантлы бер вәкиле, әдәбият эшенә бөтен барлыгын биреп хезмәт итәргә алынган әдип. Аның «Китмә» дип исемләнгән менә бу шигыре фикерне тагын бер мәртәбә раслый шикелле.

...Менә мин дә дөмә ятим калдым,
Әнкәйне дә кайттык без җирләп.
Әткәй-әнкәй булып тик син калдың,
Ятим итмә мине, Шигърият!
Катлаулы бу тормыш.
Дуслар мәңге
Ташламаслар димә син төбәп.
Соңгы дусым ташлап киткәндә дә,
Ташлап китмә мине, Шигърият!
Чоңгылларсыз гына булмый чорлар.
Сыналулар бетми ул, димәк.
Чорлар ялгыш биткә төкерсә дә,
Төкермә син биткә, Шигърият!
Беркөн мине үлем алып китәр.
(Белмим, шагыйрь аңа ник кирәк?)
Тик ул чакта китмә минем белән,
Бу дөньяда кал син, Шигърият!

*1980, сентябрь*

## «МӘХӘББӘТКӘ — МӘРХӘМӘТ»

Без — ул вакытта шагыйрь булырга, әдәбиятка, халыкка хезмәт итәргә ашкынып торучы бер төркем студент яшьләр — бүгенгебезне алтмышынчы еллар түреннән ничегрәк күз алдына китергәнбез икән? Ул чакта максат ноктасы биегрәк, хыял канатлары киңрәк иде бугай. Беренче китап чыгарырга дәртләнеп йөргән көннәрдән соң да инде егерме биш еллап гомер үткән. Телисең-теләмисеңме менгән үрләреңнән күренгән офыкларыңа карап уйланырга кала. Иҗат юлын бер чордарак башлаган чордашларымның күбесе инде кырык бишләрне узып, илле ягына авышты. Еллар заяга үтте дип әйтеп булмый, шул чорда һәркайсы 5—6 яки 10—15 китап чыгарды, укучылар күңеленә юл ярды, әдәбиятта үз урынын табарга тырышты. Р. Харис, Г. Рәхим, Р. Мингалимов, Р. Гатауллин, моңарчы тәнкыйть классификациясендә аерымрак саналып йөргән Рәшит Әхмәтҗанов, К. Сибгатуллин, Ш. Маннапов, Ә. Гадел кебек шагыйрьләрне күздә тотып әйтәм моны. Кайберәүләренең инде «Шигырь китапханәсе» дигән сериядә сайланма томлыклары да дөнья күрде. «Шигырь китапханәсе», Тукай, Такташ, Кәрим, Җәлил, Хәкимнәр чыккан басма, шагыйрь хәзинәсендәге иң яхшы әсәрләр керә торган җитди басма. (Кайберәүләр туган көн яки бүтән шәхси бәйрәмнәрдә истәлек бүләге эзләп аптырыйлар: халык тарихына, китапка мәхәббәте булган кеше өчен бу сериядә чыккан тупланмалар, халкыбызның өч томлык аңлатмалы сүзлеге яки халык иҗаты әсәрләр җәүһәрләрен туплаган күптомлыклар менә дигән бүләк бит!)

Быел шушы «Шигырь китапханәсе» сериясендә замандашларым, ике сабакташымның сайланмалары дөнья күрде. Берсе — Рөстәм Мингалимовныкы, икенчесе — Рәдиф Гатауллинныкы. Илле яше тулу уңае белән Р. Мингалимов иҗаты турында матбугатта бераз сүз булып алды бу арада. Бу юлы сүзем икенче китап — Рәдиф Гатауллинның «Мәхәббәткә — мәрхәмәт» дигән китабы турында.

Шигырьләр, җырлар, поэмалар җыйнамасы дип бирелгән бу 320 битлек китап 2400 данәдә, күрер күзгә матур итеп, супертыш белән чыгарылган. Шагыйрь иҗаты турындагы кереш сүзне Зөлфәт язган. Автор үзе дә, бу олы хезмәткә зур җаваплылык белән килеп, һәм эчтәлек ягыннан булсын,

һәм форма-композиция ягыннан булсын, эффектлырак итеп төзергә, иҗатының төрле кырларын мөмкин кадәр аныграк һәм калкурак итеп күрсәтергә тырышкан. Исемнәре үк шигъри яңгырап торган унөч бүлек бар китапта. «Гөлләр су сорый», «Егерме дүрт йолдыз һәм унҗиде диңгез», «Арыш дулкынлана», «Күңелдә ике яз», «Бөекләр язган хатлардан», «Нигез сагындырса», «Европада татар шагыйрьләре», «Ватандар моң» һ.б. Болар очраклы исемнәр түгел, мәгънәләрен саклаган хәлдә, алар әсәрләрнең язылу елларын, хроникасын да билгели. Әйтик, «Гөлләр су сорый» авторның 60 нчы еллар уртасында чыгарган беренче китабы иде. «Күңелдә ике яз» җыры 70 нче еллар ядкәре...

Сайланмага кергән шигырьләрнең күбесе таныш. Бергә яшәп иҗат иткән елларның ташка баскан билгеләре алар. Кайбер шигырьләр университеттагы әдәби түгәрәк елларын искә төшерә, кайберләре хатлар алышып торган еллар турында уйлата, кайберләре соңгы ун-унбиш елда булып үткән әдәби мохит хәлләрен хәтерләтә... Хәер, болары шәхсирәк кичерешләр. Ә әдәби хәрәкәт — иҗтимагый күренеш. Һәр иҗатчы халык тарихына, аның гасырлар буена чарланып киленгән эстетик идеалына, киләчәгенә барырлык хәзинә-өлеш белән билгеләнергә тиештер.

Иң әүвәл шунысын ачыклап үтәргә кирәк: Рәдиф Гатауллин — лирик рухлы романтик шәхес. Романтика хәзерге заманда садәлек, эчкерсезлек кебек дефицитрак сыйфат, прагматик акыллылар күзлегеннән караганда, хәтта наив, беркатлы сыйфат. Рәдиф Гатауллин, үзе танып белгән шушы катлаулы һәм тынгысыз дөньяны күңел призмасы аша үткәреп, фикердәшләр эзләп, шигырьләрен кешеләргә юллый. Кыйбласы — гуманизм, кешелеклелек. Чыннан да, үзе әйткәнчә, «юк, шагыйрьгә килешмидер һәм шик, ачу уйны җырда калкыту». Миңа калса, Рәдиф Гатауллинның язганнарын берничә чорга бүлеп карарга мөмкин. Туган ягына бәйле үсмер еллары, университетта, соңрак Үрәзмәт мәктәбендә укыткан еллары һәм Казанга төпләнеп, нәшрият, редакцияләр белән бәйле еллары. Иҗат чыганаклары — яшьлек еллары хатирәләре, илләр буйлап сәяхәтләрдән алган тәэсирләр, дөньяви классик мирас тупланган китап хәзинәсе.

Кемгә ничектер, миңа Рәдифнең башлангыч чорда иҗат ителгән шигырьләре күбрәк ошый. Такташлар кебек зур шагыйрь булырга ымсыну бар аңарда. Аның «Шагыйрь тавышын бер кат ишетмәгән, ләкин гүя иң якын танышым» дип, «Такташ тавышы» дигән шигырендә язып чыгуы да очраклы түгелдер. «Кое», «Кыз җавабы», «Чакыру» кебек шигырьләр әле хәзер дә бик самими һәм тәэсирле яңгырыйлар. Алар табигать баласының табигый хисләре. Табигатьнең үзендәге кебек гармония бар аларда. Хис һәм фикер гармониясе. Шуңа күрә дә 60 нчы еллар урталарында ук Рәдиф Гатауллин үзенең укучылары, бигрәк тә яшьләр арасында үзенең тарафдарларын таба алды. Өстәвенә үзе дә халык алдында еш чыгыш ясый, шигырьләрен үзенә генә хас осталык белән тәэсирле итеп укый, үзенекен генә түгел, классик яки бүтән яшьтәш шагыйрьләрнең дә әллә никадәр шигырьләрен яттан сөйләп бирә...

Әлбәттә, бүгенге поэзиядә Рәдиф Гатауллин дигән исемне басылып чыккан китаплары яулап бирде аңа. 1966 елдан башлап хәзергәчә аның уналты китабы чыкты. Татарча, русча китапларының гомумданәләрен исәпләсәң, җитмеш меңнән артык булыр. Элегрәк басылган китапларны искә төшерүем шуның өчен, чөнки бу сайланмада аларның һәммәсеннән иң яхшы дигән үрнәкләр теркәлгән. Китап, бигрәк тә сайланма китап — шагыйрь йөрәгенең кардиограммасы. Күңелнең һәр тирбәнеше ярылып ята. Әйе, Рәдиф үзебезнең шигъри мирасны, классик поэзияне яхшы белә. Моны без аның «Бабич», «Йөзүчеләр» кебек озын шигырьләрендә, Һейне, Бернс, Китстан, Элюар, Нәсими кебек мәшһүр шагыйрьләрдән тәрҗемә үрнәкләрендә күрә алабыз. Әйе, әйткәнебезчә, Рәдифтә лирик башлангыч көчле. Моны аның халык арасында таралган «Күңелемдә ике яз», «Язгы ташу», «Безнең җыр» кебек җырлар аша яхшы тоябыз. Ә инде «Уел», «Сәлам», «Маңкортлар», «Европада татар шагыйрьләре» кебек шигырьләрен укып, без аның халык язмышы, тел, җыр-көй, шигърият язмышы өчен борчылуын аңларбыз.

Әйткәнемчә, китап шактый калын, аны актара-актара, бүлекләрдән бүлекләргә күчә-күчә, алган тәэсирләр дә, шигырьләргә карап, үзгәреш кичерә. Яхшы шигырьләр белән бергә, күңел һәм аң кабул ук итмәгән строфалар яки тулы-тулы битләр очрый да, авторга киңәш йөзеннән кайбер фикерләрне әйтү теләге дә уяна. Иң күзгә ташланганы — фикри җегәре булмаган сүзләрнең күплеге, һәр әдәби әсәрдә, шигырьдә бигрәк тә, һәр сүзнең, техник термин белән әйтсәк, файдалы эш коэффициенты югары булырга тиеш. Каян килә күпсүзлелек? Юкса бит Рәдиф — әдәби белемгә, эрудициягә, поэтик культурага ия кеше. Сәбәпләре, бәлкем, тармаклыдыр; минемчә, шуларның берсе — формада, дөресрәге, формасызлыкта, иҗатының башлангыч чорында алынган юлыннан тайпылуында. Ачыграк итеп әйтсәк, халык иҗаты, халык поэтикасы нигезендә үз йөзен таба башлаган шагыйрь, еллар уза төшкәч, модага, шау-шуга иярепме, иркле формалар белән мавыга башлады. Иркле шигырь ул — һәр конкрет фикернең һәм сурәтнең кабатланмас калыбы. Иркле шигырьдә, гадәттә, фикер гегемонлык итә. Хис өстенлек алган шагыйрь өчен ул форма бик кулай булмаска да мөмкин. Миңа калса, иркле форма Рәдиф Гатауллинга, табышлардан бигрәк, шигъри таркаулык һәм күпсүзлелек китерде. Юкса шигырь дип тәкъдим ителгән төрле мөрәҗәгатьләр, хатлар, багышламалар сәяхәт көндәлекләрендәге фикерләр, гап-гади озын юллар белән язылган публицистик прозага да кереп

бетә алырлар иде. Шагыйрь үзе дә бу хакта уйлана, күрәсең. «Әнкәй белән мәңгелек сөйләшү» дигән шигырьдә мондый юллар бар: «Әнкәй, чакыр мине, һаман чакыр моңга... Кайтар һаман асылыма!» Эчке үзгәреш аның соңгы елларда язган шигырьләрендә дә сизелә. Китапның «Ватандар моң» дип исемләнгән бүлеккә кергән «Кара да гына урман уртасында», «Былбылга эндәшү», «Әтисезлек...», «Юк, ятимлек димим»... кебек шигырьләре шуны күрсәтә.

Белдереп үтәргә кирәк нәрсәләрнең тагын берсе шул: китапта өндәүләр, бигрәк тә сораулар бихисап күп. Ир уртасындагы кеше күп сорауларга үзе җавап та бирә алырга тиештер бит. Әдәби Хәятыбыздагы кайбер хәлләр, шәхси мөнәсәбәт, интереслар турында да шигырьләр чыгару мәҗбүри түгелдер. Андый язмалар да җитәрлек китапта. Шулай ук Рәдиф тәнкыйтьчеләрнең аның китапларына дөнья классикасы хәзинәсеннән кергән рух — төрле геройлар, исемнәр, мифлар һәм башкаларның артыграк булуы турында әйткәннәрен дә исеннән чыгармасын иде.

Ярый, теләкләрне шушында туктатып торыйк. Үзе әйтмешли, «ирләр булыйк!». Әйткәннәрем дә җитешсезлек эзләүдән түгел, шагыйрьләр булыйк, һәрхәлдә, шуңа омтылыйк, диюем. Рәдиф Гатауллин — Татарстан Язучылар союзы каршындагы поэзия секциясенең җитәкчесе, «Казан утлары» журналында поэзия бүлеге мөдире, шигъри хуҗалыгыбызга турыдан-туры җаваплы кеше. Бу миссия аңа үз иҗатына үтә таләпчән булуын сорый.

Әйе, без моннан егерме биш еллар элек тормышта бергә аралашкан кебек, калын китапларыбыз да китап киштәләрендә янәшә торыр дип уйладык микән? Уйлаган булсак, күбебезнең ул хыяллар чынга ашты. Язмышка, тормышка, шул китапларны чыгарган кешеләргә рәхмәтле дә була белик. (Җаяләр эчендә генә әйтеп узыйк: андый сериядә чыккан китапларның һәм күләме, һәм тиражы, һәм полиграфик сыйфаты бертөсле булырга тиеш, юкса кайчак кешесенә, дәрәҗәсенә, урындыгына карап, кайсыбер китапларны юка, кайберләрен кирпеч кебек калын итеп чыгару гадәте дә бар.) Шулай итеп, Татарстан китап нәшрияты быел ике шагыйребезнең сайланма томлыкларын чыгарды. Шуларның берсе без югарыда сүз алып барган Рәдиф Гатауллинның «Мәхәббәткә — мәрхәмәт» китабы. Хәзер шигырь сөючеләр, шушы китапны укып, каләмдәшебезнең тулы бер иҗаты турында фикер йөртә ала. Без аларның мәхәббәткә генә түгел, шигърияткә дә мәрхәмәтле булуын телибез. Чөнки бу сериядә китап чыгарырга әзер шагыйрьләребез әле байтак безнең.

*1987*

## ЗАМАНА ЯЗУЧЫСЫ

Рауль Мирхәйдәров... Кем ул? Татар укучысы беләме, таныймы аны? Сорауга җавап шул: аз белә. Хәтта язучыларыбызның да шактые аны укып түгел, ишетсә ишетеп кенә беләдер. Хәбәрдарларның берәүләренә ул — мавыктыргыч сюжетка корылган детектив романнар авторы, берәүләренә — хакимиятнең теләсә нинди югары даирәләрендә үз була алган супершома замана егете, берәүләренә — дөньяны чолгап алган җинаятьчел коррупция кармавычларын аяусыз кисеп торучы куркусыз шәхес. Ни генә димәсеннәр, ул — иң әүвәл безнең милләт баласы, рус телендә иҗат итүче татар язучысы. Тормыш кредосы, иҗат принциплары, эстетик карашлары турында фикер йөртер өчен язучы үткән тормыш юлын бераз гына булса да шәрехләү кирәк.

Рауль Мирсәет улы Мирхәйдәров 1941 елда Казакъстанның Актүбә өлкәсендәге Мартук поселогында туа. Үзе әйтүе буенча, аның әти-әнисе чыгышлары белән Оренбург ягыннан.

Раульнең үсмер-яшьлек еллары Актүбә шәһәрендә үтә. Ул биредә 1960 елны тимер-юл техникумын тәмамлый. Соңрак төзүче-инженер була. Егерме еллап төзүче булып (прораб, участок начальнигы һ.б.) эшләү дәверендә аңа Советлар Союзының бик күп республикаларында, йөзләгән шәһәрләрендә булырга туры килә. Ир-егет чагында ике дистәдән артык ел Ташкентта яши. 30 яшендә «Полустанок Самсона» дигән беренче хикәясен яза һәм ул Мәскәүдәге «Родники» дигән альманахта басылып чыга. 1975 елда Р.Мирхәйдәров Яшь язучыларның бөтенсоюз киңәшмәсенә чакырыла һәм тиздән, «Молодая гвардия» нәшриятында «Оренбургский платок» исемле китабы дөнья күргәч, ул СССР Язучылар союзына кабул ителә. Кырык яшеннән Рауль Мирхәйдәров төзелеш эшеннән китә һәм гомерен тулысынча әдәби иҗатка багышлый. Ул бүгенге көндә дистәләгән китаплар авторы. Әсәрләре чит ил телләрендә һәм СССР халыклары (казакъ, үзбәк, грузин, татар, каракалпак) телләрендә күп тапкырлар тәрҗемә ителеп басыла. Хәзерге вакытта Мәскәүдә яши.

Болар — Р.Мирхәйдәров биографиясенең кайбер штрихлары. Укучылар беркадәр мәгълүмат алсын дип язуым. Гадәти биография. Раульнекенә караганда әллә нинди катлаулы, әллә нинди маҗаралы язмышлар бихисап бу дөньяда... Әмма ни гаҗәп — тормышта, әдәбиятта Рауль Мирхәйдәров феномены бар! Болай әйтерлек нигез бар. Беренчедән, ул — гаҗәп күп һәм нәтиҗәле эшли торган язучы. Һәр ел саен диярлек аның берәр калын романы басылып чыгып тора! (Язылып кына түгел, басылып!) «Пешие прогулки» (1988), «Двойник китайского императора» (1989), «Судить буду я» (1990) һ.б. Кемнәрдер бер-ике табаклык китабын дистә еллар чыгара алмый изаланган заманда бит бу! Икенчедән, аның романнары миллионлаган (!) данәләр белән нәшер ителә (танылган прозаикларыбызның әсәрләре 3—5 мең тираж белән чыга хәзер). Өченчедән,

махсус филологик һәм әдәби белеме булмаган төзүче-инженер яза бу китапларны. Өстәвенә язу белән дә утыздан ашкач кына шөгыльләнә башлаган, нульдән...

Уйланырлык. Бу арада Р.Мирхәйдәровның романнарын җентекләп укып чыктым. Төрле уйларга этәрде алар. Кая бара дөнья? Киләчәктә әдәбият нишләр? Татар язучысының хәле ничек булыр? Тукай-Дәрдемәндләрне, Такташ-Җәлилләрне, Туфан-Хәкимнәрне, Юзәй-Шәүкәтләрне, Мөдәррис-Харисларны кемнәр укыр? Китапларыбызның тиражлары аз, укучылары сирәк... Ә менә Мирхәйдәров китапларын укыйлар. Русча әйткәндә, спрос бар. Хикмәт фәлән телдә язуда гына түгел. Әнә рус классикларының китапларына да бик ябышып ятмыйлар хәзер...

Сер нәрсәдә соң? Моңа төгәл җавабым юк. Фаразлый гына алам. Миңа калса, Р.Мирхәйдәров без шаһитлары булган бүгенге җәмгыятьнең, системаның, идарәчеләрнең яшәү рәвешен, кылган һәм кылырга теләгән гамәлләрен ниндидер бер эчке сиземләү белән, рентген аша карагандай, ачык күрә, тоя, үлчи, бәяли. Ә җәмгыять, беләсез, бөтен организмы белән диярлек җинаятьчел вируслар белән агулы. Замана каһарманнары (әллә имгәкләре?) без күрергә теләгән идеалларның капма-каршылары булып чыкты. Оешкан җинаятьчелекнең хакимияттәге югары түрәләр белән үрелеп берегүе, бик күпләр өчен акчаның иманга әйләнүе, рухи кыйммәтләрнең очсызланып кадерсезләнеп бетүе, бөтен нәрсә диярлек сатыла-сатылынила алынуы — һәммәбез күз алдында. Р.Мирхәйдәров романнарындагы персонажлар менә шушы вазгыятьнең авансценасында төп рольләрне уйнаучы геройлар. Тәрбиябез буенча без күрергә теләгән хәләл хезмәт геройлары түгел, ә акыл-хәйлә, янау-үтерү белән дөнья кендеген тотучы яңа геройлар — Артур Шубариннар...

Р.Мирхәйдәров үз әсәрләрендә, теләсә — «законлы бур», теләсә — генпрокурор, теләсә «төнге күбәләк» булып табигый сөйләшә ала! Бу — профессиональ осталык. Ул моңа ничек ирешкән? — монысы минем өчен чыннан да сер.

Дөресен әйтим: Р.Мирхәйдәров әсәрләрен укыганда, гел ләззәтле генә хисләр кичермәдем мин. Ят дөнья. Ят гамәл-кыланмышлар. Без кинода гына күргән зур акчалар дөньясы. Психологик яктан аңлап бетермәгән йә аңларга теләмәгән нәрсәләр күп. Күрәсең, заманына күрә алынган тәрбия һәм дә өстәп үткән гомер консерватизмы үз хасиятен башкара булса кирәк. Әмма нишлик? — күңелең белән кабул итмисең, акылың белән килешергә мәҗбүрсең. Йә без артта калган, йә тегеләр бик «алга» киткән. Язучы «чырайсызлар» заманының чыраен дөрес күрсәтә. Каләм сукасы, эчке буразна эченә төшеп, шәп ерып бара... Гыйбрәт алу, нәтиҗәләр ясау — укучылар эше... Шунысы да бар: Р.Мирхәйдәров — бу җинаятьчел дөньяның елъязмачысыннан бигрәк, аның тикшерү-өйрәнүчесе... Бу бик мөһим момент: язучының социаль аналитик булуы зур нәрсә. Тормыш, дөньябыз ничек? — аның чагылышы безнең күзләрдә, идеалларда, җырларда, әсәрләрдә. Р.Мирхәйдәровтан, бәлки, Бунин яки Еники чалымнарын эзләү кирәкмидер, бәлки, Ж.Сименон яралгысы анда көчлерәктер...

Рауль Мирхәйдәров, әйткәнемчә, ординар булмаган, кабатланмас шәхес. Эш аты, әйткән сүзен үтәүче ир-егет, көяз-фанат (М.Мәһдиев, Рауль иҗат йортларына килгәндә берничә чемодан белән 15 тән дә ким энә-җептән төшкән костюмсыз килми ул, дия торган иде), сәнгатькяр. Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп узыйк: Р.Мирхәйдәров — бик зур кыйммәткә ия нәкыш әсәрләре коллекциясе иясе. Сәнгатьне тирән тоючы белгеч буларак, ул җыйган картиналар әледән-әле төрле күргәзмәләрдә күрсәтеп торыла. Язучы кеше өчен бу да ят шөгыль түгел, һәрхәлдә, тарлык түгел, киңлек.

Әсәрләрне укыганда, авторның профессиональ осталыгы да уйландыра. Бүгенге укучы күңеленә эленке-салынкы җөмләләр, беркатлы наив фикерләр белән юл салып булмый хәзер. Стиль — Кешенең нәкъ үзе инде ул дигән гыйбарә бар. Дөрес нәрсә. Язучы кемнәр яки нинди вакыйгалар турында язмасын, барыбер күпмедер дәрәҗәдә әсәрдә автор язмышы чагылмый калмый. Раульнең стиле — логик төзек, динамик стиль. Сүзләрнең җегәре зур. Шул җегәрле сүзләр мавыктыргыч сюжет чылбырында гаять тәэсирле көчкә әверелә. Укучыларны «тота» алуның бер сере шунда, минемчә. Тагын бер мөһим нәрсә, ул — төгәл сурәтләү. Язучы кайдадыр, кайчандыр үзе күргән кирәк детальләрне фотографик төгәллек белән кабатлап күз алдына китереп бастыра ала. Мәсәлән, «Пешие прогулки» романында Кырымдагы Күктүбә тирәсен тасвирлаган урыннар бар. Заманында мин үзем дә шул җирләрне күп таптадым. Хәзер дә әзме-күпме хәтердә. Ә менә Раульнең әсәрен укыгач, мин анда әле кичә генә барып күреп кайткандай хис иттем. Кирәк һәм иң характерлы деталь-штрихлар шулкадәр осталык белән тотып алынган. Афәрин, молодец! дияргә генә кала. Тарлык-киңлек сүзе чыккач, күңел түрендәге эчке уйлар да төртеп чыга: кемнәребез бар да, кемнәр юк! Кан яратылышы буларак, кемнәр кайда туып, нинди сыйфатта кем булып кайларга таралмаган!

Үзем күреп белгәннәрне генә искә төшерсәң дә байтакка җыйнала. Магаданда — Бөгелмә ягы Альберт Фәттахетдинов, Красноярскида — Минзәлә егете Ринат Суфеев (Роман Солнцев), Чиләбедә — Рөстәм Вәлиев, Ташкентта — Әсхәт Мохтар, шунда ук Җәүдәт Ильясов... Кайберләре дөньяның фаниеннан бакыена күчтеләр инде... Кемдер әйтер — татарга нинди кагылышлы язучылар инде болар? Килешәм дә кебек. Шәкли яктан сүз дә юк, ерак качканнар. Явыз Иван Казанны алганнан соң, асыл ирләр еракларга киткән кебек... Әмма нишләргә соң? Сыркыдыдан яңа Һади Такташ, Пенза ягындагы Пешләдән Шәриф Камал, Нижгардан Кави Нәҗми, Оренбурдагы Мостафадан яңа Муса Җәлилләр килерме? Килмәсләр кебек... Шулай булгач, каннарында төрле иньекцияләр булса да, төбендә татарлыгы яткан, бүген бүтән телләрдә иҗат итүче егетләребезне нигә онытырга? Булган дәрт-рухларының иҗат потенциалларының беразын гына булса да уртак генофонд тамырына нигә тоташтырмаска?

Рауль Мирхәйдәровны укучыларыбыз белми әле дип башта әйтсәм дә, хәл бөтенләй алай ук түгел. Моннан ике ел элек безнең журналда аның «Игълан белән танышу» исемле повесте басылып чыккан иде. Россиядәге зур афералар-алдашуларны тасвирлаган «За все — наличными» дигән яңа романының өзекләре «Республика Татарстан» газетасының биш-алты санында дөнья күрде. Һәм, ниһаять, «Казан утлары» Марс Шабаев тәрҗемәсендә аның «Иртәләгән сагыш» исемле романын тәкъдим итә. Бәлки, бу роман язучы иҗатының иң характерлы әсәре түгелдер. Әмма анда безнең язмышлар, безнең уртак сагышлар...

*2000, июнь*

## РОЗАЛИНА — ГӨЛСУКМАК...

Розалина...

Миңа калса, бик тә шигъри исем. Роза гөлле Шәрыкны да, лина, ина, сина кушымтасы Гарепне дә берләштерә кебек бу сүзтезмә. Фамилиясе дә Шах сүзенә бәйле. Шаһи кызы — Шаһиева. Хәер, шагыйрәнең исеме Хөббиҗамал йә Миңлемәрвәрниса булса да, үзен күргәч, бу сүзләр шигъри яңгырар иде.

Кем соң ул Розалина Шаһиева? Бүгенге интеллектуаль мохит аны яхшы белә. Гавам арасында белмәгәннәр дә табылыр. Сорауга җавапны үземчә шәрехлим. Белгәннәр исләренә төшерер, белмәгәннәр күңеленә сеңдерер.

Розалина — халкыбызның гүзәл бер кыз баласы. Өч бала тәрбияләп үстергән шәфкатьле Ана. Табигать алдында үз бурычын үтәп, мәңге яшь кала алган сөйкемле кыз. «Баласыз чагымны хәтерләмим», — ди ул. «Хәзер безгә форсат: пакь яралу, гамәл кылу камил токымны».

Розалина — галимә, этнограф, сәнгать белгече. Заманында пединститутта укыткан, сынлы сәнгать буенча аспирантура тәмамлаган. 25 еллап гомерен сәнгать дөньясына багышлаган. Музейлар, күргәзмәләр, иҗади конференцияләр... Дөньяның төрле кыйтгаларында фәнни докладлар белән чыгышлар, татар сәнгатен җиһанга белдерү буенча хезмәтләр. Сәяхәтләр — Багдад, Мәскәү, Истанбул, Абу-Даби, Баку, Амман, С.-Петербург һ.б. Төп максаты: төрки халыкларның бердәм рухи Хәятын киңәйтү, дөньяга таныту. «Шигърият, дип әрни ярты җаным, фән, дип калган яртым кабатлый».

Розалина — тәрҗемәче, тарихчы һәм телләр белгече. Студент елларында ук, ул инде шәрык классикасы үрнәкләрен татарчага, үзебезнең татар шагыйрьләрен русчага тәрҗемә иткән (Хәйям, Дәрдемәнд, С. Хәким). Галимнәребезнең дистәләрчә фәнни хезмәтләре — диссертацияләре русчада аның тырышлыгы аша дөнья күрде (К. Насыйри, Х. Госман). Аның шәрык телләрендә иркен аралашуын, татар һәм рус телләрен камил белүен күреп, аксакал әдипләребез — Н. Исәнбәт, С. Хәким Розалинага зур өмет баглаганнар иде инде.

Розалина безнең өчен, дуслары һәм әдәбият сөючеләр өчен, иң әүвәл — Шагыйрә. Әйтергә кирәк, Ходайдан талант куәсе мул салынган зур Шагыйрә. Ихтимал, шәхесенең бу үзенчәлеге турында иң башта ук әйтергә кирәк булгандыр. Әмма алда саналган тормыш бусагалары, хезмәтләре аша килергә мәҗбүр булды ул бүгенге зур Поэзиягә.

Ул — Казанда туып, шәһәр тәрбиясе алган әдибә. Бездә андыйлар бармак белән генә санарлык. Шуңа күрәдер дә аның шигърияте үзенчәлекле, күбебез күнеккән тезмәләрдән шактый нык аерыла. Үзенең экспрессивлыгы, сурәтлелеге, тарихилыгы белән аерыла. Иҗатыннан кайбер үрнәкләр китерик. «Казансулар буйлап йөзеп килгән алтын сандык — минем үткәнем», «Илаһи бөек мәгънәнең бер тамчысы — Гомер», «Яшел-сары, кызыл-зәңгәр — авазларның тасмасы», «Телсез иптәш кызым, җан ачкычым — хөрлек, миһербанлык чишмәсе», «Бәрәңге чәчәкләренең күгелҗем төтенендә» (игътибар итегез: төсләр куе!), «Дәү әтием аткан кызыл болан күзләрендә үлем сагышы. Сөлек-сөлек елан балалары тоягына беткән ябышып...»

Шагыйрә ике телдә — татарча һәм русча яза. Кайсы телдә уңышлырак иҗат итә? Бу хакта миңа хөкемдар булу кыен. Ихтимал, ике телдә бер үк дәрәҗәдә язу мөмкин дә түгелдер. «Татарчада — ру-

хым, русчада — шигъри эстетикам», — ди ул үзе. Татарча шигырьләрендә стиль чатаклыклары да юк түгел. Тик шунысы бар: оригинал фикер ташкыны, сурәтләр тезмәсе, көтелмәгән ассоциацияләр сине бөтереп ала, әсир итә, шуңа да кайбер вәзен төгәлсезлекләрен сизмисең яки сизәргә теләмисең... Мастер, оста һәрдаим эшләргә, янарга тиеш шул!

Әйткәнемчә, сәнгать белгече, нәкыш дөньясы кешесе буларак, аның иҗатында картина-сурәтләр салават күпередәй балкый. Тикмәгә генә әйтмәгәндер ул: «Сәясәткә гүзәл хыял өрдем, дау куәте бирдем Сәнгатькә». Кайбер шигырьләре үзе бер картинаны яки төсле сурәт-детальләрне күз алдына китереп бастыра, «Һава чөмерүче атларың», «Яса миңа, рәссам, кызыл төлке!», «Күңелемдә җирән бураларың», «Кара күзле җәйран — Төркия!»...

Һәр әдибә — үзе бер дөнья. Ул — Ж. Санд яки А. Ахматовамы, Г. Сәмитова яки С. Сөләймановамы — алар үтә катлаулы шәхесләр. Алар бәргәләнә, очына, фейерверк була, көлгә әйләнеп, яңадан ялкынга әверелә. Розалина да шулар нәселеннән. Ул — җен-пәриләрнекеннән генә түгел, Алиһәләр нәселеннән. Тагын шигырьләренә багыйк. Нигә әле ул «Багдад урамында Зөләйханы күреп» (Ирактагы хәлләрне кичереп), Самосырово (Саумосырово — әнисе әйткәне буенча) чүплегендә казына; нигә әле ул кыз-хатын башы белән Азатлыгыбыз өчен бәргәләнә? «Без коллыктан АЗАТ!!! Безнең алда — әле күренмәгән яңа юл! Яңа тылсым, кодрәт: инанулар, гүзәл илаһларга табыну», — ди. Шушы хәлиткеч чакларда да үзе турында гына уйлап яткан каләмдәшләре турында болай дип тә өстәп куя: «Борча булып, парча язып яттың...».

Розалина ун яшьләреннән бирле шигырь яза. Җиденче сыйныфта укыганда, «Ялкын» журналында беренче шигырьләрен бастыра. Аннан озак еллар тынлык... Сәбәпләре дә булгандыр. Әмма ул һәрвакыт язды. Өзгәләнде, ярсыды, үкседе... Соңгы елларда гына аның матур-матур гына шигырь бәйләмнәре чыкты («Казан утлары», «Идел», «Аргамак» һ.б.). Ниһаять, аның беренче китабы дөнья күрде һәм ул сезнең кулларда.

Кара, соры, ак аргамак җиктем...
Киләчәккә юллап барышы.
Үлгәндә дә күзем ачык калыр
күзәтергә алар чабышын.

Без бу китап чыгуга ихлас сөенәбез. Халык язмышының Бөеклеге һәм Фаҗигасе бишегендә тибрәнгән Ана-Сабый өчен.

*1995, декабрь*

**ТУҢМА, ТУГАН!**

Кайчак миңа дөньяда ике Мөдәррис яши кебек тоела. Берсе — шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов (таныклыктагыча — Әгъләметдинов), икенчесе — гап-гади Җир улы Мөдәррис («мудрец», «әкә», «нәни гигант» дигән кушаматлары да бар). Утыз елдан артык миңа шуларның «икесе» белән дә даими аралашырга туры килә. Бу хәлгә мин офтанмыйм, киресенчә, сөенәм, үземчә язмыш бүләге дип кабул итәм.

Татар җаны булган һәр кешегә шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов исеме таныштыр дип уйлыйм. Белеп җиткермәгәннәр булса, белерләр. Милләт буларак сакланып калырга һәм үсәргә теләсәк, рухи ориентирларны чамаларга тиешбез.

Мөдәррисне каләмдәш буларак шактый ук яхшы белеп, иҗаты турында үземчә бер фикер-мөнәсәбәт булса да, бу очракта аның Хәяттагы һәм иҗаттагы төп остазларының берсе Рәис Даутов сүзләрен искә төшереп үтәсе килә.

«М.Әгъләмов — җитмешенче еллар башында татар поэзиясенә үз шигъри аһәңе белән килеп кергән, традицион формада язса да, фикерләүдә һәм тасвирда индивидуальлеккә ия булган һәм шуны даими үстерә барган шагыйрьләрнең берсе. Аның поэзиясенә музыкальлек, классик поэзия һәм халык иҗаты традицияләреннән үсеп чыккан табигыйлек һәм эчке бер моң хас. Кечкенә генә поэтик деталь аша ул туган ил, халык язмышы, аның үткәне һәм киләчәге турында фәлсәфи гомумиләштерүләр ясарга омтыла һәм күп очракта моңа ирешә дә. Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы да үзенчәлекле табышлар белән аерылып тора. Форма ягыннан М.Әгъләмовның шигырьләре төгәл ритмикалы, шома, йөгерек телле».

Әйе, бу бәяләмәдә шагыйрь иҗатының төп сыйфатлары шактый төгәл әйтелгән. Мөдәррис Әгъләмов, утыз елдан артык татар шигъриятенә тугры хезмәт итеп, Тукай, Бабич, Туфан традицияләрен үстереп, үзен танымаска һәм санлашмаска мөмкин булмаган талант иясе икәнен раслады. Кайберәүләр кат-кат талпынып та үрелеп алалмаган Тукай бүләге билгесен дә беренче әйләнештә үк, китереп дигәндәй, күкрәгенә беркеттеләр аның. Юкка түгел, җырдагычарак әйтсәк, «юкка түгелдер». Миңа калса, аңа бу олуг бүләк милли идеяне эстетик идеал иткәне һәм шуны сәнгатьчә оста гәүдәләндергәне өчен бирелде («Тамыры кайда — безгә гөл шунда; Халкыбыз кайда — безгә ил шунда»; «Чит

җирдә су коенам, И Туган Идел генәм! Чит җирдә су коенсам да, йөрәгем синең белән»; «Була вакыт: актарылып, яшьнәп. Болыт сыман шашып бушанабыз. Алдансак та, мәхшәр кичерсәк тә, илгә, Киләчәккә ышанабыз!»).

Татарстан китап нәшриятында әле яңа гына чыккан «Иман тәрәз шакый» исемле сайланма шигырьләр китабын күздән кичергәч, бу фикерем ныгый гына төште. Мәгълүм хакыйкать: нинди генә акыл иясе булып, күңелеңдә нинди генә асыл фикерләр, хикмәтле уйлар йөртсәң дә, әгәр җаныңдагын кешеләр күңеленә көчәрлек итеп әйтеп бирә алмасаң, синнән Илгә-Җиргә әллә ни фәтва (мәгънә-файда) юк. Талант, бәлки, күңелеңдәгең бүтән күңелләргә уйдырып сала белүдер әле ул. Мөдәррис — югары кимәлдәге профессиональ Шагыйрь, чын безнеңчә талантлы милли Шагыйрь, зур Шагыйрь!

Шагыйрьлекне белү өчен шагыйрьнең китабын уку җитә. Һәм, чыннан да, шул бик җиткәндер дә. Шагыйрьне кеше, адәми зат буларак белү шулхәтле хаҗәтмени? Ә белсәң һәм дә шактый ук яхшы белсәң? Адәмлек белән Шагыйрьлекнең бер заттагы гармониясен күзәтү, әлбәттә, үзе бер кызык нәрсә. Мөдәррис Әгъләмовның шәхес буларак безнең даирәдә үзенең югары рейтинглы имиджы бар. Ул — әдәби мохитнең үзенчә бер Хуҗа Насретдины, Мюнхгаузены. Аның холкы, яшәү рәвеше, әйткән-сүткәннәре, язган-сызганнары турында мәзәкләр чыгаралар, мәҗлесләрдә сөйлиләр, «ул әйткән!» дип көләләр, тел шартлаталар... Хәтта кайчак кирәк-кирәкмәгәндә дә аның исеме белән авыз чайкыйлар. Әлбәттә, күп сүз арасында төрлесе була, кешене гел күтәреп әйтелгәннәр генә булмый... Кыскасы, Мөдәррис шәхесе күпләргә кызык табу өчен җирлек бирә. Күпләргә көлеп-елмаю өчен әнә шул кызык җиткән дә инде. Аларның кеше җанын тирәнтенрәк аңлар өчен вакытлары да, әллә ни теләкләре дә юктыр, бәлки. Шагыйрьнең яшәү рәвешен беркадәр белгән, мөмкинлеген һәм чикләнгәнлеген чамалаган кеше — Аның язмышының шактый ук трагик контурларын да күзалларга мөмкин. Замандаш каләмдәшләр арасында Ул — ялгызлыкның һәм сәях ireклелекнең бөтен төсмерләрен тойган, ләззәтен һәм газапларын йөрәге аша кичергән кеше.

Кайбер укучыларыбыз, мөгаен, экзистенциализм дигән фәлсәфи билгеләмәне белә булыр. Ялгызлыкның, гомумән, Ялгыз Яшәү рәвешенең, Ялгыз Рухның үзенә күрә бер моделе ул. Нигә Аккош күленең үзенең берәр Сартры, Камюсы яки Бердяевы булмаска тиеш ди әле! Гыйбарә бар: Кеше ирексездән туа, гаҗәпләнеп яши, сагыш белән үлә. Һәрхәлдә, ике инстанциядә — Килүдә һәм Китүдә — Ул барыбер ялгыз. Фәкать гаҗәпләнеп, дөньяны танып-белеп яшәгәндә генә Ул үзе кебек кемнәрдер арасында...

Күз алдына китерегез: көзге төн, урман шавы, шомлы җил... утын һәм тәмәке төтене белән ысланган такта өй. Япа-ялгыз. Мич суынып бара... Нинди генә уйлар килмәс кешегә! («Төнлә уянам да... кинәт әле Барлыйм юкны-барны: Ашамлыкны барлыйм, киемнәрне — Әллә картаяммы? Хатларны да өр-яңадан укыйм, Укыйм шигырьләрне — Өр-яңадан сөеп, кача йокым, Әллә яшәрәмме? Әллә инде... Мәчегә бирәм сөт, Сөяк бирәм эткә. Бәлки, шулай баралардыр китеп Мәңгелеккә, мәңгелеккә...») Казаннан ун-унбиш чакрымда гына булсаң да, аерым бер Ялгызлык Планетасындагы кебек хис итәсеңдер. Яки янә бер күренеш: кыш, су юк, газ-мазар юк, кисәк-кисәк электр уты да бетеп ала... Бөтен өмет сөремләнгән, яргаланган, әмма тышка зәңгәр төтене чыга торган бәләкәй мичтә, мич алдындагы җәйдән әзерләнгән коры каен утыннарында...

Хәер, хәлне алай ук драмалаштырмыйк әле! Аккош күле — болай үзе табигатьнең гүзәл бер почмагы ул. Ә Мөдәррис — аның хуҗасы! Язучыларның кечкенә генә авылчыгында кышын ул төп хуҗа. Ул монда хәят кичергән егерме ел эчендә әдәбиятыбызның нинди генә затлары яшәмәгән биредә! Х. Туфан, И. Гази, Г. Бәширов, С. Хәким, А. Шамов, Р. Ишморат, Н. Дәүли, 3. Нури, А. Әхмәт, М. Мәһдиев, Р. Харис, Р. Мостафин, Р. Гаташ, М. Рафиков, Г. Рәхим, Ф. Шәфигуллин, Н. Юзиев... Ә яшьрәкләр, бүген актив иҗат итүчеләр ничаклы! Шагыйрь буларак Мөдәррис шушы Аккош күлендә «пешеп» җитте. Алда саналган язучылар анда «пропискада» яшәсәләр, алар янына кемнәр генә килеп йөрмәгән дисез! Сәйфи Кудаш, Мостай Кәриме дә, Фәридә Кудашева, Илһам Шакировы да, Михаил Львов, Давыт Көгелтине дә... Мөдәррис аларның һәммәсе белән диярлек табындаш, әңгәмәдәш булган кеше. Кем белә, бәлки, ул кайчан да булса Аккош күле тарихын язып та чыгар әле! Әдәбиятыбызның байтак сәхифәләре анда язылган бит. Уйланганым бар: Мөдәрриснең, күңеле сәях булса да, иҗат йортларына, рәсми ерак сәфәрләргә чыкмавында (үземнең дә сәфәрләргә димләгәнем булды. Тукайның 100 еллыгында Әстерханга алып барырга теләдем, бармады. Бүтән тәкъдимнәр дә булды...), бәлки, Аккош күле аурасы гаепледер? Бәлки, шулай, кораб түшенә ябышкан кабырчык кебек, бер җиргә берегеп ятуның иҗатта үзгә мәгънәсе — нәтиҗәлелеге бардыр? Бусы бәхәсле булса да, ул бер нәрсәдә тәгаен хаклы: чәчелмәде Мөдәррис. Дулкынга кунып йөргән акчарлак кебек, бер жанрдан икенчесенә сикереп күчкәләк булмады. Шагыйрь булып килде әдәбиятка, шул юлын ныгытты, лазер нуры кебек, Шигырьдә үтәләй тиште. Яшьрәкләргә бер мисал булып гыйбрәт алырга ярый моннан.

Алда әйткәнемчә, без Мөдәррис белән утыз елдан артык бергә уралып яшибез. Соңгы елларда Аккош күлендә без иң күп аралаша торган каләмдәшләр бугай. Җәйләрен очрашмый, әңгәмәләшмә-

гән көн сирәк була. Шагыйрьнең төрле чагын күргәнем бар. «Җен алыштырган» чакларына да шаһит. Әмма соклану тойгысы күбрәк. Кайчак аның «вилла»сына керәсең (ишек ачык. Гомумән, үзе өйдә булмаганда ишегендә йозак торса да, ачкычы шул йозак янында ук булыр), йоклап ята Шагыйрь. Тимер караватта, бала ук булмаса да, үсмерләргә хас какча гәүдәле «нәни гигант». Йомышың булса да, уятырга кыймыйсың. Чыгып киткәч уйлап куясың: шушы малай сымак кына Шагыйрьнең юка иңнәрендә халык уй-гамьнәренең ничаклы йөге ята!

Гомумән, безнең гаиләгә ул табигый рәвештә үз кеше булып керде. Ятим булгангадырмы, акыллы, зирәк булгангадырмы, әти-әни аны үз баласыдай кабул итте, 60 нчы еллар башында Казанның Әмәт тавы итәгендәге йортыбызда Мөдәррис, «Коймаклар» шигырен шартлатып укый-укый, әнием пешергән коймаклар белән сыйлана иде. Соңрак, егерме еллап үткәч, Балык Бистәсендә ул бездә (дөресрәге, энекәшем Илдус хуҗа булган йортта) атналап, айлап яшәп-яшәп ала иде. Әти-әниләр мин кайтканга күбрәк сөенгәннәрдерме ул вакытта, әллә Мөдәррис кайткангамы, кистереп әйтә дә алмыйм. Әти-әни аны бик хөрмәт итте. Һәрхәлдә, Тукай бүләге алган китапны ул бездә торып язды, төзеде. Хәзер инде әни гүр иясе. Сөйләшкәндә, әти-әни турында сүз чыкса, ул да аларны, минем кебек, «әти», «әни» дип искә ала. Шул чакта күзләрем дымлана...

Мөдәррис дустым! Менә Сиңа да 50 яшь тулды. Ирләр буларак, турысын әйтик — байтак яшь бу! Бу очракта Сиңа «кояш гомере дә тели» алмыйм, бәхетне «кояш сүнсә дә, Әминә Җәлилне көткән шикелле» көт дип тә әйтә алмыйм. Алда салкыннар аяк киенгән черек көздә болай дим: «Туңма, туган! Туңма, рухдашым!» Синең җаның өшергә тиеш түгел. Әдәбият-сәнгать дөньясында Сине хөрмәт иткән дусларың күп. Күңел учаклары белән генә булса да без бер-беребезне җылытырга бурычлы. Шулай тиеш.

*1996, 13 октябрь*

## ЧАТЫРТАУ — БИЕК ТАУ...

* * *

Һәр кешенең күңелендә күпмедер шигырь-җыр ята. Шулай да чын мәгънәсендәге шагыйрьләр санаулы гына. Сүз шигырьне намус эше итеп, җәмгыять тормышының бер бик мөһим һәм үтә җаваплы бер эше итеп күрүчеләр, шул миссиягә фидакарьләрчә алынучылар турында бара, билгеле. Әдәбият — җаныңның олылыгын, иманыңның ныклыгын сынау мәйданы. Бу рухи сынау безнең шигърияттә аеруча үзгә дәрәҗәдә. Чөнки татар шигърияте — күпләрне күргән, төрле хәлләрне кичергән шигърият. Ул байтак гасырлар буена Вакыт Галиҗәнапларының мәрхәмәтсез җилләрен дә, халыкларны кан-яшькә батырган хан-патшалар дәверләрен дә үткәргән, яу-көрәшләрне, яну-тузуларны да күргән... Аның бүгенгесендә дә бүтән халыклар шигъриятенең куәтле вәкилләре белән алышырлык көчле шагыйрьләре бар. Бу гасырның соңгы чирегендә татар шигъриятенә килеп, үзенчә аваз салырга, булган хәзинәгә аз гына булса да өлеш кертергә батырчылык иткән һәр яшь кеше үзенең нинди зур сынау мәйданына килгәнлеген анык белергә тиеш. Марсель Галиев, миңа калса, моны яхшы аңлый кебек. Болай уйларга нигез бар. Беренчедән, ул шигърияткә шактый әзерлек белән килә; икенчедән, шигырь эшенең зурлыгын һәм четереклеген тоеп, артык кабаланмый, ашыкмый, чәбәләнми; өченчедән, мөгаен, иң мөһиме — аның кешеләр белән бүлешәсе, шушы дөнья, тормыш өчен кирәк булган сүзләре, фикерләре, бай күңеле бар. Шагыйрь язмышының ил-дөнья язмышыннан аерылгысыз икәнлеген аңламаса, үзенең бер шигырендә ул болай дип әйтмәс иде: «Гел беренче булып Заман төби Шагыйрь белән чыккач дуэльгә!»

Марсель — Азнакай якларыннан. «Чал Уралның соңгы дулкыны булып, зәңгәр пирамидадай торган Чатыртаулар» (бу — Кырым Чатыртавы түгел, безнең төбәктәге Чатыртау!) төбәгеннән. Биографиясе — заманга һәм үз буынына хас биография — мәктәп, армия хезмәте, нефть предприятиеләрендә эшләү, университет... Соңгы биш ел эчендә Марсель Галиев — Татарстан Язучылар союзы каршындагы матур әдәбиятны пропагандалау бюросы хезмәткәре. Марсельнең поэзия эшенә ихлас күңел куеп, җитди рәвештә шөгыльләнә башлавына ун ел чамасы. Хәтердә: Марсель Азнакайда эшләгән елларында язучыларның Әлмәттәге бүлегенә еш килеп йөри иде. Кабинетта яки бакчадагы чирәмгә чыгып утырып шигырь укулар, фикер алышулар, киңәшләр, бәхәсләр һаман истә. Яшьлекнең тыелгысыз ашкынулары, татлы хыяллар, беренче шигырьләрне матбугатка чыгарасы килү теләге... Бик тиз генә бик күп итеп яхшы шигырьләр язып, бик тиз генә китап чыгарам дип йөргән беркатлы саф еллар инде артта калды. Бертөрле рәхәт кызышып, ажаган кебек беренче балкып алулардан беренче китапка кадәр дистә ел чамасы вакыт үтте... Бәлкем, бу кадәр вакыт бераз озаграктадыр, чөнки гомер дигәннәре дә әллә ни озын түгел бит. Әмма Марсель өчен заяга узмады ул еллар. Бу елларда ул төпле белем алды, әдәби традицияләрне өйрәнде, кешеләрнең язу тәҗрибәләре аша үзенең иҗади мөмкинлекләрен ачыклады. Вакытлы матбугатта да шактый нәтиҗәле эшләде ул. Байтак санда мәкаләләр, зарисовкалар, рецензияләр, хикәяләр, шигырь цикллары бастырды. Алар арасында «Март», «Яшел соната» кебек парчалар белән беррәттән, «Кар абагалар», «Ул чакта» кебек

күләмле повестьлар да бар. Республикабыз матбугаты битләреннән тыш аның әсәрләре «Волга» журналында, «Молодая гвардия» чыгарган альманахларда да урын алды. Шулай ук яшь язучыларның илкүләм зур җыеннарында (Яшь язучыларның VI Бөтенсоюз киңәшмәсе, яшь шагыйрьләрнең X Бөтенсоюз фестивале һ.б.) катнашулар да аңа әдәбият турында да җитдирәк уйларга һәм иҗат офыкларының киңәя төшүенә булышлык иткәндер. Болар һәммәсе дә үзенә күрә беренче зур сынауга, беренче китапка китерә торган үсү баскычлары булды.

Безнең бүгенге шигъриятtә төрле-төрле, үзләренең иҗат йөзләре булган талантлы шагыйрьләр күп. Аларның һәрберсендә үзенә генә хас берәр көчле як бар. Берәүләр сурәтләү чараларының бай, шигъри тукымада нәфис бизәкләрнең күп булуы белән кызыклы, икенче берәүләр телнең, хәтта аерым бер сүзнең мәгънә төсмерләрен, яңгырауларын оста файдаланалар, өченчеләр фикер-хис агышының эчке эмоциональ мөмкинлекләрен ачалар. Әлбәттә, эзләнүләрнең нәтиҗәлелеге беренче чиратта шагыйрьнең талантына һәм замана, җәмгыять куйган проблемаларга җавап бирерлек дәрәҗәдәге гражданлык позициясенә бәйле. Марсель Галиев шигырьләре рәсемле, сурәтле шигырьләр, уйлы-гамьле шигырьләр («Шүрәлеләр булып каеннарда уйнаклады учак шәүләсе...», «Таҗларына йомып ак кояшны, күл төбенә чумган төнбоек...», «Бу җаныңны чайкап алыр өчен, дөнья гүя сулар яраткан...», «Күңелемә сыйган бөтен Тарих убылып китә, һава упкыннары үткәндә...» һ.б.). Ул — интеллектуаль поэзия вәкиле. Примитив шигырьләр аңарда юк дәрәҗәсендә. Ул дөнья поэзиясенең яхшы үрнәкләре нигезендә иҗат итәргә омтыла. Дөрес, кайбер шигырьләрендә ул әлеге теләгән максатына ирешеп тә бетә алмый. Аерым бер шигырьләрендә инде моңарчы поэзиядә булган авазлар да ишетелгәли. Ләкин болар үзеңнең индивидуаль йөзеңне ачыклау процессындагы котылгысыз нәрсәләр. Нечкә тоемга, рәссам күңеленә ия булган Марсель Галиевнең нәкъ үзенеке генә булган байтак яхшы шигырьләрен дикъкатьле укучы аның китабын укыгач күрер, тиешенчә бәяләр дип уйлыйм.

Марсель Галиевнең беренче китабы. Авыр, ләкин татлы, газаплы зур иҗат юлына чыга егет. Хәерле юл аңа! Зур максатлар гына зур юлга чыгара ала. Һәр шагыйрь — үз халкының бөтен рухи куәтен, бөтен рухи матурлыгын һәм бөеклеген күрсәтә алырга омтылырга тиеш. Шагыйрь — көрәшче дә, Матурлык арттыручы да бу дөньяда. Кешелекле Матурлык бик тә кирәк Җир йөзенә!

*1978, июль*

* * *

Моннан шактый еллар элек бер өлкән каләмдәшем үз китабын мондый сүзләр язып бүләк иткән иде: «Кешеләрне ярату — авыр эш. Бу хезмәттә без фикердәшләр булып, бер юлда булсак икән!». «Эш» һәм «хезмәт» сүзләренең астына сызылган иде. Еллар узган саен шуңа ионанам: бик тә дөрес әйтелгән бит! Безнең агай-эне өчен бигрәк тә... Әйе, әдип — кешеләрнең кешелеген күреп, аны хөрмәтләргә, ихтирамларга, яратырга тиеш. Хәтта, әйтер идем, яшәргә котыртырга тиеш! Марсель Галиев моны бик яхшы аңлый! Кемдер, бәлки, җилкә җыерып, йөзен чытып әйтеп куяр: шул тәкәббер, эгоист Марсельме? Үтеңне чыгарырлык сарказмлы Марсельме? Шул «купык» мактанчыкмы? Әйе, шул Марсель Галиев. Шагыйрь, эссеист, прозаик, сатирик Марсель Галиев. Чынлап та, күпләребезгә караганда кеше рухын югарырак кимәлдә олылый белә ул! Әйдәгез, иҗатына багып (ә иҗат — критерий!), җыр текстларын гына искә төшерик: «Һаваларда торна тавышлары», «Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Көзге моң» — Кеше рухының нинди генә тибрәнешләре юк аларда. Гомумән, болар классик җырлар, киләчәккә барачак затлы җырлар. М. Галиев соңгы елларда шигырьләрне сирәк яза. (Дәрдемәнд тә күп язмаган!) Әмма язганнары — җитлеккән чын шигырьләр. Юморист-сатирик буларак, кайбер язмаларына күз салыйк. Менә «Өмә» әсәре. Язучылар йорты янында өмә мәш килә. Кемнәр генә юк анда! Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов, Туфан Миңнуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Хәйдәр дә, мәрхүм Фәннур Сафин, Камил Кәримов, Рөстәм Мингалимов та... Күбесен чеметеп ала Марсель, берничә сүз белән характер чалымнарын сурәтли, кыскасы, көлә! Һәм яратып көлә!

Күптән түгел генә «Мәдәни җомга»да чыккан «фәлсәфи төкерек»не, бәлки, укыгансыздыр. Сүз, бер караганда, татар Мюнхгаузены, «нәни гигант» Мөдәррис турында гына шикелле, ә бит, асылда, юморескада бүгенге көннең актуаль мәсьәләләре күтәрелә, әдәби казанда кайнаучы күпме шәхесләрнең холык-фигыльләре ачыла. Ә язмышы! Ирексездән елмаясың, иреннәрең генә түгел, кендекләреңә кадәр көлә! Дөньялар яктырып китә! Шуннан соң аны ничек кешеләрне яратмый дисең. Шулай шул, мәгълүм хакыйкать: үзеңне зурлауларын теләсәң, кешеләрне олыла; бергә-бергә үскәндә, илең дә зураер, куәтләнә-көчәя барыр.

«50 яшемә «Гасырлар китабы»мны әзерлим» дип берничә ел әйтеп йөрде Марсель. Ул китап менә-менә чыгып җитә булса кирәк. Ул әсәрнең журналда чыккан («Казан утлары», 1997, № 9, 1998, № 1, 2. — *Р. Ф.*) өлеше дә әдәби вакыйга булырлык. Миңа калса, шәхесләрнең әдәби портретларын мондый нечкәләп нәфис итеп иҗат иткән әдип юк иде әле бездә. Мәгънә дисәң мәгънә, образ дисәң образ бар... Ә теле? Аңлаган кеше өчен ул — яңа Фатих Хөсниебез бугай... Журналыбызның яңа са-

ны белән танышып, аның туганягы, Казанга, укыган университетына багышланган эссеуйланула-рын, Р. Яхин, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Р. Нуриев, Х. Сарьян һәм башкаларны иҗат кешесе һәм шәхес буларак тасвирлаган портретларын, нәкъ менә портретларын (бу очракта Марсельнең ару гына рәссам булуының да хикмәте бардыр) укыгач, әйткәннәремнең хак булуына ышанырсыз дип уйлыйм.

Моннан 30 еллар элек, 60 нчы еллар ахырында — әле Марсель беренче әдәби тәҗрибәләр ясый башлаган чорның шаһиты булырга туры килде миңа. Күпмедер йогынтым да булды бугай. Аның 1979 елда чыккан «Еллар чалымы» дигән беренче шигырь китабына язган кереш сүземдә мондый юллар бар иде: «М. Галиев — интеллектуаль поэзия вәкиле... Ул дөнья поэзиясенең яхшы үрнәкләренә йөз тотып иҗат итәргә омтыла». Шөкер, ялгышмаганмын. Дөрес, хәзер аның колачы киңрәк, шигырь белән бергә проза үрелеп бара, аларга фәлсәфи эсселары һәм юмор әсәрләре кушылып китә. Булсын, иң мөһиме: фикри һәм шәхси яктан алар зәгыйфь, мескен түгел, провинциональ түгел. Заман дәрәҗәсендә. Егерменче йөз ахырында язылган «Гасыр китабы» киләсе гасырда да дәвам итепер дип ышанасы килә.

Ә тәкәбберлеккә килгәндә, бу сүзне ничек аңлыйсың бит. Кемдер горурлыкны тәкәбберлек дип, күңел байлыгын бушатуны мактану дип аңлавы мөмкин. Әйе, Марсель үзгә холыклы шәхес. Кайчак бөердән юан тавыш чыгарып, каты бәгырьле кеше сыман күренгәләсә дә, белегез, бу — аның тиз яраланучан күңелен саклау чарасы буларак, үзенә күрә бер панцирь-калкан гына. Мин аның яшьле күзләрен дә күргәнем бар. Гомумән, ул бу дөньяны күбрәк дымсу күзләр аша күреп иҗат итә бугай...

*1996, октябрь*

## БОЛАЙ ГЫНА ГАДИ КҮРЕНӘ УЛ...

* * *

Кеше кем генә булып, нинди генә дәрәҗәләргә ирешмәсен, әгәр ул әдәбият дөньясына килеп, анда урын дауларга тели икән, аның барлык анкета мәгълүматларын онытып торып, язганына багасың, иҗатына карап, аңа бәһа бирәсең. Илдус Гыйләҗевнең укучылар кулына ирешкән һәм инде матбугатта уңай фикерләр яулаган беренче җыентыгын актарам... «Җир китабы». Бу китапның исеме төгәл, исеме җисеменә бик туры килә. 120 дән артык шигырьне берләштергән бу җыентыкны мин Татарстаннан, үзебезнең әдәби ыгы-зыгылы мохиттән еракта — Пицундада, Иҗат йортында укып яттым. Ашыкмыйча, сеңдереп, үземчә анализлап. Бөтенесенә дә мөкиббән китмәсәм дә, тулаем алганда шигырьләр күңелемә хуш килде. Сабый чак, балалык елларында бик газиз булып та, хәзер инде беркадәр ерагая төшкән (кызганычка каршы) җир язмышы, яшәеш язмышы, кешеләр язмышы ул шигырьләрдә.

...Шушы матур,
мәрхәмәтле җирдә үсеп,
тугайларда, урманнарда
печән чабып, агач кисеп,
терекөмеш төсле якты
чишмәләрдә сулар эчеп,
чуклы чыбыркы шикелле
елгаларны йөзеп кичеп...

язылган шигырьләр алар. Бездә хәзер шигырь язучылар, дөресрәге, техник яктан яңгырашлы, килешле, грамоталы итеп язарга сәләтлеләр байтак. Ләкин алар күп вакыт шигырьне ясый, ә тудырмый. Ә шигырь туарга тиеш! Шигырьне шигырь иткән төп хасиятләрнең берсе — аның табигыйлеге, самимилеге. Илдусның шигырьләре бу яктан әлеге таләпкә бик тә җавап бирә: алар табигый дә, самими дә. Әмма һәрнәрсәдәге кебек, монда да чама кирәктер, юкса, артык гади, артык гавамча бәян итәм дип, «бер каптырмалы» язмалар да килеп чыгарга мөмкин. Автор моны үзе дә сиземли булса кирәк: «Кайберәүләр өчен, бәлкем, беркатлырак күренәмдер...» Мондый сизенү булгач, шагыйрь бу шикне тудыручы сәбәпләр турында да алга таба уйланыр дип ышанасы килә.

Шагыйрьнең дөньясы, тематик диапазоны турында китаптагы шигырьләрнең исемнәре үк кычкырып әйтеп тора. «Басуларым төсе», «Кара туфрак», «Кеше көчле дә бит...», «Шигырьләрне җиргә язам», «Аермагыз җирдән», «Кадерсезләмәгез икмәкне», «Өмет кирәк авылларга», «Җир китабы», «Язгы басу», «Кош күңеле — туган җирләрдә» һ.б. Һәрберебезгә аңлаешлы, күңелгә ятышлы исемнәр. Мондый исемле шигырьләр язу хокукын берәү дә бездән тартып алмаган. Әмма яшәү рәвешебездән чыгып караганда, күбебез өчен мондый исемле шигырьләр язып чыгару бик үк табигый булмас иде. Ә Илдус Гыйләҗевнең исә җир кешесе буларак та, шагыйрь буларак та чын хакы, үз хакы бар. Шагыйрьнең публицистик рухтагы шигырьләреннән тыш лирик, интим мәхәббәт шигырьләре

дә юк түгел. Әмма алар да барыбер теге яки бу ягы белән шул ук дөньяга — Игенчеләр Иле дөньясына бәйләнгән.

«Башка эшкә инде күнегелмәс, төп шөгылем — икмәк үстерәм!» — ди ул һәм... шигырьләр яза, китаплар чыгара. Бу заманда, һәр шөгыль бөтен вакытыңны һәм җан җегәрен таләп иткән заманда бүлгәләнеп була микән? Бер үк вакытта Җир кешесе — бу очракта оештыручы-җитәкче һәм әдәбиятта эз калдырырлык шагыйрь булу мөмкинме? Уен сорау түгел. Кемнәрнеңдер Илдусның язганнарына аның хоббие ул диебрәк тә каравы бар. Әйдә, без процесска атама бирүдән элек нәтиҗәгә — хезмәткә карыйк. Ә нәтиҗә әлегәчә күңелле.

...И. Гыйләҗевнең яңа кульязма итеп әзерләгән кайбер шигырьләре белән дә таныш мин. Аларда иҗади үсеш нык сизелә, фәлсәфи рухлы шигырьләр күбәя төшкән. Шунысын да искә алып үтик: Илдус әдәбиятта бүген генә яралган зат түгел. Моннан 15—20 еллар элек тә ул шигырьләр яза иде. Ялгышмасам, бер арада университеттагы әдәбият түгәрәгенең җитәкчесе булып та эшләп алды. Шигъри күңеленең шулай баш күтәреп чыгуы бер дә очраклы хәл түгел. Эчке рухның яңару, өлгерүе билгесе бу. Гомумән, безнең әдәбиятта табиб, укытучы, диңгезче, игенче, очучы һәм башка һөнәр ияләре дә бар. Моңарчы алар сынатмады. И. Гыйләҗевнең яңа җыентыгы бу сүзләргә тагын бер дәлил дип уйлыйм.

*1989, гыйнвар*

* * *

Илдус Гыйләҗевнең шигъри дөньябызда үзен ныклап раслый башлавына да ун еллап вакыт узды инде. Кайчан яза башлавын үзе генә беләдер. Ул хәзер берничә китап авторы: «Җир китабы», «Җилкенү» һ.б.

Бу кереш сүзне язганда, моннан җиде ел элек И. Гыйләҗевкә Язучылар берлеге әгъзалыгына керергә биргән рекомендация — тәкъдим язуыма карап алдым. Анда болай язылган булып чыкты.

«Бездә хәзер шигырь язучылар, дөресрәге, техник яктан яңгырашлы, килешле, грамоталы итеп язарга сәләтлеләр байтак. Ләкин алар күп вакыт шигырьне ясый, ә тудырмый. Ә шигырь туарга тиеш! Шигырьне шигырь иткән төп хасиятләрнең берсе — аның табигыйлеге, самимилеге. Илдусның шигырьләре бу яктан әлеге таләпкә бик тә җавап бирә.

И. Гыйләҗевнең үз темасы, үз стиле, үз укучысы бар, димәк — үз дөньясы бар. Аның шигырьләрен мөкиббән китеп яраткан укучыларны беләм. Алар, нигездә, авыл кешеләре, игү-чәчү, җир-су кешеләре. Асылда, без — татар телендә иҗат итүче каләм ияләре — нәкъ шулар өчен язабыз да бит. Чөнки чыгышыбыз Җирдән, бүгенге Хәятыбыз, яшәү-сулышыбыз Җирдә, киләчәгебез Җирдә.

Илдус Гыйләҗев — интеллигент кеше. Затлылыгы байтакларга бүлеп бирерлек. 70 нче елларда университетның татар филологиясен тәмамлаган. Туган ягы — Азнакайга кайтып, төрле җаваплы урыннарда эшләгән. Үз вакытында солдат хезмәтен үтеп, офицер булган. Татарстанның халык депутаты итеп сайланган. Әмма без Илдус Гыйләҗевне шагыйрь буларак белгән чор аның авыл хуҗалыгы рәисе булып эшләгән вакытларга туры килде. Председатель-рәис һәм шагыйрь. Сирәк кулланыла торган сүзтезмә (дөрес, заманында кайберәүләр булды: шагыйрь Ринат Рәхимов, җыр текстлары язучы Марсель Гыймазетдинов...). Фәкать язу эше белән генә шөгыльләнгән кешегә дә әле Шигърият галиҗәнаплары хакына, көн генә җитмичә, байтак төн йокыларын да сарыф итәргә туры килә. Ә рәис-шагыйрь кешегә? Иртә таңнан торып нәрәт бир, иртә-кичен җир-басу сулышын тыңлап йөр, яуган яки яумаган яңгыр-коры өчен борчыл-көен, гади игенче халыкның йөз төрле гозерен аяк астына салмаска тырыш, өстәгеләргә яки янәшәндәгеләргә горурлыгыңны саклаган хәлдә ярап кара... Өстәвенә, «заман кемнең заманы?» дигәндәй, бу заман бит — «кыргый базар» заманы, ярминкәләр заманы, үзгәртеп кору-кормауның шомбай-төрләре заманы! Әле шәхси тормыш та бар бит: гаилә хәлләре, балалар, оныклар китергән шатлыклар, борчулар... Мал-туар, бакча-түтәл... Гомумән, авыл җирендә эш-мәшәкать чиктән ашкан. Шагыйрь беренче китабын тикмәгә генә «Җир китабы» дип атамаган иде шул.

Ни чәчсәң, шуны урырсың, ди халык. Тормышның үзәгенә, гади халык күңеленә никадәр якын булсаң, — язган сүзең дә, көйләгән җырың да шулкадәр тормышчан, халыкчан, яшәүчән буладыр. И. Гыйләҗев шигырьләре гади, хикмәтле, табигый яңгырашлы. Миңа калса, шагыйрь үзенең күпме һәм нәрсә күтәрә алганын, ягъни нәрсә турында, ни өчен, кем өчен язганны яхшы белә. Ә инде күтәргәнен, көчле кулы белән тимер чөюче атлет кебек, ул егетләрчә күрсәтә, дә белә.

Кемдер әйтер Илаһ Шигърият ул тәрәзәдән сызгырып кына катыңа менә торган кәнизәк түгел, аңа бөтен күңел җылыңны, гомер-вакытыңны багышларга кирәк — шулчак кына, бәлки, үзеңне юлдашы итәр; ә болай, игү-чәчү, мал-туардан арткан вакыт илһамы — дилетантлык, үзешчәнлек, дияр. Моның белән дә килешмичә булмый. Әмма табигатьтән шагыйрь булып туып та, шуңа бөтен гомерен багышлый алмаган, дөресрәге, язмыш мөмкинлек бирмәгән талант ияләре була. Андыйлар турыдан-туры «старттан — финишка» барганнарга караганда күбрәктер дә әле...

Илдус Гыйләҗев — гомеренең төшлегендә җирдә нык басып торучы ир-ат. Фани дөньялыкта кирәк саналган байтак игелекле гамәлләр кылынган. Аның хәзер, тормыш куу хәлләрен дилетантлыкка калдырып, төп эш итеп иҗатны сайларга да хакы бар.

*1995, ноябрь*

## ЯНУ ЙӨРӘКТӘН БАШЛАНА

Татарстан китап нәшрияты әле күптән түгел генә «Чистопольские страницы» исемле калын бер җыентык чыгарды. Анда сугыш чорында эвакуациядә яшәгән язучыларның Чистайда иҗат ителгән әсәрләре, туганнары, якыннары белән язышкан хатлары: истәлекләре урнаштырылган. Үзләренең фоторәсемнәре дә, яшәгән йортларының сурәтләре дә бар. Арада зур, мәшһүр исемнәр шактый. Дөресрәге, шул хәвефле елларда исән-сау калып, совет әдәбияты елъязмасына ныклы төстә кереп урнашкан кешеләр. Күп көч куеп, шактый мул искәрмә-комментарий белән баетылып, яхшы кәгазьдә 45 мең данә итеп чыгарылган бу басма, һичшиксез, игътибарга лаек. Хәер, матбугатта бу китапны хуплаган рецензияләр басылгалады да инде.

Шушы китап геройларының Чистайдагы тормыш рәвеше белән танышу дәвамында, икенче бер параллель уй минем миемне бимазалап торды: ә бу вакытта турыдан-туры сугыш кырында, алгы сызыкта, партизан отрядларында көрәшкән яисә концлагерьларда газап чиккән иптәшләрнең, шул җөмләдән язучыларның хәлләре ничегрәк булды икән? Сугыш дигән үлем уенында тормыш, яшәү, киләчәк өчен көрәшкән кешеләр беренче чиратта алар бит! Нинди генә экстремаль шартлар булмасын, туплар тынган арада, алар да иҗат иткән, көндәлекләр язган, туганнарына, дусларына хатлар, истәлек фотоларын җибәргән... Турыдан-туры сугышта катнашкан — Ил өчен бердәнбер гомерен биргән яки җиңү шатлыгын татып, исән кайтырга насыйп булган өлкән каләмдәшләребезнең фронт чорларын чагылдырган материаллардан (әсәрләр, хатлар, мөрәҗәгатьләр һ.б.) бер күркәм басма чыгарырга иде бит. Иң беренче булып әнә шул китап дөнья күрергә тиеш иде, безнеңчә. Байтак республикаларда йөреп-күрүемнән чыгып әйтәм: безнең язучылар сугышта чагыштырмача иң күп санда катнашкан. Кайтмый калып, мәрмәр тактага уелганнарның исемнәре шактый ук озын безнең... Әйе, бүгенге тыныч тормышыбыз өчен шәһит киткән этиләребез, бабаларыбыз хатирәсен онытырга һич тә хакыбыз юк. Көрәш һәм үлем кырларыннан безгә ирешелгән һәм әлегәчә сакланып калган һәр документ, кәгазьгә төшкән һәр сүз яңа буыннар өчен изге васыять саналырга тиеш.

Күңелне әнә шундый уйлар биләгән көннәрнең берсендә «Казан утлары» журналының 10 санында (1987) басылган бер яңа әсәргә тап булдым. Ул — шагыйрь Зиннур Мансуровның «Балкыш» дигән поэмасы. Автор төп исем янына кечерәк хәрефләр белән болай дип тә өстәгән: «Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар». Димәк, әсәр Х. Мөҗәйгә бәйләнешле. Мөҗәй... Әдәбият тарихын белгән кешеләр өчен таныш исем, якты исем. Шагыйрь Мөҗәй. Полковник Мөҗәй! Ул әле генә исемнәрен атамый гына әйтеп узылган каһарман улларыбызның берсе бит, халык горурланырлык шәхесләребезнең берсе! Димәк, әлегә хәтеребез исән, легендар затларны онытып ук бетермибез икән. Соңгы 10—15 елдагы әдәби елъязмабызга әйләнеп карасак, батырларча һәлак булган фидаи каләмдәшләребез турында беркадәр әсәрләр барлыгын күрербез. Әйтик, Р. Харисның Җәлил һәм аның көрәштәшләренә, Ф. Кәримгә багышланган шигырь цикллары, И. Юзеевның шул ук Мөҗәй турында «Язылмаган поэма»сы...

Мин әле бу очракта тезмә үрнәкләрнең кайберләрен генә искә төшердем, һәм менә тагын Хәйретдин Мөҗәй исеме белән бәйле яңа әсәр. Чыннан да яңамы ул, рух хәзинәсен баетыр дәрәҗәдәме? Ни әйтсәң дә, инде моңарчы матбугатта басылып чыккан көндәлектән җимләнеп язылган бит. Әнә шундый шикләнү катыш кызыксыну белән укыдым мин бу поэманы. Бер укыдым, тагын берничә кабат күздән кичердем. Чын мәгънәсендә кызыксындырды. Үзгенә дә үтеп керә алдым шикелле. Материалны күбрәк белү теләге уянып, Х. Мөҗәйнең «Сугыш язмалары»н яңадан җентекләп өйрәндем, берочтан аның бик үк зур булмаган әдәби мирасы белән дә янәдән танышып чыктым. Шуннан соң гына поэманы тирәнтен аңлый алдым, үземчә бәяләдем дип исәплим. Файдалы, мәгънәле шөгыль булды бу минем өчен. Беренчедән, Х. Мөҗәй шәхесенең зурлыгына, зирәклегенә инандым; икенчедән, Зиннур Мансуровның шагыйрь буларак яңа якларын, яңа мөмкинлекләрен ачтым, үзенә генә хас фикерләү рәвешенең камилләшә баруын күреп сөендем.

Бу очракта шунысын да әйтеп узарга кирәк: безнең әдәбиятта сугышның алгы сызыгыннан торып язылган, югары иҗади кыйммәткә ия булырлык әсәрләр бик үк күп түгел. Алар — беренче чиратта М. Җәлил, Ф. Кәрим шигырьләре, Г. Әпсәләмов, Г. Кутуйларның хикәя һәм нәсерләре... Әлбәттә, кайбер исемнәр белән әлеге исемлекне озынайтып та булыр иде. Әмма бүгенге укучы кулына килеп ирешкәннәре күп түгел. Ә менә чын мәгънәсендәге сәргаскяр, зур хәрби дәрәҗәле өлкән офицерның язмалары безнең өчен аеруча әһәмияткә ия. Андый затның күзәтүләре, теге яки бу хәрби ситуацияне бәяләве, гомумиләштерүләре үзгәрәк кабул ителә. Максатлар бер — җиңүгә омтылу булса да, рядовой солдат белән полк командирының идарә итү, перспективаны күзаллау һәм җаваплылык

җәһәтеннән аерымлыклары да аз түгел. Өлкән командир масштаблырак күрә, дәрәҗәсенә карап, әгәр ул хикмәт иясе дә булса, сугыш кебек фаҗигаләр аренасында Яшәү белән Үлем турында тирәнрәк фәлсәфи нәтиҗәләр ясый. Бу уңайдан Х. Мөҗәй, командир һәм язучы буларак, безнең горурлыгыбыз саналырга хаклы. Кайбер халыклар, әгәр андый каһарманлык күрсәткән уллары булса, аларның исемнәрен мәңгеләштерү буенча күп нәрсәләр эшләр иде...

Әнә шул легендар шәхесне янә искә алып, аны тагын бер мәртәбә халык күңеле мәйданына чыгарып, Зиннур Мансуров бик кирәкле изге эш башкарган. Кешеләрне чын яратып, аларның каһарманлыгын әләм рәвешендә күтәреп кенә яңа рухи үрләр яулап була. Дөрес, шагыйрьнең максаты Х. Мөҗәй шәхесенә игътибар юнәлтү генә түгел. Әлеге әсәр — моннан 45 еллап элек язылган сугыш көндәлегенең хуҗасы белән бүгенге көннән торып әңгәмәләшү, каһарманның гакыллы сүз сөрешен дәвам иттерү; ул вакытта бер яссылыкта булып та, хәзер исә бүтән төсмерләр алган проблемалар турында уйлану, яшәештәге мәңгелек сорауларга җавап эзләү... Гомумән, Зиннур Мансуров — мәңгелек темалар — рух проблемалары турында киңәеп уйланырга омтылучан шагыйрь. Иҗатчының мондый сыйфаты аның күпсанлы мәкалә-эсселарында да ачык тоемлана. Яшәешнең байтак мәсьәләләрен колачлаган «Балкыш»та исә каләмгә иркенлек киң бирелгән.

Жанры ягыннан поэма-рулада дип исемләнгән әлеге әсәр шигърилек җәһәтеннән тыгыз, укучыга беркадәр яңа информация бирә торган кыска гына кереш сүздән һәм унбер бүлектән тора. Һәр бүлеккә эпиграф-башлам рәвешендә Х. Мөҗәй көндәлегеннән берничә җөмлә китерелә. Алар — шигъри бүлек-кишәрлекләргә ни чәчелгәнен белдерүче язулы флагчыклар, үзенә күрә юлкүрсәткечләр шикелле. Әмма шагыйрь әлеге кишәрлекләргә беренче чиратта үз уйларын, үзенең шатлыклы яки борчулы фикер орлыкларын чәчкән, шулай итеп үзенең иҗтимагый-эстетик карашларына ярашлы шигъри басуын тудырган. Поэманың тел төбе бүгенгегә тоташкан, байтак кына канатлы тәгъбирләр үткәннәр аша киләчәккә төбәлгән. Әйтик, рәсем-сурәтләре безнең көннәргә килеп җитмәгән бөек шәхесләр — Кол Гали, Шиһаб Мәрҗани, Каюм Насыйриларны искә төшерә дә, шагыйрь болай дип әйтеп куя: «Кара шәүләң катып калса, үлмәс халык күзендә?!» (Киная, кисәтү бит бу!) Икенче бер урында Х. Мөҗәй көндәлегендә язылган окоптагы ак әтәч турында уйланып, шагыйрь борынгы Кырымдагы фаҗигаи хәлләрне искә төшереп ала. Яки, солдатларның, кырдагы салам эскертләрен яндырып, шулар төтене ышыгында дошман күзеннән эз яздыруын күз алдына китереп: «Иләндәге төтенгә дә була икән таянып!» — ди. Мәгълүм хакыйкать: фидакарь җаннар өчен һәр заманда да көрәш мәйданы киң.

Яный барлык шагыйрьләргә
бәрелешнең яңасы.
Ватан исән калсын өчен
кемнәргәдер — атыласы,
кемнәргәдер — асыласы,
кемнәргәдер — янасы...

Ә яшисе дә килә! Һәр җан иясе өчен — иң кадерлесе яшәү бит. Яшәү, мәхәббәт, сәгадәт... «Ташбилгем дә калмас, бәлки, ядка алып еларга. Яратудан янды, диеп, я-ра-ту-дан ян-ды, диеп аңлатырсыз елларга!..» Көрәшченең гомере тоташ яну. Бу мәгълүм аксиома Хәйретдин Мөҗәй мисалында күчерелмә мәгънәдә түгел. Шуңа күрә дә Зиннур Мансуров бу тетрәндергеч фаҗига турында төрле аспектта, кайта-кайта ассызыклап яза: «Безне күмер хәлендә дә танучылар табылыр», «Йокса йоксын тәнгә корым — каралтмасын күңелне», «Без ... яңадан яралганнар мәгъмүр Болгар көленнән!», «Тамырларым, бикфорд кебек, янып килә йөрәккә!..» Әйе, йөрәк маен сыздырып, эчтән янып язылган юлларга охшый болар.

Максатлы фикер үсешенә һәм драматик ситуациягә буйсындырылган уңай мисалларны тагын бик күп тезәргә мөмкин. Китерелгәннәре дә җитәр кебек. Максатым поэманы сүтеп-җыеп анализлау түгел, әсәрне уку халәтендә алган тәэсирләремне уртаклашу гына. Миңа калса, Зиннур Мансуровның бу әсәре аның бүтән поэмаларына караганда халыкчан теле, анык, төгәл стиле, кешелекле-гуманистик рухы белән үзгә бер уңай якка аерылып тора. Гомумән, «Балкыш» шагыйрь иҗатының үсешен күрсәтерлек әсәр булып чыккан. Поэманы уку процессында авторга әйтәсе килгән киңәш-теләкләр дә уянгалады. Әйтик, авыллар язмышы турында уйлану рәвешендә язылган бер бүлек булса да начар чыкмас иде. Х. Мөҗәй язганча, сугыш бәрелешләре күбрәк авыллар, хуторлар тирәсендә бара. Күпме авыллар кырыла!.. Сугыш бетеп, 30—40 еллар үткәч тә, тыныч вакытта да бик күп вак авылларны массовый төстә бетердек бит... Гомумән, авыл турында бергәләп уйга калырлык фәлсәфә чыгарып була. Сугыш язмаларында да андый бүлеккә ярарлык отышлы юллар бар.

Хәйретдин Мөҗәй үзенең атаклы сугыш язмаларын кырык яшен тутыргач язган («Җилкәдәге кырык яшем җитәр әле, хуш, әйдә, ахыр чиктә газиз халкым гомеренә кушарга»). Ә Зиннур Мансуровка әле кырык ук тулмаган, әмма инде бу чиккә якынлашып килә. Түгәрәкләп әйткәндә, яшьтәшләр, кырыктагылар уйлануы алар: көндәлек үзе дә, яңа язылган поэма да. Тик бу яшьтәшләр арасын-

да ярты гасырга якын вакыт ята. Замана бүтән, шартлар бүтән, буыннар бүтән. Шулай ук һәр ике язмада да уртаклыклар байтак: ил, халык язмышы турында, киләчәк хакында уйлану...

*1987*

## «БАРЫСЫ НИБАРЫСЫ КИЛЕШӘ!»

Нәрсә ул Шигърият? Хисләрнең сурәтеме? Уйларның аҗаганымы? Кайгы-шатлыкларның, сөенү-сагышларның күңелдәге кардиограммасымы?.. Кем белә... Әлегә «Нәрсә ул Шигърият?» дигән сорауга берәүнең дә төгәл җавап бирә алганы юк. Гомумән, аксиомадай җавап була да алмыйдыр, һәм аның, бәлки, кирәге дә юктыр. Әмма... Шигърият никадәр генә сер булмасын, аның тәгаен бер сыйфаты — атрибуты бар, ул — тәэсир итү көче.

Фәиз Зөлкарнәйнең шигырьләрен укыганда, әнә шундый уйлар килде. Мин үзем Фәизне шагыйрь буларак җентекле беләм дип әйтә алмыйм. Ул безнең әдәбиятта иң әүвәл үҗәт-принципиаль сүзле, аналитик фикерләүгә ия талантлы тәнкыйтьче буларак билгеле иде. (Сүз уңаеннан әйтеп узыйк: бездә хәзер җитди һәм объектив тәнкыйть юк диярлек хәлгә төште. Ул — кайбер газеталарда күзәтү, шәхси шәрехләү рәвешендә яшәп-пыскып килсә, күпчелек матбагада прагматик нигездә теге йә бу «шәхес»кә хезмәт күрсәтү рәвешендә генә хөкем сөрә.) Әдәбият сөючеләрне уйландырырлык җитди китаплары бар Фәизнең («Кешем, асылың кем?» 1984; «Әверелеш: шигырь парадокслары», 1988; «Чакма чакмый ут чыкмый», 1991). Соңгы араларда көндәлек матбугатта шигырьләре күренгәли башлады. «Үзе шаян шәкерт, үзе хәким казый да» дигәндәй, ул Куш йөрәкле әдип булып чыга инде: үзе тәнкыйтьче, үзе шагыйрь.

Әүвәле дөньяны яраткан,
аннары — безне, туфрактан әвәләп.
Тырышкан җиде көн буена...
Миңа калса,
мин аңлыйм кебек Алла хәлен.
Җиде көн генә түгел,
кайчаннан бирле бит инде
тәгәрәтәм җир буйлата,
әвәрә киләм бу җан белән;
Әвәлим —
иҗат итеп бетә алмыйм
үземне.
Кыен яратыла икән кеше.
Кыендыр Алла булуы...

Таныш хис: үзеңне эшеңнең остасы — «яратучы»сы итеп тою, Сүзеңә хуҗа була алу, Шагыйрь язмышын күтәрү — тәкъдиреӊ йөге. Түзәсең. Менә «Ачы ачыш» шигыре.

Җүләр баштан акыллы фикер
иске авыздан яңа сүз
көтмә икән
нәтиҗә сәбәпсез
күләгә ялгызы
йөрми икән
ярасыз батыр
хәсрәтсез татар
булмый икән.

«Ялгыз карт» шигырендәге образ-сурәт тә хәтергә уелып кала:

аптыраш
авыз тишеген эзли калтырап
кашык
самоварда тонык чагылыш рәсем
гүя чәйләп утыра йорт иясе.

Ф. Зөлкарнәй — минемчә, шигырьдә «саф сәнгать» вәкиле һәм күпмедер дәрәҗәдә сюрреалистик алымнар белән эш итүче әдип. Дөрес, иҗатчыга нииндидер тарафдарлык ярлыгы тагу четерекле нәрсә. Әйтик, моннан биш йөз еллар элек Нидерланд рәссамы Босх ясаган рәсемнәрне күргәч, испанлы С. Дали да, бүгенге татар рәссамы Ә. Шаһиевлар да бер дә юк җирдән башламаганнар икән, дип куясың. Ә кем ул Босх? Реалистмы? Сюрреалистмы? Авангардистмы?.. Шуңа күрә Зөлкарнәй шигырьләрен дә һәркем үзенчә аңлар, үзенчә бәяләр. Күпчелек шигырьләрдә күнегелгән ритм гына түгел, хәтта тыныш билгеләре дә юк. Шунысын да искәртик: шәкли оригинальлек кемнәргәдер ошамас. Ә бит төбенә төшеп уйлап карасак, ошау-ошамау — критерий түгел. Мода сеанслары күрсәт-

кәндә дә, безгә кайбер модельләр ошап җитми бит. Әйдә, ошатма, үзеңә ошаганын сайла. Булдыра алсаң... Беркем мәҗбүр итми. Сәнгатьтә, бу очракта шигърияттә дә хәл шулайдыр ул.

Моннан унбиш еллар элек миңа Испаниянең Барселона шәһәренең Пикассо музеенда булырга туры килгән иде. Анда, нигездә, Пикассоның үсмер-егет чагында ясаган рәсемнәре куелган. Ул рәсемнәр шулкадәр оста эшләнгән ки, Шишкинның бер якта торсын... Хәтерем ялгышмаса, шул реалистик эшләре өчен рәссам 19 яшьтә Сәнгать академиясенең алтын медален дә алган. Ә аннан соң маэстро иҗаты нинди генә үзгәреш-әверелешләр кичермәгән! Кемнәр тарафыннандыр «абстракт кыланчыклык» дип бәяләнгән күпме эшләр иҗат итмәгән! «Акбүз атка көмешләнгән кара йөгән килешә...» дип башланган дүртьюллыгымны, соңгы ике юлын үзгәртеп һәм бу җәһәттән дәвам итеп, «Дөнья тоткан талантларга нишләсә дә килешә!» дип әйтәсе килә.

Ф. Зөлкарнәй — әдәбиятта үз сүзен, үз йөзен тапкан, әдәби процесска философларча киң карашы булган төпле фикерле әдип. Көяз яңгырашлы, уйлы-гамьле бу иҗатны һич тә «барысы нибарысы» дип кенә булмый. Иҗаты аның холкына, кредосына бик-бик килешә! Ул — кемнәрдер сыман, үзе йөзә дә белми торып, бүтәннәрне диңгезләрне иңләргә әйдәүче тренер түгел инде. Әдәбиятны Фәиз тыштан да (тәнкыйтьче галим буларак, һәм бүгенге әдәби хәрәкәтне оештыручыларның берсе буларак), эчтән дә (төрле жанрларда үзе иҗат итеп) бик яхшы белә. Аның үҗәтлеге исә — үз иманына, үз кредосына тугры булырга омтылу ул.

*1996, 17 ноябрь*

## КАЙТУ

Хәзер күпләр китаптан бизде, дибез. Бу сүзләрдә хаклык бар. Аның каравы, — парадокс, — китаплар да бик күп чыга бит. Элегрәк, ягъни 15—20 еллар элек, мәгънәгә ия һәм дә кирәк китапны кулга төшергән кеше төлке тоткан кебек бәхетле, бүтәннәр алдында абруйлы, хәтта бай кеше исәпләнә иде. Ә хәзер? Урам-чатлар, киоск-киштәләр китаплар белән тулы. Дөресрәге, төрле төстәге, төрле форматтагы, төрле бизәктәге полиграфик товар белән тулы. Ә асылда, чын китаплар, классик мәгънәдә без аңлаган яхшы китаплар сирәк һәм бик сирәк.

Әле күптән түгел — быелгы җәйнең эссе июнь көннәрендә кулыма бер яңа китап керде. Карап торырга матур, затлы китап. Күзне дә, кулны да иркәләрлек. Тышында авторның исеме — Мөдәррис Вәлиев, титул битендә китапның исеме— «Яшьлектән хат». Үтә бер кызыксыну белән, үзгә бер халәттә, бер тында укып чыктым мин бу китапны. Кичерешләр дә үзгә иде: яшьлегем искә төште, моңланылды да, эссе чүлдән талгын җилле яшел оазиска кергәндәй дә хис иттем, нечкә тоемга көйләнгән аерым строфалар сокландырды да, сискәндерде дә... Нәрсәдер яңага сусау булган, ахры (гәрчә миңа эшем буенча көнгә ким дигәндә 150—200 бит язма укырга туры килә). Чын мәгънәсендәге профессиональ осталыкка, төгәллеккә сусау. Сүздә чама хисен белгәннәргә сусау. Туган җир, Туган як турында, Ана һәм Яр турында төчеләнмичә, тыйнак итеп, серле дә, шул ук вакытта әдәпле итеп әйтә белгәннәргә сусау һәм дә ахыр чиктә (без һәрберебез күпмедер дәрәҗәдә сабый да бит әле!) эчтәлегенә ярашлы матур бизәкле «тәти» китапларга сусау... Шулай тәэсирләнеп укуның тагын бер сәбәбе бар. Мин бу егетнең (хәзер инде дөньялыкта ат уйнаткан ир-егет) заманында беренче шигырьләренә, үземчә фатиха биреп, республика газетасында чыгарышкан идем. Бу утыз еллап элек булган хәл. Ул вакытта аның исем-фамилиясе Салих Маннапов иде, уналтысы яңа тулган иде. Менә хәзер ул — 45 яшьлек Мөдәррис Вәлиев булып беренче шигырь китабын чыгарган. «Татарстан яшьләре»ндә (30 октябрь, 1969) басылып чыккан әлеге фатиха-кереш сүздән берничә абзац китереп узасым килә. «Таныш булыгыз: Салих Маннапов» дип атала ул бәләкәй мәкалә.

«Әдәбиятны бик яратып, аның сер-тылсымнарына төшенергә тырышып, үзләре дә каләмнәрен сынап караган укучылар арасында иң активлардан берсе — Салих Маннапов. Ул Әлки районы Татар Мулласы авылында яши. Алпар урта мәктәбенең 9 классында укый. «Коммунизм юлы» газетасы каршындагы әдәбият-иҗат түгәрәгенә йөри. Инде менә өч-дүрт ел буе аның матур гына шигырьләре район һәм республика балалар газетасы битләрендә басылып килә. Шигырьләрен игътибар белән күзәтеп, җентекләп укып барам. Миңа калса, яшьли ятим калып та, мәрхәмәтле, игелекле кешеләр куенында үксезлек күрмичә, тулы хокуклы гражданин булып чыныгып үсеп килүче, тырыш укучы, җәмәгать эшләрендә актив катнашучы Салихның күңел түрендә шигъри талант чаткылары, кешеләргә әйтер сүзе, табигать күренешләренә, кешеләрнең яшәешләренә, гомумән, дөнья хәлләренә карата үзгә бер поэтик карашы бар. Әлбәттә, Салихның шигырьләрендә төгәлсезлекләр, күпләр тарафыннан әйтелгән, кабатланган образлар, тиешле поэтик югарылыкка күтәрелә алмаган юллар, тәгъбирләр дә бар. Кайчак шигъри бизәкләр, образлар стихиясе аны төп фикер агышы магистраленнән читкә алып-алып китәли: тәҗрибәсе җитенкерәмәгән яшь автор атын тыя алмаган, тарантас башындагы малайны хәтерләтеп куя... Сүзнең бөтен мәгънәви төсмерләрен, нечкәлекләрен сизеп, тоеп, аңлап, аның кадерен белергә өйрәнү, әйтерeңне төгәл, кыска, шигъри итеп сөйли белү ахыр чиктә чын мәгънәсендәге осталык-вакыт, тәҗрибә һәм тырышлык белән килә торган сыйфатлар. Әгәр

Салих, әдәбият эшенә ихлас күңел куеп, алга табан шуңа бар сәләтен һәм тырышлыгын салырга теләсә, аңа шатлык һәм газаплар белән тулы өйрәнү мәктәбен узарга туры киләчәк. Тагын шуны әйтәсе килә: заманыбыз — акыл, гыйлем заманы, укымышлылар заманы. Үз эшләренең бүгенге осталары, заманга иш һөнәр ияләре, белгечләр, нинди генә өлкәдә эшләмәсеннәр, аларның һәркайсы әдәбият-сәнгать турында шактый бай мәгълүматка ия. Димәк, алар яратып кабул итәрлек, уйландырырлык, күңелләренә хуш килеп, эстетик ләззәт китерерлек әсәрләр, бу очракта шигырьләр язу уен эш түгел. Димәк, бүгенге көн кешеләрен, үз замандашларыңны дулкынландырырлык итеп язу өчен, безгә тикле яшәгән бабаларыбыз калдырган хәзинә мирасны да, бүтән халыклар әдәбиятлары казанышларын да тирәнтен үзләштерергә, бүгенге талант ияләренең иҗатларын да яхшы белергә тиеш булабыз. Кыскасы, армый-талмый өйрәнергә, җаның-тәнең белән тырышырга, бар күңел байлыгын салып иҗат итәргә! Яшең уналтыда чакта, күңелең тулы дәрт-ашкыну булганда, һәммә авырлык чигенә әле! Яшьлек җиңеп чыкмаслык нәрсә бармыни ул дөньяда!»

Ярый, заманына хас (яшь чакта безне дә тәүфикълы булырга бик шәп өйрәтәләр иде!) дидактик оетКы күбрәк булса да, яшь шагыйрьгә бу үгет-нәсихәтле язма беркадәр тәэсир иткәндер, бәлки. Ә хәзер Шагыйрьнең үз китабына кереш сүз итеп язганнарын укып карыйк.

«Исәнмесез, хөрмәтле Укучы! Бу «хат»ны (ягъни китапны) язучы кем икән дип аптырап калмагыз. Мөдәррис Вәлиев — бик күпләр шикелле, гап-гади сүзләрнең шигъри юлларга әйләнеп китү хикмәтен бала чагында ук кичергән затлардан. Бер каләмдәшебез әйтмешли, әллә инде «Игезәкләр» йолдызлыгы астында тууы аркасындамы, бишектә чакта ук «чып-чын» тәхәллүсе (псевдонимы), ягъни икенче исеме булган аның. Чынында, һич тә уйлап чыгарылмаган, кырыс дөнья бабай кушкан яңа исем-фамилия, тора-бара үзеннән-үзе «Салих Маннапов» дигән әдәби кушамат булып китә. Ихтимал, ике исем кушып, бу малайга язмыш ике мәйданда берьюлы иҗтиһат итү мөмкинлеге биргән, бер үк вакытта ким дигәндә икеләтә көч-хезмәт түгеп кенә ике исемеңне дә аклый алу шартын куйгандыр... Шигырьләре белән «күзгә чалына» башлаган Салихны төрле хәл-әхвәлләр әдәби тәнкыйть дигән өлкәгә алып кереп китә. Китаплары чыга, җәмәгатьчелектә таныла. Аннары инде гомумән дә аңа Мөдәррис Вәлиев дигән рәсми исеме белән нәшрият хезмәтен җигелеп тартыр чак килә. Мөгаен, нәширлек — шулай ук иҗат эшедер, һәм аны һәркем табигать биргән сәләтенә карап башкарадыр. «Күкрәгендә шигырь уты сау» булса да, беренче мәхәббәт шикелле, ул инде эчкәрәк йомыла, чит-ят, салкын-саксыз кулга кагылдырасы да килми башлый икән. Нигездә моннан күпмедер вакыт элек язылган «парчалар»ның бер өлешен болай туплап чыгару — «яшьлектән килгән хатлар»га кеше гомеренең кадерле һәм мәгънәле бер сәхифәсе итеп карау белән бәйле. Шуңа күрә әлеге китапның авторы, бәлки, инде «җитмешенче-сиксәненче елларда ук калган» Салих Маннапов түгел, ә аның бүгенге «варисы» — Мөдәррис Вәлиев булырга тиештер дип уйланылды. Сез күрерсез: кош теледәй генә бу китапта «шагыйрьлеккә дәгъва да һәм, иң мөһиме, андый ихтыяҗ да юк (дөресен әйтим, бу җөмлә мине сискәндереп һәм сагайтып та куйды. — *Р. Ф.*). Бар булганы — бары тик күңел халәте, җан хәрәкәте генә». Документ рәвешендә китерелгән бу ике сөземтә-цитата (ретростатик язма булып чыкты бугай бу) күп нәрсәгә ачыклык кертә, байтак кирәк мәгълүмат бирә шикелле. Аларда — үсеш кардиограммасы, нәтиҗәсе матур булган метаморфоза. Шигырьләренә сүз бирер алдыннан Шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе турында биобиблиографик белешмә биреп узсак, алар, һичшиксез, әдип иҗатын ныграк аңларга ярдәм итәр.

Мөдәррис Харис улы Вәлиев 1953 елның 30 маенда Татарстанның Әлки районы Яңа Камка (Миләүшә) авылында туган. Балалык һәм үсмер еллары шул ук районның Татар Мулла авылында үткән. Алпар авылында урта мәктәп тәмамлаган. Казан дәүләт университетында белем алганнан соң, хезмәт юлын «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясендә башлый. 1979 елдан ул «Казан утлары» журналы редакциясендә өлкән редактор, җаваплы секретарь, баш редактор урынбасары булып эшли. 1989 елдан 1992 елга кадәр Татарстан китап нәшриятының баш редакторы хезмәтендә. Бүгенге көндә «Мәгариф» китап нәшрияты директоры.

Аның шигырьләре 60 нчы еллардан башлап республика матбугатында даими басыла, күмәк җыентыкларга керә, радио-телевидениедән яңгырый. 80 нче елларда ул әдәби тәнкыйть өлкәсендә актив иҗат итә. «Сезгә ышанам» (1984), «Тамыр тирәнлеген яфрак тоя» (1988), рус телендә «Возвращение Звезды» (1992) дип исемләнгән китаплары басылып чыга.

Мөдәррис Вәлиев (Салих Маннапов) — Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Кыскасы, инангансыздыр, булдыклы, шәп егет икән бит бу Мөдәррис Вәлиев дигәннәре! Һәрхәлдә, «Казан утлары» күзлегеннән караганда тәгаен шулай. Ун ел редакциядә эшләп, журналыбызның иҗтимагый абруе өчен көчен кызганмаган зат. Аның бүген дә журналдан аерылганы юк. Инде унбиш еллап редколлегия әгъзасы, даими авторыбыз. Дөрес, күбрәк ул әдәби тәнкыйтьче һәм җитәкче нәшир булып катнаша. Ә шагыйрь буларак иҗатын башлаган әдип «Казан утлары»нда нибары бер тапкыр — моннан 16 ел элек басылган икән. Журналыбызда шигырьләренең икенче тапкыр басылуы. Моны кайту димичә нәрсә дисең инде.

*1998, июнь*

**«ЧЫНЫГА ТОР...»**

Моннан җиде-сигез ел элек: «Фәйрүзә Исмәгыйлова кем ул?» — дип сорасалар, мөгаен, шигырьдәгечә «таныйм да, танымыйм» дип әйткән булыр идем. Үзен юньләп күреп белмим (беренче күрешеп сөйләшү 1991 елның көзендә дип хәтердә калган. «Казан утлары» редакциясенең корректорлар бүлмәсендә какча гәүдәле, дымсу күзле, өлкән курс студенткасы кебек тере, шул ук вакытта сәер оялчан кызчык-ханымны күргәч, «бу күбәләк җан иясенең дә сагыш-моңы, нужа-хәсрәте бардыр инде, юкса шигырьгә ябышмас иде» диебрәк уйлап та куйган идем), язганнарын да матбугатта бик сирәк күреп барам. Шулай да Р.Зәйдулла, Г.Морат, Л.Зөлкарнәйләр белән бер үк чорда Шигъриятькә килүчеләр арасында Исмәгыйлова дигән өметле каләм иясе барлыгын белә идем, әмма аның хакында ачык, бөтен фикерем юк иде. Хәзер Фәйрүзә ханым иҗаты турында беркадәр беләм дип исәплим. Китап итеп чыгарырга әзерләнгән кулъязмасын җентекләп укырга туры килде. Йөз иллеләп шигырь анда. Нигездә, кыска шигырьләр.

Әдәбиятчыга — башлап язучымы ул, классикмы — төп критерий бер: нәрсә турында язасың, ничек язасың? Әлбәттә, белгәнне язарга; әлбәттә, үзеңчә, шул ук вакытта кешеләргә дә ирешерлек халыкчан итеп язарга тиешсең. Бу таләпләргә Фәйрүзә шигырьләре, нигездә, җавап бирә дип уйлыйм.

Ф.Исмәгыйлова — дипломы буенча журналист саналса да, асылы белән педагог-тәрбияче ул. Университет тәмамлагач, дистә еллар буе балалар бакчасында — нәниләр арасында (Миңа калса, хатын-кыз шагыйрә өчен, илһам өчен менә дигән җирлек!). Авылның әнә шул нәниләр дөньясында үзенең дә алма кебек өч баласы да тернәкләнеп үсеп килә.

Ни әвәләсәм — шул пешәр:
сигезле итсәм — сигезле,
кабартма итсәм — кабартма,
мөгезле итсәм — мөгезле.

Шундый уйлар белән бүген
юдым да онлы кулымны,
әвәли-әвәли сөйдем
елмаеп яткан улымны!

Бәхәсләшмәсләр дип уйлыйм: мондый юлларны язу өчен белү генә җитми, кичерү кирәк, әйтү генә җитми, күңел кардиограммасын ачып салу кирәк. Мисалга тагын берничә юл:

Алны-ялны белми елыйсың —
шулай җиңәм мин, дисең.
Чыныга тор: үскәч хәсрәтләрне
җылап та җиңә алмыйсың.

*** * ***

Нәни малай керде төшкә —
өлгерәлмәсәм дә танып,
туп уйнаткандай, күкләргә
чөепләр сөйдем аны.

Ә аннары атындырдым,
утырттым да агач атка.
Малай күккә томырылды —
Акбүз атка канат чыкты!

Ярый, Фәйрүзә белгәнен белеп яза, дидек, ә «ничек яза?»ны ничек дәлиллибез? «Үзенчә яза» дию бик абстракт сүз. Шулай да әнә шул «үзенчә»гә керә торган, минемчә, бик әһәмиятле бер сыйфат — чама хисе. Без заманында шигырь-поэма дип аталган су буе фикерсез язмалар укып үстек. Ялыктырды алар безне. Кыска формаларның соңгы дистә елларда лаеклы урын даулавы әнә шул мәгънәсез (мәнсез) озынлыкка бер протест-гамәл булгандыр, күрәсең. Егет сүзе — кыска булыр. Шигырьдә кызларның егет булуы ошый миңа. Фәйрүзә дә озынга сузмый шигырьләрен. Сүз — эпик колач җитмәүдә түгел, хикмәт — үз (сүз) кадереңне белүдә, фикер җегәрен анык белүдә, әдәп-тактта һәм, ниһаять, укучыны хөрмәтләүдә.

Сирәк язам шигырьләрне
алданган чакта гына,
өзелгән чакта гына,

ялганган чакта гына.

Шигырь Дөньяны үзгәртә аламы? Шагыйрьләр (шул исәптән без дә) әйе, шигырь-илаһи сүз күпмедер дәрәҗәдә үзгәртә, яхшырта ала дип, шул ышаныч белән гомер кичкән кешеләр. Әмма ялган пафос, фальшь белән Дөньяны яхшыга үзгәртү түгел, киресенчә, бозасың гына. Карлыгач томшыгы белән балчык ташып оя сылаган, кырмыска бөек архитектура үрнәге түмгәк-храмын корган кебек, шигырьче дә фәкать үзе күтәрә алган идея-фикерне, шуңа кешеләр алдында җавап тота алырга лаек булып, бүтәннәргә җиткереп иҗат итәргә тиеш. Бу, әле беренче китабын яңа чыгарып килә торган Фәйрүзәдән бигрәк, үзебезгә — шагыйрәдән яшь буенча күпкә өлкән каләмдәшләргә дә кагыла. Фәйрүзә бу хакта уйланамы, уйлаганмы, белмим, әмма эчке тоемы, интеллекты моны, ягъни алда әйтелгәнне, интуитив рәвештә яхшы аңлый кебек.

* * *
Мөлдерәмә күңел белән
Вакыт дәрьясында агышым.

* * *
Үзем генә каласы бар...

* * *
Гөлчәчәкле алан булыр
күз яшьләрем тамган урын.

* * *
Ярамый икән иртәгә
язларның кичке акылы...

Фәйрүзә ханым ерак Азнакайда — әдәби хәрәкәтнең үзәгеннән (хәер, бу төбәктән дә шактый кызыклы шагыйрьләр үсеп чыкты соңгы егерме-егерме биш ел эчендә: М.Галиев, Ф.Гыйззәтуллина, Н.Әхмәдиев, И.Гыйләҗев...) шактый еракта яши. Шаулы, бәхәсле мәдәни-әдәби «казанда» аралашып яшәмәү сизелә. Инде мәгълүм мотивларны кабатлаулар очрый. Техник яктан эшләнеш — рифма-ритм төгәлсезлекләре дә юк түгел. Самимилек, ихласлыгы белән алдыра да, күбесен кичерәсең. Иң мөһиме — иҗатта очу биеклекләрен бутамау. Бөркет үзен чыпчык, чыпчык — бөркет дип, очыш юлларын бутаса, көлке...

...Элек әдәбиятка керү кыен иде. Күпме киртә-капкалар! Һәм... көндәлек матбугатта ничаклы талант иясенә кулъяулык чаклы мәйдан! Партия органнары җитәкләгән басмаларда ун-унбиш юл чын шигырь чыгару үзе бер вакыйга иде. Ә хәзер хөррият! Сүз ирегеннән тыючы юк. Ә хәзер кемнәр генә чыгармый китапны! Яз да яз! Фәйрүзәнең үзе әйтмешли, әвәлә дә пешер! Юк шул! Беренче карашка гына җиңел кебек. Хәзер ул кыен чын әдәбиятка юл яру! Ни өченме? Беренчедән, моңарчы җыелган (һәм тыелган!) Бөек Мирас безгә иреште. (60 нчы еллар башында яхшы китап таба алсаң, төлке тоткан кебек сизә идең үзеңне.) Икенчедән, китап укучы кимеде, гавам китаптан бизде. Базарың булмый торып, чүлмәк ясап яшәп кара! Өченчедән, язу-сызу эшендә (әдәбиятта дип язасы килми) бик болганчык заман. Тәҗрибәсез укучыга ориентлашу кыен. Шәп тышлы, ялтыравыклы бизәкле китаплар тулып ята. Кайсы җәүһәр дә, кайсы ком-балчык (һәммәсе буяп бизәлгән!)?.. Шуңа күрә дә хәзер Зур Әдәбиятка кереп, үзеңә урын даулау бик кыен. Мондый хезмәткә алыну — сабый батырлыгына тиң.

...Сүз әйтмәгез
хис канатында
оча белүче
бу хатынга.

Оча бирсен
Җирдәге тормышны
әз генә булса да
матурлап.

*1999, июль*

**«ЧИКЛЕ ЧИКСЕЗЛЕК»**

Рәмис Аймәтнең 2000 елда чыккан «Шомырт салкыннары» дип исемләнгән китабы һәм соңгы елларда язылган шигырьләре (алар «Мәгариф» нәшриятында «Айның ар ягында» исеме белән аерым китап булып чыгып килә) белән танышкач, бүгенге шигъриятебез, бигрәк тә яшьрәк шагыйрь-шагыйрәләр иҗаты турында төрле хисләр кичереп, уйланыбрак калдым әле. Уйланыбрак кына түгел, үзүзем белән сөйләшеп дигәндәй, бәхәсле уйларга да тарыдым шикелле. Бусы да ярый. Димәк, битараф калдырмаган, уяткан, кузгаткан…

Рәмис Аймәт—шагыйрь, һәм дә профессиональ яктан шактый ук җитлеккән шагыйрь. Шигырьләре гамьле, мәгънәле; композицион яктан төзек, күбесе камил дәрәҗәдә. Рәссамнәр өчен пространство һәм пропорцияне «үтәли күрү» ничек мөһим булса, шагыйрь өчен Сүзнең куәтен һәм мәгънәви матурлыгын тоя алу иң кирәк зарурлык. Шуңа өстәп, әлбәттә, күңел генә үлчи ала торган чама хисе… Тырышып, өйрәнеп кенә булдырырга мөмкин нәрсәләр түгел; Табигатьтән, тумыштан бирелә торган сыйфатлар алар. Йә бар, йә юк. Шөкер, шагыйрьлекне Рәмискә табигать үзе мул биргән. Өстәвенә Рәмис Аймәт көнкүреш-яшәештә дә булдыклы, үткен егет булып чыкты. Менә дигән журналист, шәп оештыручы буларак, әдәби-иҗтимагый тормышта аның инде үзе сызган буразналары, ярыйсы ук саллы хезмәт-биографиясе бар. Әйтик, барлыгын да бик азлар гына белгән Шәриф Камал музеен яңадан халыкка танытты ул. Мөмкинлекләре чикле булса да, музейны үзенә күрә бер мәдәни учакка әйләндерә алды. Хәзерге көндә Габдулла Тукай музее директоры буларак нәтиҗәле, актив эш алып бара. Моннан җиде-сигез ел элек әле утызы да тулмаган яшь егет Язучылар берлеге рәисе урынбасары булып та эшләп алды. Ул вакытта берлек әгъзасы да түгел иде бугай… Матбугатта, бигрәк тә «Шәһри Казан» газетасында, аның күренекле каләм осталары белән төпле әңгәмә-язмалары һаман истә. Республика масштабындагы күпсанлы әдәби-музыкаль кичәләрнең истә калырдай булып узуында да аның хезмәте зур: сценарийлар яза, оештыра…

Ярый, хуш, болары шәп; шигърияткә күчик. «Нәрсә ул Шигърият, нәрсә ул Поэзия?» дип, риторик сорау куеп тормабыз. Чөнки төгәл билгеләмәсен барыбер беркем дә әйтә алмас. Галимнәр матдә-төшнең үзәгенә үтеп өйрәнә алсалар да, хис һәм фикер төенен таркатып анализлап бетерү мөмкин түгел. Мәхәббәт шикелле, ачып бетерелмәгән серлелеге белән мәңгелектер дә ул. Ә сер булганда гөманга урын бар. Шуңа күрә һәркемнең үз аңлавы, үз мөнәсәбәте. Берәүнең берәүгә «син—үзең шигырь!» дигәнен ишеткән бар. Димәк, ул—кызык, бай, гомер буе өйрәнеп яшәрлек кеше! Үзебез дә бер сорау куйыйк әле: борынгы заман шагыйренең мәхәббәт шигырьләре бүгенге шагыйрьнекеннән нәрсәсе белән аерыла? Кайчакта фәлән гасырда язылган шигырьләр күбрәк тә тәэсир итә әле! Шулай булгач?.. Юк, һаман языла, язылачак мәхәббәт шигырьләре! Димәк, ул—кабатланырлык, «кабат яңырлык» мәңгелек тема, мәңгелек яңу мәйданы. Ә «заман улы», «бүгенге көн каһарманы», «чор елъязмасы» дигән төшенчәләр каян килгән? Без бер-беребезне рәсми йә нәрәсми рәвештә бүгенге көн сулышын тойдырткан әсәрләр язарга өндәмибезме? Хак нәрсәме бу, әллә күпмедер дәрәҗәдә мәңгелеккә омтылуны чикләүме? Күз алдына китерик: каядыр—күренерлек ераклыкта йорт-оя янып ята, кемдер ут эчендә, ә шул вакытта син, бернигә исең китмичә, мәхәббәт шедевры язып утырасың… Бер җирдә—фаҗига, бүтән бер җирдә—тантана. Вердикт чыгарып, хөкемдар булу кыен. Бер уйласаң, үлемсез әсәр тудыру—үзе могҗиза, үзе батырлык бит әле! Әй, дөнья! Кем шагыйре син? Кайда яшисең? Фәләстыйнда яки Швед җирендәме? Франциядә яки Чечнядамы? Кояш бер булса да, болытлар төрле, җирдәге күләгә-шәүләләр төрле… Тамчы балкышлары бертөслерәк күренсә дә, чыкныкымы, күз яшенекеме икәнен сирәкләр белә.

Рәмис Аймәт шигырьләрен укыганда килгән сораулы уйлар бу. Иҗат кредосы, эстетик принциплары үткән гасырның икенче яртысында формалашкан, әдәбиятка алтмышынчы елларда килеп, бүген 60 яшьлекләр рәтендә саналган, поэзиябез кемнәр кулына кала дип җитди уйланып йөргән кеше башына килгән уйлар. Рәмис—бездән соң килгән буын, безнең балаларыбыз буыны. Кайсы заман шагыйре соң бу Рәмис Аймәт дигәннәре? XVIII яки XIX гасырныкымы, әллә XXI некеме? Рәмиснең үтә индивидуаль шигырьләрен укып моңа тиз генә җавап табу кыен. Ә беләсе килә! Заман чалымнарын сиземлисе, тоясы килә. Мине, сине борчыган проблемалар турында шагыйрьнең дә мөнәсәбәтен ачыклыйсы килә!

Ялгызлык—иҗатчының гомер юлдашы. Шагыйрь кеше ялгызлыкта Дөнья белән сөйләшә торган зат. Шуңа да иҗатта лирик «мин»нең булуы табигый хәл. Әмма… чама белән… Шагыйрьнең «лирик мин»гә тулы хакы булса да, фәкать тоташ «мин»гә генә хакы юктыр. Рәмиснең байтак шигырьләрендә «Дөнья һәм Мин» (бәлки әле, «Мин һәм Дөнья»дыр?) төп лейтмотив булып бара. «Мин Коръәннең әле бүгенгәчә язылмыйча калган аяте» (!), «Көтәм хәзер бары Үземне мин, кайтам хәзер бары Үземә», «Мин әле тумаган, ә инде Күкләрдә укыйлар җеназа», «Үз күчәрем тирәсендә үзем сәгать угы кебек әйләнәм», «Мин җирләргә төштем. Озаккамы?..» Мондый юлларга, һәр шигырьдә үк булмаса да, икесенең берсендә тап буласың, С. Рәмиевнең «Мин»е кечкенә булып кала…

Әллә Рәмис, «искәрмәсе булып кануннарның», моңарчы беркем дә белмәгән үзгә микро яки макродөнья тудырамы? Һәрхәлдә егеттә моңа омтылыш бар. Амбиция дә, нарциссслык та, сәләт тә. Тудыра калганда кешеләргә (гавәмгә дип әйтсәк тә ярыйдыр) кызык һәм тансык булырмы ул дөнья?

Дөресен әйтим: Рәмис шигырьләрен кат-кат укып та, язганнарының җелек-үзәгенә үтә алмыйча шактый изаландым. Ә «ачкыч» «Шомырт салкыннары» китабының аннотациясендә ачык ята икән ләбаса. Анда болай язылган: «Китап — яшәү-үлем арасында бәргәләнгән мәңгелек җанның сыктау һәм тантана итү үзгәлеген тоя алучыларга багышлана…» «Мәңгелек җанның үзгәлеген тоя алучылар» күп булмаска да мөмкин. Әмма һәр кешенең шигырьләргә карата үз фикере булуы бик ихтимал. Мин, мәсәлән, шагыйрьнең кайбер шигырьләрен укыганда үзгә бер сәер хис (һәрхәлдә дәртле, шатлыклы, «яшәргә котырта торган» хис түгел) кичердем: әйтерсең айлы төндә мәрмәр ташлар арасында — Мәңгелек Йортта йөрим… Ялгызлык. Мәгърурлык. Билгесезлек. Чарасызлык. Мизгеллек… «Зират җиле…» Шигырьләрдә төшенкелек мотивлары да җитәрлек. «Язмыш суккан имән кебек мин дә, аунап ятам җирдә — ни чара?», «Белмәдегез кадерем! Нурым хәрам! Җирдә— золым. Барыйм кая мин?», «Каракоштай атылыр гарешләргә, соң сулышым, соңгы сәламем», «Дөньямда тереклек юк инде, юк күптән», «Ах, арылган чиксез галәмнәрдә оча-оча бөтен көчемә», «Авып бара шәмем…», «Кәфенемне бирче ак бүз ертып, икмәк кебек, җаным төрергә»… Әгәр, С. Хәким әйтмешли, «Мусалар, Алишлар торып», Туфаннар, Батталлар, Исәнбәтләр уянса, яшь шагыйрьнең әлеге шигырь юлларын укып гаҗәпләнерләр иде кебек… Остазларча, көрәшчеләрчә (һәр көчле кеше көрәшче булмый, һәр пәһлеван мәйданга чыкмый икән!) сабак-киңәшләрен бирерләр иде… Автордан янә бер цитата: «зыр-зыр килеп мин үз күчәремдә, чыгармын күк тәмам чыгырдан». Чыгырдан ук (чамадан ук) чыкмаска иде бит!..

Алда әйтелгәнчә, Рәмис Аймәт — чын шагыйрь. Шигырьне шактый оста үрә белә. Табигать стихиясендә табигый «эри» ала. Ул үзен Җир, Су, Күкнең тере бер күзәнәге итеп тоя һәм шуны шигъри сурәттә раслый да. Яңгыр белән бәйләнешле берничә шигырьне генә укысагыз да, сез моңа инанырсыз. Үзеңне Табигать берлегендә тою зур нәрсә, шагыйрь өчен — бигрәк тә. Китапта поэтик күренешләр аша уйга салырлык строфалар шактый мул. Гомумән, шагыйрьнең потенциаль мөмкинлеге зур. Хәер, яше дә бәләкәй түгел: җитлеккән Пушкиннар, Байроннар яше. Татар шагыйрьләренең дә байтагы (Бабич,Тукай, Такташ, Кәрим, Җәлил…) кырык яшьләренә кадәр тормышта һәм поэзиядә төп миссияләрен үтәгәннәр инде. Үрнәкләр, гыйбрәт алыр хәлләр җитәрлек.

Шәхси-интим хисләргә күп урын бирелсә дә, Р. Аймәт иҗатын тематик яктан тар дип әйтмәс идем. Мәңгелек категорияләр белән фикерләүгә омтылыш булгач, тар була да алмый. Мәсәлән, Ирек турында фәлсәфи шигырьләре бик тә гыйбрәтле. Шәхес Ирке фонында ил-халык Ирегe турында да тирән мәгънәле фикерләр әйтелә. Соңгы елларда язылган әсәрләрендә, үткән заман термины белән әйтсәк, гражданлык хисләре көчле. Шулай ук Р. Аймәт шигырьләрендә Такташ, И. Юзеев, Роб. Әхмәтҗан, Зөлфәт кебек шагыйрьләр иҗатына хас романтик юнәлеш тә уңышлы үстерелә дип беләм. Киләчәктә, шагыйрь иҗатының аңа гына хас асыл сыйфатларын күреп, аңа гына хас үзенчәлекләрен тәфсилләп анализлаучылар булыр әле. Шәхсән минем үземне Рәмиснең кайбер шигырьләре үлем-яшәү, мәхәббәт-хыянәт, хыял-чынлык, галәм-күзәнәк, җир-күк, җәннәт-кыямәт, рия-ихласлык, мәңгелек-мизгел кебек категория-төшенчәләр турында янә кайтып уйланырга мәҗбүр итте.

Шигърият дип җан атып тормаган бу заманда (андый заман юк та бугай) һәр талантның халык файдасына тулырак көчендә эшләве безнең өчен бик мөһим. Шигърият мәйданында, ир-егетләрдән бигрәк, кыз-кымыз мәш килгән чорда бигрәк тә.

Дөньяларның кайсы читендә мин,
Вакытларның кайсы чигендә,
Гомеремнең кайсы мизгелендә,
Хыялымның кайсы күгендә
Яшим икән?

Бу юллар Р. Аймәтнең «Икән?!» исемле шигыреннән. Шагыйрьгә үз сорауларына җавап табарга булышыйк.

Дөньяның читендә түгел, уртасында, көрәшче булып, ил гаме белән яшә! Вакыт эчендәге вакытны табып, халкыңа хезмәт ит! Гомереңнең иң матур чоры — хезмәттә яну чоры. Хыялыңның күге—ил бәхетенә багышланган олуг иҗат булсын!

*2004, декабрь*

## КИТАП ГАСЫРЫ КИТӘМЕ?

**1999** дагы тугызлы саннарның аякләре салынып түгәрәкләнгәч, язмаларыбызда рәттән симез өч «**000**» күренгәч, яңа гасыр быел ук башлана дип уйлаучылар да булды бугай. Ашыкмыйк: өченче

меңне башлаган яңа гасыр таңына тагын бер ел бар әле! (Бу хисап миладИ буенча, һиҗри белән исәпләсәң, бөтенләй бүтән гасырда әле без!) Бәрәкәтсез тиз узса да, бер ел әллә никадәр хәл-вакыйгалар, көтелмәгән үзгәрешләрне үз эченә ала әле ул. Исән-сау булсак, яңа гасыр бусагасын атлаганда укучылар белән уртаклашырлык яңа уй-фикерләр табылыр, бәлки. Ә хәзергә — язма сүз, басма китап язмышлары сүз сәнгатенә бәйле каләмдәшләрем хезмәте турында.

...Китап гасыры үтеп бара. Бу сүзләрне кәгазьгә төшерәм, ә җан бәргәләнә. Кул яза, күңел килешми. Ә нишлисең, Вакыт Галиҗәнапларына каршы чара юк. XX гасыр — информация-коммуникация ягыннан — телефон, радио, самолет, телевизор, кибернетика гасыры булды. Фән казанышлары кешеләрнең рухи дөньясын бик нык үзгәртте. Шулай да дөньяны танып белүдә, эстетик тәрбия бирүдә Китап төп чыганак булып кала бирде. Шулай булмый ни! Китап — ничә гасырлар буе Кеше акылының могҗизасы саналды. Гомер бакый Кеше җанының сердәше булды. Ул — уйлатты, елатты, сөендерде, нәфрәтләндерде, хыялландырды... Гомер буе сабак бирде... (Китап белән бергә хатлар язу, хат алышу гасыры да үтеп бара түгелме соң? Кызганыч... Ничәмә-ничә буын хат язып, хат көтеп хыялланып яшәде бит!) Ризасызланып булса да, килешергә туры килә: гасырыбызның соңгы чирегендә телевидение һәм компьютер системасы информация пространствосыннан басма Китапны шактый кысрыклады да. Бер генә мисал: кайчан гына яхшы язу машинасы булдыру турында хыяллана идек. Хәзер аларның хаҗәте бетеп бара... Фән акылы казанышларын гавами акыл үзләштерергә өлгерә алмый. Цивилизацияле дөнья компьютерның интернет челтәре белән эш итә хәзер. Кешелек аңы тарихында үзе бер революция. «Виртуаль чынбарлык», «тинейджер» (компьютер «җанлы» кешеләр) дигән төшенчәләр барлыкка килде. Меңәр чакрым ераклыктан кешеләр үзара мәгълүмат алу гына түгел, хәтта тәнни-хисси мөнәсәбәтләргә дә керә алалар дип сөйлиләр... Йа Хода, илаһи дип йөргән Китабыбыз нишләр инде? Ахырзаман бәндәләренең Аңа ихтыяҗы булырмы?

Дөресен әйтик, күңелдә тәшвишле уйлар булса да, Китап язмышы белән нисбәтән киләчәккә өметсез үк карамыйм. Халкыбыз Китапның үз язмышы икәнен аңлар дип ышанам. 200 еллап тарихы булган Америка өчен китап — бер нәрсә булса, меңәр еллык дәүләтле тарихы булган Европа илләре өчен, бәлки, икенчерәктер китапның миссиясе... Ә безнең өчен ул төп байлык. Ул моңарчы безнең өчен — Дәүләт тә, Дин дә, Гыйлем чыганагы да булып килде. Элгәргеләребезнең бөек сүзләрен искә төшерик: «Мәгъмур Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады... Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады (...), алар сәламәт әле, алар яңгырый әле» (Г.Тукай). «Иҗтимагый иректән мәхрүм ителгән халыкта әдәбият аның вөҗдан һәм ачу авазын ишеттерү өчен бердәнбер трибуна булып тора» (А.Герцен). Болар — үткән гасырларның хикмәти җан авазлары.

Әйе, без Китаптан аерылырга тиеш түгел. Әлегә «Йосыф-Зөләйха» кыйссаларыннан, «Идегәй» дастаннарыннан килгән рухи яктылык яшәтә. Китапларга салынган җегәр-көч бик тә кирәк әле безгә. Хәзерге рәсми статистика ягыннан карасаң да, алга киткән байтак халыклар нисбәтендә, бүген дә югары белемгә ия кешеләр саны буенча без шактый түбән урында. Һәрхәлдә, киләсе гасырның байтак дистә елларында без Китап Укучы Халык булып дөньяга кереп калсак иде! Шушы урында бик тә мөһим бер нәрсәне ачыклау кирәк. Нинди китап белән киләчәккә бармакчыбыз соң? Кайларда алар? Кемнәр чыгара аларны? Авторлары кем? Укучылары кем һәм күпме? Чыннан да, чигәләреңне тотып уйланырлык хәл. Бер карасаң, китапка дәрт кими бара дибез, икенче яктан — дөнья тулган китап белән. Зур форматлысы, кечкенәсе, ялтыравык тышлысы, рәсемлесе... Тик аларның күбесе, иң аз дигәндә өчтән икесе — псевдокитаплар, полиграфик ысул белән кәгазьгә төшкән опуслар, кеше җанын көчләүче язмалар, очсыз анекдот-мәзәкләр, хайвани инстинктны кытыклаучы детектив хикәяләр, порножурналлар... Югары кыйммәткә, тәрбияви әһәмияткә ия, эстетик зәвык белән чыкканнары да җитәрлек. Фәнни басмалар, белешмә сүзлекләр, дөнья классикасы үрнәкләре... Алар, кызганыч, азрак керә йорт түрләренә. Китапханәләр, китап кибетләренә караганда затлы банк биналары, коммерция офислары күбрәк төзелә хәзер. Әлбәттә, аларның үз дөньясы, үз китаплары, күбрәк табыш алуга файдалы методик әсбаплар... Татар дөньясының китап чыгару тарихына баксаң, бер уртак хәлгә тап буласың: гасыр башында да, гасыр ахырында да матбагада хөрлек булган: теләсә нәрсә чыгарып була! Ләкин аерма бар. Татар галәмендәге китаплар, нигездә, берничә төрдә: матур әдәбият (шул исәптән халык иҗаты үрнәкләре); дини әдәбият; дәреслекләр, фәнни-белешмә басмалар. Бәлки, китапчы-галим, академик Ә.Кәримуллин да шул фикердәдер. Ул чорда әдәпсез-оятсыз «әдәбият» үрнәкләрен таба алмыйсың. Шуңа күрә ул замандагы китап мирасы, нигездә, милләт киләчәгенә, аның мәгърифәтенә хезмәт иткән, милли үзаңны үстергән. Р.Фәхретдин, Г.Тукай, Г.Исхакый, Дәрдемәнд, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов һәм башка әдипләрнең иҗаты шул хакта сөйли. Ә хәзерге вазгыять? Хәлнең ничеклеген алдарак беркадәр әйттем шикелле. Китап дөньясында хаос. (Рәсәйдәге яшәүнең көзгесе!) Күпләр нәрсәнең китап, нәрсәнең антикитап икәнен аера алмый. Парадокс хәл: Китапны «китап» бетереп бара. Республикада, белүемчә, китап чыгаруга лицензия-хокук алган йөзләгән

нәшрият (!) бар. Нигә шулкадәр үрчегәннәр соң алар? Аларның күплегеннән берәр нәрсә отабызмы? Төгәл җавап бирү авыр, күңел авазы «отмыйбыз» ди. Чөнки аларның туксан фәлән проценты, ничек кенә булса да, нәрсә чыгарып булса да, табыш алу максатын куйган басмаханәләр. Миңа калса, бүгенге көндә традицион тәртиптә төп ике оешма — Татарстан китап нәшрияты һәм «Мәгариф» нәшрияты гына дәүләтчел сәясәт алып барып, киләчәкне күз алдында тотып, эшчәнлек алып бара. Һәрхәлдә, бу нәшриятлар чыгарган китаплар өчен, нигездә, оялырлык түгел. Кайбер чыгарма мисаллар табып була булуын. Әлбәттә, бу төп нәшриятлар тагын да нәтиҗәлерәк — күбрәк китаплар да чыгара алыр иде дә, әмма бюджет тарафыннан каралган суммаларның да өчле-тугызлы, ягъни ярым-йорты бирелүе сәбәпле бөтен тулаем көчендә эшли алмый. Шул сәбәпле байтак авторлар, очсызлырак чыгара торган коммерция басмаханәләргә мөрәҗәгать итәләр. Ә эшкуар басмаханәчеләр теләсә ни чыгарырга әзер! Андый авторлар, мең бәла белән акча юнәтеп чыгарган китапларын үзләре сатып, үзләре урнаштырып йөрергә мәҗбүрләр. Дәрдемәнд, Акмулла яки кырык тартмачы... барысы бергә буталган...

Китапханәләргә кергәч, бөрешеп калам
Китап киштәләре алдында.
Бөек уйлар тулы изге сарайдан соң,
Кичке Күккә карыйм нарасыйланып.
Анда да мәңгелек йолдызлар...

* * *

Ике хәзинә бар дөньяда: саклагыз!
Каберстан аның берсе. Гел гөлдә булсын!
Китапханә икенчесе. Күңелдә булсын!
Базар болай да калыр...

...Булды заманнар — безнең халык китапларны күмәргә дә мәҗбүр ителде. Яндырылудан саклап калганнарын, Иманлы тормышка өмет өзгәч, кояш астында рәнҗетелгәнче, ичмасам, укымышлы затларның җәсәде белән изге туфракка иңсен дип, үз акыллары белән дә күмделәр аларны...

Безгә, минемчә, Китапларны, Чын Китапларны саклау, үстерү, аларны яңа буыннар рухына сеңдерү юнәлешендә кардиналь чаралар кирәк. Дәүләти максат һәм стратегик планнар белән.

Беренчесе, һичшиксез, булган бөек мирасны (шөкер, ул бар! Булмаса, нишләр идең!) җыеп-туплап, бастырып, һәрдаим халыкка җиткерү, ирештерү, аңына сеңдерү. Бу җәһәттән, ассызыклап үтик, байтак эшләр эшләнә дә. Тел, әдәбият, тарих институты (хәзерге Тел, әдәбият, сәнгать институты), Татарстан китап нәшрияты, соңгы ун елларда барлыкка килгән «Мәгариф» нәшрияты, «Мирас» журналы... Халыкка ирештерелгән уникаль басмалар... Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, «Идегәй» дастаны, Мөхәммәдъяр поэмалары, Утыз Имәни, Кандалый әсәрләре...

Икенчесе — дин нигезләрен ныгытуга, әхлакый тәрбиягә ярдәм итә алырлык югары кимәлдәге әсәрләрне, икенче төрле әйткәндә, иманлы әдәбиятка өстенлек бирү. Бу — җәмгыятьне савыктыруның бер юлыдыр. Бездә хәзер төрле-төрле басмаханәләрдә дини әдәбият шактый күп басыла. Тик аларның төп өлеше әлегә кустарь дәрәҗәдә. Рәшидә абыстай (Р.Исхакова) чыгарган китап-брошюралар үз вакыты өчен ярап та куядыр, алар да кемнәргәдер кирәктер. Әмма... Дин тәгълиматы ягыннан да, художество-нәфислеге ягыннан да, Мәрҗани, Риза Фәхретдин, Муса Бигиев, Галимҗан Баруди хәзрәтләренең хезмәтләре югарылыгына, һай, ерак әле бүгенге дин хадимнәренә!

Күңелдә иман булмаса —
мәчет ни дә, азан ни!
Җәһаләт белән сәрхушлек
безне әле озак җәзалар...

Өченчедән, борын-борыннан безнең халыкның Китапны изге дип санавын истә тотып, традицион мәгънәдәге әдәби әсәрләрнең сыйфаты камил булырга тиешлеген онытмаска тиешбез. Бу — безгә, һөнәре итеп әдәбиятны сайлаган профессиональ язучыларга карый. Язучы исемен, кесәсендә шуның шаһадәтнамәсен йөрткән күпме каләм ияләренең күпме чүп-чар «әсәрләре» дөнья күрә! Үзебездән дә ояла белик! Таләпчәнлек җитми. Әзме-күпме иҗади процесска йогынты ясый алырлык иҗат оешмаларының, остаханәләрнең, әдәбият-сәнгать өчен җаваплы дәүләт хадимнәренең таләпчәнлеге җитми. Тумыштан килгән сәләт-талант бер нәрсә, ә осталык — икенче нәрсә, аңа ирешер өчен гомер кирәк, үзеңне аямау кирәк. Дөресен әйтик, чын мәгънәсендә туган телнең нечкәлекләрен белгәннәр дә сирәкләнеп бара... Төптәнрәк уйласаң, безнең Китапның башында — дөнья цивилизациясенең җәүһәре, иң мөкәммәл китап Коръән тора. Шуны онытмаска иде!

Ярый, фәлсәфәбезне кыскартып, җиргә төшик, бүгенге яшәешебез хәлләренә, бүгенге реаль вазгыятькә килик. Менә дәверебезнең яңа бер елы башланды. Газеталар, журналлар язылган

әбүнәчеләр саны буенча яңа тиражлар белән басылып чыга башлады. Яңа дигәч, гадәттә, күбрәк, мулрак итеп күрәсе килә дә бит! — ни хәл итмәк кирәк, — татар матбугатын быелга алдыручылар ишәймәде. Димәк, милли үзаңны үстерүче бер фактор кимеде. Димәк, үзбилгеләнүгә, дәүләтчелеккә, бәйсезлеккә (Декларация кабул ителүнең 10 еллыгында!) яңа адым атланмады. Хакыйкать: татар телендә чыгучы басмалар, асылда, милли идеяне халыкка сеңдерүче басмалар бит алар. Матбугатка язылуның сайлаулар кампаниясе вакытына туры килүе дә безнең өчен зыянга гына булды. Депутатлыкка үтү өчен берсен берсе этеп-таптап, саташыр дәрәҗәгә җиткән кандидатларның (ә аларның абсолют күпчелеге — эш башында торучылар) үз марафоны. Күбесенә китабың ни дә, журналың ни!.. Сүз дә юк, китап алдыру, көндәлек матбугатка язылу матди җитешлеккә бәйле. Парадокс: җәмгыятьтә акча күп тә, акча юк та! Галәмәт күп баскычлы, күп пирамидалы идарә структура кешеләренә акча бар һәм мул бар, гади игенчегә — юк; хоккей, машина куу ярышлары өчен акча бар, милли университет ачарга, классикларның күптомлык китапларын чыгарырга — юк; башкаладан килгән ярым шәрә, ярым наркоман «поп-йолдызлар»га астрономик суммалар бирер өчен акча бар, ә өлкән бер хөрмәтле(?!) язучыга каләмхак түләргә — юк... Бәлки, кәгазьгә кытлыктыр? Кәгазь чыганагы — шау урманнар кырылып киселә бара... Алай дисәң, дөнья кәгазь белән тулган. Шәһәр җирләрендәге почта әрҗәләрендә дыңгычлап тутырылган реклама газеталары... Тик татарчалары гына юк. Хәер, сайлау өндәмәләрендә андыйлары да очрый... Безнең матбугатны укучылар, шул исәптән «Казан утлары»н да, байлар, финанс магнатлары, елгыр малтабарлар (ярый ла бертуган Кашаповлар кебек керемнәренең бер өлешен, әйтик, зәкят өлешен, халык өчен кирәк китаплар чыгаручылар булса!), бар вөҗүдләре һәм гамәлләрен фәкать өстәге идарәчегә яки идарәчеләргә карап эш йөртүче марионет җирле түрәләр түгел, ә тормышларын очын очка ялгап баручы гап-гади кешеләр — игенчеләр, авыл интеллигенциясе, пенсионерлар, укытучылар, студентлар... Алар, чыннан да, бүген ярлы катлам. Бик теләгәндә дә, языла алсалар, бер яки ике газета-журналга язылалар. Бу очракта җирле хакимият башлыкларыннан күп нәрсә тора. Халыкка, төрле юлларын табып (алдынгыларны бүләкләү, пенсионерларга бушлай яздыру, авыл мәктәпләренә, китапханәләргә шефлык итү һ.б.), рух хәзинәсен илтә алу саваплы да, мәгънәле дә булыр иде, хезмәт кешесенең күңелен яулау да булыр иде! Хаким кеше хәким дә булса икән! Тормышыбызда андый тәңгәллек мисаллары да бар: быел җәй Президент М.Шәймиевнең республика китапханәләренә яңа китаплар кайтару өчен 2 млн. сум акча бирдерүе — җәмәгатьчелек рухын савыктырып җибәрде. Дөрес, Президентның мөмкинлекләре гаять зур. Әмма түбәкләр җирлегендә район башлыкларының да дәрман-хокуклары шактый... Сүз уңаеннан шуны да әйтеп узыйк: район башлыкларының туксан процентлабы Казанның авыл хуҗалыгы һәм ветеринария институтларында (хәзергечә әйтсәк, академияләрдә) укып чыккан кешеләр. Күп нәрсә аларның интеллектуаль әзерлекләренә бәйле. Шулай булгач, бу югары уку йортларында тиешле гуманитар белем бирү дә көнүзәк мәсьәләләрнең берсе булып кала.

Китап гасыры үтеп бара дидек. Гасыры үтсә дә, Китап дигәннәре бездән кул болгап тиз генә үтмәс әле, боерган булса... Ел ахырында гына татар халкының рухи тормышында бер тарихи вакыйга булды: ниһаять, күп буыннар хыялланган «Татар энциклопедик сүзлеге» дөнья күрде. Олы казаныш. Әйтүләренчә, алдагы елларда биш томда энциклопедик басма чыгачак. Күпме генә зарлансак та, олуг әдипләрнең (мәрхүмнәрнең дә, исәннәрнең дә) күптомлыклары чыгып тора. Соңгы елларда татар тарихына караган, объектив мәгълүматларга бай булган саллы-саллы фәнни китаплар халыкка иреште. Сәләтле яшь (чын мәгънәсендә яшь!) талантларның китаплары чыккалап тора. Милли мәгариф системасының тернәкләнеп килүенең бер мисалы бу. Киләчәккә өмет-ышаныч бар. Гасырлар буе тупланган генетик аңга, халык акылын һәм хакимнәрнең җегәр-куәтен кушып, бергә-бергә иҗтиһат иткәндә, киләсе гасырда да Китап безнең гомерлек юлдашыбыз булыр, шәт. Амин!

*1999, ноябрь*

## СЕЗ КИТАПЛАР ҖЫЯСЫЗМЫ?

Унике-унөч яшьләрдәге сөйкемле генә малай тышлары инде саргая төшкән китап бәйләмнәрен, читләре чачаклана башлаган журнал төргәкләрен тәкәллефсез генә кузовның бер почмагына атты да мыгырдап куйды:

— Күптән чыгарып ташлыйсы чүпләрен ташып йөриләр шунда!..

Яңа фатирга күчерешергә, булышырга дип килгән олыларның да берсе әлеге малайның сүзен куәтләде:

— Хәзер бит газ! Ягарга мич юк...

Кешеләр ыгы-зыгы килеп өйдән әйбер ташыйлар. Машина өстендәге малай белән әлеге агай ташыган берсен урнаштырып торалар. Китап өемнәре өстенә аяк киемнәре, мендәрләр, корымлы табалар менеп утырды. Мескен китаплар, кайчандыр кемнәрнедер сөендергән, кемнәргәдер бик газиз, кадерле булган басмалар йөзләре белән бозлы такталарга елышып, аста калдылар.

Шул ук көнне булды: телевизордан хоккей күрсәттеләр. Канадалылар белән чехлар очрашты бугай. Уенның бик яман кызган бер мизгелендә бер хоккейчының кәшәкә таягы сынды. Хоккейчы сынган таягын уен мәйданыннан читкә ыргытты да, әллә ни арада яңасын алып, уйнап та китте. Ә сынык кәшәкә таягы янында мәхшәр купты: олы-олы кешеләр шул таяк өчен талаштылар... Оператор объективны тиз генә стадион эченә юнәлтте.

Бу хәлләр, бер көн эчендә үк булгангамы, хәтергә нык кереп калды. Машина кузовында китапларны типкәләп кенә йөртүче ять-яшь малай һәм җимгә ташланган ач җанварлар кебек кәшәкә таягына ябырылган әзмәвердәй кешеләр. Әлбәттә, атаклы хоккейчы уйнаган таякны үзеңдә булдыру гаеп эш дип әйтмим, әмма журнал-китапларны җыеп барган, бүтән кадерле әйберләре белән бергә, аларны да әйбәтләп бәйләп, яңа фатирга күчерүче хуҗа кешенең шулай ачу китерерлек гаебе бар микән?

Юлда, төрле шәһәрләрдә, авылларда йөргәндә теге яки бу нәрсә белән чын мәгънәсендә мавыккан («Яшь ленинчы»ның бер рубрикасы «Мавыгулардан — ачышларга» дип тиккә генә аталмый лабаса!) кешеләрне байтак күрдем мин. Ниләр генә җыймыйлар алар! Дөресен әйтим, борынгы яки сирәк очрый торган китапларны, газета-журналларны, кулъязмаларны җыючы кешеләрне азрак очраттым. Дөрес, бөтен дөнья китапка тартылган хәзер, без барыбыз да диярлек китап дөньясы эчендә. Барыбыз да укыйбыз. Китапны яратып укымаган укучы әлегә сирәктер. Ләкин уку белән укуның аермасы бар бит. Кулыңа ни эләксә, шуны укырга була, үзеңә кирәклене, файдалы булганны эзләп табып укырга була. Бу урында, кадерле укучылар, шуны әйтеп узасы килә: без һәммәбез дә иксез-чиксез байлыкларга ия булган китаплар дөньясын яхшы беләбезме? Ул байлык безгә күбрәк ачылсын өчен кулларыбызда «китапларны яхшы белү» дигән ачкыч бармы? Китап таулары каршында ни алырга, ни сайларга белми югалып калмыйбызмы? Теге яки бу әсәрнең кем тарафыннан, кайда, кайчан язылганлыгына, кайчан, кайда, күпме, ничәнче басмада чыгуына игътибар итәбезме? Минемчә, күп очракта җитәрлек кызыксынмыйбыз без. Бик мавыктыргыч һәм бик файдалы китаплар укып та, аларны кем язганын да белмичә китапханәләргә кире илтүче балалар азмыни?!

Гадәттә, файдадан бигрәк, кызыкка, маҗараларга гына корылган китаплар тиз укыла, тиз йотыла һәм тиз онытыла да. Ярый, китап кызык ди. Ә шул китапны тудыручы кеше — язучы бар бит әле! Китабын укыганда аның турында ничек уйламыйбыз ди инде! Ул бик күп китаплар яза. Китаплары кызык икән, ул үзе тагын да кызыграк, димәк! Сез уйланасыз микән: язучы бу китапны ни өчен язган? Ни өчен ул бүтән вакыйганы түгел, ә нәкъ менә бу вакыйганы сөйли, ни өчен бу алым белән язган (әйтик, әсәр хатирә-искә төшерүләргә корылган яки беренче заттан сөйләнә ди)? Әсәрдә укыганга охшаш вакыйганы син бүтән авторда очраттыңмы? Ул ничегрәк тасвирлаган иде? Сиңа кайсы күбрәк ошый? Әгәр әсәр тарихи яки документаль икән, синеңчә, ул тәгаен дөресме? Анда язылганнарның һәммәсенә ышандыңмы? Иптәшләрең ул китапны укыганнармы? Аларның фикере ничек? Китап ничә данә басылган? Ул рәсемләме яки рәсемсезме, рәсемнәре уңышлымы? Син үзең рәссам булсаң, ничегрәк ясар идең? Китап кибет шүрлекләрендә озак ятамы яки бик тиз алып бетергәннәрме? Сорауларны бик күп, бик күп дәвам итәргә мөмкин. Китапны кулга алгач, һәммәбезгә дә шундый уйлар киләме, дуслар? Минемчә, фәкать китапларның әнә шул якларына игътибар иткәндә генә, яңа укып чыкканны элек укыганнар белән чагыштыра алганда гына, аларның чын рухи мәгънәсендәге бәяләрен һәм кыйммәтләрен аңлап буладыр. Дөресен әйтим, мәкалә башында телгә алынган әлеге малайның китапларга карашы мине рәнҗетте. Шундый сөйкемле малай чеп-чи надан булып күренде. Кем белә, бәлки, ул мәктәптә начар укучылардан саналмыйдыр да. Бәлки, яхшы спортчыдыр... Мин аңа ул көнне бераз аңлаттым. Әйткәннәрем гел файдага киткәндер дип уйламыйм. Бәлки, бу мәкаләне ул да укып чыгар. Мин моны ул малай өчен дә язам бит әле!

Тагын бер гыйбрәтле мисал: күптән түгел без Әлмәттә бөтен яктан ихтирамга лаек бер олы язучының юбилеен уздырдык. Залның фойесына язучының моңа кадәр чыккан китапларын күргәзмә итеп куймакчы булдык. Китапханәләрдән, уку залларыннан, кешеләрдән әлеге язучыбызның элегрәк чыккан китапларын эзләдек. Юк. Табып булмады! Ахырда язучының соңгы ун-унбиш ел эчендә чыккан өч-дүрт китабын витринага куюю белән чикләндек. Асылда, бу күргәзмә-витрина әдип хезмәтенең уннан бер өлешен дә күрсәтә алмады... Ә кая киткән элгәреге басмалар? Нигә сакланмаганнар?

Минемчә, мондый аяныч хәлләр гамьсезлектән, саксызлыктан, басма китапның, фикернең кадерен белеп җиткермәүдән килә. Әйтик, Г.Тукай, Г.Ибраһимовның үзләре исән чакта чыккан китапларының тулы җыелмалары кемнәрдә генә бар икән хәзер! Ә Такташ, Җәлилләрнең беренче чыккан китапларын кулга тотып карау кайсыбызны гына дулкынландырмас иде икән?! Ә бит әле алар әллә кай ерак заманнарда яшәмәгәннәр!

Еш кына укучылардан аерым язучыларга һәм Язучылар союзына, теге йә бу китапны сорап, хатлар килә. Сорау да бик әйбәт. Кирәклеге, хаҗәтлеге дә бик әйбәт. Ләкин җибәрергә теләгәндә дә

аерым кешеләр генә бөтен ихтыяҗны канәгатьләндереп бетерә алмый бит. Кирәк китапларны беренче чиратта син үзең үз вакытында алып калырга тиешсең, фәкать син үзең генә аларны кирәгенчә таба алачаксың. Әйтик, мәктәптә Җәлил музее яки почмагы оештырасыз икән, «Моабит дәфтәре»нең беренче басмасы, Ленин премиясе бирү турындагы Указ, ул вакытта чыккан мәкаләләр сезгә бик кирәк булачак. Ул материалларны еллар узгач табу җиңел булмаячак, димәк, аларны кул астында чакта, бүген үк хәстәрләп куярга кирәк. Яки сез зур галим һәм язучы Н.Исәнбәт иҗатына багышлап күргәзмә оештырасыз ди. «Татар халык мәкальләре»нең өч томлыгын анда куярга, һичшиксез, кирәк булачак. Инде хәзер аның беренче томын табу җиңел эш түгел. Өченче томы да бетеп бара. Ә бер ун елдан, егерме елдан алар бик сирәк очрый торган библиографик басмага әвереләчәк. Дөрес, яхшы әсәрләр еллар үтү белән кабат басылып торалар. Тик бөтен басмалар да кабат чыгып бетә алмый, тарихи факт буларак, иң төгәл, иң гадел итеп фәкать шул заман шаһитлары гына сөйли ала.

Сирәк очрый торган китапларны җыю һәм туплау буенча укымышлы кешеләр борын заманнардан ук зур эшләр башкарып килгәннәр. Хәзер дә бу эш белән махсус оешмалар шөгыльләнә. Фән кешеләре һәм әдәбиятчы студентлар җәйләрен китап, кулъязмалар, җырлар, бәетләр табу нияте белән экспедицияләргә чыгалар, хәзинә алып кайталар. Авылларда яшәүче китап сөючеләр аларга зур булышлык күрсәтәләр. Элекке заманнарда ук атаклы елъязмачылар, китап җыючылар булган. Еш кына аерым кешеләр тырышлыгы белән җыелган рухи хәзинә — кайбер олы тарихи вакыйгаларның, аерым бер чор-дәверләрнең нечкәлекләрен ачыклаучы бердәнбер чыганак булып калган. Фаҗигале хәлләр дә булгалап торган, төрле социаль сәбәпләр яки табигый бәхетсезлекләр — янгыннар, җимерелүләр байтак байлыкларны юкка да чыгарып килгән. Берничә мисал: утызынчы елларда галим Х.Бәдигыйның бик күп фольклор материаллары тупланган китапханәсе янгында харап була. Галим Җ.Вәлиди җыйган зур аңлатмалы сүзлек кулъязма килеш югала, Г.Ибраһимов архивының да байтак өлеше әрәм була... Бәхеткә каршы, кыйммәтле-кыйммәтле әсәрләр, китаплар, кулъязмалар сирәк булса да табылгалап тора. Менә шул чакта кайбер гади фидакарь затларның акыллы һәм укымышлы булуларына, рухи байлыкларның кадерен белүләренә, олы җанлы булуларына хәйран каласың, рәхмәтләр укыйсың.

Бәлки, сез күзәтеп барасыздыр: бездә китаплар турында язылган китаплар да чыккалап тора. Әле менә яңа гына атаклы китап җыючы (ул профессиясе буенча артист) Н.Смирнов-Сокольскийның рус телендә «Минем китапханәм» исемле ике томлы библиографик китабы чыкты. Мең биттән торган хезмәттә ул үзендәге кыйммәтле китапларның исемлеген теркәгән! Мең бит! Моннан ун ел элек шул ук авторның «Китаплар турында хикәяләр» исемле китабы да чыккан иде. Китапларның язмышы турында нинди генә гыйбрәтле язмалар юк анда! И.Романовскийның «Китаплар һәм тормыш», В.Лидинның «Минем дусларым — китаплар» һәм башка шундый китап турында китаплар бар бездә. Татар телендә дә кызыклы һәм файдалы китаплар чыкты: әле яңа гына вафат булган И.Рәминең «Истәлекләр. Татарча басма сүз» (Казан, 1965), галим А.Фәтхинең «Сирәк очрый торган кулъязмаларның тасвирламасы» (Казан университеты китапханәсе фонды буенча), галим Ә.Кәримуллинның «Казан татар матбугатчылыгы тарихыннан» («Казан утлары», 7 сан, 1968) дигән хезмәтләре. Тагын, тагын бар әле ул хезмәтләр. Кызыксын гына! Күрә генә бел!

Китаплар! Безнең республикабызда гына көн саен берничә китап чыгып тора. Аларның бөтенесен укып та бару мөмкин түгелдер. Әмма китапны яхшы белгән кеше бихисап китаплар арасында югалып калмый, үзенә кирәк китапны тиз таба ала. Укучы балаларга нәшриятлар тарафыннан чыгарыла торган тематик планнар, библиографик язмалар, каталоглар белән танышу да файдага гына булыр. Үткән заманнар әдәбиятын өйрәнгәндә мәгълүм бер чордагы төрле халыклар әдәбиятын чагыштырып карау, билгеле бер темага язучыларның әсәрләреннән күргәзмәләр оештырып, әдәби музейларда ешрак булу, һичшиксез, китап сөючеләрне баетачак, зәвыкларын үстерәчәк. Уйласаң, юллар күп. Иң мөһиме — яхшы китапларга бөтен ишекләр ачык бездә! Теләк кенә, китапка мәхәббәт кенә булсын! Әйдәгез, кадерле яшь дуслар, бергәләшеп, киңәшләшеп яхшы һәм файдалы китаплар җыйыйк! Китап — безнең турылыклы дустыбыз һәрчак яктыга илтәр, тормышыбызны ямьлерәк, мәгънәлерәк итәр.

*1969, апрель*

**КИТАП — БЕЗ УЛ**

Хәзерге чорда бер генә әдәбиятны да бүтән халыклар әдәбиятыннан тыш, аерым гына карап, өйрәнеп, объектив бәһаләп булмый, булса да, андый бәһа берьяклы булыр. Без яшәгән күпмилләтле илдә бигрәк тә. Шартлы рәвештә күз алдына китерик: каршыбызда дөнья халыклары әдәби картасы ди, һәр халыкның әдәби-эстетик куәтен белдереп, төрле балкыштагы лампочка-шәмнәр янып тора ди... Татар әдәбиятын белдергән ут-якты ничегрәк? Бик тонык түгелдер дип уйлыйсы килә. Хәер, кистереп тә әйтеп булмый. Әмма бер нәрсә ачык: татар әдәбияты үзенең бар булганы белән дөньяга

тиешенчә күренеп балкый алмый әлегә. «Лампочкаларын» сөртеп, чистартып яки яңага алыштырып куйсаң, рухи мирас «батареяларына» бөтен үткәргечләрне тоташтырып чыксаң, аның яктысы, һичшиксез, көчлерәк, тәэсирлерәк булыр иде. Мин моны язма әдәбиятыбызның күпгасырлык бай хәзинәсе барлыгын, әлегә аның киң масса үз укучыбызга һәм дә бүтән халык вәкилләренә кирәк дәрәҗәдә ирешелмәгәнлеген искәртеп әйтәм. Шунысы да бар: әдәбият — безнең халыкның мәдәнилеген белдерүче бердәнбер юан тамыр. Материаль культураны белдергән борынгы шәһәрләр, корылма-һәйкәлләр заманында җимерелеп беткән, архитектура яки сәнгатьнең бүтән төр үрнәкләренең эзе дә калмаган диярлек... Әнә шул, Тукай әйтмешли, «туплар да вата алмаган» мирасны, кояш астына чыгарып, бүгенге халыкка кайтару — әдәбиятыбызның зурлыгын раслау, гомумән, милли үзаңны үстерү буенча бердәнбер дөрес юлдыр дип беләм. Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп узыйк: дәүләте булган халыкның әдәбияты белән дәүләтчелеген югалткан (әмма аны кайтару өметен өзмәгән) халык әдәбияты шактый ук аерыла да. Соңгысының иҗтимагый функцияләре киңрәк тә булырга мөмкин. Турыдан-туры ук булмаса да, дәүләт институтының кайбер сыйфатлары чагыла ул әдәбиятта. Һәрхәлдә, татар әдәбиятында бу нәрсәне күрергә була. Әмма мирас тавын актарып, энҗеләрен яңадан кайтару өчен титаник хезмәт сорала. Озын юл үткән әдәбиятны, китап тарихын халык рухының тарихи көзгесе дип саныйбыз икән, мирасны тәртипкә китерүдә гуманитар фәннәргә кагылышы булган һәр белгечнең актив катнашуы шарт. Тарихчының да, филологның да, библиографның да, дәүләт эшлеклесенең дә, нәшрият хезмәткәрләренең дә... гомумән, китапка, аның мирасына кагылышлы һәр затның да. Кызганыч, еш кына болай да ишле булмаган белгечләр арасында теге яки бу мәсьәлә (әйтик, имля мәсьәләсеме ул, яки берәр мәшһүр тарихи шәхес турындамы) хакында гомумәш өчен әһәмияте булмаган проблемалар чыккалап тора. Кирәк эшкә сарыф ителәсе җегәр юкка әрәм була. Ара-тирә вульгар социологизм заманнарындагы авазлар да яңгырап ала. Күрәсең, торгынлык чорында формалашып, дистә еллар буена фәндә лидерлыкка күнеккән кайбер өлкәнрәк иптәшләр үзләренең бүгенгегә бик үк туры килмәгән позицияләрен тиз генә бирергә теләмиләр...

Инде мәсьәләгә конкрет килеп, бүгенге көндә китап чыгару хәлләре турында сүз алып барыйк. Без теоретик юнәлештә нинди генә фәлсәфә корсак та, трибуналардан нинди генә тәэсирле чыгышлар ясасак та, талантларның сирәк булуларын һәм аларны сакларга кирәклеген раслап күпме генә сөйләсәк тә, ахыр чиктә, безгә төп бәяне язган әсәрләребез, китапларыбыз бирә. Китапсыз язучы юк. Әйе, шулай. Ә укучысыз да язучы була алмый бит. Язучы — китап — укучы. Заманыбыз өчен шактый четерекле проблемаларны китереп чыгара торган өч төшенчәне берләштерә бу чылбыр. Ә үзара тоташу төеннәре бик хикмәти катлауланды хәзер. Беренчедән, мөмкинлекләр турында. Сугыштан соңгы чор белән чагыштырганда, язучылар саны чама белән җиде-сигез тапкырга артты, димәк, мантыйк буенча, китап чыгару күләме дә шул чама артырга тиеш иде, ә ул күләм, асылда, үзгәрмәде, татарча матур әдәбият чыгару буенча нәшрият мөмкинлекләре шул 50 нче еллар дәрәҗәсендә калды. Бу очракта бүгенге язучыга китап чыгаруның ни дәрәҗәдә кыен икәнлеге турында сүз озайтуның кирәге юктыр. Икенчедән, халыкның (укучының диикме?) китапка карашы үзгәрде, аны (китапны) дөньяны танып белү һәм эстетик матурлык чыганагы итеп карау кимеде, икенче төрле әйткәндә, киң масса, бигрәк тә яшь буын, китаптан бизде. **Укучыга** караганда **караучы** күбәйде. Басма хәрефне экрандагы сурәт алыштырды. Шуңа да китапларыбызның тиражы нык кимеде, кибетләрдә сатылмый ятучы китап өемнәре артты. Өстәвенә югарыдан куелган сәясәт һәм «алдынгы» педагогларыбызның тырышлыгы нәтиҗәсендә авылларыбыздагы мәктәпләрдә татар телендә укытуны киметү яки бөтенләй диярлек бетерү — туган телдә укучылар санын юк дәрәҗәгә калдырды. Өченчедән, китап язмышы өчен тулысынча җавап бирә торган төп бер хуҗаның булмавы тез астына нык сукты. Язучы яза, әсәрен нәшрият басарга кабул итеп алса, үзенең бурычы үтәлгән саный. Нәшрият китапны чыгара һәм «тудырган баласын» китап сату оешмаларына тапшыра. Шулай итеп, кульязма — китап рәвешенә килә-килә, үзенең хуҗаларын алыштырып тора. Ярый ла китап сатылып, укучылар күңеленә ирешсә? Ә инде сатылмый икән, китап сатучылар нәшриятны гаепләр, нәшрият, үз чиратында, бу хәлне язучы әсәренең камил булмавы белән аңлатыр. Һәрхәлдә, бер-береңә сылтарга урын бар, әмма төп җаваплылыкны үзенә алып берәү дә зыян күрмәс. Гыйбрәт өчен гасыр башында татарча бик күп китаплар чыгарган дистәләгән нәшриятларның тәҗрибәсенә күз салыйк. Нәшрият үзе авторын тапкан, үзе бастырып чыгарган, үзе әзерләп чыгарган товарын үзе тараткан. Дөньяның кайсы почмагына гына барып җитмәгән ул татар китаплары! Китапчылар үзләрен аямыйча эшләгәннәр, әлбәттә, табыш та алганнар, ә бит иң мөһиме — китап таралган, мәгърифәт нуры чәчелгән, милләт күңеле нурланган! Язучылар үзләре дә кул кушырып утырмаган, китабы язмышы аларның бәгърендә булган. Заманында Тукайның да «Сабах» басмаханәсендә экспедитор булып эшләгәнен искә төшерик. Безнеңчә, яхшы әсәрләр, кирәк китаплар төрле кулларда йөрмичә, эзлекле бер хуҗалы, ияле булырга, алар өчен төп җавап тотучылар булырга тиеш.

Дүртенчедән дип, тагын бер мәсьәләне куярга була. Авторлар үзләре дә китапларын теләгән ияләренә-укучыларга ирештерер өчен көч куярга тиешләрдер бит! Ихтимал, тиеш каләм хакы исәбенә чыккан китапларның бер өлешен, әйтик, чирегең, авторның үзенә тапшырыргадыр? Ул да булышсын үз китабына!

Шушы югарыда әйтелгәннәр нисбәтендә тагын бер конкрет проблема — тиражлар проблемасы килеп баса. Татар китапларының тиражы, кызганычка каршы, үсүгә бармый. Объектив сәбәпләр белән бергә, бу мөһим идеологик акциядә оештыру һәм пропаганданың сүлпән куелуын, җирле оешма җитәкчеләренең бу эшкә битараф каравын, сатучыларның китап белән сәүдә итә белмәвен дә ассызыклап әйтеп үтәргә кирәк. Уйлап баксаң, республикада басма китапка мөнәсәбәте булган меңәрләгән кешеләр исәпләнә ләбаса! Һәрберсе елына берничә генә дистә китап таратса да, нәтиҗә матур гына булыр иде. Сүз уңаеннан тагын бер фикерне бәян итеп узыйк: соңгы елларда республикабызның иҗат интеллигенциясе вәкилләреннән группалар оештырып, аларны шәһәр үзәкләреннән ерактарак урнашкан аулаграк төбәкләргә шефлар итеп билгеләделәр. Бик әйбәт. Әгәр алар белән бергә нәшриятыбыз чыгарган басмаларны төягән берничә автолавка республикада һәм чит өлкәләрдә ел әйләнә хәрәкәттә булса (театр коллективлары, филармония артистлары татарлар яши торган бик ерак төбәкләргә мәдәни миссия белән барып чыга бит!), классикадан булсын, бүгенгедән булсын, тәрбияви әһәмияте булган ничаклы китап тарала алыр иде, туган телдәге сүз сәнгатенә сусаган никадәр күңелләрне (ә редакцияләргә китап сорап байтак хатлар килеп тора, бигрәк тә чит өлкәләрдән) сугара алыр иде!). Дистә еллар буена туган телдә бер генә китап та кермәгән татар авыллары да бар бит дөньяда!

Ә уйласаң, әдәбият җәүһәрләрен тарату юллары бар бит ул. Хәзер төрле бәйрәмнәр, фестивальләр, слетлар, ярышлар бик еш узып тора. Авыл масштабында булсын, район яки республика күләмендә. Әлеге бәйгеләрдә җиңүчеләргә истәлек бүләкләре белән бергә китаплар төргәге (әйтик, «Татар халык иҗаты» томлыклары, «Шигырь китапханәсе» сериясе, сувенир басмалар һ.б.) тапшырып булмас идемени? Кайчакта сабантуй батырларына кыйммәтле җиңел машиналарга хәтле бирәләр. Ә шул акчага бөтен сабантуй сабыйларына матур-матур китаплар өләшеп булыр иде!..

Инде янәдән тиражларга кайтыйк. Хәлебездән беркадәр зарлансак та, татарча 20—30 мең данә тарала алырлык җитди әсәрләребез дә бар бит әле. Тираж комиссиясенә әнә шундый заказлар да килгәли. Гадәттә, алар канәгатьләндереп бетелми. Ни өчен? Чөнки норматив тираждан берничә мәртәбә артык булган әсәр өчен авторга бермә-бер артык гонорар түләргә туры килә. Бу — нәшрият өчен финанс ягыннан файдага түгел. Парадокс килеп чыга: бер яктан татарча китапларга тиражлар кими, тиражлар җыя алмыйбыз дибез, икенче яктан, булган ихтыяҗны да үти алмыйбыз. Ә типография машиналары тик тормый. Инде дөньяга күптән даны таралган берәр мәгълүм калын китапны рус телендә 100әр, 200әр мең данә бастыра бирәләр. Бирелгән кәгазь фондының күпмесе шул китапларга кереп бетә. Дөрес, алар коммерция күзлегеннән караганда төшемле, ә менә халыкның милли культурасын, үзаңын үстерүдә аларның рольләре нинди? Шунысы да бар: андый китапларны теләсә кайсы өлкә нәшрияты да чыгара, ә менә үзебезнең телдә без фәкать Татарстан китап нәшриятында гына бастыра алабыз бит. Уйланырлык хәл.

Күңелдә борчу тудырган тагын бер күренеш турында әйтәсе килә. Соңгы елларда иҗтимагый фикер тудыруда катнашучы бәгъзе затлар тарафыннан шигъриятькә, поэзиягә тискәрерәк караш урнашып килә, хәтта, әйтер идем, җае туры килгәндә аңа типкәләбрәк китү бар. Мондый тенденция тарафдарларының дәлилләре: поэзия хәзер популяр түгел, халыкның шигырьгә исе китми, шигырь китапларыннан керем юк һ.б. Монда шом салырлык ике нәрсә — беренчедән, күпләрнең шигырьгә (димәк, матурлыкка, сафлыкка, ихласлыкка) ихтыяҗ булмау, икенчедән, җырдан-шигырьдән файда-керем эзләү. Их, ил экономикасына зыян шигырьдән генә килсә икән! Казанда шыплап тулган хәрби заводларның кайсы гына Кешелеккә эшли дә, күпмесе кемгә файда китерә икән?

Ирексездән «Сарыкны кем ашаган?» мәсьәле искә төшә. Ә татар шигъриятенә килсәк, ул, асылда, күпгасырлык әдәбиятыбызны бар иткән жанр, ул — үткән тарихи юлыбызның көзгесе. Һәм бүгенге көндә дә безнең поэзия бөтенсоюз күләмендә дә йөз кызарта торган поэзия түгел. Шунысын да онытмыйк: шигырь әдәбиятның Әнкәсе! Бүгенге ФТР заманының прагматик күзлегеннән генә карамыйк аңа, шигырь-җыр аша гасырлардан бүгенгене, киләчәкне күрә белик! Адәм баласының тормышы гел исәп-хисаптан, файда-керемнән генә тормый. Шигырь — иман юлдашы. Дөньяда шатлык белән кайгы, мәхәббәт белән нәфрәт, яшәү белән үлем булганда, шигырь дә җаныбызда булыр.

Шигырь-җыр бетсә, кешедә иман-ышаныч та бетәр. Әгәр дә кемнәрдер бүген шигырьдән йөз чөерсә, иртәгә алар прозаңнан да, драматургияңнән дә баш тартыр...

*1988, февраль*

**БӘЙРӘМ КИТЕРГӘН КИТАП**

Ниһаять, күптән көтелгән китап — «Татар балалар поэзиясе антологиясе» дөнья күрде. Чыгасы алдан ук мәгълүм булгангамы, үзенең характеры һәм мәгънәви эчтәлеге белән әле моңарчы күрелмәгән басма буласынамы, культурабызның үсеше белән кызыксынган бик күп иптәшләр чынлап зарыгып көттеләр аны. Менә ул хәзер безнең кулда — укучылар кулында. Китап кибетләрендә ябырылып алалар: берәмләп тә, икешәрләп тә, унарлап та... Бүләккә дип тә, киләчәктә сирәк очрый торган библиографик басма бит әле бу дип тә. Алырлык та шул: укыйм дисәң, укырлыгы, тотыйм дисәң, тотарлыгы бар. Өстәвенә бәһасе дә шактый арзан...

Антология — грек сүзе, безнеңчә чәчәкләр җыйнамасы дигәнрәк мәгънәне аңлата. Бу очракта исем җисеменә бик тә туры килә. Төзүчеләр (Нәкый Исәнбәт, Гәрәй Рәхим, Равил Кукушкин) зур тарихлы татар әдәбияты хәзинәсеннән балалар өчен язылган иң яхшы шигъри үрнәкләрне сайлап алганнар, аларны билгеле бер тәртипкә китереп, беркадәр библиографик белешмә-мәгълүмат биреп, кыскасы, зур эшкә алынып һәм аны ахыргача башкарып чыгып, фидакарь хезмәт күрсәткәннәр, туган әдәбиятыбызның күп меңләгән укучыларына поэзия чәчәкләреннән чын мәгънәсендә олы бүләк әзерләгәннәр. Бу очракта басманың җаваплы редакторы Фәрваз Миңнуллинның зур ролен дә танып үтәргә кирәк. 368 биттән торган бу китапка 108 авторның әсәре кергән, шулай ук татар халык авыз иҗатының балалар дөньясына караган кайбер җыр-такмак-табышмак үрнәкләре дә урнаштырылган. Китапның авторларга караган бүлеге XIX гасыр ахырында яшәгән мәгърифәтче һәм шагыйрь Габделмәннән Рахманколыйдан башланып, соңгысы бүгенге яшь буынның талантлы бер вәкиле Зиннур Мансуров исеме белән тәмамлана. Җыенысы 356 әсәр. Шигырьләр, җырлар, әкиятләр, мәсәлләр, балладалар, поэмадан өзекләр...

Иң әүвәл басманың игътибарны җәлеп итә торган ягы һәм төп әһәмияте шунда: ул — әдәбият тарихында бердәнбер, күләме һәм кыйммәтенең саллылыгы белән әле моңарчы күрелмәгән басма.

Кеше күңеле шулай яралган инде: аның беренчел нәрсәләргә мөнәсәбәте һәрчак үзгә, сокланулы. Беренче мәхәббәт, беренче язгы чәчәкләр, беренче бала һәм беренче булган тагын бүтән нәрсәләр безнең җаннарны әллә ничек сафландыра, бөегәйтә бит. Беренче татар балалар поэзиясе антологиясе! Бу китапны беренче мәртәбә кулга тотып, ашыга-ашыга актарып чыгу да әллә никадәр шатлыклы тойгылар уятты миндә. Күпләр, тагын бик күпләр шундый ук, дөресрәге, шуңа охшашлы хисләр, кичерешләр белән канатланалардыр. Дөрес, берничә гасырлык китап культурасы булган халык өчен беренче яки икенче дигәнрәк төшенчәләр казаныш билгесе булып яңгырамаска да мөмкин, һәм аның шулай булуы табигый дә. Җыелма характердагы басмалар, әйтик, календарьлар, инде йөз илле ел чамасы элек үк гамәлдә булган. Шулай ук балалар өчен шагыйрьләрнең аерым һәм күмәк җыентыклары, халык иҗаты үрнәкләренең тупланмалары инде бу гасыр башында ук байтак нәшер ителгәннәр. Соңгы илле-алтмыш ел эчендә дә шушы юнәлештә байтак игелекле эш башкарылган. Әмма моңа кадәр бу төр рухи байлык күпме һәм ни рәвешле генә дөнья күрмәсен, аларның берсе дә без бүген кулыбызда тоткан антология белән тиңләшә алмый. Бу — уникаль басма!

Антологиягә кергән әсәрләрнең бөтенесе диярлек миңа таныш. Шулай ук киң катлам укучыларга да аларның күпчелеге мәгълүм булырга тиеш. Ләкин гаҗәп хәл: бөтенесен бергә тоташтан карап чыккач, тәэсирләр бөтенләй үзгә. Аерым энҗе бөртеге үзенчә бер ямь белән җемелдәсә, ә алардан тезелгән тулы бер таҗны күргәч, караш беркадәр үзгәрә, үткенәя төшә икән. Чагыштырасың, кабат кайтып укыйсың, күңел бизмәнең белән янә үлчәп карыйсың да, бүтәнрәк нәтиҗәләргә киләсең: элегрәк синең күз явын алган кайбер бөртекләр алай ук балкымыйлар икән бит! Кара, син бик үк игътибар итеп җиткермәгән беришә бөртекләр чын җәүһәрләр икән ләбаса! Әлбәттә, болай сайлану, болай бөртекләү чагыштырыр әйбереҢ, сайлар байлыгың булганда гына мөмкин. Шунысы бәхәссез: балалар өчен мондый махсус антология күп гасырлы, нык традицияле зур әдәбият җирлегендә генә туарга мөмкин.

Антологиядә төрле дәрәҗәдәге шагыйрьләр, әдәбиятта тоткан урыннарына һәм балалар поэзиясенә керткән өлешләренә карап, төрле күләмдә урын алганнар. Кайберләренең егермеләп, унбишләп шигыре урнаштырылса, икенчеләренең ике-өч яки аерым бер шигыре кергән. Хезмәтеңә карап — урының. Бу — асылда, дөрес принцип, гадел принцип. Эш күләмдә генә дә түгел. Бу китапка кергән һәр автор, нинди дәрәҗәдә генә катнашмасын, үзенчә бәхетле саналырга хаклы. Иҗаты-шигырьләре белән аның Балалар Илендә тере тамыры бар! Тукай әйтмешли, «Әйдә, иҗтиһад ит!», яңа шытымнар җибәр, күкрәп чәчәк ат, сабыйларны сөендер, җирдә изгелекне арттыр, дөньяны бизә! Балаларны тәрбияләү — ул мәңгелек проблема; балалар дөньясында эш күп, балалар әдәбиятында яхшы әсәрләргә урын җитәрлек!

Рухи мәгънәле һәр китап гомумәдәбият турында җитди уйлануларга этәрә. Минем үзем өчен күңелдә йөргән, әмма әле тәмам формалашып бетмәгән кайбер фикерләр антология белән танышканда ачыклана төште. Уйлап карасак, һәрбер зур әдип балалар язучысы да булырга тиеш

бит. Чөнки бу нәрсә аның кулыннан килә. Әгәр кайбер олы язучыларның балалар өчен әсәрләре юк икән, бу әлеге шәхес үз талантын бөтен барлыгы белән файдаланып бетермәгән дигән сүз. Ә әдәбиятларның, халыкларның горурлыгы булган зур талантлар моны яхшы аңлаганнар. Рус әдәбиятыннан А.Пушкин, Л.Толстойларны алыйк, татар әдәбиятыннан Г.Тукай, Дәрдемәнд, М.Җәлилләрне искә төшерик, чит ил әдәбиятыннан В.Гюго, М.Твен, Дж.Лондоннарның иҗатларын күздән кичерик... «Татар балалар поэзиясе антологиясе»ндә бу закончалык ярылып ята. Балалар шигъриятенең алтын фондын тәшкил иткән иң күп әсәрләр классик һәм бүгенге көндә иҗат итүче танылган зур шагыйрьләр өлешенә туры килә. Санап китик: инде югарыда исемнәре телгә алынган Г.Тукай, Дәрдемәнд, М.Җәлил... Алар янына М.Гафури, Ш.Бабич, Һ.Такташ, Н.Исәнбәт, Ә.Фәйзи, Х.Туфан, Ф.Кәрим, С.Хәким, Н.Арсланов, Зыя Мансур, Ә.Давыдов, Ш.Мөдәррис, Г.Афзал, С.Сөләйманова, Ш.Галиев, И.Юзеев, М.Шабаев, Роберт Әхмәтҗанов, Р.Мингалим, Ф.Яруллин, М.Әгъләмов, Зөлфәт исемнәрен куйсак, сүзебез дөрескә чыгар сыман. Әлбәттә, үзләренең төп иҗатларын балаларга багышлаган Б.Рәхмәт, А.Алиш, З.Туфайлова, Ә.Бикчәнтәева, Җ.Тәрҗеманов, М.Фәйзуллина, Х.Халиков, Р.Миңнуллин, Җ.Дәрзаманов һәм тагын башка кайбер иптәшләрнең бу антологиядәге рольләре үзеннән-үзе аңлашыла шикелле. Аларның шигырьләре антологиядә кабатланмас бер бизәк булып торалар. Ә.Сирин, Ә.Ерикәй, С.Гыйльфан, С.Баттал, Н.Дәүли, З.Нури, М.Ногман, М.Мазунов, М.Әхмәтгалиев, Х.Камалов, Р.Вәлиева, Г.Рәхим, Г.Зәйнашева, Ә.Рәшитов, Ш.Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов, Р.Вәлиев, Зиннур Мансуров, М.Газизов һәм тагын бик күп иптәшләрнең шигырьләре хаклы урыннарны алмаганнармыни? Авторлар күп, әйткәнемчә, йөздән артык: һәммәсенең исемен атап китү мөмкин түгел. Шунысы ачык: антологиядә исеме бу басмага лаек булмаган автор юк. Сүз, катнаштырылырга тиеш булып та, онытылып яки бүтән берәр сәбәп белән керми калган иптәшләр турында гына булырга мөмкин. Авторларның күп, иҗатларының төрле һәм киң колачлы булуы, табигый, гомумантологиянең дә тематик диапазонын билгели. Ә тематик колач киң. Беришe шигырьләр Туган җир, Ватан, Халык кебек бөек төшенчәләрне эченә алып, аларга тугрылыклы булырга өйрәтсә, икенчеләре балаларны хезмәт сөяргә, белемле һәм намуслы булырга өнди, беришеләре табигатьне яратырга, әйләнә-тирәбездә яшәгән тереклек ияләренә мәрхәмәтле булырга чакыра. Гомумән, балалар белергә тиеш булган рухи һәм матди тормышыбызның бик күп якларын эченә алган бу әсәрләр.

Антологиянең ахырында (бәлки, ул китапның башында ук торырга тиеш булгандыр) Равил Кукушкинның «Җирдә яңа кеше өчен» дигән күләмле мәкаләсе урнаштырылган. Төпле мәкалә. Автор балалар шигъриятенең төп асыл сыйфатларын дөрес билгели, бүгенге үсеш тенденцияләренең характерын ачыклый, үткән мирасның киләчәккә алырдай уңай якларын анализлау белән бергә, безнең балалар поэзиясенең алдагы үсеш перспективаларын да күрсәтергә тырыша. Балалар шигърияте өлкәсендә аерата хезмәт күрсәткән (Г.Тукай, Б.Рәхмәт) һәм бүгенге көндә актив эшләп килүче (Ш.Галиев, Р.Мингалим) шагыйрьләрнең уңышлары нәрсәдә икәнен, аларның эстетик принципларын ачыклап, балалар шигъриятенә керткән өлешләрен дәлилле итеп аңлата. Дөресен генә әйткәндә, балалар шигърияте турында мондый аек карашлы, теоретик яктан нык һәм анализ ягыннан тирән, шигъриятнең нечкә серләренә төшенеп язылган хезмәтләр бездә әле моңарчы юк иде шикелле. Җыйнап әйткәндә, төзүче һәм төп мәкаләнең авторы буларак, Равил Кукушкинның бу антологиянең дөнья күрүендә хезмәте зур.

Антология — Татарстан Язучылар берлеге һәм китап нәшриятының уртак тырышлыгы белән дөнья күргән басма. Ләкин антология кадәр антология, аерым оешмалар яки аерым кешеләр никадәр генә тырышмасыннар, теләк белән генә эшләнә торган нәрсә түгел. Хикмәт — әдәбиятның зур булуында. Фәкать зур әдәбиятта гына мондый коллектив китап туарга мөмкин. Ә әдәбиятның зур булуы вакытлы матбугатка да бик нык бәйле. Бу антологиягә кергән күпчелек әсәрләр үз вакытында газета һәм журнал битләрендә басылганнар. Кайберләре инде революциягә кадәрле үк «Ак юл», «Тәрбиятел әтфал» һ.б. журналларда чыкса, байтак өлеше совет чорындагы газета һәм журналларда дөнья күргән. Бу җәһәттән республика балалар матбугатын, аерым алганда «Ялкын» (элеккеге «Пионер») журналын һәм «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасын аеруча әйтеп үтәсе килә. Аларның балалар әдәбиятын үстерүдәге өлешләре зур. Балалар матбугатының мәрхәмәте һәм ярдәме белән тулы бер буын язучылар тәрбияләнеп үсте. Бүгенге антология — инде ачылган чәчәк бәйләме булса, ә аның тамырлары исә — әнә шул матбугат органнарында. Сүз уңаеннан күңелгә шундый хыялый бер уй да килә: әгәр без күптән теләп йөргән яшьләр журналы да яңадан чыга башласа, балалар һәм үсмерләр әдәбиятында әллә никадәр уңышлар булыр иде! Шулай ук ныклы җирлек-нигез белән бергә, без инициативаның да ролен киметеп күрсәтергә җыенмыйбыз. Билгеле хакыйкать: соңгы ун-унбиш ел эчендә Татарстан Язучылар берлеге балалар әдәбиятын үстерүдә аеруча зур кайгыртучанлык күрсәтә. Сер түгел, әле 60 нчы еллар башында гына балалар әдәбиятының арттагыгы турында еш һәм ачынып сөйләнелә иде. Ныклап тотынгач, гомумигътибар арткач, балалар әдәбиятында, бигрәк тә балалар поэзиясендә хәлләр шактый ук яхшыга үзгәрде.

Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышларда, язучылар съездларында, пленумнарда балалар әдәбиятын үзәккәрәк куеп сөйләшенә башланды. Үзебездә генә түгел, бөтен Союз мәйданында да татар балалар әдәбиятының абруе әкренләп күтәрелә барды. 1975 елда Союз күләмендәге журнал — «Детская литература»ның тулы бер саны диярлек безнең балалар әдәбиятына багышлап чыгарылды. Бу эш тулысы белән Татарстан Язучылар берлеге идарәсе инициативасы белән эшләнде. Әлеге антологияне чыгаруда да төп эшне язучылар башкарды. Академик басма булмаса да, мондый зур, әдәби тарихны иңләгән китапны әзерләүдә фәнни оешмаларның, бигрәк тә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәренең бөтенләй читтә калуы аңлашылып җитми. Фәнни оешма адресына болай кагылып үтүнең мондый мәгънәсе дә бар: хәзер Мәскәүдә «Бөтен дөнья балалар әдәбияты китапханәсе» сериясендә дистәләгән томлы китаплар чыга. Әдәби мирасны тупларга һәм сакларга алынган галим иптәшләрнең әлеге сериядә безнең балалар әдәбияты вәкилләренең теге яки бу дәрәҗәдә катнашуы турында төпле уйланганнары, шушы юнәлештә кылган гамәлләре бармы икән? Юкса кайчак, сабан туе мәйданы таралгач, кулларына сөлге тотып чыккан кешеләр кебек, «Фәлән басмага фәләннәр генә кергән, фәлән дә керергә тиеш иде!» — дип сөйләнеп йөрүчеләр дә табылгалый... Кыскасы, киң дөньяга тарала торган басмаларда күбрәк басылуны оештыруда без һәммәбез хәл кадәренчә актив катнашырга тиешбез. Булган байлыкны кояш күзенә күрсәтә белү — зур эш ул.

Балалар поэзиясе антологиясе — балалар шигърияте җәүһәрләрен барлауда беренче зур тәҗрибә. Табигый, мондый зур тәвәккәл адымда беркадәр җитешсезлекләр дә булучан. Аларны антология белән танышкан һәркем үзенчә тоядыр. Миндә дә теләк йөзеннән кайбер фикерләр туды. Алар мондыйлар: ихтимал, әдәбиятыбызның борынгырак чорыннан да кайбер үрнәкләр кертергә кирәк булгандыр. Теләгәндә, аларны Кол Гали, Котби, Сараи, Мөхәммәдъяр кебек борынгы әдипләрнең әсәрләреннән табу мөмкиндер. Болай эшләү әдәбиятыбызның күп гасырлы булуына тагын бер игътибар юнәлтү булыр иде. Тагын бер төгәлсезлек: автор исемнәре астында урнаштырылган библиографик белешмәләрне бирүдә тәгаен бер эзлекле принцип сакланмаган. Кайбер авторларның биобиблиографияләрендә төп сәхифәләр санала, кайберләренекендә саналмый, берәүләренекендә — бәя бирүгә охшашлы җөмләләр китерелә, икенче берәүләренекендә ул юк. Шулай ук кайбер тәгъбирләрдә стилистик кытыршылыклар очрый, кайбер җөмләләр тиешенчә редакцияләнмәгән. Биш-алты юллык белешмәдә алар аеруча күзгә ташлана. Кайбер шагыйрьләрнең антологиягә керми калуы да сиздерә. Бу бигрәк тә чагыштырмача яшьрәк буын шагыйрьләргә карый. Әйтик, Ә.Габиди, Р.Хәлиуллина, Г.Садә кебек шагыйрьләр белән беррәттән, Д.Сирай, Ә.Гадел, М.Галиев, Р.Хисмәтуллин, Х.Әюпов, Р.Низамиев, Р.Юнысов, Хәйдәр кебек авторларның да исемнәре булса, антология, һичшиксез, тагын да тулылана төшәр иде. Ара-тирә антологиягә кергән авторларның кайбер шигырьләрен шул ук авторның уңышлырак шигыре белән алыштырып куясы да килә. Хәер, бусы инде субъективрак теләк тә булуы мөмкин. Антологиядә инде төзәтелергә соң булган үкенечлерәк хаталар да киткәләгән. Әйтик, минем үз исемем астына икенче берәүнең «Ямь-яшел» дигән шигыре кереп утырган. Уңайсызрак хәл. Китапның тиражы да зур түгел, нибары 10 мең данә. Бермә-бер артык булса да таман гына булыр иде.

Татарстан китап нәшрияты үз полиграфик мөмкинлекләре дәрәҗәсендә затлы китапларны булдыра алган хәтле күбрәк чыгарырга тырыша. Кечкенә форматлы сувенир китаплар, төрле альбом-буклетлар, юбилейлар уңае белән чыгарыла торган басмалар... Полиграфик эшләнеше ягыннан «Балалар поэзиясе антологиясе» дә әнә шундый күркәм китаплар рәтенә керә. Китап яхшы кәгазьгә басылган, каты тыш белән төпләнгән, һәр бит милли орнаментлар белән бизәлгән.

Китапны бизәүгә художник З.Хөсәенов күп көч куйган. Гомумән, бу китапны чыгаруга катнашкан һәр кешенең хезмәте ихтирамга һәм зур рәхмәткә лаек. Безнеңчә, бу антологияне, тагын да тулыландырып, тагын да камилләштереп, русча әзерләү дә яхшы булыр иде.

Әйе, татар балалар әдәбияты үсештә. Бүгенге көндә аның бу эшкә ихлас алынып, фидакарьләрчә хезмәт итүче дистәләгән талантлы вәкилләре бар. Бу уңайдан Р.Кукушкин мәкаләсендәге сүзләр бик урынлы: «Татар совет балалар поэзиясе бүген, гуманистик һәм прогрессив рухлы бөтен дөнья халкы, бөтен дөнья әдәбияты белән берлектә, җирдә Яңа кеше өчен, аның киләчәк матурлыгы өчен яңа шигъри үрләр яулый». Антология — әлеге сүзләрнең дөреслегенә ачык дәлил.

*1981, февраль*

## САНДУГАЧ КЫНА ДИМӘССЕҢ

Татарстан китап нәшрияты соңгы ун-унбиш ел эчендә халык күңелендә, тарих елъязмасында калырлык байтак игелекле эшләр башкарды. Агымдагы яңа әсәрләр белән беррәттән, рух хәзинәсен тәгаен баетырлык шактый саллы, фундаменталь хезмәтләр дә дөнья күрде. Әйтик, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (3 томда), «Татар халык иҗаты» (12 томда), классик әдипләребезнең (аларның

исемнәре генә дә дистәдән артык) күптомлыклары һәм, ниһаять, «Татар әдәбияты тарихы» (5 томда)... Ихтимал, еллар үтеп, килер буыннар 70—80 нче еллар матбага тарихын өйрәнгәндә, бу чорны үзгә бер мәгънәле, матур бер дәвер булган икән дип, сагынып һәм горурланып искә алырлар әле. Китапны сәнгатьчә әсәр итеп, заманча полиграфик ысуллар белән бизәп, укучы кулына тапшыру, шиксез, һәр басмаханәнең изге омтылышыдыр. Бу җәһәттән безнең нәшрият та, илдә абруйлы һәм зур традицияләргә ия булган нәшрият буларак, үз дәрәҗәсенә лаек рәвештә, эчтәлеге белән күңелне баетырлык, тышкы кыяфәте белән күзне иркәләрлек яхшы китаплар чыгарырга тырыша. Әлеге омтылыш сувенир-бүләк китапларны чыгарганда бигрәк тә ачык чагыла. Типографик җиһазларның заманча ук булмавына, план чикләүләре һәм башка төр кыенлыкларга карамастан, нәшрият андый нәфис китапларны укучылар кулына әледән-әле бүләк итеп тора. Уч төбенә генә сыешлы, әмма күңелне әсир итә алырлык әсәрләрдән Г.Тукай («Шигырьләр»), Һ.Такташ («Гасырлар һәм минутлар»), М.Җәлил («Шигырьләр»), М.Фәйзи («Галиябану»), Г.Камал («Беренче театр»), Г.Кутуй («Тапшырылмаган хатлар»), Ф.Кәрим («Шигырьләр»), Х.Туфан («Шигырьләр»), «Татар халык мәкальләре» (рус телендә) китаплары әнә шундыйлардан. Һәм менә бу китаплар рәтенә тагын бер мәгънәле басма өстәлде. Исеме — «Сандугачым-былбылым». Карасу-яшел төстәге китап тышлыгында фамилия-мазар юк, алтын йөгертелгән тал яфраклары арасында сандугач берүзе ыспай гына басып тора... Бу инде китапның төп каһарманы — үзе — шул Сандугач; китап битләренә кунып нәрсәләр әйтеп сайрыйсың, күңелләребезгә нинди хис-тойгылар саласың, нәрсәләр бәян итәсең?

«Сандугачым, сайрап җибәр, тавышларың асылдыр; асыл тавышларың белән йөрәгемне басылдыр» дип җырласалар да, Син бу юлы күңелләрне әллә нишләттең әле, Сандугач! Кая йөрәк басылу! — ярсыттың, моңландырдың, тетрәндереп сөендердең, горурландырдың, сагышлаттың, хыялландырдың, өзгәләндердең һәм дә... гамьгә дә батырдың. Яшьлектә генә була торган татлы һәм сагышлы хисләргә күмдең. Мин Сине болай ук дип белми идем! Күрәсең, көтелмәгән бу очрашуга минем әзерлегем дә булмагандыр.

Бу китап һәр нисбәттән дә оригиналь һәм уникаль китап. Уйлап карагыз: сандугач исеме белән кергән, дөресрәге, беренче юлы сандугач исеме белән башланган 500ләп дүртьюллык теркәлгән аңа! Әдәбиятта әллә нинди китаплар бар ул барын, әмма мондыен беренче күрүем. Китап кыска гына кереш сүздән һәм тематик яктан бүлгәләнгән 15 кисәктән тора. Төзүче һәр бүлек-ояга аерым бер уртак мәгънәгә ия җырларны туплап урнаштырган. «Сандугачлар сайрашалар, Туган илем гөл, диеп; Туган илнең, туган җирнең кадерләрен бел, диеп». Аңлашылып тора: бу юллар Туган җир, Туган ил турындагы бүлектән. Ихтимал, сандугач исеменнән җырлаучы туган-үскән җирләреннән читтә йөреп, нужалар күреп, үз якларына кире әйләнеп кайткан берәр җандыр әле... Бәлки, кайту турында хыяллана гынадыр?.. «Сандугачлар усакта, китми алар кусак та. Дошманнарга сер бирмәбез, дуслар исән-сау чакта!» Бу дүртьюллык, әлбәттә, дуслар белән аңлашып яшәүнең ямьлелеге, мәгънәлелеге, ныклыгы турында. «Сандугач ояга керсә, балалары гөр килә. Кадерен белеп кенә яшик — яшь гомерләр бер килә». Боларның да хикмәте бик ачык: «Бу дөньяда бер нәрсә юк — яшьлектән кадерлерәк!» — дип әйтә түгелме соң былбыл? «Сандугачның канатына хатлар кыстырдың мәллә? Ах, дигән тавыш ишеттем, сагынып кычкырдың мәллә?» Хат-хәбәр көтүгә багышланган җырлар бүлегеннән бит бу. Сагынып көткән кешедән килгән сәлам хаты да үзе бер зур бәхет бит! «Сандугачка ашаталар чикләвек төше генә. Бу дөньяда рәхәт яши бәхетле кеше генә». Әйе, кеше яшәвенең асылы — бәхеткә ирешеп, максатлы яшәүдә. «Сандугачым-былбылым, кичә кайларда булдың? Дөнья бәяләре биреп сатып алырдай булдым». «Сандугач кунсын — сыгылсын, былбыл кунсын — бөгелсен. Тау ярылсын, таш эресен — ташлар ярым түгелсең!» Боларның мәхәббәт-гыйшык шигырьләре икәнлеге чәчрәп тора. Шуңа күрә дә бу бүлек күләм ягыннан да зуррак, тәэсир итү ягыннан да үзгәрәк, үтемлерәк. Ә менә мондыйлары? «Сандугачны тотып алдым кунган таллары белән. Солдатларга китсәң иде сөйгән ярларың белән!» Яки «Сандугач кунган киртәдән кисеп алдым чырагач. Ярын тартып алган идем, кире бирдем елагач». Күрәсез, Сандугач гел моңаеп, уфылдап кына утырмый, кирәк чакта кинаяле сүз дә әйтә, җор көйләр көйли, төрттереп тә куя... Шушы рәттән тагын бик күп мисаллар китереп, һәр бүлеккә аеруча хас дүртьюллыкларны анализлап, аларны үзенчә шәрехләп чыгарга мөмкин.

Әйе, сандугачым-былбылым! дибез, сайра-сайра! дибез. Безнең халык сандугачны шулкадәр изгеләштергән, шулкадәр илаһилаштырган ки, хәтта вакыты-вакыты белән сүзләрне чыгарган җырчы кеше белән сандугач үзе берләшеп үк китә безнең күңелләрдә. Әйтерсең көе белән сүзләрне дә сандугач үзе чыгарган! Ә асылда, Кеше сандугач авазына үз моңын, үз көйләрен, үз аһәңен, үз күңелен салган бит! Сандугач — татар халык поэтикасының гүзәл символы, кешеләр күңеленә үзенә күрә бер ачкыч. Сандугач тавышы белән бәйләп кеше дөньяга үзенең нинди генә уй-хисләрен белдермәгән дә, нинди генә кичерешләрен сиздермәгән. Сандугачка бәйләп интим кичерешләрне генә түгел, дөнья-замана барышына караган каршылыклы тойгыларны да, социаль тигезсезлеккә каршы ачулы әрнүне дә, актив протестны да әйткән җырчылар. Әйтик, Николай патша белән

сандугачның җырга кирәрлек нинди бәйләнеше булырга мөмкин? Юк, халык ничектер җаен китереп аларны да бәйләгән. «Сандугачлар яратмыйлар кырау тигән бакчаны, нигә яшен сукмый икән бу Миколай патшаны?» Яки «Сандугачның балалары саз сулары эчмәгән; ярлы диеп кимсетмәгез — бай да сират кичмәгән». Юк, шаярып булмый сандугач белән, үзе бәләкәй генә булса да, халык язмышын, халык күңелендәгесен җырлый торган кодрәтле бер сорнайчы ул! Тормышка аның гаҗәп дәрәҗәдә кирәклеге турында халык үзенең бер-ике юллыгында болай дип тә өстәгән: «Сандугачым, сайра, сайра, өзеп сайра кирәген!» Сандугачка бәйле җырлар — халык рухының, әхлагының, матурлыкны аңлавының үзгә бер көзгесе ул. Ул җырлар аша халык күңеленең киңлеген дә, уйларының тирәнлеген дә, хыялларының бөеклеген дә тоярга, аңларга мөмкин. Хәтта язмыш җилләре аркасында дөнья буйлап сибелгән халык турында демографик мәгълүматлар да табарга мөмкин бу җырларда. Берничә генә мисал: «Сандугач, былбыллар булсам, очар идем Болгарга». «Нигә безнең араларга Урал таулары үскән!», «Сандугачлар ашый микән Сарытау җиләкләрен?», «Китәм, дигәч, китәм инде Әндиҗан каласына», «Сандугачлар Уелда, Уелда су буенда», «Сандугачлар урманда, безнең дуслар Германда». Әйе, сандугачны халык поэтикасының бер символы, күңелләр ачкычы, дидек. Уйлап баксаң, безнең халык иҗатында андый символ булырлык бүтән җисем-атамалар да бар әле. Әйтик, Урал тау исеме кергән күпме җырлар бар безнең! Ә Идел яки Агыйдел турында? Галим И.Надиров раславы буенча, Агыйдел исеме белән бәйләнешле җырларның саны гына да ярты меңнән арта. Аларны да киләчәктә аерым китап каһарманнары итәсе иде.

Күләм ягыннан бәләкәй генә булган бу китап, бигрәк тә аның поэтикасы турында шактый ук тәфсилле бер гыйльми хезмәт язарга мөмкин булыр иде. Бу җырлар нигезендә халык эстетикасының, фикерләү рәвешенең, эстетик идеалның төп принципларын чамалап була. Телнең сыгылмалылыгы, сурәтләү чараларының җете һәм үтемле булуы, ассоциатив янәшәлекләр һәм каршылыклы параллельләр, герой (бу очракта сандугач) тирәсендәге мохит һәм даирә, ритм-рифма һәм башка мәсьәләләрне тикшереп, кызыклы гына күзәтүләр, ачышлар ясарга мөмкин. Бәлки, вакыт табып, халык иҗаты поэтикасын өйрәнүчеләрнең берәрсе бу китапка янәдән мөрәҗәгать итәр әле.

Шулай итеп, нәшриятыбыз укучыларга Сандугач китабы бүләк итте. Әле яңа гына чыккан бу китапка ия булган, туган тел тәмен белүче кешеләр, һичшиксез, үзләрен бәхетле хис итәрләрдер. Менә мин дә ике атнадан артык инде бу яшел тышлы бәләкәй китапны кулымнан төшерми диярлек янымда йөртәм. Хәер, бер мин генәме икән?! Быелгы сабантуйда күргән бер хәл искә төште. Ямьле көн. Каенлы аланлык. Халык диңгезе. Амфитеатр кебек урнашкан мәйданда атаклы көрәшчеләр бил алыша. Халыкның бар игътибары шул көрәшчеләрдә. Бермәл кунаклар утыра торган махсус эскәмиядә утыручы мөхтәрәм бер танышыма күзем төште. Кулында шушы Сандугач китабы. Кызык булып китте. Күзәтәм. Таныш абзыем, көрәш сүлпәнрәк (көрәшчеләр арасында да сөлгегә сөйрәлеп йөрүчеләр очраштыргалый!) барган араларда кесәсеннән китапны чыгара да берәр битен укып та куя (китап төзүче-хуҗа тарафыннан шул сәгатьтә генә бүләк ителде бугай). Ул гына да түгел, хисләнә-хисләнә, янәшә утыручыларга да укып күрсәтә. Шулай итеп, эссе көн үзәгендә, кемнәрнеңдер күңелен биләп, сабантуй мәйданында, түрдә утырды быел Сандугач. Хәер, үз урынын белеп утырган!

Кемдер сорап куяр, бик мактыйсың, шулай бернинди теш тидермәслек китапмыни соң ул, дияр. Гашыйк булган кеше ярының кимчелеген күрмәгән шикелле (китапка чыннан да гашыйкмын), минем өчен ул һәр җәһәттән шактый ук камил китап. Тагын да яхшы итеп күрергә ниятләнүдән туган кайбер күзәтүләрем һәм теләкләрем генә бар. Бөтен бүлекләр дә сәнгати көче һәм композицион бөтенлеге ягыннан тигез дәрәҗәдә үк түгелләр. Ихтимал, кайбер бүлекләрне (әйтик, шартлыча алганда, сабырлык һәм сагынуга багышланганнары) берләштерергә дә мөмкин булыр иде. Йөзәрләгән менә дигән кыска җырлар арасына эстетик тоем авыр кабул итә торган кайбер (алар бер унлапка җыелыр) дүртьюллыкларны кертмәгәндә яхшы булыр иде (әйтик, «Ат күкрәгемә, җәлләмә, юк мәллә наганнарың» яки «Без сөйгәнгә не касайся — без сөймәгән да чурта» һ.б.). Мондый бүләк китапта сирәк-мирәк кенә булса да, хәреф хаталарының китүен дә хуплап булмый. Мондый җитешсезлекләр бу уникаль тарихи китапның гомум дәрәҗәсен һич кенә дә төшерә алмый. Бу әйтелгәннәр алга таба андый характердагы китаплар чыгарганда тагын да игътибарлырак булырга чакыру гына.

Китапның кереш мәкаләсендә төзүче тарафыннан әйтелгән мондый сүзләр бар: «Шатланган, моңайган, сагышланган, сөенгән, көенгән, яраткан, сагынган чакларында җырлар өчен кешегә моң бүләк итүче Сандугачка рәхмәт». Ә без, үз чиратыбызда, китапны дөньяга чыгару өчен зур көч куеп, шушы җырларны җыючы һәм китап итеп төзүче Туфан Миңнуллинга, рәссам Тавил Хаҗиәхмәтовка, нәшрият һәм типография хезмәткәрләренә олы рәхмәтебезне һәм сокланубызны белдерәбез. Китапларыбызның геройлары Сандугачлар була алганда без әле, шәт, озак яшәрбез!

*1985, июль*

**БЕРДӘМ БУЛЫЙК!**

Ил җегәрен, аның киләчәген тәшкил иткән яшьләрнең яраткан газетасы «Татарстан яшьләре»нең олуг бәйрәмен чын күңелдән тәбрик итеп, үземнең дә тәүге иҗат башлангычым белән шушы басмага катнашым барлыгына ихлас горурланам. Республика киңлегендә иң беренче шигырем шушы газетада дөнья күрде! 1958 ел. Мин 8 нче класс укучысы. Ул шигырь «Яз» дип атала.

Уята арган җаннарны
җылы нуры Кояшның.
Бөре яшел күзен ача,
сулышын тоеп язның.

Гөрләвекләр тибрәнә...
Күкнең зәңгәрлекләре.
Тургай җырына коена
кыр-басу киңлекләре.

Язның һәр көне, сәгате
дөньяны ямьләлэтә.
Бу яз көнне яшь булуың
бәхет бит икеләтә!

14—15 яшьлек үсмернең шатлыгын, күңел бәйрәмен, белмим, хәзерге яшьләр бар тулылыгы белән аңлар микән? Әле хәзер дә, шатлыктан язгы март карларына ятып аунар идем дә, хәзер ул безнең урамдагы кебек гөнаһсыз чиста карлар юктыр кебек...

«Татарстан яшьләре» — бөтен дөнья буйлап таралган татар яшьләренең иң зур һәм иң ихтирамлы, иң зур тиражга ия газетасы. Газета дигәнне мин үземчә киңрәк тә аңлыйм: үзгә формада булса да (әлбәттә, аны «Литературная газета», «Известия», «Комсомольская правда» кебек күләмле итеп күрәсе килә), ул — халыкның соңгы дистә елларда югалган яки югалып бара торган гадәт-традицияләрен — әдәп-инсаф, җыр-моң, тел-лөгать, аулак өйләр яки кичке уеннар, җыеннар кебек халкыбызның рухи сурәтен күңелләребездә янәдән торгыза торган үзенә күрә бер университет, искечә әйтсәк, гали мәдәни мәдрәсә дә.

«Татарстан яшьләре»н мин 30 елдан артык алдырам (без бәләкәй чакта аның исеме бүтән иде). Почта тартмасыннан алынган газеталар арасыннан иң элек үзебезнекенә үреләм. Күнегелгән. Шул бер бәләкәй хәрәкәт белән әз генә булса да яшьлеккәрәк борылам кебек... Дөресен әйтим: газетада басылган бөтен материаллар да җанга тынычлык бирә дип әйтмим. Заманы шундый. Оетып йоклата торган язмалар дәвере узды. Имансызлык, итагатьсезлек, җенси тотнаксызлык, миһербансызлык кебек күренешләр турындагы язмалар, әлбәттә, төрле буын кешеләрендә төрле фикерләр уята. Хәер, мораль-этик темалар гына түгел, җитдирәк иҗтимагый-сәяси хәлләргә багышланган язмалар укыганда да төрле-төрле уйлар килә. Әле генә яшьләр журналы «Идел» турында язылган мәкаләләрне укып, гаҗәпләнеп, һәм дә сагаеп калдым. Нидән туган вәсвәсә соң бу? Авыртмаган башка тимер таяк дигәндәй, ни өчен әле «Идел» журналының башлыгына шулай ташланалар? Әгәр эш процессында редакциядә бәхәсле мәсьәләләр бар икән, — нигә башта коллективта үзара сөйләшеп ачыкламаска? Каләм иясенә урамда «ряженый»лар шикелле маскарад ясап йөргәнче, өстәл янына утырып, халык өчен игелекле эшләр турында фикерләшү хәерлерәк бит. Бөтен илгә мәгълүм: «Идел» коллективы, беренче чиратта аның мөхәррире Римзил Вәлиев, безнең матбугат тарихында булмаганча, юк журналны бар итеп, ярты ел эчендә тиражны 100 меңгә җиткерде. Егетлекне хупларга, бәһаләргә кирәк.

Римзил Вәлиев — тәҗрибәле журналист, язучы. Үзәк матбугат органнарында эшләп, әдәбият-сәнгать үсешенә зур өлеш керткән кеше. Ике телдә чыга торган журналны җитәкләр өчен ике телне камил белергә дә кирәк бит әле!

«Идел» — татар халкы яулап алган, дөресрәге, моннан берничә дистә еллар чыккан басмаларның берсе буларак торгызылган басма. «Идел» — (хәзер, шөкер, нәниләр өчен «Салават күпере» дә чыга башлаячак!) халкыбызны киләчәккә илтәчәк бер рухи плацдарм ул. Кайбер шовинистик лозунгларга җавап итеп, русчалатып шуны әйтәсе килә: «Идель — наша надежда!»

Гафу итегез, мавыгып китеп, «Татарстан яшьләре» бәйрәмен онытып җибәрдем бугай. Бәйрәм көнендә төп теләк шул: безнең матбугат Ренессанс чоры кичерә. Ренессанс — безнеңчә, Яңарыш дигән сүз. «Салават күпере», «Яшь ленинчы» («Сабантуй»), «Ялкын», «Идел» һәм иң күп укучыга ия «Татарстан яшьләре» (бәлки, исеме җисеменә үк туры да килеп бетмидер, чөнки ул — бөтентатар яшьләр газетасы) һәммәсе бердәм, тату һәм фикердәш булырга тиешләр дип уйлыйм. Бәйрәмнәр мөбарәк булсын!

*1990, гыйнвар*

## РӘХМӘТ ӘЙТЕР ЧАК

Үз гомерендә кешенең дөньядан күбрәк алган чорлары була. Киресенчә, үзен җелеккә калдырганчы суырган чорлары да юк түгел бу дөньяда. Күк катларында йөзгән хыялый чаклары, егылып төшеп җирдән сөйрәлгән чаклары... Бурычлы чаклары... Түләр чаклары... Шулай ук тагын бер чоры була икән кеше гомеренең (бәлки, ул чыныгу, өлгерү белән бәйледер, төрле кешегә ул төрле вакытта киләдер) — дөньяга, кешеләргә рәхмәт әйтү чоры. Ул гомер йомгагының очы белән бәйле булмаска да мөмкин. Яшь кырыктан узгач, әдәбиятта чирек гасырдан артык хәл кадәри хезмәт итеп, ике дистәләп китап чыгаргач, минем дә булган хезмәтемә, яраткан гамәлемә булышлык күрсәткән кешеләргә рәхмәт әйтү ихтыяҗы артты. Ә бит кул сузган кешеләр, аңлаган һәм ярдәмләшкән, күңелгә дәрт, ышаныч өстәгән кешеләр аз булмады! Шуның өстенә безгә — 60 нчы еллар башында әдәбиятка килгән буынга — дөньяның сугышларсыз чагы, сәяси һәм иҗтимагый тормышның чагыштырмача сәламәт дәвере дә туры килде бит әле! Безнең яшь чак, көчнең ташыган, теләкләрнең тыелгысыз үрләгән чагы. Халыкның, бигрәк тә яшьләрнең, әдәбиятка, аеруча шигъриятькә тартылган, поэтик сүзнең дөньяны яхшыга үзгәртә алу көченә ихлас ышанган чагы. Шигъриятнең кодрәтенә, әлбәттә, без үзебез кирәгеннән артыграк та инанганбыз. Язуын язу, инануын инану, ә язганны бастырып чыгарасы, укучыга җиткерәсе килә бит! Ә кайда бастырасы? «Социалистик Татарстан» кебек зурлар газетасына без башлап язучыларга үтү кыен, «Казан утлары»нда да берничә шигырь бастырыр өчен еллар буе көтәргә кирәк (ярый әле көтеп-көтеп тә чыгарсалар!). Йөзәрләгән яшь авторлар өчен район газетасы форматындагы бердәнбер яшьләр газетасы — «Татарстан яшьләре» кала... Анда да шигырьләрнең ничек чират көтү хәлләрен мәктәптә укыган вакытлардан бирле беләбез... Безнең бәхеттән 1960 елны «Яшь ленинчы» яңадан чыга башлады. Редакторы — Венера апа Ихсанова. Редакция хезмәткәрләре дә бездән өлкән булсалар да, күз күргән кешеләр, күбесе университетның татар бүлеген тәмамлаган иптәшләр. Саимә Ибраһимова, Хәмзә Зарипов, Илгизәр Сәмигуллина, Рәисә Яхина, Рушания Шакирова, Әнәс Сәләхетдинов, Зоммер Гыйләҗев... (Кайберләренең безнең арада булмавына күңел һаман ышанып бетми.) Газетаны илкүләм дәрәҗәле итүдә (СССРда беренче булып чыга башлаган пионер газетасы бит ул!) бөтен редакция коллективы, бөтен авторлар активы гаять зур интузиазм белән эшләде ул елларны. Редакция хезмәткәрләре безнең кебек яшь авторларны да оста җигә белде. Без дип, шул чордагы яшь язучыларны күздә тотып әйтәм: Рөстәм Мингалимов, Рәдиф Гатауллин, Гәрәй Рәхим, Ренат Харис, Фәнис Яруллин, Рахмай Хисмәтуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Җәүдәт Дәрзаманов, Шамил Маннапов, Тәүфикъ Камалиев, Әхмәт Рәшитов, Клара Булатова, Кадыйр Сибгатуллин, Роза Хәлиуллина һәм тагын бик күпләр... Нинди генә язмалар белән катнашмадык без «Яшь ленинчы»да! Ул кечкенә хәбәрләр, репортажлар, мәкалә-уйланулар, рецензияләр, шигырьләр, җырлар... Кемдер мин «Яшь ленинчы»да повесть-хикәя, кемдер шигырь-поэма, кемдер пьеса яки әкият бастырдым дип, эчке бер горурлык белән әйтәдер. Мин үзем күбрәк шигырьләр һәм мәкаләләр язып катнаштым. 1960 елдан бүгенге көнгә хәтле җыенысы илледән артык язма бастырганмын. Байтак бит бу! Җыйсаң, үзе бер китаплык! Шулай булгач, игелек күрсәткән үз газетаңа ничек рәхмәт әйтмисең ди! Бер мин генә түгел, йөзәрләгән бүтән авторлар да газетабызга карата шундый рәхмәтле хис белән яшиләрдер дип уйлыйм. Тагын шунысы да бар: редакция хезмәткәрләре авторлар белән журналистик этик нормаларны саклап, дустанә эшли беләләр. Автор принципларына һәм стиль-үзенчәлекләренә тимичә, аны рәнҗетмичә, барыбер үзләренә кирәк рәвешле эшләттерә иделәр. Бу — күптәннән, газета чыга башлаган көннәрдән килә торган традиция. Ә язмаңның үзең теләгәнчә басылып чыгуы үзе бер бәхет бит ул. Авторларны газета интереслары өчен эшләтә белү үзе бер сәнгать!

Кайчак уйлап куям: әгәр «Яшь ленинчы»быз яңадан чыга башламаса, яңа буын яшь язучылар анда чыныгу алмаган булса, безнең бүгенге әдәбиятыбыз, бигрәк тә балалар әдәбияты нindирәк хәлдә булыр иде икән? Икеләнмичә әйтергә мөмкин: күпкә кайтыш булыр иде. Әллә никадәр язучы биредә әсәрләрен бастырып кына калмады, үзләре редакциядә эш урыны табып, журналистика мәктәбе узып, чыныгып, зур иҗади үрләргә күтәрелделәр. Төрле вакытта кемнәр генә эшләп чыкмады «Яшь ленинчы»да! М.Шабаев, Р.Харис, Х.Халиков, Ә.Гаффар, Р.Миңнуллин, Зөлфәт, Р.Мингалимов... Хәзер дә биредә М.Әгъләмов, Э.Шәрифуллина, Г.Садә кебек шагыйрьләр хезмәт итә. Моннан 20 еллар элек, мин дә берара бу редакциядә газета чыгаручы (выпускающий) булып эшләп алган идем, редакция белән типография арасында арадашчы булып йөри торган эш ул. Көне буе диярлек газетаны язучы редакция хезмәткәрләре белән газетаны калыплаучы (верстальщица) типография кешеләре белән аралашасың (сүз уңаенда әйтим, бүгенге ГЖН директоры Дилбәр ханым Хәйруллина типографиядә безнең газетаны да җыя иде).

Ә кичен эш бетүгә барганда, ниһаять, главлит (цензор)ның серле ПФ хәрефләрен суктыра идең. Газета чыккан көннәрдә төн урталарына кадәр калган чаклар да була. Типография эшчеләренең авыр һәм четерекле шөгыльләрен үз күзләрем белән күрү бик тәэсирләндергән иде ул чакта. Менә бит олы яшьтәге апалар, абыйлар, кургаш тузаны йотып, без кәгазьгә төшергән сүзләрне нинди тимер машиналар аша үткәреп, күпме көч һәм күз нуры түгеп азап чигәләр. Юк, мәгънәсез, халыкка кирәксез нәрсәләрне беркайчан да язмаска! — кеше хезмәтенең каһәре төшәр! — үзең инанган, йөрәгең кушкан, хакыйкатьне әйтә торган чын сүзләрне генә кешеләргә тәкъдим итәргә кирәк! Фәкать шулай гына! Редакциядә, дөресрәге, типографиядә ярты ел гына эшләп алсам да, үзем өчен, алдагы иҗатым өчен бик тә кирәк булган әнә шул сабакны алып чыктым. Шуның өчен генә булса да гомер буе рәхмәт әйтерлек бу газетага.

Ул елларны Татарстанда чыга торган бөтен газета-журнал редакцияләре, шул исәптән «Яшь ленинчы» да Бауман урамындагы Матбугат йортында урнашкан иде. Еш кына бу бинага кереп, язучыларның Тукай клубы (хәзер инде бу клуб бинасы «Мәгариф» нәшриятының эш бүлмәләре итеп үзгәртелгән. Ә Тукай клубы Мөштәри урамындагы Язучылар берлеге йортына күчерелде) ягына менә торган баскычлардан күтәрелгәндә, әчке бер моңсулык белән элек редакция урнашкан бүлмәләрне күзләп узам. Хәзер ул бүлмәләрдә авыл хуҗалыгына бәйле оешмалар эшли. (Хәзер «Время и деньги» газетасы редакциясе урнашкан). Ә бит заманында 60 нчы еллар урталарында яшь язучыларның, бигрәк тә яшь шагыйрьләрнең үзенә күрә бер штабы иде бит бу бүлмәләр! Һәрхәлдә, безнең өчен ул шулай иде. Хәзер газета, безнең яшьлекләрне шәһәрнең иске, тарихи өлешендә калдырып, яңа җиргә — Казансуның теге ягына күчте. Редакция бүлмәләрендә дә хезмәткәрләрнең күбесе яңа кешеләр. Әмма газета үзенең төп бурычына тугрылыклы булып кала бирә: яшь буынны тәрбияләүдә армый-талмый үзеннән өлеш кертә.

Мин бу язманы әдәбиятка бәйләнешле кеше буларак яздым. Табигый, төп сүзем дә газетаның әдәбиятка, язучыларга бәйләнеше хакында булды. Әгәр газетабыз турында, аны укып, анда катнашып үскән, хәзер төрле профессияләре булган бүтән замандашларыбыз язса да, барыбер «Яшь ленинчы» турында үз сүзләре белән, үзенчә, минем кебек, рәхмәтләр укырлар дим.

*1984, октябрь*

**«ИДЕЛ»ГӘ УН ЯШЬ!**

«Без — Иделле халык. Хәзер инде «Идел» журналлы да булдык. Хәер, борын-борыннан Идел безнең рухыбызда, җыр-көйләребездә, җаныбызда. Без — Идел балалары, Иделкәйнең суын эчеп үскән кешеләр, аны үзебезнең тәнебездә, (хәтта процентлап исәпләсәң дә байтакка чыга!) вөҗүдебездә йөртәбез...

Әйе, «Идел» — байтак дистә еллар буе берничә буын көрәшеп, кан-яшь елап, күп кимсенүләр һәм югалтулар аша яулап алынган журнал. Күп көч куеп, азап белән килгән бәхетнең шатлыгы да зуррак, кадерлерәк була. Шуңа күрә дә без — теге яки бу дәрәҗәдә әдәбиятта катнашып килгән каләм ияләре — Иделнең бөек исеменә лаек итеп иҗат итәргә тиешбез дип беләм. «Идел бит ул тирән бит ул, Идел бит ул киң бит ул!» Журналыбыз, чыннан да, киң күңелле булып, төрле төбәкләргә чәчелгән талантлы яшь милләттәшләребезгә күбрәк юл ачсын; һәр җөмләсе, һәр бите, һәр әсәре мәгънәле һәм тирән булсын!

Бу юлларны мин нәкъ ун ел элек язганмын. Хәзер дә уй-теләк, фикерләрем үзгәрмәде, киресенчә, бу теләкләр көчәйде генә. Бу еллар эчендә хыялдагы гына түгел, реаль журналның йөзләгән санын күрдек, укыдык, яраттык, уйландык, кайчак көрсенебрәк куйган чаклар да булгандыр, һәрхәлдә, бу журналга карашыбыз, мөнәсәбәтебез анык хәзер. Кистереп әйтеп була: өметләрнең күбесе акланды. Бик тә четерекле — үзе кызык, үзе фаҗигале шушы ун ел эчендә үзеңне саклау, йөзеңне һәм мәсләгеңне югалтмау бер басма өчен дә җиңел нәрсә түгел. Моны әдип буларак һәм матбага эшендә катнашкан кеше буларак әйтәм. Журнал шушы еллар эчендә шактый көчле авторлар төркеме булдыра алды. Бүгенге көннең иң актуаль проблемалары, бигрәк тә милли-сәяси темалар яшьләргә хас кыюлык белән даими яктыртылып киленде. 90 нчы еллар башындагы милли азатлык көрәше, бүтән басмалар белән чагыштырганда, аеруча тәфсилле һәм объектив яктыртылды дип уйлыйм. Йөзләгән яшь авторларның беренче мәртәбә «Идел»дә дөньяга күренүләре — журналның төп вазифасын башкаруы чагылышы. Полиграфик яктан да журнал яшьләргә хас зәвык белән матур итеп бизәлеп чыга. Әлбәттә, редакциядә тирән белемле, талантлы каләмдәшләребезнең эшләве төп нәтиҗәгә китерә дә инде. Журнал чыга башлаганнан бирле эшләүчеләр — Ркаил Зәйдулла, Нәбирә Гыйматдинова, Роза Кожевникова соңрак килеп кушылганнар — Фәиз белән Ләис Зөлкарнәйләр, Рашат Низамиев, Рәфикъ Юныс, Солтан Шәмси, Сергей Малышев, Марат Закир... Болар бит үзләре зур бер көч! Шуларга өстәп күпме фидакарь гамәли хезмәткәрләр...

Юбилей уңаеннан, гадәттә, күбрәк мактау сүзләре ишеттерелсә дә, теләкләр дә юк түгел. Иң мөһиме — тиражны арттыру, журнал укучыларның сафын ишәйтү. Киләсе гасырда үз телебездә укучы яшьләрнең күбрәк булуын теләү — безнең җанда, канда бит! Ә әлегә бу ямьле җәй көннәрендә унъеллык юбилей бәйрәме матур һәм мәгънәле узуын телибез!

*1999, май*

## БАЛАЛАР МАТБУГАТЫ ҺӘМ БЕЗ

Балалар матбугаты дигәндә, «Ялкын» журналын һәм «Яшь ленинчы» газетасын күздә тотып әйтүем, ә без дигәне, шәт, аңлашыладыр, анысы инде бөтенебез — бу басмаларга теге яки бу дәрәҗәдә бәйләнешле кешеләр — укучылар, укытучылар, тәрбиячеләр, язучылар, журналистлар, сабыйлар, малайлар, кызлар, үсмерләр, әтиләр, әниләр, өлкәннәр... «Матбугат» һәм «без» дигән бу ике зур төшенчәне бергә янәшә куеп сөйләү үзеннән-үзе, табигый рәвештә тәрбия, бигрәк тә яшь буынны тәрбия итү мәсьәләсен кузгата. Мәгълүм хакыйкать: гуман эчтәлекле матбугат, гуман эчтәлекле әдәбият — болар бөтенесе безнең басма сүзнең нигезен тәшкил иткән нәрсәләр — һәр шәхесне төрле яклап тәрбияләүгә булыша: гражданин буларак илсөяр сыйфатларын үстерә, күзләребезне үткенләтә, хисләребезне нәфисли, җәмгыятьне тагын да камилрәк итеп активрак төзешергә әйди, гүзәл табигатебезнең нигезендә яткан кешелеклелек тойгыларыбызны арттыра. Үз вакытында тиешле әхлакый тәрбия алган, үз вакытында әдәбиятны, әйтик, поэзиянең яхшы үрнәкләрен укыган, музыканың серле авазларын ишетеп тәэсирләнгән, рәсем яисә театр сәнгатен күреп, ишетеп үскән яшь кешенең җәмгыять рухын рәнҗетә торган эшләрне эшләмәве, андый хәлнең булган очракта да бик сирәк булганлыгы да бәхәссез нәрсә. Кешегә информация бирү һәм эмоциональ тәэсир итү чыганакларының берсе буларак, матбугатның роле әйтеп бетергесез зур. Шуңа да тәрбия эше бөтен кешелек масштабында иң актуаль мәсьәләгә әверелгән чорда, безнең илдә балалар матбугатына гаять зур игътибар бирелә.

Балалар журналын яисә газетасын кулга алып, күңелгә хуш берәр хикәя һәм шигырь укыгандамы, күзне иркәләрлек берәр рәсем карагандамы яки республикабыз балалар тормышыннан алынган берәр күркәм хәбәр белән танышкандамы яисә почта таратучының калын сумкасында таныш исемдәге газета-журналларны күргәндәме — еш кына балалар матбугатының үткән юлы, бүгенгегә китереп тоташтыра торган баштагы чыганаклары турында уйланасың. Әйе, бүгенге балалар матбугаты басмаларының сыйфаты канәгатьләнерлек, күңел булырлык. Нәрсәгә таянып авыз тутырып шулай дип әйтә алабыз? Чөнки алар, идея-художество эчтәлеге ягыннан булсын, зәвык белән бизәлеше ягыннан булсын, илебездә балалар өчен чыгарыла торган иң яхшы басмалар рәтендә торырлык. Моны бүтән телләрдә чыга торган журналлар белән таныш һәм, гомумән, балалар матбугаты белән хәбәрдар булган кешеләр яхшы белә. Үзенең сыйфаты белән «Ялкын» журналы, әйтик, «Пионер», «Костер», «Березка» (Белоруссия), «Дугас» (Латвия) журналлары белән мәйдан тотарлык журнал. «Пионер» журналы (Мәскәү) коллективының «Ялкын»га җибәргән котлау хатында менә мондый юллар юкка гына язылмаган дип уйларга кирәк. «Татар пионерларының журналы яз башында туды. Бөтенсоюз журналы «Пионер» да яз башында дөньяга чыкты. Алар илебездәге пионер матбугатының беренче карлыгачлары булдылар». 1974 елның көзендә «Яшь ленинчы» газетасының 50 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә күп кешеләр — үзебезнекеләр дә, килгән кунаклар да — бер фактка хәйран калып гаҗәпләнделәр: бәй, безнең «Яшь ленинчы»быз — бөтенсоюз газетасы «Пионерская правда»дан да өлкәнрәк икән ләбаса! Тикмәгә генә аны ил күләмендә иң яхшы балалар газетасының берсе дип зурламыйлар икән! Әйе, эчке инану белән безнең балалар матбугаты «канәгатьләнерлек» дигәнбез икән, — бу сүзне, теләгәндә, һәрберебез әйтә аладыр, — әмма бу сүзне әйтерлек көннәргә хәтле гыйбрәтле юл үтелгән. Ә үткән юл — китап һәм матбага тарихы, аның традицияләре — гасырлар белән билгеләнә. Бездә инде революциягә хәтле дә балалар өчен махсус басмалар булган. Мәсәлән, Ф.Агиев нәширлегендә чыккан балалар журналы «Ак юл»ны гына искә төшерик («Ялкын» журналы соңгы биш-алты ел эчендә заманында «Ак юл»да басылган кайбер әсәрләр белән таныштырып та алды). Әгәр үз вакытында бу журналда М.Фәйзи, Н.Исәнбәт, Б.Рәхмәт кебек күренекле язучылар һәм шагыйрьләрнең балалар өчен язылган матур-матур әсәрләре басылган икән, димәк, без бу журналны да балалар матбугатыбызның ерак башлангычында торган бер басма дип әйтә алабыз.

Балалар матбугатының төп бурычы — балаларны гуманистик рухта тәрбияләү, киләчәк җәмгыятьне актив төзүче таза һәм бәхетле буын әзерләргә булышу. Бу нәрсә исә хезмәт сөюдән һәм югары әхлак нормаларын үзләштерүдән тыш мөмкин түгел. Шуңа күрә дә балалар матбугаты, беренче чиратта, үзенең төп игътибарын һәм мәйданын балаларның үз тормышын — укуларын, хезмәткә катнашуларын, уй-хыялларын, ял һәм иҗат итүләрен, гомумән, алар тормышының бүтән

якларын яктыртуга бирә дә. Тәрбия фәкать конкрет тормыш җирлегендә алып барылганда гына максатка ярашлы. Даими чыгып килә торган рубрикаларына гына игътибар иткәндә дә журнал һәм газеталарның балалар тормышы белән тыгыз элемтәдә яшәгәнлекләрен аңлап була. Менә «Яшь ленинчы»ның кайбер рубрикалары: «Кем булырга, нинди булырга?», «Ничек яшисең, отряд?», «Пионер булсаң, шундый бул!», «Туган ягым — яшел бишек», «Мавыгулардан — ачышларга», «Сиңа әйтер сүзем бар» һ.б. Шулай ук «Ялкын» журналының да ун меңләгән укучылары яратып кабул иткән бүлек-рубрикалары бар. «Пионер ялкыны», «Пионер почтасы», «Әдәплеләр клубы», «Үзең яса!», «Яшь хәбәрчеләр мәктәбе», «Сәнгать битләре»... Боларга өстәп, укучы балаларның фикерләү сәләтен арттыра, дөньяга карашларын киңәйтә торган тагын әллә ничаклы материаллар! Классик әдәбият үрнәкләре, балалар әдәбияты тарихы сәхифәләре, дөньяга танылган мәшһүр спортчылар турындагы язмалар, төрле ил халыкларының хикмәтле әкиятләре, фән-техника яңалыклары, кроссворд-башваткычлар... Ә «Яшь ленинчы»ның Шәвәлие, «Ялкын»ның Чаткысы инде дистә еллар буе балаларның чын юлдашларына, якын киңәшчеләренә әверелделәр. Тормышның алгы сызыгында, пионер хәрәкәтенең үзәгендә булуның да бездә инде үз традицияләре бар. Тауга биеккәрәк менгән саен, үткән юлың ачыграк булып күренә, диләр... Моннан утыз-кырык ел элек балалар матбугатына теге яки бу мөнәсәбәттә бәйләнеше булган кешеләрнең язмышларына күз салыйк. Кемнәр генә юк алар арасында! Ил күләмендә мәшһүр галимнәр, язучылар, предприятие-оешма җитәкчеләре, хәрби начальниклар, танылган эшчеләр, рәссамнар... Кайбер исемнәрне генә хәтерлик: Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гыйлем Камай... Бу очракта атаклы рәссам Харис Якуповның газета аша әйткән сүзләрен искә төшерәсе килә. «Минем беренче рәсемнәрем моннан кырык елдан артык элек «Яшь ленинчы» газетасында дөнья күрде. Безнең класс малайларыннан Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган сәләтле яшь шагыйрь Мөхәммәт Әхмәтгалиев, хәзерге көндә атаклы рәссам Лотфулла Фәттахов, танылган балалар язучысы Җәвад Тәрҗеманов, Патрис Лумумба исемендәге халыклар дуслыгы университеты профессоры Габделхак Галиуллинның һәм башкаларның беренче әсәрләре «Яшь ленинчы» битләрендә басылды... Газета безнең яшь йөрәкләрдә Туган илгә кайнар мәхәббәт хисләре тәрбияләде. Өлкән яшьтә булсак та, безнең өчен ул әле дә бик якын. Аңа чын күңелдән рәхмәт әйтәбез». Шик юк, тагын дистә еллар үткәч тә, бүген балалар матбугатында актив катнашучы яшь иптәшләр, зур кешеләр булып үсеп җиткәч, шундый ук рәхмәт сүзләре әйтерләрдер. Шулай булыр. Күз алдында бит: кайбер укучылар башлангыч классларда укыган вакытта ук «Алмаш» битләрендә, «Яшь сәләтләр клуб»ларында һәм Чаткы конкурсларында мәкалә-хәбәрләр, шигырь-хикәяләр бастырып, каләм шомартып чыныгып үсәләр дә мәктәпләр тәмамлыйлар, ә аннан югару уку йортларына керер алдыннан өлгергәнлек аттестатлары белән бергә «Ялкын» яки «Яшь ленинчы»да чыккан язмаларын да теркиләр. Чыннан да, бу язмалар яшүсмерләрнең өлгергәнлеген, билгеле бер рухи мәктәп үткәнлеген белдерә торган таныклыклар бит.

Балалар әдәбияты, балалар матбугаты тарихына күз салсаң, язылмаган бер закончалык ачыла төшә. Зур һәм бөек язучыларның иҗатлары һәрвакыт диярлек балалар дөньясыннан аерылгысыз. Пушкин һәм Толстойның, Тукай һәм Җәлилнең, Гюго һәм Экзюпериның тулы иҗатларын аларның балалар өчен язган әсәрләреннән тыш күз алдына китерү кыен. Татар әдәбияты тарихындагы күренекле шәхесләрнең күпчелеге балалар әдәбиятында да якты эз калдырганнар. Бер яктан, язучылар үзләре балалар матбугаты аша үзләренең нәни укучылары йөрәгенә юл ярырга тырышсалар, икенче яктан, басмаханә җитәкчеләре, газета-журнал хезмәткәрләре үзләренең басмаларына яхшы язучыларны мөмкин кадәр күбрәк тартырга тырышканнар. Һәм бу хәл аңлашыла да. Чөнки язучы актив катнашкан басма һәрвакыт кызыклырак, баерак, мәгънәлерәк булып чыга, басылган материаллар тел ягыннан камил һәм халыкчанрак була. Уйлап карасаң, тел ул — теге яки бу басманың сыйфатын билгеләүче төп күрсәткечләрнең берсе бит. Кайбер язучылар балалар матбугатында катнашучы сыйфатында гына түгел, бәлки эшне башлап йөрүчеләр дә булганнар, редакцияләрне җитәкләгәннәр. Журнал тарихын гына алыйк: Муса Җәлил «Кечкенә иптәшләр»нең җаваплы редакторы булып эшләгән. Элегрәк елларда «Пионер каләме», «Пионер» исемнәрендә чыккан «Ялкын» журналының башында күренекле балалар язучылары — А.Алиш, А.Әхмәт, Г.Мөхәммәтшин, Л.Ихсановалар торган. Бу факт үзе генә дә балалар матбугаты белән язучыларның тыгыз бәйләнешы турында сөйли. Бүгенге көндә дә һәр балалар редакциясенең үз тирәсенә җыйган язучылар активы бар. Әйтик, Н.Исәнбәт, Н.Арсланов, Җ.Тәрҗеманов, Н.Дәүли, Ш.Рәкыйпов, З.Нури, М.Хәсәнов, И.Салахов, Г.Минский, Ш.Бикчурин һәм башкалар күбрәк «Ялкын» журналында язышсалар, Г.Бәширов, Ә.Еники, Ф.Хөсни, М.Әмир, Г.Ахунов, Н.Фәттах, Г.Галиев, Ш.Галиев, А.Гыйләҗев, И.Юзеев, Т.Миңнуллин, Х.Халиков, Зөлфәт, Роберт Миңнуллин һәм башкалар күбрәк «Яшь ленинчы»да катнашып киләләр. Әлбәттә, бу шартлы бүленеш. Балалар күңелен баетырлык әсәрләрең бар икән, рәхим итеп, теләсә кайсында бастыр, редакция хезмәткәрләре шат кына булачак. Әйтик, Ф.Яруллин, А.Тимергалин, Ф.Шәфигуллин, М.Мәһдиев, Г.Хәсәнов, М.Әгъләмов, Р.Батуллин кебек язучылар һәр ике басмада да актив катнашып киләләр һәм бу бик

яхшы. Соңгы елларда «Яшь ленинчы»да булсын, «Ялкын»да булсын, яшь һәм урта буыннан күпме шагыйрьнең менә дигән шигырь бәйләмнәре дөнья күрде. Ш.Галиев, Ә.Баян, М.Шабаев, Р.Мингалим, Г.Рәхим, Р.Гатауллин, М.Галиев, З.Мансуров, Ф.Сафин, Р.Хәлиуллина, Роберт Әхмәтҗанов, Рәшит Әхмәтҗанов һәм тагын бик күпләр. Кайбер язучыларыбыз турыдан-туры балалар матбугаты аша зур әдәбиятка килделәр. Әйтик, хәзер инде зур, чын язучыга әверелгән диңгезче Миргазиян Юныс, танылган шагыйрь һәм язучы Фәнис Яруллин, табигать турында менә дигән китапларның авторы Гарәфи Хәсәновларның иҗатларын балалар матбугатыннан башка күз алдына да китереп булмый. Хәер, бер алар гынамы соң? Без бөтенебез дә шушы «Яшь ленинчы», «Ялкын» битләреннән күтәрелдек түгелме соң?!

Әйе, балалар матбугаты язучыларыбыз өчен урынны мул бирә. «Ялкын»ның яртысыннан артыгы язучыларыбызның әсәрләре белән чыга, «Яшь ленинчы»ның да өчтән бере чамасын әдәби әсәрләр тәшкил итә. Яшь буынны тәрбияләүгә булышлык итә торган күпме язмалар анда! Тормышыбызның нинди генә яклары күрсәтелеп, нинди генә әһәмиятле мәсьәләләре һәм проблемалары күтәрелми аларда! Әйе, болары бик яхшы. Ләкин язучыларның балалар матбугаты каршындагы бурычлары да тау кадәр әле. Редакция хезмәткәрләре белән сөйләшкәндә, сүзнең очы һәрвакыт диярлек шуңа килеп терәлә: язучыларыбызның күбесе балалар тормышын, бүгенге мәктәп тормышын яхшы белмиләр. Язганнарыбызның күбесе моннан әллә кайчан үткән бала чагыбыз хатирәләреннән тора. Без еш кына ерак үткәндәге хәлләрне бүгенге тормышка механик рәвештә күчерәбез. Ә бит бүгенге балаларның табигате һәм хыял-омтылышлары шактый үзгә! Сер түгел, без әле хәтта үз балаларыбызның да күңел дөньяларын белеп бетермибез. Безнең йә вакытыбыз җитми, йә кызыксына белүебез шуның кадәр. Димәк, балалар тормышын белү, аларның рухи халәтен аңлау өчен мәктәпләргә тантаналы очрашуларга барып, шигырь яки хикәя уку гына, почетлы пионер булып түр башында утырулар гына җитми. Аралашуның, тормышны өйрәнүнең үтемлерәк һәм файдалырак бүтән формаларын эзләргә кала. Бүтән юл юк.

Тагын бер мәсьәләгә тукталып үтәсе килә. Ул — балалар әдәбиятына, балалар матбугатына мөнәсәбәт, аны пропагандалау һәм зурлау мәсьәләсе. Мәгълүм аксиома: балалар матбугаты зур һәм абруйлы булса, әдәбият зур була, әдәбият зур булса, аның тәэсир итүе көчлерәк була, димәк, киләчәк буыннарны һәрьяктан җитлеккән итеп тәрбия итү юлы кыскара, максат якыная дигән сүз. Дөньяда һәрнәрсә конкрет. Абстракт дөреслек булмаган кебек, абстракт мөнәсәбәт, абстракт пропаганда да юк. Минемчә, безнең балалар матбугаты, гәрчә аларның титул битләрендә орден яки медаль эмблемалары булмаса да, зур пропагандага һәм ихтирамга лаек басмалар. Кызганычка каршы, балалар әдәбияты тарихын, балалар басмалары тарихын өйрәнү эше бездә начар куелган. Бу өлкә буенча белгечләр юк дәрәҗәсендә. Шуңа күрә җитди фәнни хезмәтләр дә юк. Алар булмагач, бу хәрәкәтнең үсү тенденцияләрен ачыклау да кыен. Күрәсең, кайбер практик чаралар күрүдә дә инициатива җитенкерәми. Әйтик, балалар әдәбиятын һәм матбугатын пропагандалау урыннары булдыру максатка ярашлы булыр иде. Дәүләт музееның әдәби бүлегендә, пионер сарайларында балалар әдәбиятына багышланган күргәзмәләр, махсус почмаклар, стендлар һ.б. оештырырга мөмкин бит. Алар үзләре бер тәрбия учакларына әверелерләр иде. Көн саен күп меңләгән данәләрдә газета яки журнал чыкса да, айлар, еллар үткән саен, алар югала бара. Редакция бүлмәләрендә яки китап палатасында бер-ике данә (кайчакта алары да тулы түгел) төпләмәләр саклану гына аз. Бер генә мисал: әле күптән түгел генә «Яшь ленинчы»да «Пионерская правда» газетасы редакциясенең Татарстан пионерларына һәм журналистларына үтенеч-өндәмәсе чыкты. Анда «Пионерская правда» газетасының югалган данәләрен (сугыш вакытында бу газета берничә ай Казанда чыккан) табарга булышуны сорыйлар. Димәк, үз вакытында тиешле хәстәре күрелмәгән. Бу әле үзәк матбугат органы белән булган хәл. Җирле матбугат белән дә бит төрле хәлләр булырга мөмкин. Болары — мәсьәләнең бер ягы гына әле. Алыйк тиражларны. Монысы иң төп моментларның берсе. «Яшь ленинчы» газетасы сугышка кадәрле, Алишлар заманында, йөз меңнән артык тираж белән басылган. 60 нчы еллар башында бу газета яңадан чыга башлап, берничә дистә меңнәрдән янәдән йөз меңнән артыкка күтәрелде. Әмма соңгы елларда газетаның тиражы беркадәр кимеде. Сәбәп нәрсәдә? Сәбәпләр байтак. Шуларның берсе бу газетаның бөтенсоюз газета-журналлар каталогына кертелмәвендә. Әлбәттә, бу хәл чит өлкәләрдәге укучылар өчен шактый кыенлыклар тудыра. Тиражның кимүендә бүтән оештыру чараларының да җитәрлек булмавы бер сәбәп, әлбәттә. Балалар матбугаты һәрвакыт пропагандага мохтаҗ. Бала бит үзбаш кына — ул бит әле күп нәрсәне белмәскә дә мөмкин — мәсьәләне хәл итә алмый. Аларга өлкәннәрнең әйтеп торуы, аңлатуы кирәк. Тиражлар ягыннан «Ялкын» журналы стабильрәк хәлдә тора. Инде шактый еллар буе журнал 70 меңнән артык тираж белән чыгып килә. Бәхеткә каршы, журнал бөтенсоюз каталогына кертелгән һәм шуңа күрә дә ул татар балалары яши торган чит өлкәләрдә дә шактый күп тарала. Бу журнал турында соңгы елларда үзәк матбугат битләрендә дә анализлы төпле мәкаләләр чыккалады. Әйтик, быел гына да «Литературная Россия» һәм «Детская литература» журналларында «Ялкын» турында мәкаләләр басылды. Моннан биш ел элек Язучылар союзы инициативасы белән шул ук «Детская литература»

журналы тулы бер санын диярлек Татарстанның балалар әдәбиятына багышлаган иде. Әлбәттә, бу чаралар балалар матбугатының Союз күләмендә абруй алуына нык булышлык итә.

Балалар матбугатын пропагандалауда мәктәп җитәкчеләренең, бигрәк тә әдәбият укытучыларының роле зур. Күп нәрсә аларның инициативасына бәйләнгән. Казанда, мәсәлән, 140 ка якын мәктәп бар. Әмма аларның төрлесендә республика балалар матбугаты төрлечә тарала. Кайбер мәктәпләрдә «Яшь ленинчы» 130—180 шәр данә тарала. Ә беришеләрендә дистәләп кенә. Димәк, хикмәт — оештыруда, мөнәсәбәттә.

Гомумән, балалар матбугатын тарату — бөтен җәмәгатьчелек, бөтен халык эше. Бу эш язучыларга бигрәк тә кагыла. Тукаебызның матбугат тарату контораларында экспедитор булып эшләгәннәрен онытмыйк! Әгәр һәр мәктәп йөз данә генә алдырса да, шәһәребездә балалар газетасы унбиш меңләп тарала алыр иде!

Әлбәттә, яхшының чиге юк дигәндәй, балалар журналын һәм газетасын тагын да яхшырту, аларның кабатланмас үз йөзләрен булдыру юнәлешендә әле байтак эшлисе бар. Безнең шартларда матбугатның кул яссуы кадәр һәр почмагы кадерле һәм аның белән сакчыллык принцибыннан чыгып эш итү хәерле. Хәзер укучысы булган һәрбер йорт диярлек бик күптөрле газета-журнал алдыра. «Пионерская правда» да, «Костер» да һәм башкасы да килә. Аларда булган кайбер материалларны кабатлау яки фикер әйтү рәвешендә басылган язмалар шул ук укучыга яңалык китерми. Яңалык булмаса, кызыксыну да кими. Шулай ук балалар күңелен яхшы белгән язучылар һәм журналистларны балалар матбугатына ныграк тартырга, аларның вакытлы матбугаттагы файдалы эш коэффициентын күтәрүгә ирешергә кирәк. Ә бу исә күпмедер дәрәҗәдә редакция сотрудникларының булдыклылыгына бәйле. Әгәр бүген балалар газетасындагы төп рубрикаларда, әйтик, «Сиңа әйтер сүзем бар»да иң җанлы, иң кызыклы материалларны язучылар яза икән, алар шулай ук бүтән сөйләшүләрдә дә тагын да активрак катнаша алырлар иде. Бу очракта язучы халкы, уйга һәм фантазиягә бай халык, үзләре үк инициатива күрсәтеп, яңа сөйләшүләр, әңгәмәләр, бәхәсләр тудырырлык темалар тәкъдим итәргә, мөһим проблемалар күтәреп чыгарга тиеш. Кыскасы, эш җитәрлек. Бары күңелең һәм теләгең генә булсын!

...Бер олы язучыбызның эш кабинетында, стенаның иң күренә торган урынында бер мактау кәгазе эленеп тора. Гадәти генә кәгазь. Алтыннар йөгерткән язуы да юк, зурлыгы да уртача гына. Ә үзе иң кадерле урында. Гаҗәпләндем бераз, юкса бу зат бит гомерендә әллә нинди бүләкләр, әллә нинди дәрәҗәдәге мактау кәгазьләре алган кеше. Нигә нәкъ шунысы тора соң эленеп? Сорадым. «Әйе, бу минем өчен бик кадерле бүләк. Укып бак, аңларсың», — диде ул. Зәңгәрсу фонда, кызыл галстук сурәте астында мондый юллар язылган иде: «Балалар газетасы белән актив хезмәттәшлек иткәне һәм иҗади дуслыкта торганы өчен...» Бу язучы миңа бу минутта бик тә олы һәм бөек кеше булып күренде. Мин аның балалар әдәбиятының, балалар матбугатының чын патриоты булганын аңладым. Гомумән, чын язучының карашы нәкъ шулай булырга тиеш тә. Чөнки сүз бит безнең һәм яшь буынның киләчәге турында бара.

*1979, сентябрь*

## БӨЕК ТӨРКИЛЕКТӘ БЕЗ ОЛУГ

Әдәбиятыбызның чыганагы — чишмә башын каян, кайсы гасырдан исәпләргә? Бу сорау риторик һәм бик гади тоелса да, заманында байтак акыл ияләрен моназара мәйданында «кылыч уйнатырга», саташырга һәм саташтырырга, хәтта ки баш шәрәфләреннән дә мәхрүм калырга мәҗбүр иткән идеологик мәсьәлә. Без, гадәттә, татар әдәбиятының меңьеллык тарихы бар дип сөйлибез. Ә ни өчен мең? Күрәсең, Болгарда ислам динен кабул итү дә бер дәлил булып торадыр. Ә бит дин кадәр дин кабул иткәнче илдә язма мәдәни җирлек булмаганмы? Ә V—VII гасырлардан килгән Урхун-Енисей язмаларын, Күлтәгин ташларындагы шигъри язуларны кая куясың?

Тарихыбызны шактый бутаганнар. «Гел бер телдә язылган тарих — әнкәсенең уңган кызы» дигәндәй, үткәнне безгә ничә гасырлар буе, нигездә, бер телдә: урыс руханиларының летописьлары (елъязмалары) буенча өйрәтеп килделәр. Аларда, әлбәттә, бүтән халыкларның, әйтик, төркиләрнең, бигрәк тә татарларның тарихы томан эченә яшерелде. Ерак тамырларны кисү, онытуыру төп сәяси факторларның берсенә әйләнде. Татар тарихын Болгар тарихына гына кайтарып калдыру әнә шул сәясәтнең бер нәтиҗәсе булды. 1944 елдагы мәгълүм карар татар шәҗәрәсен, нигездә, Идел буе төбәгенә генә бәйләп аңлату өчен кирәк иде. Өстәвенә берничә имля алыштыру да халык хәтерен яхшы ук томалап куйды. Хәтта шундый абсурдка барып җителде, кайбер мөтәгалимнәр, мөтә-җитәкчеләр татар язма әдәбиятын октябрь инкыйлабы белән бәйләп, башлангычын шуннан эзли башладылар. Уйласаң — уйланырлык. Дөнья — куласа, XX гасыр ахырында дөнья галимнәре Казан шәһәренең кимендә меңьеллык тарихы барлыгын исбатлыйлар. Шәһәр кадәр шәһәре булган халыкның үзенчә дәүләте, язмасы, әдәбияты булмаганмы?

Тагын шунысы да бар: ерак гасырлардан берән-сәрән сакланып калган язма үрнәкләре дә, шактый ук шартлы бүленгән социаль-иҗтимагый дәверләргә яраклаштырып, аларга сәяси-сыйнфый төсмер биреп, тарихыбызның аерым чорларын бер-беренә каршы куеп, һәркайсын күпмедер дәрәҗәдә аерымланган итеп күреп өйрәнеп килгәнбез. Дөресрәге, ихтыяри яки ихтыярсыз мәҗбүр ителгәнбез. Галим Ш. Абилов сүзләре белән килешми мөмкин түгел. «... ул вакытта мең елдан да артык вакыт эчендә дәвам итеп, колач җәеп, тоташ бер тәсбих тасмасы рәвешендә сузылып үсә барган әдәбиятыбызның бербөтен чылбырын танымаска дучар ителәчәкбез. Бу — урта гасырларны эченә алган татарның бербөтен әдәбиятының үзеген тәшкил иткән Алтын Урда дәверендәге ядкарьләрен кисәкләргә аерып, төбәкләргә бүлгәләү, аның дөнья классикасы рәтендә торган әсәрләреннән колак кагу булыр иде».

Ни кызганыч, халык, интеллигенция, хәтта без, язучылар, үз әдәбиятыбыз тарихын белмибез. Без, асылда, үтеп баручы егерменче гасыр әдәбиятының символы Тукайны беләбез.

Татар әдәбиятының фәлән гасырлык тарихы дигәндә, шиксез, бәхәсләшерлек нәрсәләр дә юк түгел. Меңәр еллык үлчәмнәргә китсәң, әлбәттә, уртак төрки тамырларга кайтып төшәсең. Шулай булуы табигый да. Бер уйласаң, нәрсә ул мең ел!

Тарихның бер тирән сулыш алуы гына. Әйтик, сиңа 50 яшь ди. Димәк, меңьеллык тарих — нибары егерме тапкыр илле. Гомумән, төркиләр — карт халык, карт милләт, карт ыру. Тарихы да озын. Димәк, безнең тарих та шулай. Сүз сәнгате тарихы да шуңа тоташа. Бик ераккарак карап уйлансак, ерак шумерларга, бик-бик ерак Океан арты континентларына барып җитеп эридер әле ул...

Татар әдәбиятын системалы өйрәнү һәм аны халыкка җиткерү ыргымнары булмады түгел, булды, дөресрәге, булган. Үткән гасырда Мәрҗанинең олуг хезмәтләре шуңа дәлил. 20 нче елларда гыйлем дөньясында бер күтәрелеш — татар тарихын фәнни өйрәнү чоры булып алды. Сугыш алдыннан (чын тарих урынына фольклор чыганакларын — эпосларны идеаллаштыру төп принцип итеп куелса да) кайбер дастаннар чыгып калды. 60 нчы еллар башында янә беркадәр җанлылык сизелде. Миңа калса, илле-алтмыш ел эчендә әдәби мирасыбызны җиткерүдә төп хезмәтләр: «Идегәй» дастаны чыгу (берничә мәртәбә шулай ук әдәби әсәрләр рәвешендә дә), Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр әсәрләре басылу, соңрак чорның бөек шагыйрьләре Утыз Имәни, Кандалыйларның томлыклары дөнья күрү... Эшләнмәгән үк түгел, беркадәр эшләнгән, әмма аз.

Мәгълүм булганча, «Мәгариф» нәшрияты «Хәзинә» дигән гомуми исем белән татар әдәбиятының иң яхшы әсәрләрен туплаган унбиш китаптан торачак сериядән томлыклар чыгара башлады. «Сүз эчендә хикмәт бар» дип аталган беренче томлык моннан ике ел элек дөнья күргән иде инде. Олуг әдибебез Әмирхан ага Еникинең кереш сүзе белән (бу хезмәт аның соңгы язмаларыннан берсе булды бугай) ачылган ул томда халык иҗаты җәүһәрләре — әкиятләр, мифлар, дастаннар, мәкаль-табышмаклар, әйтемнәр, мәзәк һәм мәзәкчәләр, бәет-мөнәҗәтләр, җырлар бирелгән иде.

Менә, шөкер, бу сериянең икенче китабы да безнең кулларыбызда. Полиграфик яктан югары кимәлдә эшләнгән бу томлык дүрт бүлектән тора. «Тузга язганны ташка уйган» исемле беренчесендә Күлтәгин истәлегенә куелган таштагы Кече Язма һәм Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрек» (төрки телләр сүзлеге) тәкъдим ителсә, «Коръән нигезенә корылган әсәрләр» дигән икенче бүлеге Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә дастаны», Мәхмүд бине Галинең «Нәһҗел-фәрадис»е, Мәүла Колый «Хикмәтләр»е, Кол Шәриф һәм Мөхәммәдъяр шигырьләре, поэмаларыннан гыйбарәт. «Легендага нигезләнгән әсәрләр»дә исә (III бүлек) Котбның «Хөсрәү вә Ширин хикәяте», Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки», «Сөһәйл вә Гөлдерсен», Сайадиның «Таһир-Зөһрә» (Бабахан дастаны), дүртенче бүлектәге «Тормыш вакыйгалары сурәтләнгән әсәрләр» тулысынча «Идегәй» дастанын эченә ала. Кызыксынган кеше өчен никадәр хикмәт, никадәр байлык!

Язучы-галим А.Яхин тарафыннан һәр бүлек алдыннан бирелгән аңлатма-аннотация характерындагы кереш сүзләр дә тирән мәгънәле һәм урынлы. Ул теге яки бу чордагы әдәби үрнәкләр аша шул заманнарның рухын, яшәеш эволюциясенең характерлы якларын ачарга тырышкан, һәрхәлдә, үз халкын, тарихын зур итеп күрергә теләп, яратып язган. Әлеге кыска эссе-мәкаләләрнең тирән мәгънәсе исемнәреннән үк күренеп тора: «Осталык, батырлык, акыл», «Татулык», «Мәхәббәт һәм хикмәт», «Горурлык».

Ахыргы сүз шул: «Хәзинә» сериясендә чыга торган бу китап — ифрат та кирәк басма. Әсәрләрнең бүгенге укучы өчен аңлаешлы бирелүе дә максатка бик тә ярашлы. Тарихта эз калдырган әдәби ядкарьләрне укып, гыйбрәт алып, бәлки, безнең халык та беркадәр «тураеп куяр», милли үзаңы үсәр.

*1999, июнь*

**ЧЫН АҢЛАШУ — КИТАПЛАР АША**

*(Каләмдәшләремнең яңа әсәрләрен укыганда туган уйлар)*

* * *

Безнең шагыйрьләр дә Мефистофельләр белән бәхәсләшә алалар хәзер! Куанычлы хәл бу! Поэзиябезнең үсешенә бер дәлил бу!

«Соңгы сынау» һәм «Тынлык белән сөйләшү» поэмаларында сүз кешелекне гомер бакый борчыган зур фәлсәфи категорияләр турында бара: Яшәү — Үлем, Явызлык — Изгелек, Тарих — Мизгел, Үткән — Киләчәк һ.б. Алынган максат — тәэсири көчле һәм фәлсәфи тирәнлектә язуны таләп итә. Минемчә, И.Юзеев, шагыйрь буларак, өлешчә максатка ирешкән, күңелләрне җәлеп итәрлек поэмалар тудырган. Бу җәһәттән авторның «Соңгы сынау»ы аеруча отышлы. Әсәр легендар Муса Җәлилнең якты истәлегенә, эшенең бөеклегенә, үлеменең үлемсезлегенә күркәм бер һәйкәл. Муса турында безнең әдәбиятта шактый язылды һәм языла. И.Юзеевның «Соңгы сынау»ы алар арасында үзгә бер урын алып тора. Үзгәлек шунда — әсәрдә Мусаның тормышын, батырлыгын сөйләп чыгуга, статик тасвирлауга кайтып калынмый; әсәр — герой-шагыйрьнең илаһи батырлыгын илаһи мохиттә, илаһи халәттә күрсәтә. Шигърияттә мондый алым аңлашыла һәм аклана. Мусаның, мәкерлектә һәм явызлыкта шайтани куәткә ия булган Мефистофель белән бәхәсе барышында, укучы буларак, ирексездән күп нәрсә турында уйланасың: Кешелек үсеше тарихы, ил-халкың язмышы турында да, яшәү мәгънәсе һәм үз шәхесең турында да... Уйлата, фикерләтә поэма. Әсәрнең әсәр булуы, бәлки, шушы уйлатуында, фикерләтүендәдер инде... «Соңгы сынау»ны укып чыккач, күңелгә тагын шундый уй да килә — әйе, шагыйрь язган. Мефистофельләр фәлсәфәсен дә җиңә алырлык иманы булган Муса образын тудырган, бик әйбәт, ә бит, тирәнрәк уйлап карасаң, эш бер авторда гына түгел, әлбәттә, хикмәт — Муса кебек батырларны тудырган җирлектә, халыкта, аның бетмәс-төкәнмәс рухи байлыгында, сынмас ихтыярында. Синдә үзеннән-үзе горурлык хисе уяна.

Камиллекнең, фәлсәфәнең чиге юк. «Соңгы сынау»ны укыганда, укучы буларак, миндә поэманы тагын да яхшырак итеп күрәсе килү теләге дә тумады түгел. Бәлки, алар субъектив фикерләрдер. Шулай да...

Беренчедән: Тиранның максаты тәгаен анык түгел. Тиран: «Тик бер генә ялгыш ясадым мин. Ләкин аны соңрак аңладым. Җир йөзендә акыл ияләрен мин үтереп бетерә алмадым». Мөгаен, Тиранның эше гел үтерүдән генә тормыйдыр. Әгәр автор шулай дип расларга тели икән, ул очракта аның (Тиранның) фәлсәфәсен, платформасын дәлилләргә кирәк. Минемчә, Тиран югарыда әйтелгән рольдә булса, фәлсәфи концепциясен шулай декларатив яран салып йөрсә, ул Тиран булып өлгерә алмас иде, аны Җир күтәрмәс иде, кешеләр аны яшәтмәс иде. Шуңа да тираннар, куян тиресе ябынган бүре кебек, үзләренең чиркангыч эшләрен кешелекле фәлсәфә битлегенә яшеренеп эшлиләр. Гитлер да «мин дөньяны канга батырам» дип чыкмады, дөньяны түбән расалардан «чистартам» диде бугай... (Сүз уңаенда шуны да шәрехлик: Тиранда турыдан-туры Гитлер шәхесе күз алдында тотыла.)

Икенчедән: Мефистофельне Тиранның эш башкаручысы, хезмәтчесе, «шестеркасы» итеп кенә күрәсе килми. Тиран тиешле тирәнлектә һәм тиешле катлаулылыкта күрсәтелсә, бәлки, акланыр иде дә. Әсәрнең хәзерге хәлендә Мефистофельгә Тиранның хезмәтчесе булырга бер дә ихтыяҗ юк. Бәлки, Мусага — Кешелеккә каршы Көчне берничә рольгә бүлмәскәдер? Шушы вариантта калдырганда, ягъни бүлгән тәкъдирдә, Тиран белән Мефистофель арасындагы мөнәсәбәтне ачыкларга, бердәм концепциядә күрсәтергә, кыскасы, Явыз Көчнең туфрагы-тамыры белән, бөтен әшәкелеге белән күрсәтергә кирәк. Ни өчен?

Чөнки, бу очракта Мусаның эше, көрәше тагын да монументальрәк, бөегрәк булып күренәчәк.

*(Илдар Юзеев. «Соңгы сынау» китабы.*
*1969, гыйнвар)*

* * *

Нажар Нәҗми — илкүләм билгеле шагыйрь, бигрәк тә Идел-Урал регионында күпмеңләгән укучыларның тирән ихтирамын казанган шагыйрь. «Казан-Уфа дуслыгы» кебек канатлы тәгъбирләрне без һәркайсыбыз яхшы белеп, каныбыз белән тоеп яшәсәк тә, шуны да онытмыйк: дуслык — аерым шәхесләргә бәйле, аның нигезен аерым кешеләрнең иман-карашлары, яшәү рәвешләре, гражданлык вөҗданнары, иҗатлары тәшкил итә... Иҗат кешесенең төп миссияләренең берсе, ихтимал, милли һәм административ чикләнүләрне оныттырып, күңелләрне тоташтыру, рухи берләштерүдер әле ул. Әлбәттә, Изгелек һәм Матурлык нигезендә. Күңелләребезне әсир итеп, бердәм уртак халәткә китерерлек тылсымлы көчкә ия уфалы дусларыбыздан, җырда — Фәридә Кудашева булса, шигырьдә — Нажар ага Нәҗми дип беләм. Дөрес, әдипләр арасында тагын бүтәннәр дә, яшьләре яки дәрәҗәләре белән өлкәнрәкләре дә бар. Алары да безгә үзенчә якын. Ә Нажар Нәҗми якынлыгы ул аерым бер якынлык, ул тормышчан, ихтыяҗи, көндәлек якынлык. Бәйрәм чагында да үз итеп килеп җитәр ул, кайгылар килгәндә дә яныбызда булыр. Безгә аның белән, үзе әйтмешли, сөйкемле «шадра пәри» белән һәрчак рәхәт! Хәер, иңнәрне иңгә терәп дигәндәй, бергә-бергә булганда аның үзенә дә ямансу түгел шикелле.

Тиздән Нажар агага 70 тула икән. Бик үк ышанасы килмәсә дә — факт. Шул уңай белән кулъязма юллаган. Сайлап алырга иркен булсын диптер инде, шигырьләрне калын папкага салып, күп итеп җибәргән, гомум күләме унбиш табаклап бардыр. Төрле еллар, төрле күләмле һәм төрле рухтагы шигырьләр, үзенә күрә сайланма характердагы тупланма. Һәрхәлдә, авторны, шагыйрь буларак, үз йөзен чагылдыра, күрсәтә алырлык әсәрләр. Укып чыккач ук та туган кайбер гомуми фикерләр, тәэсирләр:

— гомеренә тигән чорда әллә никадәр тарихи катаклизмнар булуына карамастан, Н.Нәҗми, үз асылын саклаган хәлдә, үз чорының лаеклы улы булып, үз заманасының шактый ук гадел елъязмачысы, ир-егет булып кала алган икән! Иҗат кредосы белән дә, тематик диапазоны белән дә, максатчанлыгы белән дә;

— ихласлык — шагыйрьлекне билгеләүче төп сыйфатларының берсе. Нажар Нәҗми — гаҗәеп дәрәҗәдә ихлас, садә шагыйрь. Ул шушы сыйфаты белән халык күңеленә юл ярды да инде;

— ул — чын интернациональ шагыйрь. Бу яктан аннан бик күп каләм ияләренә өйрәнергә була. Күрәсең, уртак ватан язмышы, сугыш фаҗигаләре, төрле халык вәкилләре белән аралашып яшәү, аларның тарихларын яхшы белү һәм тагын бүтән гыйбрәтле хәлләр кичерү — аны чын мәгънәсендә халыклар дуслыгы җырчысы иткән. Бу җәһәттән аның бүтән халыклар алдында татар халкының олы шәхесләрен пропагандалауга, культурасының һәм теленең абруен күтәрүдә дә хезмәте һәм батырлыгы зур. Без, йомыкыйлыктанмы яки бүтән сәбәпләр аркасындамы, әйтергә җөрьәт итмәгән кыю-кыю фикерләрне ул бөтен ил алдында оран салып әйтә алды. «Татар теле» шигыре генә ни тора! Рәхмәт аңа!

Нажар Нәҗми — җырчы шагыйрь. Аның, һич югында, берәр җырын гына булса да җырламаган яки үзалдына шыңшып булса да йөрмәгән кеше юктыр безнең якларда. Демократик рухлы шагыйрьнең җыр кебек демократик жанрга мөрәҗәгать итүе бик табигый. Ул җырлар безнең күңелләрне баетты: кирәк чакта йомшартты, кирәк чакта ныгытты, яшәргә өндәде, дөньялыкта кеше булып калырга чакырды.

Китапны укыган чакта кичергән тагын бүтән матур уйлар да булмады түгел. Югарыда әйтелгәннәре дә шагыйрь иҗатының төп чалымнарын тасвирлый шикелле.

Тагын шунысын да өстәп әйтәсем килә: әтиләр яшендәге (минем әти дә аның кебек 1918 елгы) өлкән әдипнең кулъязмасын мин коллегам-каләмдәшем әсәрләре дип тә укыдым бит әле. Ни әйтсәң дә, без ике чор кешеләре — тормышны, аның чагылышы булган сәнгатьне, бу очракта поэзияне, аңлауда аерымлыклар булуы да бик табигый. Уку процессында шагыйрь белән бәхәсләшәсе, киңәшләшәсе килгән моментлар да булмады түгел. Поэмаларын укыганда туган теләк-фикерләрне язып үтсәм, олуг шагыйрь үпкәләмәс дип уйлыйм.

«Иблис» поэмасы безгә инде таныш. «Казан утлары»нда чыккан вариантында да, китапта да укыдык. Гомумән, көчле әсәр. Шулай да бер бәхәсле уй: Әхмәтнең улы Мәхмүтнең җанын фида кылырлык дәрәҗәдә әти-әнисенең туган җиренә ашкынуы акланамы? Һәр җан өчен үзе туган җир

газиздер бит. Авторча, аның кендеге киселгән җир ул кадәр үк әһәмиятле түгел, ә күз күрмәгән (Мәхмүт өчен) як — җәннәт иле... Каян бу хис? Әнисенең җырлары ашамы? Шулайдыр. Аның үзе туган җирдә туган үз җыры юк микәнни? Кулны бөергә куеп бәхәсләшмим, шулай да бу моментның тормышчан чынлыгына шикләнәм. «Татар каны» — интернациональ рухлы әсәр (поэма, гомумән, кан мотивына корылган). Зур тәрбияви мәгънәгә ия. Язылышы да тыгыз, вакыйгалар бик динамик. Романнарга сыешлы вакыйга. Фаҗигаләр кичергән, сугышлар (сугыш үзе гайре табигый нәрсә, антитормыш) күргән кеше психологиясеннән караганда барысы да үз урынында кебек, геройларның кылганнары аклана. Шулай да Иван, бөтен ил бетереп, һәлак булган Зифаның кызын (Зифа донор сыйфатында Иванга кан биргән) эзләп йөрер микән? Бүгенге прагматик укучы моңа ышанырмы? Ул авторның теләге белән генә шулай йөрми микән? Дөрес, Иван аны таба алмый шикелле. Автор үзе дә әйтеп куя: «Син тапмасаң, үзем табармын». Бу фикерне дә тәкрарлап түгел, уйланыр өчен әйтүем. Гомумән, олуг Әдипкә рәхмәт хисләрен җиткерәм.

*(Наҗар Нәҗми. «Сиңа барам» китабы. 1987)*

* * *

Соңгы елларда Р. Мингалим үзен балалар һәм олылар шигъриятендә актив эшләп килүче үзенчәлекле шагыйрь итеп танытты. Аның 1971 елда чыккан «Алкын су» китабына әдәби җәмәгатьчелек югары бәя биргән иде. Һәм, ниһаять, шагыйрьнең яңа шигырьләр китабы.Ниләр илтә соң шагыйрь үзенең укучыларына?

Китапка җыенысы иллеләп шигырь һәм «Күз карасы» исемле поэма тупланган. Автор шигырьләрендә дә югары профессиональ дәрәҗәсендә, үз позициясенә тугры булып калган: сүзгә саранлык, фикри тыгызлык, тормышчан кырыслык, һәм, иң мөһиме — тормыш, кешеләр, яшәеш турындагы уйларын ихлас уртаклашу. Шагыйрь шигырьне бизәк итеп кенә күрми, ә аны тормышны тагын да матурайтыр, яхшыртыр өчен корал итеп карый.

Кыска гомердә үзеңне
Син төшенергә өлгер;
Һәм урын табарга өлгер,
Нәкъ синең урының булсын.
Булган кадәр урыныңда
Халкыңа тугры бул син.

Китаптагы шигырьләрне ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин: лирик шигырьләр һәм лирик-публицистик шигырьләр. Һәр ике төркемдә дә уңышлы шигырьләр байтак. «Дөнья каршысында», «Бар да барып җитәрләр», «Җай», «Әллә инде», «Болай түгел идем дә бит», «Күл өстенә таң җәелде», «Олыгайгач», «Без игезләр түгел», «Шундый бер нокта», «Яшь шагыйрьгә», «Очраштык та», «Йөгереп китсәм», «Бу авылда», «Өйләнеп кайтуың бар», «Еракташы зәңгәр офыгым», «Сүндер утны», «Чакыр аны», «Нарасый бу», «Сызгырып килер пулясы», «Көнчегә», «Киләләр»... Шигырьләрне укып чыккач, шундый нәтиҗәгә киләсең: Р. Мингалим татар шигъриятенең иң әүвәл фикерне алга сөрә торган юнәлешендә (рассудочная поэзия) шактый ук кызыклы шигырьләр иҗат иткән икән.

Инде китапның яртысы чамасын тәшкил иткән «Күз карасы» поэмасы турында берничә сүз. Бу әсәр вакытлы матбугатта басылып чыкты һәм уңай яктан телгә алынды инде. Мин дә бу хуплауга кушылам. Ни өчен? Беренчедән, хәзергә зур төзелеш турында язылган бу әсәр — беренче зур шигъри әсәрләрнең, тәүге карлыгачларның берсе; икенчедән, автор, бу гигант төзелешнең мәгънәсен яшәешебезнең иң мөһим проблемалары берлегендә карый, үзенчә хөкем йөртә, эшнең асылын ачарга омтыла, һәм, әйтергә кирәк, күп очракта поэтик дәлилли, ышандыра; өченчедән, авторның нияте изге — хезмәт кешеләрен олылау, чын кешеләрне зурлау.

Миңа хәзер
Шигырьне
Кирпеч, балчык, ком итәргә түгел,
Комны, балчыкны, кирпечне
Шигырь итәргә кирәк.
Цехларны, машиналарны
Шигырь итәргә кирәк.

* * *

Тик аның яшәр еллары

Ярсулары, язлары —
Бүгенге безнең максатка
Таянып тора бары.
Ә максат — корал була ул
Хискә әйләнү белән.
Ул коралдан куәтлерәк
Коралның югын беләм.

* * *

Җир өстендә безнең туган йортлар,
Җирдә эткәйләрнең кабере.
Күз карасы кебек түгәрәк җир,
Күз карасы кебек кадерле...

Авторның нияте — зурдан, сүзе — олыдан. Ул үз буынының бүгенге тормыштагы урынын билгеләргә тели, тоткан юлларының дөреслеген, күргән маякларының яктылыгын гуманистик күзлектән чыгып бәһаләргә омтыла.

Безнең —
җимерүчегә
үзебезнең караш,
үзебезнең
үзгә —
ачуыбыз бар.
.............................
Чаллы җимерелмәскә салына!

Чаллы җимерелмәскә салына! Менә поэманың төп лейтмотивы.

* * *

Рөстәм Мингалим татар балалар поэзиясендә әйдәп баручы көчләрнең берсенә әверелеп бара хәзер. Үткән ел чыккан «Бәхетле исем» китабын әдәби җәмәгатьчелек хаклы рәвештә елның уңышлы китапларының берсе дип таныды. «Исәнме, эткәй» китабы өр-яңа шигырьләрдән тора. Күбесе 1977 елны язылган. Җыенысы — уртача озынлыктагы утызлап шигырь. Китап белән танышу процессында иң әүвәл шуңа игътибар итәсең: сурәтләү рәвешләре һәм хикәяләү алымнары буенча мондый характердагы шигырьләр безнең балалар поэзиясендә юк иде шикелле әле. Бу нәрсә авторның ачык индивидуаль йөзе турында сөйли. Икенче яктан, күңелгә шундый сорау да туа: бу хәл әйбәтме, начармы? Әйбәт ягы шунда — мондый шигырьләр нәни укучыларга дөньяның, яшәешнең яңа буяуларын, яңа төсмерләрен, яңа аһәңнәрен алып килә. Шулай ук дөньяның катлаулы, серле икәненә ишарәли алар, дөресрәге, төшендерәләр, танып белү процессында активрак катнашырга әйдиләр, уй ялкаулыгын күпмедер «яза» төшәләр. Мәсьәләнең икенче ягы: монда чама хисе югалмаска тиеш. Яңа алымнар моңа кадәр килгән традицияләрнең ниндидер бер дәвамына органик рәвештә тоташкан булырга тиеш. Кискен аерылганда, укучының аңлау, ярату урынына фәкать сәерсенеп кенә куюы бар.

*(Рөстәм Мингалим. «Алкын су» — 1971, «Исәнме, эткәй» — 1978 — китаплары.)*

* * *

Төп эш шигърияткә бәйле булгач, шигырьләр, шөкер, байтак укыла. Көн саен шигырьләр, шигырьләр... Күп кешеле урамда кайчак йөз-битләргә битараф була башлыйсың, хәтта туясың. Шулай ваемсыз барганда, кинәт бер йөз очрый, бер караш! Юк, ул чибәр зат карашы гына булмаска мөмкин. Ул, бәлки, бөркет карашлы бер өлкән кешедер... Бу көтелмәгән очрашудан син баеисың, яшәвең мәгънәлерәк булып китә. Зиннур Мансуровның бу китабын уку миндә шундыйрак хисләр уятты. Яхшы шигырьләр язган, шәп!

Шуны билгеләп үтәсе килә: Зиннурда Ходай биргән поэтик ТОЕМ бар. Мин бу төшенчәгә киңрәк мәгънә салып әйтәм; ул — бүтәннәр күрә алмаганны күрә алу да, ул — сизенү дә, ул — предметны яки күренешне үзгә бер призмада карау да, ул — тылсымга, сергә күпмедер ачкыч таба алу да...

Икенчедән, Зиннур Мансуровта яхшы мәгънәдәге ГАМЬ бар. Гамьле, уйлы кеше бушка сүз очырмый. Бу — безнең эштә иң кирәкле сыйфатларның берсе. Ахыр чиктә язучының гражданлык

йөзе дә шул була бит инде. Шигырьләренең мәгънәви тулылыгы аның шигырьләренең тематикасында ачык чагыла. (Китап шартлы рәвештә өч бүлектән тора. Беренче һәм икенче бүлекләрдә тормыш, бүгенге һәм киләчәк, иман ныклыгы, намуслылык, бурыч, рухи ныклык һәм башка шундый зур категория-төшенчәләр турындагы шигырьләр тупланган, ә өченче бүлектә — урыны-урыны белән бик бәхетле, вакыты-вакыты белән якты сагышлы мәхәббәт шигырьләре).

Өченчедән, авторда ЧАМА хисен нечкә тоя алу һәм образлы, төгәл, халыкчан ТЕЛ бар. Шигырьләр — кыска, җыйнак. Уңышлы яки уңышсызрак юллар булырга мөмкин. Әмма акланылмаган юллар очратмадым.

* * *
Инеш тулып ак болытлар ага...

* * *
Һавадан кош моңы иңсә дә,
тузганак тоталмый үз таҗын...

* * *
Бер тамырдан үскән куш каен сез,
икегез дә —
минем язмышым.

* * *
Авыр булса, йөрәгемә аусын
Казанымның Сөембикәсе!

* * *
Ачуланма, әнкәй,
кешеләргә
шигырь итеп укыйм хатыңны...

* * *
Җирдә кабат күрешмәсәк,
очрашырбыз җырларда...

Минемчә, әле китерелгән юллар олуг, серле шигърият турында сөйли. Аларны махсус сайлап китермәдем. Образлы тәгъбирне һәр шигырьдә табарга була.

Китапка кереш сүз язган Әхсән Баянов беренче сүзләрен «Шагыйрьгә ышаныч» дип башлый. Әйе, Зиннур Мансуров иҗаты әдәби җәмәгатьчелектә аның киләчәгенә зур ышаныч уята.

Зиннур Мансуров — әдәбиятыбызга соңгы елларда килгән сәләтле һәм иң төпле каләм ияләреннән берсе. Ул — эстетик принципларын тәгаен ачыклаган, сайлаган эшенең зурлыгын һәм җаваплылыгын нык тойган әдип, сынау һәм сыналу баскычларын үтеп, инде иҗаты белән үз иманын раслау стадиясенә күчкән каләмдәшебез. Үтелгән тормыш һәм хезмәт юлы да (ул — студент, солдат, журналист), поэзиядә кылынган гамәл дә һәм аның бу китабы да, аның гражданин һәм шагыйрь буларак өлгергәнлеген раслый. З. Мансуровны әдип дип атавым җөмлә эченә очраклы кергән төшенчә түгел. Ул — күпкырлылыкка омтылган иҗатчы. Ул балалар өчен дә, олылар өчен дә уңышлы яза. Поэзиянең нечкә серләренә төшенү белән бергә, сәнгатьнең бүтән төрләре белән дә нык кызыксына. Аның сәнгать кешеләре — рәссамнар, композиторлар, артистлар, архитекторлар турында дистәләгән мәкаләләре бар. Шунысы характерлы: ул — алар хезмәтенең үзенчәлекләрен ачу белән бергә, фактны яки күренешне гомумкультурабыз фонында карап, тарихи перспективада күрә белә. Гомумән, аның мәкаләләре — фикри яктан дәлилле, теоретик яктан кызыклы, аерым очракларда бәхәсле булулары белән хәтердә кала. «Йөрәк уйлый да белсен», «Сүзне олылау» һ.б. мәкаләләре әнә шундыйлардан. Фикерлелек һәм күпкырлылык — чын әдипләргә хас сыйфатлар. Зиннурга да хас алар. Бездә яхшы шигырь язучы иптәшләр аз түгел, ә әдип сыйфатына ияләре, кызганычка каршы, берәм-сәрәм генә.

Зиннур Мансуров шигърияте — уйлы-гамьле шигърият, нәфис шигърият. Акланмаган озынлык яки техник эшләнеше ягыннан кытыршылыклар аның шигырьләрендә юк диярлек. Шагыйрь һәр

фикерне яки күзаллаган сурәтне үзенә кулай булырга мөмкин булган бердәнбер отышлы формаларда бирергә омтыла (халык иҗатындагы гаять отышлы, инде онытылып бара торган мәкаль-тәгъбирләрне дә кертеп) һәм, әйтергә кирәк, күп очракларда ул аңа ирешә дә. Мәгълүм хакыйкать: олы һәм кешелекле фикере булган шигърият, кагыйдә буларак, башка халык вәкилләре өчен дә үз һәм якын. З.Мансуров шигырьләре бүтән телләрдә дә табигый яңгырый. Аның кайбер әсәрләре рус телендә үзәк матбугатта да уңай бәя алды инде.

*(Зиннур Мансуров. «Кул бирәм» китабы. 1979)*

* * *

Китапны укыганда башка килгән төп уйлар шул: татарча тәрҗемәдә Уитмен ничек яңгырый, бөек шагыйрьнең фикерләре безнең телдә югалып калмыймы, табигыймы, поэзия сөючеләр ничек кабул итәр, һәм ниһаять, бу китапны чыгару бүген ни дәрәҗәдә актуаль һәм кирәк? Сүзне соңгысыннан башлыйк. Әлбәттә, безнең шартларда һәм нәшриятның бүгенге хәлендә теләсә нинди телдән, теләсә нинди язучы яки шагыйрьне теләсә никадәр чыгарып та булмый, чөнки мөмкинлекләр чикле. Соңгы дүрт-биш елда шигырь тәрҗемәсе буенча нинди әсәрләр чыкты соң дигәндә, әллә ни мактана алмыйбыз. (Ленин юбилее уңае белән «Дуслык букеты» сериясендә чыккан китаплар күләм ягыннан зур күпчелекне тәшкил итсәләр дә, аларның күбесе художество эшләнеше (тәрҗемәчеләр ягыннан) йомшак булу сәбәпле, ни киң катлам укучыларны, ни китап сату оешмаларын сөендерә алмады.) XX гасырның дөньякүләм зур шагыйрьләре Н.Хикмәттән тыш (бусы 50 нче елларда бер бәләкәй китап булып чыкты), П.Неруда, Г.Лорка Аполлинерларның безнең телдә аерым китап булып чыкканнары юк. Шулай ук, япон һәм шәрык поэзиясенең (классикасы һәм бүгенгесе) яхшы үрнәкләре безнең телебездә юк диярлек. Инде, ниһаять, бөек шагыйрьләрнең берсе Уитмен чыккан икән, бу сөенечле вакыйга. Ни өчен нәкъ менә Уитмен? Чөнки — гаҗәп хәл — Уитмен, гәрчә шигырьләре моннан йөз илле еллар элек язылган булса да, ул — нәкъ бүгенге көн шагыйрьләрнең берсе. Кешелек тарихында, әлбәттә, бөек шагыйрьләр байтак. Ләкин күбесе, иҗатлары теге яки бу ягы белән бүгенгегә тоташкан булса да, беренче чиратта, фәлән дәвер, фәлән чор шагыйрьләре булып кала. Ә Уитмен исә һаман өр-яңа, әйтерсең лә ул вакытка буйсынмый торган рух. Бөекләрнең әсәрләре гадәттә ләззәтләндерә, сокландыра, ә Уитмен сискәндерә, ияртә, фикердәше булырга өнди. Шуңа да, бүгенге заман шагыйрьләренә аның йогынтысы зур. Хикмәт, күрәсең, Уитменның мәңгелек проблемалар, мәңгелек темалар турында язуындадыр, космик масштабта фикерләвендәдер, кыю поэтик ачышларындадыр. Тагын бер мөһим момент: Уитмен бөек оптимист. Хәтта дөньяның, тормышның иң күңелсез, иң алама яклары турында сөйләгәндә дә ул акыллы, шат һәм киң күңелле, Хозыр Ильяс кебек тынычландыручан. Ул караңгыда да яктылык, үлемдә дә яшәү күрә. Әдәбиятта мондый ирләрчә оптимизм бик кирәк нәрсә. Ахыр чиктә, яшәүне раслау, Әмирхан Еники әйткәнчә, «яшәргә котырту» — әдәбият өчен иң кирәк сыйфатлардан берсе. Шуларны искә алганда, Уитмен шигырьләренең татар телендә чыгуы бик тә вакытлы. (Сүз уңаенда бер факт: матбугатта язылганча, күптән түгел чуаш шагыйре Г.Айги берничә дистә француз шагыйрен тәрҗемә итеп, үзенә күрә бүгенге француз поэзиясе антологиясе төзеп, чуаш телендә чыгарып, Франциядәге иң зур әдәби премияләрнең берсенә лаек булды. Бу очракта тәрҗемәләү факты халыкара әдәби вакыйгага әверелде. Тотынгач, чыннан да, зурдан тотынырга кирәк, иҗтимагый максат куеп тотынырга кирәк шул!)

Рухыма якын шагыйрь буларак, китапны кат-кат укып чыктым. Кулымда булган «У.Уитмен. Избранное» («Худ. литература», М., 1954), «Мой Уитмен» (К.Чуковский. «Прогресс», М., 1966), «Жизнь и творчество Уитмена» (М.Мендельсон. «Наука», М., 1969) китапларындагы русча шигырьләрне татарчадагысы белән сүзгә-сүз диярлек чагыштырып чыктым. Кызганычка каршы, инглиз телен юньләп белмәү сәбәпле, оригинал белән чагыштырып булмады, тик кайбер шигырьләрнең яңгырашларын һәм композицион контурларын шәйли алдым. Һәрхәлдә, инглиз телендәгесе белән русчасы арасында да аермалар байтак күренә. Әмма юлларның урнаштырылу ягыннан татарча текст күп очракта инглиздәге оригиналга якынрак. Гомумән, тәрҗемәләр татарча матур яңгырый. Поэзия белән, аның атрибутлары — сурәтләү чаралары (инверсия, кабатлаулар, параллелизм, поэтик синтагмаларның ритмик чиратлашуы һ. б.) белән хәбәрдар кеше өчен тәрҗемәләрнең күбесе сәнгатьчә эшләнгәнен тиз аңлар. Кыска күләмле шигырьләрнең тәрҗемәләре аеруча яхшы тәэсир калдыра. Мәсәлән: «Җырым бер минем», «Бер җырчы кызга», «Бервакыт мин үткән идем», «Төшемә бер шәһәр керде», «Авыл күренеше», «Кара янган дала малае син» һ.б. Озын шигырьләрдән президент Линкольн истәлеге итеп язылган «Ишек алдымда, йортым каршында, бу язда сирень чәчәк атканда» яхшы һәм төгәл итеп тәрҗемәләнгән. Гомумән алганда, Уитмен татарча да көчле яңгырый ала икән!

Әлбәттә, шигырь тәрҗемәсендә вакыйга булырлык мондый зур хезмәттә без шәйләп бетермәгән җитешсезлекләр дә булырга мөмкин. Аларын алга таба белгечләр һәм укучылар әйтер. Без булганына бәя бирик: тәрҗемәче буларак, Марс Шабаев үзенең төп вазифасын намус белән башкарган, үзенең күңел байлыгын кызганмыйча, бу хезмәткә берничә ел иҗат гомерен салган. Ихтимал, бу китап турында бәхәсләр дә булыр әле.

Хәер, Уитмен турында йөз елдан артык байтак илләрнең әдәби даирәләрендә бәхәсләшәләр. Һәрхәлдә, шунысы ачык: бу тәрҗемә китабы күп кенә шагыйрьләр өчен, беренче чиратта, яшь буын каләм ияләре өчен, бер гыйбрәтле мәктәп булачак. Уитмен безнең күзгә күренеп үсә торган поэзиябезнең офыгын тагын да киңәйтәчәк.

*(У.Уитмен. «Үлән яфраклары».*
*Марс Шабаев тәрҗемәсе. 1975)*

* * *

Әдәби сәләте һәм фантазиясе булган кеше, теләгәндә, берәр яки берничә яхшы шигырь, йә булмаса берничә яхшы хикәя яза алса да, аның теләгәндә дә яхшы очерк яза алмавы мөмкин. Чөнки очерк язу өчен табигый сәләт һәм осталык белән бергә, язарга алынган объектны энәсеннән җебенә кадәр белү, аны, ягъни тормыш материалын, тарихи перспектив үсештә күрү, икенче төрле әйткәндә, тикшеренүче булу сорала. Кыскасы, очерк язу — авыр хезмәт. Шуңа күрә дә без, еш кына яхшы очеркларның сирәк күренүе турында ачынып-ачынып сөйлибез дә.

Миңа калса, Рахмай Хисмәтуллин — шушы жанрда актив һәм нәтиҗәле эшләп килүче аз санлы иптәшләребезнең берсе. Матбугат һәм әдәбият елъязмасында аның исеме инде ике дистә елдан артык даими күренеп килә. «Салават күпере» дигән үзенең беренче очерклар китабын чыгарганга да 15 еллап гомер узды.

Бүгенге көндә Рахмай Хисмәтуллинның дөньяга чыккан өч китабы бар. Моннан тыш аның китапларга кермәгән, вакытлы матбугатта басылган яки басылмаган дистә-дистә табак әдәби әсәрләре һәм мәкаләләре бар. Кемнәр турында һәм алар турында ничек яза соң автор? Китапларның төп каһарманнары — бүгенге кешеләр: эшче яшьләр, инженер-техник хезмәткәрләр, галимнәр, врачлар, хезмәт ветераннары, колхозчы-игенчеләр. Тикмәгә генә автор бер китабына язган кереш сүзендә болай дип язмагандыр: «Бу очеркларда чагылган үзеңнең сыйфатларыңа күз сал, замандаш!» Рахмай Хисмәтуллин — чын мәгънәсендә үз замандашлары җырчысы. Ул — бүгенге замандашыбызның киләчәк буыннар өлге итеп алырлык күркәм якларын тасвирларга тырыша.

Очеркта документаль төгәллек һәм тормыш дөреслеге сакланырга тиеш. Юкса әле арабызда яшәп иҗат иткән, әйтик, илнең зур төзелешләрен җитәкләгән Социалистик Хезмәт Герое Е.Королев, Түбән Каманың атаклы хирургы Ф.Хәйбуллин, монтажчы Ә.Дәминов, колхоз председателе З.Закиров, халык театры режиссеры Н. Нуретдинов кебек реаль кешеләр турында, фәкать тормыш дөреслегенә турылыклы булып, объектив бәя бирә алу дәрәҗәсенә күтәрелә алып кына язарга мөмкиндер.

Рахмай Хисмәтуллин — романтик пафоска, эмоционал сөйләмгә бай автор. Илсөяр табигатьле, халык бәхете өчен көрәшкә әйдәүче шәхес ул. Ул — уйлана, борчыла, чагыштыра, сөенә, әрни, көлә, чакыра... Газиз туган илнең игелекле уллары булырга чакыра ул. «Дан сиңа, Туган җирем!» нәсере белән башланган «Күкрәү авазлары» дигән очерклар китабы — тулысы белән Актаныш яклары һәм шул якның кешеләре турында. Бу китапта Рахмай Хисмәтуллинны әдип каләменә ия язучы итеп танып була. Соңрак «Туган як» төшенчәсе тагын да киңәя төшә: ул инде Татарстанның бүтән төбәкләре дә — Чаллы кырлары, Түбән Кама корылмалары...

Рахмай Хисмәтуллин — шагыйрь кеше. Аның матур-матур шигырьләре әледән-әле матбугат битләрендә күренеп тора. Менә аның әле күптән түгел генә «Социалистик Татарстан» газетасында басылган бер шигыре.

## БИШ КАЙГЫМ

Әллә бу биш чатлы йолдыз
Минем йөрәгем микән?

Миндә яши көне-төне биш кайгы,
Биш кайгыдан януларым ешайды.
Бу биш кайгым йолдыз кебек биш чатлы,
Биш чаты да җанга якын дәү атлы:

Үзем, гаиләм, халкым, илем, Җир шарым —
Бишесен дә күмсен иде нур бары.
Гаҗәп түгел үзем булсам бер чаты,
Чөнки күңелем биш кайгымның уртасы.
Бомба түгел, пуля гына атылсын,
Шәһәр түгел, бер йорт кына ватылсын,
Әрни башлый йөрәктәге биш зарым:
Үзем, гаиләм, халкым, илем, Җир шарым!..

Рахмай Хисмәтуллинны актив җәмәгать эшлеклесе дип тә беләбез. Татарстанның, гомумән, илнең нефтехимия үзәге булган Түбән Камада үткәрелгән һәр әдәби-музыкаль кичә, теге яки бу дәрәҗәдә Р.Хисмәтуллин катнашуыннан башка узмый. Ул озак еллар буе шәһәрнең «Кама таңнары» әдәби берләшмәсенең җитәкчесе булып эшләде, яшь әдәби талантларның үсүенә эшлекле ярдәм итте. Р.Хисмәтуллинның дөньяга чыккан проза һәм драматургия буенча да җитди хезмәтләре бар.

*(Рахмай Хисмәтуллин. «Салават күпере», «Күкрәү авазлары» исемле очерк китаплары. 1979)*

* * *

Газинур Моратов — соңгы биш-алты ел эчендә поэзиябезгә килгән иң өметле яшьләребезнең берсе. Аның үткән ел чыккан «Җир хәтере» дигән китабы моңа ачык дәлил. Күңеле шигырьгә ябык булмаган кешеләр өчен ул — шактый ук гыйбрәтле китап. Бәйләнер өчен сәбәп булырлык кайбер строфаларга карамастан, ул китаптагы шигырьләр аша күңеле бай, йөрәге кайнар шагыйрьне тоярга була. Минемчә, шагыйрь үз миссиясен аңлап иҗат итә. Шулай да бу дөньяда, бигрәк тә безнең заманда, Тукай әйтмешли, «шигырь бүтән дә, дөньяны әйләндерә торган чыгыр бүтән...» Әле яңарак шигырь язырга алынган кешеләрнең, шул исәптән Газинурның да, бу ачы дөреслекне һәрдаим истә тотуын теләп киңәш итү артык булмастыр. Хәер, заманның шигырь өчен егылып китәргә тормавын ул үзе дә яхшы ук шәйли шикелле. Көндәлек матбугатта әледән-әле күренеп торган әдәби-публицистик мәкаләләре шул хакта сөйли.

Газинурның нинди төр шигырьләре күңеленә хуш дип сорасалар, «егет булып, ир-егет булып язган шигырьләре» дип әйтер идем. Әдәбиятчылар терминологиясе белән әйтсәк, фәлсәфи-публицистик, фәлсәфи-гражданлык шигырьләре. Алар әлеге әйтелгән китапның «Оран», «Фидакярләр» бүлекләрендә шактый. Халык тарихы, каршылыклы бүгенге, һәм әлегә бик үк ачык булмаган киләчәк хәлләре кызыксындыра һәм борчый аны... Дөрес, кайбер шигырьләрендә моңарчы поэзиябездә булган мотивлар, калыплар, тәгъбирләр дә очраштыргалый. Аларны өйрәнү чорының кимчелекләре дип кабул итик. Газинурның үз поэтик байлыгы да җитәрлек. Юкса ул үзенең бер шигырендә «...Үзебезне тапкач кына үзебез булып калабыз» дип, тикмәгә генә язмагандыр.

Киләсе елга Г. Моратовның «Мин дөньяны тыңлыйм» дип исемләнгән яңа китабы чыгарга тиеш. Ул китапка кергән байтак шигырьләр белән мин таныш. Алар шагыйрьнең зур киләчәгенә ышанычны тагын да ныгыталар. Хәзер Газинур егерме җидесе белән, Тукай яше белән бара. Яшәлгән гомере бик аз да түгел, заманына карап, әле күп тә түгел. Ышанийк һәм кул сузыйк егеткә! Вакытында күрсәтелгән ышаныч еш кына мул җимешләр бирә.

*1969—1987*

## ЯНӘ МӘХӘББӘТНАМӘ

«Мәхәббәт китабы... Мәхәббәтнамә, имеш. Тәвәккәллегеңме бу, әллә тилелегеңме? Мәхәббәт кадәр Мәхәббәт турында бит! Кешелек яратылганнан бирле исәбе-саны булмаган бихисап адәмнәр кичергән илаһи сөю тарихына, гыйшык утында янударын җанына-тәненә сыйдыра алмаган күпме нечкә күңеллеләрнең Сүздә, Авазда, Төстә, Ташта иҗат итеп калдырган бөек хәзинәсенә ни генә өсти алырсың икән, бичара!» дияр кемдер. Алай уйлаучы да, шиксез, минем кебек үк хаклыдыр. Моннан кырык еллап элек язганмын: «Яздым Мәхәббәт турында, янып-көеп мин дә бер. Җир өчен миллиардтан бер, минем өчен — бердәнбер. Дөньяның чын кадерен тик сөйгәндә беләсең. Яздым Мәхәббәт турында, — яшим әле күрәмсең!» Әйе, һәркем үзенчә хаклы.

Мәхәббәтнең мәгънәсен бүтәннәргә аңлатырга тырышу мәгънәсезлек үк булмаса да, ихтимал, бик үк акыллы гамәл дә түгелдер. Бу җәһәттән әйтик, Данте мондыйрак сүз әйткән: «Мәхәббәт йөртә Кояшны, яктырта йолдызларны!» Ай-һай, алай ук микән?! Әмма ничәмә гасыр буе ничәмә буыннар яратып, теләп тәкрарлый бит шушы тәгъбирне. Димәк, ышанасылары килә шуңа! Шәрыкның икенче бер мәшһүре, Мәхәббәттән исереп, «бер миңеңә алыштырам Сәмәрканд, Бохараны!» дигәнме әле? Бу диванасы бигрәк тә юмарт булып чыга түгелме соң? Ә айлы төннәрдә

күктән йолдызлар чүпләп, сөйгәннәре алдына сибүчеләр, аларны учларына өеп салучыларның исәбе-чуты юк... Күрәсез, бик серле һәм хәтәр нәрсә икән бит бу Мәхәббәт дигәннәре! Серлеме, сихриме, илаһимы — монысы бер хәл, ә менә көче, кодрәте — монысы инде бәхәссез! Мәхәббәттә янган кеше могҗизалар тудыра, бөек эшләр башкара. Кем белә, бу якты дөньяга без, бәлки, шушы Бөек Мәхәббәт хисен тояр өчен генә киләбездер әле!

Мәхәббәт ул үзе шулкадәр абстракт төшенчә, әмма шул ук вакытта үтә конкрет, үтә индивидуаль, интим нәрсә дә. Шарламадагы тамчылар агышы бер-берсен кабатламаган шикелле, Мәхәббәт тә кабатлана алмый. Ләйлә белән Мәҗнүн, Ромео белән Джульетта, Таһир белән Зөһрә, Галиябану белән Хәлилләрнең, язмышларында уртаклыклар күренсә дә, гыйшкый янулары гел бердәй булгандыр дип уйламыйм мин. Безнең заманга да кагыла бу. Мисалга, бүгенге яшьләрнең мәхәббәттәге уй-кичерешләре, хис-тойгылары төп гомерләрен үткән гасырда кичкән безнең буынныкыннан шактый үзгәрәк бугай. Без — сугыш чоры, сугыштан соң формалашкан буын, нигездә, хыял һәм китап балалары. Үсмер чактагы хыялның иң бөеге, әлбәттә, Мәхәббәт булды. Порнография, секс, эротика, наркотик кебек төшенчәләрнең исемен дә белмәгән бәхетле чак! «Тыелган җимеш» татлы инстинктта гына. Мөгаен, бәхетебездер — без Мәхәббәтнең табигый асылына табигый юл белән, озын-озак хыялый урау юл белән килдек (һәм соңармадык та шикелле!), һай, ул малай чактагы «ис керә» башлаган айлы кичләр, сәгадәтле сәгатьләр! Күз алдына китерегез: кыш, кич, буран... ә син күрше урамдагы «сөйгән яр»ың тәрәз каршына бата-чума килеп, пыяладагы бозны эретәсең, борыннан акса ага, әмма Аны (шәүләсен!) янә бер күреп кайтасың. Сагынылган, көндез мәктәптә күреп туелмаган икән!.. Әй, ул кесәсенә салып җибәргән хат-хәбәргә җавап көтүләр! Әй, ул кинода күргән яки китапта укыган хәлләрне күз алдына китереп, хыялда аларга үзеңне дә катнаштырып саташулар!.. Хәзер шуларны көлемсерәп искә төшерәсең дә, татлы хатирәләр җанга бәлзәм булып иңә.

Ә Мәхәббәттәге уртак яклар? Алары да җитәрлек. Йөзләребез буйлап тәгәрәгән күз яшьләребез һәммәбезнеке бертөсле — төссез, каннарыбыз — кызыл, көлүләребезнең аһәңе бердәй, илереп елауларыбыз һәммәбезнеке дә әрнүле. Бәхетлеләр — охшаш, бәхетсезләр генә төрле-төрле була, дисәләр дә, Мәхәббәтнең фаҗигаи өлешендә уртаклыклар безнең күбрәктер дә әле. Мәхәббәт илаһи гармониянең гаранты булырга тиеш кебек булса да, ул гел генә дә бәхет-сәгадәт, шатлык-сөенечләр генә китерми икән шул! Мәхәббәт белән Нәфрәт һәрчак янәшәдә. Бөеклек белән Түбәнлек арасы пычак йөзе кадәр генә. Аллаһы Тәгалә Адәм белән Һауваны җәннәттән сөргән. Сәбәбе булган, диләр. Бүлешенмәгән Мәхәббәт аркасында тарихта калырлык зур-зур сугышлар чыккан. Көндәлек тормышта бәет чыгарырлык хәлләр дә бихисап. Үзара аңлашуда чәчәк, хушбуй, тәм-том кебек хаҗәт әйберләр урынына пычак, элмәк, агу кебек гайре табигый нәрсәләр килеп керә. Аннан инде китә судлар, мәхкәмәләр... Зиндандагыларның (хәер, аларның гына түгел) татуировкаларына игътибар итегез, һәрберсендә диярлек сөйгәннәренең исемнәре яки Мәхәббәткә бәйләнешле берәр сүз сырланган була.

Гомумән, Мәхәббәт турында тирәнрәк уйланган саен, каршылыклы хисләр күбәя генә бара. Ә бер уйласаң, сере бик гади: бөек табигый инстинкт буенча Адәм баласы дәвам-нәсел калдырырга, үрчергә омтыла. Русча әйткәндә, охота к умножению. Ә Мәхәббәт дигәннәре моның прелюдиясе түгелме соң? Әмма нинди прелюдия! Бәлки, җәннәткә керер алдыннан (насыйп булса!) шундый хис кичерәләрдер?

Чү! Мин әйтәсе төп уемнан читкәрәк киттем түгелме? Мәхәббәттә дә бит сөйләнүдән бигрәк, гамәл үзе тансык. Сүз бит Мәхәббәтнамәнең, минем «Мәхәббәтнамә»нең бүтәннәргә хаҗәте турында иде. Күңелем сизенә, хәтта ышанам: кемнәргәдер кирәге булачак бу китапның! Кем белә, кайбер уй-хисләр кемнәрдер өчен гыйбрәт-сабак та булыр әле... Биредә мин берни яшермичә күңелемне түктем, бер шигырем юлларындагыча, «хөкем гадел булыр, беләм. Мин үземирешкән кадәр дөресен яздым, чын күңелдән». Дөрес, ихласлык әле ул аргумент ук түгел. Ихласлыктан тыш кайбер фикерләр, күзәтүләр, «аңлатып булмаган» нәрсәне үземчә аңлаулар да бар бит әле бу шигырьләрдә. Кешеләр бу тормышта бер-беренә иптәш, иш, фикердәш эзли. Мин дә үземә гомер буе җандаш эзләдем. Икенче төрле әйткәндә, җан ашы — җанаш эзләдем. Таптыммы-юкмы — икенче нәрсә, әмма мәгълүм бер мәзәктәге шикелле, «процесс үзе кызык һәм матур» булды. Матурлык булган икән, бар икән, нигә аны кешеләр белән уртаклашмаска! Мәхәббәт — Аллаһның серле-могҗизалы бүләге ул. Шул ук вакытта Бөек Сер дә! Ә Сернең бөтен хикмәте кем беләндер бүлешәсе килүдә бит!

Әйе, моннан утыз еллар элек мин бер «Мәхәббәтнамә» чыгарган идем инде. 1976 елда Казанда басылган «Шигырьләр һәм поэмалар» мәҗмугасы эчендә аерым бер ки-тапчык-бүлек рәвешендә (әлеге җыентык 1978 елны Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды). Үзенчә бер төзек композицияле, күңел-кальбемнең шул чордагы үзенчә бер кардиограммасы иде ул. «Ирек», «Сафлык», «Сагыну», «Син», «Бәйрәм», «Гөнаһ», «Өзгәләнү», «Каршылык», «Хушлашулар», «Төшләр», «Хатирәләр», «Юану» дигән бүлекләр бар иде анда. Ә хәзер менә «Мәхәбәтнамә»нең

яңасы, тулырагы тәкъдим ителә. Беренчесендә — 30 яшькә кадәр язылган шигырьләр иде, бусына исә соңгы 30 елда язылганнар да өстәлде. Вакыт байтак үткән. Теләсә-теләмәсә дә, Адәм баласының үзгәрми чарасы юк. Үзгәреш гелән шәхес һәм шигърият файдасына гына булмаска да мөмкин; ни дисәң дә, еллар үткән саен, күзләр уңа төшә, гаҗәпләнү хисе кими, дәрт-ялкын сүрелә... Әмма шунысы бар: яши-яши акыл утыра, тәҗрибә арта, реаль тоем көчәя... Чая яшьлекнең кайнар яратуы янына олпат олылыкка хас хөрмәт дигән бөек хис өстәлә.

«Мәхәббәтнамә»нең бусын, теләсәм дә, аерым бүлек — «оя»ларга утыртып чыга алмам. Мәхәббәт агачының төп үзәге янына яңа үсентеләр чыккан, алар зурайган, тармакланган, ябалдашлары, бер-берсенә керешеп, уралып беткән... Шуңа күрә үсмер чактагыдан бүгенгәчә шигырьләр кайчан, ничек язылган булса, шулай урнаштырырга карар кылдым, һәр шигырь, һәр строфа, һәр юл конкрет шәхесләр, конкрет язмышлар белән бәйләнгән. Аңлаганнар аңларлар. Кемнәрнеңдер күңел тибрәнешләре — өзгәләнү-сагышлары, ярсу-янулары, өмет-хыяллары минеке белән күпмедер тәңгәл килә алса, аңлашуга, ягъни фикердәш, күңелдәш булуларына ышаныч бар. Шулай булыр дим: чөнки һәммәбез шушы Кояш астында Бәхеткә дәгъва кылып туабыз, яшибез, олыгаябыз бит. Фәлсәфирәк итеп әйтсәк, ихтыярсыз туабыз, гаҗәпләнеп яшибез, сагыш белән үләбез... Шатлык һәм Бәхет һәркемгә тансык. Бер җырда әйтелгәнчә, «җирдә күпме җаннар йөри, иясез шатлык булып!..» Бу шигырьләр кемгәдер ияле шатлык булырга булыша алса икән дигән теләктә калам.

*2003, июнь*

## «АҢЛАЕШЛЫ» ҺӘМ «АҢЛАЕШСЫЗ» ШИГЫРЬЛӘР ЯКИ ПОЭЗИЯНЕҢ ГРАЖДАНЛЫК ЙӨЗЕ

*(Әдәбият галиме Ибраһим Нуруллин белән әңгәмә)*

**И. Нуруллин.** Поэзия мәсьәләләре һәрвакыт игътибар үзәгендә булып килде. Бүген дә көн тәртибеннән төшкәне юк. «Литературная газета» битләрендә бу турыда фикер алышу өзлексез дәвам итә. Шактый еллар элек «Социалистик Татарстан» газетасында да поэзиядә Тукай һәм Җәлил традицияләренә кагылышлы фикер алышу үткәрелгән иде. Традицион һәм иректе шигырьгә бәйләнешле бәхәс тә булып алды. Янәсе, кайсы яхшы һәм кирәк, кайсы яшәргә хаклы?! Бәхәссез ки, тиешле идея-художество таләпләренә җавап биргән тәкъдирдә традицион шигырь дә, ирекле шигырь дә кирәк һәм һәр икесе файдалы эш башкаралар. Минемчә, бәхәс, әгәр шулай әйтергә яраса, «аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр тирәсендә барырга тиеш иде. «Аңлаешлы» шигырь дигәндә, мин барлык поэтик чараларны, эмоциональ, ягъни тирән хис белән сугарылган әһәмиятле фикерне укучының йөрәгенә, йөрәге аша аңына җиткерүгә хезмәт итә торган шигырьләрне күздә тотам. «Аңлаешсыз» дигәннәрендә исә, киресенчә, ул чаралар фикерне (әгәр ул булса!) яшерүгә, томан белән өртүгә хезмәт иттерелә. Иректе һәм ак шигырь беренче төргә карый алганы кебек, традицион шигырьнең дә «аңлаешсыз» булуы мөмкин.

**Р. Фәйзуллин.** Шигырьләрнең, Сез әйткәнчә, «аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» булулары бер яктан, шагыйрьнең талантына, осталыгына, икенче яктан, укучының әзерлегенә, әдәбиятны аңлау дәрәҗәсенә бәйле. Һәрхәлдә, бу юнәлештә сөйләшкәндә укучыны уртага алып әңгәмәләшү хәерле. Гомумән, без поэзиягә кагылышлы бүтән мәсьәләләр хакында да фикер алышырбыз дип уйлыйм. Чөнки шигърият турында сөйләшү ул минем өчен, асылда, бөтен татар әдәбияты турында сөйләшү кебегрәк тә. Әгәр без фәлән йөз еллык әдәбиятыбыз бар дибез икән, алар — иң әүвәл шигъри сөйләмгә корылган әсәрләр. Әгәр әдәбиятыбыз бүтән халыкларга беркадәр (кызганычка каршы, аз) таныш икән, алар иң әүвәл Тукайны, Җәлилне беләләр. Инде бүгенгә килсәк, башка жанрларның куандырырлык җимешләр биреп, үсеп-формалашып килүен таныган хәлдә, шигърият әдәби хәрәкәттә үзенең традицион лидерлык хәлен һаман саклап килә әле. Кайсы яктан алсаң да: кыю, кирәкле фикерләр әйтү ягыннан да, әсәрләрнең сәнгатьчә нәфислеге, камиллеге ягыннан да бөтен дөнья күләмендәге әдәби «ярминкәгә» алып барырлык новелла, хикәя, повесть, роман, пьесаларыбыз берән-сәрән генә булса, бүтән халыкларга да күрсәтә алырлык шигъри әсәрләребез байтакка җыйнала дип беләм мин. Бер генә факт китереп үтик: «Бөтен дөнья әдәбияты китапханәсе» сериясендә чыккан 200 томлык китапларда бездән — борынгыдан алып бүгенгегә кадәр — 17 шагыйрь катнаша. Кызганычка каршы, проза әсәрләребез бу авторитетлы басмада бер генә исем белән дә чагылыш таба алмады. Әлбәттә, монда жанрның үз өстенлекләре дә бар. Әйтик, традицияләрнең зурлыгы, кыскалык, ритмлылык һ.б. Шигырь — фикер һәм хиснең табигый рәвештә эмоциональ төенләнүе ул.

Тагын шуны да әйтик: әдәбиятта актив эшләп килүче өлкән һәм урта буын вәкилләренә иш булып, шигърият сафына күтәрелгән байтак талантлы яшьләребез бар. Бу исә алга таба да шигъриятнең гүзәл үрнәкләре туачагына ныклы ышаныч бар дигән сүз. Шуңа да карамастан мин үзем шәхсән бүгенге шигъриятебез турында шактый уйланам һәм беркадәр борчылам да. Әниләр әйтәләр бит: ба-

ланың хәсрәте үзе үскән саен арта гына бара... Шуның кебек, шигъриятебез дә үсә тора, проблемалары ишәя тора. Һәр үсү, белгәнебезчә, каршылыклар белән бара. Әйтик, поэзия үсә, ә китапларыбызның тиражлары ишәйми, менә дигән шигырьләр белән янәшә зәвыксыз, халтура әйберләре байтак урын ала бирә, яхшы шигъри үрнәкләребез бар дибез, ләкин аларны бөтенсоюз һәм дөнья укучысына тиешле дәрәҗәдә күрсәтә алганыбыз юк... Без хәзер һәммәбез дә беркадәр аптырашлы хәлдә калдык шикелле. Шагыйрьләр дә, укучылар да, хәтта тәнкыйтьчеләр үзләре дә. Шигырьләр, шигырьләр, шигырьләр... Арада бик яхшы шигырьләр бар. Ә шигърият үзе, гомумән, кая таба бара? Процессның барышы ничек? Бүтән халыклар шигърияте нисбәтендә ничек?.. Төптәнрәк уйлап баксаң, эш бит болай: язылган әсәрләребезгә комментарийлар, аңлатмалар алуга караганда, без (бу очракта, шагыйрьләр) әйдәүгә, барыр юлларны, маякларны билгеләп ачыклашуга мохтаҗ. Минемчә, әле тәнкыйть шигъриятебезнең үсү тенденцияләрен ачыклау, барыр юлларны билгеләү процессында үз ролен үтәп җиткерми шикелле.

**И. Нуруллин.** Мин үгезне мөгезеннән эләктерергә теләгән идем. Сез исә максатка уратыбрак һәм чигенү белән килү юлын сайлыйсыз. Бәлки, шулай кирәктер.

Иң элек мин татар әдәбиятында поэзия бүтән төрләрдән, аерым алганда, прозадан өстенрәк тора дигән мәгънәдәге раславыгызны шик астына алыр идем.

Әйе, «зур стажлы» татар әдәбиятында «шигъри сөйләмгә корылган әсәрләр» күп гасырлар буе өстенлек алып килде. Ләкин бу барлык әдәбиятларга да карый торган хәл бит. Кайчандыр хәтта фәнни трактатлар да шигырь белән язылган. Реализм әдәби юнәлеш буларак мәйданга килгән дәверләрдә исә эпик жанрлар алга чыкты, әдәбиятның җитлегү дәрәҗәсе проза белән, аеруча роман белән үлчәнә башлады. Бу закончалык татар әдәбиятына да карый. XX гасыр башында ук инде биредә проза активлашты. Моннан соңгы чорларда да ул үз урынын бирми килә. Дөрес, соңгы елларда проза бездә беркадәр сүлпәнәя, ә поэзия җанлана төште. Әмма прозадагы бу хәлне мин үтеп китә торган күренеш итеп карыйм. М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар», Ш. Бикчуринның «Каты токым» һәм Г. Ахуновның «Идел кызы» романнары, Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын», А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» һәм М. Зариповның «Үзеңнеке — үзәктә» повестьлары әнә шундый оптимизмга нигез булып торалар.

Башлыча, Р. Гамзатов, К. Кулиев, М. Кәрим исемнәре белән бәйләп карала торган авар, балкар һәм башкорт әдәбиятлары турында сүз барса, Сезнең тезис, әлбәттә, дөрес булыр иде. Бу очракта исә зур прозасы белән ир булып җитешкән татар әдәбиятына кыска ыштан кидерү сыман нәрсә килеп чыга.

«Шигырь тәнкыйте»нең үз бурычын үтәп җиткерү-җиткермәвенә килгәндә, бу үзе аерым зур мәсьәлә. Тик шуны гына әйтим: «проза тәнкыйте» яисә «драматургия һәм театр тәнкыйте» турында да Сез әйткәнне кабатларга мөмкин булыр иде. Һәм, гомумән, язучылар җәмәгатьчелегенең әдәби тәнкыйтьтән канәгать булган чагын мин хәтерләмим.

**Р. Фәйзуллин.** Иң әүвәл бер нәрсәне ачыклау мөһим — ул да булса шигъриятнең иҗтимагый тормышта тоткан урыны мәсьәләсе. Әлбәттә, һәр халыкта, аның тарихи үсеш шартларына һәм рухи культура традицияләренә карап, бу мәсьәлә үзенчә куела һәм аңлатыладыр. Куелган соравымны татар шигърияте мисалында, хәлемчә тәфсилләп, шәрехләп китмәкче булам. Булган заман: бездә мәкаль, җыр яшәгән, «Кыйссаи Йосыф» кебек поэмалар, бәетләр сөйләнелгән (дөресрәге, көйләнелгән), телдән телгә, кулдан кулга йөргән, күчерелгән. Ул чорларда әле сүз сәнгатенең бүтән төрләре әллә ни таралыш алмаган. Димәк, халыкның бөтен рухи тормышы, акыл-хикмәте шушы тезмә формадагы әсәрләрдә фокуска тупланып чагылыш тапкан. Чөнки бүтән юл юк, мөмкинлек булмаган. Инде гасырлар аша бүгенгә килик. Кешенең рухияте сәнгатьнең әллә никадәр яңа төр һәм жанрларын тудырды. Сүз сәнгате, үзе генә дә күпме төр һәм жанрларга бүленеп, мөстәкыйль үсеш алды. Һәр жанр реаль тормышның мәгълүм бер кисәген чагылдыруда билгеле бер монополия алды шикелле. Чыннан да, киносценарий буенча экранда күрсәткәнне шигырьдә әйтеп бетереп булмаска мөмкин, романда тасвирлаганны поэмада чагылдыру авыр һ.б. Канатлы сүзнең, җырның (шигырьнең) халык язмышының хәлиткеч вакытларында үткен һәм дәһшәтле корал була алганын истә тоткан хәлдә, көндәлек тормышта без еш кына поэзия дигән затлы жанрның нәфис иңнәренә күтәрә алмаслык йөкләр өймибез микән, дөресрәге, өяргә тырышмыйбыз микән? Шигъриятнең символы да гыйбрәтле: борынгы мифлар буенча Пегас — Тулпар ат (димәк, көчле дә булырга тиеш ул, күпмедер йөк тә тарта алырга тиеш), ләкин канатлы ат шул ул! Канат янына тәртә куеп булмый. Сез үзегезнең миңа биргән соравыгызда «әдәби тәнкыйтьтә хезмәт бүленеше яши бит» дисез. Әдәби жанрлар арасында да шундыйрак «бүленеш» булырга тиештер.

Ә эпик жанрларның бүгенге миссиясе турында фикерләрегез уйландырып куйды әле. Кызык. Шулай да, әдәбиятның җитлегү яки үсеш дәрәҗәсе ни өчен нәкъ проза жанры, аерым алганда, роман белән генә билгеләнә икән? Ни өчен шул ук миссияне поэзия яки драматургия үти алмый? Прозаны «авыр артиллерия» дию иң беренче кемнең акыллы башына килгәндер, әйтү кыен, — мин үзем шәхсән бер нәрсәгә инанганмын: әдәбиятның нигезендә шигъри сүз, шигъри образ, шигъри хикмәт ята.

Поэзиясе, шагыйрьләре зур булган әдәбият олы әдәбият саналырга хаклы. Әдәбият тарихында, гомумән, әдәби хәрәкәттә, бик өстә генә яткан бер фактка игътибар итик — шагыйрь кеше, теләп алынса, бүтән жанрларда да кинәндереп эшли ала. Пушкин, Лермонтов, Тукай иҗатларын гына искә төшерик. Ә кайсы гына хөрмәтле прозаигыбыз поэзиядә эз калдырырлык шигырьләр язып күрсәтә алыр икән? (Яшьли шигырь язып прозага күчкәннәр бар, сүз алар турында бармый, кире процесс турында бара.) Поэзия — яшьлек, проза — балигълык, диючеләр бар. Минемчә, дөрес үк формула түгел бу. Заман таләпләренә кыю һәм фидакарь җавап бирә алырлык теләсә нинди яшьтәге әдип кеше әдәбиятта яшь була ала. (Монда яшь — «яшел» мәгънәсендә түгел, яшь кеше дә хикмәтле була ала бит! Мәсәлән, Тукай!) Мин Сезнең белән өлешчә килешәм: тормышның төрле якларын төрле планда яктырткан чәчмә әсәрләр иҗтимагый үсешнең билгеле бер этабында лидерлык хәлен алып торырга мөмкин. Ләкин билгеле бер чорда гына. Кайчан? Анысы һәр халыкның гомумкультура үсеше дәрәҗәсенә карый. Шулай да ни өчен чәчмә эпик әсәрләр билгеле бер вакытта тормышны чагылдыруда төп көзге булып ала алды яки була ала соң? Чөнки ул әсәрләр тормышны массовый формада танып белүдә бердәнбер диярлек чыганак иделәр. Юкса күз күрмәгән җирләр, илләр, холыкгадәтләр турында укучы каян белә алган булыр иде. Хәзер бу юнәлештә прозаның йөге җиңеләйде, аның вазифаларын яхшырак һәм үтемлерәк формада бүтән нәрсәләр — радио, телевидение, кино, газета-журналлар һ.б. башкара. Минемчә, безнең кайбер прозаикларыбызның бер бәласе шунда: алар классик кануннар белән, әйтик, Толстойларча эпик колач белән эш итәргә тырышып, үз әсәрләренә һәркемгә мәгълүм һәм һичкемгә кирәк булмаган «зур-зур тормышчан кисәкләр» тутыралар. Киләчәктә, минемчә, бүген әле бик нык сыман күренгән жанрлар диктатурасы җимереләчәк, йомшаграк әйткәндә, нык үзгәрәчәк.

Роман турында моннан унбиш еллар элек «Иностранная литература» журналында байтак илләрнең язучылары һәм әдәбиятчылары белән берлектә үткәрелгән бәхәсләрне, М. Шолоховның: «Безгә роман кирәкме, юкмы?» — дигән сорау крәстияннең быел ашлык чәчәргәме, юкмы диюе шикелләрәк ул» дигән сүзләрен хәтерләгән хәлдә барыбер бу мәсьәләдә ачыкланырга тиеш урыннар бар дип беләм. Жанрның киләчәктәге үсү перспективасы һәр халыкның тарихи-социаль шартлары һәм хәле нисбәтендә каралырга тиеш. Бер бизмән бөтен нәрсәгә ярамый. Роман — тормышның үзгә бер зур, бөтен күзәнәкләрен күрсәтә торган көзге. (Шигырь дә тормыш көзгесе, ләкин ул бераз бүтәнрәк көзге, бераз томанлырак, буяулырак көзге димме?) Роман өчен тулы телле (чөнки, телсез милли әдәбият була алмый; тел, халык теле — әдәбиятның нигезе) тормыш кирәк. Тиккә генә түгел бит, моңарчы уңышлы дип саналган проза әсәрләренең иң зур күпчелеге авыл җирлегендә туган. Бу — табигый. Авылда тел бар, шул телдә сөйләшүче тулы канлы персонажлар бар, кыскасы, җирлек бар. Ә хәзерге промышленность предприятиеләрендә эшләүчеләр яисә техник фәннәр дөньясындагы галимнәр һ.б. тормышыннан алынып, татар телендә роман язылуы сирәк күренеш. Әлбәттә, ясап була, һәм ясаучылар да бар, ләкин ясау ясау инде. Шигырь белән эш бераз бүтәнчәрәк. Үз телендә сөйләшүче бер генә кеше, шагыйрь үзе генә калса да, ул нәрсәдер тудыра алырга мөмкин. Шагыйрь үзе инструмент, үзе флейта, ә романист ул — дирижер кебек, оркестры өчен аңа күп инструмент кирәк...

Тизлек заманча кыска, лаконик формалар таләп итә. Ә шигырь моны эшли ала. Шигырьне бик тырышып яклавымның хикмәте шунда. Заманага кыска гына сүзләрдә зур хисләнү-кичерешләр, уйланулар тудыра алырлык юллар кирәк. Фәләненче гасырларда яшәгән бөек шагыйрьләрнең илаһи сүзләрен еш кына үзалдыбызга әйтеп йөрүләр тикмәгә түгел бит. Пышылдапмы, кычкырыпмы әйтәсең дә аларны, уйландыра, үз тормышыңда күргән хатирәләрне актарта, хыялландыра... Кыскасы, шигырь — үлемсез, шигырь — мәңгелек. Кешелек яшәгәндә, шигырь-җыр яшәячәк! Ә бүтән, соңрак туган, беркадәр ясалмарак жанрлар турында болай кистереп әйтү кыен.

**И. Нуруллин.** Шигъриятебезнең иҗтимагый тормышта тоткан урыны. Минем дә теләгем сүзне нәкъ шушы мәсьәләдән — лирик поэзиянең иҗтимагый роле мәсьәләсеннән башлап китү иде. Әмма Сез бу мәсьәләне поэзиянең әдәби төр буларак үзенчәлегенә кайтарып калдырасыз, дөресрәге, шушы ягын калкытыбрак куясыз. Бусы артык каты чикләвек түгел. Дөрес әйтәсез, әдәби төрләр һәм жанрлар арасында да «хезмәт бүленеше» ята. Лириканың, мәсәлән, үз предметы, үз объекты, үзенең «чи материалы» һәм, димәк, үз бурычлары бар. Бүтән жанрлар башкарырга тиешле эшне шигъриятькә йөкләү, билгеле, лириканың үзенә дә, гомумән әдәбиятка да файда китермәячәк.

Мин исә икенчерәк нәрсәне күздә тотам: поэзия кемгә һәм ничек хезмәт итәргә тиеш?

Сезнең соңгы еллардагы шигырьләрегез, Равил, минем карашымча, фикер тирәнлеге һәм шул фикерне укучыга җиткерүгә хезмәт итә торган үтемле поэтик чаралар эзләү һәм табу белән аерылып торалар. Әмма кайчандыр Сез, минемчә, «аңлаешсыз» дигән поэзиягә күпмедер өлеш керткән идегез. Үзегезгә кайбер яшьләрне дә иярттегез. «Наз» исемле җыентыгыгызга «Нюанслар иле»н кертүегезгә карап, «аңлаешсызлык» принципларыннан баш тартмагансыз дигән фикергә килдем.

Җыентыкны ачабыз да түбәндәге юлларны укыйбыз:

**Әсир**

Вазада җикән-камыш.
Ханым көлмәк салгандагы җил
ул бик аз шул...

Хәзергә мин бу язманың шигырь булу-булмау мәсьәләсен бер якта калдырып торам да, шигъриятне аңламаучы кеше данын күтәреп булса да, ачыктан-ачык әйтәм: кат-кат укып та, уйланып та, бернәрсә дә аңлый алмадым. Ни әйтергә теләде шагыйрь? Хатынның сылулыгы да җикән-камышның исен китәрә алмады дипме? Ул чагында кем әсир? Ни өчен әсир?

Ныклы иманым миңа болай ди: бер үк шигырь, әйтик, академикка да, сыер савучыга да аңлаешлы булырга, академикны да, савымчыны да дулкынландырырга, рухи баетырга тиеш.

Поэзиянең иҗтимагый ролен мин шулайрак аңлыйм. Сезнең бу хактагы фикерегезне ишетәсе иде, Равил.

**Р. Фәйзуллин.** Егерме биш яшендә үпкә чиреннән вафат булган Әсгать Фәхри болай дип язган: «Сез, бәлки, гаҗәпләнә торгансыздыр? Гаҗәпләнерсез дә шул, чөнки шагыйрьләрнең эшләре гаҗәбрәк. Без чәчәкләрдән сүзләр, ә сүзләрдән чәчәкләр ясыйбыз». Сүзләрдән — чәчәкләр... Сез, Ибраһим ага, үлән-чәчәкләрне күреп, танып, исемләп күп беләсездерме, әйтә алмыйм, үзем, кызганыч, бик күп чәчәкләрне исемләп белмим. Күбесен таныйм, кай тирәләрдә үскәнен чамалыйм, әмма байтагының исемен, хасиятләрен белмим. Үзем туып үскән тирәдә бу шулай, чит-ерактагы үлән-чәчәкләр турында әйткән дә юк! Тиешле мәгълүматым булмагач, мин аларны аңлыйм, беләм дип әйтә алмыйм, әлбәттә. Шигырьләр белән дә эш шулайрак тора. Гомумән, миңа шигырьне аңлашыла яки аңлашылмый дигән төрләргә бүлеп карау сәер. Кемгә ничек? Берәүгә — тирәнрәк аңлашыла, берәүгә — алай ук түгел. Алыйк бөтен халыкка аңлашыла дип танылган Тукайны гына: кем күпме һәм нәрсә аңлый бит! Һәммә кеше бертигез һәм бертөслерәк аңласа, Тукай турында йөзләгән тикшерүчеләрнең хезмәтләре дә кирәк булмас иде. Шулай ук Тукайның замандашы Дәрдемәнд иҗатын да төрле кеше төрле дәрәҗәдә аңлый дип беләм. Ул да бит татар халкының талантлы шагыйре!

Дөресен әйтим, шигырьнең бер күз йөртеп чыгуга ук үтә күрәли аңлашылып җитүен, шәхсән, мин үзем өнәп тә бетермим. Бөтен нәрсә кинәттән ачылып, тәмам аңлашылып бетсә, дөнья ничек кызыксыз булыр иде! Телдә «тылсым», «сихри» һәм башка сүзләр бар. Болар яшәештәге бөтен нәрсәнең дә «аңлашылып» бетмәвенә ишарә ич. Шигырьләр генә аерым чыгарма булып тормыйлардыр. Шигырь — ике тапкыр ике — дүрт түгел. Нигәдер бездә шигырьне, анатомия театрындагы шикелле, кисәкләп аңларга һәм аңлатырга тырышалар. Шигырь иң әүвәл хис аша акылга тәэсир итәргә тиеш. Бездә исә, кызганычка каршы, еш кына шигырьне тоймыйлар, ә өйрәнәләр.

«Аңлашыла» дигәннән, мәсәлән, халтура шулкадәр яхшы аңлашыла ки, хәтта бөтен материаль мотивлары белән... Мин үзем аңлавы гомергә җитәрлек шигырьләр ягында. Мәңгелек шигырьләрне гомер буе укысаң да, алар һәрчак нindидер яңа яклары белән ачыла һәм аңлашыла бара.

Шагыйрьләр әүлия түгел. Абсолют хакыйкатьне әйтергә алынучылар да түгел. Алар халык алдында үз-үзләре белән сөйләшә. Әгәр ак кәгазь битләренә күңелебез түрендә яткан иң газиз уй-хисләребезне төшерәбез икән, бу әле: карагыз, безнең эчләрдә нинди җәүһәрләр ята, күрегез безнең байлыкны, шаккатыгыз! — дию түгел, киресенчә, дөньябызга, яшәвебезгә, тормышыбызга карата менә безнең уйларыбыз, менә без сөенгән нәрсәләр, менә безне рәнҗетә торган әйберләр дию, эчке дөньябызны сезгә курыкмыйча ышанып ачу, сезнең белән чын йөрәктән ачыктан-ачык сөйләшү, киңәшләшү, сезнең үзегезнең күңел түрләрендә яткан җәүһәрләрне беләсе килү, сезне ихтирам итү.

Инде соравыгызның соңгысына, турыдан-туры миңа караган өлешенә җавап бирим. Кыска шигырьләрне моннан унбиш ел элек яза башлаган идем һәм бүген дә дәвам итәм. Аларның бер өлеше — җитмешләп миниатюра моннан унөч ел элек — 1965 елда «Казан утлары»нда басылып чыкты. Алар, кемнәрдер уйлаганча, «мөгез чыгарырга тырышу»дан түгел, рухи ихтыяҗ булганлыктан язылган әйберләр. Хәзер уйлап карыйм: бәлки, бу күренеш (бу очракта бүтән яшьтәшләремнең дә шигырьләрен истә тотып әйтәм) — 50 нче еллар поэзиясендәге тасвирчылыктан, акланмаган озынлыктан, мәгънәсез риторикадан туеп, кыскалыкка, фикер әйтүгә омтылу, бәлки, буш һәм ялган поэзиягә яшь бер кешенең (дөресрәге, берничә студент-шагыйрьнең) үзенә күрә бер протесты булгандыр. Шул еллардагы бер шаяру искә төшә: кайчак шигырь китапларын ача идек тә, шырпы тартмасы куя идек, шул шырпы тартмасы каплаган юлларны (7—8 юл) юри укып карый идек. Автор шул җидесигез юлда берәр нәрсә әйтә алганмы, берәр поэтик табыш бармы? Ә чын шагыйрь әйтергә тиеш! Бу — яшьлек шаяруы, әлбәттә; шулай да Мирсәй Әмир мәзәгендәге шикелле, «нәрсәдер бар монда!» Дөрес, «Нюанслар иле»ндә чыккан миниатюралар арасында уңышлысы яки уңышсызрагы булырга мөмкин. Мисалның да уңышлы яки уңышсызын (бу Сез китергән «Әсир»не аклау өчен әйтү түгел) китерергә мөмкин. Бусы — икенче мәсьәлә. Эш принципта. Әгәр 1965 елда матбугатта 70ләп кыска шигырь эчендә 700ләп сүз (бу урында рационализмда гаепләмәссез дип уйлыйм) чыгарганмын икән, мин бу сүзләр өчен һәм аларның мәгънәви нагрузкасы өчен җавап бирәм, һәм ул миниатюраларда

беркадәр мәгънәви һәм поэтик табышлар бар дип беләм. Шунысы гаҗәп: оппонентлар ни өчен шул вакытта берничәшәр мең юллы, шактый буш бүтән әсәрләрне күрмәделәр соң? Гаҗәп. Бу яңалыкның тышкы ягына, ягъни формасына гына игътибар итү түгелме соң? Бу — үзе бер формаль караш яки формализмның үзе түгелме соң?

Ә тулаем алганда, «Нюанслар иле»ндәге шигырьләрне чагыштырмача дөрес аңлап анализлаган кеше — яшь тәнкыйтьче Мансур Вәлиев булды. («Казан утлары», 1974, 6 сан.) Бу мәсьәләдә мин аның фикере белән килешәм.

**И. Нуруллин.** «Аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» дигән сүзләргә икебез ике мәгънә салып сөйләшәбез икән ләбаса. Беренче атаманы мин поэзиянең магистраль юлыннан бара торган талантлы шагыйрьләр иҗатына, ә икенчесен шигъри ребус төзергә яратучы шагыйрьләрнең тегеләйме-болаймы формализмга тартым экспериментларына карата кулланам. Сез исә чын шигъриятнең катлаулы һәм бай эчтәлекле булуы һәм бу эчтәлекне укучының тиз генә чумырып бетерә алмавы турында сүз алып барасыз.

Әйе, даһи шагыйрьләрнең әсәрләре заманнан заманга күчеп яши, һаман яңа ягы белән ачыла бара. Бу әсәрдән алган тойгы да, фикер дә кешедә төрлечә булырга мөмкин. Әмма шунысы бәхәссез: укучы (хәзерлеклеме ул, түгелме, барыбер) бер укуда яисә тыңлауда ук дулкынланырга, күңеле һәм акылы өчен шигырьдән күпмедер азык алырга тиеш. Шул очракта гына укучыда кабат уку, ятлау теләге туарга, шигырь аны уйландырырга мөмкин. Шактый билгеле шагыйребезнең «Ат» исемле шигыре, белмим, бу таләпкә җавап бирә микән... Сүз «әкияттән дулап чыккан» ат турында бара. Башта ярыйсы гына укыла: сары тояк, ак бәкәл, озын нәфис сыйрак, киерелгән танау һ.б. Кинәт төртелеп калам:

Ул — давылда һәм кояшта
Үз төсен югалткан байрак.

Ярсу ат белән байрак арасында нинди уртаклык бар? Тагын укый башлыйм. «Ә ике күз — ике беләү» дигән сүзләргә абынып, ат күзе белән беләү арасында охшаш билге табарга азапланып утырам да дәвам итәм. Тагын тукталып калам:

Аңында ашкыну кошы,—
Ул кан күрде микән чыкта —
Кошның ике канат очы
Колак булып бәреп чыккан.

Соң нәрсә әйтергә теләде шагыйрь? Җавап соңгы юлда: «Юк, мин аңа атланмыймын». Ягъни бик билгеле хакыйкать: без сугыш теләмибез. («Илгә дошман басып керсә дә, атланмассызмы?» дигән сорау биреп бәйләнеп маташмыйм инде, хәерле булсын.) Шундый юлларны укыгач, М. Светловның илленче елларда рус «новаторларына» карата әйткән түбәндәге сүзләре хәтергә төшә: «Яшь шагыйрьләрнең күбесе шундый кыландырып язалар ки, ни турында сүз барганны да тиз генә чамалый алмыйсың. Оригинальлек артыннан кууларында, банальлектән качарга тырышуларында алар гаҗәеп банальлек күрсәтәләр».

Ачык булса кирәк, сүз шигырьдәге уй-тойгыны гәүдәләндерә торган шигъри сурәт һәм алымнарның укучыга якын һәм аңлаешлы булырга, ягъни беренче укуда яисә тыңлауда ук шигырьнең бербөтен эмоциональ тәэсир бирергә тиешлеге турында бара.

Такташны да тыңлап карыйк:

Бишьеллыкның бөек гигантлары
Һаман үсә, һаман күккә таба үрелә,
Башларыннан инде сез яшәгән
Коммунизм кыры күренә.

Кайсыбыз гына, өй түбәсе яисә агач башына менеп, офыкның киңәйгәнен күреп үсмәгән! Шунлыктан әлеге строфадагы поэтик сурәтне без бик җиңел кабул итәбез һәм аңа салынган гаять тирән фикерне «йотып» җибәрәбез. Ә бит җитлеккән Такташның барлык шигырьләре дә шундый ачык, төгәл, кирәк икән, «үтә күренмәле». Нишлибез инде, Равил туган, Такташны да сез өнәп бетермәгән шагыйрьләр җөмләсенә кертәбезме?

Дәрдемәндкә килсәк, әйе, ул талантлы шагыйрь. Ләкин аны Тукай белән бер тактага куюың гына төзәтмә кертүне таләп итә. Биредә «милләт» белән «халык» төшенчәләре бутала булса кирәк. Мәгълүм булганча, В. И. Ленин соңгы төшенчәгә эшче белән крәстиянне генә кертә. Дәрдемәнд һич тә Тукай мәгънәсендә халык шагыйре түгел иде. Чөнки аның уй-кичерешләре күп кенә очракта халыкның (башлыча крәстияннең) иң төп, иң зур теләк-омтылышларына авваздаш булып җитә алмады.

**Р. Фәйзуллин.** Еш кына уйланыла: тарихи зур рухи мираска ия булган халыклар, әйтик, немец, француз, рус, инглиз һ.б. үзләренең даһи улларын объектив бәяли беләләр, социаль чыгышларының

ниндилегенә карамастан, калдырган рухи мирасларыннан чыгып, аларны гомуммилләт горурлыгы итеп санарга һәм байрак итеп дөньяга күтәрергә тырышалар. Пушкин, Гете, Байрон, Бодлер... Минемчә, аларның да (Пушкиннарның) уй-кичерешләре күп кенә очракта халыкның (башлыча крәстияннең) иң төп, иң зур теләк-омтылышларына аваздаш була алмагандыр. Күрәсең, хикмәт — халыкның мөстәкыйль фикерләү дәрәҗәсенең ниндилегендә. Гомумфикерләү дәрәҗәсе һәм милли горурлыгы югары булган халык, рухи мирасны бәяләгәндә, иң элек иҗтимагый-эстетик законнар белән эш итә, һәм, киресенчә, мөстәкыйль иҗади фикерләү дәрәҗәсе һәм үзаңы түбәнрәк булган (гасырлар буе изелеп хаким милләт кул астында яшәү сәбәпле; бу хәлнең шулай ук бүтән тарихи сәбәпләре дә булырга мөмкин) халыкның бериш вәкилләре еш кына шәрә социаль тойгылар белән эш итүчәнрәк. (Мәсәлән: өлешчә пролеткультчылар, гарәп хәрефләре белән басылган китапларны туздырып, яндырып йөрүче үз «активистларыбыз» һ.б.) Беләсез, заманында Тукай белән Дәрдемәнд үзләре дә бер бәләкәй нәрсәдә аңлаша алмый йөдәгәннәр. (Сүз Тукайның «Йолдыз» газетасында басылган «Мөтәшагыйрьгә» исемле шигыре мөнәсәбәте белән Дәрдемәнднең «Вакыт» газетасында чыккан «Шагыйрьгә» исемле шигыре турында бара.) Ә без исә хөрмәтле профессорыбыз белән бу мәсьәләдә аңлашырбыз дип уйлыйм. Югарыда әйтелгән мәгълүм исемнәрдән тыш, XX гасыр башында татар халкының тәрәккыяте өчен янып йөргән, ләкин бүгенге укучы исемнәрен һәм әсәрләрен бөтенләй диярлек белмәгән әдипләребез дә юк түгел ич. Алар иҗатының демократик өлешен халыкка кайтарганда, һичшиксез, байый гына төшәр идек.

Сезнең сүз сөрешеннән шундыйрак фикер аңлашыла: «Ни өчен бүгенге кайбер талантлы дигән яшьләребез Такташча язмый икән?» Шундук берничә сорау туа: ни өчен нәкъ Такташча? Такташ иҗаты бүгенге һәр яшь шагыйрь өчен әйдәүче үрнәк көчме? Ни өчен Такташ татарча гына яңгырый, нигә аның иҗаты, Тукай иҗаты кебек, бүтән халыклар өчен дә уртак рухи хәзинәгә әверелмәде? Хикмәт авыр тәрҗемә ителүдә генә микән? Дөрес аңлашылсын: Такташка күләгә төшерергә яки аның поэзиядәге урынына «ревизия» ясарга җыенмыйбыз. Такташ — зур шагыйрь, халык күңеленә тирән кергән шагыйрь. Ул сихри таланты белән берничә дистә еллар буе, үзеннән соң килгән байтак сәләтле каләм ияләрен үзенә «буйсындырып» килде. Бу «буйсындыру», асылда, бәләкәй Такташлар, «такташчыклар» туура сәбәп булды. Такташның яхшы традицияләре яңа сыйфатта үссен өчен, таланты белән Такташтан ким булмаган көчләр килүе кирәктер шул.

Минемчә, бүгенге яшь буынның Сез кабатларга яраткан «аңлаешлылыкка» үз карашы бар. Ул — үз халкың укучысы белән бергә, совет халкын тәшкил иткән бүтән халык вәкилләренә дә аңлаешлы була алу. Уртак максатлар, уртак кызыксыну-омтылышлар, уртак тормыш шартлары, әйтик, саф русчалыкны, саф кыргызчалыкны яки саф татарчалыкны гына хупламый. Ихтимал, «саф» сүзен «архи» белән дә алыштырырга ярыйдыр. Чөнки бу очракта милли чикләнгәнлек күздә тотыла. Чынбарлык милли һәм интернациональ моментларның заманча чагыштырмада булуын таләп итә. Әгәр шагыйрь үз иҗатын бүтән халыкларның да тәкъдир итүен тели икән — бу табигый. Рухи байлыгың бар икән, аны бүтәннәр белән бүлешү гаеп түгел ич! Ләкин син тәкъдим иткәнне алар ничек кабул итәр? Менә нәрсәдә хикмәт. Бу биеклеккә ничек ирешергә соң? Әлбәттә, өйрәнеп, мәгълүм биеклеккә күтәрелгәннәрдән гыйбрәт алып, бар талантыңны җигеп, фикерне үзеңчә әйтү юлларын эзләп, әдәбият арсеналында булган ысулларны сынап... Дөрес, безнең арадан да талант орлыгы булган кайбер шагыйрьләр сыналган, әзер юл белән киттеләр. Ләкин үсү юлында беркадәр ат ала алганнары үзләренчә юл ярып баручылар арасыннан булды.

Эзләнүләр, билгеле, шома гына бармый. Тәҗрибә төсендәге әйберләр матбугатта чыккалады. Кайберләренең кызыклы гына фикерләре булып та, эчке җылылыгы җитмәү сәбәпле, укучы аларны йөрәге белән кабул итмәде, хәтта ачулы рәвештә сәерсенеп читкә дә тибәргәләде. Кайбер яшь шагыйрьләр, шигырьнең хисси башлангыч икәнен онытып, акыллы математик конструкцияләр белән мавыгып алдылар. Кайберләре Көнбатыш һәм рус шагыйрьләрен шулкадәр яхшы өйрәнделәр ки, хәтта телнең милли аһәңен һәм фикерләү рәвешен онытып ук җибәрделәр. Кайберәүләр, Союз аренасына бик тиз чыгарга теләп булса кирәк, ярым шигырь, ярым подстрочник характерындагы язмалар «иҗат» иттеләр.

Кыскасы, бүген халыклар арасындагы рухи бәйләнеш Такташ иҗат иткән 30 нчы еллардагыдан нык аерыла. Коммуникация һәм информация чаралары үсә барган саен, Җирпланета кечерәеп калгандай булды. Кешенең, гомумән халыкның гыйлеме артты, гаҗәпсенү тойгысы кими төште. Язучы хезмәте бермә-бер авырайды. 70 нче елларда иҗат итүче язучылар хәзер замана тудырган яңа проблемалар, яңа мәшәкатьләр белән мәшгуль.

Сез «аңлашылмаган» шигырьгә мисал итеп Р. Харисның «Ат» исемле шигырен китергәнсез.

«Ат», «Ярсыган ат», «Яткан ат» шигырьләреннән торган бу триптихны мин Сез уйлаганча ук аңлашылмый дип уйламыйм. Бу шигырьләр моннан җиде-сигез ел элек, автор иҗатының башлангыч чорында язылган. Дөрес, алар шактый авыр кабул ителәләр. Моңа «калканга да акыл тамган»(?) кебек сәеррәк юллар да сәбәпче. Ренат — рациональ шагыйрь. Ул — уйлы шагыйрь, фикер шагыйре. Өстәвенә ул беркадәр рәссам да. Ул шигырьгә әллә нинди буяулар, төсләр сала, шигырьне ориги-

наль метафоралар белән чуарлый. Бу, күрәсең, аның үзенә ошый. Ә бүтәннәргә? Зур потенциаль мөмкинлекләре булган Ренатка теләк йөзеннән шуны әйтәсе килә: халыкның гасырлар буена яшь белән юылып, моң һәм акыл белән өртелеп килгән күңел авазы һәм ритмына сизгеррәк булырга иде.

**И. Нуруллин.** Диалогыбыз бәхәс рәвешен алды кебек. Бу яхшы. Тик ара-тирә ул ике чукрак сөйләшүенә охшап куйгалый. Сез, мәсәлән, минем Такташ уңае белән әйткән сүзләремдәге мәгънәне үзегезчә формалаштырып, болай дисез: «Ни өчен бүгенге кайбер талантлы дигән яшьләребез Такташча язмый икән?» Мин мәсьәләне алай ук тарайтмаган идем үзе. Хәер, эш анда түгел. Минем фикерне, нигездә, дөрес аңлатасыз дип уйлыйк. Ләкин Сез үзегез үк оештырган җөмләдәге «анык» дигән сүзне төшереп калдырып, «ни өчен нәкъ Такташча» дигән сорау куясыз да, мәсьәләне бөтенләй бүтән яссылыкка күчерәсез. Такташча язу бер нәрсә, Такташча анык язу икенче нәрсә. Беренчесе — Такташка иярү булса, икенчесе — Такташ поэзиясе нигезендә яткан төп эстетик принципны гына тормышка ашыру була.

Мин Такташча гына түгел, бәлки Тукайча, Туфанча, Некрасовча, Твардовскийча, Светловча һәм башка талантлы шагыйрьләрчә язуны яклыйм. Ә инде аларның барысына да берьюлы ияреpгә мөмкин түгел. Димәк, бу шагыйрьләр өчен уртак принциптан чыгып язу турында сүз бара. Кыскасы, мин лирикада халыкчанлык һәм реализмны яклыйм.

Шул ук вакытта Бальмонт, Сологуб, Поль Верлен, Артур Рембо, Малларме, Хлебников, футурист Кутуй, имажинист К. Нәҗмиләрчә язуны якламыйм. Икенче төрле әйткәндә, мин декадентлык күренешләренең, модернизм принципларының поэзиябезгә үтеп керүенә каршы. Хәтерем алдамаса, Малларме бугай, болай дип әйткән: әгәр шигырьне аңлап булса, ул начар шигырь. Күренә ки, «аңлаешсызлык» принцибы әллә кайдан түгел, бәлки символистлардан килә икән.

Поэзиядә иҗат принциплары, художество методлары, аерым алганда, реализм һәм модернизм мәсьәләләре һич тә эстетик проблема гына түгел, идеологик проблема да ул.

Миллилек һәм халыкчанлык мәсьәләсенә кагылып яхшы иттегез. Поэзиядә «аңлаешлылык» һәм «аңлаешсызлык» дигән нәрсә бер ягы белән нәкъ менә халыкчанлык мәсьәләсенә килеп тоташа.

Сез болай дисез: «Уртак максатлар, уртак кызыксыну-омтылышлар, уртак тормыш шартлары, гомумән, объектив уртак яшәеш «саф милли күренешләрне», әйтик, саф русчалыкны, «саф кыргызчалыкны яки саф татарчалыкны хупламый». Шуңа күрә, сезнең фикерегезчә, хәзерге яшь буын шагыйренең теләге — «милли укучы белән бергә, совет халкын тәшкил иткән бүтән халык вәкилләренә дә аңлаешлы булу». Моңарчы килеп киткән бөек шагыйрьләр, белмим, бүтән халык укучыларына аңлаешлы булуны төп максат итеп яздылар микән? Минемчә, аларның һәркайсы үз халкы турында уйлап, үз халкы язмышы өчен тирәнтен борчылып иҗат иткән. Аларның поэзиясе бүтән халыкларга да үтеп кергән, яратып укыла башлаган икән, бу инде ике сәбәпкә бәйле. Беренчесе — бөек шагыйрьне тудырган халыкның тормышы, димәк, гомумкешелек яшәешенә хас сыйфат һәм күренешләрне дә үз эченә туплаган. Икенчесе — әлеге шагыйрь туган халкы тормышына тирәнрәк үтеп кергән, шундагы гомумкешелек элементларын тулырак һәм калкурак итеп күрсәтә алган. Моңа тагын сәнгатьтә, шул исәптән поэзиядә, гомумилек белән индивидуальлекнең диалектик берлеге мәсьәләсен дә өстик. Ягъни олы фикер белән сугарылган кичереш һәрвакыт шагыйрьнең шәхесенә генә түгел, бәлки милләтенә дә бәйле үзенчәлеккә ия була. «Халыкчанлык» төшенчәсе бар икән, кирәк икән, милләтләр яшәгән дәвердә ул рус, кыргыз яисә татар халыкчанлыгы рәвешендә генә гәүдәләнә ала. Әнә шундый халыкчанлыктан мәхрүм булган булсалар, әйтик, Пушкин, Байрон яисә Гейне шулкадәр дан казана алырлар иде микән? Яки менә М. Кәрим, К. Кулиев, Р. Гамзатов һәм безнең С. Хәким милли үзенчәлекләреннән башка таныла алырлар идеме? Юк, бу һич тә милли чикләнгәнлек түгел. Сүз зур шагыйрьләрнең беркайчан да космополит булмаулары турында гына бара.

Шагыйрьне бүтән халык вәкилләре дә аңласын өчен, дисез сез, алдынгы әдәбият шагыйрьләреннән гыйбрәт алырга, алар арсеналындагы ысулларны сынарга кирәк. Әлбәттә, бусы да кирәк. Әгәр ул шагыйрьнең бүтән халык укучылары игътибарын җәлеп итәрлек бай эчке дөньясы һәм олы фикере булмаса? Хәер, мин икенче мәсьәләгә күчә башлаганмын икән. Иң әүвәл әйтелгәннәргә карата Сезнең фикерне ишетәсе килә.

**Р. Фәйзуллин.** Зур һәм талантлы язучы иҗатында гомумкешелеккә хас мотивларның булуы турында бәхәсләшмәбез дип уйлыйм.

Инде соравыгызның ахырында: «Әгәр ул шагыйрьнең бүтән халык укучылары игътибарын җәлеп итәрлек бай эчке дөньясы һәм олы фикере булмаса?» дигән шик белән килешеп бетмәс идем. Гыйбрәтле тарихы булган һәр халыкның үзенә лаек бүгенге җырчылары табылмас микәнни? Бездә дә зур шагыйрьләр бар. Өлкән һәм урта буыннан мисал китермичә, чагыштырмача яшьрәк буыннан бер генә исем — М. Әгъләмовны гына әйтеп үтәр идем. Аның фикерләрен бәләкәй димәс идем мин. Аның күп кенә әсәрләре халыкның рухи язмышы турында җитди уйланырга җирлек бирә. Ихтимал, Мөдәрриснең кайбер шигырьләре бүтән милләт укучыларына да кызыксыз булмас иде (мәсәлән, үзенең шигъри куәте белән мәгълүм рус шагыйре Н. Рубцовтан бер дә ким санамас идем мин Мөдәррисне). М. Әгъләмов бер мисал гына. Бүтән исемнәр дә китерергә мөмкин булыр иде. Эш, мөга-

ен, күрә белүдә, таный, бәяли һәм күтәрә белүдәдер. Игътибар иткәнегез бармы? — бүгенге шигырь китапларының тиражлары, түгәрәкләбрәк алганда, уртача — 3000. Сан ягыннан бездән күп кечерәк милләтләрдә дә нәкъ шундыйрак тираж. Шунысы аянычлы: бездә бөтен шигырь китаплары да, бөтен шагыйрьләрнеке дә бер чама тираж белән басыла. Мондый «тигезлек»нең укучы зәвыгын тәрбияләүдәге роле аңлашыла булса кирәк. Сүз үзеннән-үзе практик мәсьәләләргә — пропаганда, ихтыяҗны өйрәнү, китап басу һәм таратуны оештыра белүгә һ.б. килеп тоташа. Бу хакта сөйләү безнең беркадәр теоретик характердагы әңгәмәбездә Сезнең өчен диссонанс булып тоелырга мөмкин. Ләкин нишлисең: язучы кеше өчен «меркантиль» бу мәсьәлә шулай ук зур әһәмияткә ия.

Язучы яки шагыйрь өчен әсәрләренең киңрәк дөньяга чыгуы нинди куәтле стимул икәнен әйткән дә юк. Бу очракта поэзия тәнкыйте (гомумән, тәнкыйть) ярдәмгә килергә тиеш. Киң катлау укучыларга акны карадан аерырга булышырга тиеш. Тәнкыйтьченең шагыйрьне ничек язарга өйрәтә алуына шикләнәм мин. Ә булышуга килсәк, ул чын мәгънәсендә булыша алыр иде. Бу җәһәттән безнең бүгенге тәнкыйтьчеләребез үзләренең төп миссияләрен үтәп бетермиләр шикелле. Сез бу хакта ничек уйлыйсыздыр? Бәлки, шагыйрьләр яки язучылар тәнкыйтьтән артыкны өмет итәләрдер? Бәлки, без язучы белән тәнкыйтьче арасындагы бәйләнешне тиешенчә аңламыйбыздыр? Кызык, Сез нинди тәнкыйтьчеләрнең нинди шагыйрьләргә конкрет ярдәме турында исемнәрен атап әйтә алырсыз икән? Мин үзем бүгенге поэзия тәнкыйтьчеләренең фикер ярлылыкларына хәйран калам. Кайтам да Г. Ибраһимовның моннан алтмыш биш ел элек чыккан «Татар шагыйрьләре»н укыйм. Дөрес, ул хезмәттә Тукай иҗатына карата ялгыш карашлар, хата фикерләр дә бар. Ләкин анда шәхес бар, шәхеснең кызыклы дөньясы, күзәтүләре, гомумиләштерүләре, ахыр чиктә, бүтәннәр өчен, шул җөмләдән шагыйрьләр өчен, яхшы мәгънәдәге файда бар. Һәрхәлдә, шуңа охшашлы «тере» хезмәтне күргәнем юк әле минем.

Инде халыкчанлык мәсьәләсенә килсәк, бер генә штрихны шәрехләп үтмәкчемен: халыкчанлык катып калган төшенчә түгел, ул да заман белән үзгәрә. Кайчандыр талантлы шәхес тарафыннан тудырылган берәр образ яки канатлы сүз индивидуаль башлангычтан гомумилеккә күчә, ягъни гомумхалык кулланышына керә, халыклаша. Ихтимал, бүген беркадәр сәер яки аңлашылып бетмәгән шигъри күренешләр дә еллар үтү белән аңлашыла төшәр.

**И. Нуруллин.** Язучы, үзенең талантына сокланып, фил сөягеннән ясалган төрбәгә кереп бикләнмәсә, чын-чыннан халык улы булса, халык бәхете өчен көрәшеп яшәү — девизына әйләнсә, аның иҗатында, әлбәттә, «гомумкешелеккә хас мотивлар» булмый калмый.

Укучының зәвыгын тәрбияләүдә, чын шигырьне эрзацтан аерырга өйрәтүдә әдәби тәнкыйтьнең роле турында да, шаять, бәхәсләшмәбез. Татар совет тәнкыйтенең үз өстенә йөкләнгән бурычны үтәү-үтәмәү мәсьәләсе турында безнең сүз булган иде инде. Бу урында тик шуны гына әйтим: талантлы һәм күренекле шагыйрьләребезнең тәнкыйть адресына кайта-кайта ачы сүзләр әйтүе борчылып уйланырга мәҗбүр итә. «Шигырь тәнкыйте» өлкәсендә, күрәсең, эшләр чынлап та шәптән түгел.

Шагыйрьләрне пропагандалауның кирәклеген мин шулай ук инкяр итәргә җыенмыйм. (Чын прозаик һәм драматурглар да моңа мохтаҗ.) Әмма тарихта мондый хәлләр дә булгалаган: халык кайчак, тәнкыйтьне бар дип тә белмәстән, үз шагыйрен үзе табып ала. Мисал эзләп торасы юк: Тукай! Бөек шагыйрь үлгән көнне үк Ф. Әмирхан болай дип язган: «...аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды». Гали Рәхим дә шул фикерне язып чыкты. «Аның халыкка мәгълүм булуы тәнкыйть аркылы булмады... Халык үзенең җырчысын үзе аралап табып алды». Сүз Тукайның интеллигентчыл даирәләргә генә танылуы турында түгел, бәлки революциягә кадәр үк иң караңгы татар авылларына кадәр үтеп керүе хакында бара. Теге яки бу талантлы шагыйрьнең уй-фикер һәм хис-тойгы дөньясы халык күңеленә авазлаш түгел икән, бернинди пропаганда да аңа ярдәм итә алмый!

Сезнең бу сүзләргә җавабыгыз, әлбәттә, әзер: мондый шагыйрьнең, бүген танылмаса да, киләчәктә танылуы мөмкин. («Ихтимал, бүген беркадәр сәер яки аңлашылып бетмәгән шигъри күренешләр дә еллар үтү белән аңлашыла төшәр».) Үз заманында беркемнең дә игътибарын җәлеп итмәгән шагыйрьнең күп еллардан соң данга күмелә алуына шикләнеп карыйм. Киләчәктә танылу «теориясе», минемчә, практик яктан да зарарлы. Формалистик трюклар ярдәмендә булса да күренергә, игътибарны үзенә җәлеп итәргә теләгән шагыйрьгә бу теория гаҗәеп кулай: мине киләчәктә аңларлар!

Бүгенге көн татар совет поэзиясен тагын да югарырак итеп күрергә теләсәм дә, аның уңышларын инкяр итәргә җыенмыйм. Бездә бөтен союз укучысына тәкъдим итәрлек олы фикерле зур шагыйрьләр барлыгына да шигем юк. «Картлар» арасыннан да, яшьләрдән дә, М. Әгъләмов турындагы сүзләрегез белән дә килешәм. Фикер дә бар аңарда, шигърият тә. Чөнки, С. Хәким әйтмешли, «ул традицион стильдә» яза. Дөресрәге, ул җеп очын яшереп маташмый, формалистик күнегүләр белән шөгыльләнми. Димәк, әйтер сүзе, укучыга җиткерергә теләгән фикере бар. Шул шигъри фикернең сыер савучыны гына түгел, бәлки әлеге академикны да баетырлык булып, тагын да тирәнәеп зураюын гына теләргә кала. Моның өчен даһи фикер ияләренең гасырлар буенча тудырган рухи хәзинәсен

үзләштерү белән бергә, тормыш китабын вакыт уздыру өчен түгел, бәлки шул тормышны яхшырту хакына җентекләп укудан башка бүтән юл юк.

Менә без эзләнү мәсьәләсенә әйләнеп кайттык. Бүтән халык укучыларына да танылу өчен, дигән идегез сез, «мәгълүм биеклекләргә ирешкәннәрдән гыйбрәт» алырга, «фикерне үзеңчә әйтү юлларын» эзләргә, «әдәбият арсеналында булган ысулларны» сынарга кирәк. Болары да кирәк, билгеле. Әмма эзләнү дигәннән шуны гына аңласа, шагыйрьнең эше хәтәр. Эзләнү ул, минемчә, беренче чиратта, шагыйрьнең үзен, үзенең тормыштагы, көрәштәге урынын эзләү. Эзләнү ул — җәмгыятьнең катлаулы, каршылыклы үсешен аңларга тырышу, тормышта нәрсә туа, нәрсә үлә, «яңа» дигәннең кайсысы уңай яңалык, кайсысы социалистик яшәү принципларына туры килми — шуларны тотып алырга, мәгънәсенә үтеп керергә омтылу.

Монысы булмаганда, форма өлкәсендәге эзләнү белән генә ерак китеп булмас.

**Р. Фәйзуллин.** Диалогыбызны тагын бер кат күңелдән кичергәч, бер бик гади сорау туды: Сез бүгенге шагыйрьләрдән кемнәрне укыйсыз соң? (Сүз укыйсы килеп укыла торган кешеләр турында бара.) Һәм аларда нинди уңай һәм җитешмәгән яклар күрәсез? Әңгәмәнең башында ук Сез мине «аңлаешсыз» поэзиягә шактый өлеш керткән» кеше дип әйттегез. Шактый сәер һәм уйландыра торган бәя бу. Шул уңайдан тагын берничә сорау: «аңлаешсыз» поэзия тарафдарларына тагын Сез кемнәрне кертәсез? «Аңлаешлы» поэзия вәкилләре итеп кемнәрне таныйсыз? Әйтик, урта һәм яшьрәк буын шагыйрьләреннән?

**И. Нуруллин.** Вакыт сыйдырган кадәр күбесен күздән кичерергә тырышам. Әмма безнең максат минем симпатия һәм антипатияләрне ачыклау булмаса кирәк.

Инде Сезгә килсәк, «аңлаешсыз» поэзиягә күпмедер өлеш керттегез» дип әйткәнмен икән, кайбер башлангыч шигырьләрегезне һәм «Нюанслар иле»н генә күздә тоткан идем. «Ирекле» һәм «ак» шигъриятегез белән дә мин Сезне, тулаем алганда, «аңлаешлылык» тарафдары итеп карыйм.

Рәшит Әхмәтҗанов исә традицион «классик» стильдә генә яза, халык иҗатын да мул куллана. Менә аның «Яшьрен сөйсәң дә...» дип башланган шигыренең беренче һәм дүртенче (соңгы) строфасы:

Яшьрен сөйсәң дә, сөюне
Ай күрә, Кояш ала.
Ала да давылга бирә,
Давыл дәрьяга сала...

Аңладыгызмы берәр нәрсә? Уртадагы ике строфа да ачыклык кертми, киресенчә, аптыраулы сорауларны гына арттыра, һәрхәлдә, мин берни аңлый алмадым, һәм, гомумән, шушы шигырьне эченә алган «Ак канатлар» китабында шигъри ребуслар тулып ята. «Тагын кемнәр?» дип, якадан алып сорамасагыз иде. Фикеремне ачык әйттем, шигырь сөючеләр дә, шагыйрьләр дә кемнәр турында сүз барганны, шаять, чамалыйдыр.

Инде минем дә Сезгә бер сорау бирәсем килә. Безнең поэзиябезнең торышы, барышы һәм киләчәге мәсьәләсе Сезнең күңелгә, әлбәттә, тагын да якынрак. Бу турыда мин фәкыйрегез белән чагыштырганда күбрәк уйланасыз, шагыйрь буларак та уйланасыздыр. Әллә ничаклы күзәтүләрегез, утырган фикерләрегез бардыр. Татар поэзиясенең, шул исәптән «яшь поэзия»нең бүгенге хәле, үсеш тенденциясе һәм перспективасы турында ничек уйлыйсыз?

**Р. Фәйзуллин.** Дөресен әйткәндә, «яшь поэзия» төшенчәсе миңа бик үк аңлашылып бетми. «Яшь» яки «карт» поэзия юк ул, бер генә поэзия бар, бер генә шигърият. Яшәлгән гомерләре буенча яшьрәк иптәшләр турында сүз бара дип уйлыйм. Яшьләр турында сөйләшү, ул киләчәк турында сөйләшү дигән сүз. Ә киләчәк турында матур сөйлисе килә. Ләкин матур сөйләү өчен ныклы җирлек, какшамас ышанычың булуы кирәк. Биредә байтак исемнәрне санап китәргә мөмкин булыр иде, хикмәт санауда гына түгел. Яшьләре белән утыз тирәсендә булган бер төркем шактый кызыклы шагыйрьләр бар. Ә унсигез-егерме яшьлек Тукайлар, Бабичлар кебек кабынган йолдызлар күренми. Ә утыз яшьлек шагыйрь яшь шагыйрь түгел. Күренәсе талант бу яшькә хәтле күренә инде ул.

Яшь әдәби көчләрне үстерү язучылар җәмәгатьчелегенең һәрвакыт игътибар үзәгендә булып килде. Үткәргән семинарларның исәбенә чыгу да мөмкин түгелдер. Язучылар союзы оештырган киңәш-семинарларда егермеләп мәртәбә катнашкан «яшь язучы» иптәшләр бар. Ә мәгънә? Яшь көчләр, үсәр өчен, канатланыр өчен, әсәр бастырырга тиеш. Матбугатта чыгу — үсүгә этәргеч бирүче иң зур фактор. Әдәби мәйданыбызның шактый тар булуы яшьләрнең әдәбиятка мулрак килүен тоткарлый, әлбәттә. «Идел» альманахы даими чыга торган журналга әверелгәч (моңа безнең ышаныч зур), хәл беркадәр яхшырыр дип уйлыйбыз. Яшь иҗат көчләре турында КПСС ҮК кабул иткән мәгълүм карар да яшьләр белән ныграк эшләүне таләп итә бит. Ләкин яшьрәк иптәшләр шуны онытмаска тиешләр: бу зур карар һәр яшь иҗатчыга зур җаваплылык та өсти, әдип исемен югары йөртергә чакыра.

Эзләнү турында өстәп әйткән сүзләрегезнең бөтенесе белән диярлек килешәм. Иҗат кешеләре арасында «туу» төшенчәсе бар. Яңа әсәр туды, яңа шигырь туды, җыр туды һ.б. Йә, кайсы аны яңалык ачам дип, теге яки бу принципка туры китерәм дип тудыра икән? Иҗат итү процессы, гомумән, художество талантының табигате турында, кызганычка каршы, без бик аз беләбез. Бу — әдәбият фәненең, гомумән сәнгатьнең иң өйрәнелмәгән өлкәсе. Иҗат процессының кайбер серләрен киләчәктә философлар, психологлар ачарлар әле дип уйлыйк.

Бу урында тагы шуны да искәртеп үтик: яшь шагыйрьләр халык поэтикасының күркәм традицияләрен кирәк дәрәҗәдә үзләштерсеннәр, үстерсеннәр өчен, алар бу юнәлештә билгеле бер мәктәп тә үтәргә тиештер бит. Икенче төрле әйткәндә, әдәби мираска кул җитәрлек шартлар кирәк. Борынгы дәвер авторлары, игътибарга лаек прогрессив мирас калдырганнары, әлбәттә, күбрәк басылырга тиеш. Соңгы ун-унбиш елда борынгы әдәбият үрнәкләрен дөньяга чыгару эше бераз сүлпәнәя төште кебек.

Әңгәмә барышында шуны да хәтердән чыгармаска иде: без, эталон рәвешендәрәк, «Тукай — халык шагыйре» (шагыйрь белән халык арасындагы идеаль аңлашу мәгънәсендә) дип белдерәбез. Ә бит XX йөз башындагы «халык» төшенчәсе белән XX гасыр ахырындагы «халык» төшенчәсе арасында аерма да бик зур. Уртак яшәеш рәвешендә совет халкы дигән төшенчә барлыкка килде. Милләтләр үзара бик нык якынайды. Замана бөтенләй бүтән. Тукай кебек бул дип әйтү җиңел, ә бүгенге заман Тукае нинди булырга тиеш? Менә монысына җавап табуы авыр. Кайчакта без эстетик казанышларны бәяләгәндә иске акча белән алыш-биреш иткәндәге хәлдәрәк калмыйбыз микән? Ә курс күптән алышынган...

Инде конкрет бүгенге поэзиягә килик. Бер сорау: Сез бүгенге шагыйрьләрнең тематик диапазонын (күтәрелгән проблемалар һ.б.) ничегрәк характерлыйсыз? Бу юнәлештә, бүтән халык шагыйрьләренә нисбәттә, Сезнеңчә, бездә хәл ничегрәк?

**И. Нуруллин.** Поэзия өлкәсендә специальләшкән тәнкыйтьче бу сорауга, ихтимал, азмы-күпме тулы җавап бирә алыр иде. Мин исә гомуми тәэссоратым белән генә уртаклаша алам. Татар совет поэзиясе, тулаем алганда һәм үзенең иң яхшы вәкилләрен күздә тотканда, минемчә, заман белән бергә атлап бара. Әмма тынычланырга урын юк. Поэзиянең кулы тимәгән күренешләр әле байтак булса кирәк.

«Яшь» поэзиядән бер мисал китерим. Игътибар иткәнегез бар микән: безнең поэзияне берара сугышка каршы көрәш темасы басып китте. Принципта бу начар түгел. Әмма шунысы сәер: андый шигырьләрне күбрәк, үзе сугыш ялкынында көеп чыккан шагыйрьләр түгел, бәлки сугыштан соң туганнар яза иде. Димәк, бу буын шагыйрьләренең (барысының да димим) үз заманы, үз чордашлары турында әйтер сүзләре җитенкерәмәгән.

Тагын бер күзәтүем белән уртаклашыйм. Ни өчендер соңгы вакытларда «сюжетлы» шигырьләр кимеде, һәрбер шагыйрь — һәм олысы, һәм кечесе — үзен тәкъдим итәргә, үзенең уй-фикер хәзинәсен укучыга тагарга тырыша. Ярый ла ул кызыклы шәхес булса, хәзинәсендә игътибарга лаеклы «энҗеләр» табылса... Некрасов поэзиясе, мәгълүм булганча, «сюжетлы» шигырьләрдән тора диярлек. Пушкин белән Лермонтов та андыйлардан качмаганнар, ә Маяковский, Исаковский, Твардовский, Дм. Кедрин, Такташ, Туфан, С. Хәким? Теләсәләр, безнең яшьләр дә андый шигырьләрне яза алырлар иде. Зөлфәтнең «Мәхәббәт» исемле көчле шигырен хәтерлик.

«Халыкчанлык» төшенчәсенең заманнан заманга үзгәрә баруы турындагы фикерегез белән килешәм. Шулай да шигърияттә халыкчанлыкның әһәмиятенә бәя биреп җиткермисез кебек тоела. Әйе, «совет халкы дигән төшенчә барлыкка килде, милләтләр үзара бик якынайды». Бу — дөрес. Ләкин бит сез ни өчендер татарча язасыз. Вл. Солоухин — рус телендә, Р. Гамзатов — аварча. Берсе дә эсперанто кебегрәк телне кирәксенми бугай.

**Р. Фәйзуллин.** Әйе, сюжетлы шигырьләребез кими төште шикелле. Бу тенденцияне ничек аңларга, ничек бәяләргә? Бәхәссез, сюжетка корылган, тиешле художество таләпләренә җавап бирерлек әсәрләр күбрәк булырга тиеш. Шулай ук 50 нче еллардагыча, вакыйганы коры сөйләп чыгуга, тасвирчылыкка корылган әсәрләргә дә кире кайту ихтыяҗы юктыр. Ул елларда су буе хәтле нинди генә озын-озын язмалар сырламады безнең агайлар!.. Заманнар үтү белән, әлбәттә, укучы ялыкты андый язмалардан, йөз чөерде андый «сюжетлардан». Халык тормышындагы рухи үзгәрешләр белән бергә фикергә сусау артты, драматик хискә, кешелеклелеккә... Шуңа күрә дә 60—70 нче еллар поэзиясе тасвирчылыктан, вакыйга сөйләүдән нык арынды... Әмма икенче чиккә ташланды — артык рациональләнде, артык акыллыланды, фәлсәфиләнде.

Сюжетлы шигырьләр турында сөйләгәндә, бүгенге шигъриятнең тагын бер характерлы моментын да искәртеп узарга кирәк дип беләм: һәр чын шигырьнең үз сюжеты да бар бит әле! Традицион мәгънәдә аңлашыла торган сюжет түгел — эчке, фикер сюжеты дип әйтимме... Фикер агышының поэтика фәне билгеләгән кануннарга сыеп бетә алмау хикмәтләре бар шул!

Инде поэмаларга килик.

Поэма хакында әдәбиятчылар күптәннән бәхәсләшәләр, ләкин бер төгәл фикергә килгәннәре юк, ихтимал, килә дә алмаслар... Чөнки яңа әдәби күренешләрнең әледән-әле хасил булып торуы да ниндидер бер тотрыклы нәтиҗәгә килергә ирек бирми. Әйтик, күптән түгел генә Р. Харисның «Рәссам» исемле әсәре басылды. Поэмамы бу, юкмы? Кистереп әйтү кыен. И. Юзеевның «Таш диварлар авазы» поэмамы, юкмы? Яки үземнең «Көрәшчеләр» нәрсә? Публицистик диалогмы яки шигъриятнең бүтән төреме? Кыскасы, хәзер безне поэманың классик төшенчәсе канәгатьләндереп бетерми, ә яңа формалары турында фикер туплап бетерә алганыбыз юк. Шулай да һәрбер шагыйрьдә кайбер шәхси күзәтүләр бар дип беләм. Шул исәптән минем дә. Мәсәлән, заманында чын поэма рәвешендә кабул ителгән «Таныш моңнар» кебек әсәрләр искерде. И. Юзеев моны үзе дә аңлый булса кирәк, шуңа күрәдер ул бүтән формадагы күләмле әсәрләр яза башлады. Кызганычка каршы, кайчак шулай да була: автор үзе эзләнүләрендә инде әллә кая алга киткән була, ә кемнәрнеңдер аңында фәлән жанрның, бу очракта поэманың, гәүдәләнеше булып әлеге искерә төшкән әсәр кала. Бу — бер. Икенчедән, соңгы вакытта яңарак төр поэмалар белән беррәттән, берише шагыйрьләр билгеле бер эзлекле композициясе булган яхшы шигъри цикллар белән чыгыш ясый башладылар. Ул цикллар, гадәттә, яхшы укыла, чөнки алар фикри яктан тыгызрак һәм мәгънәлерәк була, өстәвенә алар кыска һәм табигый (поэмада, телисеңме-теләмисеңме, жанрның классик кануннарын үтәү беркадәр ясалмалыкка китерә). Ясалмарак поэмаларга караганда, төзек шигырь цикллары күбрәк ошый төшә миңа. Гәрчә андый шигырь циклларына караганда, поэманың теләсә кайсына, хәтта беркадәр йомшагракларына да тәнкыйтьчеләр игътибарлырак. Күрәсең, күләмлерәк жанрлар күбрәк булган саен, әдәбият зуррак була дип наив аңлаудан киләдер бусы. Гомумән, поэма турында сөйләшү зур әзерлек һәм тәҗрибә сорый. Бу хакта С. Хәким, С. Баттал, И. Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Мингалимов, Ә. Баянов, М. Шабаев, Р. Харисов һ.б. иптәшләр үзләренең уй-фикерләре белән уртаклашсалар, әлбәттә, кызыклы булыр иде, мәсьәләгә беркадәр ачыклык керер иде.

Ә шигъриятнең тематик киңлеге, күтәрелгән темаларның актуальлеге һәм зурлыгы мәсьәләләренә килгәндә, «белеп язу», «белгәнне язу» турындагы фикерләрегез белән тулысынча килешәм. Бу бик мөһим, һәр сәнгатьнең төбендә ята торган нәрсә дип беләм. Тормышны белмичә, дөресрәге, тиешенчә белмичә, аны тагын да яхшырту турында авыз ачу да мөмкин түгелдер. Шагыйрь кешегә тормышны прозаик кебек белмәсә дә ярый дигәнрәк фикер дә яшәп килә. Бу — дөрес фикер түгел. Ихтимал, шагыйрьгә күбрәк тә белү кирәктер әле, чөнки ул кыска формада — яшәешнең асылы турында, «төше» турында әйтергә тели. Һәр әдипнең үз белгәне, үз мөмкинлеге, үз зарурлыгы, үз кирәклеге бар. Талантка җәмгыятьнең таләбе дә әнә шуларга бәйле рәвештә ташламасыз һәм каты булырга тиеш. Табигатьтән бирелгәнне талант дөрес юнәлештә һәм кирәккә сарыф итәме? Ул үзенең тиешле рухи биеклегендәме? Монда үзеннән-үзе шагыйрьнең гражданлык йөзе, гражданлык сыйфатлары мәсьәләсе килеп баса. Шагыйрь, гомумән әдип, асылда, үзеннән кача алмый. Шигърияттә маска белән яшәп булмый. Шагыйрь үзенең күңелен, йөрәген — яралымы ул яки саумы, барыбер — бүтәннәргә курыкмыйча, яшермичә ачып сала алуы белән шагыйрь дә инде! Тикмәгә генә шагыйрьнең фидакарьлеген аның ихласлылыгы белән бергә бәйләп карамыйбыз бит! «Актер» шагыйрьләрне танымыйм. Шигърият уен аренасы түгел. Тукай әйтмешли, «кирәк түгел мәгънәсе юк көлке уен!» Куян йөрәкле булып та, арыслан авазы чыгарырга азапланучылар очрый. Андый хәлдәгеләр көлке һәм кызганыч, әлбәттә. Шагыйрьнең гражданлыгы минем өчен шул: үз өстеңә, үз өлешеңә тигәнне авырсынмый күтәрә алу. Ә халык кадәр халыкның үзенең талантлы уллары күтәрергә тиеш йөге һәрчак була. Авыры да, җиңеле дә. Кайчак бездә шулай да килеп чыга: шагыйрь космик мәшәкатьләр өчен шулкадәр борчыла, дөньяның әллә кайсы кыйтгаларындагы ташларны «елата», ә үзе йөри торган сукмактагы каны саркып яткан ташны күрә алмый яки күрергә теләми... Шунысы сәер, халыкара вакыйгаларның берәр эффектлырагы турында берәр газетада хәбәр укып, шул ук хәбәр турында шул ук газетада берәр риторик «шигъри» чыгыш ясаса, кайберәүләр шундук үзенә зур гражданин шагыйрь исемен дәгъвалыйлар. Күрәсезме, янәсе, бөтен дөнья гаме йөрәгем аша уза минем! Андыйларга ышанмыйм мин. Бар, күр, бел, аннан инде күргәнеңә мөнәсәбәтеңне белдер, кирәк булса сөрән сал, кычкыр, өндә, халыкларны күтәр!.. Зур мөмкинлегең (һәм субъектив, һәм объектив яктан) юк икән, үз биеклегеңнән үз белгәнеңне яз! Камыр кыңгырау кагарга яратучыларга караганда, С. Хәким кебек, артык кычкырмый-нитми генә халык гамен кайгыртып йөрүче затлар күбрәк ошый миңа. Шагыйрьнең гражданлыгы, егетлеге һ.б. турында Сезнең дә фикерләрне ишетү яхшы булыр иде.

Кем нинди телдә яза һ.б. мәсьәләләргә килсәк, мин, әлбәттә, татар телендә язам. Чөнки белгән (анысы да чагыштырмача) бердәнбер телем ул. Әлбәттә, беренче чиратта үз халкым өчен язам. Ә менә ул халыкның укучысы бик чуар. Төрле телле бит. Менә эш нәрсәдә! Үз телеңдә язу гаҗәп түгел, авыр да түгел, ә язганыңны үз халкың вәкилләренә җиткезү кыен хәзер. Сүз монда шөһрәт яулау турында бармый, үз эшеңнең табигый нәтиҗәсе турында уйлану, борчылу турында бара. Туган телләрен белмәгән ватандашлар күпме хәзер! Мисалга ерак барасы түгел: әле Казанда, үз тирәмдә, миңа дустанә мөнәсәбәттә булган байтак яхшы кешеләрне беләм. Аларның күбесе белемле, заманның катлаулы һөнәрләрен үзләштергән, саф күңелле кешеләр. Татар сәнгате белән кызыксыналар,

аның үсүен телиләр, уртак эстетик казанышларда безнең өлешне дә күрәселәре килә. Шул исәптән бүтән халыклар да сокланырлык шагыйрьләребез турында хыялланалар. Ә үзләре, күп очракта, нихәтле генә парадокс булмасын, шигъриятнең бөтен нечкәлекләрен аңларлык дәрәҗәдә ана телен белмиләр. Дәрт бар, дәрман юк шикеллерәк килеп чыга. Алар безнең иҗат белән фәкать тәрҗемә аша гына таныша алалар. Бу әле Казанда шулай, ә бүтән республикаларда яшәүчеләр нишли? Кыскасы, укучыларыбызның шактый зур бер интеллектуаль контингенты татар шигырен (ул үзе аны үзебезнең татар шагыйрен укыйм дип атый) рус телендә укый, бәяли, горурлана, тәнкыйтьли... Йә, хуш, хөрмәтле шагыйребез бу очракта нишләргә тиеш? Яхшы шигырь ул сыер савучыга да, академикка да бер чама аңлашыла дип тынычланып торырга тиешме? Юк! Шагыйрь кеше, гомумән, һәр әдип, югарыда искә алынган укучылар турында да нык уйланырга һәм истә тотарга тиештер. Авылдагы бер катлам укучылар контингенты белән генә чикләнергә ярамый, минемчә. Ихтимал, тора-бара аның да күпмедер өлеше әле югарыда әйтеп үтелгән категориягә күчүе мөмкин.

**И. Нуруллин.** Поэзиянең принципиаль мәсьәләләренә нисбәтән бер үк караштa торуыбыз, билгеле, мине шатландыра. Шагыйрьнең гражданлыгы, намуслылыгы, иманы ныклыгы, принципиальлеге, «үз йөген» күтәрүдәге чыдамлылыгы, «егетлеге» турындагы фикерләрегезгә рәхәтләнеп кул куям.

Сез тагын минем өчен кадерле булган һәм студентларыма күп еллар буе тукып килә торган бер фикеремне, авызымнан алып дигәндәй, әйтеп бирдегез. Әйе, шагыйрь, әйтик, прозаиктан ким белмәскә, бәлки әле күбрәк тә белергә тиеш! Берәү кул арбасына салып йөк илтә, икенчесе — үз җилкәсендә. Йөкләрнең авырлыгы тигез булсын өчен соңгысының икеләтә-өчләтә көчле булуы кирәк түгелме? Әнә шуның шикелле, прозаик, типик характерлар иҗат итеп һәм аларны үзара тормышчанрак мөнәсәбәткә куеп, тормышның берәр ягын үзе аңлаганга караганда тирәнрәк итеп ачып бирергә мөмкин (әдәбият тарихында андый очраклар еш булган). Шагыйрьгә исә мондый мөмкинлек бирелмәгән. Ул үз исеменнән сөйли. Дөнья турында дөрес һәм тирән фикер әйтү өчен, аңа, димәк, тойгыхис үткенлегеннән тыш, гаять зур акыл көче, фикерләү куәте һәм тирән белем кирәк.

Шул уңайдан яңадан өйрәнү һәм эзләнү мәсьәләсенә кайтмый булмый. Бөек фикер ияләренең идеяләре яктылыгында тормыш китабын җентекләп уку — өйрәнү һәм эзләнүнең төп юнәлеше дигән фикерне әйткән идем бугай. Тормыш китабы... Нәрсә бу? Шагыйрь, минемчә, барыннан да элек, үз даирәсен, үз төбәген, үз халкын энәсеннән җебенә кадәр яхшы белергә тиеш. Юк, бу милли чикләнү дә түгел, бүтәннәрне өйрәнүнең кирәклеген дә юкка чыгармый. Бит Җирне аңлау өчен Айга баралар, Марс яисә Венерага космик аппаратлар җибәрәләр. Башка халыклар белән танышмыйча, үзеңне дә аңлап булмый.

Ярый, шагыйрь фикер иясе дәрәҗәсенә күтәрелде ди, үз төбәген биш бармагы кебек белә ди. Соң, ул әйтергә теләгәнен ничек, нинди алым һәм чаралар ярдәмендә җиткерергә тиеш? Без форма өлкәсендә эзләнү мәсьәләсенә килдек. Фикер булсын, эчтәлек булсын, шуңа лаеклы форма үзеннәнүзе табыла диючеләр белән мин килешмәс идем. Форманы да эзләргә кирәк. Биредә дә халык поэзиясе, Кол Гали, М. Колый, Тукай, Такташ һәм Туфаннар традициясеннән үсеп чыга торган үз стилеңне булдыру, ачыклау өчен син планетаның күп гасырлар дәвамында яшәгән бөек шагыйрьләренең тәҗрибәсен өйрәнергә тиешсең. Шул исәптән хәтта модернизм һәм башка шайтанизм шагыйрьләренекен дә.

Әмма хикмәт шунда: нәрсәне алырга һәм нәрсәне кире кагарга?

Модернизм шагыйрьләренең иҗат принциплары, белмим, безнең поэзия өчен кулай була алырмы? Бит модернист ул — үтә чыккан индивидуалист. Аның уй-фикер һәм хис-тойгылары үтә субъектив. Менә ни өчен аның шигырьләре саташып сөйләшүне хәтерләтә.

Модернист шагыйрьнең уй-хис дөньясы һәм поэтикасы белән укучыларның киң катлавы арасында авааздашлык була алмавын исбат итеп торасы юк дип беләм.

Рус совет поэзиясендә, бүтән халыклар, шул исәптән татар совет поэзиясендә бер төркем шагыйрьләр катлауландырып яза башлап, аерым алганда үтә «ассоциатив» шигырьләр ярдәмендә новаторлыкка дәгъва итәләр. Юк, мин аларны модернистлар димим. Күбесенең «оригинальлеге» модернистлардан арткан киемгә төренүләрендә генә димәкче булам. Әңгәмәбезнең башында «аңлаешсыз» шигырьләр дигәндә, мин нәкъ менә шуны күздә тоткан идем.

Поэтик фикерең зур икән һәм поэтик формаң укучының кабул итү аппараты белән принципта каршылыкка керми икән, сине һәркем (гомумән, берни укымаучылар турында сүз бармый) укыячак, ләззәт алачак, аның эстетик зәвыгы үсәчәк. Үз ана телендә сөйләшми һәм укымый башлаган милләттәшләребезнең игътибарын җәлеп итәр өчен дә шуннан бүтән юл юк.

**Р. Фәйзуллин.** Сез, «хикмәт шунда: нәрсәне алырга һәм нәрсәне кире кагарга?» дисез. Чыннан да, нәрсәне алырга, нәрсәне кире кагарга соң? Бу очракта шагыйрьләргә поэзия тәнкыйтьчеләре дә ярдәмгә килергә тиеш. Иҗат эше — тудыру эше, иҗади экстаз вакытында шагыйрь үз язганы турында объектив ук фикер йөртә алмаска да мөмкин. Нәрсәне кире кагарга (монда мин идея-эчтәлек-

тән бигрәк, форма турында әйтәм)? Әгәр безнең бәхәскә (әңгәмәгә) кушылучылар табылса, алар дәвам итәрләр дип уйлыйм. Шулай да эзләнүчеләр турында берничә авыз сүз.

Нигә дип без әле модернизм шагыйрьләренең иҗат принциплары турында сөйләшәбез? Бүгенге татар поэзиясе алдында шундый куркыныч бармыни? Кемнәр алар «модернистлардан арткан киемгә төренүчеләр»? Р. Харисмы, Р. Мингалимовмы, Роберт яисә Рәшит Әхмәтҗановлармы, Р. Фәйзуллинмы, Р. Гатауллинмы? Миңа калса, бүгенге татар поэзиясендә эзләнүчеләргә караганда, эзләнергә теләмәүче, үз-үзләреннән канәгать, шома һәм буш, тук һәм мәгънәсез шигырь язучы тезмәчеләр хәвефлерәк. Уйлап карыйк: Сез уйлаганча, «аңлашылмый» торган шигырьләр, әйтик, бер елга күпме чыга икән? Китап нәшрияты чыгарган җыентыкларны карыйк, газета-журнал битләрендә басылган шигырьләрне барлап чыгыйк. Уртача әзерлекле укучы өчен аңлашылмаган уннан артык шигырь табылыр микән? Ышанып әйтәм, «аңлашылмый» торган шигырьләргә караганда, бернинди аңлау да кирәк булмаган буш шигырьләр ун, йөз мәртәбә күбрәк. Әлбәттә, аңлашылмый торган шигырьләр кирәк дип әйтергә теләмим. Күбрәк эзләнү кирәк дим, ә ул исә шома гына бармый, брак та булгалый, ләкин аңа карап эзләнү туктарга тиеш түгел. Фәкать эзләнү генә кызыклы ачышларга китерергә мөмкин.

Ә ассоциатив фикерләргә корылган шигырьләргә килгәндә, минемчә, монда бәхәсләшер нәрсә юк. Ассоциация — ул бер чара. Ул чара борынгыдан актив кулланылышта булган. Шул ук дүртьюллык халык җырларын алыйк. Беренче карашка, бернинди уртаклыгы күренмәгән беренче ике юл белән соңгы ике юл арасында күп очракта ниндидер бер эчке бәйләнеш була. Ул эчке ассоциатив бәйләнешне тояр өчен күңелең бай булу гына кирәк. Әгәр бүгенге шагыйрьләр борынгыдан килгән бу алымны профессиональ иҗатта тулырак мөмкинлекләре белән файдаланалар икән, моннан поэзия байый гына.

**И. Нуруллин.** Бездә, билгеле, модернистлар юк. Чөнки модернизм иҗтимагый идеалларга кул селтәп, үз «мин»еңне бердәнбер реальлек итеп санап, шул «мин» хакына гына яшәүдән башлана. Модернистларның формаль казанышларын тәнкыйтьсез кабул итеп «ультра-яңа» чаралар ярдәмендә оригиналь булырга тырышучылар, әлбәттә, бар. Бу очракта мин А. Вознесенский һәм Б. Ахмадулина тибындагы шагыйрьләрне күздә тоткан идем. Моның кайбер чалымнары бездә дә булганлыгын искәрттем бугай.

Дөрес әйтәсез, «аңлаешлы» шигырьләр бездә чагыштыргысыз күп басыла, һәм аларның күпмедер өлешенең («күпмедер» дим, чөнки кем санаган?) дөньяга чыкмавы хәерлерәк булыр иде. Үтә «ассоциатив», ягъни кроссворд тибындагы шигырьләрне яклаганда әнә шундый урта кул, хәтта начар шигырьләргә сылтану беркадәр «тыелган алым» түгелме? Аларны чын мәгънәсендә халыкчан һәм югары художестволы шигырьләр белән янәшә куеп карарга кирәк. Шунда кемнең кемлеге ачыкланыр.

Ассоциативлык уңае белән халык җырларын бик урынлы искә төшердегез. Мондый җырларны да башлап кемдер чыгарган. Ул үз күңелендә, хыялында туган ассоциацияләрне җырга кертеп җибәргән. Бу ассоциация бүтәннәр күңелендә аваздаш булса, җырны эләктереп алганнар да башкару процессында тагын да камилләштергәннәр. Ә инде аваздашлык тапмаган ассоциацияләр кабул ителмәгән андый җырлар онытылган. Халык шагыйрьләренең дә бит төрлесе булган: талантлысы, таланты чамалысы, халыкча уйлаучы һәм хис итүчесе, халыктан аерыла төшкәне.

Без бүген халык җырларының әнә шундый «сайлап алынганнары» белән генә эш итәбез. (Җыентыклардагы бик күп примитив җырлар исәпкә керми. Чөнки аларның күбесен, әйтик, очраклы авторлар чыгарган, һәм безнең фольклорчылар язып алган.) Аларда исә чын мәгънәсендәге халыкчан ассоциативлык. Бүгенге шагыйрь шул традицияне үстереп китә икән, аңа карата мактаудан бүтән сүз әйтеп булмый. Ә инде иҗтимагый мәсьәләләрне йөрәгенә бик үк якын алмый торган шагыйрь үзенең артык һәм субъектив ассоциацияләрен шигырьгә тутырса, яки оригинальлеккә дәгъва итә торган ассоциацияләрне гакыл белән уйлап чыгарса, мондый шигырьләр, белмим, киң катлау укучыда аваздашлык таба алырмы?

Минем теләк бер генә: шагыйрьләр «яхшы һәм төрле» булсын. Индивидуаль йөзләрен чагылдыра торган теләсә нинди поэтик чара куллансыннар, тик шигырьләре ниндидер элита өчен генә язылмасын. Китап укый торган барлык кешеләрнең дә күңеленә һәм акылына азык бирердәй булсыннар. Хәтта укымаучыларны да укырга мәҗбүр итсеннәр.

Нокта куярга вакыт түгел микән инде безгә, Равил? Әңгәмә байтакка сузылды, күп кенә уртак нокталар ачыкланды. Барлык мәсьәләләр буенча да бер фикергә килү, минем Сезне, Сезнең исә мине үз «иманыбызга» китерү турында уйлау утопия булыр иде. Әйдә, кайбер мәсьәләләрне укучыларга, бүтән белгечләргә һәм Вакыт исемле хакимгә калдырыйк.

**Р. Фәйзуллин.** Шартлы рәвештә генә булса да, нокта куярга мин дә каршы түгел. Ихтимал, хатлашу тәртибендә алып барылган һәм бераз озаккарак сузылган бу әңгәмәнең, полемика сәнгате күзлегеннән караганда, кайбер кимчелекләре булу ихтималына карамастан, поэзия белән якыннан кызыксынган кешеләр өчен, уйлану тәртибендә генә булса да, беркадәр файдасы булыр дип ышанам.

Сөйләшкәннәрне бер кат күздән кичергәннән соң, кайбер конкрет күзәтүләр һәм нәтиҗәләрдән тыш, бер нәрсә ачыклана: бүгенге татар поэзиясе турында ныклап һәм җитди рәвештә сөйләшергә вакыт җиткән икән. Аның бүгенге үсеш дәрәҗәсе һәм үсү перспективалары шуны таләп итә дә. Без сүзебезнең башында ук, асылда лирик поэзия турында сөйләшүне күздә тотсак та, бәхәс процессында беркадәр поэзиябезнең бүтән мәсьәләләренә дә кагылып-кагылып алдык. Бу — табигый. Поэзиядә партиялелек һәм халыкчанлык, традицияләр дәвамы һәм новаторлык кебек зур һәм принципиаль мәсьәләләр белән беррәттән, әдәби процесска кагылышлы кайбер бүтән практик моментларны телгә алуыбыз белән мин шәхсән беркадәр канәгать. Ләкин тулысынча түгел. Шагыйрь — Тәнкыйтьче — Укучы турында, ихтимал, нәтиҗәлерәк сөйләшү дә мөмкин булган булыр иде. Минемчә, бу өч инстанция арасындагы бәйләнеш принципиаль мөһим. Безнең көндәлек тормышта нәкъ шул «өч нарат» арасындагы реаль мөнәсәбәт бик катлаулы һәм буталчык. Кызганычка каршы, кайчак шигырьләрнең реаль кыйммәте шактый дәвамлы вакыт берәмлеге узгач кына ачыклана, бәяләнә. Нәрсә яхшы, нәрсә начар икәнне бүген үк активрак ачыклый алганда да әдәбиятыбыз ота төшәр иде. Җыр, поэзия — үзенең табигате белән нечкә, нәфис, яклауга мохтаҗ, хәтта, әйтер идем, беркадәр яхшы мәгънәдәге «сылу зәгыйфь» жанр. Ул дөрес аңлашылсын һәм бәяләнсен өчен бик мөһим тагын бер шартның саклануы зарур: шагыйрьнең талантлы булуы белән бергә, укучының да, укучы буларак, талантлы булуы кирәк. (Бу хакта без аз сөйлибез, аз язабыз. Моннан ун еллар чамасы элек «Казан утлары»нда Аяз Гыйләҗевнең «Син үзең кем, укучы?» дигән чыгышы гына хәтердә калган.) Әмма аннан да бигрәк, шагыйрь белән укучы арасындагы тәнкыйтьченең роле әдәби процесста һаман тиешле югарылыкта түгел, минемчә. Гадәттә ул шактый артта... Ә киң катлау укучыларга поэзияне, гомумән әдәбиятны төп аңлатучы алар булырга тиеш бит! Аларның катнашы белән теге яки бу әдәби чор яки әдәби күренешләр, шәхесләр турында әдәбият дәреслекләренә, методик кулланмаларга, вуз программаларына һ.б. кертеләләр. Бу — мәсьәләгә үтә җаваплы килүне, объектив булуны һәм поэзиянең үзен дә нык белүне, аңлауны сорый торган зур миссия. Мәсәлән, бер генә мисал китереп узыйк. «Татарстан тарихы» дигән фундаменталь хезмәттә республикада культура үсешенә багышланган бүлекнең (1945—1965) шагыйрьләр хакындагы өлешен укып китик. «Крупный вклад в послевоенную татарскую поэзию внесли своими произведениями поэт-песенник А. Ерикеев, поэты А. Исхак, Ш. Маннур, М. Садри, Н. Арсланов, З. Нури, Ш. Мударрис». (Казан, 1968, 668 бит.) Дөрес язылмаган дип әйтеп булмый. Әмма 70 нче еллар урталарына кадәрге дәвердә югарыда саналган иптәшләр кебек үк (бәлки, кайберләре күбрәктер дә) Г. Афзал, С. Баттал, З. Мансур, Б. Рәхмәт, Ш. Галиев, И. Юзеев, Х. Камалов һ.б. поэзиябез үсешенә өлеш кертмәделәрмени? Мондый характердагы берьяклылык «История советской литературы» (Москва, «Наука» нәшрияты, 1965) һ.б. хезмәтләргә дә хас түгел дип әйтеп булмый. Әдәбият дәреслекләрендә дә бүгенге көн татар әдәбиятына караган бүлекләр (һәм шулай ук элегрәк чорларга караган бүлекләр дә), һичшиксез, яңадан каралырга, тулыландырылырга тиеш. Бу — беренче чиратта әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр (алар, башлыча, шул фәнни хезмәтләрнең һәм дәреслекләрнең авторлары да) эше.

Сүземнең ахырында поэтикага караган тагын бер нәрсә турында әйтеп узарга телим. Бездә соңгы ун-унбиш ел эчендә поэзиябезнең үсеш нисбәтендә, шигырьне өйрәнү фәне дә беркадәр җанлана төште. Ләкин бу хезмәтләр хәзергә, Н. Юзиевның, Х. Курбатовның кайбер хезмәтләрен искә алмаганда, башлыча шигырьнең җисми ягын өйрәнүгә кайтып кала. Мин бу очракта Х. Госман, М. Бакиров хезмәтләрен күздә тотып әйтәм. Поэзиябездәге рухи үсешне, фикер үсеше эволюциясен, бүтән халыкларның поэтик казанышлары яктылыгында тикшергән тулы канлы хезмәтләр юк дәрәҗәсендә. Аерым шагыйрьләр иҗатына багышланган монографияләр дә сирәк күренә. Ә алар бик кирәк. Киң катлам укучыларны поэзиягә ныграк якынайтуга, шагыйрь белән укучы арасындагы чын аңлашуга ярдәм итәр иде алар. Юкса шагыйрьләр меңләп исәпләнгән заманда (мәсәлән, Мәскәүнең үзендә генә ике меңнән артык шагыйрь исәпләнә) укучы да гадел һәм акыллы киңәшчегә бик мохтаҗ бит!

Бүгенге поэзиядә тагын бик күп ачыклыйсы нәрсәләр бар, әлбәттә. Әйтик, шигърияттебездә традицияләр һәм бүгенге чынбарлыкны иҗади үзләштерү, әдәби осталык, мәктәпләрдә татар поэзиясен укыту, гомумән, татар әдәбиятын пропагандалау мәсьәләләре...

Болар турында җентекләбрәк сөйләшүгә поэзиябезне яратып, үсеше өчен янып яшәүче бүтән иптәшләр кушылырлар, әңгәмә барышында башлап та ахырына чыгалмаган кайбер мәсьәлә-проблемалар турында дәвам итәрләр дип ышанам.

*1975—1977*

## «ВАТАН БУЛА БЕР ГЕНӘ!..»

*(«Идел» журналы хезмәткәре белән әңгәмә)*

*— Киләчәктә дөнья белән шагыйрьләр идарә итәр, дигән бер акыл иясе. Мин моңа ихлас күңелдән ышанам. Кайбер илләрнең дәүләт, хөкүмәт башында язучыларның, журналистларның*

*утыруы да әлеге фаразның дөрес булачагына ишарәли кебек... Равил әфәнде, әйтик, әгәр Сезне Татарстан Президенты итеп сайласалар, Сез иң беренче нәүбәттә нинди карар кабул итәр идегез?*

— Уйнакчанрак сорау, ахрысы, бу. Шартлы сорауларга шартлатып җавап әйтүе дә кыен. Татарстан, дибез, димәк, ул Татар Иле булырга тиеш бит инде. Ә ул, асылда, рәсми куелышы белән өяз, өлкә дәрәҗәсендәге бер административ берәмлек, татар халкының чиреге чамасын гына сыендыра алган кечкенә бер төбәк. Өстәвенә моңарчы мөстәкыйльлегә дә юк дәрәҗәсендә булып килде. Үзәк, Мәскәү өчен донор вазифасын үтәп килүче «өяз-ил»нең авыз тутырып әйтерлек Президенты була ала микән?

Ярый, Аллага тапшырдык, алай бик сорагач, ризалаттыгыз, Президент булдым ди. Беренче карарлар, фәрманнармы? Атна-ун көн буена бөтен халыкны республика территориясен чистартырга, тазартырга чыгарыр идем. Бөтен техник транспорт чараларын эшкә җигеп җиребездә күзгә күренеп яткан бөтен чүп-чарны, тимер-томырны, пыяла ватыкларын җыйдыртыр идем. (Алай берьяклы кубарылу — экономик зыянга булыр, дияр кемдер. Ә без соң һәр елны Яңа ел, Раштуа бәйрәмнәрен, хезмәт хакы булу-булмауга карамастан, унар көн тик ял итеп ятмыйбызмыни?) Бездә 1 кв. километрга 50дән артык кеше туры килә. Шуның сау-сәламәт булган яртысы гына эшләсә дә, бер ун көн эчендә дөньябыз чистарыр иде. Юкса җиребезне чүплеккә әйләндереп бетердек бит! Цивилизациягә ия халыклардан оят. Җир куеныннан байлыкны суырып алып, ярым-йорты файдаланып, җимереп, җир өстенә чәчтек. Миңа калса, ил киңлекләрендә аунап яткан тимер-томырны җыйсаң, Эвересттан биек булыр иде өем; руда комбинатларына, домна мичләренә әллә ничә еллар буе җир ертып ала торган чимал кирәк булмас иде.

*— Быел Сез Татарстан халык депутаты булып сайландыгыз. Безнең депутатлар корпусы алдында бик тә катлаулы бурыч — татар халкының суверенлыгын гамәлгә ашыру бурычы тора. Чын суверенлык исә мөстәкыйль дәүләтчелек торгызылган тәкъдирдә генә булырга мөмкин, ягъни федерация составында чын бәйсезлек тә, чын суверенлык та була алмый. Бу мәсьәләгә Сезнең карашыгыз ничек?*

— Россия үзенең суверенлыгын игълан иткәч, безнең хәл тагын да катлаулана гына төште. Моннан 20 еллар элек басылып чыккан дүртьюллыгым хәтергә килде.

Туган ягы — чүл булса да,
үзе өчен гөл генә.
Ватан катлы-катлы булмый,
Ватан була бер генә!

Ихтимал, моннан 450 еллап элек югалткан дәүләтчелекне әле тиз генә торгызып булмас. Гасыр башында, бигрәк тә Октябрь революциясе елларында, мөстәкыйльлек юнәлешендә зур адымнар эшләнгән иде. Әмма соңгы 50—60 ел эчендә, бигрәк тә Сталин хакимияте чорында, без каты рухи имгәтүләр кичердек. Миңа калса, объектив сәбәпләр — тарихи-территориаль үзенчәлектән һәм халыкның сәяси әзерлеге дәрәҗәсеннән чыгып, безгә хәзер СССР федерациясе составында мөстәкыйль республика статусына ирешергә кирәк.

*— Сез — 60 нчы еллар башында, империядә сәяси климат беркадәр җылына төшкән вакытта, әдәбиятка килгән буын вәкиле. Ә менә шагыйрь буларак, илкүләм танылуыгыз, әлеге дә баягы торгынлык елларына туры килә. Ләкин, дөрес аңлашыла күрсен, бу әле һич тә шагыйрь торгынлык идеологиясенә хезмәт итте дигән сүз түгел. Киресенчә, без Сезне конъюнктурага бирешмәгән туры сүзле шагыйрь буларак беләбез. Әмма шул ук вакытта бүгенгесе көндә күп кенә эстетик кыйммәтләрнең үзгәрә баруын да онытырга ярамый. Хәтердә: Сезнең иҗатыгызга югары бәһа биреп язылган әтрафлы мәкаләләр үзәктә дә, җирле матбугатта да күп басылды. Инде иҗатыгыз турында үзегезнең дә фикерне беләсе килә иде...*

— Җылы сүзегез өчен рәхмәт. Ата-ананы, Ватанны, Дәверне сайлап алып булмый. Без, хәзер 50гә якынлашып килүче буын, бер яктан, бәхетле — үзегез әйткәнчә, әдәбиятка «60 нчы еллар башында, сәяси климат беркадәр җылына төшкән вакытта» килдек; икенче яктан, сөт чүлмәгенә төшкән тычкан шикелле, торгынлык чорының нәкъ үзәгенә эләктек. Байтак талантлар сынды, күпләр ярашты, мәсләген ситуациягә карап көйләргә өйрәнде. Бүген эш башына килеп утырганнарның күбесе әлеге административ-әмер системасында өлкән агайларга тастымал тотып торган егетләр. Алар имансыз, шунысы белән куркынычлар да.

Инде конкрет иҗатка — язганнарыма килгәндә, бер генә шигыремнән дә, аларның бер генә юлыннан да ваз кичмим. 30 елдан артык чорда 30лап китабым чыккан, шигырь исәбе, кыскаларын

да кертеп, 2 меңнән артыкка җыйнала бугай. 30 ел — сынар, сыналыр өчен җитәрлек вакыт. Дөрес, язганнарның төрле дәрәҗәдәгеләре бар. Анысы, үзегез аңлыйсыз, табигый хәл. Сизеп, күреп йөрим, хәзер байтак кына каләмдәшләр үзләренең кайбер конъюнктур максатлардан чыгып язылган әсәрләре өчен уңайсызлык кичерәләр. Киштәләрдән кайбер бөтен-бөтен китаплар шуып төшеп, билгесезлектә югала... Бу яктан җаным тыныч. Карагыз, актарыгыз китапларымны, аннан күземә багарсыз, шәт, оялып читкә борылмам. Аннан, тагын бер куанычым: талантлы яшьләр арасында дусларым, фикердәшләрем күп. Күп мәсьәләләрдә алар белән берлек тоям. Иҗат кәгазьдә генә түгел, яшәү рәвешендә яхшы чагыла бит.

*— «Казан утлары» журналының баш мөхәррире буларак, Сезгә бүгенге әдәби процесс белән аерата якыннан танышып барырга туры килә торгандыр. Сез ничек уйлыйсыз, хәзерге татар әдәбиятының иң зур казанышы һәм кимчелеге нәрсәдә?*

— Һәр әдәбият, шул исәптән аның казанышы да, тарихи фактор белән бәйле. Безнең әдәбият — зур әдәбият, мең еллык тарихлы әдәбият. Бу үзе — халыкның тарихи казанышы. Үткән Әдәбият — эчтәлеге белән, ислам кануннарына тугрылыклы хәлдә, гуманистик рухлы, Явызлыкка түгел, Изгелеккә хезмәт итүче әдәбият. Җир йөзендәге барлык халыкларның тигезлеген, кешелекнең гомумбер гармоник бөтенлеген таный, адәм балаларының бергә-бергә ярдәмләшеп яшәү идеясен яклый. Без — шул мирасның варислары. Ә менә шушы мирасны тиешенчә белмәвебез Сез телгә алган кимчелекле сыйфатка әйләнә. Монда әдипләребезнең интеллектуальлеге, зыялылыгы, тарихи хәбәрдарлыгы, чынбарлыкны фәлсәфи анализлый белү сәләте кебек мәсьәләләр килеп баса. Аяныч, бездә Язучылар берлеге әгъзалары ишле булса да, заманага лаек әдипләр бик санаулы. Үткәнне нигезле анализлый алмау, киләчәкне тарихи перспективада күреп җиткермәү, минемчә, әдипләребезнең бер кимчелеге. Кимчелекләр янәдән дә күп. Әйтик, шундый зур әдәбиятыбызны бөтендөнья аренасында демонстрацияли алмау яки Ходай биргән талантны, сәләтне нәтиҗәсез исраф итү, иҗади фидакарьлек җитмәү... Әлбәттә, монда төрле сәбәпләр бар. Халык саны буенча РСФСРда икенче, СССРда алтынчы урында торган халыкның үз хокукый дәүләт системасы булмавы, үз җиренә үзе хуҗа була алмавы, һичшиксез, рух дөньясына, шул исәптән әдәбиятка да нык суга...

*— Татар әдәбиятының, аерым алганда шигъриятнең, киләчәген ни рәвешле күзаллыйсыз?*

«Шигырьне укымыйлар» дип,
сөенү җиңелрәк.
Бездә Әдәбият әнкәсе —
гомердән Шигърият!

Әнкәләрен санламаучы
сантыйлар да җитәрлек.
Бездә Шигырь — аңлаганга —
башың Себер китәрлек!

Сүз дә юк, прагматизм һәм шигърият бер-берсенә ят төшенчәләр. Соңгы дистә елларда нык җәелгән имансызлык, хәзерге химикатлар кебек, Поэзия гөлен нык көйдерде. Әмма Демократия заманының кешеләр күңеленә шифа, савыктыргыч көч бирүе өметләрне яңарта. Күз яше һәм көлү чаткысы, сөю һәм сагыш мәңгелек. Димәк, поэтик хис тә мәңгелек. Тагын шунысын да онытмыйк: рациональ акыл белән өртелгән Гарептән тыш, серле һәм хикмәтле, заманында математика китапларын да шигырь белән язган Шәрык тә бар бит әле. Без бу һәр ике дөньяга да мөнәсәбәтле халык бит!

*— Бүген совет империясендә күппартияле система оешып килә. КПССка, аның җитәкчелегенә халыкның ышанычы отыры какшый бара. Хәзер КПСС — чын мәгънәсендә консерваторлар партиясе. Бу РКПның оештыру съездында да бик ачык күренде. Мондый шартларда «халкым» дип җан аткан әдип-язучыларның КПСС әгъзасы булып торуы максатка ярашлы дип уйлыйсызмы?*

— Кеше партия әгъзасы булып тумый. Яшәү, Үлем кебек категорияләр нисбәтендә партиялелек шартлы нәрсә... Дөньяда сәяси партияләр бик күп. Вакыт үткән саен партияләрнең максаты, платформасы, хәтта исемнәре үзгәрергә мөмкин. Хәзер бездә шул процесс бара да. Миңа калса, партияләр хакында сүз барганда, чиктән чиккә ташланулар да күзгә ташлана. Әйтик, фәлән кеше озак еллар партия әгъзасы булып торган икән, җәмгыятьтәге бөтен негатив күренешләр өчен ул гаепле дигән сүз түгел бит. Коммунистлар арасында да төрлесе бар. Ахыр килеп, теге яки бу партиядә тору кешенең ихтыярына һәм дөньяга карашына бәйле. Шунысы ачык: дөньяда бер уртак

идеягә ышанган яки табынган кешеләр төркеме, группалар, партияләр һәрчак булган, һәм ул алга таба да шулай булачактыр. Безнең әдәбият тарихында коммунист шагыйрь Сибгат Хәким кебек кешеләрне дә, һәм шулай ук партиясез провокаторларны да табып була.

*— Сез күп ил-җирләр гизгән кеше. Ихтимал, юл йөргәндә, Сезгә байтак гыйбрәтле хәлләрне күрергә дә туры килгәндер. Әйтегез әле, Сезнең өчен читләрдә йөреп алган иң зур тормыш сабагы нидән гыйбарәт булды?*

— Адәм баласы яңа җирләр, илләр күргәч, телиме-теләмиме, үзен бүтәннәр белән, үз ил-җирен яңа күргән җирләр белән чагыштыра. Бу хистән мин дә мәхрүм түгелдер инде. Андый очракта миндә ике төрле хис бәргәләнә. Бер яктан, безнең Идел-Урал буйлары дөньяның иң гүзәл җирләренә торгысыз булганына, бигрәк тә электәгесенә горурланасың, сөенәсең; икенче яктан, бүтән илләрнең яшәү рәвешен, тормыш тәртибен күреп, күп чак әрнисең, «нигә алай соң?» дигән уй өзә... Бу ике каршылыклы хиснең күңелне биләве табигый халәт микән? Гайре табигый икәнен белсәм, җанга тынычрак булыр иде...

*1990, июль*

## БЕР МУЕНГА ИКЕ КАМЫТ

**Татарстан Югары Советы сессиясе башланырга санаулы көннәр, санаулы сәгатьләр калып бара. Бу сессиядә Дәүләт суверенитеты мәсьәләсе каралырга тиеш. Халыкның гасырлар буе көткән өметләре акланырмы? Мондый чакта кем генә битараф булыр да, тыныч кына йоклап ятар икән? «Социалистик Татарстан» газетасы хәбәрчесе «Казан утлары» журналы баш редакторы, Мамадыш районы Үсәли округыннан сайланган Татарстан халык депутаты Равил ФӘЙЗУЛЛИН белән очрашты.**

*— Эш бүлмәгездән Казанның бик матур панорамасы күренеп тора икән. Әнә Казансу аша Кремль, Сөембикә манарасы күренә, Югары Совет бинасы өстендәге кызыл әләм җилфердәп тора. Бу күренешләр Сезне дә уйландыра торгандыр, депутатларыбызның икенче сессиясе алдыннан Сез нинди хисләр кичерәсез икән?*

— Күңелне тулысы белән көтү хисе биләп алган. Өмет белән хәвеф аралашкан көтү хисе. Куерып яшенле болыт килгәндә, табигатьтә дә шундый бер вакыт булып ала. Бу болыт җиргә шифа, бәрәкәт китерерме, булган иген-чәчүләрне имгәтеп, боз сугып китмәсме?

*— Нигә алай хәвефләнергә урын булырга тиеш соң әле? Белгәнебезчә, сессиянең көн тәртибенә без күптән көткән мөһим мәсьәләләр куела. Татарстанның суверенитеты мәсьәләсен безнең халык дистә еллар, хәтта гасырлар буе көтте. Халык әллә ничә айлар буе бик сайлап үз депутатларын билгеләде. Алар халык ышанычын аклый алмаслармыни?*

— Акларга тиешләр, мәҗбүрләр. Әмма хәл ителергә тиеш мәсьәләләр бик четерекле. Беренчедән, ничә әйтсәң дә, бездә гомумсәяси аң шактый түбән дәрәҗәдә әле. Халык дигән зур сүзгә тел тидерәсе, халык көченең зурлыгына шик төшерәсе килми, ләкин киң масса арасында битарафлар, мәсьәләнең төбен аңламаган яки аңларга теләмәгән кешеләр дә күп. Коллык психологиясе безгә бик нык сеңгән. Гражданин буларак теге яки бу мәсьәләне мин дә хәл итәргә тиеш дигән тойгы күпләребездә урнашып бетмәгән. Моңарчы мөһим мәсьәләләрне өстән кемнәрдер хәл иткәч, көтү-өер булып, дәррәү кул чабып хуплап утырырга өйрәнгән халык. Соңлап уянабыз, озак кузгалабыз, «татар акылы төштән соң» дигән кинаяле әйтемне онытып җибәрәбез. Хәвеф хисе тууына икенче бер сәбәп тә бар. Беләсез, моннан бер атна элек Татарстанның Югары Советы республикабызның дәүләт суверенитеты турында Декларация проектын игълан итте. Аңа хәтле Декларацияләрнең бүтән проектлары да булган иде. Әйтик, Татарстан Гражданлык комитеты проекты... Әлбәттә, проектларның һәркайсы күп акыл көче куеп иҗат ителгән. Әмма Югары Совет Президиумы тәкъдим иткән Декларациянең бер пункты, дөресрәге, беренче иң кирәк пункты миндә аңлашылмаучылык һәм ризасызлык уятты. Анда болай дип язылган: «Татарстан Совет Социалистик Республикасы — суверен дәүләт, яңартылган РСФСР һәм СССР Союзы Федерациясе субъекты». Бу формулировканың беренче өлешен яклаган хәлдә, җөмләнең икенче өлешен артык дип, юридик яктан мәгънәсез дип саныйм. Ни өчен? Гади генә әйтсәк, бер муенга ике камыт кигезмиләр. Бер башка ике картуз да кимиләр. Бәхетле кешеләрнең әти-әниләре дә икешәр булмый.

*— Проектларны акыллы кешеләр күп көч куеп эшләгән, дидегез. Алайса, алар нигә шундый абсурд формулировканы игълан иткәннәр икән соң?*

— Мин Президиум әгъзасы түгел, шуңа күрә бүтәннәр өчен җавап тоту кыен. Шулай да сизенүем һәм бу проектны төзегән эшче группада катнашкан депутатларның әйтүе буенча, әлеге «артык койрык», югарыдан басым ясап экстерн тәртиптә өстәп кертелгән. Бу актның хата икәнлеген вакыт бик тиз ачыклар. Койрыкны таккан кешеләр үзләре бүгенге иҗтимагый хәрәкәтнең койрыгында бармыйлар микән? Ә лидерлар исә алдан халыкка юл ярып барырга тиеш. Бөтен яктан да.

*— Әйе, андый мөһим документларның һәр сүзе, һәр хәрефе төгәл һәм үз урынында булырга тиеш. Соңгы елларга кадәр, дөресен әйтик, гади халык андый рәсми актларны, әйтер идем, хәтта Конституция, Декларация кебек документларны ул кадәр җентекләп өйрәнеп тормады шикелле. Элекке Конституцияләрдә дә халыкларның иреге, дәүләт системалары турында кызыктырырлык сүзләр бар. Тик ул пунктларның күбесе реаль тормышта гамәлдә генә түгел иде. Менә Сез әйткән Декларациядәге теге яки бу пункт-статьялар да алга таба да бары тик кәгазьдә генә калмас микән? Һәр сүз өчен артык гасабиланмыйбызмы?*

— Хокукларны һәм бурычларны төгәл ачыклый торган заман килде. Төптәнрәк уйласаң, һәр кеше үзе бер суверен дәүләт ул. Кояш астында шәхес икәнен тоеп яшәр өчен һәркем үзенең кешелек статусын анык белергә тиеш. Халык кадәр халык, милләт кадәр милләт бигрәк тә. Ә инде Декларациянең беренче пунктына килсәк, анда суверен дәүләт дип беркетеп кую — ул сәяси хокук алу дигән сүз. Безгә хәзергә шул ягы кадерле. Суверенлык, мөстәкыйльлек алга таба ни дәрәҗәдә булыр, вакыт күрсәтер. Без бу сессиядә, ниһаять, ТАССРдан ТССРга күчеп, «А» хәрефеннән котылырбыз, иншалла. Ләкин «А» белән эш бетте дип авыз ачып утырырга һич ярамый, безгә хәзер «Б» кирәк, ягъни Бәйсезлек, реаль Бәйсезлек! Татарстанны РСФСР һәм СССР субъекты итеп, ике хуҗага беркетеп кую — һәм сәяси, һәм экономик тормышта дөнья хәтле буталчыклар китереп чыгарачак. Әйтик, конкрет бер мәсьәлә турында СССР бер төрлерәк, РСФСР икенче төрлерәк закон чыгара ди. Бу очракта Татарстан кайсының законын танырга тиеш була? Яки Татарстан бер төрле закон игълан итте ди, РСФСРга бу ошамый һәм танымый, ә СССР кабул итә ди. Мондый очракта нишләргә тиеш булабыз? Закон-канун чыгарылып та, аның үтәлми калуы бездә гайре гадәти хәл түгеллеген искәртсәк, бигрәк тә уйландыра шул.

*— Үзегез беләсез, быелгы җәй һәрьяклап бик киеренке җәй булды. Татарстанга мөстәкыйльлек яулап алу юнәлешендә байтак митинглар булып узды. Матбугат, радио-телевидениедә дискуссия-дебатлар бара. Митинглардагы транспарантларга игътибар иткәнсездер, арада мондыйлары да бар иде: «Мы в Россию не входили!», «Навеки с Россией — навеки в рабстве?» һ.б. Татарстанга Травкин һәм Ельцин килеп китүе дә төрле кешеләрдә төрле тойгы калдырды. Татарстанның суверен дәүләт булуын таләп, кайбер шәһәрләрдә ачлык игълан итүчеләр дә бар. Татарстан белән Россия мөнәсәбәтләренә карата карашыгыз ничек? Бу — төп каршылыкларны тудырган үзәк мәсьәлә түгелме?*

— Мондый авыр сорауларга, шартлатып, Тукай шигыре белән җавап бирәләр иде: «Рус белән тормыш кичердек сайрашып...» Әмма ул шигырьнең кайбер бүтән юлларын күрмәмешкә салыша идек. Анда мондый юллар да бар бит: «Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук!» Мин болай уйлыйм: Россия — дөньяның зур бер иле. Без бергә тарихи гомер кичергән ил. Шуңа күрә, Россия турында сөйләшкәндә, без кермәдек, без чыкмадык, кермибез, чыкмыйбыз, дип, керделе-чыктылы сөйләшергә ярамый. Россия күпмедер дәрәҗәдә без үзебез дә бит әле. 68 мең кв. км бер ашъяулык кадәр җир бөтен татар иле дигән сүз түгел... Без Россия белән бертигез дәрәҗәдәге хокукта бергә-бергә хезмәттәшлек итеп, тату яшәргә тиешбез. Сизгерлекне таләп итә торган хәлләр дә күзәтелә соңгы вакытларда. Кайбер кешеләр, әллә чынлап, әллә юри, Татарстанны Россия белән каршы куеп күрсәтергә телиләр. Янәсе, татарлар каядыр аерылып чыкмакчылар икән (без кая китик икән? Айга очыйкмы?), көчләп татар теле укытачаклар икән (дөрес, бу җирдә гомер буе яшәп, ипи-тозлык кына булса да җирле халык телен белүдән берәүнең дә башы чатнамас иде дә бит), милли бәрелешләр килеп чыгуы бар икән кебек имеш-мимешләр тараталар. Күбрәк безгә күчеп килгән кешеләр тарата моны, үзенең милләтен онытканнар тарата. Паникага бирелмик! Ирек атлы Демократия баласын тумаган килеш ләхеткә иңдермик, башка чыкмаган гаиләнең салынмаган йортын сүтә башламыйк! Соңгы вакытларда тагын да бер төрле сәер фикерләр дә ишетелгәли: янәсе, Татарстанда татарларның чиреге генә яши, шулай булгач, «ачык ишекле» республикага суверенлык кирәкме икән? Бусы инде, рус үзе әйтмешли, более чем

оригинально! Кайда гына үзен ирекле тоеп, үз җиренә, үзе хәләл эшләп тапканына хуҗа булып яшәргә икән соң бу татар дигән халыкка? Соравыгызга җавабым: дуслыкның нигезе — тигезлек. Тигез булсак, дуслык та булыр, бәрәкәт тә булыр. Безнең халык бүтәннәр белән уртак тел таба ала торган халык ул.

*— Равил әфәнде, егерме биш еллар элек язылган бер шигырегездә мондый юллар бар иде: «Үткән бөеклеккә кайтып булмый, сагынып кына була...» Бүген дә Сез шундый фикердәме?*

— Бу шигырьнең ике төсмере бар: берсе, шәхси ягы, икенчесе, сәяси, тарихи ягы. Әйе, замана үзгәрә. Һәр демократик үзгәрешләр өмет уята бит. Яшьлек үтте дип үкенеп кенә ятып булмый, киләчәк өчен, балалар өчен көрәшәсе бар. Шанлы үткән турында? Спираль буенча яки бүтәнчәрәкме, тарих гел үсештә, иҗтимагый тормыш кайный. Карагыз бүтән халыкларны — яһүдләр үзләренең тарихи ватанында оешып, шактый көчле дәүләт төзеп куйдылар; сәгате килеп суккач, тиз арада немецлар берләште. Безнең илдә дә моңа охшаш күренешләр юк түгел. Әзәриләр (азәрбайҗаннар) Ирандагы милләттәшләре белән ныграк аралаша башлады. Безнең халыкка да карый бу хәрәкәт. Бик күп татарларның тарихи ватанга — Казанга тартылулары сизелә. Чит илләрдә яшәүче кардәшләребез дә ешрак кунакка килә башлады. Бер милләт халкының консолидациягә омтылышы законлы күренеш.

Җире уртак дибез, эше,
таңы...
Ә шулай да
һәр кавемнең
аерым-аерым каберстаны...

*— Дәүләт суверенитеты милли суверенитетка бер баскыч ул. Дөрес, һәр халык аны үзенчә үтә. Шулай да сессия нинди нәтиҗәләр белән бетәр икән, халыкның өмете гаять зур. Депутат буларак...*

— Мин әле бит (хәер, мин генә микән?) депутат булып өлгереп кенә киләм. Элек депутатлар берни диярлек эшләмиләр иде, хәзергеләреннән исә бөтен нәрсәне хәл итүләрен таләп итәләр. Күбесенең реаль власте булмаган килеш. Хәтерегездәме, Шәриф Камалның «Депутат»ы? Шуның хәлендә калмасак ярар иде. Миңа калса, без һәммәбез бер нәрсәне ачык аңларга тиеш: халыкларның тигезлеккә омтылышы — объектив, прогрессив күренеш, хуплый торган хәл. Томаналык, хәерчелек талаштыра кешеләрне. Күңеле дөрес, кешелек горурлыгы булган җаннар яхшыга бару юлларын эзләргә тиеш. Баш чиста булырга тиеш. Баш чиста һәм гамьле булса, тән дә чиста булыр, җиребез дә.

*1990, 19 август*

## «ДОШМАНЫМ МИНЕМ — ВАКЫТ...»

*(«Тулпар» журналы хезмәткәре белән әңгәмә)*

**...Мин «Казан утлары» журналының баш мөхәррире бүлмәсенә килеп кергәндә, аның хуҗасы — 60—70 нче елларда «Нюанслар иле» циклы белән төрки дөньяны шаулаткан, үзенчәлекле әсәрләре аркасында күп кенә мактау һәм тәнкыйть сүзләре ишеткән шагыйрь Равил Фәйзуллин каядыр чыгып китәргә җыенган иде. Бер сөйләшер өчен генә ерак юллар үтеп Казанга килгәнемне аңлаткач кына, ул берничә минут вакытын бүләргә булды.**

**— Мине тиздән түбәнгә чакырырга тиешләр,— дип, алдан ук кисәтеп куйды Равил Фәйзуллин («Казан утлары» Матбугат йортының унынчы катында урнашкан).**

**«Мин дә төшеп калган малайлардан түгел. Бәлки, биш минут урынына кырык биш минут та сөйләшергә туры килер әле»,— дип, эчемнән генә уйлап куйдым да диктафонымны көйләп, шагыйрьгә беренче соравымны юлладым:**

*— Соңгы елларда басылып чыккан шигырьләрегездә моңсулык, сагыш, чарасызлык көчле тоела. Моның сәбәбе нидә?*

— Сагыш, моңсулык табигатьнең дә асылында ята бит ул. Кеше гел тук һәм рәхәт кенә яшәсә, шигырь язарга утырыр иде микән? Моң-сагышлы булуны мин шагыйрьлек дип саныйм. Мөгаен, яшьлек чорындагы шигырьләремдә дә сагыш-моң булгандыр. Әмма хәзер, илледән узганнан соң, аның төсмерләре бүтәнчәрәк. Монда Вакыт дигәннәре зур роль уйный. Яшьлектә язылган шигырьләремдә дөнья күбрәк яшел төстә, хәзергеләрдә бүтән төсләр дә җитәрлек. Офыклар бүтәнчә, ачыграк һәм ераграк булып күренә. Бу ачыклык олыгаю белән дә, үз мөмкинлекләреңне

чамалау белән дә, фани яшәү финишының төсмерләнүе белән дә бәйледер. Әлбәттә, бу тойгылар сагыш-моң белән бәйле һәм мин моны табигый халәт дип уйлыйм.

Икенчедән, моңа хәзерге җәмгыятьнең әхлаксызлыгы да сәбәпчедер. Сүз дә юк, кайчандыр хыялланган күпмедер хөрлек килде, әмма ул хөрлек нинди уйларга этәрә, ул хөрлекнең җимешләре кемгә хезмәт итә? Үзәктәге, илдәге тәртипсезлек бездә дә үз чагылышын тапмыйча калмый. Нинди генә кеше булмасын, ул барыбер туганнан бирле җәмгыять белән бәйле. Шигърияттә дә бу ачык күренә. Шулай да мин хәзерге шигырьләремдә өмет чаткысы, рациональ ышаныч та күрәм.

*— Шулай да, минемчә, соңгы еллардагы иҗатыгызда оптимистик рух шактый кимеде. Менә шигъри әсәрләрегездән ике мисал. Беренчесе 1968 елда язылган «Көрәшчеләр» поэмасыннан. Сез анда:*

Бөтен планета буйлап
вакансия:
Көрәшчеләр кирәк!
Көрәшчеләр, —

*дип оран салдыгыз. Ә хәзер инде 1994 елда «Казан утлары»нда басылган шигырегезне укып карыйк.*

...Яшәдең, эшләп җан аттың.
Йә, үзгәрттеңме бераз
Дөньяны, Илне?
...Сизәме Тау — очып төшкән
тәмәке көлен.

*Соңгы шигырегез Дөньяны, Җирне үзгәртү идеясеннән ваз кичүегезне аңлатмыймы? Мин моны «Көрәшчеләр» поэмасына җавап сыманрак кабул итәм...*

— Юк, «Көрәшчеләр» поэмасы ул заман өчен яхшы гына девиз, әйбәт кенә өндәү булды, аны кешеләр кабул иттеләр. «Көрәшчеләр кирәк!» дигән сүзләр милли үзаңны, милли әдәбиятны үстерүдә үзенең ролен үтәде. Мин әле дә бу өндәмәләрдән ваз кичмәдем. «Көрәшчеләр кирәк!» утыз ел элек язылса да, күптән түгел Дәүләт Суверенитеты кабул иткәндәге митингларда яңгыраган өндәүләргә авваздаш булды. Әмма митинглар чоры үтте инде... Ялкын да бит бер- чакны сүрелеп кала, әмма эчке процесс барыбер бара. Шигырьләремдә бүгенге көннең яраларын ачып салуым да көрәшнең бер формасы бит ул. Шуңа күрә мин ул сүзләрдән ваз кичтем дип уйламыйм.

**...Кызып кына барган әңгәмәбезне бүлеп ишек шакыдылар һәм бүлмәгә кыска буйлы, ярлы гына киемле, чуалып беткән җирән мыеклы берәү килеп керде. «Авылдан килгән берәр өйрәнчек автор микән, әллә Равил абыйның шоферы-фәләнеме» дигән фаразымны тиз таратты бүлмә хуҗасы:**

— Таныш бул. Тукай премиясе лауреаты, шагыйрь Мөдәррис Әгъләм.

**Мин, Мөдәррис абыйның шигърияте белән яхшы таныш булганга, телсез калдым. Бездә әз-мәз рифма төзи белгән кеше дә костюм киеп, галстук тагып: «Мин шагыйрь!» — дип кукыраеп йөри бит. Ә монда?.. Нинди талант һәм нинди гадилек!**

**Шулчак Мөдәррис Әгъләмов телгә килде һәм Равил абыйга: «Машина хәзер килеп җитәчәк. Аскы катка төшеп көтеп торыйк», — дип, бүлмәдән чыгып китте.**

— Машина килгәч тә миңа шылтыратырсыз, төшеп җитәрмен, — дип озатты аны баш мөхәррир.

**...Әңгәмәне дәвам итеп, Равил Фәйзуллинга үземне күптәннән борчып йөргән бер сорауны бирергә җөрьәт иттем:**

*— Сезне күпләр фикер шагыйре дип исәплиләр. Бу турыда үзегез нәрсә уйлыйсыз? Шигърияттә, гомумән, хис өстенлек алырга тиешме, әллә фикерме?*

— Мондый бәхәс булырга тиеш тә түгелдер. Хәзер композиторлар үзләре текст язалар, көй чыгаралар, үзләре җырлыйлар. Бәлки, кайберәүләрне хисләндерәдер, әмма ул «шедевр»ларда логик фикер, уй юк. Икенче яктан, бездә логик яктан дөрес, математик конструкцияләүгә корылган шигырьләр язучы кешеләр дә бар. Ләкин ул шигырьләр хиссез. Мин боларны ике чиккә ташлану дип исәплим. Хистә болганып кына да, логик трюклар күрсәтеп кенә дә укучыны тәэсирләндерерлек чын шигырь иҗат итеп булмый. Шигырьдә хис һәм фикер бергә туарга тиеш. Минем күп кенә әсәрләремдә алар табигый укмашып киләләрдер дип уйлыйм. Дөрес, кайбер шигырьләремдә фикер өстенлек итә. Болары инде — кыска шигырьләр. Бу шигырьләрем интеллектуаль дәрәҗәләре югарырак торган, үземә фикердәш кешеләргә адреслана, алар мин әйтергә теләгәнне аңлаячаклар дип беләм. Кыска шигырьдә бар хикмәт — фикердә. Гомәр Хәйям робагыйларының да төп мәгънәсе шунда бит...

*— Вакыт дигәннән, минем карашка, Сезнең күп кенә шигырьләрегез — Вакыт, Заман кебек мәңгелек төшенчәләр турында уйлану, аларның асылын эзләү...*

— Вакыт — абстракт төшенчә. Шуны әйтә алам, минем беренче шигырьләремдә үк аның белән көрәш башланды. Иң зур дошманым да, санлашкан һәм курыкканым да Вакыт булды. Вакыт мөнәсәбәтендә бик күп нәрсәләрне шәйләп буладыр. Яфрак яру да, чәчәк ату да Вакыт бит ул. Чишмәләр агуын әйтәсе дә юк инде... Вакыт сагышка да этәрә. Минем 1963 елда язылган бер шигырем бар. «Җил — Вакыт ул» дип атала ул. Үземчә Вакытны аңлавым инде. Анда бик яхшы күренә шушы әйбер. Сез әйткән Яшәеш, Вакыт, Мәңгелек, Үлем кебек төшенчәләр турында уйлау миңа иртә килде. Тәнкыйтьчеләр дә кайчак: «Синең иҗатыңның балалык, өйрәнчеклек чоры булмады»,— дип әйтә киләләр. Әмма бу нәрсәдән — әйтә алмыйм.

*— Гафу итегез, сүзегезне бүләм. Мин сезнең күп кенә шигырьләрегезне тикшереп, шундый нәтиҗәгә килдем, яшьлек чоры иҗатыгызда якты киләчәк өчен көрәшкә өндәп торган Вакыт соңга таба гадел, әмма рәхимсез хөкемдарга әверелә...*

— Бәлки, Сез монда һәркемгә сизелерлек Вакыт атрибутларына зур игътибар биргәнсездер. Хәер, үземә дә тикшереп карарга кирәк...

**— Сезне буш кул белән озатасым килми, — диде шагыйрь, шигърият турында сүзне бүлеп. — Диплом эшендә ярдәм итәрлек кулланмалар бирәсем килә. Хәзер шуларны эзләп алып керим...**

**Аның бүлмәдән чыгып китүенә күп тә үтмәде, зеңгелдәп телефон шылтырады. Трубканы күтәрдем. Мөдәррис Әгъләмов тавышы... Нишләргә? Равил абыйны чакырсам, әңгәмә тәмамланды дигән сүз. «Их, ни булса да булыр», дип уйладым да, мин телефон шнурын үзәк чыбыктан тартып алдым.**

**Берникадәр вакыт үткәч, Равил абый килеп керде һәм бусагадан ук:**

**— Шылтыратучы булмадымы? — дип сорады.**

**Мин «әйе» дип тә, «юк» дип тә җавап кайтармадым...**

**— Бу китаплар сиңа, — дип, ул алып кергән ике-өч китабын миңа тоттырды. — Вакыт бар чакта әңгәмәбезне дәвам итик.**

*— Үзегез иң яхшысы дип санаган әсәрегезне атасагыз иде...*

— Өч, дүрт, биш, алты юлдан торган кыска шигырьләр. Менә әле аларның һәммәсен бергә җыеп китап чыгарырга телим. Кыска шигырьләрем минем характерыма һәм тәҗрибәмә ныграк туры килә. Гомумән, мин аз сүзле, артыгын сөйләшергә яратмыйм. Сәхнә шагыйре дә түгелмен. Сәхнә шагыйрьләрендә аерым бер сәләт, көч бар. Мәсәлән, Әнгам Атнабаевта. Ә менә миндә андый теләк юк. Дөрес, яшьрәк чакта бераз бар иде... Күңелемдә яткан әйберләрне сәхнә аша әйтеп бетерә алмыйм мин. Гомумән, кыска шигырьләр белән залны яулап булмый.

*— Белүемчә, кыска шигырьләрегез әлеге көнгә кадәр бәхәсләр тудырып килә. Кемнәрдер аларга сокланып бетә алмый, ә кемнәрдер шигырьгә дә исәпләми. Аларны язу идеясе Сездә ничек туды?*

— Минем өчен шигърият — эчке, рухи яшәеш формасы ул. Ә кыска шигырьләргә килгәндә, мин аларны язуны, үземчә, бүтәннәрне хөрмәт итү дә дип исәплим.

Кыска шигырь бер-ике сүз белән генә сезне фикерләшүгә, киңәшләшүгә чакыра. Минем төп максатым — уйланыр өчен укучы күңеленә орлык салу. Абсолют хакыйкатьне әйтергә Аллаһы Тәгалә дә, пәйгамбәр дә түгел без. Мин кыска шигырьләремдә бөтен кешелекне күз алдымда тотмыйм. Мәсәлән, мәхәббәт турындагы шигырьләрне алып карыйк. Андагы бер сүз өчен күпме хис кичерергә кирәк булганын үзем генә беләм.

Дөресен әйтик, без үскәндә (50 нче еллар) шигъриятебез шактый көпшәк иде. Әгәр дә кече яшьтән үк чын поэзиядә тәрбияләнгән булсак, хәзерге шагыйрьләребез дә күпкә көчлерәк булыр иде. Шулай да без киләчәк өчен иҗади җирлек әзерләдек, торгынлык чорында да әдәбиятка яңалык кертергә тырыштык. Бездә шигърият көчле дип исәплим, нәрсәдән килә соң бу? Бүгенге татар әдәбияты — әлегә дәүләтсез әдәбият. Дәүләтсез булмаган килеш тә, шөкер, без әдәбиятлы халык. Образлы әйткәндә, дәүләтле әдәбият — ул иркә әдәбият. Аның әтисе һәм әнисе бар. Безнең әдәбиятыбыз ятимлектә үсте. Үткәндә һәм бүгендә, җанда, күңелдә булган дәүләт функцияләрен күпмедер дәрәҗәдә әдәбият үз өстенә алды. Яшереп кенә булса да, рәсми даирәләргә ярамаган фикерләр дә яңгыраштырды. Эзоп теле нык үсте.

*— Ярамаган фикерләр дигәннән, бер нәрсә кинәт хәтергә килеп төште әле. Әнгам Атнабаевның 90 нчы еллар башында язылган «Менә шулай!» исемле бер шигыре бар:*

Көн дә иртән: «Великая Русь», —
дип
уяталар урыс таңнары.
Менә тагын урыс кышы җитте,
көрәп ява урыс карлары...

*Ә Сез фикерне 1969 елда ук әйткән булгансыз икән:*

Космополит түгел,
шөкер,
халкым да бар, ил дә, Ватан да.
Мин тынычмын:
татарныкы диеп
төртеп күрсәтмимен ал таңга...

*Белүемчә, сезнең мондый «усал» милли шигырьләрегез, әйтик, «Гөмбәзләре кояшмыни», «Бер генә» һ.б. байтак. Алар өчен эзәрлекләүләр булмадымы?*

— Әйе, дөрес әйтәсез, минем «торгынлык» чорларында язылган милли шигырьләрем шактый булды. Шулай да эзәрлекләделәр дип әйтә алмыйм. Мин властьларга ышанычлы кеше булып тоелдым. 24 яшьтә Әлмәттә язучылар җитәкчесе булдым, аннары Республика Язучылар берлегендә җаваплы урында эшләдем. Мин үземә-үзем рәсми «саклау челтәре» кордым шикелле.

Икенчедән, публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләре дә байтак язылды. Алар да мине җил-давылдан ышыклады. Аннары шигырьләремне аңлап бетерү, төбенә кадәр төшенү дә авыррак бит... Кемнәрдер өчен...

*— Равил абый, Сез «Идел» журналының 1995 елгы 1 санында: «Татар халкы әлеге көндә тарихи махмыр чорын кичерә»,— дип язган идегез...*

— Кичерә, кичерә. Башы бик авырта. Айну бара.

*— Йөзләрчә еллар буе сеңдерелгән коллык психологиясеннән, куллары татар канына буялган ил хакимнәренең исерткеч ялган вәгъдәләреннән халкыбыз айнып бетәр дип уйлыйсызмы?*

— Айнып бетәргә тиеш бер. Бүтән юл юк. Кешелек бетмәгән очракта, татар үзенең кем икәнлеген аңларга һәм расларга тиеш.

*— Күңелне борчып торган тагын бер мәсьәләгә кагылмыйча китә алмыйм. Соңгы вакытта бердәм татар әдәбиятын Татарстан татарлары әдәбияты, Башкортстан татарлары әдәбиятына бүлгәләү сизелә...*

— Китап чыгаруны әйтәсезме?

*— Юк, яшәү һәм иҗат итү мохитләренең төрлелеген әйтүем. Уфа татар иҗатчылары бертөрле мохиттә, Казанныкылар башка мохиттә кайный. Ә ике арада аралашу, фикер алышу юк. Халкыбыз таркау... Бу бердәм халыкның бүлгәләнүенә китермәс микән?*

— Татарстаннан читтә яшәгән милләттәшләребезнең күп кенә әсәрләрен «Казан утлары»нда бастырып чыгарырга тырышабыз. Башкортстан татарларының бездәге татарлардан аерып торучы үзенчәлекле сыйфатларын да күрәм мин. Казан ханлыгы җимерелгәч, исән калу, рухи мәдәниятеңне күтәрү әлеге Татарстан җирендә Уфага караганда авыррак булган. Тере калыр өчен, Казан ягы татарларына урыска төрлечә яраклашырга, буйсынырга туры килгән. Ә Уфа якларына, тау, дала ягына урыска буйсынырга теләмәгән, хөр, азат кешеләр — милләтнең шактый көчле өлеше киткән. Шуңа күрә бездә хәйләкәррәк, усалрак, һәм шулай ук миссионерлар сандалын үткән түземрәк халык яши. Ә «хәйләкәр» сүзе ул үзе дә бик күп мәгънәләргә ия. Башкортстан татарлары исә, миңа калса, чистарак һәм «беркатлырак».

Элегрәк Уфа һәм Казан әдәбият әһелләренең үзара аралашуы бик көчле иде. Мин моны татар язучылары белән башкорт язучыларына карата да, андагы татарлар белән биредәгеләренә карата да әйтәм. Хәзер сәясәтчеләр күбрәк аралаша. Әмма халкыбыз өчен аның әллә ни файдасы сизелми. Большевикларның бердәм татар халкын төрле милли республикаларга бүлгәләп, милләт буларак юк итү сәясәте әлеге көндә үз җимешләрен бирә.

*— Иҗатыгызга кире кайтып шуны да өстәр идем: минемчә, Сезнең соңгы шигырьләрегездә үз-үзегезгә бикләнү бар. «Без» концепциясе «мин»гә күчә...*

— Чынлап тамы?! Шигырьләремне үземә дә тикшереп чыгарга кирәк әле. Сезнең бу фикерләрегез дөрес булмаска да мөмкин, чөнки Башкортстан халкы минем күпчелек шигырьләремне укудан мәхрүм бит. Казанда чыккан китаплар Уфага барып җитми. Мөгаен, Сезнең фикерләрегез дә күбрәк вакытлы матбугатта басылган шигырьләремә нигезләнгәндер...

*— Дөресен әйткәндә, Башкортстанның үзәк китапханәсендә дә Сезнең 1985 елдан соң чыккан китапларыгызны табып булмый. Равил абый, шагыйрь өчен иң кирәкле сыйфат нәрсә, сезнеңчә?*

— Шагыйрь дигәч, сүзнең асылын, эчке мәгънәсен аңлаган кеше күз алдына килә. Әдипнең төп бурычы, әлбәттә, үзеңне тудырган кавемнең максатларын ачыклап, кешелегеңне саклаган хәлдә халкыңа хезмәт итү. Һәр халыкның үз идеалы. Шагыйрь туган халкына юл күрсәтеп баручы маяк шәхес булырга тиештер. Ул үзенә-үзе генә хуҗа түгел, шуңа күрә меркантиль эгоизмнан ерак булырга кирәк.

*— Татар шигъриятенең киләчәген ничек күзаллыйсыз? Яшь буыннан, «яңа Фәйзуллиннар» үсеп чыга алырмы?*

— Яхшыраклар үсәр дип өметләнәсе килә! Без шигърияткә килгәндә милли мәктәпләр күп иде әле. Иң мөһиме — туган телдәге СҮЗ бар иде. Соңрак ул сүзне үтерделәр. Әле без ифрат кыен

чорны кичерәбез, чөнки 70—80 нче елларда бик күп татар мәктәпләре ябылды. Телебез киселде. Әдәбиятыбызга алмаш булып килерлек талантлы яшьләр урыслашты. Хәзер, Аллага шөкер, бу чорлар артта калып бара дип уйлыйк. Шулай да урыслаштыруның нәтиҗәләре тагын унар елга сузылачак әле. Татар мәктәпләренең беренче сыйныфларына кергән балалар үсеп җиткәнче. Аларны боз сукмаса, ачы җилләр таратмаса, киләчәктә әдәбиятыбыз күтәрелеп китәр дип уйлыйм. Әмма бүгенге хәлләргә килгәндә, мин канәгатьмен дип әйтә алмыйм. Талантлар аз. Сәбәбе шул — киселгән тел...

**...Равил абый, сәгатенә карый-карый, бүлмә буйлап йөренә башлады. Ул борылган арада мин телефонны кире тоташтырып куйдым. Телефон яңадан эшли башлады...**

*— Әңгәмәнең соңында, Башкортстандагы бердәнбер татар журналы «Тулпар» турында фикерегезне ишетәсем килә...*

— «Тулпар» журналына иң изге теләкләр телим. Алга таба, сезнең кайбер материалларны «Казан утлары»нда урнаштырып, безнең материалларны «Тулпар»да биреп хезмәттәшлек итә башласак, әйбәт булыр иде. «Тулпар» болай яхшы гына журналга охшаган. Эчтәлеге ягыннан да, эшләнеше ягыннан да күңелгә ятышлы. Журналыгыз татар дөньясының чын мәгънәсендә тулпары булсын иде!

**...Равил Фәйзуллин белән хушлашып, «Ватаным Татарстан» редакциясенә төшеп барганда, каршыма шыбыр тиргә баткан Мөдәррис абый Әгъләмов очрады. Күрәсең, ул телефон эшләмәүдән тәмам гаҗиз булып, үзе менеп киләдер инде. Уңайсыз булып китте. Хәер, ике әдип йөзләрчә чакрым үтеп, әңгәмәләшергә килгән яшь каләмдәшләренең кечкенә шуклыгын кичергәннәрдер дип өметләнәм.**

*1995, август*

## «ШАШ, РУХЫМ, — ДУЛАСЫН ҖАН!»

*(«Сөембикә» журналы хезмәткәре белән әңгәмә)*

Кичәрләр дип, озак еллар күпер салдым,
Эш беткәндә карап баксам — елгам кипкән?..
Гомер буе нур чәчәм дип, җырлар яздым,
Томнар чыккач, карыйм: укучы бар микән?!

*— Шактый ук борчулы уйлар бар бу юлларда. Сәбәп нидә?*

— Без беркадәр үзгә, кешеләрнең таланты кадерсез заманда яшибез. Шагыйрьләрнең уртак мәсьәләләрне уртага салып болай сөйләшеп утырулары — үзе бер татлы халәт. Уртак идеяләр, хыяллар, милли хисләр белән ялкынланып йөри торган кешеләрнең шулай уйланып утырулары да тансык, кадерле. Шәхсән мин үзем ирләр поэзиясе, хатын-кыз шигърияте дип аерып карау ягында түгел. Мин хатын-кызны талантсызрак дип әйтә алмыйм. Бу сәер заманда ирләр төшенкелеккә ныграк бирелде кебек... Ә хатын-кыз гасабилана, уйлана, шул уйланулар еш кына шигъриятә эз калдыра. Элегрәк китабы чыкса, язучы илһамланып иҗат итә ала иде әле. Ә бүгенге вазгыять, кызганыч, алай түгел. Прозаның хәле тагын да авыррак дияр идем мин. Шигъриятә талантлы, зур шәхесләр бар әлегә.

*— Сезнең тагын бер шигырьне искә төшерик әле.*

Академиклармы?
Бездә дә бар. Байтак алар:
хакыйкый да әгъза,
әгъза да хакыйкый...
Тик нишләптер юк арада
        берәр Нәкый,
                яки Бакый,
                        йә Исхакый.

— Әхлак кануннары шактый какшаган бу чорда нәрсәгә таяна алабыз соң? Миңа калса, бер ышанычлы нигез, ул — халык иҗаты. Өлкән буын — халык авыз иҗатыннан ризыкланган буын китеп бара. Талантлы Мәһдиевне озаттык, Аяз ага, Гариф ага олыгаеп килә. Талантлы Марсель Гали дә әлегә калын әсәрләргә тотынмый. Кәләпүш киеп йөри торган чиста күңелле балалар үсеп килә, шуларда өмет. Алар, ныклы рух тамыры — халык иҗатына, халык тарихына, халык эстетикасына табигый тоташсалар, яңа талантлар калкып чыгар, иншалла!

Шигырьнең дога кебек йөргән чагы — дөньяны үзгәртәбез дип инанып йөргән чакларыбыз сагындыра. Ул чакларда, әлбәттә, җиң сызганып ирләр иҗат итә, хатын-кызлар безнең янда бизәк иде. Хәзер «Казан утлары»ның шигърият бүлегенә — шагыйрь Рәдиф Гаташ янына каз бәбкәләре кебек тезелешеп шигырь язучы кыз балалар килеп йөри. Бер караганда, әйбәт бу. Әмма араларында үсмер

егетләр юк. Монысы борчый. Шулай да сүзне бик үк моңсу булмаган шигырь юллары белән тәмамлыйк:

Курыкма, биек оч, Кошым!
Күк чикне беләмени!
Көл, күңел! Дөнья моңы
бер безгә генәмени!
Оч, оч, Кошкай, кис җилләрне!
Шаш, Рухым, — дуласын җан!
...Егылсак — белгән-күргәннәр
яхшыга юрасыннар!

*1998, гыйнвар*

## «МИН КҮКӘЙДӘН ҮЗЕМ ЧЫКТЫМ!» — ДИП ӘЙТКӘН ДИ БЕР ЧЕБЕШ...

*(«Сөембикә» журналы хезмәткәре белән әңгәмә)*

*— Әле генә Сезгә багышланган «Равил Фәйзуллин. Заман. Иҗат. Шәхес» дигән зур күләмле затлы китап дөнья күрде. Шушы китап аша хәзерге заман бөтен татар поэзиясенең үсеш юлын күзәтергә мөмкин. Әлеге китапта Сезнең турыда язган һәр автор (ә алар җитмешләп!) диярлек шигъриятебезгә «ишек шакымыйча гына», өйрәнчеклек чорын үтмичә генә килеп керде, дигән фикер әйтә. Мин үзем дә «Яшь ленинчы»да Сезнең беренче шигырьләрегезне бастырып чыгарганыбызны хәтерлим, һәм Сезне шул чакта ук һич тә башлап язучы шагыйрь дип кабул итмәдем, алай дип уйлау башка килеп тә карамады.*

— Димәк, Сез үзегез дә әлеге китаптагы авторлар фикеренә кушыласыз?..

*— Һичшиксез! Әмма ни өчен шулай икәнен берәү дә ачыкларга омтылмый. Ә үзегез нилектән шулай дип уйлыйсыз? Әллә Сезне бала чактан ук элекке дворян гаиләләрендәге кебек тәрбияләделәрме?*

*Каһарманым*:

— Мин күкәйдән үзем чыктым! дип әйткән ди бер чебеш... — диде дә шаркылдап көлеп җибәрде. Ә шулай да мин аңа:

*— Әйе шул, Раббыбыз Сезне үзе үк шагыйрь итеп яраткан!*

— Саимә апа, мин бит үземне беркайчан да шагыйрь дип атамадым...

*— Туктагыз әле, Фәйзуллин әфәнде, менә Сез әдәбият ветераны... (дидем дә үзем аптырап киттем: ничек инде — Равил — ветеран?!) 23 яшьтән СССР Язучылар союзы члены, 25 яшьтән Әлмәт язучылар бүлеге җитәкчесе; РСФСР язучылар съездында иң яшь делегат, иң яшь идарә члены; иң яшь Тукай премиясе лауреаты; ике йөз томлык «Бөтендөнья әдәбияты китапханәсе» сериясендә шигырьләре басылган иң яшь исән автор һәм башкалар вә башкалар, рус әйтмешли, чем дальше, тем больше. Кыскасы, Сез, Фәйзуллин әфәнде, гомерегезне тулысынча әдәбиятка багышладыгыз. Хуш, шуннан ни чыкты — хәзер әдәбиятның җәмгыятьтәге роле нинди? Кылган гамәлләрегездән канәгатьме?*

— Шәхсән үзем өчен әдәбият юлын сайлау дөрес булган. Һич үкенечле түгел. Бала чакта хыялланганның байтагына ирешелгән. Миллионлаган кешеләр белән китаплар аша уй-фикер бүлешенгән (Равил Фәйзуллинның төрле телләрдә чыккан кырыклап китабының гомуми тиражы миллионга якын. — *С. И.*). Бу — зур бәхет. Без яшәгән чор идеологиясенең позитив яклары да бар иде. Мәсәлән, без әдәбиятны кеше аңын формалаштыручы төп факторның берсе дип инанып үстек. Чыннан да, ничәмә буын (һәм ничә гасыр!) китаптан рух алып тәрбияләнде. Иҗтимагый идеал, эстетик идеал китап белән бәйле булды. Димәк, әдәбият белән. Сез әйткәнчә, әдәбиятның җәмгыятьтәге роле гаять зур иде. Хәзер вазгыять башка. Кимеде әдәбиятның роле, дәрәҗәсе кимеде, укучысы кимеде. Караучы (телевизорны) күбәйде. Карау — иң әүвәл күз эше. Уку — ми эше. Аң аша күзаллау яхшырак, мәгънәлерәк, файдалырак. «Бөтен прогрессивлар регрессив, әгәр кеше үзе таркалса», — дигән бер шагыйрь.

Ә ветеран дигәндә, нихәл итмәк кирәк — килешергә туры килә. Язучыларның белешмә китабын актарып, беркөн аптырабрак калдым: Язучылар берлегенә (без элегрәк Союз дия идек) миннән алда кергәннәр унлап кына кеше калган. Шулай итеп, әдәби гомер ягыннан караганда, иң яшьтән иң өлкәннәр рәтенә күчеп барыш икән...

*— Әйткәнемчә, әдәбиятка яшьли килдегез, элекке Советлар Союзының аркылысын буйга айкадыгыз, дөньяны да иңләдегез. Башка әдәбиятлар вәкилләре белән аралашудан туган фикерләрегез Сезне нинди гамәлләргә этәрә?*

— Алты яшәр юлдан кайтса, алтмыш яшәр көрәшә килер, дигән гыйбрәтле сүз бар. Чыннан да, бик күп йөрелде, яшь чакта йөрелеп калынды. Монысы да бик мөһим. Кемнәрне генә күрмәдек тә кемнәр белән генә аралашмадык. Совет әдәбиятының горурлыгы булган кешеләр — Микола Бажан, Сөләйман Рустам, Юхан Смуул, Эдуардас Межелайтис, Чыңгыз Айтматов, Олжас Сөләйманов, Кайсын Кулиев, Давыт Көгелтинев, Василь Быков, Мостай Кәрим, Владимир Солоухин... Миңа Назыйм Хикмәт, Михаил Шолохов, Александр Твардовский, Константин Симоновларны да күреп калырга туры килде. Юлда йөрүләрнең, сәяхәтләрнең бер зур мәгънәсе шул: дөньяны чагыштырып танып беләсең, нишләп аларда алай да, бездә нигә болай? Шанлы үткәне булып та, татар бүген нишләп бу хәлдә? Җавап бирүе кыен булган бик күп сораулар туа читләрдә йөргәндә... Тагын мондый сүзләр дә бар бит әле: язучы буласы кеше утыз яшькә кадәр укырга, алтмыш яшькә кадәр сәяхәт кылырга, алтмыштан туксанга (!) — язарга тиеш.

*— Димәк, сезнең нәкъ язар чак җиткән?*

— Шулайга юрыйк.

*— Ә менә хәзер, бездәге яңарыш чорында, элек тугандаш әдәбиятлар дип әйтә идек бит инде, алар белән аралашу ничегрәк...*

— Хәзер аралашу азайды. Аерым бер рәсми кешеләрнең төрле дәүләт, республикаларга йөрүләреннән тыш, язучыларның төп контингенты ерак сәяхәт-сәфәрләрдән мәхрүм. Милли әдәбиятлар (әлбәттә, һәр әдәбият милли), дөресрәге, бүтән халык әдәбиятлары белән зур мәгънәдә аралашу аз. Күбрәк үз казаныбызда кайныйбыз. Билгеле бер чорда анысы да ярады. Үзебезнең тарихны, тыелган әдәбиятны, онытылган шәхесләрне беркадәр барлый алдык. Әмма аралашу — ихтыяҗ. Глобальләштерү заманында, аз санлы халыкларның хәле мөшкел заманда, бүтән халыклар мисалын, аларның рухи юлбашчыларының фикерләрен, уй-сәясәтләрен белү зарур. Юкса «йотылганыңны» үзең дә сизми калырсың...

*— Сез байтак еллар «Казан утлары»ның баш мөхәррире, җитәкчесе. Бөтен тарихи гамәле белән бу журнал татар халкының төп әдәби-мәдәни журналы. Журналның бүгенге хәлләре ничек?*

— Табигый сорау. Тагын берничә елдан «Казан утлары»ның (төрле елларда төрле исем белән чыккан: «Безнең юл», «Яңалиф», «Атака», «Совет әдәбияты». — *С. И.*) 1000 нче саны дөнья күрер, иншалла. Үзем, шагыйрь әйтмешли, «бер горурлык хисе» тоям: бүгенге көнгә журналның 165 саны минем имзам белән, минем фатихам белән чыккан. 165 томлык әдәби энциклопедия! Байтак акыл җегәре, күз нуры түгелгән... Бүгенге хәлгә килсәк, әлегә шөкер. Әмма борчулар да юк түгел. Укучылар даирәсенең без теләгән дәрәҗәдә булмавы. Сүз тираж турында. Элегрәк елларда үзен татар дип исәпләгән һәр гаилә диярлек «Казан утлары» һәм «Азат хатын» («Сөембикә») журналларын алдыра иде. Журналның яртысыннан күбе Татарстаннан читтә тарала иде. Тиражлар зур иде. Хәзер вазгыять бөтенләй бүтән. Тиражлар азаюның анык сәбәпләре дә бар: туган телдә чыгучы газета-журналлар күбәйде, ә укучылар саны артмады, милли рухлы интеллектуаль катлам «юкарды» гына. Безне укый торган контингент — укучылар, авыл интеллигенциясе, галимнәр, студентлар, пенсионерларның матди хәле авырайды, ә череп баеганнарның үз шөгыле, алар милли матбугат белән «вакланмый»... Әле шунысы бар бит — үзебезгә дә тәнкыйть аша карый белик — һәр язганыбыз алтын да түгелдер...

Шулай да күңелебезне төшермибез. Әле күптән түгел генә Мәскәүдә чыга торган «Дружба народов» журналы җитәкчеләре безнең редакциядә булдылар. Тәҗрибә уртаклашырга килгәннәр. Заманында миллионга якын данә белән чыккан журналның тиражы нибары өч мең. Безнекеннән өч мәртәбә кимрәк. Берәү: «Минем мунчам гына янды, күршенең йорты бөтенләй көл булды», — дип сөенгән ди. Бездә андый сөенү юк. Үзебезгә дә ныклабрак эшләргә кирәк.

*— Башка шагыйрьләрнең иҗат җимешләрен, китапларын Сезнекеләр белән чагыштырганда, шактый зур аерма күренә. Китап төзү культурасы турында әйтүем. Мәсәлән, Сезнең биш томлык сайланмаларыгызның беренче томы Ркаил Зәйдулла язган мәкалә белән ачыла. Аның аша укучы томлык авторы белән шактый киң таныша. Аннары «Үсмерчак дәфтәреннән», «Яшьлек дәфтәреннән», «Солдат дәфтәреннән» дигән һәм башка шундый бүлекләре бар. Үзеңә кирәген сайлап укыйсың. Бүтән томнар да пөхтә, фәнни эшләнгән. Әсәрләрнең язылу еллары, искәрмә-аңлатмалар, авторлар турында белешмәләр... Мин моны китапка хөрмәт дип аңлыйм. Шушы принципларыгыз турында дип әйтимме, сөйләсәгез...*

— Китап — минем язмыш. Хәер, күбебезнең дә инде. Тирәнрәк уйласаң, милләтебезнең язмышы да моңарчы Китап белән бәйле булды бит. Дәүләтчелек идеясенең дә төбе Китапка тоташкан. Мөстәкыйльлекне, дәүләтне югалткан чорларда дәүләти институтлар функциясен шул ук китап, шул ук әдәбият (дини, дөньяви) саклап калды бит. Бик нык заманча «алга киткән» милләттәшләргә, эш башында утыручы түрәләргә дә онытмаска иде моны! Ә китап төзү культурасына килгәндә, бусы инде язучы кешенең профессиональ вазифасы.

*— Эш башында утырып юньле язучы, шагыйрь булып була микән диючеләр бар. Ә шулай да, әйтик, Г. Афзал, Н. Фәттах, А. Гыйләҗевләр кебек профессионал гына булу мәҗбүри микән?*

— Дөнья әдәбияты тарихында әллә нинди мисаллар бар. Шагыйрьләр арасында ханы-патшасы да, дәрвиш-сукбае да булган. Тарихта эз калдырганнары да җитәрлек. Бу очракта кистереп әйтү кыен. Кеше ләхетенә кеше керми дигәндәй, кемгә ничек язган! Үзем сайлаган юл минем өчен дөрес. Шагыйрь кешегә гражданин булу, иҗтимагый актив булу мәҗбүри дип уйлыйм мин. Бигрәк тә безнең заманда, безнең шартларда. Богема тормышы белән яшәп, «бөегәеп» йөреп, халыкка игелекле хезмәт итү икеле. Хәтта Ходай биргән талантың булганда да. Бездә кайберәүләр шагыйрь имиджын сәеррәк аңлыйлар. Кайчак мисалга Тукайны китерәләр. Алар, бөек шагыйрьнең җисми яшәү рәвешен генә күзаллап, аның бик тә гыйбрәтле «Мин коеп куйган шагыйрь генә түгел...» дигәнен онытып җибәрәләр бугай. Әдәбият үзәгендә һәрчак иҗтимагый яктан нык үзәкле шәхесләр торган. Державин, Гете, Дәрдемәнд... Ә безнең заманныкылар: Мостай Кәрим, Кайсын Кулиев, Рәсүл Гамзатов, Давыт Көгелтинев...

*— Сез Татарстан Язучылар берлегенең Кабул итү Комиссиясе рәисе. Элек тә күбрәк кеше кабул итү тенденциясе бар иде. Янәсе, Мәскәү акчаны күбрәк бирә дигәннән. Хәзер дә көтүе белән язучылыкка аласыз кебек. Ни максаттан икән?*

— Алай ук димәс идем. Гамәлебез әдәби җәмәгатьчелек алдында, аның ихтыяры белән эшләнә. Берлеккә теге яки бу авторны остаханәләр тәкъдим итә, Кабул итү Коллегиясе аларның иҗатын җентекләп өйрәнеп хәл итә, аннары карар идарә тарафыннан раслана. Өстәвенә соңгы чорда кабул ителгән авторлар турында «Казан утлары»нда тәфсилле мәгълүмат бирелә. Бәлки, элекке елларда иҗатлары бик үк югары дәрәҗәдә булмаган кайбер кандидатларны Берлеккә алу очраклары булгандыр, әмма мондый хәл кагыйдә түгел. Ихтимал, чит регионнарда яшәүче авторларга ташлама ясалгандыр... Язучыларның соңгы корылтаеннан соң таләпләр артты. Соңгы бер ел эчендә нибары биш кеше әгъзалыкка кабул ителде.

*— Үкчәгә басып килүчеләр бармы?*

— Кайнар сулышларын җилкә сизми. Аяк тавышлары еракта...

*— Сүз җае чыккач, сорыйм әле: Сез соңгы 35 ел буе тоташтан Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы булып торасыз икән. Әдәбиятыбыз тарихында андый аналог юк. Иҗтимагый актив язучылардан Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Гариф Ахунов та алай озак дәвер идарәдә тормаганнар. Бу феноменның сере нидә? Һәм шуңа өстәп, кырык еллап әдәби хәрәкәтнең үзәгендә торган язучы, гомерлек дигәндәй, идарә әгъзасы буларак, Сез бүген язучылар оешмасының эше турында нинди фикердә?*

— Беренче сорауга җавап: сайладылар. Идарәне язучыларның иң югары органы — съезд (корылтай) сайлый. Сигез съездның һәрберсендә дә каләмдәшләрем ышаныч күрсәткәннәр дип уйлыйм. Соңгы берничә съездда идарәгә сайлаулар яшерен тавыш бирү юлы белән үтте бит.

Язучылар оешмасы турындамы? Мин идарә әгъзасы булып торган бу елларда җиде рәис алышынды. Оешма эшчәнлегенең төрле чорын күрергә туры килде. Язучылар оешмасы — иҗтимагый оешма. Оешманың эшчәнлеге күп факторларга бәйле: җәмгыятькә кирәклек дәрәҗәсе, дәүләтнең карашы — кайгыртучанлыгы яки битарафлыгы, язучыларның таланты һәм активлыгы, җитәкченең булдыклылыгы һ.б. Моннан, әйтик егерме еллар элек, оешманың дәрәҗәсе, реаль көче, мөмкинлекләре зуррак иде. Чөнки функциясе бүтәнрәк иде ул елларда. Шактый нык идеологияләштерелгән, хакимият белән иҗатчыларны тоташтыручы, күпмедер дәрәҗәдә комиссар ролен үтәүче оешма иде. Үзгәртеп коруларга бай яңа заман килгәч, күп республикаларда язучылар оешмалары үзгәреп бетте, бүлгәләнде, күп үзәклегә әйләнде. Мәскәүдә шулай, Санкт-Петербургта, безнең күрше Чабаксарда... Бездә, төрле каршылыклар булса да, бүлгәләнү булмады.

*— Ә ПЕН-клуб? Сез анда әгъза да бугай әле...*

— Әйе. ПЕН-клубның функцияләре бүтән бит. Ул халыкара оешма, ПЕН-клубыбыз булу — Татарстан өчен дәрәҗә. Байтак илләр, республикалар ул халыкара оешмага әлегә алмадылар әле. Аннан соң ПЕН-клуб әгъзалары язучылардан гына тормый, анда галимнәр, журналистлар, сәясәтчеләр дә бар.

*— Сез 1990—1995 елларда Татарстан Югары Советы депутаты булдыгыз. Ул вакытта депутат язучылар, ялгышмасам, бишәү иде. Алга таба ул язучыларның һәммәсе диярлек кат-кат депутат булып сайландылар. Сез үткән сайлауда да, аннан алдагысында да үз кандидатурагызны күрсәтмәдегез?..*

— Һәр кеше бу җәмгыятьтә үз урынында булырга тиеш. Иҗат эше — минем өчен иң мөһиме, һәм, нигездә, шуның белән шөгыльләнәм дә. Ә депутатлык?.. Ундүртенче чакырылыш депутатлары, кызганыч, Декларация, Конституция кабул иткән уникенче чакырылышның бик мөһим законнарын юкка чыгардылар. Депутатларның бик күбе, мөгаен, яртысыдыр, шул ук депутатлар иде. 180 градуска борылырлык сәясәт кылучы депутат була алмыйм шул мин.

*— Тукай исемендәге Дәүләт премиясен чиратка куеп бирәләр (минем фикер генә түгел). Аны ел саен бирү мәҗбүри микән? Зур сәнгати әһәмияткә ия булмыйча, темасы өчен бирелгән очраклары да бар бит. Сез ничек карыйсыз моңа?*

— Тукай премиясе хәлләре миңа яхшы таныш. Миңа аны бик яшьли бирделәр. Комиссия әгъзасы булып байтак еллар эшлим. Сезнең сүзләр белән килешәм. Премия ул иҗат кешесенә стимул бирер өчен куелган акция. Конкрет берәр күренекле яңа әсәр өчен бирелеп, ул бүләк бүтән иҗат кешеләрен «сез дә шундый әсәр, моннан да яхшырагын иҗат итегез» дип «котыртырга» тиеш. Нигездә, бу принцип сакланса да, кайчак премиянең нигезләмәсеннән читләшкән очраклар да була. Моннан егерме еллап элек язылган әсәрләр өчен дә, гомум иҗаты өчен дә бирелгәләде. Иҗатчының бөтен иҗатын бәяләү өчен бүтән чаралар да бар бит югыйсә: мактаулы исемнәр, орден-медальләр, югары пенсияләр...

*— Равил Фәйзуллинның иҗатында башыннан ук — сәясәт, миллилек... Шаккаткыч! Хәзер, заманалар үзгәргәч, милләт «аналары, аталары» күбәеп китте, теләсәң ни язарга, теләсәң ни сөйләргә була. Ә теге вакытларда Фәйзуллинга ничек тимәделәр, аны ничек күрмәделәр икән? Заманасы өчен шактый усал, хәтта хәтәр шигырьләрегез байтак бит...*

— Бу сорауга озак итеп җавап биреп булыр иде. Журнал урыны да исәпле, җае да ул түгел. Җавапның шигъри вариантлары:

Мин — рухым ирешкән кадәр
дөресен яздым чын күңелдән.

Яки:
Вөҗданым белән сөйләшәм —
Шул минем шигъриятем.

Күңелдәген яшермичә ярып әйтү дә бәяләнә кайчак. Ачык күкрәккә туп-туры атарга да базмыйлардыр...

*— Кыска шигырьнең яшәүгә хокукын сорау астына алып, аның турында сүз булсын өчен бәхәсләшәләр микән? Югыйсә бер, ике, өч, дүртьюллыкларга никадәр уй, фикер, фәлсәфә салырга кирәк бит! Татар поэзиясендә, кыска формалар булгаласа да, үз иҗатыгыз белән Сез кыска шигырьләргә тулы гражданлык хокукы бирдегез. Хәзер һәр шагыйрь диярлек кыска шигырь яза башлады...*

— Кыска шигырьләр белән иҗатымны башладым, хәзер дә язам, ахыргача язармын, боерган булса. Бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы. Кыска сүз бу очракта кыска шигырь укучыны әңгәмәгә, соавторлыкка чакыру, аңа ышану, хөрмәт итү. Васыять озын булмый. Шигырь шагыйрьнең үзенчә бер васыяте бит ул. Хәлиткеч хәлдә озын сөйләмиләр. Шигырь тууы — үзенчә бер хәлиткеч акт ул. Хәлиткеч хәл һәрчак үзебез белән. Шәхси планда да, милләт масштабында да...

*— Совет чорында формалашкан кеше буларак, хәзерге җәмгыятьтә Сез үзегезне ничек хис итәсез, ничек яшисез?*

— Күз алдына китерегез: гомере буе ил дип, көн дип бил бөккән карт кибет алдында сөт алыр өчен җитәр-җитмәс тиеннәрен санап тора, яныннан борын асты да кипмәгән үсмер чит илнең затлы машинасында выжылдап узып китә. Бу — шартлы күренеш. Мин, әлбәттә, әлеге карт кеше яки әлеге җелеге оешмаган егет кисәге хәлендә дә түгел. Шулай да күңелгә тия! Хәләл хезмәтнең кадере юк заманда яшибез. Шул исәптән әдәби хезмәтнең дә. Ә, гомумән, күп гасырлык татар әдәбиятында җәүһәрләр күп. Бәһаләүче генә булсын!

*— Беренче китабыгыз балалар өчен чыкты. Дөнья әдәбиятында да шулай ул, һәр олы язучы балалар өчен язуны бурычы дип саный. Гомумән дә, балалар әдәбияты халыкны үстерү перспективасы бит ул. Бу өлкәдә планнарыгыз?*

— Сез дөрес әйтәсез, чын иҗат кешесе киләчәк өчен эшләргә тиеш. Балалар өчен язу — изге гамәл. Уеңда гына булса да, бала чагыңа кайтасың, чистарынасың, сабыйларча дөрес мантыйк белән фикерли башлыйсың. Элегрәк елларда, иҗат башында балалар өчен язсам да, күңелдә олылар иде, ә хәзер, киресенчә, олыгая төшкәч, балалар өчен язасы килә башлады. Сау булсам язармын дип уйлыйм. Теләк зур. Теләкне тормышка ашыруда ике яшьлек улым Газиз дә булышыр кебек. Теле ачылып, бик матур «сайрый» башлады. Гаҗәеп дөнья бит ул — сабыйлар дөньясы.

*— Хыялларыгыз?*

— Шаяннар-тапкырлар мәҗлесендә ишеттем бугай: татардан сораганнар имеш, «вперед» сезнең телдә ничек була, дип. «Алга!» — Ә «назад»? — «Бездә андый сүз юк, андый чакта кырт борылабыз да тагын алга китәбез», — дип җавап биргән, ди. Шушы мәзәктәге шикелле, алга барырга исәп. Язарга, китаплар чыгарырга. Әзерләнгән ун томлыгымны дөньяга чыгарасым бар.

* * *

Җәлилләр, Фучиклар фонында
Үлеп үлемсезлек яулау
Бердәнбер юл түгел тормышта! —

дигән шигъри юлларындагы фикерен Равил Фәйзуллин үзенең иҗаты белән раслады. Биш томлык «Сайланмалар», аның турындагы «Заман. Иҗат. Шәхес», «Борынгы миф һәм бүгенге шигырь» дигән һәм башка китаплар, йөзләгән фәнни хезмәтләр, мәкаләләр, башка язмалар шул хакта сөйли. Шушындый бөек Шәхес белән бер заманда яшәвем өчен мин үземне бәхетле саныйм, аны белүем өчен горурланам!

*2003, август*

## «ЫШАНЫЧ ЗУР, ХЫЯЛ КӨЧЛЕ ИДЕ…»

*(Равил Фәйзуллин белән Рәфикъ Юныс әңгәмәсе)*

*Әңгәмәгә «печтик кенә» кереш сүз*

1960 елның җәе. Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керергә дип имтиханнар биреп йөрим. Бирдем, конкурсны да үттем, мин хәзер — шанлы уку йортының тулы хокуклы студенты! Тик… алай гына түгел икән бит әле. СССР башында Хрущев атлы гаҗәеп бер реформатор тора иде ул чакны. Аның тынгысызлыгының җиле миңа да тиде. Ике ел эш стажы булмаганнар беренче уку елын заочниклар кебек эшләп укырга тиеш икән бит! Мондыйлар безнең арада 4–5 кеше җыелды бугай. Мин үзем киң маңгайлы Равил атлы малайны гына хәтерләп калганмын… Минем ничектер шунда дәрт сүрелде. Монда укытучылар әзерләнгәнен белү исә котны ук алды.

Кыскасы, ошбу арбадан төшеп калдым мин. (Бөтен группабыздан бер (!) укытучы чыккан, диделәр. Шамил Маннапов, Фарсель Зыятдинов, Фирдәвес Гарипова, Шәриф Асылгәрәев, Флера Баязитова, Әнвәр Шәрипов, Рүзәл Йосыпов кебек «группадашларым» бөтенләй башка даирәдә шөһрәт казандылар.)

Тормышымның әнә шул вариантыннан баш тартып, ниләр җуйдым икән? — Бу турыда кат-кат уйланганым бар минем. Һәрюлы гел бер фикергә киләм: югалтуларымның иң зурысы — Равил Фәйзуллин янәшәсендә иҗат итмәвем булгандыр.

Ике ел эшләп, өч ел армиядә хезмәт итеп 1965 елда янә беренче курска (бу юлы журналистикага) кергәндә Равилебез инде иң күп мактала һәм иң күп сүгелә торган, ягъни иң популяр шагыйрьгә әйләнеп өлгергән иде. Моңа аның шул елны «Казан утлары»нда чыккан, ирекле алым белән язылган, «Нюанслар иле» дигән кыска шигырьләр циклы да сәбәп булды… Шул чордарак мин «Татарстан яшьләре» гәҗитенең Равил җитәкчелек иткән әдәби берләшмәсенә дә йөреп алдым әле.

Ни дип сөйлимме боларны? Шул елларда Равилнең бер күркәм сыйфаты күренде. Киң күңеллелеге. Булачак классик безнең шул ничә көнлектер танышлыгыбызны да олылап, миңа гел якын танышы, сабакташы итеп карады, кирәк чакта ярдәм дә итеште әле. (Айдар Хәлим соңрак болай дип язар: «Ул бик кешелекле, рухи һәм матди юмарт. Эшчән. Кешене бервакытта да кимсетмәс, хурламас. Арага кермәс, интригалар, чуар интереслардан ерак торыр…») Мин исә, табигый ки, «сабакташымның» тормыш һәм иҗат юлын бик тә дикъкатьләп күзәтеп бардым.

1967 елда беркая да бирмәгән мәкаләмдә болай дип язганмын: «Яшьләр потларга табынырга яратмый алар. Нык алданганлыкларын, нindidер бер бәндәне (Сталинны) алла урынына күргәнлекләрен аңлагач, алар ачулы-тәнкыйтьчел караш белән бөтен дөньяны күздән кичерделәр, һәрнәрсәгә яңа бәһаләр куеп чыктылар. Шуны белгән хәлдә, иҗекләр санауга корылган традицион шигырь калыбының яңа буын шагыйрьләргә катып калганлык символы, тере хисне буып торучы зиндан диварлары булып күренүенә гаҗәпләнергә кирәк микән?.. «Фетнәче» дип иң әүвәл саф башында барган Равил Фәйзуллинны атадылар, һәм аңа яңа шигърияткә дигән күсәкләрне дә, беренче булуның романтик тәмен дә мул татырга насыйп булды… Фәйзуллинның үзенчәлеге нидә? Талантлы булудан тыш, күзәтүчән, дөньяны образлы күрә, абстракцияләүгә һәвәс…»

Моңа өстәп хәзер шуны да әйтәсе килә: Равилнең ирекле шигырьдән китүе качу да, чигенү дә булмады. Ул анда сугышлы разведка үткәреп, традицион шигырьгә нindidер бер хөрлек, табигыйлек, тормышчан интонацияләр алып кайтты.

Карама күзгә — тонгандыр.
Карама йөзгә — сулгандыр…

Татар шигырендә болай иркен сөйләшкәнне ишеткән юк иде кебек әле. Шагыйрьнең тудыручы, үстерүче һәм үтерүче куе-тыгыз вакыт ташкыны фонында яшәешне берьюлы образлы-символик

итеп тә, шулкадәр гади-тормышчан итеп тә сурәтли алуы күңелгә ниндидер сихер-тылсым кебек тәэсир итә иде.

Инде күптән җәй икән!
Җанда моң әллә ниткән…
Өлгергән бодай кырыннан
кыз бала йөгереп үткән, —
йомрыланган тезләреннән
орлыклар чәчрәп киткән…

Эре адымнар белән әдәбиятыбызның түренә узган яшьтәшем гел сөендереп кенә тормады. Аптыраткан, уйга салган чаклары да була иде.

Шактый каршылыклы дөнья бит ул Фәйзуллин дөньясы. Иркенәя торгач, бөтенләй иркенәеп китеп, шигырь калыбында көндәлек язып баруны гына хәтерләткән нәмәрсәләр дә төшкәләде Равилнең каләменнән. Ташып торган дәрт-дәрманын кая юнәлтергә белмичә, «Көрәш! Көрәш!» дип тә тәкрарлады бит әле ул. Ә бу — саф җилләр искән, яңарыш барган илдә яшәү иллюзиясе тудыра иде, ягъни ул чактагы сөрсегән режим өчен кулай эш иде. (Шөкер, иҗат гомеренең 30 еллабы тоталитар заманда үтсә дә, режимга майлы калҗалар тәтемәде Фәйзуллиннан. 5 томлык әсәрләрен чыгарганда аңа бер генә шигыреннән дә баш тартырга туры килмәде бугай, бер-ике шигырендә 2–3 хәрефне алыштыру да бик җитте.)

Вөҗданым белән сөйләшәм, —
шул минем шигъриятем!

Равилнең девизга тиң ошбу юлларын тәнкыйтьчеләреннән кем генә сокланып кабатламады икән? Минем исә кайчакта болай дип әйтәсе килә башлый иде: «Хатын-кыз заты, гыйшык-мыйшык турында сөйләшеп туймас нинди вөҗдан булды инде бу!»

Шигырьдә «лирик герой» дигән нәрсә дә бар бит әле. Ул шагыйрьнең үзе белән тәңгәл килергә дә, килмәскә дә мөмкин. Р.Фәйзуллинга кадәр лирик геройлар шигырьгә бизәнеп-ясанып, фәрештә кыяфәтендәрәк чыгалар иде. Равилнеке исә бик макталмаган якларын да яшереп-нитеп тормый. Менә мондый лирик геройны күргәнегез бар идеме сезнең?

Бишмәт эләктерелгән бер төймәгә генә.
Теләк тә, хәл дә юк…
…Шамук мәчеседәй кайтып киләм…

Аталар һәм балалар. Катлаулы, кайчакта газаплы мәсьәлә. Буыннар алышынган сикәлтәләрдә шактый рухи байлыгы коелып калган татар өчен аеруча четерекле ул. Ата-ананың баланы хаталардан аралап каласы, үз копияләре итәсе килә. Баланың исә «далада» беркайчан да булмаганны — үзенекен табасы килә. Алгарыш та булсын дибез бит. Фәйзуллин ошбу мәңгелек мәсьәләгә ачкыч юнәткән түгелме?

Үз иманың булсын.
Тик ул иман
сызып ташламасын минекен.
Мин — әтиең.

Равил үзенең фамилиясен кыскартмады, Әхмәт Фәйзи белән Җәүдәт Фәйзиләрне кысрыкларга уйламады. «Фәйзуллин»да, бигрәк тә аның басым белән әйтелә торган урта иҗегендә, ниндидер бер егәр бар. «Приватизацияләп», шагыйрь бу фамилиягә анда моңарчы беркайчан да булмаган көч-куәт салды. «Гамзатов», «Айтматов»лар кимәлендә яңгыратырга да ымсынды бугай. Мескенлектән гарык татар да шуны ук теләп торды. Ләкин нидер җитми калды. Бәлки, җитмәгән нәрсә талант та булмагандыр… Бик тә, бик тә җиткерергә теләү үзе төп сәбәп булмады микән әле?

Фәйзуллин бит ул шигърияткә авызлыкланмаган ярсу Пегаска, дөлделгә атланып килеп керде, шуңа да иң биек үрләренә шул беренче елларда менде ул. Тагын да биеккәрәк меним дип, иҗатының нәтиҗәсе турында күбрәк уйлый башлау, нәтиҗәне планлаштыруга артык зур әһәмият бирү бәйсезлеген киметә төшмәде микән? Нәтиҗәне тәэмин итәргә мөмкин шартларга һәм кешеләргә бәйле башламадымы икән? Һәрхәлдә, иптәшләре шагыйрьдә конформизм, юл куючанлык чалымнары күренә башлаганын сизми калмады.

Ләкин шунысы да хак: санаулы язучылар рәтендә озак еллар Мәскәү «обоймасы»нда йөрсә дә, Равил Фәйзуллин «служилый шагыйрь»гә әйләнмәде, Мәскәү Кременә дә, Казан обкомына да бил бөкмәде.

Хәтта киресенчә дә әле.

Космополит түгел,

шөкер,
халкым да бар, ил дә, Ватан да.
Мин тынычмын:
татарныкы диеп
төртеп күрсәтмимен ал таңга.

«Минеке» дип бүлмим күкне, айны,
мөһер сукмыйм ел фасылына…
Милләт исемен такмыйм урман-суга,
агач-ташның иң асылына…

Бу шигырь 1969 елны язылган. Аны нинди ләззәт кичереп укыганымны һич онытасым юк. Җанны гына түгел, тәнне дә басып торган милли мескенлек каядыр олакты — җилкәләр үк тураеп китте. Урыс шовинизмының яңагына безнекеләрнең болай чалтыратып сукканы юк иде әле.

«Колонизатор әлифбасы» дигән шигырь исә 1975 елны язылган:

Куа да,
бүтән ыру адәмнәрен
җиреннән-суыннан,
үз хатыны, балалары алдында
хозурланып әйтә тиран:
«Җиндем!..» — диеп.

Бераз вакыт үткәч,
оныкларына тукый:
бу җирләрне азат иттем!…

Соңрак —
иске зират урыннарын абзар ясагач,
оныкларының балалары:
«Ватаным!..» дип шигырь яза.

Бусы инде — җитдирәк гамәл, системаның үзенә кизәнү. Кырым җирлегендә язылган, ләкин безнең тарихка да бик мач килә…

Әдәбияттагы күрше басуларга — проза белән драматургиягә генә кереп чыгудан да тайчанган, шагыйрь булуны барыннан да өстен куйган Фәйзуллин гомерендә бер тапкыр депутат булып карады. Татарстан Югары Советында. Җаны түзмәгәндер инде: республикабызга Суверенитет бирәчәк XII чакырылыш иде бит бу. 30 августтагы Декларация игълан ителәчәк 30 август көне Югары Советта аның ялкынлы һәм акыллы чыгышы белән башланып китте… Ләкин актив депутат чыкмады шагыйрьдән. Аның ниндидер без белмәгән уйлар белән иелгән авыр башы «татар» һәм «культура» дигән сүзләр яңгырагач кына калкынып куя иде.

Бераздан бу барлы-юклы мөстәкыйльлекне дә җую башланды. Иҗатында чагылмагач, шагыйрь боларны күрмиме, әллә күреп тә күрмәмешкә салышамы дип йөрсәм, тегесе дә түгел, бусы да түгел икән. 1999 ел азагында ул «Идел»гә «Идея» дигән бик тә үткен, кыю шигырен китерде. Шунда мондый шаян уй килгән иде башка: «Казан утлары»нда борганнардыр, бәлки?» Шагыйрь Равил Фәйзуллин баш мөхәррир Равил Фәйзуллиннан тәвәккәлрәк бит! Хәер, тегесен дә йөрәксез димәс идем…

Куркаклар күп ләкин. Хәбәрчеләребез язуынча, татар өчен хәлиткеч мәлдә, халык исәбен алу әзерләнгәндә, Башкортстанда татар телендә чыга торган «Кызыл таң» һәм «Өмет» гәҗитләре татарга каршы да эшләгәннәр. Татар телендә чыга торган «Тулпар» атлы яшьләр журналы исә, Татарстан чиген дә үтеп кереп, Нәбирә Гыйматдиновага «татар-башкорт язучысы» дигән мөһер суккан! Нәбирәбез, Башкортстанның кай якта икәнен дә белмәгән, мишәр кардәшләрен дә коткыга бирелмәскә, татар дип язылырга өндәп мәкаләләр чыгарган Нәбирәбез, күргәч егылып китә язды… Үткән заманның чукындыру осталары Малов, Ильминскийлар искә төшә. Алар да бит татар җанына аның үз теле аша үтеп керергә омтылганнар.

Ә безнең үзебездә җилнең кай яктан исә башлавын сизү белән кинәт өнсез калганнар яки, матбугатта урын биләп, башкаларны өнсез калдырганнар азмы әллә? Иң кызыгы шул тагын: тегендәгеләре дә, бездәгеләре дә вазгыятьне аңлап хәлгә керүне сорый бит әле. Теләктәш булуны! Шаккатудан гаҗиз калып ни әйтергә белми торганда, кинәт, рәхәт бер ташкын булып, хәтер түреннән сүзләр агыла:

Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга.
Куркырга-өркергә

җай бар ул һаман да…

Менә ул шигъри сүз егәре!

Бик сирәк була торган хәл: Р.Фәйзуллин исеме турында бәхәсләр барган беренче елларда шагыйрьләр һәм тәнкыйтьчеләр генә түгел, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, Роберт Бикмөхәммәтов, Рифкать Әхмәтҗанов кебек прозаиклар һәм галимнәр дә, җылы сүз әйтеп, аның иҗенә иңнәрен куйдылар. Тикмәгә түгел бу. Уйлавымча, Равил Фәйзуллинның шау-шу куптарып шигърияткә килүе тарихта һәм археографиядә — Нәкый Исәнбәт, Равил Фәхретдинов, Миркасыйм Госманов, тарихи прозада — Нурихан Фәттах, җыр сәнгатендә — Илһам Шакировлар эшчәнлеге, сөргеннән Хәсән Туфан кайту, янә «Кыйссаи Йосыф» басылып чыгу, Марсель Сәлимҗанов килгәч Г. Камал театры тернәкләнеп китү кебек татарның милли аңы уянуны әзерләгән олы гамәлләргә килеп ялгана…

Күптән түгел «Мәгариф» нәшриятында «Равил Фәйзуллин: заман, иҗат, шәхес» дигән китап дөнья күрде. Бер иҗат әһелен шулай бөтен яклап тасвирлау, шундый да әтрафлы-тирән «стереопортрет» тудыру юк иде әле бездә.

Шулай да Равил үзе генә җавап бирә алырлык сорауларым да калган иде минем.

Сезнең алда — Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Габдрахман улы ФӘЙЗУЛЛИН белән әңгәмә.

— *Син, Равил, «Менә без дә үсеп җиттек, әни!» дип язган идең. Әле «кайчан гына». 35 ел элек кенә. Хәзер бөтенләй дә үсеп җиттең инде, әйеме?*

— Артыгы белән! *(Көлә.)*

— *Алтмыш яшеңне каршыларга җыенасың. Күп әйберләр бар. 40 китап. Шанлы исемнәр. Кәгазьгә язып биргән исемнәрдән тыш абруй бар. Кәефләр ничек соң синең?*

— Кәефләр ару болай. Алга таба шушы алган юлдан тайпылмыйча, темпны киметмәскә тырышып эшләргә инде. Темп анысы кимер инде ул бераз. Чөнки күзләр уңа төшә. Гаҗәпләнү хисе кими — еллар үткәчтен… Ләкин бүтән юл юк безнең. Алга барырга! Максат бар бит. Максат — халыкка хезмәт итү. Мин дөрес юл алдым дип исәплим. Бүтән эшне бик белеп тә бетермим, шушы әдәби эшкә кече яшьтән үк кердем һәм уңга-сулга тайпылмыйча шул юлдан барам шикелле, кырык елдан артык инде.

— *Мин сине, беләсеңме, кайчаннан бирле беләм? Мин, син дә инде, 10 нчы класста укыган чак бу, «Пионер» журналы бер әдәби кушымта чыгарган иде. Шунда синең «Туган йорт» дигән шигырең дә бар иде. «Кара син аны, язып та күрсәткән бит!» дип, сокланып исемеңне күңелгә бикләп калдым. Үзем дә язгалыйм бит инде.*

— Әйе, хәтерлим. 1959 елны булды шикелле. Сыек алсу төстә чыккан иде ул кушымта. Кушымтасы ук сакланмаган, ләкин үземнең шигырьне кисеп алганмын.

— *Беренче тапкыр университетта очраштык бит.*

— Әйе, имтихан биргәндә.

— *Иң әүвәл мин сиңа теге шигырьне язган малай буларак игътибар иттем, шул икән инде Равил Фәйзуллин дип. Төс-кыяфәтеңә дә дикъкать ителде. Үзең язганча, болын хәтле булмаса да, киң маңгай. Үз-үзеңне тотышың, атлап йөрүләреңнән үк ниндидер бер үзенчәлек, шәхес чалымнары сиземләнә иде. Менә шул тырпаеп торган «мин»еңбөтен киләчәк язмышыңа тәэсир иткәндер дип уйлыйм мин. Син әдәбиятта куптарган шау-шулар, шигырьдәге үзенчәлекле урының таланттан да әүвәл менә шуннан килеп чыккандыр ул.*

— Дөньяны яхшыртырга дигән зур теләк бар иде. Безнең саф, наив, чиста вакыт бит инде. Өлеш кертәсе килә иде. Ул чакта әле коммунизмны якынайтасы килү дә булгандыр.

— *Ул заман өчен табигый бу. Ләкин минем әйтәсе килгәнем бүтән иде. Тукайлар, Такташлар, Туфаннардан соң дистә еллар буена ниндидер иссез-төссез, системага дан җырлауга гына корылган шигырьләр ташкын булып агылды. Моң да юк, шагыйрь шәхесе дә юк анда. Кайбер искәрмәләр-чыгармалар булган булуын. Аннары, дөньялар бераз үзгәргәч, ихлас шагыйрьләр килә башлады. Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Роберт Әхмәтҗанов… Талант ягы шәп. Шәхес тә бар. Ләкин алар һаман да әле үзләрен күпләр эчендәге «мин» дип хис итәләр иде кебек. Күпләрнең берсе, күмәклекнең өлеше итеп. Ә син бөтенләй башкача килеп кердең: башта — мин, аннары калган бөтен дөнья! Шулаймы?*

— Анысын миңа әйтүе кыен, ләкин ышаныч һәм хыял бик көчле иде.

— *Менә шул «мин»ең биргәндер дә инде ул ышанычны. Син иркен язып киткәнсең, беркемгә һәм берникгә карамыйча.*

— Аның чоры шулай туры килде инде. Дөньясы иркенрәк иде. Син әйткән ул «минлек» булган булса, аны күрсәтергә мөмкинлеге дә ачылган. Иҗтимагый шартлар дигән нәрсә. Аннан, син әйтә

башладың бит әле, иссез-төссез поэзия, дип. Безнең, яшь студент шагыйрьләрнең, бик ачу килә торган иде шуларга. Исемнәрен әйтеп тормыйм инде.

— *Әйтсәң-әйтмәсәң дә мәгълүм инде алар: Нур Гайсин, Галимҗан Латыйп, Мөхәммәт Садри... Тәнгә чыккан кызамык тимгеле кебек, алар бөтен татар шигыренең хәлен чагылдырдылар... Теге синең «минлек»кә кайтыйк әле, Равил. Каян ул синдә? Нәселдән килмиме? Бәлки, сезнең «нәселнең күзе яшел»дер?*

— Безнең әни затлы нәселдән. Бай да булганнар. Ул хәтта миңа кайчакта әйтеп тә куя иде, йөрмәле шул хәерче малайлары белән, дип. Бет иярмәсен дип әйткәндер инде, бет иде ул вакытта. Чагыштырмача хәлле яшәдек, эти — колхоз председателе.

— *Ә-ә-ә! Бусы бик зур әйбер. Кемнәргәдер баш иеп яшәү булмаган, димәк, авылда.*

— Мәктәптә дә, «бишле»гә укыгач, председатель малае булганга яклыйлар, дип әйтәләр иде. Әзрәк кыйнаштыргалыйлар да иде. Чөнки... Ул вакытта хезмәт көненә эшләү бит. Әти отчет-сайлау җыелышында әйтә инде, тырышып кына эшлик, быел икмәкне хезмәт көненә 200 граммнан түгел, 300 граммнан бүләбез, дип. Ел үтеп китә, колхоздан тагын себереп алып бетерәләр ипине. Әтинең вәгъдәсе үтәлмәгән була. Тагын алдады, диләр инде авылда. Олылар сөйләшкән сүз миңа да килеп бәрелә... Ниндидер бер сыйнфый аерымлыкны, безгә карата сыйнфый ачулы мөнәсәбәтне тоя идем мин. Эзе кала бит инде моның. Аннары әни озын тәнәфескә дип бер кисәк май ягылган ипи бирә иде. Класста ипи алып килә торган тагын 3–4 кенә малай бар. Мин кайбер дус малайларга өлеш чыгарам, әлбәттә. Тик ул ипинең бөтенесен дә биреп бетереп булмый бит инде. Тегеләре дә рәхмәт әйтеп кенә тормый әле. Такмак та чыгарганнар иде хәтта:

Әче башы урманында
Ике ябалак уйный.
Бирмә, Равил, ипиеңне,
Барыбер тамагым туймый.

Менә болар бар да беркадәр аерымланырга мәҗбүр иткәндер инде. Мин болар кебек түгел дигән уй булган. «Бишле»гә укыйм бит, укытучылар да мактап, күңелне үстереп тора. Ары китәсемә, үземнән «кеше» чыгасына ышанганмын инде.

— *Бусы аңлашылды алайса. Инде сәләт-талант ягы. Нәселдән килмиме?*

— Кистереп әйтә алмыйм. Бала чакта бик сизмәдем. Хәер, эти язгалый иде, хәзер дә язгалый. Хәтта матбугатта актив язышкан өчен Балык Бистәсе район газетасы Кадыйр Сибгатуллин премиясен дә бирде. Энем — Рөстәм Фәйзуллинның да (Акъегет) шигъриятта урыны бар инде. Кем белә, бәлки ерак нәселдә дә каләм ияләре булгандыр.

— *Тәнкыйтьчеләрең беравыздан сине, өйрәнчеклек чорын үтеп тормады, диләр. Алай ук түгелдер түгелен. Мин үзем сине чын мәгънәсендә шагыйрь дип 23 яшеңдә язган «Карт балыкчы» дигән шигыреңнән соң таныдым. Шулай да бик тиз җитлеккәнсең. Университетка килгәнче кайда, нинди шигырь мәктәпләре үттең?*

— Ботинкадан башланды бар да. Мин бәләкәй әле — 7–8 яшьләрдәдер. Безнең авылга баянчы Гани Вәлиев килде, Җәвәһирә Сәләхова белән. Утырам концертта шулай — качып кергәнмендер инде. Миңа уены да, җыры да әллә ни тәэсир итми, мин боларның ботинкаларын карыйм. Елык-елык килеп торган, лакланган ботинка! «Зур үскәчтен шундый ботинка киеп йөрсәм шәп булыр иде, — дип уйлыйм. — Авылга шуны киеп кайтсаң, эти белән әнигә дә шатлык була бит инде». Андый ботинка киеп йөрерлек зур кеше булыр өчен нәрсә кирәк? Мин китап укыган бала, минем өчен язучы иң зур кеше. Күңелдән шигырь төртеп торгандыр инде, тора-бара «Шагыйрь булам!» дип йөри башладым. 4 нчедә укыганда микән, 5 нчедә микән, директорыбыз Гариф абый Шәйдуллин кулыма «Әдәбият теориясе» дигән китап тоттырды. Әтиләр белән бик дус иде, минем ни дип хыялланып йөргәнне белә. Габдрахман Сәгъдинең бу китабы латин шрифтында язылган иде. Шигырьнең рәтен беләсе килә бит — өйрәндем бу шрифтны, ерып чыктым китапны!

— *Дәрт көчле, әйеме?*

— Дәрт көчле! Мин аның яртысын аңламадым да инде, силлабик система ни дә силлабо-тоник система ни анда — аермыйм, белмим, ләкин кайбер нәрсәләрне чамалый башладым. Менә шул булды минем шигырь мәктәбе. Бусы да теге син әйткән «минлек»кә тәэсир итми калмагандыр инде... Аннары — район газетасында шигырьләрем басыла башлау, анда эшләгән Рәшит Гарипов, Хәмзә Зариповларның киңәшләре... Университетка килгәч, ярты еллап Даут Сөнгатов чабуына ябышып йөрдем. Талантлы гына яшь шагыйрь бар иде бит, минем якташ, бәлки, беләсеңдер.

— *Беләм Даутны, ачы язмышын да беләм. Аракы әсирлегенә эләгеп юкка чыккан талантлы шагыйрь.*

— Даут мине бик күп татар шагыйрьләре белән таныштырды. Шул даирәгә керәсе килә бит инде... Язучыларның Тукай клубына йөрибез, бер «Әдәби җомга»ны да калдырган юк. 1–2 елдан

анда үзебезгә дә чыгыш ясау насыйп булды. Университетның әдәби берләшмәсендә катнашучылар буларак.

— *Син ул берләшмәнең җитәкчесе дә булдың бит әле.*

— Әйе. Аннары — китте, мин сиңайтим! Буа ерылган кебек булды. Гәҗит-журналларда басыла башладым, нәшриятка да илтеп бирдем кулъязмаларны. 1964 елда «Казан утлары»нда теге «Нюанслар…» чыкты.

— *Ай үсәсен көн үскән Камыр батырларның куркыныч ягы да бар бит.*

— Нәрсә? Ничек?

— *Гел көчләре артканны сизеп тора алар. Шуны күрсәтәсе, сыныйсылары килеп, beләкләре кычытып тора. Әле кичә генә көче җитми иде берәүгә — бүген ничек икән? Синең әдәбиятта шулай тиз үсүең дә психологик яктан бик кызык. Бер шигырең дә бар бит әле:*

Дуамал күтәрермен дә
уңайсыз төшәрсең күк…

— Анысы соңрак аның. Хәсән Туфанга бу. Мин Хәсән агага шигырьләремне илтеп биргән идем. Ул теге яшел карасы белән бөтенләй бетереп ташлаган инде. Бик күңелем төшеп чыктым. Бер дә яхшы сүз әйтмәде ул миңа. Әз генә булса да өмет калдырмады. (1970 елда Р.Фәйзуллин Хәсән аганың юбилее уңаеннан бик җылы мәкалә бастырачак.)

— *Бу кадәресен үк көтмәгән идем. Хәсән агага шулай…*

— Ул чакта бернинди авторитетлар белән исәпләшми идек. Максималист чак. «Безнеке дөрес!» дигәнгә нык инанганбыз.

*— Җир җимермәк идек!*
*Күкне ватмак идек!*
*Мәңгелеккә балкыр*
*утлар якмак идек!*

*— Шундый чак инде бу сезнең, алайса.*

— Әйе. Без инде Назыйм Хикмәтләрне, Уитменнарны, Балтыйк буе шагыйрьләрен укыйбыз. Межелайтислар, Айтматовлар Ленин премияләре ала анда. Безнең дә шулай зураясы килә. Булмый ул Галимҗан Латыйплар белән, үзебез яңача язып чыгабыз, милләтне күтәрәбез, дибез. Без инде дөнья әдәбиятын беркадәр өйрәнеп, чын хакыйкать сүзенең тәмен тоя башладык.

— *Амбицияләр зур, димәк. Тукайлар күлмәген киеп карау булдымы?*

— Нишләптер ул чакта Тукайга мөкиббән кителмәде. Ул безгә кадимирәк булып күренә иде. Күрәсең, Тукайның асылын аңларга өлгермәгән булганбыз.

— *Аяз Гыйләҗев әйткән булган, салават күперенең бер башында — Тукайны, икенче башында Фәйзуллинны күрәм, дигән. Дөресен генә әйткәндә, мин дә синнән шуны көткән идем. Безнең заман Тукае булырсың дигән идем. Талантыңны, кыюлыгыңны, үз-үзеңә ышанычыңны күреп. Үзеңчә итеп әйтсәк, син «болай да бәләкәй түгел», бик күпкә ирештең. Ләкин син Тукай була алмадың.*

— Әйе. Минем бит исемем бүтән.

— *Язу процессыннан тыш эшләр белән артыграк мавыгып ташладың бугай син. Үзең җитештергән продукциянең барып ирешүе, нәтиҗә бирүе, резонанс туу синең өчен үтә мөһим иде. Бик табигый нәрсә үзе, бер гаебе дә юк. Хәзер, базар заманында, хәтта мактала да бу. Ләкин, ни генә булмасын, ул синең төп эшеңә бераз зыян салды бугай. «Һәр табуда күпме югалтулар» дип язган идең бит әле, шуның кебек инде менә.*

— Бу — субъектив фикер. Бәхәсле әйбердер. Беренчедән, мин Тукай булырга беркайчан да теләмәдем. Мөдәррис Әгъләмовтагы кебек, андый чир булмады миндә.

— *Ярар, Тукай түгел ди, татарның бүтән бер бөек шагыйре ди…*

— Синең сүзеңдә хаклык бар. Ничек әдәби мәйданга чыгып була, зуррак булып чыгып була — бу хакта, әйе, уйлана идек. Үрнәкләре бар бит. Айтматовлар, Көгелтиневләр ничек күтәрелде әнә, Мостай Кәримнәр. Безнең дә олы мәйданга чыгасы килә иде, яшерен-батырын түгел. Аның өчен нәрсә кирәк? Аның өчен урысча басылырга, бүтән телләргә тәрҗемә ителергә кирәк… Минем ул чакта шигырь теле чамалырак иде. Урысча китапларны да күп укыгач, урысча фикерләү өстенлек алган, күрәсең… Тәрҗемә иткәндә иң әүвәл ни кирәк? Фикер кирәк. Телбизәкләр бик күчми анда. Тел хисабына күбрәк фикер сөрешенә игътибар ителә иде шул… Һәм шушы тәрҗемә эшләрен оештыру, чыннан да, байтак кына вакытны ала иде. Бу — сверхзадача куеп эшләү инде.

— *Вакытны да ала, ихласлылыкны да киметергә мөмкиндер әле.*

— Табигыйлеген дә киметә торгандыр, әйе, чөнки тәрҗемә өчен эшләү булып чыга бит инде. Бу нинди яңгыраш, нинди резонанс алыр икән дип уйлыйсың.

*— Тукайны үрнәк итмәсәң дә, бөеклек юлы турында уйлангансың бугай син. Бер шигырең дә болай дип язасың:*

Шагыйрьләрне үлемсез итә
халкы өчен яну.

Ә бит үлеп үлемсезлек яулау –
бердәнбер юл түгел тормышта.

*Монысы да син, 1968 елда. 1981 елда исә фикерең никтер үзгәрә:*

Корбан була алсаң гына
тибрәнер исемең
мәңгелек рәшәсендә.

— Бардыр инде андый әйберләр.

*— Бөеклек дигәндә, талантлы, үтә талантлы кешегә дә ниндидер бер чикне үтү кирәктер. Үз-үзеңне аямау чигеме икән бу? Тукай була алу-алмау бер хәл, шул ягы да бар: Тукай буласы киләме әле кешенең. Миңа, әйтик, Тукай талантын бирделәр дә ди, әмма — язмышын да өстәп. Алырмын микән әле мин?*

— Әйе, минем дә уйлаган бар моны. Миңа Ленин язмышы кирәкми. Тукай да буласым килми. Аннары, Тукай турындагы фикерләрем бик каршылыклы минем. Тукай — халыкның бәгырендә, монысы һичшиксез шулай. Ләкин аны рәсми рәвештә дә күтәрделәр ич. Мәскәү дә дигәндәй...

— *Нәрсәсе начар соң моның?*

— Аны күтәргәч, бөтен игътибар аңа китте. Аның янәшәсендәгеләр, әйтик, Исхакый, аннан акылсызрак булмаган, милләт мәсьәләсендә акыллырак та булган әле.

— *Мәскәү, син әйткәнчә, Тукайны күтәргәндә Исхакый кайда иде соң?*

— Кая булсын?

— *Чит илдә иде.*

— Гомумән, татар әдәбияты тарихы юньләп өйрәнелмәде бит. Борынгылары да, соңгы чорлары да. Хәтта Тукай үзе дә халыкка берьяклы гына тәкъдим ителде. Ул чорда рәсми үзәк һәр халыктан берәр шәхесне күтәрүне мәгъкуль күрде. Ясалма рәвештә — казакъта — Җамбул, лезгинда — Сөләйман Стальский, осетинда — Коста Хетагуров… Әгәр дә без Галимҗан Латыйпларны гына түгел, Галимҗан Ибраһимовларны, Тинчуриннарны, Исхакыйларны да укып, Мәрҗани, Риза Фәхретдиннәрне дә белеп үскән булсак, безнең әдәбият хәзер гел бүтән булыр иде.

— *Тегеләрен алганнар бит аны бездән, Равил. Инде Тукай да булмаса? «Тукай» дигән байрак булмаса? «Туган тел»не гимн итеп җырлап, киләчәккә өметне саклау булмаса? Татарстаннан читтә, хәтта башка илләрдә дә Тукай җәмгыятьләре оешмаган булса?*

— Яхшы, хәзер менә, бер гасырдан соң да һаман аңа гына табынабыз икән, нинди прогресс булырга мөмкин ди? Минемчә, бөекләргә табынудан бигрәк, хезмәтең белән алар эшен дәвам итү файдалырак һәм саваплырак.

— *Тукайлар, Такташларныябырылып укыган халык берзаман шигырь укымый башлады. Кызыл пропаганда язып күңелен кайтардылар халыкның, шигырьдән биздерделәр. Шәп лириклар буыны килеп, хәлне бераз үзгәртте үзгәртүен. Ләкин гади юл белән генә халыкны янә шигырьгә кайтарып булмый иде инде, күрәсең. Менә шунда син куптарган шау-шу бик тә ярап куйды.*

— Безнең төркемнең роле булды дип уйлыйм, әйе. Шигырьгә игътибар артты. Ул бездән генә тормады, безгә вакыты шулай туры килде инде.

— *Бәлки, җаныңның ваклыгын гына түгел, олылыгын да тулаем заманга гына сылтап калдырырга кирәкмидер? 80 нче, 90 нчы елларда әнә иҗтимагый җанлану, хөрлек хәттин ашкан иде. Кемнәр килеп ни күрсәтте соң?*

— Монысы дөрес, әйе, дальше.

— *Дальше дан турында сөйләшеп алыйк. Кинәт ишелеп төшкән дан ничек аяктан екмады сине? Япь-яшь малайны?*

— Анысын мин белмим инде.

— *Белгәнсең! Бу турыда кат-кат уйлангансың син. Шигырьләреңнән күренә бу. Болай дип тә язгансың:*

Аңладым: Дан атын
        тезгенләү — көч икән!
Тыңлату дәвасы, —
эш икән, эш икән!

*Сөбханалла, син гел аякта нык басып тордың. Ә бит барлы-юклы даннарын аракы белән кушып эчеп япь-яшь килеш дөньядан ук киткән шагыйрьләр дә булды безнең. Бер генә дә түгел.*

*Сезнең теге төркем дә шактый тотрыклы булып чыкты ул яктан. Ул «бишлегегез» турында Марсель Галиев гаҗәп шәп итеп язган иде. Кайбер нәрсәләрне генә ачыклыйк. Әмәт тавына ничек килеп урнаштың син?*

— Общежитиедә яшәп карадым да 2 нче курста киттем аннан.

— *Нигә киттең?*

— Анда-а-а! Дүрт кеше бәләкәй бер бүлмәдә! Минем төнлә утырасы килә, даһи шигырьләр язасы килә — хут юк.

— *Аралашырга кеше күп аның каравы.*

— Университетта да аралашып туйган көне буе. Миңа ялгызлык кирәк. Миңа бөеклекне раслар өчен көч тупларга кирәк! Әмәт тавында бүлмә таптым — подвал шикелле кап-караңгы бүлмә. «Ниһаять!» дидем шунда үз-үземә. Минем кәгазем минем өстәлемдә кайтуыма нәкъ шул үзем калдырган килеш тора! Капланып җыладым мин шатлыгымнан.

— *Өйнең бер бүлмәсе инде бу, әйеме?*

— Бер бүлмә, өйнең хуҗасы бар. Соңыннан без ул йортны сатып та алдык. Әтиләр күчтеләр. Аның мунчасы бар ие, алмагачлары. Үзе шәһәр уртасында, үзе — авыл! Өч кенә тукталыш «Кольцо»дан.

— *Сезнең ул «бишлек»тә син инде, Рәдиф Гаташ, Ренат Харис…*

— Рөстәм Мингалим белән Гәрәй Рәхим килеп кушылды… Андагы ул хөрлек, фикер очышлары! Ул сүгүләр теге мөтәшагыйрьләрне, ул үзебезнең бөеклек турында уйланулар, хыялланулар! Просто котырып бетәдер идек. Бу инде Язучылар союзы да түгел, башка да түгел. Штаб, чын штаб иде — яшь әдәбият штабы. Булмаган кеше калмады анда. Мәһди (Мөхәммәт Мәһдиев. — *Р.Ю.*) дә килде — язучы түгел әле ул чакта. Мәһдигә рекомендация биргән кеше мин *(көлә)*. Бүген аксакал булып йөрүче күп агайлар ул заманда әдәбият офыгында күренмиләр иде әле. Шул чор эчендә бик күпләрне Язучылар союзына алышуда катнашырга туры килде: Мөсәгыйть Хәбибуллин, Мансур Хәсәнов, Сафа Сабиров, Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллин…

— *Элек татар зыялылары дөньяга тоташкан булган. Чит илләрдә укыган кешеләребез дә шактый. Совет чорында бетә бу. Шуңа күнеккәнбез дә инде. Сибгат агабыз әнә шигырь дә язды, Англиягә барырга кыстыйлар, бармыйм, арышларның баш кысканын күрми калырмын дип.*

— Әйе! Мин аны көлеп сөйли торган идем инде.

— *Син менә күп йөрдең — Союз буйлап та, дөнья буйлап та.*

— Бик күп йөрдем! «Обойма»га керә башладым бит Мәскәүдә дә. Бөтен СССРны айкап чыктым, чит илләрдә дә булдым. Берәр зур әдәби бәйрәм үткәрелсә, әдәбият көннәреме анда, фәләнме — шушы Идел буе — Урал төбәгеннән Мостай Кәримне ала торганнар иде, мине ала торганнар иде. Аңа кадәр Зәки абый Нури шактый йөргән, Гариф абый Ахунов йөрде инде…

— *Ни бирде бу сиңа?*

— О-о-о! Бик күп нәрсә бирде! Син менә әйтәсең миңа, нигә Тукай булмадың, дип. Тукай буласы килмәү шуннан да әле ул. Була алмаган да булыр идем, эш анда түгел. Тукайның бөек шагыйрь икәнен соңрак та аңлаганмындыр әле. Бу йөрүләремдә дөньяда бүтән зурлыклар бар икәнен күрдем мин.

— *Синең өчен сине читтә белүләре бик тә мөһим булган кебек. Шундый шигырең дә бар бит:*

Шагыйрь булсаң, дөнья өчен
данның, януың кирәк.
Януыңны халыкларның
күмәк тануы кирәк.

— Яшермим, әйе, Союз күләмендә танылу теләге бар иде. Хәзер бүтәнчәрәк уйлыйм, теге вакытта олы максат шул иде… Мин ул чорның бик күп бөек язучылары белән аралаша алдым, шулардан күп нәрсәгә өйрәндем.

— *Нәрсәгә, мәсәлән?*

— Иң әүвәл, фикерләүгә… Микола Бажан, Чыңгыз Айтматов, Рәсүл Гамзатов, Кайсын Кулиев, Эдуард Межелайтис, Василь Быков, Давыт Көгелтиневләр, Мостай агалар бит үз халыкларын да күтәрәләр, үз әдәбиятларын дөнья әдәбияты белән бәйли беләләр иде. Безгә шул җитмәде.

Ул совет әдәбияты кумирлары белән аз-маз аралашкач, аларның үсеш юлын беркадәр чамалагач, шуны аңладым мин: үз халкыңның телен һәм тарихын юньләп белми торып, барыбер болар кебек булып булмый икән. Чөнки син үз халкыңның илчесе була алмыйсың… 1972 елда, күпме кешене аптырашка салып, Ибраһимов институтына аспирантурага керүемнең төп сәбәбе шул аның. Халык иҗатын өйрәндем. Үз халкыңны аның теле җәһәтеннән дә, фикерләү рәвеше, образлар системасы ягыннан да шәбрәк белим дисәң, иң кулае шул.

— *Дөрес, әйе… Равил, син бит болай дип язган идең:*

*Бездә шигырь — аңлаганга —*

*башың Себер китәрлек.*

*Пафос көчле монда синең. Себер китүгә «лаек булу» шагыйрьнең буй җитмәс тәвәккәллеге сыман бәяләнә... Хәсән агабызның Публий Овидий Назон турында бик матур шигыре бар әнә — ике мең еллап элек Римнан сөрелгән шагыйрь. «Вөҗданы белән сөйләшкән» язучылар Себер юлына гел әзер торырга тиештер инде ул. Бер Аурупа шагыйре, француз бугай, репрессияләнгән совет шагыйрьләреннән көнләшүен әйтә. Шагыйрь сүзенең көчен күрсәтә бит бу, ди... Яулап алынган, җәберләнгән татар халкының шагыйрьләренә каләмне очлы тоту һич хәрәм булмас иде югыйсә. Ләкин өлкән буын язучыларыбыз сәяси ирек мәсьәләсенә дә, милли азатлык мәсьәләсенә дә бөтенләй кагылмадылар кебек. Кемнәрнедер Себер җибәргәннәр, төрмәгә япканнар яки хәтта атканнар икән — моның өчен түгел, ниндидер ялган чебеннәрдән фил ясап. Күп кенә татар шагыйрьләренең чәче золым системасына шигъри рәхмәтнең татлырагын эзләп агарды.*

*Инде күктән фани җиргә төшеп уйлансак... син хаклы да кебек... Син искәрткәнчә, ул усал заманда урыслар да әллә ни майтара алмаган әнә. Ә бит юкса... Бәлки беләсеңдер, шундый әйтем кебек нәрсә бар икән: «Мәскәүдә тырнакны киссәләр, Киевта бармак чабалар». Казанда кул кисәләр дип өстәгәндә дә ярыйдыр, Казанны гел Куликово кырының дәвамы итеп карадылар бит.*

*Тыелган чикне кемнәр үтә алды бездә? Салих Баттал. Аның Мәскәү редакцияләренә җибәреп басылмаган, КГБ кулына эләккән «Я отрекаюсь» дигән памфлеты соңыннан «Идел»дә чыкты — синең кереш сүз белән. Себерне инде бер урап кайткан Хәсән агабызның татар теле турындагы «Алмаз» дигән шигыре һәм Искәндәр Рушан иseme белән басылган, Табеевнең җен ачуын чыгарган берничә шигыре. Наҗар Нәҗминең «Татар теле» дигән шигыре. Разил Вәлиевнең «урыс капкасы» турындагы строфасы. Әхсән Баяновның «Шаһгали» дигән шигыре. Илдар Юзеевның Тукайның патша белән сөйләшүе турындагы шигъри әсәре. Батулланың кайбер әкиятләре... Беткәндер дә, бәлки? Бу фонда син нык аерылып торасың. Синең берүзеңнең унлап «хәтәр» шигырең бар. Аларның кайберләре әле хәзер дә бик җилле яңгырый.*

*Шигырь юлы арасына милли эчтәлекле мәгънә салу сезнең буында һәм соңрак — егетлек, үзенә күрә бер кыюлык модасы санала башлады. Ләкин... аңлыйлар идеме соң моны? Синең теге шигырьдә дә бит, «Башың Себер китәрлек» алдында, «аңласаң» дигән сүз тора.*

*Чернышевский үзенең «Что делать?» дигән романына мондый аскы эчтәлекне, Батуллача әйтсәк, астарны мул салган. Аңласыннар өчен «проницательный читатель» дигән өстәмә образ кертә ул, ара-тирә, шуңа мөрәҗәгать иткән булып, җеп очын күрсәтеп ала. Безнең күбесенчә бер күзәнәкле әсәрләр генә укып өйрәнгән укучы синең кинаяләреңне генә түгел, тел яшерми әйткән «крамола»ларыңны да аңлап җиткермәде бугай. Кәефеңне кырмый идеме бу нәрсә?*

— Юк, ул вакытта кәеф кырылмый иде. Шигырь укучы күп бит. Арада аңлаучылары да була. Шул җитә иде... Искәргәнлекләре миңа да килеп ирешкәли иде. Хәзер менә — да! Хәзер күрмәүләренә, аңламауларына — аптырыйм да, кимсенәм дә.

— *Синең белән бергә Күктүбәдә иҗат йортында булганда, мин синең Кырым татарлары дип ут йотып йөргәнеңне күрдем. Байтагын белә, аралаша да идең бугай. Кырым татарларын яклап язган көчле-көчле шигырьләрең дә бар. Ул чакта бу да «хәтәр» тема иде бит.*

— Монысы табигый инде аның. Кырым татарларын илләреннән сөрүне хуплап та әсәрләр язылды. Мин менә шуңа шаккатам.

— *Бездә түгелдер ич?*

— Бездә түгел дә, барыбер совет әдәбиятында инде. 4–5 язучыны атый алам...

— *Акчага, әйбергә кызыкмадың бугай инде: «Мин һаман да мөлкәтсез-малсыз килеш», — дисең. Ә менә җитәкче урыннарга ымсынган чаклар булмадымы?*

— Юк, ымсынмадым. Мине шуңа әзерләгәннәр иде үзе. Язучылар союзы председательлегенә. Башта Әлмәткә җибәрделәр әле, андагы язучылар оешмасын җитәкләргә. Ә анда бу урынга өметләнеп торган кеше булган икән. Малай гына әле мин ул чакта. Күпләр шунда карап торды. Көтте: нишләр икән бу? Аннары Юныс Әминовлар, Гамил Афзаллар, булдыра алганымны күрепме, ярдәм итә башладылар. Биш еллап эшләгәч, әйткәнемчә, үз теләгем белән Әлмәттән китеп, аспирантурага кердем. Вәлиев, өлкә комитеты секретаре, ачуланып ташлады үземне: «Ты что, мы готовим тебя, а ты!..» Союз председателе урынбасарлыгыннан да үзем киттем. Бер үк вакытта яхшы шагыйрь дә, яхшы администратор да була алмасымны аңладым. Аннары 13 ел профессиональ шагыйрь булып бик иркен яшәп алдым мин. Анда инде исем дә бар иде, китаплар да чыга — яшәп була! Соң гына торам, төне буе утырам. Табигатькә чыгып хозурланып кайтам... Менә син дә бер килеп киткән идең миңа.

— *Әйе, өчәүләп урманда чаңгыда йөреп кайттык: син, мин, Миңлебикә ханым.*

— Әйе, шулай 3–4 сәгать урманда чаңгыда йөреп кайта торган идем. Аннары малайлар белән көрәшергә чыгам — атнага 1–2 тапкыр. Бераз кәефләнеп утырабыз — бөеклекләр турында сөйләшеп. Дөресен әйтим, байтак эшләп калынды ул елларда.

— *Равил, бер шигыреңдә син болай дип тә әйтәсең: «Безнең бу — савапка торырлык гөнаһлар».*

— Әйе-әйе, бар андый шигырь.

— *Синең лирик герой анда, бәлки, ике җәннәтлек савап эшләп яткандыр, анысын белмим. Беләсем дә килми. Хәзер бер олы темага күчәргә телим мин. Татарның язмышы кыл өстендә. Әхлак та калмаса — бөтенләй бетәбез… Менә син, Равил, татар өчен җан аткан кеше, әйт әле: татар зыялылары, аларның да каймагы булган язучылар, журналистлар, галимнәр, сәнгать әһелләре, ягъни халык үзе өчен үрнәк санаган, гел күз уңында торган катлам — без халыкның әхлакый хәле өчен үзебезне җаваплы санарга тиешме? Әллә битараф кына күзәтеп тора алабызмы? Бусы муллалар эше аның дип?*

— Битараф кала алмыйбыздыр инде.

— *Алайса, без халыкка әйтергә тиештербез бит. Йә — Ислам әхлагы буенча яшик, дип. Йә — халкыбызның шактый дәрәҗәдә шул ук дини әхлакка нигезләнгән әхлакый традицияләре буенча, дипме шунда. Йә — әхлак ул инде искергән нәрсә, һәркем үз күңеле кушканча яшәсен, дипме? Нәрсә булса да әйтергә тиештербез ләбаса.*

— Әхлак, әхлак… Киңрәк алыйк әле бу мәсьәләне. Сүз бит милләт язмышы турында бара, әхлак — аның төп нигезләреннән берсе. Хәзер әгәр дә дөньяда милләтне саклап калу буенча берәр рецепт бирүче кеше булса, ул бөек кеше булыр иде. Милләтне әхлак белән генә саклап калып булмый.

— *Мин әхлак белән генә димим бит. Тагын күп нәрсәләр кирәктер. Әхлак бит аларның юлын кисми. Ләкин, әхлак бетсә, башкалары таяныч була алырмы безгә?*

— Әхлаксыз булмый инде, сүз дә юк. Әгәр дә мөстәкыйль дәүләтебез булса, үз әхлагыбызны урнаштырыр идек… Минем хәтта Төрекмән башын да гаеплисем килми. Аның үзенә күрә идеяләре-нияләре бардыр, ул нәрсәгә булса да омтыладыр. Гарәп илләрендә, Иранда да нәрсә дә булса бардыр, белеп кенә җиткермибездер… Ә менә без — кеше арбасындагы кеше. Баракта яшәп, үз бүлмәңдә менә дигән әхлак нормалары булдыра алмыйсың.

— *Омтылырга кирәктер бит?*

— Кирәк, сүз дә юк.

— *Тукай була алмадың дигәнемнең тагын бер мәгънәсе шул: синнән милли лидер чыга ала иде бит, Равил. Җиңелүебез лидер булмаудан да ул. Мондый кешенең сәяси көрәш башында торуы да мәҗбүри түгел. Рухи лидер булуы да җитә. Халык гөж килер иде: «Фәйзуллин болай дип әйткән!», «Фәйзуллин тегеләй дип әйткән!» Менә шундый Фәйзуллиннан мәхрүм калдырдың бугай син безне, Равил!*

— Бәлки, безнең җирлектә андый лидерга чыгарга хут бирмәгәннәрдер? Безнең татар бик тә үзенчәлекле халык бит ул… Аннан, тегеләр — Айтматовлар, Мостай агалар — алар бит чагыштырмача «чиста кыр»да калкып чыкты. Ә бездә бит әдәбият бай. Үтә зурлар, алыплар булмаса да, тигезрәк — талантлар күп. Алар бер-берсенә бик калкынырга хут та бирми бит әле… Татарның бердәм булмавы бик борчый мине. Адәм көлкесе бит: галимнәребез урыс гәҗитендә мәш килеп сугышып яталар! «Адәмнәр имин булсын өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән затлар» — галимнәрең өерелеп талаша икән, нинди әхлак булырга мөмкин ди?

Мине бик борчыган тагын бернәрсә хәзер — татарның үз телендә укымавы. Язучының төп иҗат нәтиҗәсе китап бит инде. Китапны язу бер авыр, чыгару — янә авыр, инде чыккан китабың да халыкка барып ирешми икән — бусы иң аянычы…

Мин үземнең язмышымнан бик канәгать болай. Чөнки теге бәләкәй чакта алган максатка туп-туры, артык тайпылышлар ясамыйча бара алдым, бу — бер, икенчедән, язылган әйберләрнең байтагын китап итеп чыгара алдым. Бик зур эш бу... Иҗат ягыннан ниндидер биеклеккә ирешелгән инде. Биеклектә калу дигән нәрсә дә бар бит әле. Ходай саулык биреп, шул биеклекне саклый алсам әгәр…

— *Ул саулык дигәннән, заманында спорт белән шулай яратып Җәлил шөгыльләнгән бугай. Безнең чорда син инде менә.*

— Синнән кала.

— *Ай-һай, алай микән? Шәп йөзәсең — диңгездә синең койрыкны гына күреп кала торган идем мин. Зур теннис уйнаганыңны сокланып күзәткән бар, үзем моңа шул синең тирдә өйрәнә башладым бит инде… Башкалар чыдамаганда рәхәти чыдап, «ләүкә-тәхеттә» дә янәшә утырган булды әле безнең.*

— Әйе, булды.

— *Утыз еллар элек, алдан ук, запаска диптер инде, менә ниләр язып куйгансың син, Равил:*

Күз алдымда күпме картайдылар!
Бер без бирешмәдек шикелле.

*Тагын:*
Ә шулай да без — без булырбыз гел!
Дәрте калыр, дәрман бетсә дә!

*Бәлки, әңгәмәне шушы шигырь юллары белән очларбыз?*

— Шәп булыр. «Мин» димәгәнмен бит, «без» дигәнмен.

## «ЗАМАНГА ИШ БУЛЫЙМ ДИСӘҢ…»

*(Шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиевнең Равил Фәйзуллин белән әңгәмәсе)*

*— Равил туган, мин сине инде кырык елга якын беләм: кылган гамәлләреңне дә, иҗатыңны да һәрдаим кызыксынып күзәтеп барам. Бер мин генә алай эшләмимдер, чөнки син күпләр өчен кызыклы шәхес, ил күзендәге кеше.*

*Алтмышынчы еллар уртасында ук инде син татар шигъриятендә мәйдан тоткан шагыйрь, җәмгыятьнең игътибар үзәгендәге гайяр егет идең. Әдәбият тирәсендәге безнең кебек яшь-кыркыннар гына түгел, олпат-олпат язучылар да нигәдер синең янга тартыла, синең белән әңгәмә корырга атлыгып тора иде. Чөнки син ул чакта ук инде саллы фикерле, зирәк акыллы, тумыштан зыялы зат идең. Еллар үткән саен, билгеле, холкыңда да, фигылеңдә дә үзгәрешләр булгандыр. Әмма син үзеңнең әлеге асыл сыйфатларыңны югалтмадың, киресенчә, аларны камилләштердең генә кебек.*

*Нәкъ кырык ел элек очрашкан-сөйләшкән чакларны искә төшереп, бүген дә сүзебезне шигърият, әдәбият язмышы, милләт һәм дәүләт язмышы, һәм шулай ук үзебезнең язмыш турында алып барсак, әйбәт булыр иде. Әйдә, иң элек шуларның соңгысыннан—үзебездән башлыйк әле… Синең язмыш үзең уйлаганча, үзең теләгәнчә бара дип саныйсыңмы? Гомер башындагы—бала чактагы хыялларың, теләкләрең тормышка аштымы?*

— Зурлап әйткән сүзләрең өчен рәхмәт. Сорауга җавап шул: Язмышка рәхмәтлемен. Кайчак уйлап та куям: Ходайның яраткан бәндәләренең берсе булып чыктыммы әллә? Бала чактагы хыялларымның байтагы тормышка ашты. Малай чакта көндәлегемә болай дип язып куйганмын: «Шагыйрь булып, китабыңны тотып кайтсаң иде Туган ягыңа!» Чынга ашты бит! Китаплар да байтак чыкты. Татарчасы, русчасы дигәндәй… Гомумтиражлары—миллионга якын. Азмы-күпме үз укучыларым даирәсен булдыра алдым. Кыскасы, кече яшьтән үк анык максатым булды, төрле якка сибелмичә, юнәлгән кыйблага барырга ихтыяр көче табылды, һәм—бик мөһим нәрсә—максатка ирешү юлында шарт-мөмкинлекләр дә булмады түгел.

*— Алтмышынчы-җитмешенче еллар белән чагыштырганда бүгенге көндә әдәбият-сәнгатьнең җәмгыять һәм дәүләт мәйданында тоткан урыны шактый кечерәйде, тарайды кебек. Моның сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсың?*

— Төп сәбәп—Вакыт факторында. Дөнья гел үзгәрештә. Моннан кырык-илле еллар элек булган вазгыять бүгенгедән бик нык аерыла. Ни дисәң дә, бу вакыт эчендә ике буын диярлек алышынды инде. 60–70 нче еллар әдәбиятын, сәнгатен, асылда, сугыш чорын күргән, күп сынау-михнәтләр кичергән буын вәкилләре тудырды. Бу әдәбиятны укучы да, нигездә, шул чорда тәрбияләнгән кешеләр булды. Ул елларда төп тәрбия чыганагы—китап, аннан кала—радио. Телевизор әле ялтырап кына килә. Компьютер кебек могҗизаларның исе дә юк… Китап—тәхеттә! Рухи яктан кешеләрнең, шул исәптән безнең һәм бездән алдагы буыннарның үзгә бер бәхетле чоры! Гомумән, уйланып хисләнү, гаҗәпләнеп хыяллану—әдәбият-сәнгатьнең үзәген тәшкил итүче компонентлар. Хәзер дөньяны прагматик акыл басты. Техник белем артты, Җир-планетаның сере кимеде, кешеләрдә гаҗәпләнү тойгысы саекты… Уенчыгы күп бала үзенчә бәхетсез бит ул—аны нәрсә беләндер кызыктыру кыен… Читкәрәк кителде шикелле. Үзебезнең хәяттан бер мисал: утызынчы-илленче елларда татарның рухи мохитен, бигрәк тә авыл мохитен, Такташ шигъриятеннән тыш күз алдына китереп була иде микән? Мөгаен, юктыр. Ә менә XX гасыр ахырын татар гавамының күпчелеге Такташсыз тәмамлады дип тә әйтеп буладыр. Мөкиббән китеп яшьләр егылып укыймы хәзер «Мокамай»ларны, «Алсу»ларны?.. Шәһәр яшьләре күбрәк «Һади Такташ» дигән җинаятьчел төркемне беләләр… Такташ үзенең бөек шагыйрь булуыннан туктамады лабаса! Уйланырлык нәрсәләр күп…

Һәр заманда, һәр җирдә «кеше җаны өчен көрәш бара»! Хәзер бу көрәшкә безнең буын кешеләре өчен беркадәр ят бүтән ысуллар, информациянең бүтән төрле чаралары тартылды…

*— Атлаган саен без: «Тормышлар авырайды, катлаулы заманда яшибез»,—дип зарланабыз. Кайчандыр син үзеңнең бер шигыреңдә: «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга»,—дип язган идең. Шулай булгач, иҗат кешесенең, әдәбият-сәнгать әһелләренең шундый хәлдә калуына бүгенге заманны гына гаепләү дөрес микән? Талантлы шагыйрьләр, язучылар бүген дә җитәрлек, ә алтмышынчы еллардагы күтәренке иҗат рухы, иҗат халәте нишләптер сүрәнәйде. Шагыйрь буларак та, җәмәгать эшлеклесе—баш мөхәррир буларак та син бу борчулы халәтнең сәбәпләре һәм аның нинди нәтиҗәләргә китерәчәге хакында еш уйланасыңдыр инде…*

— Барыбер заман факторын исәпкә алмау дөрес булмас. Мәгълүм дастанда әйтелгәнчә, «Заман кемнең заманы»? Кызганыч, хәзер акча заманы (дөресрәге, хәзергә акча заманы, тормыш гел генә кыргый базар көенә бармас). Безнең чорда, нигезе дөресме-юкмы, барыбер иман заманы иде. Исеме нинди «изм» белән генә аталмасын, халыкта якты киләчәккә ышану бар иде. Ул ышанычны кешеләр күңеленә иңдерүчеләр кемнәр иде соң? Искерәк терминология белән әйтсәк, идеология хезмәткәрләре—укытучылар, язучылар, сәнгатькярләр… Ышаныч тудыручыларның авторитет-дәрәҗәләре дә зур иде. Гомумән, без үскәндә укытучы кеше—изге, язучы кеше—Алла кебек кабул ителә иде. Ә хәзер?.. Вазгыять бөтенләй бүтән! Кем гаепле? Минемчә, гаепнең бер очы—бүгенге Дөнья җиһангирләренә—зур сәясәт башында торучыларга тоташа. Алар халыкны кат-кат алдадылар, гади кешеләрнең өметен кистеләр. Сүзләре бер, гамәлләре икенче төрле булды. Халык, нигездә, бернәрсәгә дә ышанмый башлады. 60 нчы елларда, мәсәлән, бездә—әдәбиятка яңа аяк басучыларда—шигъри Сүз белән Дөньяны яхшырта алабыз дигән тирән инану бар иде. Бездә генә түгел, миллионлаган әдәбият-сәнгать сөючеләрдә дә… Хәзер язучы халкы үзе дә «шигырь—бер нәрсә, Дөньяны әйләндерүче чыгыр икенче нәрсә» икәнен бик яхшы төшенде инде…

Ә иҗади мохит, иҗади атмосфера, иҗади рух мәсьәләсенә килсәк, бу очракта байтак нәрсә иҗатчыларның үзләреннән дә тора. Әйе, бездә сәләтле, хәтта талантлы, эшсөяр каләм ияләре аз түгел. Берничә дистә исем санап китәргә мөмкин булыр иде. Алар—безнең байлыгыбыз. Әмма безгә максади берлек җитенкерәми. Әлбәттә, һәр иҗат кешесе—аерым бер дәүләт кебек; сүз иҗади эзләнүләр, иҗат стиле берлеге турында (без төрле реализмнар тарафдарлары булып яшәп карадык инде) бармый. Сүз—милләт язмышында СТРАТЕГИК БЕРЛЕК турында бара. Өстәвенә кайберәүләрдә шәхси амбицияләр дә кирәгеннән артык булып чыкты: кемдер үзен Тукай дип саный; кем Наполеон яки Гете сыйфатында хис итә; кемдер мәхәббәт лирикасында үзен, ким дигәндә, Петрарка дип исәпли; кайбер кемсәләр, түрә булгач, мин язучыларның иң кәттәсе—беренчесе дип уйлап саташа… Тормыш ыгы-зыгысына бирешеп, көнкүреш ваклыкларыннан күтәрелә алмыйча, Бахус бабай хозурында үзен югалтканнар да аз түгел…

Шулай да борын замандагы бер хаким-җиһангир сүзләрен ара-тирә искә алу да ярыйдыр. Гаскәрләре белән сугыш-орышка керер алдыннан ул әйткән, имеш: ишәкләр белән шагыйрьләрне саклагыз!—алар безгә сугыштан соң да кирәк булачак әле. Өстәп әйтергә генә кала—шагыйрьләр тарих өчен дә кирәк бит әле!

*— Халык, милләт язмышы турында уйламаган, кайгыртмаган кешедән язучы да, олы шәхес тә чыкмый торгандыр. Ә бүген милләтебезне саклап калу, аның гомерен озайту өчен иң беренче чиратта ниләр эшләргә кирәк дип санйысың?*

— Әгәр бу сорауга конструктив (бу очракта гамәлгә ашырырлык дигән мәгънәдә) анык җавап (бу очракта күрсәтмә-инструкция мәгънәсендә) бирә алсам, минем гражданлык статусым аерым дәрәҗәгә ия булыр иде... Әңгәмәбезнең иң мөһим һәм иң авыр соравыдыр бу. Моннан 30 ел элек язылган «Кирәк безгә» дигән шигыремне хәтерләп үтсәм, абстракт булса да, өлешчә җавабым саналыр бәлки.

Тәкъдир шундый: бик аздан да олы шатлык
таба алырга,
        сөенергә кирәк безгә.
Олимп уты ягар чакта,
сүнеп барган
учагыңа тын өрергә кирәк безгә.

Заманга иш булыйм дисәң—
кем бер янса—
ун яшьнәргә,
        ун янарга кирәк безгә.
ТОРМЫШ дигән ХАЛЫКАРА САБАНТУЙДА
батыр булып
        калалырга

кирәк безгә!

Азмы-күпме булган Дәүләтчелегебезне сакларга, ныгытырга, көчәйтергә тиешбез. Яшәешебезнең хәзерге этабында бу —мәҗбүрият. Аның өчен халыкның милли үзаңы югары булуы кирәк. Бу изге гамәлдә язучыларыбыз шактый өлеш кертә ала дип уйлыйм.

*— Соңгы елларда безнең җәмгыятебез бик нык, хәтта кирәгеннән артык нык сәясиләште кебек. Иҗат әһелләребезнең шактые сәясәт урманына кереп адашты. Син үзең дә замананың иң болгавыр чорында—туксанынчы еллар башында, Югары Совет депутаты булып, ул карурманга кереп чыктың. Менә хәзер, сәясәттән бераз читләшкәч, бу мәсьәләгә ничегрәк карыйсың? Иҗат кешесе сәясәттән ерактарак торырга тиеш дип санsocsыңмы? Шигърият белән сәясәт бер-берсеннән нindирәк ара калдырып яши алалар?*

Сәясәттән ераклашкан саен,
Табигатькә ныграк елышам.
…Тәгәрәде кызыл кыргый алма
елан үтеп киткән юл аша.

— Моннан чирек гасыр элек язылган бу дүртъюллыкта да куелган сорауга җавап сыман ишарә бар кебек. Сәясәт дигән төшенчәгә кем нинди мәгънә сала бит! Бар агымдагы тактик максат, бар стратегик максат. Әгәр иҗат кешесе бүгенгесен бүген үк бетереп бара торган сәясәттә «үсә Казан, үсә нурланып, башкалабыз Москвадан якты нур алып» җыры көенә «эреп бетә» икән, ул кеше—кызганыч. Әгәр талантлы кеше, үзенең иҗади индивидуаль йөзен саклап калып, халыкның киләчәген кайгыртып сәясәттә катнаша икән, аны хупларга кирәк. Безнең язучы депутатларның күбесен соңгылар рәтенә кертер идем. Шундый сорау да туа: үз милләте, үз халкы өчен җанатар кешене сәясәтче дип атап буламы? Мин шәхсән үземне сәясмән дип санамыйм. Шул ук вакытта җәмгыятебездә булган хәлләргә битараф кала да алмыйм. Әйтик, мине үзебезнең Илбашын сайлау хокукыннан мәхрүм итәләр икән, сүзләремне кәгазьгә мин теләгән алфавит белән язуны тыялар икән, ни җан белән тыныч калмак кирәк! Үткән ел язган «Саклыйк Республиканы!» дигән шигырь дә сорауга беркадәр җаваптыр. Сәясәтче булу-булмау икенчел нәрсә, ә шагыйрь әйтмешли, гражданин булу мөһим, зарур, хәтта мәҗбүри...

*— Элеккерәк елларда күп кеше сүз иреге юклыктан, цензура кысуыннан зарлана иде. Инде сүз иреге дә игълан ителде, цензура да бетерелде, әмма аңа карап зарланучылар иҗатта әллә ни майтара алмадылар, журналистика да, әдәбият-сәнгать тә дәррәү күтәрелеп, берничә башка үсеп китмәде. Әллә соң ул «сүз иреге» дигән нәрсә шигъриятькә зыян гына китерә микән? Демократия азрак булган саен, шигырь теле—эзоп теле көчәя генә бара бит… Әнә Муса Җәлил үзенең иң яхшы шигырьләрен Моабит төрмәсендә язган…*

— Сүз иреге дигән сүздә күпмедер шартлылык бар. Нинди генә заман, нинди генә катылыклар булмасын, Сүзне тыю мөмкин түгел. Уйны богаулап булмый бит! Дөрес, кеше җанына курку салып, Сүзнең канатын кисеп, вакытлыча аның яңгырау, таралу, басылу сферасын чикләп була. Тарих күрсәткәнчә, диктаторлар идарә иткән чорларда була андый хәлләр. Әгәр үзебезнең җирлеккә якынрак килеп, татар әдәбиятына күз салсак, шуны әйтә алабыз: төрле гасырларда—бик борынгы заманда да, ханнар заманында да, патшалар заманында да булган әдәбиятыбыз һәм хәзер дә бар! Нindидер шартлар булмаса, әдәбият та, сәнгать тә туа алмый! Кысулар, чикләүләр, икенче төрле әйткәндә, цензура булмаса, әлбәттә, Әдәбият Агачы кәүсәлерәк, ябалдашлары мәхәббәтлерәк күренер иде. Шул моментны да искәртеп узыйк. Күп нәрсә шәхескә, талантның зурлыгына бәйле. Пәһлеваннар белән һәркем исәпләшә! Зур талантлар торгынлык дигән заманда да менә дигән әсәрләр яза алдылар: Ә.Еники, С.Хәким, С.Баттал, А.Гыйләҗев, Ш.Хөсәенов, Г.Афзал, М.Мәһдиев, М.Юныс, Т.Миңнуллин, И.Юзеев һ. б.

*— Синең үзеңне дә шулар рәтенә кертәсе килә. «Космополит түгел», «Гөмбәзләре ояшмыни!», «Тәкъдир язган эшләр…», «Колонизатор әлифбасы», «Дошман—сигез, без—тугыз», «Шайтан каласыннан КамАЗларга карап», «Әлмәттә җир тетрәү» һәм башка дистәләгән, заманы өчен шактый кыю шигырьләрең цензура шактый көчле саналган заманда язылды бит.*

— Хәтерләвең өчен рәхмәт. Сүземне дәвам итеп шуны гына өстисе килә: кулымнан килсә, хөр фикергә түгел, халтурага цензура кертер идем мин. Азмы-күпме такмак чыгара алган, кесәсе калын булган һәркем «китап» чыгара ала хәзер. Элек мөмкин булмаган эш. Чын китапның кадерен

җибәрүдә искиткеч зыян салды бу үзешчәннәрнең «китаплары!» Нигездә, бихисап саналган хосусый нәшриятлар чыгарды аларны…

*— Әйе, бүгенге көндә Татарстанда төрледән төрле эреле-ваклы ике йөздән артык нәшрият бар. Шулай ук яңа журналларыбыз, газеталарыбыз да пәйда булды. Болары яхшы. Әмма ул китапларның, газета-журналларның тиражлары, гадәттә, берничә меңнән артмый. Җиде миллион халыкка бер тамчы гына бит бу! Китап кибетләребезнең күбесе ябылып бетте, хәзер инде китапханәләргә дә кул сузучылар күренә башлады. Укучысы булмаса, киләчәктә әдәбият үзе дә әкренләп юкка чыга барырга мөмкин бит. Без бу мәсьәләне Дәүләт Советында кат-кат күтәрәбез, таләп итәбез. Ә җитәкчеләр: «Заманалар үзгәрде, хәзер халык китаптан читләште, компьютерга бирелде»,—диләр. Мисал итеп көнбатыш илләренә төртеп күрсәтәләр. «Әдәбият-сәнгать ул халыкның кечкенә бер өлешен генә кызыксындыра»,—дип тә куялар. Менә син үзең ул агайларга ничегрәк җавап бирәсең?*

— «Пәри—башка, җен—башка» диләр безнең халыкта. Россия гомер-гомердән читләргә кызыгып, читләрдән өлге алып яшәде. Әйтик, дин тәгълиматы византиялеләрдән кергән булса, дәүләт төзелеше системасы—Алтын Урдадан… Хәзер дә әнә, Европа күзенә карап, Америкага иярмәкче… Дистәләгән милләтләрне бетереп, тоташ Россия халкы (дөресрәге, рус халкы) ясамакчы. Янәсе, Америкадагы халыклар америкалы дип йөртелә бит… Аңлапмы, аңламыйчамы, мондый «прогресс» карашлылар безнең җирлектә дә бар. Әдәбият-сәнгатьнең, бигрәк тә әдәбиятның, безнең рухи тормыштагы гомер бакый алып торган урынын белер өчен, аз гына артка—үткәнгә, тарихка борылып карау кирәк. Меңьеллык әдәби тарихыбыз бар, дибез. Әйе, бу шулай. Болгар яки Алтын Урда чорымы, Казан ханлыгы яки соңгырак чорлармы—һәр дәвердән конкрет шәхесләр, конкрет әдәби әсәрләрне санарга була. Йә, мондый байлык күп халыкларда бармы? Русларныкымы яки нибары ике йөз еллап тарихы булган америкалыларныкымы? Шуңа күрә безнең халык язмышында әдәбиятның үзгә роле, үзгә миссиясе. Әдәбият, җыр-моң—безнең төп байлыгыбыз. Төптән уйласаң, безнең бүтән милли байлыгыбыз юк та бугай әле… Шунысын да искәртик: иң авыр гасырларда да дәүләтчелекнең кайбер функцияләрен (тәрбия, мәгърифәт, хөкем кануннарын…) теге яки бу күләмдә әдәбият саклап кала алды бит. Әгәр,—диниме, дөньявимы,—әдәбиятыбыз булмаса, бездә бүгенгәчә исән калган дәүләтчелеккә омтылу хисе дә булмас иде. Әгәр чыннан да «әдәбият-сәнгать ул халыкның кечкенә бер өлешен генә кызыксындыра» икән, бу—безнең фаҗигабез. Без һәммәбез дә,—син олы түрәме, гади мөгаллимме,—халыкка тарихи чынлыкны аңлатып, милли үзаңны күтәрү юнәлешендә эшләргә тиешбез. Үзләрен дөнья кендеге дип санаган, болганчык чорда зур байлык (кызганыч, ул байлыкны милли байлык дип санап булмый. Хәер, ул мал-мөлкәтнең язмышы алда ничек булып бетәр бит әле. Дөнья бу!) туплаган, әлегә зур дәрәҗә йөрткән агайларга яки энекәшләргә әйтер сүз шул: кайдан чыкканны онытмаска иде!

*— Иҗат кешесен дә, гомумән, милләтне дә иң беренче чиратта өмет яшәтә. Әмма ләкин буш хыяллар, ялган өметләр белән гомер кичереп, үзең дә сизмичә, ярык тагарак янында калуың мөмкин бит. Безнең әдәбиятның, безнең милләтнең киләчәккә ныклы өмете, төпле ышанычы бар дип саныйсыңмы? Һәм ул нидән гыйбарәт? Нәрсәгә таяна?*

— Сораулар җитди. Яшәвебезнең асылына бәйле сораулар. Иң әүвәл шәхсән яктан чыгып җавапланам: әгәр әдәбиятның, милләтнең киләчәгенә өмет, ышаныч булмаса, иҗат эшенә алыныр идемме? Ышаныч нидән гыйбарәт? Чагыштырмача зур санда халык бар (хәтта яртылабы милләт гаменнән читләшкән, космополитләшкән һ. б. «лашкан» булса да), димәк, милләт бар; аңлаганнар өчен зур һәм гыйбрәтле тарих (ул бик нык бозып өйрәнелгән һәм аңлатылган; объектив өйрәнгәндә, тарихның бик күп сәхифәләре безнең милләт файдасына булачак) бар; күпләребезнең геннарында «без дәүләтле халык булган һәм киләчәктә дә булырга тиеш» дигән эчке бер горур тойгы яши…

*— Әйдә, дөнья гамен бер читкәрәк куеп, үзебезгә кире кайтыйк әле… Безнең халык сине зур шагыйрь һәм мәртәбәле «Казан утлары» журналының баш мөхәррире буларак белә. Заманында син, күпләребезне көнләштереп, казна эшендә эшләмичә, шактый вакыт чып-чын шагыйрь булып кына яшәгән идең. Хәзер шул елларны сагынмыйсыңмы?*

— Сагынам, әлбәттә. Кеше буларак—яшьлекне, ир кеше буларак—көчле, дәртле ир-егет чагымны сагынам. Гомумән, мәшһүр язучыларның күбесе гомерләренең билгеле бер өлешен фәкать иҗат эшенә генә багышлаганнар. Мисаллар күп, үзебезнең әдәбиятта да, бүтән халыклар әдәбиятында да. Казна эшен дә, иҗат эшен дә ал да гөл итеп югары дәрәҗәдә алып бару мөмкин түгел диярлек. Гомер—кыска, Вакыт—цейтнот…

*— Син гомер-гомергә һәр урында беренче булып килдең. Шигърияттә дә, җәмәгать эшләрендә дә, китап бастыру, премияләр алу өлкәсендә дә иң элек өлгерә, яшьтәшләреңнән гел алда бара идең. Хәтта суда йөзү, чаңгы шуу ягыннан да сиңа тиңнәр табылмый иде. Син һәр эшне җаның-тәнең белән бирелеп, булсынга дип, ахырына кадәр җиткерәм дип эшлисең. Хәтта шигырь язганда, җитди нотык тотканда да маңгаеңнан тирләр тамып тора. Ә тормыш гел эштән генә тормый бит ул. Күңел бәйрәм дә сорый. Күңел бәйрәмнәрең нидән гыйбарәт синең?*

— Пенсия яшендәге кешегә җылы сүз кирәк ул дипме, артыграк мактап ташладың шикелле. Күңел бәйрәме дигәннәре хәзер күбрәк нәни улыма бәйле. Хәзер аңа дүрт яшь. Кызык чагы. Аңа дөнья кадәр вакыт һәм көч сарыф итәргә кирәк. Әмма ул биргән шатлыкны берни белән дә үлчәп бетереп булмый.

*— Синең шигырьләреңә дистәләгән композиторлар тарафыннан бик матур көйләр язылган. Шулар арасыннан халык күңеленә мәңгелеккә уелып калырдайлары да шактый. Ә үзеңә аларның кайсысы аерата якын, аерата кадерле. Ялгыз чакларыңда күбрәк кайсы җырыңны авыз эченнән көйләп йөрисең?*

— Җыр димәктән, Разил туган, мин сине җырлар короле дип саныйм. Бу өлкәдә минем хезмәт зур түгел. Махсус җыр текстлары язганым да булмады. Заманында шактый ук исемле композиторлар аерым шигырьләргә берәр-икешәр (нигездә, берәр) көй яздылар язуын. Әмма алар күп түгел. Кайберәүләр, «Аккошлар» (Ф. Әхмәтов көе) җырын яхшы, диләр. Минем үземә сүзләре бик үк ошап бетми. Ш. Шәрифуллинның «Иясез шатлык» дигән бер җыры бар. Аны радиодан сирәк кенә биргәлиләр. Ошый ул миңа, сүзләреннән канәгатьмен. Шушы җырны кайчак авыз эченнән мыгырдаштыргалыйм…

*— Сүзебез ахырында соңгы вакытта кылган гамәлләр һәм планнар турында берничә сүз әйтсәң икән.*

— Үткән 2004 елда төп эшләремнең берсе: Татарстан Язучылар оешмасы тарихын язу булды. Архив документларына нигезләнеп, аерым фактларга һәм вакыйгалар нисбәтендә соңгы чор татар әдәбиятының үсеш тенденцияләрен ачыкларга тырыштым. Бу хезмәт аерым китап рәвешендә чыкса да, алга таба мин аны тулыландырырга телим. Татар әдәбияты тарихын өйрәнүчеләр өчен бер кирәкле кулланма булсын дим.

— Соңгы ун елда язылган шигырьләремнең аерым китап булып дөнья күргәне юк. Элегрәк ике елның берендә (кайчак хәтта ел саен!) яңа шигырь китапларым чыга иде. Монда берәүнең дә гаебе юк. Нәшриятка җыйнап, әзерләп биргәнем булмады. Яңа дигән шигырьләрем, алар арасында бик кыскалары да, поэмага тартым озыннары да бар. Җыенысы—ун табак чамасы булыр. Шуңа өстәп—вакыт җитте бугай—истәлек-хатирәләр дә язасы килә. Гыйбрәт алырлык, күргән-кичергән хәлләр шактый. Әдәби мохиттә байтак яшәлде бит.

## ХАЛЫК АНЫ УЛЫ ДИП АТЫЙ!

*(«Юлдаш» газетасы журналисты Рафис Газиз белән әңгәмә)*

Равил Фәйзуллинның халык аңына төбәлгән һәр язганы, Тукайча дөрес сүзе — инде тарих дисәк тә була. Өйрәнелергә һәм киләчәк буыннарга җиткерелергә тиешле тарих! Шигърият дөньясында «ат уйнаткан» әдипнең әсәрләре тормышта авырлыкларга каршы торырга, түзем һәм кешелекле, көчле ихтыярлы булырга, сыгылганда сынмаска өйрәтә. Безнең теләсә кайсы милләттән һич тә ким түгел икәнлегебезне, халкыбызның горур Улы үзенең әсәрләре аша раслый, милләтебезнең рухи тураюын, горур һәм бай яшәвен тели.

Р.Фәйзуллинның 40тан артык китабы дөнья күрде. Поэзия өчен шаккатырлык сан бу! Аларның гомуми тиражы миллион данәгә җитә!

Р. Фәйзуллин кебек, яшь шагыйрь булып саналган чагында ук, Казан һәм Мәскәү нәшриятларында калын-калын китаплар чыгарган шагыйрьләр сирәк, бик сирәк. (Сүз уңаеннан, ул хәтта университетта укыганда ук ике китап чыгарырга өлгерә!) Биш томлык «Сайланма әсәрләр»е дә басылды (исән язучылардан андый бәхеткә ирешкәннәрнең беренчесе ул). Балалар өчен дә ун китабы чыкты. (Сүз уңаеннан, аның басылып чыккан иң беренче китабы да балалар өчен иде.)

«Килькистан» дип шаярткан төбәк малае белән шигырьләре аша Франция, Италия, Англия, Монголия, Сүрия, Венгрия, һ.б. ил халыклары да күптән таныш. Шактый гына шигырь үрнәкләре «Дөнья шигърият антологиясе»нә кертелгән. «Бөтендөнья әдәбияты китапханәсе»ннән 200 томлыгына кергән исән шагыйрьләрнең иң яше дә Р. Фәйзуллин булды.

СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп алынганда (бик зур дәрәҗә), аңа нибары 22 яшь була... Һәм шунысын да әйтеп үтик: СССР Язучылар съездының иң яшь делегатын (инде илдә танылган шагыйрьне) Мәскәүнең Колонналар залында меңләгән әдип дәррәү алкышлап каршылый.

Р. Фәйзуллин 1968 елда (24 яшендә!) Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеген җитәкли. 1973 елда Казанга кабат әйләнеп кайткач, 1977 елга кадәр Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе булып эшли. Ә инде 1989 елдан алып ул «Казан утлары» журналын җитәкли. 32 яшендә РСФСР Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы булуга ирешкән Р. Фәйзуллин Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы (инде тоташ 38 ел буе!) һәм бүгенге көндә берлеккә кабул итү буенча коллегия рәисе.

27 яшендә (!) «Хезмәттәге батырлык өчен» медаленә лаек булган Р. Фәйзуллинның Татарстан, Рәсәй һәм Халыкара дипломнарын, мактаулы бүләкләрен санап чыгу гына да күп урын алыр иде... Аның иҗаты турында дөнья халыкларының зур әдипләре күп язды. Шагыйрьнең үзенә багышлап язылган шигырьләр дә байтак. Аның әсәрләренә нигезләнеп, иң оста рәссамнарыбыз тулы бер цикл портрет-рәсемнәр иҗат итә...

Р. Фәйзуллин әдәбият көннәрендә дә, Г. Тукай, А.С. Пушкин һәм дөньяның башка халыкларының данлы Улларына багышланган истәлекле бәйрәмнәрдә, халыкара конгресс-конференцияләрдә дә катнашырга, үзебездәге һәм чит илләрдәге югары уку йортларында да чыгышлар ясарга өлгерә. (Үзебездәге һәм чит төбәкләрдәге сабантуйларда, үзенең иҗат кичәләрендә ясаган чыгышларын әйтмим дә инде!) Менә бүген мин аның Кремлебезгә каршы якта, Казансу янында урнашкан «Идел-Пресс» бинасындагы эш бүлмәсендә. Хөрмәтле укучыларыбыз, әйдәгез, шагыйрь, публицист, фикер иясе, халкыбызның яраткан журналының баш мөхәррире Р. Фәйзуллиннан кызыксындырган сорауларга җаваплар алыйк әле.

*— Равил абый, сугыш еллары баласы бераз үзенең балачагын искә төшереп үтсә иде...*

— Әгәр дөньялыкта кешеләр яхшы яктан искә алырлык ниндидер гамәлләр кылынган икән, димәк, тормыш дигән ак дәфтәргә эзләр баштан ук дөрес салынган дип уйлыйм. Төгәлрәге — өлкәннәр дөрес юнәлеш биргәннәр. Кешенең киләчәк язмышы бала чакта ук салына, диләр. Ундүрт яшькә кадәр авылда яшәлде. Авылны беләсез инде, анда эш-мәшәкать җитәрлек. Төрлесе булгандыр, әмма якты яклар күбрәк булды. Балачакка тел-теш тидереп буламы соң! Ул чакта таңнар гел алсу, офыклар гел ымсындыргыч, хыялларның чиге юк!..

*— Хәзер инде Сезнең иҗатны мәктәпләрдә өйрәнәләр. Сер булмаса, укыганда татар теле һәм әдәбиятыннан нинди билгеләр ала идегез?*

— Дөресен әйтим, грамматик кагыйдәләрне бик үк өнәп бетерми идем. Нишләптер безнең укыту системасында җанлы телнең үзенең асыл хикмәтләрен сеңдерәсе урынга, балага кагыйдә ятлаталар. Чит телләрне укытканда, бик сиздерә бу хәл. Гадәттә, ул чит телдә йөз сүз дә белми, ә кагыйдәне өйрәнергә мәҗбүр... Ә татар әдәбиятына килгәндә, ул — зур әдәбият! Аны өйрәнгәндә төрле билгеләр алынырга мөмкин...

*— Университетның соңгы курсында укыганда, аннан чыгарылу «бәхете» эләккән булган икән...*

— Чын мәхәббәт барыбер җиңә дигәндәй, дипломны мин шул ук елны алдым. Чөнки яхшы укыдым, өстенлекле стипендия алып укыдым. Хәлиткеч айда университеттан чыгарылу мәсьәләсендә, чыннан да, кайбер конфликтлар булды. Үземнең дә «һавалы» чакларым иде шул... *(Елмая.)*

*— 1986 елның июнендә, радиация нурларының котырынган көннәрендә, Чернобыльдә булгансыз... Ирексездән, шагыйребез Ф. Яруллинның Сезнең турыда бер рус гәҗитендә «Татар Островские» дигән баш астында чыккан мәкаләсе искә төшә...*

— Мин анда үзем генә түгел, бер төркем татар һәм украин язучылары белән булган идем.

*— Тормышта бик үкенгән чаклар булдымы?..*

— Андый чаклар булды, әмма «бик» дип әйтерлекләре күп булмады. Ир-атка үкенеп йөрү килешеп тә бетми. Үкенеч булырлык эшләр кылмаска тырышырга кирәк.

*— Сезгә бирелгән бихисап бүләкләр арасында иң кадерлесе?*

— Мөгаен, Тукай премиясеедер. Миңа аны 1978 елны бирделәр.

*— Хәзер артык тир түкмичә генә муллыкта яшәүчеләр дә, «черек бай»лар да җитәрлек... Ә инде халкына шулкадәр хезмәт итүче, бик күп китаплар авторы Равил абыйның «хәл»е ничегрәк?*

— Беркайчан да мескен яшәмәдем. Студент чакта ук меңәр сум бурычым була торган иде. Андый акчаны теләсә кемгә биреп тормыйлар *(елмая)*, гади студентның стипендиясе 22 сум чакта. Димәк, егеттә, бәләкәй генә булса да, әйләнештәге мая булган... *(Көлә.)* Мин байлыкка кызыккан кеше түгел. Бай да булмадым, хәерче дә булмадым. Хөр, бәйсез яшәргә тырыштым.

*— Дөньяда Сез аяк басмаган җир калмады, дисәк тә ялгышмабыз... Җир йөзендә Сезне иң гаҗәпләндергәне ни-нәрсә булды?*

— Дөрес, күп илләрдә булынды. Дөнья гизү — ул үзе олы мәктәп. Бу яктан язмышка рәхмәт. Гаҗәпләнерлек нәрсәләр күп күрелде. Гаҗәпләнү бер нәрсә, кешегә бит әле чагыштырып карау хасияте дә бирелгән. Кызганыч, ул чагыштырулар күп чакта безнең милләт файдасына булмады. Безнең халык бүтәнрәк, яхшырак тормышка лаек...

*— Бөек композиторыбыз С. Сәйдәшевкә куелган истәлек ташының (Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылында) Иделгә караган ягына Сезнең шигъри юллар уелган, диләр...*

— Әйе. Сынчы Фарис Фәтхи ташка уйган ул юллар мондый:

Җир бирә, Җир ала.
Озатып җыр кала.

Чайкала, чайкала,
Иделдә ай кала...

*— Бу уңайдан бер сорау: Сезнең турыда җыр чыгаручылар да юкмы әле?*

— Нинди җыр ди ул?! *(Елмая.)* Гомеремне язу эшенә багышлап, дөньяда калырлык бер җыр язып калдыра алсаң да ярар иде әле!

*— Шигъри сүзләренә популяр җырлар язылган Равил абый үзе җырларга яратамы икән?*

— Кызганыч, мин җырчы түгел. Күңелдә нindidер көчлегә охшаган тавыш бар. Әмма аны кеше тыңларлык музыкаль аһәңгә туры китерү мөмкин эш түгел.

*— Сезнең белән булган кызыклы хәл-вакыйгалар турында каләмдәшләрегез яза тора. Берсен үзегездән ишетсәк иде...*

— Кылт итеп искә төште әле, җырчы Гөлзадә Сафиуллина: «Бер очрашуда, сүз артыннан сүз чыгып, минә Равил Фәйзуллин белән бер мәҗлестә булдык әле, дигән идем, берәү: «Ул һаман да исәнмени әле?» — дип сорап куйды», — ди.

*(Автордан. Чыннан да, Р. Фәйзуллин — әдәбиятта күптәнге шәхес. Инде 60 нчы елларда ук классик әдипләребез Г. Бәширов, С. Хәким, Х. Туфан кебек исемнәр белән рәттән саналып йөри иде.)*

*— Бүген әйтелгән сүз иртәгәгә ярамый, дигән гыйбарә бар...*

— Әгәр бүген әйткән сүзем, бу очракта шигырь дип әйтик, иртәгәгә ярамаса, Фатих абый Хөсни әйтмешли, «ничу» язарга! *(Елмая.)*

*— Кәефләр киткән чак та буладыр... Бу очракта нишлисез?*

— Мөмкинлегем булганда, кешеләрдән качып, ялгыз калырга тырышам, урманга чыгу ягын карыйм (шөкер, минем дача өем Аккош күле янында — урман эчендә). Хәер, нигә проза сүзе, шигырь белән җавап бирик.

Сәясәттән ераклашкан саен,
Табигатькә ныграк елышам.
...Тәгәрәде кызыл кыргый алма
елан үтеп киткән юл аша.

*— Шигырь артыннан шигырь туа... Әле эштәге вазифалар да, гаиләдәгеләр дә... Гаҗәп, барысына да ничек өлгерәсез?..*

— Гомер ул кыска да, озын да. Зиндандагылар өчен һәр сәгать — бер гомер. Бәхеттән исергәннәргә ае да сәгатьтән ким... Яши белсәң, гомер узмый ул, йөри белсәң, ияр тузмый ул, диләрме әле? Бу хакта (Вакыт хакында) 1978 елда мондый юллар язылган:

Яшәү — кыска. Аҗагандай!
Үтә гомер цейтнотта!
Бөтен өмет, бөтен ышаныч —
үзем өчен үзем генә белгән
Вакыт эчендәге Вакытта!..

*— Һаман көндәлек алып барырга да вакыт табасыз, диләр...*

— Тәфсилләп язарга вакыт җиткерә алмыйм. Бу — минем гаебем инде, әлбәттә. Язучы кешегә көндәлек бик кирәк! Шулай да көннекен көнгә дигәндәй, берничә юл (факт, дата, исемнәр һ.б.) теркәп куям. Шулар аша байтак элек үткән күп хәлләр искә төшә.

*— Равил абый, сезнең шигырьләрне халкыбыз бик яратып укыгангамы, «Мәхәббәтнамә» һәм әле яңа гына чыккан «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» китабыгызны беркайдан да табып булмый...*

— Соңгысы бик тиз таралып бетте. Үткән ел чыккан «Мәхәббәтнамә» китабы кайбер китап кибетләрендә әлегә бар бугай.

*— Мәхәббәт дигәннән, Сез моннан ун еллар элек бер әңгәмәдә «миңа яратудан бигрәк, аңлаган кеше кадерлерәк» кебегрәк фикер әйткән идегез...*

— Әйе, шундыйрак сүзләр бар иде шикелле. Әле бит аның мондые да бар *(елмая)*:

Гомер буе җандаш эзләдем мин.
Азмы янып чапканым булды!
Җандашлар дип, күпме кандашларга
нурым түгеп бакканым булды!
Хәер ... кайчак җандашларымны да
төшләремдә тапканым булды!..

*— Сер булмаса, Наилә ханым белән ничек таныштыгыз?*

— Теннис кортында. Ул — табибә. Мин үземне дә шигырьләрем белән кемгәдер рухи сихәт бирәм дип уйлыйм. Димәк, туры киләбез булып чыга.

*— Шагыйрь йөрәгенә дә юл тәмле ризык ашадыр, мөгаен?..*

— Нигъмәтебездә нәрсә була, шул ярый миңа. Күңел тынычлыгы булса, һәр хәләл ризык — тәнгә сихәт.

*— Алдагы гаиләләр белән элемтә бардыр инде?..*

— Әлбәттә, алар бит минем гомеремнең аерылгысыз өлеше. Үткәнемә төкерсәм, миңа да төкерүләре бар бит...

*— Улыгыз Газизгә «иптәш» алып кайтырга исәп юкмы дигәндәй?..*

— *(Елмая.)* Әллә юри, әллә чын дигәндәй, әле яңа гына шигырь сыман берничә юл язып куйганмын. Бәлки, җавап урынына ярар:

Бәйрәм чыршысыннан җыеп,
аллы-гөлле бизәкләрне
бер тартмага төреп куйдык.
Исән булсак,
Кирәк булыр!
Малай тездән
төшеп бара...
Кечерәйгән киемнәрен,
уенчыгын-муенчыгын
бер шүрлеккә
төреп куйдык.
Исән булсак,
кирәк булыр!..
(Өмет — шайтан!)

*— Белгәнебезчә, 60 нчы елларда Яңарыш кичергән татар поэзиясендә «Фәйзуллиннар буыны» барлыкка килде. Нәсел-нәсәбегездә бу «буынны» дәвам итүчеләр булырмы дигәндәй?..*

— Авыз тутырып әйтү кыен. Нәселгә килгәндә, бертуган энем Рөстәм дә (автордан: ул, ягъни Акъегет «Татар радиосы»нда эшли) әдәбиятка якын кеше. Аның да шигырь китаплары бар.

*— 50 яшьлек юбилеен Казансу елгасы буйлап җиде чакрым йөзеп «билгеләп үткән», хәзер 60ны узган Равил абый тагын шундый рекорд куярга җыенмыймы?*

— Төшләргә керә ул йөзүләр. Кабатлап булырмы-юкмы, әмма теләк бар. Бәлки, атаклы йөзүче Искәндәр Фәйзуллин дигән кешене ишетеп беләсездер. Заманында йөзәр чакрым марафон йөзүләре ясаган кеше. Матур үрнәк!

*— Яңа фатир алуыгыз турында «Юлдаш»та язган идек инде...*

— Көнкүрешкә кереп китәбез шикелле. Ярый. Мин алай фатирга интегеп яшәмәдем. Яңа фатир дигәндә, элек яшәгән фатирны бүтәнгә алыштыру булды. Монысының түшәме биек. Тегесендә, чөеп уйнаганда, малайның башы түшәмгә бәрелә иде.

*— Каләмдәшегез Ә. Гаффар әйтмешли, кояш белән җир арасында халкыбыз исән-имин чагында, укучыларыбызга ни теләр идегез?*

— «Юлдаш» кебек олы басма укучыларына теләкләр бәләкәй була алмый. «Юлдаш» милләттәшләребезне туплау юлында изге эш башкара, телебезне, гореф-гадәтләребезне саклау сагында тора. Иң элек барчагызга да саулык телим. Сау-сәламәт булсак, халкыбыз да көчле булыр. Җан тынычлыклары телим. Иманлы эшләр кылыр өчен җан тынычлыгы кирәк. Горурлык телим. Безнең үткән тарихыбыз рухи төз булуыбызны таләп итә. Бер акыл иясе әйткән ди: «Әгәр халык халык булып калырга теләсә, өч нәрсә мөһим: тарихыңны белү, хезмәт сөю, талантларны ихтирам итү». Һәммәбезгә бу язлар бәхет китерсен!

*— Хөрмәтле Равил абый! Яңа нигездә гаиләгезгә исәнлек-саулык, бәхетле тормыш. Сезгә алга таба да бәрәкәтле, мәгънәле иҗат телибез!*

— Рәхмәт, Рафис туган!

**«ТАЯНЫЧ УЛ — ХАЛЫК...»**

*(Драматург Туфан Миңнулин белән әңгәмә)*

**Равил Фәйзуллин.** *Туфан Абдуллович! Бу әңгәмә барышында мин Сиңа «Сез» һәм «ага» сүзләре белән мөрәҗәгать итмәкчемен. Ихтирамым да зур, беркадәр яшь аермалары да бар...*

**Туфан Миңнуллин.** Алай итмик әле, Равил! Төрки-татар дөньясында үзара якыннар һәрвакыт Син дип сөйләшә. Без бит замандашлар, әдәбиятка да бервакыттарак килдек, кочаклашып йөрмәсәк тә, бергә дустанә гомер кичердек, иҗат иттек, балалар үстердек, иң мөһиме—фикердәш була алдык. Шуңа күрә бу әңгәмә инде акыл утырткан ике өлкән әдип сөйләшүе булсын.

**Р.Ф.** *Килешәм. Син безнең журналыбыз кунагы бүген, шуңа күрә сүз, нигездә, Синең иҗат һәм аңа бәйләнешле мәсьәләләр тирәсендә булыр, хуҗа сыйфатында сорауларны мин бирәм булып чыга инде.*

*Моннан нәкъ ун ел элек (Алмалы ел иде ул! Быел да шуңа охшап тора.) Синең туган ягың Кама Тамагында, туган авылың Олы Мәрәтхуҗада татар әдәбияты-сәнгатенең кабатланмас бер бәйрәме булган иде. Япь-яшь Туфанга нибары 60 яшь. Татарстанның гаҗәп матур урыны—Идел белән Каманың тоташкан урынында, биек ярда (ялгышмасам, исеме Айгыртау) татар рухын биеккә күтәргән Дуслар Учагы дөрләгән иде. Көн матур, чакырылган кунаклар берсеннән-берсе күркәм, бәйрәм хуҗасы—бөек... Матур сүзләр, мәңгелеккә омтылыш... Шул вакыйгадан соң ун ел гомер үткән дә киткән. Ул бәйрәм Синең үзеңә дә охшагандыр дип уйлыйм. Мөгаен, гомерем булса, ун елдан соң фәләннәрне эшләрмен дип уйлап хыяллангансыңдыр, дөньяда фәлән уңай үзгәрешләр булыр дип фараз кылгансыңдыр… Йә, Туфан ага, егерме беренче гасырның бишенче елында кәефләр ничек? Үзеңнән, дөньядан канәгатьме?*

**Т.М.** Минем яшьтә кәеф иң беренче чиратта саулык-сәламәтлек белән бәяләнә. Ул яктан Ходайның биргәненә шөкер әлегә, кем әйтмешли, әкрен генә йөгереп йөрибез. Аннан инде безнең кәеф иҗат белән нык бәйләнгән. Анда да, иншалла, тик торган юк. Өйдә дә иминлек. Димәк, үземнән канәгать, зарланырга хакым юк.

Дөньядан канәгать дип әйтә алмыйм. Мин һәм Син теләгәнчә әйләнми дөнья тәгәрмәче. Иң авыр кичерелгәне—туксанынчы еллар башында Рәсәйдә шәйләнгән демократиянең бетүгә таба баруы. Бигрәк тә күсәкнең юан башы безнең тарафларга төшә. Ничәмә-ничә гасыр хыялланган дәүләтчелеккә ирешү юлында җилкенеп алган идек, Суверенитет турында Декларация кабул иттек, Төп законыбыз—Конституциядә безне өметләндергән маддәләр пәйда булды. Бүген алар юкка чыкты. Үзен татар дип санаган кайсы кешенең йөрәге әрнемәс бу хәлгә. Шуңа каршы тора алмау чарасызлыгы җанны каезлый. «Нишләргә?» дигән сорауны үземә еш бирәм, тик җавабын таба алмыйм. Сүз шәхсән үзем турында гына бармый. Минем күңелемнән татарның үз дәүләте булырга тиеш дигәнне беркем дә тартып ала алмый. Мине яратмаган илне мин Ватаным дип әйтә алмыйм. Ничек һәр татарның күңеленә шул хисне сеңдерергә? Нишләргә?

**Р.Ф.** *Язучы эшчәнлегенең ахыр нәтиҗәсе—китап. Хезмәтләре театр, спектакльләр белән бәйле булган драматургларның китапка карата фикерләре, шагыйрьләр яки прозаикларныкыннан, бәлки, беркадәр үзгәдер. Ни генә булмасын, китап барыбер китап инде ул! Берничә ел элек Синең 10 томлык әсәрләрең басылып чыкты. Сирәк була торган куанычлы хәл. Соңгы дәвердә безнең заман язучыларыннан бары Т. Әйдинең генә мондый санда томлыклары чыга алды. Үткән заман классик әдипләрнең дә күптомлы сайланма әсәрләре әзерләнә дип беләм. Әйе, язу—бер хикмәт, китап итеп чыгару—үзе бер тарих, ә менә укучы күңеленә барып ирешү... Менә шул соңгысы—китапның кешеләргә барып ирешүе яки ирешмәве турында Синең фикерне беләсе килә. Хәтереңдәдер, әле май аенда гына булып үткән язучылар съездында да байтак сүз булды бу хакта. Китап—безнең тарихыбыз, данлы үткәнебез. Китап—безнең киләчәгебезме?*

**Т.М.** Бүгенге көндә чын һәм хәтта чын ук булмаган язучыга да китап чыгару зур проблема түгелдер. Республика җитәкчеләре ярдәмнәреннән ташламыйлар. Бүген төп мәсьәлә—чыннан да, китапның укучыга барып җитүе һәм укылуыдыр. Монда проблема баштан ашкан. Китап укучылар азайды. Бу татарда гына түгел, күпсанлы урыста да шулай. Аларның китап, журнал тиражлары бик түбән. Күрәсең, мондый хәл заман шаукымыдыр. Бүген кешенең йөрәге һәм башыннан алда корсагы йөри. Корсак кайгысы белән генә яшәүченең билгеле инде рухы ярлы була. Рухы ярлы кешегә китап кирәкми. Ләкин бу вакытлы фаҗигадер. Кешеләребез күңеленә азык җитмәвен тоеп, эзләнерләр һәм китапка килеп юлыгырлар дип өметләнәм.

**Р.Ф.** *Театрсыз милләтне күз алдына китерү кыен. Дөньяда без аңлаган классик мәгънәдә театрлары булмаган, әмма яшәгән һәм яшәячәк милләтләр дә бардыр, бәлки. Безнең шартларда театр—халыкның милләт булып яшәвенең бер билгесе. Әйтик, халыкны рухи берләштерүдә,*

*телебезне саклауда театрның роле бик зур. Шуннан чыгып, беләсе килә: театрларыбызның бүгенге хәлләре ничек? Әйтик, тагын 15–20 елдан аларны ничек күз алдына китерәсең?*

**Т.М.** Дөньяда театры булмаган милләт юк. Театрның формалары төрле-төрле. Без ияләшкән, рәсмиләштерелгән театрның формасы бердәнбер түгелдер. Татарда рәсми исем алган театрга хәтле күңел ачулар булмаганмы? Туйлар театр түгелмени? Кич утырулар да театр. Иң зур театрыбыз—Сабан туе. Анда милләтне милләт итеп саклый торган компонентлар тулып ята. Тел осталарының ярышлары да даими булып торган. Әйтик, казакъ, кыргыз халкында айтыс дип аталган бәйгеләр бүген дә үткәрелә. Татарларда да булган ул, әле без Мәскәүдә укып йөргәндә Измаил паркы дип аталган җирдә Нижгар, Тамбов, Пенза төбәкләреннән чыккан татарларның яшьләре кара-каршы такмак әйтешәләр иде. Шулай итеп телләрен саклыйлар һәм чарлыйлар иде. Егет белән кызның кара-каршы басып такмак әйтешүе—менә дигән театр. Профессиональ театрыбызга килгәндә, ул, әлбәттә, яшәячәк. Нинди булуы мине әллә ни борчымый. Татарча сөйләшүче, татарча фикерләүче, татар җанлы театрыбыз гына булсын.

**Р.Ф.** *Хәтердә: 80 нче еллар уртасында «Әлдермештән Әлмәндәр»не Бөтенсоюз телевидениесеннән күрсәттеләр. Без, бер төркем язучылар, Пицунда иҗат йортында идек. Җыелышып утырдык телевизор каршына. Бүтән милләт язучылары да байтак җыелды. Карыйбыз: экранда үзебезнең яраткан артистлар, үзебезнең тел, җанга якын мохит… Күз яшьләрен китерер дәрәҗәдә горурлык! Күңел бәйрәме! Менә шундый матур сәгатьләр бүләк иттең Син безгә ул чакта! Хуш, болары—үткән заман. Татар драматургларының, шул исәптән Синең әсәрләрең, бүтән илләр, халыклар сәхнәләрендә куеламы хәзер?*

**Т.М** Әгәр без СССРдан аерылып чыккан союздаш республикаларны мөстәкыйль ил дип кабул иткәнбез икән, аларда минем пьесалар куелгалап тора. Бигрәк тә Казакъстанда, Үзбәкстанда. Россиядәге башка милли театрларның репертуарында мин язганнар бар. Бигрәк тә Төньяк Кавказ республикаларында мин популяр. Урыс театрларында—юк. Хәтта Казаныбыздагы урыс телле театрларда да мине драматургка санамыйлар. Хәер, мине генә түгел, гомумән, татар драматургиясен алар санга сукмыйлар. Күрәсең, безнең дәрәҗәгә «төшәселәре» килми. Урыс әйтмешли, черт с ними. Миңа үзебезнең театрлар да бик җиткән, алар бер дә урысныкыннан *(урысныкы микән әле бүгенге урыс театрлары)* ким түгелләр.

**Р.Ф.** *Соңгы елларда Камал театры инициативасы белән «Яңа татар пьесасы» дигән конкурс-ярышлар (нишләптер конкурсларны соңгы вакытта «бәйге» дип яза башладылар. «Бәйге» сүзе, минемчә, ул күбрәк ат чабышларына карый) оештыралар. Әлбәттә, җиңүчеләр билгеләнә. Бу конкурсларга Синең карашың? Һәм өстәп: татар драматургиясенең киләчәге кемнәр кулында?*

**Т.М.** Конкурсмы, бәйгеме—миңа барыбер. Тегесе дә монысы да ярышу инде аның. Мондый гамәлне мин хуплыйм, ярышырга яратам. Элеккеге ярышларда катнаша идем, соңгысында катнашмадым. Чөнки конкурсның шартлары канәгатьләндермәде. Анда урыс телендә язылачак драма әсәрләре дә кабул ителә, диелгән иде. Татар телендә язылмаган пьеса татарныкы була алмый дип саныйм. Чөнки тел—әдәбиятның төп үзәге, умыртка сөяге. Татар телендә яза белмәгән язучы татарларны да мин татар язучысы дип атамыйм. Гафу итсеннәр. Татар язучылары буласылары килсә, татарның теленнән җирәнмәсеннәр, объектив сәбәпләр эзләп акланмасыннар. Ана телсез милли әдәбият—ул яһүдләр теориясе. Алар безне кыйбласызлыкка өндәп, үзләре Израильгә карыйлар. Без башка халык, ни кызганыч, безнең Израилебез юк, без үзебезне үз телебез белән сакларга мәҗбүр ителгән. Әлегә, дип тә өстәп куйыйм. Драматургиябезнең киләчәге кемнәр кулында дигәндә, татарча камил язучы татарлар кулында булыр дип өметләнәм.

**Р.Ф.** *Фараз итеп, әгәр Камал театры, байтак дистә еллар аның төп хуҗасы М.Сәлимҗанов дөньяда булмаса, бүгенге Туфан Миңнуллин шушындый зур була алыр иде микән?*

**Т.М.** Мин Марсельне татарның бөек режиссеры дип саныйм һәм аның белән бергә иҗат итү бәхете тигәнгә язмышыма рәхмәтле. Әмма Марсель булмаса, мин дә булмас идем дип әйтергә телем әйләнми. Мин үземне мөстәкыйль фикер йөртүче шәхес дип исәплим. Кемнеңдер итәгенә ябышып дәрәҗәгә ирешү минем өчен ят нәрсә. Мин драматург буларак режиссерлар Сабир Өметбаев, Равил Тумашев, Гали Хөсәеновларга рәхмәтемне әйтеп торам. Сабир абый Өметбаев, мәсәлән, Минзәлә театрында беренче пьесамны куйды. Әсәр буларак шактый ук йомшак булса да куйды. «Үзең язганны үзең сәхнәдән кара, үз ялгышларыңны күрсәң, драматург булачаксың, күрә белмәсәң, театрга пьеса күтәреп килмә» диде. Аны ничек онытасың...

Әлбәттә, Марсельнең миңа тәэсире зур булды. Ул чын укымышлы, эрудицияле шәхес иде. Ләкин ул да мин язганнарга мохтаҗ иде. Төп мәсьәләләрдә фикерләр берлеге безне якынайтты, берләштерде. Һәр драматургның бәхете—аны аңлаган режиссерның язмышына туры килүе. Бүген

мин Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев белән уртак тел табарга тырышам, Түбән Кама театры режиссеры Рөстәм Галиев белән дә борчагыбыз пешә.

**Р.Ф.** *Син бөтен табигатең-холкың белән карьера өчен яратылган кеше түгел. Гөбедән чыккан тавыш белән турыдан ярып сөйләшү, ачымы-төчеме, хакыйкатьне ярып салу… Син дипломатик кануннарның бөтен нечкәлекләрен белеп бетергән кеше дип уйламыйм. (Ә кем белә, бәлки, киресенчәдер…) Шулай да… Син, карьера кешеләренә хас булганча, хакимият-власть тирәсеннән беркайчан да китмәдең. Язучылар оешмасы парторгы, соңрак шул оешманың рәисе. СССР Югары Советы депутаты, Татарстан Дәүләт Советы депутаты… Хәзер дә Татарстан Дәүләт Советында даими комиссия рәисе урынбасары… Малың бар, даның бар дигәндәй... Нигә Хемингуэйлар кебек табигать стихиясендә ял итеп, кирәк чакта бар вакытны фәкать иҗатка гына биреп яшәмәскә?*

**Т.М.** Килешеп бетмим, Равил. Карьерага омтылмаган кеше шәхес була алмый. Ә мин үземне шәхес дип санаым. Ләкин нинди карьерага омтыласың бит. Мине иҗат карьерасы һәрвакыт камчылап торды. Бүген әйтергә ярыйдыр инде, мин Туфан Миңнуллин дигән исемне алу өчен тырыштым. Кайберәүләр бит язган әйберләре астына фамилияләрен куялар да Татарстанның атказанган фәләне дип өстиләр. Шул өстәмәләрсез генә кем икәнемне белсәләр, мин максатыма ирешәм дип шатланам. Әйе, ул яктан чын карьерист мин. Ләкин мин кемнәрнең дә садакасы хисабына, «служебный карьерага» ирешергә теләмәдем. Андый карьерага ирешер өчен әллә ни тырышырга кирәкми бит—кемнәргәдер ярый белергә генә кирәк. Минем дәрәҗәле исемнәрем шактый, һәм алар миңа язучылык һөнәре өчен мин нәчәлство тирәсендә буталып йөри башлаганчы ук бирелгәннәр. Хезмәтемне вакытында күреп алып бәяли белгәннәргә рәхмәт. Депутат булып сайлануларым да шуңа бәйләнгәндер дип уйлыйм.

Власть башында утыручыларга «ярый белүем»нең хикмәте нидәндер, өзеп әйтә алмыйм. Һәрхәлдә, ялагайланудан түгел. Күпләр хакимияттә утыручыларның психологиясен аңлап бетерми. Анда ялагайларны өнәп бетермиләр. Чөнки ялагайлар—ышанычсыз кешеләр. Алар, җае чыкса, үз туганнарын да саталар. Өстәгеләр мөстәкыйль шәхесләрне хөрмәт итәләр. Әлбәттә, ул мөстәкыйль шәхес өстәге икенче мөстәкыйль шәхеснең урынын биләргә тырышса, ул чакта аңа каршы көрәш башлана. Җиңелгәнне анда кызганмыйлар. Мин берәүнең дә урынын алырга тырышмадым, берсенең дә тәхетенә кызыкмадым, әйтәсе сүзем җанны борчыганнан әйтелә, ихластан сөйләнелә. Нәчәлство без уйлаганча ук акылсыз түгел, нәрсәнең ни өчен әйтелгәнен бик яхшы аңлый.

Ә инде, Хемингуэйча яшәп иҗат итүгә килгәндә, мин алай да яшәп карадым. Ләкин без яшәгән ил Хемингуэйлар өчен түгел. Кешенең кадере булмаган илдә алай яшәп булмый, кычкырып ачтан үләсең. Телиме-теләмиме, кеше үзе яшәгән мохиткә яраклаша. Без нихәтле генә мөстәкыйль булырга тырышсак та, имгәтелгән буын—безгә, үзебезчә яшәргә тулы ирек бирелсә дә югалып калабыз, ирек өчен көрәшүебез үзара сукранышудан узмый.

**Р.Ф.** *Сүз җебенең очын югалтмыйча, әңгәмә башын искә төшерик әле: син «Суверенитет турында декларация кабул иттек. Төп законыбыз—Конституциядә безне өметләндергән маддәләр пәйда булды. Бүген алар юкка чыкты», дисең. Ә кем гаепле?*

**Т.М.** Үгезнең мөгезен эләктерәм дисең инде. Кем гаепле? Ялгышмасам, урысның бер зыялысы да заманында Россиянең мөшкел хәлгә төшкәненә «Кто виноват?» дигән сорау куйган булган. Кемнәрнедер гаеплисе дә килми. Бардыр инде, Алтын Урда империясен саклый алмаганбыздыр. *(Хәер, һәр империянең таркалырга тиешлеген тарих исбатлап тора.*) Болгар дәүләте җимерелүендә дә үз кулыбыз юк түгелдер, Казан ханлыгын да бар төркиләр бергә җыелып яклый алмадык. Яулап алучы дәүләт, табигый хәл, үз кагыйдәләре белән эш йөртә. Шуның өчен яулап алган бит инде ул, татарга яхшы булсын дип бәреп кермәгән. Бер тарихи факт мине өметләндерә — дүрт гасыр ярым албасты астында яшәсәк тә, милләт буларак югалмадык. Берничә тапкыр үзебезнең саклану иммунитеты исән икәнлекне күрсәтә алдык. Бигрәк тә соңгысы — Декларация кабул иткән көннәрдә дәррәү уянуыбыз өметне көчәйтте. Без бүген каршыбызда кем торганны күреп чигендек, кем гаепле? Әлбәттә, кайбер конкрет мәсьәләдә кемнедер гаепләп тә буладыр. Ләкин, зинһар, кирәгеннән артык каты кагылып бер-беребезне рәнҗетешмик. Тарихи ситуацияне дөрес бәяләп чигенә белик. Әмма һәрдаим көрәшкә әзер булырга кирәктер. Әйткәнемчә, рухыбызның сәламәтлеген сакларга өйрәник. Әмма болар гына төгәл һәм тулы җавап түгел. Кем гаепле? дигән сорау кала бирә. Бәлки, аңа Син дә, бүтән дә җавап эзләр. Кем гаепле?

**Р.Ф.** *Нигә депутатларның берәрсе җитди политик акция ясамады? Әйтик, протест йөзеннән мандатыннан ваз кичмәде? Парламентның яртылабы элекке состав, ягъни 90 нчы еллардан бүгенгегә кадәр депутат булып торучылар бит. Заманында үзләре үк чыгарган законнарны үзләре үк сүттеләр. Депутатлары шундый булгач... Глобаль уйлаучы даирәләр, дөнья җиһангирләре диюем, «бу халыкны теләсә нишләтеп тә була» дип тә уйлыйлардыр, бәлки?*

**Т.М.** Бу чын шагыйрь соравы. Сәясәтче мондый сорауны бирмәс инде. Мин дә сәясәтче түгел. Шуңа күрә җавабым да үзебезчәрәк булыр иде. Бәлки, ул җавап та түгелдер, уйлану гынадыр. Син әйткәнчә, минем дә протест ясап депутат мандатыннан демонстратив рәвештә баш тарту уе башыма килгәли. Соңгы елларда бу теләк көчәя төште. Ләкин шунда әтинең әнигә әйтә торган бер сүзе искә төшә. Әни нигәдер булса ризасызлык белдереп тузына башласа, эти: «Тукта, кызма әле син, Халисә», — дия иде. Әни бераз сүрелгәч икенче төрлерәк уйлый иде. Ярый, Синеңчә булсын, мин депутат мандатын атып бәреп, әйтәсе сүземне әйтеп сессиядән чыгып киттем ди. Шуннан ни була? Ни үзгәрә? Ни кызганыч, берни дә үзгәрми. Берәүләр мине яклап дуларлар, берәүләр кызганырлар, берәүләр ялгышты диярләр, дурак дип әйтүчеләр дә табылыр. Заманында мин Минтимер Шәрипович президентлыкка сайланганда аның яклаучысы (доверенное лицо) булдым. Шунда миңа, президент Дудаев кебек булсын иде ул, дип әйтүчеләр була иде. Мин аларга, президент Дудаев кебек булсын өчен халкың чечен кебек булырга тиеш, дип әйтә идем.

Суверенитетның беткәннән-бетә баруын күреп дулыйм да, күмерем бераз сүрелгәч, уйлыйм: «Тукта әле, дим, минем протест ясап китүемә караганда, сүземне туктаусыз трибунадан әйтеп тору отышлырак түгел микән?» — дим.

**Р.Ф.** *Син «Татар кодексы» Кануннамәсенең төп авторы. Аның тезислары ун еллар элек «Казан утлары»нда да чыкты. Соңрак, тәфсиллерәк итеп (яңадан редакцияләнгән варианты диикме), «Идел» журналында басылды. Миңа калса, бик җитди Кануннамә ул. Яһүдләрнекен әйткән дә юк, Төрекмән башы Ниязовның да (ул, мөгаен, коллектив хезмәттер инде) «Рухнамә»се дә гыйбрәтле. Аның белән татар укучысы да танышса, файдага гына булыр. Әлбәттә, һәр халыкның үз карашлары, үз кануннары, үз идеаллары… «Татар кодексы»н халык аңына сеңдерү өчен нишләргә кирәк?*

**Т.М.** Төгәл генә белмим. Без өстән әйтелгәнне хакыйкать дип кабул итәргә өйрәтелгән. Милләтне саклауның эчке динамикасын үзләштермәгән. Татар теле нигә кирәк, татар теле белән кая барып була дип сөйләнүче татарга җан ирегә турында сөйләп, ни эш кырып була икән? Милли хисләре булса да, хакимият башында утыручылар гына милләтне саклый алмыйлар. Аларга таяныч кирәк. Ә таяныч ул—халык. Мин—татар дигән хис һәр татарның җанында булмаса, Мәскәүне сүгүдән ни файда? Әгәр җаныбызда татарлык була икән, Мәскәү дә, Вашингтон да пычагым да кыра алмый. Менә шуны аңлатырга тырыштык Кодекста. Аны мәктәпләрдә өйрәнеп яшь буынның җанына сеңдерә алсак иде. Ни кызганыч, мәктәптә укытучылар арасында аны аңлатырдайлары күп түгел. Татар дигән сүзне кычкырып әйтергә курыкканнар үзләре кебекләрне тәрбияли. Югыйсә татар булып татар өчен көрәшүнең ни начарлыгы бар. Мин, мәсәлән, татар дип әйткәндә бүтәннәрне түбәнсетмим, үземне генә зурлыйм.

**Р.Ф.** *Без язучылар күп дистә еллар Язучылар оешмасына елышып яшәдек. Шунда җыелдык, утырышлар уздырдык, мактаныштык, тәнкыйтьләдек һәм тәнкыйтьләндек… Оешмасыз иҗади яшәүне күз алдына китерү кыен иде. Чөнки күбебезнең иҗади язмыш (иҗади яктан бәяләнү, китаплар чыгаруга булышлык, исем-премияләр алу, югары органнарга, сайлауларга тәкъдим итү һ. б.; шулай ук көнкүреш-матди хәлләр—фатир, пенсия, путевка-юлламалар алу һ. б.) Язучылар оешмасына бәйле иде. Хәзер вазгыять бүтән. Шулай да гадәт-менталитет белән без һаман да оешмага ниндидер өмет белән карауны дәвам итәбез. Гәрчә иҗтимагый оешма буларак Язучылар берлегенең мөмкинлекләре чикле хәзер. Синеңчә, оешманы язучылар үзләренең туган йорты кебек күрсеннәр өчен яңа сайланган җитәкчеләргә һәм, гомумән, язучылар коллективына ниләр эшләргә кирәк?*

**Т.М.** Төрле хәлләр булды. Язучылар оешмасы коммунистлар оештырган кыса диючеләр табылды. Бәлки шулайдыр. Күпләргә Язучылар берлеге кирәкмидер дә. Миңа да шәхсән аның практик яктан кирәге юктыр. Ләкин без бер һөнәр кешеләре буларак очрашып сөйләшмәсәк, фикер уртаклашмасак, кирәк чакта үзебезнең катгый сүзләребезне әйтмәсәк, ни булыр? Җыр да бар бит:

Агай-эне—ак мыек,
Бер-беребезне какмыек.
Каккан-суккан чакларда да
Бер-беребезне яклыек.

Без барыбыз да аерым-аерым, «качып» эшли торган һөнәр иясләре. Озак «качып» йөргәннән соң агай-энеләрнең нишләп йөргәнен, ни уйлаганын беләсе килә. Үзең турында сөйлисе килә. Менә шундый чакта бергә җыелып аласың да рәхәтләнеп сөйләшәсең. Өнәп бетермәгән кешеләреңне дә сагынган буласың. Кеше — табигатьтә көтү инстинкты белән яшәүче җан иясе. Көтү булып яшәсәк тә, көтүчеләрне яратып бетермәүче «кәҗәләр» без. Шуңа күрә безнең рәисләребез дә үзләрен чыбыркы аскан көтүче дип хис итмәсеннәр иде. Ә андый көтүчеләр булгалады арабызда. Көтүче

роленә кергәч, үзләрен зур язучы дип тә уйлады кайбер бахырлар. Мин Язучылар берлеген без татарларга бигрәк тә кирәк оешма дип саныйм һәм аның җитәкчеләре безне татарлык идеясе тирәсендә берләштерергә, яшь талантларны барларга, аларга юл ачарга булышырга тиешләр дип уйлыйм.

**Р.Ф.** *Кеше телиме-теләмиме, барыбер кемгәдер, нәрсәгәдер хезмәт итә («Нәрсәгәдер» дигәнне ниндидер идея-максатка дип әйтүем). Ахыр чиктә, Синең иҗат та, минем һәм фәләннең иҗаты да җәмгыятьнең билгеле бер ихтыяҗларына хезмәт итә. Элек коммунистик партия әгъзалары идек... Хәзер дә төрле партияләр җитәрлек. Ялгышмасам, Син хәзер «Бердәм Россия» фиркасе әгъзасы. Депутат булып та шул партиядән үттең шикелле. Классик драматург, депутат, элеккеге коммунистның (берәр ел Язучылар оешмасының парторгы булып та тордың бит әле) бүгенге идеологик кредосы нидән гыйбарәт?*

**Т.М.** Идея дигән нәрсә бар. Шул сүз тамырыннан чыккандыр—идеал дигән төшенчә бар. Янә дә сәясәтчеләр ясаган идеология дә бар бит әле.

Белгәнем кадәренчә, коммунистик идеянең бер генә начарлыгы да юк. Кешеләр кайсы расадан, кайсы милләттән булуларына, тормыш баскычының кайсы басмасында басып торуларына карамастан—тигез хокуклы булырга тиешләр. Начармыни? Байлыкка шул байлыкны җитештерүчеләр хуҗа булырга, теге яки бу табигый шартлар аркасында кеше эшкә яраксыз икән, андыйлар җәмгыять тарафыннан якланырга тиешләр. Начармы? Безне бердәнбер сагайткан нәрсә—коммунистик идея дөньяны кирәгеннән артык материаллаштерә—кешеләрне диннән аера. Коммунистик идеянең кешеләрнең аңына үтеп керә алмавының сәбәбе бәлки шундадыр да. Ул идеал була алмады. Кешене рухыннан аерырга ярамый. Һәр идеяне дә яхшы яки начар максатта файдаланырга була. Рухы ярлы, белеме сай, күңеле саф булмаган кешеләр иң изге китабыбыз Коръән Кәримнән дә әшәкелек эзләделәр. Авыр булса да әйтергә туры килә, безнең бер өлкән язучыбыз «Коръән серләре» дигән әсәр язып, изге китапны пычратты.

Коммунистик идеяне большевикларваклады, аңардан үзләренең диктатурасын кертү идеологиясе ясадылар. Идеяне әкияткә әйләндерделәр. Без аңа ышанмый башладык. Коммунизм төзү идеясе мәзәк-анекдотлар материалына әверелде. Экономика законнарын белмәгән надан җитәкчеләр хәерче СССРда егерме елдан коммунизм булачак дип игълан иттеләр. Хәер, кем белә, бәлки ул наданлыктан да булмагандыр, алданырга өйрәтелгән халыкны тагын бер тапкыр алдау өчен махсус уйланылган сәясәт булгандыр. Андый алдаулар күп күрелде шул. Шуны бүгенге сәясәтче «демократлар» бик оста файдаланып, властька менеп утырдылар. Коммунистик идеягә халыкны каршы куеп коммунистлар партиясен тараттылар. Әлбәттә, алдау ысулы белән эш йөрткән партия кайчан да булса бер таралырга тиеш иде. Ләкин мин чын күңелемнән ышанып әйтәм, коммунистик идеянең төп тәгълиматлары яшәргә тиеш. Ерткыч капитализмның акулаларына каршы үзенең дәлилле сүзен әйтеп барырлык көч яшәргә тиеш. Чөнки халыкны алдау бүген дә дәвам итә. Ләкин коммунистик идея өчен көрәшүчеләр, Дума депутатлары кебек, үзләренең шәхси мәнфәгатьләрен генә идея хисабына яклаучылар булырга тиеш түгел.

Күзәтүләрдән чыгып шундый нәтиҗәгә дә килдем әле мин: Рәсәй дигән дәүләттә нинди генә идея белән кайсы гына партия хакимияткә килмәсен—тулаем гомумхалык файдасына берни дә үзгәрми. Барысы да халык исеменнән властьны эләктереп алалар да халыкны оныталар. Шундый илдер инде бу, күрәсең.

**Р.Ф.** *Син матди яктан каләм ияләре арасында иң хәлле (бай дисәң дә ярыйдыр) язучы. Газетадан укып белдем: бер елны Синең еллык керемең 1 млн. сумнан артык булган икән. Моңа Син хәләл хезмәт һәм булдыклылыгың белән ирешкәнсең. Бик әйбәт. Язучы халкына да гел хәерче булырга димәгән. Акчаны Ирекkә юл диләр. Асылда, иҗат кешесе ирекле булырга тиеш тә. Матди бәйлелек мескенлеккә тарта. Бер шагыйребез юкка гына болай язмагандыр:*

*Илһамлы каләме өстеннән*
*гомере буе*
*карап торды ипи күзе.*

*Син, минемчә, моннан азат. Ирек, иҗат, җәмгыятьтәге урын кебек категорияләр (бәлки, төшенчә дип әйтергәдер) турында Синең кебек шәхес ни уйлый икән? (Иҗат кешеләре дә төрле бит әле: музыкант, сынчы-архитектор, рәссам, артист һ.б.) Хәерче килеш олы сәнгать тудырып буламы?*

**Т.М.** Әйе, булмый. Хәерче, теләнче шәхес була алмый, ә шәхес булмаган кеше иҗат итә алмый. Әмма байлык та иҗат итәргә бердәнбер гарантия түгел. Бай хәерче, бай теләнчеләр дә була—шуны да онытмыйк. Син мине бай дип атыйсың. (Шулай язып өйгә рэкетирлар җибәрмә тагын! Өебездә чын караклар кызыгырлык әйберләр юк.) Әлбәттә, мин акчасыз кеше түгел. Ләкин мин аңа

табынмыйм. Кергәнен «туздыра» барам. Ничек туздырганымны оныкларым белә. Минем дә бит муеннан бурычка батып акчасыз утырган елларым бар иде. Акча миңа мирас булып калмады. Ул чакта да мин хәерче, теләнче булмадым. Иң авыр сугыш елларында, ачлыктан шешенгәндә дә әни безне теләнергә чыгармады. Аңардан берәр әйбер сораганда да, «җыламый, шыңшымыйча сора» дия иде. Бик тә яшәргә теләсәң, тырышасың инде ул, акчасы да табыла. Мин бит авыл баласы, бүген тапканны бүген кабып бетерүче түгел. Алдагысын да уйлыйсың. Бүген, мәсәлән, чын картлыгым турында да уйлыйм. Дөньяда мәгънәле итеп яшәргә тырыштым—шул гына.

«Ипи күзе» бөтенебезгә дә карап тора. Татарда хәерче язучы юктыр ул. Акчасы чамалылар күп, хәерчеләр юк, Аллага шөкер. Гомумән, хәерчелек, теләнчелек татарга хас сыйфат түгел. Җыламыйк.

Җан биргәнгә җүнен бирә—
Үзе яраткан Ходай,

—дип җырлыйлар безнең авылда.

**Р.Ф.** *ПЕН-клуб эшчәнлегеннән бик азлар хәбәрдар. Халыкара бу оешма бүлегенең Татарстанда оештырылуына да ун елга якын. Оештырылган көннән башлап Син аның президенты саналасың. Бу оешма һәм аның эшчәнлеге турында укучыларыбызга беркадәр мәгълүмат бирсәң икән?*

**Т.М.** Бу турыда, минемчә, байтак язылды инде. Гәҗит укыштырып, радио тыңлаштырып баручылар беләдер. Укымаганнарына сүз әрәм итеп сөйлисем килми, барыбер укымаячаклар. ПЕН-клуб — безнең язучыларыбызның турыдан-туры чит илләр даирәсенә чыгып, татар әдәбияты, татар тарихы, татар кешесе белән бөтәннәрне таныштыручы оешма ул. Безне чит илләрдә белмиләр. Мәскәү безне чит илләр күзеннән яшереп саклады һәм саклый. ПЕН-клубның бердәнбер вазифасы шул. Арабызда шул оешмага каршы көрәшеп маташучы ахмаклар да булды. Нишләтәсең, анысы да татарлык.

**Р.Ф.** *Син Язучылар оешмасында рәислек иткән чорда «Татарстанның халык язучысы», «Татарстанның халык шагыйре» дигән исемнәр булдырылды. Югары оешмаларны шушы исем кирәклегенә күндердең. 1986 елдан башлап 18 кешегә бирелде бу исем. Шуларның 11е вафат, 7се исән. Синең үзеңә дә бу исемне күптән бирергә кирәк дигән фикерләр булды. Имеш, Син үзең теләмисең икән… Хикмәт нәрсәдә? Гомумән, бу исем турында фикерең?*

**Т.М.** Имеш, димә, Равил. Теләмәгәнемне Син үз колагың белән ишеттең. Роберт Миңнуллин «Безнең дәрәҗәгә төшәсе килми Туфан абыйның» дип төрттереп тә куйды. Аңардан сенсация ясарга кирәкми. Сәбәбе бик гади—без андый исемне булдырырга йөргәндә, аны бик сирәк язучыларга гына бирерләр дип уйлаган идек. Күп дигәндә өч-дүрт шагыйрь һәм язучы булыр дигән идек. Андый югары дәрәҗә өчен 18 кеше күп ул. Мин ул исемне йөрткән беркемне дә кимсетергә теләмим. Бары тик шул өч-дүрт арасына керергә үземне лаек түгел дип кенә саныйм. Әйткәнемчә, бүген миңа Туфан Миңнуллин дигән исем бик җиткән. Дан өстәмәгән бүләккә кызыгырлык яшьтән узганмындыр, ахрысы. Бөтен бүләкләрне, дәрәҗәле исемнәрне үзең белән алып китәргә язмасын иде.

**Р.Ф.** *Без әдәбиятка килгәндә, ягъни үткән гасырның 60 нчы еллар башы була инде бу, тулы бер аксакаллар төркеме бар иде. Г. Бәширов, Х. Туфан, Ш. Маннур, А. Шамов, И. Гази, С. Хәким, М. Әмир... Тагын биш-алты исем санарга була. Алар безнең өчен зур абруйлы шәхесләр иде, әйткән сүзләре дә канун кебек катгый иде. Без алардан беркадәр шүрли дә идек шикелле. Кылган гамәлләрне, язган-сызганнарны алар күзе белән дә карап бәяли идек... Аксакаллар бит! Алар ни әйтер?... Хәзер кайтып чагыштырып карыйм: аларга ул вакыт 50–60 яшь булган икән! Хәтта бүгенге бездән дә яшьрәк! Әйе, без дә шактый озын гомер кичереп киләбез, яшьләребез дә зур, ә аксакал була алдыкмы соң? Ата-бабаларыбыздан калган әхлак нормалары сакланамы хәзер? Замана бүтән булгач, без үзебез дә бүтәнме, яшьләребез дә без теләгәнчә түгелме? Мин бу хакта еш уйланам. Синең фикерне дә беләсе иде!*

**Т.М.** «Без яшь чакта сыерлар да мөгрәп кайталар иде көтүдән» дип әйткән ди колагы катыланган бер әбекәй. Дөнья шулай үзгәреп торадыр инде ул. Минем үземә дә еш кына андый уй килә. Без, өлкәннәр, вакландык бугай, элеккеләр саллырак фикерле белә, үзләрен мәртәбәлерәк итеп тоталар иде дип уйлыйм. Без, яшьләр, тәртиплерәк, әдәплерәк идек дип тә әйтәсе килә. Уйлап-уйлап торам да элеккеләрнең дә кәефебезне җибәргән кайбер гамәлләре искә төшә. Мисаллар эзләмик, үткәннәргә селтәнүне мин егетлеккә санамыйм. Инде бүгенгегә килсәк, мин үземә аксакал дип караучы шактый яшьләрне беләм. Күп кенә язучылар Синең шигырьләрдән өзек алып үзләре

язганнарга эпиграф итеп куялар. Кеше олыгайгач үзенә күбрәк игътибар өмет итә. Элеккеләр әйбәтрәк иде дип фикер йөртү шуның нәтиҗәседер ул.

**Р.Ф.** *Син — көндәлек (вакытлы дип тә әйтәләр) матбугатта иң актив язышкан әдип. «Кызыл тышлы дәфтәр»дән сәхифәләр иң тиражлы, тәрбияви әһәмияте зур булган басмаларда бик еш басыла. Мин үзем аларны яратып укыйм. Халык та яратып танышып барадыр дип уйлыйм. Син аларны үз иҗатыңда нинди урын тота дип исәплисең?*

**Т.М.** Үз иҗатына зур эш итеп караган язучының көндәлек алып бара торган дәфтәре бардыр ул. Чөнки бар күргәнне, ишеткәнне хәтердә саклап тору мөмкин түгел. Кемнәрдер көндәлеген күрсәтми, мин исә күрсәтердәйләрен матбугатка биреп барам. Мин аларны әдәби яктан эшкәртеп тә тормыйм. Тора-бара бу әдәбиятның публицистика дип аталган жанрында эшләү рәвешен алды. Аларны дөньяга чыгаручыларга рәхмәт, ошатып укучыларга рәхмәт.

**Р.Ф.** *Син кырык елдан артык «Казан утлары» журналының даими авторы. Озак еллар буе аның редколлегия әгъзасы да. Утырышларда, Синең белән аерым очрашуларда гел әйтә киләм: баш редактор буларак, ярты вакыт подписка-тираж мәсьәләләре белән шөгыльләнеп үтә. Хәзерге 6–7 мең тираж—бик күп оештыру эшләренең нәтиҗәсе. Шуңа да карамастан кимү тенденциясе дәвам итә. Шактый көч куеп чыгарган журналны күпләр укуын теләү—табигый хәл. Тираж—әдәбият язмышын күрсәткән фал. Син журналда эшләсәң, бу юнәлештә нинди гамәлләр кылыр идең? (Шуны да өстәп әйтим: туган ягың Кама Тамагында да журналны бик аз алдыралар. Чагыштырыр өчен: Сабада—300 данә, Кама Тамагында—27 данә.)*

**Т.М.** Соңгы җөмләне хакимият укый торган гәҗиткә дә яз әле. Бәлки, файдасы тиеп, күбрәк язылырлар. Нишләтим инде ул язылмаганнарны. Мин, мәсәлән, татар телен һәм әдәбиятын укытучылар «Казан утлары»н укып барырга тиешләр дип саныйм. Бу аларның профессиональ мәҗбүри бурычлары. Районндагы һәр китапханә журналны алдырырга тиеш. Җыламасыннар укытучылар, «Казан утлары»н алдырырлык кына акча түләнә аларга. Аңламаган укытучыларга хакимият аңлатырга тиеш. Әгәр дә әдәбият укытучысы бүгенге әдәби процесстан хәбәрдар түгел икән, аның әдәбият укытырга хакы юк. Ә инде калган Кама Тамагы татарлары сабалылардан бераз көнләшсеннәр иде, бигүк надан түгел лә инде без.

**Р.Ф.** *Классик Туфан Миңнуллин шәкертләр үстердеме? Булса, алар кемнәр?*

**Т.М.** Шәкерт үстерү минем эшем түгел. Гомумән, әдәбиятта остазлыкны һәм шәкертлекне өнәмим. Һәр язучы әдәбиятка остаз сүзен кабатламыйча, үз сүзен әйтер өчен килергә тиеш. Без—өлкән буын аларга үз сүзен әйтер өчен шартлар тудырырга тиеш. Минем яратып әйтә торган бер сүзем бар: миннән яхшы язучыны яратып бетермим *(чөнки көнләшәм)*, ә миннән начар язучыны җенем сөйми. *(Чөнки ул әдәбиятның әче дошманы.)* Мин киләчәк буынга фәлсәфи карыйм. Әгәр бездән соң татар язучылары килмәсә, безнең кирәгебез юк, без язганнарның кирәге калмаячак. Безне алыштыручы яшь буын бездән талантлырак булырга тиеш, бу—табигать законы. Һәр талантлы татар язучысы минем өчен бик тә кадерле. Талантлылар арасында үзеңне кеше итеп тоясың. Сәләтсез һәм өстәвенә әрсез язучылардан Ходай сакласын.

**Р.Ф.** *«Дус» сүзе бар. Бер иҗекле генә…*
*Ә мәгънәсе—чиксез һәм тирән.*
*Әй, кыен шул асылын бу сүзнең*
*дөрес итеп аңлап бетерү! —*

дип язган идем мин «Сәйдәш» поэмасында. «Дусларыңа карап үзеңә бәһа бирерләр» дип тә әйткәлиләр. «Заманалар авыр, еллар ябык, дус-иш кирәк гомер итәргә!» дип җырлаган борынгыларыбыз һәм хәзер дә җырлыйбыз. Фикердәшләрең бармы, булса, дуслык мөнәсәбәтләре нинди критерийлардан чыгып корыла?

**Т.М.** Дуслык дигән төшенчә гомер үткән саен үзенең төсмерен үзгәртеп тора. Яшь чакта күп кешегә дус дип эндәшәсең. Шуңа күрә дусларның саны да күп була. Яши-яши кемнәрдер арбадан төшеп кала, йә син алар белән бер арбада утырып барырга теләмисең, йә сине утыртмый башлыйлар. Чөнки тормышка карашың җитдиләнә барган саен, сайлана башлыйсың. Шешәдәшләр, әшнәләргә түгел, фикердәшләргә мохтаҗлык арта. Дуслык бит ул корбан да сорый торган нәрсә. Дустың дип санаган кешеңә син һәрвакыт бурычлы. Ул бурычны дус дигәнеңнән түләтергә телисең икән, димәк, анда дуслык булмаган. Дус ул синең иң яшерен серләреңнең дә сандыгы. Шуңа күрә дусларым бар минем дип әйтергә күңел базмый. Якын иткән фикердәшләрем бар, Аллага шөкер. Табындашларым да аз түгел. Кешеләр арасында кешеләрчә яши беләмдер, ахрысы. Эш кешеләрен хөрмәт итәм, үзен шәхес дип санаганнарга якынаям. Кайчандыр дус булып йөреп тә, тормыш аерган замандашларымны онытмаска тырышам. Әйткәнемчә, бүген дустанә аралаша торган даирәм тарая

бара. Марсель Сәлимҗанов та вафат булды, Илдар Юзеев та юк инде, Шәүкәт Галиев белән дә сирәк очрашабыз, Альберт Яхинны да телефоннан гына ишетәм. Ләкин мин аларны һич онытмыйм. Гариф абый Ахуновны да сагынам. Әдәбият дөньясына кергәндә алар минем таянычым булдылар.

Бүген күбрәк үземнән яшьрәкләр белән аралашам. Разил Вәлиев, Марсель Галиев, Нәбирә Гыйматдинова… Алар белән миңа кызык.

Тормыш бит ул кызыклы нәрсә. Шагыйрьләр Роберт Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләмов белән мин, мәсәлән, бер табын артында кочаклашып утыра алмыйм. Ләкин талантлары өчен хөрмәт итәм. Синең белән дә шулай. Алда әйтелгән шагыйрьләр белән аналогия үткәрергә теләмим. Әмма без икебез ике холыктагы кеше. Синең белән җәелеп сөйләшеп утырган юк диярлек. Син һәрвакыт каядыр ашыгасың, Син безне каядыр үтеп барышлый гына күрәсең. Синең вакытың минутлап бүленгән. Җыелышларның, мәҗлесләрнең дә башында гына күренәсең дә югаласың. Син берәү белән дә якалашмыйсың, киеренке мөнәсәбәтләрне уратып үтә беләсең. Ә мин болганчык кеше. Син акыл белән яшәсәң, мин күбрәк хис белән яшим. Синең турыда төрле сүзләр дә ишеткәлим. Әмма мин сине хөрмәт итәм. Син — талантлы милләттәшем. Милләт мәсьәләсендә, әдәбиятка караштa безнең фикерләр һәрвакыт диярлек тәңгәл килә. Татарның талантлы баласын холык-фигыленә игътибар итмичә хөрмәт итәргә тиеш без.

Ә инде якын итмәгәннәргә килгәндә, алар турында сөйләп торасым килми. Бар андыйлар. Ясалма кешеләрне яратмыйм. Киеренке мөнәсәбәтләрдә әдәп кагыйдәсен онытып пычракта аунарга яратучыларны җенем сөйми. Үзен дөньяның кендеге дип санаучылар да миңа юлдаш түгел. Алар еш кына мине үртәп, мине бәхәскә тартып кертергә маташалар. Андыйлар белән бәхәскә кереп вакланмыйм. Мин аларны күрмим генә. Минем өчен алар юк бәндәләр. Читтән караганда, бәлки, баламут кебегрәк күренәмдер, әмма корсакка төртеп сөйләшә башласалар усалланам.

**Р.Ф.** *Менә мең елга бер туры килә торган (шөкер, ул безнең гомергә туры килде!) Казан юбилее да үтеп китте. Бу бәйрәм төрле кешедә төрле хис калдыргандыр. Әмма Казанның бу олуг юбилее тарихка гына күз төбәү түгел, киләчәк турында ныклап уйлану өчен бер җай да. Син Олы Мәрәтхуҗа улы булсаң да, Казан кешесе бит инде. Балалар белән, гомер белән шушы шәһәргә береккән. Казан—бөтендөнья татарларының карап торган мәркәзе. Киләчәк гасырларда да ул шулай булып калырмы?*

**Т.М.** Әлбәттә, Казан — безнең башкалабыз, мәркәзебез. Күзне төбәп карап торган үзәгебез. Аның тарихы да татар халкы тарихы. Дан тоткан, үзен якларга тырышкан, яклый алмаган, татарлыгын нык югалткан, тагын бер дәртләнеп селкенеп алган, янә дә сүрелә башлаган. 1000 ел дип ничә ел шаулыйбыз. Шулай кирәктер, зур юбилей бит. Әмма мин бүген ул бәйрәмне таралып, куанып бәйрәм итә алмыйм. Әллә ни булды минем белән, бәйрәмнәр кызык булмый башлады. Күбрәк уйландыра. Без үз-үзебезне юатыр өчендер инде, Болгар дәүләтен, Алтын Урданың бөеклеген еш искә алабыз. Билгеле, тарихны белергә кирәк. Әмма үткәннәр белән генә яшәү бәхетсезләр шөгыле. Кызык түгел. Рәсәйне мин Ватаным дип әйтә алмыйм инде. Мине кирәксенмәгән ил миңа Ватан була алмый. Республика, җөмһүрият дип тә горурланырлык сәбәпләр кими бара. Соңгылары бигрәк күңелне төшерде. Латинга кайтуны сузып-сузып килдек тә баш казыгы куйдык. Милли югары уку йорты дип сөйләндек, ул идеяне дә үтерделәр. Үземне мин алданган кеше итеп хис итәм. Мәскәүне гаеплибез, гел Мәскәү генә дә түгелдер инде. Көрәшергә теләмәгән үзе егыла. Хәерле булсын. Казаныбыз 1000 еллык «исконный урыс шәһәре» булып калмагае. Мәскәүнең ул юбилейны зурлап бәйрәм итүе дә шуңа ишарәли шикелле. Бүтән мәсьәләләрдә безне зурларга ашыкмый бит. Ләкин мин аппатиягә бирелмәскә тырышам. Шагыйребезнең «Кисмәк өстенә каракош иттифакый кунган ул» дигән өмет белән үземнең рухи халәтемне саклыйм.

**Р.Ф.** *Әдәбиятта, сәнгатьтә тәнкыйть дигән төшенчә бар. Төшенчә генә түгел, тәнкыйтьче дип аталып йөрүче һөнәри төркем бар. Алар үзләренчә хәрәкәттә: язалар, сөйлиләр, китаплар чыгаралар… Безнең турыда да—Синең белән минем иҗат турында диюем—байтак яздылар. Игътибарлары өчен рәхмәт, әлбәттә. Шулай да… Син үз иҗатыңда тәнкыйтьнең реаль тәэсирен, ягъни булышлыгын тойдыңмы? Гомумән, бүгенге көндә әдәби тәнкыйть Синеңчә нинди булырга тиеш?*

**Т.М.** Кайдан килеп керде икән татарга бу сүз? Үзенеке микән? Төп мәгънәсе нәрсәне аңлата икән: кемне дә булса салып таптауны, әллә үтереп мактауны? Бүген минем үземнең шәхсән тегесенә дә монысына да исем китми. Буласы, начармы-яхшымы—булган. Әдәби тәнкыйтьнең мин әйткән һәр ике формасы әдәби мохиткә яңа кереп баручыларга куркыныч. Иҗат кешесен таптап та, мактап та үтерергә мөмкин. Мисалларны Син дә, мин дә беләбез. Нинди генә булса да тәнкыйтьнең төбендә кешелеклелек ятарга тиештер. Тәнкыйтьнең оператив формасы бар. Ул рецензияләр рәвешендә языла. Моны мин реклама дип кенә кабул итәм.

Әдәби тәнкыйтьнең чын асылы—анализдыр. Әйтик, язучыны теге яки бу әсәрне язарга нинди сәбәпләр этәргән, максатына ирешә алганмы язучы, ирешә алмаса, ни комачаулаган, бүгенге җәмгыять күзлегеннән караганда әһәмиятлеме язылган әсәр, язучы үз фикерен ни дәрәҗәдә осталык белән әйтә алган. Гомумәдәби процесста үз урыны бармы әсәрнең һәм башкалар, һәм башкалар. Мондый тәнкыйть-анализ теләсә кемне уйландыра. Син язучылык хезмәтенең ничаклы җаваплы икәнен янә бер тоясың, ягъни үз эшеңә читтәнрәк карап бәя бирәсең. Бер кызыклы факт. Мин язган пьеса буенча куелган спектакльне карап утырам берзаман. *(Кайсы икәнен әйтмим.)* Шунда үзем дә сизмәстән онытылып китеп «болай язмыйлар!» дип кычкырып куйдым. Анализлы тәнкыйтьтән соң ул язучы «чыннан да болай язарга ярамый икән, төзәтергә кирәк» дип уйлансын яки үзенең «дөрес язганына» инансын иде.

**Р.Ф.** *Мәгълүм булганча, Татарстанда татарларның чиреге чамасы гына яши. Республикадан читтә яшәүче шул күпчелек кавем турында Син нәрсәләр уйлыйсың? Аларның күбесен милләтебез балалары санап без үз-үзебезне алдамыйбызмы? Байтагы үз телен оныткан, тарихи рухи тамырлар өзелгән… Аларны янә җыю мөмкинме? Мөмкин булса, нишләргә?*

**Т.М.** Безнең кыска гына әңгәмәдә бу турыда нидер әйтү бик авыр. Бигрәк тә «нишләргә?» дигән сорауга җавап эзләве катлаулы мәсьәлә. Мин аңа җавап та бирә алмамдыр, ахры. Татарның язмышыдыр инде ул сибелеп яшәү. Атилла бабаларыбыздан башлап Болгар, Алтын Урда дәүләтләренең чиге дә очсыз-кырыйсыз. Алтын Урдадан ничә ханлык кына бүленеп чыккан. Бүген татар кайда гына яшәсә дә, нигездә, үз җирендә яши—килмешәк түгел. Мин инде Америка, Финляндия, Австралия ише илләрдә гомер кичерүчеләрне әйтмим. Аларны язмыш җиле сипкән. Үз илеңдә генә төпләнеп яшәүгә канәгать булмыйча кая да булса бару борынгы бабаларыбыздан калган инстинкттыр, күрәсең. Менә шул татарны ничек татар итеп сакларга? Ничек бер идея тирәсенә тупларга? Безнең кебек үк Җир шарының бөтен почмагында диярлек яшәгән яһүд халкы моңа иреште. Аңа инде югалу куркынычы янамый. Глобализация турында күбрәк алар сөйләсә дә, алар бу эпидимиягә эләкмәячәк. Киресенчә, дөнья белән үзләре идарә итәргә җыеналар. Бәлки, безгә алар моделен кулланыргадыр? Заманында бит «Татар үткән җирдә яһүдигә эш юк» дигәннәр. Бу сыйфатыбыз безнең әле дә күпмедер дәрәҗәдә саклана дип уйлыйм. Кайда кем булып эшләсә дә, татар югалып калмый, җаен, хәйләсен таба. Ләкин, ни кызганыч, татарлыгын яһүд кебек саклап калырга хәйләсе җитми. Бигрәк тә урыска үзен «ашата». Яһүд марҗага өйләнсә дә, татарга кияүгә чыкса да яһүд туа, татардан—урыс туа. Югыйсә эчке тотрыклылыгы ягыннан урыс татардан көчсезрәк.

Без татар-башкорт мөнәсәбәтләрен куертып сөйләргә өйрәндек—татар башкортлаша дибез. Ә мин моңа әллә ни борчылмыйм. Татарның маңгаена башкорт дип язсаң да, ул башкорт була алмый. Ә башкорт бик тиз татарлаша һәм урыслаша. Бүгенге башкортларны шул хафага сала да инде. Мин аларның хәлен аңлыйм. Чуаш та, мари да була алмый татар. Инглиз, французга да әйләнмидер. Ә менә урыска әйләнә дә куя! Әллә соң урыс үзе дә татарга әйләндеме дип уйлап куям кайчакта. Бик тиз уртак тел табалар бит. Тел киртә булып тормый. Мин проблеманың сәяси ягына махсус кагылмадым. Чөнки Россия дигән илдә безне милләт буларак сакларга теләүче хакимият булмады һәм булмас та шикелле. Әлегә бездән «котылу» сәясәте көчәйгәннән-көчәя бара. Шушы шартларда саклану юлын табарга иде. Бу Татарстаннан читтә яшәүче татарларга гына кагылмый, бу — барыбыз өчен дә уртак проблема. Бездә «Берләшик!» дигән чакыру еш әйтелә. Шул берләшүнең тормышка ашыру юлларын табарга, һәр форсаттан файдаланырга иде. Иң мөһим бурычларыбыз, бүгенге көндә иң актуале, минемчә, Мәскәүнең безне төрле этник төркемнәргә бүлеп таркатуына каршы торудыр. Әгәр дә, без—Казан татары, без—мишәр, без—себер, әчтерхан татары, без—типтәр, без—керәшен дип сөйләнсәк, тиз арада беребезнең дә калмавы бик ихтимал. Башкортлар белән бәхәсне тирәнгә җибәрмәскә иде. Экстремизмга һичничек юл куярга ярамый. Аларның югарыда әйтелгән проблемасын безгә аңларга һәм аңлашырга кирәктер.

Бер куаныч—читтәге бик күп татарларыбыз Казанны үзләренең дә башкаласы дип саный. Шулай булгач, Казанны чыннан да бөтен татарларның кыйбласы дәрәҗәсендә тотарга иде. Татарның иҗтимагый фикере, мәдәнияте бары тик үзе таныган рухи башкаласында гына формалаша ала. Моны үзебез дә аңларга һәм бүтәннәргә дә аңлатып торырга тиешбез.

Бүген диннең йогынтысы көчәя бара. Мөселман татарлар да, керәшен татарлар да дингә милләт күзлегеннән дә карарга тиешләрдер. Төп динебез безнең ислам дине. Шул дин тирәсендә берләшкән хәлдә, үзебезнең гарәп тә, иранлы да түгеллегебезне онытмасак иде. Бүген мәчет-мәдрәсәләребезгә урыс теле кереп бара. Татар мәчетендә бөтен мөселманнарга уртак телдә—Коръән телендә булса, калган сөйләшүләр бары тик татарча гына булырга тиеш дип саныйм. Миңа, мәсәлән, керәшен татарларының үз чиркәүләре булуы ошый. Бер керәшен апасының «ярый әле үз чиркәвебез булды, урыска әйләнеп бетә язган идек» дигәнен мин еш искә алам. Без бит интернационализмны башкаларны олылап, үзебезне түбәнәйтү дип аңлый башладык.

**Р.Ф.** *Гадәттә әңгәмә ахырында бирелә торган традицион сорау: алдагы көннәргә нинди уй-планнар корып яшисең?*

**Т.М.** Бер җыр искә төште:

Агыйделнең аръягында
Күтәрелде томаннар.
Аерылырга түгел иде
Безнең корган планнар.

Әдәбияттан, театрдан аермасын иде Ходай. Яшьлектә язмасаң да, «кызыклар» күп. Урам тулы чибәр кызлар—кайсына сүз кушсаң да килешә, мәҗлесләрдә «Алмагачы» көенә дә сиптерәсең, дусларның хисабы юк, сәламәтлек—корычтай. Картайгач… Әйтеп тормыйм инде. Бердәнбер кызык—язудыр. Хәтта әдәбият белән кызыксынып карамаганнар да картайгач яза башлыйлар. Язу бит әле ул үз-үзең белән сөйләшү дә, чөнки сине үзеңнән башкалар тыңламый башлый. Кешеләр дә тыңлый алырлык әсәр язасы килә. Туктап булмастыр инде. Ул «чир» үзем белән бергә генә китәрдер. Әле менә дәртләнеп кино өчен сценарий язам. Рамил Төхфәтуллин «куябыз!» ди. Авызына бал да май. Тагынмы? Тагын да бар эшләр... Ходай гына күпсенә күрмәсен.

## ИСКӘРМӘЛӘР

### ЭЛГӘРГЕЛӘР, БҮГЕНГЕЛӘР

**Үлемсезлек символы.** — Г. Тукайның тууына 110 ел тулу уңае белән Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Мин Тукайга киләм» (1996) исемле җыентыкка (бу басмада Тукайга багышланган шигырьләр тупланган) кереш сүз итеп язылган. Мәкалә шулай ук «Казан утлары» (1996, 4 сан) журналында басылган.

**«... Булдым һич тә онытылмас кеше».** — Тукайның 100 еллыгын билгеләп үтүгә Татарстан җәмәгатьчелеге берничә ел алдан хәзерләнә башлады, һәм юбилей уңае белән республика хөкүмәте махсус карар да кабул итте. Мәкаләдә шушы олуг тантанага хәзерлек мәсьәләләре күтәрелә. Беренче мәртәбә «Тукай турында уйланулар» дигән исем белән «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан», 1983, 2 октябрь) газетасында басылган. Шулай ук шагыйрьнең «Җырларда — ил гаме» (1984) дигән мәкаләләр һәм публицистик язмалар китабында урын алган. Сүз уңаенда әйтеп узыйк: 1986 елның маенда Тукай-Кырлай авылында Тукайның 100 еллыгына багышлап үткәрелгән шигъри бәйрәмне Р. Фәйзуллин ачты һәм алып барды.

**Ә горурлык хисе һаман шул.** — М. Җәлилнең шәхесе һәм иҗаты Р. Фәйзуллинның дистәләгән шигырьләрендә һәм мәкаләләрендә чагылыш таба. Бу язма — төрле елларда (1968, 1976, 1980, 1996) язылган мәкалә-эсселарның җыелмасы. «Казан утлары» (1996, 2 сан) журналында басылган.

**Шагыйрь, поп һәм якташ.** — «Казан утлары» журналында (1998, 11 сан) басылган. Яков Емельяновның (1848—1893) 150 еллык юбилее республика матбугатында шактый киң билгеләп үтелде. Юбилей мөнәсәбәте уңаеннан шагыйрьнең туган ягында — Алан Полян һәм Котлы-Бөкәш авылларында әдәби-музыкаль кичәләр булып узды. 1999 елның 17 сентябрендә узган бу юбилей кичәләрендә Р.Фәйзуллин, Г.Рәхим (Г.Родионов), Ш.Мостафин, Ә.Сафиуллин; җырчылар Г.Ибушев, Л.Әхмәтова, һәм шулай ук Балык Бистәсе районы хакимияте башлыгы Р.Хәйруллин катнашты.

**Аның сазы төзек саз иде.** — 1992 елда олуг әдип, галим Нәкый Сираҗетдин улы Исәнбәт (Закиров) 93 яшендә вафат булды. Хушлашу сүзе булып язылган бу язма беренче мәртәбә басыла.

**Тынгысыз җанлы олы шагыйрь.** — Шагыйрь Х. Туфанның (1900—1981) 70 еллык юбилее уңаеннан «Яшь ленинчы» («Сабантуй», 1970, 9 декабрь) газетасында басылган. «Җырларда — ил гаме» (1984) китабына кергән.

**Ул киләчәккә атлый.** — Г. Кутуйның (1903–1945) 70 еллык юбилее уңаеннан язылган. «Яшь ленинчы» («Сабантуй», 1973, 1 декабрь) газетасында һәм «Җырларда — ил гаме» (1984) китабында басылган.

**Авылдаш.** — Истәлек рәвешендә язылган бу язма Равил Фәйзуллинның 1998 елда чыккан «Сайланма әсәрләр»енең IV томында басылган.

**Батмаска туган Баттал.** — Салих Вазыйх улы Батталның (1905—1995) 100 еллыгы уңаеннан «Казан утлары» журналында (2005, 8 сан) басылган.

**Вөҗданына тугры әдип.** — 1999 елны татар әдәбияты классигы, Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еникинең (1909—1999) 90 яшьлек юбилее уңаеннан «Казан утлары» журналы (1999, 3 сан) юбилярга махсус сәхифә багышлады. Ул сәхифәдә Ф.Хөсни, Н.Нәҗми, Р.Фәйзуллин, Ф.Миңнуллин, Р.Мостафин, Ә.Баяннарның истәлекләре, уй-фикерләре урнаштырылган иде. Томлыкка кергән текст шул журнал язмасы буенча бирелә. Күләме ягыннан әллә ни зур булмаган бу мәкалә шулай ук Ә.Еникинең «Мәгариф» нәшриятында 1999 елда чыккан «Мәк чәчәге» китабына (әдипнең үзе исән чакта чыккан соңгы китабы) кереш сүз булып та басылды.

**Олы шагыйрь, киңәшче шагыйрь.** — Шагыйрь С. Хәкимнең (1911—1986) 60 еллык юбилее уңае белән язылган. «Татарстан яшьләре» газетасында (1971, 4 декабрь) һәм «Җырларда — ил гаме» (1984) китабында басылган.

**Шагыйрь турында җитди хезмәт.** — Тәнкыйтьче Р. Мостафинның «Советская Россия» нәшриятында (1979) басылып чыккан «Сибгат Хаким» дигән китап-монографиясенә рецензия. «Казан утлары» (1980, 5 сан) журналында һәм «Җырларда — ил гаме» (1984) китабында басылган.

**Хикмәтле дә җыры, дәртле дә.** — Шагыйрь, тәрҗемәче Н. Арслановның (1912—1991) 60 еллык юбилее уңаеннан язылган. Иҗат портреты рәвешендәге бу күләмле мәкалә беренче мәртәбә «Казан утлары» (1972, 9 сан) журналында басыла, соңрак «Җырларда — ил гаме» (1984) китабында урын ала.

**Прометей утың сүнмәсен!** — Мәкалә Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәримнең (1919—2005) тууына 80 ел тулу уңаеннан язылган. «Казан утлары» журналында (1999, 10 сан) басылып чыккан.

**Халыкчан шагыйрь.** — Шагыйрь Г. Афзал (1921) иҗаты турында Р. Фәйзуллинның берничә мәкаләсе бар. Шул исәптән, шагыйрьнең «Сайланма әсәрләр» (1991) китабы да Р. Фәйзуллинның «Ак намусым күзен тутырып карап тора...» дип исемләнгән кереш сүзе белән чыккан. Томлыкка кергән бу күләмле мәкалә беренче тапкыр «Казан утлары» (1971, 5 сан) журналында, соңрак «Җырларда — ил гаме» (1984) китабында басыла.

**Хуш, халык шагыйре.** — 2003 елда Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзал (Афзалов Гамил Гыймазетдин улы) вафат булды. Шул сәбәптән язылган хушлашу сүзе.

**Егет әдип.** — Прозаик Г. Ахуновның (1925—2000) 60 еллык юбилее уңае белән рус телендә язылып, «Литературная Россия» (1985, 27 сентябрь) газетасында басылган. Мәкаләнең кыскартылган варианты шулай ук «Кызыл таң» (Уфа, 1995, 18 сентябрь) газетасында дөнья күрә.

**Зураеп калу.** — Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновның (1925—2000) вафаты мөнәсәбәте белән язылган хатирә-эссе. «Зураеп калу» (Гариф Ахунов ядкәре) исеме белән «Татарстан» (2000, 7 сан) журналында басылган.

**Үзбәк абый үз иде.** — Нефтьче галим һәм язучы Үзбәк Саттаров (1922—19...) истәлегенә язылган мәкалә. «Казан утлары» (2003, 3 сан) журналында басылган.

**«Һәркем җирдә бер бизәк...»** — Шагыйрь һәм прозаик К. Латыйпның (1927) 70 еллык юбилее уңае белән язылган һәм «Казан утлары» (1997, 6 сан) журналында басылган.

**Салмак уйлы хәким шагыйрь.** — Шагыйрь һәм тәрҗемәче Ш.Мәхмүдов (1928) (Шамил Анак) иҗаты турындагы бу мәкалә «Матурлык илчесе» исеме белән «Яшь ленинчы» («Сабантуй», 1979, 21 август) газетасында басылган.

**Тирәбездә яхшы кешеләр.** — «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан») газетасында басылган. Соңрак бу мәкалә исеме газетаның даими рубрика атамасы булып китә.

**Очрашулар.** — Драматург Ш. Хөсәенов (1929) турындагы бу мәкалә-эссе «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан», 1979, 2 декабрь) газетасында басылган, «Җырларда — ил гаме» (1984) китабына кертелгән.

**Өлкәнебез (Чал чәчле, яланаяклы)** — М. Шабаев (1933) — Р. Фәйзуллинның башлангыч иҗат юлында мәгълүм бер уңай роль уйнаган шагыйрь. «Чал чәчле, яланаяклы» — беренче тапкыр «Яшь ленинчы» («Сабантуй») газетасында басылган, соңрак «Җырларда — ил гаме» (1984) китабына кертелгән. Мәкаләнең «Өлкәнебез» дигән өлеше 2003 елны язылган һәм шул ук елны «Казан утлары»нда (8 сан) басылган.

**Яшәүгә ышаныч.** — «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан», 1983, 17 июль) газетасында басылган, соңрак «Җырларда — ил гаме» (1984) китабына кертелгән.

**Хәтер.** — Шагыйрь З. Насыйбуллинның (1937—1986) «Гамьнәр илендә» (1987) исемле китабына кереш сүз булып басылган. «Казан утлары» (1987, 2 сан) журналында чыккан.

**Җиңәргә яратылган.** — Мәкалә «Татарстан» журналында (1999, 11 сан) Ф.Яруллинның (1938) яңа шигырьләренә кереш итеп басылган.

**Бар шундый бер Батулла.** — Прозаик, драматург Роберт (Рабит) Батулла (1938) турындагы бу мәкалә «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан», 1998, 27 март) газетасында басылган.

**Тукайлар, Бабичлар юлыннан.** — Башкортстанның халык шагыйре Равил Бикбаевка (1938) 60 яшь тулу уңае белән язылган мәкалә. «Казан утлары» (1998, 11 сан) журналында басылган.

**Салмак, әмма саллы.** — Шагыйрь Ямаш Игәнәйнең (Анатолий Нестерович Малов, 1938—1997) «Игелекле төбәк» (1988) исемле китабына кереш сүз булып басылган.

**Якташ.** — Күпсанлы җырлар авторы, шагыйрь Мансур Шиһаповның 2005 елда чыккан «Җырлыйсы җырларым бар әле» китабына кереш сүз итеп бирелгән.

**Нечкә хисле, батыр йөрәкле.** — Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның (1941—1995) шәхесе һәм иҗаты турында. Мәкалә «Казан утлары» (2001, 4 сан) журналында басылган.

**Әйдәүче.** — Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Тәүфикъ Әйди (Әйдельдинов Тәүфикъ Рамазан улы, 1941—2001) иҗатына багышланган хезмәт. Т.Әйдинең күптомлыкларына кереш сүз итеп басылган.

**Яна-яна иҗат итә.** — Әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлимнең (Хәлимов Айдар (Борис) Нәҗметдин улы (1942) 60 еллыгы уңаеннан язылган мәкалә. («Татарстан», 2002, сан) журналы.

**Заманга иш иҗат.** — Шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Ренат Хариска (1941) 60 яшь тулу уңае белән язылган мәкалә. «Казан утлары»(2001, 5 сан) журналында басылган.

**Нурлы һәм моңлы шигырьләр.** — Шагыйрь Гәрәй Рәхимнең (Григорий Васильевич Родионов) (1941) «Моңнарым» исемле китабына кереш сүз. «Татарстан яшьләре» (1980, 2 октябрь) газетасында һәм «Җырларда — ил гаме» (1984) китабында басылган.

**«Мәхәббәткә — мәрхәмәт».** — Шагыйрь Р. Гаташның (1941) «Шигырь китапханәсе» сериясендә чыккан «Мәхәббәткә — мәрхәмәт» китабына рецензия. «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан», 1984, 4 октябрь) газетасында басылган.

**Замана язучысы.** — Мирхәйдәров Рауль Мирсәет улы (1941) — Мәскәүдә яши һәм рус телендә иҗат итә. Күп кенә романнар, повестьлар авторы. Әсәрләре кат-кат басылып, миллионлаган данәләрдә дөнья буйлап таралган. «Казан утлары» (2000, 8— 10 саннар) журналы аның «Иртәләгән сагыш» («Ранняя печаль») дигән романын татарчага тәрҗемә итеп чыгарды. Р.Фәйзуллинның бу мәкаләсе әлеге роман чыгу уңае белән язылган һәм шул ук журналда (2000, 8 сан) басылган.

**Розалина — гөлсукмак.** — Шагыйрә һәм сәнгать белгече Р. Шаһиеваның (1945) «Кара мәрҗән» (1977) дип исемләнгән беренче шигырь китабына кереш сүз. Шулай ук «Казан утлары» (1998, 4 сан) журналында да басылган.

**Туңма, туган!** — Шагыйрь М. Әгъләмовның (1946) 50 еллык юбилее уңае белән язылган. «Мәдәни җомга» (1996, 22 ноябрь) газетасында басылган.

**Чатыртау — биек тау.** — Шушы исем астында томлыкта урын алган бу мәкалә ике өлештән тора: аның беренче өлеше «Кешелекле матурлык өчен» дигән исем белән М. Галиевнең «Еллар чалымы» (1978) китабына кереш сүз буларак дөнья күргән, икенчесе — «Бергә-бергә үскәндә» дип аталып, М.Галиевнең 50 еллык юбилее уңаеннан «Татарстан яшьләре» (1996, 15 октябрь) газетасында басылып чыккан.

**Болай гына гади күренә ул.** — Бу мәкалә дә ике өлештән тора: беренчесе — шагыйрьнең «Җир китабы» исемле китабына рецензия, һәм ул «Татарстан яшьләре» (1989, 14 гыйнвар) газетасында басылып чыга; икенчесе — «Казан утлары» (1996, 1 сан) журналында шагыйрьнең шигырьләр циклына кереш мәкалә буларак урын алган.

**Яну йөрәктән башлана.** — 1987 елда «Казан утлары» журналының 10 санында шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Зиннур Мансуровның (Мансур Зиннур Мөҗип улы, 1949) Хәйретдин Мөҗәйгә багышланган «Балкыш» исемле поэмасы басылып чыкты. Мәкалә шул поэмага рецензия рәвешендә язылган («Социалистик Татарстан», 1988, 13 гыйнвар).

**«Барысы нибарысы килешә».** — Тәнкыйтьче һәм шагыйрь Ф. Зөлкарнәйнең (1951—1997) «Идел» (1996, 2 сан) журналында басылган шигырьләренә кереш сүз.

**Кайту.** — Әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Мөдәррис Вәлиев (1953) турындагы бу язма «Казан утлары» (1998, 8 сан) журналында аның шигырьләр циклына кереш мәкалә буларак басылган.

**«Чыныга тор...»** — Азнакай районында яшәп иҗат итүче, шагыйрә Фәйрүзә Исмәгыйлованың (1963) Татарстан китап нәшриятында (1999) «Җанымда яз рәсеме» дигән беренче китабы чыга. Шагыйрә турындагы бу мәкалә әнә шул китапка кереш сүз итеп язылган. Язманың беренчел нөсхәсе шулай ук «Казан утлары» (1999, 9 сан) журналында да дөнья күрә.

**Чикле чиксезлек.** — Шагыйрь Рәмис Аймәт (Аймәтов Рәмис Кыям улы, 1968) иҗаты турында уйланулар рәвешендә язылган бу мәкалә «Казан утлары» (2004, 2 сан) журналында чыкты. Шул ук язма Р.Аймәтнең «Чикле чиксезлек» исемле шигырь китабында кереш сүз итеп басылды. («Чикле чиксезлек». «Мәгариф» нәшр., 5—9 б.)

**КИТАП БУЛЫР ГҮРГӘЧӘ...**

**Китап гасыры китәме?** — «Казан утлары» (2000, 1 сан) журналында басылган.

**Сез китаплар җыясызмы?** — «Яшь ленинчы» («Сабантуй») (1970, 17 гыйнвар) газетасында басылган, «Җырларда — ил гаме» (1984) китабына кертелгән.

**Китап — без ул.** — Атналык «Мәдәни җомга» (1998, 5 июль) газетасында «Шигырь — әдәбиятның Әнкәсе» дигән исем белән басылган.

**Бәйрәм китергән китап.** — 1980 елда Татарстан китап нәшрияты «Татар балалар поэзиясе антологиясе»н чыгара. Бу хезмәт әнә шул әдәби-мәдәни вакыйга уңае белән язылган «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан») (1981, 15 март) газетасында басылган.

**Сандугач кына димәссең...** — Драматург Туфан Миңнуллин тарафыннан төзелгән «Сандугачым-былбылым» дигән сувенир китапка рецензия. «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан») (1985, 28 июль) газетасында басылган.

**Бердәм булыйк!** — «Татарстан яшьләре» газетасының чыга башлавына 70 ел тулу уңае белән язылган мәкалә. «Гали мәдәни мәдрәсә» исеме белән шул газетада (1990, 16 гыйнвар) басылган.

**Рәхмәт әйтер чак.** — 1984 елда «Яшь ленинчы» («Сабантуй») газетасы чыга башлавына 60 ел тула. Юбилей уңае белән язылган бу мәкалә шул ук газетада (1984, 6 октябрь) басылган.

**«Идел»гә ун яшь!** — Совет дәверендә татар җәмәгатьчелеге ярты гасыр чамасы яшьләр журналы булдыру хәстәрендә булды. Мәскәү хакимиятеннән рөхсәт алу өчен берничә буын татар язучысы көрәште. Ниһаять, 1989 елның июлендә «Идел» журналының 1 саны дөнья күрде. Шул уңай белән шагыйрьнең шатлык хисләрен белдереп язган кечкенә күләмле язмасы («Идел», 1989, 1 сан) чыккан иде. Бу томлыкка кергән язма әлеге журналның ун еллыгы уңае белән басылган («Идел», 1999, 6 сан).

**Балалар матбугаты һәм без.** — Шагыйрьнең «Җырларда — ил гаме» (1984) китабында басылган.

**Бөек төркилектә без олуг.** — 1999 елда «Мәгариф» нәшрияты «Хәзинә» сериясеннән «Ул дәрья да бу дәрья» исемендә борынгы әдәбият җәүһәрләре (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Колшәриф шигырьләре, Мөхәммәдъярның «Нуры содур» һ.б.) тупланган хрестоматик характердагы китап чыгарды. Бу мәкалә шул җыентыкта кереш сүз итеп бирелгән. Бу томлыкка кергән тулырак вариант «Казан утлары» (2000, 9 сан) журналында басылган.

**Чын аңлашу — китаплар аша.** — Авторның бу рецензия-мәкаләләр циклына өстәмә исем итеп — «Каләмдәшләрнең яңа әсәрләрен укыганда туган уйлар» дип тә куелган. Илле елга якын иҗат дәверендә Р.Фәйзуллин Татарстан китап нәшриятында чыккан йөзләгән китапларга рецензия-бәяләмә язган әдип. Алар беркайда да басылмаган. Бу томлыкка әнә шул рецензияләрнең берничәсе (И.Юзеев, Н.Нәҗми, Р.Мингалим, З.Мансуров, Р.Хисмәтулла китаплары турында) кертелә.

**Янә Мәхәббәтнамә.** — Татарстан китап нәшрияты 2003 елда Равил Фәйзуллинның «Мәхәббәтнамә» дип исемләнгән китабын бастырып чыгарды. Эссе-уйлану рәвешендә язылган бу хезмәт әлеге китапта кереш сүз буларак урын алган.

**ӘҢГӘМӘЛӘР**

**«Аңлаешлы һәм аңлаешсыз» шигырьләр яки поэзиянең гражданлык йөзе.** — 60—70 нче елларда вакытлы матбугатта, шул исәптән «Казан утлары» журналында да хәзерге татар поэзиясенең үзенчәлекләре турында бәхәсләр еш булып тора. Шагыйрь һәм галим әңгәмәсе журнал редакциясе тәкъдиме белән булган бәхәсләргә беркадәр йомгак ясау ниятеннән языла һәм бу уртак хезмәт. «Казан утлары»нда (1978, 3 сан) басылып та чыга. Соңрак «Җырларда — ил гаме» (1984) китабына да кертелә.

**«Ватан була бер генә!..»** — 90 нчы еллар башында «Идел» журналы республикабызның күренекле шәхесләре белән «7 сорау» дигән рубрикада әңгәмәләр оештырган иде. Бу язма — шуларның берсе. Р.Фәйзуллин — Татарстан Югары Советы (XI чакырылыш) депутаты һәм «Казан утлары» журналының баш мөхәррире буларак, «Идел» журналы хезмәткәре, шагыйрь Г.Морат сорауларына җаваплар бирә. Чыгыш татар һәм рус телләрендә («Идел», 1990, 9 сан) басылган.

**Бер муенга ике камыт.** — Журналист Ф.Хуҗиәхмәт белән әңгәмә рәвешендә бирелгән бу язма «Социалистик Татарстан» (1990, 24 август) газетасында басылган.

**«Дошманым минем — Вакыт».** — Журналист Илдус Фазлетдиновның Равил Фәйзуллин белән әңгәмә-интервьюсы. Уфада татар телендә чыга торган яшьләр журналы «Тулпар»да (1996, 3 сан) басылган.

**Шаш Рухым, дуласын Җан...** — 1998 елның гыйнварында «Сөембикә» журналы шагыйрь һәм шагыйрәләрне (Р.Фәйзуллин, И.Юзеев, Л.Шагыйрьҗан, Ф.Гыйззәтуллина, Р.Баубекова (Кожевникова) һ.б. җыеп татар әдәбияты һәм поэзиясенең киләчәге турында сөйләшү уздырды. Бу мәкалә — шагыйрьнең шул кичәдәге чыгышы. «Сөембикә» (1998, 3 сан) журналында басылган.

**«Мин күкәйдән үзем чыктым!»** — дип әйткән ди бер чебеш... — Журналист Саимә Ибраһимованың Равил Фәйзуллин белән интервьюсы. Әңгәмә. «Сөембикә» журналында (2003, 8 сан) басылган.

**«Ышаныч зур, хыял көчле иде!..»** — Р.Юныснең Равил Фәйзуллин белән әңгәмәсе. Шагыйрьнең 60 еллык юбилее уңаеннан үткәрелгән күләмле бу интервью «Идел» (2003, 8 сан) журналында басылган.

**«Заманга иш булыйм дисәң...»** — 2000 еллардан башлап шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев Татарстан телевидениесендә татарның күренекле шәхесләре белән «Утырып уйлар уйладым» дигән баш астында әңгәмәләр үткәреп килә. Томлыкка кергән бу мәкаләнең нигезе — шул циклдагы телевизион тапшыруда Равил Фәйзуллин белән әңгәмәләшү. Әңгәмә «Мәдәни җомга» (2005, 4 февраль) атналык газетада басылган.

**Халык аны Улы диеп атый.** — Шагыйрь белән әңгәмә. «Юлдаш» (2005, 14 сан) газетасы.

**«Таяныч ул — халык...»** — Равил Фәйзуллинның Туфан Миңнуллин белән әңгәмәсе. Әңгәмә күренекле драматург һәм җәмәгать эшлеклесе Т.Миңнуллинның тууына 70 ел тулу уңаеннан «Казан утлары» (2005, 9 сан) журналында басылган.

# ЭЧТӘЛЕК

## Элгәргеләр, бүгенгеләр

Үлемсезлек символы
«...Булдым һич тә онытылмас кеше»
Ә горурлык хисе һаман шул...
Шагыйрь, поп һәм якташ
Аның сазы төзек саз иде...
Тынгысыз җанлы олы шагыйрь
Ул киләчәккә атлый
Авылдаш
Батмаска туган Баттал
Вөҗданына тугры әдип
Олы шагыйрь, киңәшче шагыйрь
Шагыйрь турында җитди хезмәт
Хикмәтле дә җыры, дәртле дә
Прометей утың сүнмәсен!
Халыкчан шагыйрь
Хуш, Халык шагыйре!
Үзбәк абый үз иде...
Егет әдип
Зураеп калу
«Һәркем җирдә бер бизәк...»
Салмак уйлы хәким шагыйрь
Тирәбездә яхшы кешеләр
Очрашулар
Атылган йолдыз кебек...
Өлкәнебез
Яшәүгә ышаныч
Хәтер
Җиңәргә яратылган
Бар шундый бер Батулла...
Тукайлар, Бабичлар юлыннын
Салмак, әмма саллы
Якташым ул минем
Нечкә хисле, батыр йөрәкле
Әйдәүче
Яна-яна иҗат итә
Заманга иш иҗат
Нурлы һәм моңлы шигырьләр
«Мәхәббәткә — мәрхәмәт»
Замана язучысы
Розалина — гөлсукмак...
Туңма, туган!
Чатыртау — биек тау...
Болай гына гади күренә ул...
Яну йөрәктән башлана
«Барысы нибарысы килешә!»
Кайту
«Чыныга тор...»
«Чикле чиксезлек»

## Китап булыр гүргәчә...

Китап гасыры китәме?
Сез китаплар җыясызмы?
Китап — без ул
Бәйрәм китергән китап
Сандугач кына димәссең
Бердәм булыйк!
Рәхмәт әйтер чак
«Идел»гә ун яшь!
Балалар матбугаты һәм без
Бөек төркилектә без олуг
Чын аңлашу — китаплар аша
Янә Мәхәббәтнамә

## Әңгәмәләр

«Аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр яки поэзиянең

гражданлык йөзе
«Ватан була бер генә!..»
Бер муенга ике камыт
«Дошманым минем — вакыт...»
«Шаш, Рухым, — дуласын җан!»
«Мин күкәйдән үзем чыктым!» — дип әйткән ди бер чебеш...
«Ышаныч зур, хыял көчле иде…»
«Заманга иш булыйм дисәң…»
Халык аны Улы дип атый!
«Таяныч ул — халык...»

**Искәрмәләр**

Литературно-художественное издание

***Файзуллин** Равиль Абдрахманович*

Избранные произведения

В шести томах

Том 5

Казань. Татарское книжное издательство. 2005

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Фәйзуллин** Равил Габдрахманович*

Сайланма әсәрләр

Алты томда

5 том

Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, Л.З.Шиһапова, Р.Н.Шакирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 6.12.2005. Форматы 84г108 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе.
«Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 24,36 + форз. 0,21.
Шартлы буяу-оттиск 25,10. Нәшер-хисап табагы 24,32 + форз. 0,36.
Тиражы 3000 д. Заказ А-885.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.